ISSN 0206-4189

# Казан утлары

6.2004



# Tatarstan Respublikası Prezidentı
# UKAZI

## 2004 yılğı Ğ. Tuqay isemendəge Tatarstan Respublikası Dəwlət premiəsen birü turında



Ğ. Tuqay isemendəge Tatarstan Respublikası Dəwlət premiələre komitetı təqdimnəren qarap, **qarar birəm:**

2004 yılğı Ğ. Tuqay isemendəge Tatarstan Respublikası Dəwlət premiəsen yazuçı **Mirğazian Zakir ulı Yunısovqa** 2002 yılda Tatarstan kitap nəşriatında nəşer itelgən "Al'batros yazmışı" digən kitabı øçen birergə.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV.**

Kazan, Kreml', 23 aprel', 2004 yıl.

# Казан утлары
# Qazan utları

2004

# 6

**(980)**

## ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Ихтыяр Гаязов, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркатип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru

# Казан утлары

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ
1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН.Яңа шигырьләр. .......... 5
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. Роман. .......... 12
Рәмис АЙМӘТ. Чикле чиксезлектә. Шигырьләр. .......... 76
Кыям МИҢЛЕБАЕВ. Акыллы атын мактар... Романнан өзек. .......... 80

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Гөлнур КОРБАНОВА. Чишмә сулары салкын шул... Шигырьләр .......... 128
Гөлнара ҖӘЛИЛОВА. Җиргә бәхет өчен тудым мин. Шигырьләр. .......... 130
Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Ә җил исә һаман исә. Шигырьләр. .......... 132

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Күңел кемне көтә? .......... 134
Нурулла ГАРИФ. Акланачак өмет. .......... 141

**ФӘН**

Гаяз ИСХАКЫЙ. Ислам мәмләкәтләрендә. .......... 145
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .......... 158

**ХӘТЕР**

Бикә РӘХИМОВА. Ул беренче иде. .......... 163

**ХӘМИТ ЯРМИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Фатих УРМАНЧЕ. Ярми традицияләре дәвам итә. .......... 170

Коръән татар телендә. .......... 176

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Дамир ГАРИФУЛЛИН. Татар күрке – Сабантуй. .......... 178

Хатлардан юллар. .......... 181
"Казан утлары" архивыннан. .......... 184
Берлекнең яңа әгъзалары. .......... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .......... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Ф. САДРИЕВА "Счастье несчастных" (окончание); отрывки из романа К. МИННИБАЕВА "Мудрый похвалит коня"(окончание);
стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА; Р. АЙМЕТА.
"Творчество молодых": стихи Г. КУРБАНОВОЙ; Г. ЯЛИЛОВОЙ;
Л. ГИБАДУЛЛИНОЙ.
"Дискуссия "Герой нашего времени": М.ВАЛИЕВ. "По ком тоскует душа?";
Н. ГАРИФ. "С надеждой на будущее".
"Наука": Г. ИСХАКИ."В исламских странах"; А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"Память": Б. РАХИМОВА. "Он был первым".
"К 100-летию Х. Ярми": Ф. УРМАНЧЕ. "Продолжаются традиции Ярми".
Коран на татарском языке.
"Книжное обозрение": Д. ГАРИФУЛЛИН. "Сабантуй—яркий праздник татар".
Строки из писем.
Из фотоархива журнала.
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Русалки"—работа художника А. ИЛЬЯСОВОЙ;
поэтесса А. ЮНУСОВА.

## IN THIS ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": F. SADRIEV'S novel "Happiness of the unfortunate" (ending); fragments from K. MINNIBAEV'S novel "The wise will praise a horse" (ending);
Verses by R. FAJZULLIN; R. AJMET.
"Creativity of the young": Verses by G. KURBANOVA; G. JALILOVA; L. GIBADULLINA
"Discussion" Hero of our time ": M. VALIEV. "After whom a soul is grieving?";
N. GARIF. "With hope for the future"
"Science": G. ISKHAKI. "In Islamic countries"; A. TIMERGALIN. "Dictionary of the nation".
"Memory": B. RAKHIMOVA. "He was the first".
"To H. Jarmi"s 100-anniversary": F. URMANCHE . "Traditions of Jarmi Proceed".
Al Quran in the Tatar language.
"Book review": D. GARIFULLIN. "Sabantui—bright holiday of Tatars"
Extracts from letters.
From a photo-archive of magazine.
New members of the Union of writers.
Diary of public—cultural life.
On our covers: "Mermaids" work of artist A. ILJASOVA;
Poetess A. JUNUSOVA.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контрол бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 17.05.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8114. Заказ Э—353
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.



## Равил Фәйзуллин

## ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Иҗат

I

Чибәрлек биреп сынады,
саулык биреп сынады...
Дөнья малын өеп биреп,
байлык белән сынады.
Дәрәҗәләргә менгезеп,
дуслар белән сынады...
Яраткан бәндәсе булып,
тәртипле яшәде Кеше,
сынауларда сынмады...

Разый булып әйтте Тәңре:
"Рәхмәтле җан!—чыдады.
Соң кат сынап, Иҗат утын
салып карыйм җанына?
Сынатмаса, изге булып,
иңәр, бәлки, яныма?
Әйдә, иҗат итеп кара!—
илһамлан иманыңда!"

II

"Чү, ни булды? Йә, бу нәрсә?
Нишлисең син, әй Кешем?
Дәһрилек бар кылганыңда,
мантыйкка сыймый эшең!
"Кеше—бөек! Кеше—даһи!
Эше мәңгелек!" имеш.
Ничек телләрең әйләнә
ихтыярсыз кол килеш?
Нишләвең бу? Әллә инде
Асылыңны оныттың?

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943) — *Татарстанның халык шагыйре; биш томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

"Мин—Табигать таҗы!" дигән
вәсвәсәгә юлыктың?"

III

...Ә ул шашып иҗат итә!
Илһам дигән очкын төшеп,
бар вөҗүден ут алган!
Хөр фикерләр ташкыныннан
чикләр-бикләр югалган!
Нәрсә даулый? Ни дәлилли?
Нәрсә расламак була?..
Яза, сыза, шигырь көйли,
шигарь белән эндәшә,
мәйданнарда кешеләргә
сүздән ялкын өләшә!
Әйткәненнән—бүтәннәргә
нурлар иңә бөркелеп.
"Кеше җаны мәңгелек!
Иҗат рухы мәңгелек!"
Ә ул ярсып иҗат итә
бер егълап, бер көлеп.

Әллә тиле? Әллә иблис?
Әллә шагыйрь? Әллә кем?..
Вә ләкин...

IV

Әйтте Тәңре: "Ялгыштым шул,
хәзер менә бел инде!
Иҗат утында дөрләгән
бу бәндәне күр инде!
Бөек Канунга карышып,
үз хөкемен үзе язган
Аллага әверелде!
Тәүбәгә килә алырлык
акыл да җыя алмый.
Үз-үзенә мәдхия укып,
Мәңгелеккә дәгъвалый!
Мин аны чын Адәм заты
итмәкче идем, бакчы!—
иҗат итеп, Дөньялыкта
бакый булып калмакчы!

Әй, Адәм!
Ни чәчсәң—шуны урырсың,
өлешең калмас миннән.
"Сөю көчле иманнан!"—
дигәнең өчен дә тиеш
әҗер сиңа, бүгеннән!
Әкренләп чирләр биреп,
"картлык" дигән "шифа" биреп,
Вакытта элеп киптерәм!—
Кануннардан чыккан өчен..."

V

...Утыра ул. Бөкре. Карт.
Тире, сөяк, күз генә...
Бу кайсы заман икәнен
әйтә алмас сүз генә...

"Заман кемнең заманы"мы?
Булган аның заманы!
Ничек заманы булмасын—
үзгәртә алгач ил аңын!
Хезмәте—данга уралган,
яшәве—алкышланган.
Сөйгән, сөелгән, янган...
Алыр тиешен алган.
Тик менә... саулык кына...
Күз яшен сөртеп торырга
кулында яулык кына...

VI

Әйтте Тәңре:
"Тынычландыңмы?
Җиттеңме инде чигеңә?
Өмет тоткан идең бугай
Тәкъдиреңне җиңәргә...
Адәм затлар, белегез, сез—
Вакыт дигән богауда.
Сезнең язмыш—сәҗдә кылып,
күнеп яшәү дөньяда!"

V

Таңга каршы яшь бер егет
җыр яза илһамланып!
Хисләре нечкә булса да,
сизә үзен, гүя—Алып.
"Бөек җыр тудырдым!— ди ул.
Мондый җырсыз моңа кадәр
кешеләр ничек торган?.."
Әйтерсең, җирдә тәүге кат
Мәхәббәт яратыла!

...Кем бу егет? Түгелме соң
әлеге картның яшь чагы?!
Рухының шашынган чагы,
хисләренең яз чагы?!

Илһамда янган һәр кеше
иҗатчы санала ала.
Юккамы патшалар, көнләп,
Шагыйрьгә каныгалар!..

Сүзләрдән һәйкәл коямы,
көй чыгарамы—сайлап
авазларның яңасын,
салкын ташларны терелтеп,
эвәлиме яңа сын,
Иҗат итү—
Кешенең бөек халәте!—
Рухының тантанасы!
Җанының тантанасы!

Тарих таный—иҗатына
җаннарын салганнарны,
максат-идеалы өчен
фидаи янганнарны,
үзләренчә үзгә дөнья
тудыра алганнарны!

**Тән-кабыгыннан котылгач,**
**җан кая китә дисез?**
**Иҗатта кала. Шуңа да,**
**Кеше җаны белән бергә**
**Бөек Иҗат үлемсез!**
**Бөек Сәнгать үлемсез!**

VI

**Тәңредән килгәнме бу өн?**
**Искәртә, әллә яный?**
**"Без яраткан Дөньядан тыш,**
**бүтән дөнья була алмый!**
**Була**
**алмый!"**

---

**Бер яшь егет шигырь яза!**
**Күңелендә—мәңге яшәү,**
**йөзләрендә таң нуры!**

## Саклыйк Республиканы!

Н. Фәттахның "Васыять" язмасы уңаеннан

*Диоген дигән бер мәшһүр*
*мичкәдә яшәгән, ди...*
*Егерме беренче гасыр бу*
*милади исәп белән...*
*Мин әле туган халкымны*
*исән-сау диеп беләм!*
*"Сызгыра торган уклар"ның*
*тавышы колагымда!*

**Атлантида калкып чыгып,**
**күтәрсен иде Аңны!**
**Күңелдә йөргән Дәүләт бар—**
**саклыйк Республиканы!**

**Губернияләп, гөбердәтеп,**
**таркатырга татарны.**
**Ак Патшаларның хыялы!..**
**саклыйк Республиканы!**

**Онытмыйк, заман бае,**
**кайдан килеп чыкканны!**
**Илгә зәкят-өлеш чыгар,**
**саклыйк Республиканы!**

**Демократмы, коммунистмы,**
**уңмы, сулмы, уртамы—**
**кирәк чакта берләшик,**
**саклыйк Республиканы!**

**"Бәхет Илендә яшим" дип,**
**васыять итмим мин аны...**
**Кем булсак та, җәптәш булыйк,**
**саклыйк Республиканы!**

**Беләм, күпләр сүгенә бүген—**
**"атаңны да, анаңны"...**
**Соңрак, бәлки, аңлашырбыз,—**
**саклыйк Республиканы!**

**Җөмһүрият!— дип, чын ирләрнең**
**күп акты шәһит каны!..**
**Respublika—бөек исем—**
**саклыйк Республиканы!**

**Алыштыручылар булса,**
**телне, җырны, иманны,—**
**үзләрен "җен алыштырсын",**
**саклыйк Республиканы!**

**Татар кайда яшәсә дә,**
**Казан—аның бакканы...**
**Өзмик кардәшләр өметен—**
**саклыйк Республиканы!**

**...Тарихка тирән кергәннең**
**тарихта калсын җаны.**
**Наивҗанлык чоры түгел—**
**саклыйк Республиканы!**

# ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

## Гомерем көзендә

Сабантуйга барган күңел белән
кайткандагы кәеф бер түгел.

...Шәфәкъ чакта таңлы куанычым:
нәни улым—өмет бөртеге.

***

Ата-анадан
яр якын...

...Күпме кала
Ил хакы?

***

Ботарлаша ике кош күктә.
Берсе—догаң, берсе—каргышың?

Соң теләгең ниләр булгандыр?—
Каурыйлары коела башыма.

## Кем белә

Офыкта торган болыттан
нинди яшен туасын?

...Беркөн килеп Илбашың
Ил ахыры булмасын!..

***

Укылмаган китапларда
бөек хикмәт ничаклы!

Пародокс: кайчакны
ипи эзли пычакны!

***

Авгейныкымы, бүтәнме—
абзарлар көрәп йөреш,
Яңа гасыр укучысын
шәм тотып эзләп йөреш!..

***

Икәү бер сулышны бүлербез дип,
кавышкан иделәр бер таңда!

...Судта сулышлары кабып (бер булып!..),
бер бүлмәле фатир бүләләр...

## Киңәш бирәләр...

Аптырама эт-көчеккә!
Тешләсә дә үчекмә!

Геракл, сабыйлык белән (!)
елан буган бишектә...

## Начар хәл

Дөньяда начар нәрсә бик күп.
Начар уйдан да начары юк!
Белә торып, сиңа юлыктым.
Шунсы начар: качар чарам юк...

## Картлык

Таулар сөзәкләнгән иде...
янә текәләнде!

...Тигез җирдән баруың да—
бары мүкәләвең.

## Чукынырга ашыгучыга

Алдан ук төртенмә!
Күрмиләр... Саналмый.

...Сасуы җитмичә
иттә корт яралмый.

***

*Безнең картлык туры килде*
*Ил каны бозык чакка.*

Медальләр-орденнар түшенә сыймыйлар...
Тик... хәл юк йөртергә. Карт авыр көрсенә...

Булса да тирәндә ягылган учаклар,
тик барып җылына алмассың берсендә...

***

Табигать Җир ямен җәйгә генә бирә.
Хөкүмәт акчаны чәйгә генә бирә.

Кешеләргә күпме байлык калдырсаң да,
алар сиңа кәфен-җәймә генә бирә.

## Шулай да була...

Хикмәт сые бездән булды.
Кабул кылу—сездән булды.
Кайтавазы—гайбәт сүзе—
тездән булды...

## Әфьюнләнү

*Мәк-киндерен күреп үстек.*
*Берәү дә тилермәде...*

*Безнең өчен кызлар иде—*
*тиле шатлык чәчәкләре.*

Күпме халык Чәчәк җанын алып,
үз җаннарын сата Иблискә!

Кеше-Чәчәк. Табигатьтә кайсы
ия булып чыга чын көчкә?

## Бер дә юкка утырып чыккан берәү сүзе

*Калмады бер хатам да,*
*Калмады чабатам да!*

Анда бер төсле бурлар.
Монда бер төсле бурлар...
Яшәсен барсын көйләгән
судья-прокурорлар!

***

Салават күпере—
Пәйгамбәр кушагы.

Җирдәге җәннәтем—
Сөйгәнем кочагы.

***

Террор-суеш—көнгә җәрәхәт.
Фәхишәлек—рухи һәлакәт.
Оят җәяүләп качкан шул илдә
Ничек була алсын бәрәкәт.

***

Алдагысын беркем белми,
алдагысы—Аллада.

...Кочак хәсрәт, кушуч сөенеч
бардыр, шөкер, алда да.

**Фоат
Садриев**

# БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН

10

Ирек кайчан, ничек аңына килгәнен дә хәтерләмәде. "Менә мин яшәүнең соңгы чигенә килеп җиттем,—дип уйлады.—Әгәр эчмәгән булсам, ишекне бикләр идем, беркем дә кермәс иде."

Күрәсең, ул күпмедер карышкан, күкрәге, умрау сөяге сызлый. Ирек караватыннан шуып диярлек төште, утны кабызды. Өйдә бөтен әйбер тузгытып ташланган—йөрерлек тә түгел иде. Ул өй алдына чыкты, утны яндырды. Анда да шундый ук тәртипсезлек, тузган әйберләр аунап ята. Ишекне ачып, тышка чыкмакчы булды, ләкин аны кыймшата алмады. Ул кабат өйгә керде, тәрәзәне ачып карагач, ишеккә сөялгән юан имәнне күрде. Димәк, болар я ике, я өч кеше булганнар. Кеше юанлыгы, өч метрдан озын бу имәнне шунсыз кузгату мөмкин түгел.

Тәрәзә борыныгыча бер ягы гына шудырып ачыла торган итеп эшләнгән иде. Бик тырышса, кырын ятып, Ирек бәлки аннан чыга да алган булыр иде, ләкин әлегә ул моның хаҗәтен күрмәде. Бер чүмеч су эчте дә урынына барып ятты.

Күпме яткандыр, сәер музыка ишетеп, ул күзләрен ачты. Өй эче яшен утыдай яктылык белән тулды. Ирек каршысында көмеш киемле, көмеш чәчле, көмеш йөзле ике кеше басып торганын күрде. "Мин төш күрәм, үзем язган повестьтагы кешеләрне күрәм", дип уйлады ул.

—Бәлки алып китәргәдер?—диде аларның берсе.

—Соң инде,—диде икенчесе.

Ачылмаган ишек аша үтеп, алар өй алдына чыгып киттеләр. Ирек калкынып, шулар артыннан чыкмакчы булды, ләкин аның җилкәсенә йомшак кына кул кагылды.

—Ят, балам...

Ул тавыш килгән якка башын борды һәм ап-ак сакаллы мөлаем картны күрде. Ирек аны шундук таныды: Мәскәүдә операциядән соң күргәне бар иде бит аның, әйе, үлеп барган чакта күрде. Әллә ул Ирекне саклаучы фәрештә микән? Карт елатырлык әллә нинди серле моң белән сөйли башлады:

—Дөньяга пәйгамбәр булып тумасаң да, сиңа гаҗәеп сыйфатлар индерелгән иде. Без шундый иткән идек, балам. Синең мондый хәлгә

*Ахыры. Башы 4-5 саннарда.*

төшүен—дөнья фажигасе. Ә бит сина жирегезне һәлакәткә тәгәрәүдән коткару вазифасы йөкләнгән иде...

Карт ана бик нык якынайды, Ирек анын фосфордай янып торучы күзләрен дә күрде.

—Галәмнең олы нияте бар. Син ана каршы барасың. Әгәр бүгеннән тәүбә-истигъфар итмәсәң, гомерең коточкыч фажига белән бетәчәк. Анладыңмы?

—Анладым,—диде Ирек, ләкин үз тавышын үзе ишетмәде...

Өйдәге яктылык, алсу төскә кереп, кинәт юкка чыкты, дөм-караңгы булып калды. Ирек, күкрәгендә дөп-дөп типкән йөрәгенең тавышын тынлап, шыбыр тиргә баткан хәлдә, гәүдәсен әле бер якка, әле икенче якка ыргытты. Ана һава житми иде. "Мин төш күрдемме, өн булдымы бу?"—дип уйлады ул, әлеге сөйләшүне күз алдыннан уздырып. Ул картның сакал бөртекләренә кадәр аермачык күрде, түгәрәк кечкенә колагына кадәр хәтерләп калды. Төштә беркайчан да алай булмый торган иде. Ләкин моның өндә дә булуы мөмкин түгел иде. Ул өйалдына чыгып утны яндырды, келәсен ычкындырып этүгә, ишек ачылып китте һәм аяк астында ятучы имән агачына шартлап бәрелде. Ирек башының коточкыч авырта башлавын тойды. Ул, чигәсен ике кулы белән кыскан килеш ыңгырашып кереп, караватына ауды...

***

—Сезне ниндидер хатын-кыз чакыра,—диде шәфкать туташы палатага кереп.

Зәнфирә анын артыннан атлады. "Хәлимә ападыр", дип уйлап барган иде, телефон трубкасында Сөембикәнең тавышын ишетеп, гажәпсенеп куйды. Теге вакыттан соң анын Сөембикәне күргәне дә юк, күрергә теләге дә юк иде.

—Исәнмесез. Хәлегез ничек?—диде Сөембикә йомшак тавыш белән.

—Рәхмәт, терелүгә таба...—дип жавап бирде Зәнфирә, ни уйларга да белмичә.

Сөембикә өчен ана шылтырату үлем белән бер булды. Зәнфирәне чәченнән сөйрәп йөрткәннән соң, ул канәгатьләнү кичергән иде. Чөнки ул жинүче иде. Ләкин тора-бара моның алай түгеллеген сизенә башлады. Анын дәрәжәле урыны, районндагы абруе, уч тутырып акча алуы—һәммәсе дә Зәнфирәдән өстен икәнен күрсәтәләр, шул вакытта кечкенә өйдә исерек Ирекне аякка бастыра алмыйча азапланучы, авызын ачса, үпкәсе күренә торган шушы хатынның бөтенләй анлаешсыз сәбәпләр аркасында үзеннән өстен икәнлеген ул ачык чамалады. Күпме генә карышса да, күпме генә баш иярга теләмәсә дә, Сөембикәнең Зәнфирә алдында кеше булып каласы килде. Теге чакта чәчләренә ябышканда, ул Зәнфирәне күрә алмады, ул анын өлешенә кергән кебек тоелды. Әгәр шул тойгылар белән яшәсә, ана күп мәртәбә жиңелрәк тә булган булыр иде. Әмма Сөембикә әлеге тойгыларын рәхимсез рәвештә читкә куды...

—Мин, теге вакытта кызып китеп, әллә ниләр кыланып ташлаганмын. Больницага барып, сезнең белән очрашып сөйләшсәк, дөрес анламаслар иде... Болынкыр бит ул гайбәт оясы. Бу сезнең өчен дә, минем өчен дә әйбәт булмас. Сез мине кичерә аласызмы?

—Әйе,—диде Зәнфирә, ничектер анын алдында үзен гаепле тойгандай итеп.—Була торган хәл...

—Рәхмәт, Зәнфирә. Сез минем өстемә басып торган авыр йөкне алып ташладыгыз. Мин сезгә мәнгелек дуслык тәкъдим итәм.

Сөембикәнең бу сүзләре Зәнфирәне аптырашка калдырды.

—Без ул дуслык белән ни эшли алырбыз икән соң?

—Әйе, бу сезгә сәеррәк тоела. Безгә бергәләп эш итәргә кирәк. Шылтыратуым да шуның өчен. Сезнең кайчан чыгасыгызны белмәкче идем. Аны тизрәк дәваларга кирәк.

—Рәхмәт кайгыртуыгыз өчен,—диде Зәнфирә.

—Әгәр кыен булмаса, чыккач миңа шылтыратсагыз иде. Өйгә килсәгез, бигрәк тә әйбәт булыр. Шунда сөйләшербез.

—Ярый,—диде Зәнфирә.

...Ул, больницадан чыккач, Иректәге үзгәрешне күреп хәйран калды. Ирек саргаеп, суырылып кипкән, күзләре эчкә баткан, сөйләшүе мәзәкләнгән, күп вакыт сүзсез уйланып ята, Зәнфирә сораган нәрсәләргә юньләп җавап бирми, сөйләшергә теләми, гомумән, бу дөньядан аерылган кешене хәтерләтә иде. Зәнфирә аңардан куркып та куйды: Ирек нидер эшләргә җыена. Әмма аның нишләргә теләгәнен белеп булмый иде. Өйгә кем кергәнен, бар әйберне туздырып ни эзләвен дә аңлады Зәнфирә. Димәк, аның күрсәтәчәкләре алда, һәммәсенә дә әзер торырга кирәк иде. Аптыраудан гаҗиз булып, больницадан кайткан көнне үк кичкырын Зәнфирә Сөембикә янына китте. Килеп керү белән, Сөембикә аны кочаклап алды, битләреннән үпте, елый-елый колагына пышылдады:

—Зинһар кичерә күрегез, мин сезнең алда шулкадәр гаепле...

Зәнфирәнең үзенең дә күңеле тулып китте, ул аның иңбашына кулын салып:

—Һәммәсе дә үткәндә калды ич инде, тынычланыгыз,—диде.

Алар өстәл артына утырып чәй эчтеләр һәм иртәгә үк авылга кайтырга булдылар. Ниятләре—Хәйрине алып килеп, үгетләтеп, Ирекне дәваларга алып китү иде. Ә болай гына ул бармаячак.

Икенче көнне караңгы төшкәч, Сөембикә үз машинасы белән килеп туктады. Зәнфирә тиз генә киенде, Ирек исә аның кая баруы белән дә кызыксынмады. Рульдә Сөембикә үзе иде. Иң элек кибеткә кереп, алар күчтәнәчләр алдылар.

Сөембикә белән Зәнфирәнең килеп керүе карт белән карчыкны телсез-өнсез итте. Гөлҗамал авыз эченнән догаларын укырга кереште, Хәйри исә:

—Әйдәгез, узыгыз, кызларым,—диде.

Сөембикә белән Зәнфирә алып кайткан күчтәнәчләрен бирделәр, гафу үтенделәр, аптыраганнан килүләрен әйттеләр. Гөлҗамал һаман аңына килә алмады, догасын укыды, "Йә Аллам, болай да була икән",—дип авыз эченнән нидер сөйләнде.

—Әнисе, самавыр куеп җибәр әле,—диде Хәйри.

—Юк, юк,—диделәр киленнәре икесе дә бертавыштан.—Без хәзер китәбез.

—Ай, Аллам, ник кенә килдегез соң? Әллә Ireккә бер-бер хәл булдымы?—диде Гөлҗамал һәм сүзләрен әйтеп бетергәнче үк еларга да кереште.

—Юк, әни, әлегә берни дә булмады,—диде Сөембикә, аны тынычландырырга теләп.—Булу ихтималы бар. Синең ярдәм кирәк, әти.

—Нинди ярдәм?

—Ирек тагын эчә башлады бит,—диде Зәнфирә.—Теге вакытта син тиргәгәч, файдасы тигән иде.

—Сиңа да үпкәм зур,—диде Гөлҗамал, Сөембикәгә якын килеп.—Берни сиздермәдең, катырак тоткан булсаң, андый хәлгә төшәр идемени ул.

—И, әни!—диде Сөембикә өзгәләнеп.—Сезне борчырлык сәбәп бар идемени... Аның бит исергәне дә, эчеп бер ялгыш сүз әйткәне дә булмады.

Гөлҗамал алъяпкыч итәге белән яшьле күзләрен каплады.

—Холкы гел үземнеке шул балакаемның...

—Тагын дәваларга алып барасы иде, ризалатып булмас, дип куркабыз.

—Ризалата алмасагыз, минем барып йөрүнең дә файдасы тимәс,—диде Хәйри каты итеп.—Үз гомеремдә мин андыйларны күп күрдем инде. Куркытып алып барган чаклар үземнең дә булды колхозда эшләгәндә. Кайткач та эчтеләр.

Сөембикә белән Зәнфирә кайтып киткәч, Гөлҗамал аптырап Хәйригә карады:

—Ни була соң инде бу, карт?

—Ни булганы аңлашыла инде: берсе аерылган, икенчесе хатын түгел. Безгә афәт килгән, дигән сүз бу...

Зәнфирә кайтып кергәндә, Ирек утны да яндырмаган, ашамаган-эчмәгән, ничек калган, шул хәлендә ята иде. Аның үзенә ачуланып каравын күргәч, Зәнфирә әллә нишләп китте.

—Ник син миңа шулай карыйсың?—диде ул елардай булып.

—Гадәттәгечә карыйм...

—Юк, Ирек, мин синең карашыңны аңлыйм. Мин синең эчүеңә дә гаҗәпләнмим. Тик бер нәрсә котымны очыра.

—Нәрсә?

—Син кемнәрдер гаепләргә маташасың.

—Нәрсә өчен гаепләргә?—диде Ирек, күзләренең агы белән карап.

—Шушы хәлгә төшүеңә. Шулай түгелмени?!—Ирек бер сүз дә дәшмәде, күзләрен йомды.—Таныргә теләмисең үз гаебеңне. Бөтенесе өчен дә кеше үзе гаепле. Кылган гөнаһлары өчен ул барыбер түли... Ничек булса да түли...

Зәнфирә күпме көтсә дә, Ирекләкән сыңар сүз дә ишетмәде. Аның дәшмәве шомлы һәм куркыныч иде. Шуңа күрә Зәнфирәнең йокысы йокы булмады, ул төнне дерт-мерт килеп кенә чыкты. Чәй эчү белән, эшкә киткәнче дип, Сөембикәләргә йөгерде. Ашыгудан эчендә нидер тартты, эт тешләгән кебек авырттырды, ләкин ул туктамады, кулы белән эчен тоткан килеш, йөгерәатлый барып җитте. Сөембикә Айгөлне мәктәпкә озаткан, үзе дә эшкә китәргә киенеп беткән иде.

—Ул нидер кылырга җыена,—диде Зәнфирә, яшьле күзләрен аңа төбәп.—Сузмаска иде бит. Хәзер үк Мәлс абыйга барып кайтмыйбызмы?

Сөембикә баш чайкады:

—Мин үз җаем белән әйләнермен,—диде ул.

Ишек алдыннан машинасын чыгарып, Зәнфирәне утыртып өенә илтте дә эшенә китеп барды.

Кичен Мәлс килде. Ирек, ул килгәч, торып утырды, аның кыяфәтен күреп, абыйсы аптырап баш чайкады.

—Иртәгә үк теге врачка барыйк, энекәш,—диде ул.

—Мин бит инде хәзер бер атна эчмим, абый. Мин үзем туктарга карар кылдым.

—Ә син үзеңнең кыяфәтеңне көзгедән караганың бармы?

—Ник булмасын, мин бит ике көн саен кырынам.

—Алайса каравың җитми. Син туктарсың, анысына мин ышанам, ә йөрәгең күтәрә алырмы соң? Синдә бит кеше кыяфәте калмаган. Бармыйча ярамый. Сиңа әз генә ярдәм кирәк. Ә болай гына туктау ике яклы.

Ирек берсүзсез ризалашты һәм алар икенче көнне үк Казанга юл тоттылар. Врач Ирекне җентекләп тикшерде, аннары аларга үзенең хөкемен чыгарды:

—Мине гафу итегез, ләкин мин сезне дәваларга алына алмыйм.

—Нишләп?—диде Ирек кабаланып.

—Ашыкмагыз, шуны аңлатам ич. Йөрәгегезнең тибеше начар, организмыгыз таушалган, бетәшкән, мин тәвәккәлли алмыйм. Сез дәвалауны күтәрә алмаячаксыз.

—Безгә нишләргә соң?—диде Мәлс.

—Иң беренчесе—эчмәскә. Мин сезгә туп-турысын әйтәм: эчсәгез—үләсез. Ләкин шунысы да бар, сезнең эчүдән тыелу аркасында үлүегез дә бар. Кайсын сайлыйсыз?

—Эчмичә үлүне,—диде Ирек, башын аска иеп.

—Ниһаять, сез дөрес фикергә килгәнсез,—диде врач җанланып китеп.—Мин сезгә шуны әйтергә телим, ничегрәк әйтсәм, барып җитәр икән?.. Шәрә электр чыбыгын күргәнегез бармы? Сезнең өчен эчү шул чыбыкны кулыгыз белән тотуга тиң. Аңлата алдыммы мин? Аннары аякларыгыз йөрми башлаячак, гангрена һәм...

—Мин инде аны үзем дә аңлаган идем...

—Анлагансыз икән, сүзне башкача алып барабыз,—диде врач, кулын рецепт кәгазе һәм ручка алып.—Мин сезгә дарулар, аларны куллану тәртибе язып бирәм. Мин ничек кушам, шул тәртиптә эшлисез.

Алар Казаннан бер букча дару төяп кайтып төштеләр. Хәлне анлатып биргәч, Зәнфирә бер дә шатланмады, анын йөзендәге монсулык сүнеп баручы шәфәкъ төсен хәтерләтте. Анын Ирекка булган ышанычы беткән иде инде.

***

Бер атнадан Мэлснын тормышы асты өскә килде. Казанга чакырып алдылар да күрше районга авыл хужалыгы идарәсе начальнигы булып китәргә тәкъдим иттеләр. Мэлс теше-тырнагы белән каршы килгәч, КПСС уставы белән китереп кыстылар, тресттан партия өлкә комитетына, өлкә комитетыннан авыл хужалыгы министрлыгына әрле-бирле йөртергә тотындылар, ахырда карышунын мәгънәсе калмады. Шулай итеп, ул совхозның баш инженеры Фаиз Шәймөхәммәтовны үз урынына калдырды да, күрше районда эшли башлады.

11

Ирек менә ничә көн инде таң атканда өеннән чыгып китә. Ул тере дә түгел, үле дә түгел. Жирдән дә бармый, күктән дә очмый. Әйтерсен лә ул бер ят дөньяда, ләкин бу дөньядан котыла алмый, нииндидер күренми торган коймалар аны элекке дөньясына чыгудан тыялар. Акрын гына барып, ул өянкеләр төбенә утырды, пыяладай тигез Ык өстеннән, мамык өемен хәтерләтеп, ала-кола томан шуыша. Анын аскы ягында Ыкнын төнге салкыны яшеренгән, өстенә әле чыкмаган кояшнын күк йөзенә җәелгән алсу яктылыгы сарка. Тиздән кояш чыгачак, анын нурлары тәэсирендә томан салынкыланып яшел үләннәргә, агач яфракларына көмеш тамчы булып куначак. Су өстеннән эреле-ваклы күбекләр ага, нииндидер бөҗәкләр җыерчык ясап уза. Бик еракта-еракта күке кычкыра. Тик белеп кенә булмый: сәгатьләрне санаймы ул, көннәрнеме, әллә айларнымы? Һәрхәлдә анын елларны санамаганын Ирек яхшы анлый. Ул күзләрен йома, игътибарын күке кычкыруыннан үзе сөялеп утырган өянкеләрнең ябалдашлары эчендә сайраучы кошлар тавышына юнәлтә. Кошлар җыры— мәңгелек сер. Анда серләр сере, анда моңнар моңы, анда җырлар җыры... Аларның тавышындагы шатлык кояшнын беренче нурлары белән кушыла. Ирек аларның кайнар тамак төпләрен күргәндәй, күзләренең очкынлануын, ботактан-ботакка сикерүләрен, ботакнын акрын гына тирбәлеп куюын күргән кебек була. Күзләрен йомып тынласа да, ул анын шулай икәнлеген һәрбер күзәнәге белән тоя. Дөнья отыры яктыра бара, кошлар бөтенесе бергә җырларга тотыналар. Гүя бинниһая олы чәчәкнең таҗлары киерелеп ачыла да, кошларнын дәртле тан җыры шатлыклы, илһамлы, серле туй булып, бөтен җиһанга тарала, чутылдаулы тавышлардан ясалган рәшәдәй, һавада тибрәнеп, тетрәнеп тора...

Ирекнен башлары әйләнеп китә. Бу кошларнын телләре нинди икән? Алар үтә дә сыгылмалы, һава тирбәлеше кебек сизгердер, кайнардыр. Ул кояш нурлары белән менә шушы табигатьтәге, очсыз-кырыйсыз җиһандагы барлык төсләрнен, моңлы авазларнын җыелмасыннан ясалгандыр... Кошлар җыры—мәңгелек сер. Анда серләр сере, анда моңнар моңы, анда җырлар җыры...

Хәзер иртәнге тымызык җил исеп куячак, кошларнын серле моңын җинел канатларына салып, әллә кайларга алып китәчәк... Җилнен күренмәс канатлары хәрәкәткә килүгә, агачлар, үләннәр, чәчәкләр баш ияләр. Җил ул вакыт кебек: үзе күзгә күренми, үзе бөтен нәрсәгә үтеп керә.

Ә вакыт мәкерле. Ул сине көн саен ваклап-ваклап урлый, ваклап ашый, җимерә. Вакыт кешене, тормыш матурлыгы белән аллап, туктаусыз куалый.

тәмам хәлен ала, кабер якасына кадәр сөйрәп китерә. Адәм баласы туганчы ук аның кармагына эләгә. Без һәрчак вакыт читлегендә. Бу күренмәс читлектән үлгәнче котыла алмыйсың, үлгәч тә котыла алмыйсың. Вакыт кеше белән бергә аның гүренә дә керә, черетеп юк итә, тәмам үзенә алып, ашап бетерә. Кеше аның барлыгын белми, ә адәм балалары телләре ачылу белән һәркөн вакыт белән сөйләшергә тиешләр. Вакыт бит һәрчак синен янәшәңдә, синең йөрәгеңдә һәм каныңда, җаныңда һәм рухыңда чаң кагып тора: "Кара,—ди ул.—Гомерең узып бара, ә син бик гамьсез яшисең, кылган файдасыз гамәлләрең өчен үкенмисең, һәр якты көн өчен рәхмәт әйтеп, аны иртәдән кичкә кадәр мәгънәле итеп уздыру турында уйламыйсың."

Ирек, авыр адымнар белән чыклы үләндә яшел эз калдырып, өенә атлый, һәркөн система, уколлар ала, дарулар, үлән сулары эчә. Алар һәр көнне ихатада кыймылдыйлар, кичләрен култыклашып Ык буйларыннан әйләнәләр. Ирек үзенә акрынлап хәл керүен, яшәү дәрте уянуын тойды, төнлә ару гына йоклый башлады.

Бер айдан Зәнфирәнең бюллетенен яптылар, ул эшкә чыкты, ә Ирек язарга утырды.

Бер көнне кич аларга Әхнәф килеп керде. Хәл-әхвәл сорашкач, өчесе дә өстәл янына утырдылар. Әхнәф әледән-әле Иреккә сынаулы караш ташлады, Ирек аның йөзенең шактый җитдиләнеп киткәнлеген, кырыслык өстәлгәнлеген, чигә чәчләренең чаларганлыгын күрде. Зәнфирә аның алдына тозлы кыяр белән бәрәңге куя башлагач, Әхнәф ике кулын күкрәк турына күтәрде:

—Үтерсәгез дә, бер грамм да капмыйм,—диде.

Ирек астыртын гына елмаеп җибәрде:

—Мин бу җир йөзендә синнән дә тәмле итеп ашаган кешене белми идем,—диде ул, елмаюдан көлүгә күчеп.—Итне мырлый-мырлый ашый иден.

—Онытмагансың,—диде Әхнәф, шулай ук көлә-көлә.—Беләсеңме, дустым, кеше никадәр тәмле итеп ашаса, шул кадәр озаграк яши, дия иде минем әби.

—Соң болай үз-үзеңне газаплап, гомереңне кисәсең бит,—дип төрттерде Ирек.

—Алдан бөкре чыга башлады. Гамьсезләндек бугай без.

—Бөкре түгел ул. Җитәкчеләрнең үз урыннарына тыелгысыз көчәя баручы мәхәббәте җен булып бүксәләренә керә, минемчә.

—Рәхәт синең белән!—дип куйды Әхнәф.—Без көннәр буе рәсми сүзләр, саннар, процентлар, гектарлар эчендә кибәбез. Без яшь чактагы тормышның тәме югалды. Килешәсеңме?

Ирекнең йөзенә моңсулык җәелде:

—Минем тәм сизү органнары сизгерлекләрен югалттылар шул инде.

—Менә мин үзебезнең балаларга аптырыйм: күңелләрендә әллә нәрсә... җылылык юк димме... Без тормышның эчендә ургылып кайнадык. Нәрсәгәдер ирешкән булдык, шуннан тәм таптык. Хәзер кеше читтән күзәтүне кулай күрә. Шул ук вакытта аңа барысы да булсын.

—Димәк, аңа шундый мөмкинлек тудыргансыз.

—Без?.. Ә син кайда?

—Мин бит тыкрыкта гына утырам.

—Ярар, ярар, мескенләнмә,—дип Әхнәф урыныннан кузгалды, күзләрендә очкыннар уйнап алды.—Чыгып сөйләшәсе сүз бар иде.

—Минем Зәнфирәдән серем юк. Әйтсәң, шушында әйт.

—Гафу итегез,—диде Әхнәф кызарып.—Сез бүтәнрәк тормыш белән яшисез ахры. Мин барысын да хатынга сөйли алмыйм. Эшем шундыйдырмы, хатыннандырмы?

—Аның икесеннән дә булуы бар,—диде Ирек көлемсерәп.

—Беләсеңме, мин ник килгән идем... Син татар иҗтимагый үзәге турында беләсеңдер инде?

—Әйе.

—Бездә дә шуның бүлекчәсен төзергә иде. Әгәр син шушы эшкә алынсаң, Болынкырда да тормышны җанландырырга булышучы оешма булырга тиеш бит инде.

—Райкомнан да зуррак нинди оешма булырга мөмкин тагын?—диде Ирек киная белән.

—Ярар, югары материяләргә кермик. ТИҮнең партиягә оппозициядә торуын син беләсең. Халык партиясе кебегрәк. Шуны шау-шусыз гына эшләргә кирәк. Үзеннең исемең телдән төшми. Абруйлырак кешеләрне тап. ТИҮ председателе Мөлеков исеменә членлыкка алуны сорап гариза язгыгыз. Ә илтеп тапшыруын кинәшербез тагын.

Ирек бераз уйланып торды:

—Синең бу күрсәтмәнне райкомныкы дип аңламаскадыр бит инде?

—Шулай, әлбәттә.

Әхнәфне озата чыккач, Ирек:

—Ник син янып-көеп беткән агачны кузгатырга ниятләдең соң әле?—дип сорады.

—Менә күктәге йолдызларны күрәсеңме?—Әхнәф кулын югары күтәреп селкеп куйды.—Алар сиңа нидер әйтергә телиләр. Яшьлегең бар иде, диләр, сине сагындык, диләр, безне нигә оныттың, диләр. Өнеңнән чыгарга вакыт сиңа, дустым.

—Миңа язарга кирәк.

—Язганнарыңны күреп торабыз. Бу эшкә алынсаң, иҗат өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр ачылачак. Әле районда революция дә ясап ташлавыбыз бар. Бусын да йолдызлар әйтә. Буйсынасыңмы аларның сүзенә?

—Буйсынам. Алар хаклыдыр, мөгаен...

Әхнәф белән алар яшь вакыттагы кебек озаклап кул кысышып аерылыштылар. Аның машинасы күздән югалгач та, Ирек капка төбендә хәрәкәтсез басып торды. Ул кабат-кабат Әхнәфнең очкынланып януы күзләрен хәтереннән үткәрде, хәтта комсомолда эшләгәндә дә алай янмый иде ул күзләр. "Мин аның каршында йөз яшьлек бабай",—дип уйлады ул. Шул ук вакытта күңеленең ничектер канатлануын, йөрәгенең ашкынып тибүен тойды. Әхнәфтәге дәртнең бер очкыны сүнмәслек булып миңа да төшсен иде, дип теләде ул эченнән генә...

***

Икенче көнне Ирек бик иртә уянды. Яхшылап кырынды, юынды, ихатада вак-төяк эшләрне карап керде. Ашап-эчкәннән соң, Зәнфирә белән бергә киенә башлады.

—Кая барасың?—диде ул аптырап.

—Әхнәф әйткәнне башларга кирәк инде.

—Бүген үкмени?

—Ә ник сузарга? Вакыт уза тора.

Алар беренче мәртәбә Болынкыр урамыннан култыклашып үттеләр. Күпләр гаҗәпләнеп карап калды, кайберәүләр гаҗәпләнгәнлекләрен сиздермәскә тырыштылар. Ничек кенә булмасын, Ирек үзен кеше итеп тойды. "Йә Хода, мин бит кешеләр белән,—дип уйлады ул чиксез куанып.—Сагынганмын икән мин сезне. Иң авыр чакларымда мине сезнең җылы карашыгыз аякка бастырды, үземне кеше итеп тоярга булышты. Янә дә килеп, сез бит әле, әти белән әни кебек, гафу итә дә беләсез икән. Әгәр бүген Зәнфирә белән култыклашып барганда каршыма килеп, миңа үпкә сүзләре әйтсәгез дә, сез тулысынча хаклы булыр идегез. Әмма берегез дә моны эшләмәде. Мәрхәмәтегез өчен рәхмәт..."

Ирекнең уйлары бүленде, аны райпо председателе Иванов кочаклап ук алды, Зәнфирәнең битеннән үпте:

—Сезне күрмәгәнгә күпме гомер, Ирек Хәйриевич?!—диде ул, ихлас күңелдән елмаеп.—Әйдәгез керик, сөйләшеп утырыйк.

—Рәхмәт, Николай Кузьмич. Хәзергә ашыгам,—диде Ирек.—

Кызыгызның хәлләре ничек?

—Үкертеп эшләп йөри. Ул сезгә рәхмәт укый инде.

Зәнфирәне больницага кертеп калдырганнан соң, ул туп-туры Вафиннарга китте. Лотфулла Габдрахманович та аны кочаклап алды. Ул нык бирешкән иде, Ирек аның гәүдәсенең гел калтырап торуын тойды.

Ул көнне биш кеше Татар иҗтимагый үзәгенә керергә гариза язды. Бер атна эчендә аларның саны егермедән артып китте. Ирек Әхнәфкә утырып Казанга барды һәм Татар иҗтимагый үзәгенең базык кына гәүдәле, калын кысалы күзлек кигән, чал чәчле җитәкчесе Мөлеков янына керде. Ул Иректне бик җылы каршылады. Иҗтимагый үзәкнең программасын, Уставын бирде, алда торган бурычларны аңлатты.

—Сезнең беренчел бурычыгыз—Татарстан Республикасының мөстәкыйльлеген таләп итеп халыктан имзалар җыю,—диде.—Шундый ук имзаларны Кама аланындагы атом электр станциясе төзелешен туктатуны сорап та җыярга кирәк. Аннары инде милли мәсьәләләр, кеше хокукларын яклау... Программада барысы да язылган.

Ирек, гариза биргән кешеләрне, кайту белән үзәк китапханәнең уку залына җыеп, ТИҮгә кабул ителүләре белән котлады. Җыелышка килүчеләр Ирекне бүлекчәнең рәисе итеп сайладылар. Ул алдагы бурычларга тукталды, имзалар җыю үрнәге язылган кәгазьләр өләште. Иң элек Болынкырны һәркайсына урамлап бүлеп алдылар. Авыллар калып торды, чөнки бүлекчәдәге кешенең күбесе пенсионерлар иде. Тора-бара эшеннән хаксыз куылган, яисә эштән китәргә мәҗбүр ителгән элекке җитәкчеләр Ирекнең туп-туры өенә килә башладылар. Аларны да алгач, бүлекчәдәгеләрнең саны алтмыштан артып китте. Бер җыелышкач, көнкүреш комбинаты тегүчеләренең хезмәт хакын кысу турында сүз купты. Ирек икеләнеп калды: коллективның эчке тормышына без катышырга хокуклымы, юкмы, дигән нәрсәгә ул ни уставта, ни программада ачык җавап таба алмады. Бу мәсьәләне киленнәре тегүче булып эшләүче ике абзый күтәреп чыккан иде. Ирек, аларның басымына түзә алмыйча, хәлне барып өйрәнергә кушты. Кеше хокукларын кысу, ягъни күрәләтә хезмәт хакын кисү факты расланса, югарырак органнарга мөрәҗәгать итәрбез, диде. Тикшерүчеләр берничә көннән кабат җыелыш җыйдырдылар, ике сәгать буе шушы мәсьәлә тикшерелде. Кайберәүләр райком, район Советы башкарма комитеты адресына җилле генә тәнкыйть сүзләре дә яудырдылар. Ирекне иң куандырганы шул булды: җитәкчелек тарафыннан кыерсытылган тегүче хатынның берничәсе ТИҮгә керде.

Бер көнне Айгөл белән Сөембикә килеп кич утырды. Кайтырга кузгалгач, аларны Зәнфирә белән капка төбенә кадәр озата чыктылар.

—Мин тыкрык башына илтеп куям,—диде Ирек, кызын җитәкләп.

Өстәл янында утырганда, Сөембикәнең карап-карап куюыннан нәрсәдер әйтергә җыенуын аңлаган иде ул. Сизенүе юкка булмаган икән: Сөембикә туктады да, Айгөлгә атлый торырга кушып, Ирекkә:

—Син ул җыелышларыңны яңадан китапханәдә үткәрмә инде,—диде.

Ирек аптырап китте:

—Ә нәрсә булган?

—Сез анда артык күп әйбер тикшерәсез икән. Бер районда ике власть була алмый бит инде.

—О-һо!—дип куйды Ирек.—Мин берәрсенең кәнәфиенә куркыныч тудыраммы әллә?

Сөембикә аның бу сүзенә җавап бирмәде.

—Юк, син өзеп әйт. Бу синең үзеңнең сүзеңме, әллә югарыданмы?

—Югарыдан, билгеле...

—Бик иртә көяләнә башлаган икән.

—Сүз озайтып тормыйк, син инде башка урын табарсың.

—Миңа башка урын кирәкми. Әнә, китапханәчеләрең көчәнсен,—диде Ирек, юри аның ачуын китермәкче булып.

—Мине эштән алуларын телисеңмени?

—Анын өчен эштән алмыйлар.

—Сөйләнеп торма инде,—диде Сөембикә рәнжеп.—Әйтерсең, үзе житәкче булып эшләмәгәнсең.

—Ул урын кадерледер шул сина.

—Җыештыручы булырга теләгем юк әле. Көчемнән килгәндә, эшлим.

—Сөембикә, без бит райкомны сукмибез. Әйт Арслановына...

Сөембикә аңа ялт итеп карады:

—Бу ни дигән сүзең инде? Ул бөтен районның Арслановы.

—Ярый, ярый, сүзгә бәйләнмә. Һәрбер арсланның үз биләмәсе.

Ирек тыкрык башында басып торган Айгөлгә кул изәде дә өенә таб китеп барды.

## Дүртенче кисәк

### 1

Әлекке сайлаулар үзе бер бәйрәм иде. Аларда, районның берәр кешесе тавыш бирергә килми кала күрмәсен, дип вәрәкәмәч килүдән дә олырак борчу булмады. Хәзер дөньялар кинәт үзгәреп китте. Быел Арсланов үзенең су баса торган жиргә оя казыган йомран хәлендә калуын тойды. Әйбәт кенә кешечә яши башлауга, гел көтмәгән жирдән афәт килә дә чыга. Афәтнең башында демократия дигән бик матур сүз калыкты да альтернатив кандидат дигән нәрсәне керттеләр. Бу инде тагын берничә кеше синең белән бер дәрәҗәдә үзен халык хөкеменә куя, дигән сүз. Үткән сайлауларда әлеге нәрсә сизелер-сизелмәс кенә узган иде. Шулай да Минзаһитны сискәндерерлек хәл булды: һәр авылда аңа каршы тавыш бирүчеләр табылды, ә район үзәгендә андыйларның саны ике йөзгә якынлашкан иде. Өлкә комитетына баргач, аның нәтиҗәләре буенча Минзаһит белән аерым сөйләштеләр. Бу инде астындагы кәнәфиеннең калтырый башлавы иде.

Ул, шуларны уйлап, бүлмәсендә арлы-бирле йөренде. Инде алар ничә көннәр район, округ, участок сайлау комиссиясе председательләрен, секретарьларын, членнарын билгеләү, шуларның исемлекләрен төзү белән мәшгуль. Һәр кандидатны жиде мәртәбә генә түгел, Нәҗмиев белән житмеш жиде мәртәбә тикшерделәр. Әз генә шик, әз генә икеләнү булганы шундук исемлектән сызылды, башкасы белән алыштырылды.

...Сөембикә Нәҗмиев бүлмәсенә курка-курка гына атлап керде. Сәбәбен үзе дә белми, әмма гомер буе бу кешедән шүрләде ул. Нәҗмиевнның йөзенең таштай хәрәкәтсез булуы, сүзләрен үлчәп кенә сөйләве, аның янына чакырылган кешеләрнең башлыча Нәҗмиев әйткәнгә буйсынып чыгуы Сөембикәгә мәгълүм иде. Әйтерсең лә аңарда гипноз, йә булмаса кара сизем бар. Аның янына кереп утыргач, Сөембикә нишләптер Нәҗмиевнын авызына карый, аның ап-ак булып хәрәкәтләнүче теле еланны хәтерләтә. Ул менә шулай карангы оя эчендә кыймшангалап торыр да кинәт сине чагып үтерер кебек.

Нәҗмиевнның гомергә бер төсле, гел җитди генә йөргән йөзендә ниндидер хәрәкәт барлыкка килде, уң як ирененең чите аскарак кыймшанды, елмайгандай итте.

—Сез торган саен чәчәк атасыз, Сөембикә Даутовна,—диде ул, алтын кысалы күзлеге аша Сөембикәгә дикъкать белән карап.

Аның ирен почмагыннан елмаюын абайлап булса да, күзләре боздай салкын һәм хәрәкәтсез иде.

—Рәхмәт,—дип кенә куя алды Сөембикә.

—Мин сезне комплиментлар әйтер өчен чакырмадым. Чәчәк жимеш бирергә тиеш... Сезгә мәгълүм булганча, алда зур, җаваплы политик кампания көтелә. Аны үткәрүдә райком бюросы сезгә зур вазыйфа йөкләргә карар кылды.—Нәҗмиевнның күзләре әз генә хәрәкәтләнеп алды.—Без округ сайлау комиссиясе председателенә сездән дә лаеклы кандидат юк, дигән

карарга килдек. Мондый ышанычның теләсә кемгә күрсәтелмәвен аңлыйсыздыр?

—Ышанычыгызга рәхмәт...—диде Сөембикә һәм өстенә ава башлаган коточкыч авыр нәрсәдән качкандай кабаланып:—Тик сез ялгышкансыз,—диде.

—Ничек ялгышканбыз?!—Нәҗмиевның кашлары түгәрәкләнеп өскә күтәрелделәр, маңгаенда бер тирән җыерчык барлыкка килде.

—Сайлау чорында клуб-китапханәләргә күпме эш йөкләнгәнен сез яхшы беләсез. Минем мондый эшкә алынуым, беренчедән, аларның эшчәнлеген сүлпәнәйтер иде, икенчедән, мин—ялгыз хатын, ялгыз бала үстерәм.

—Сез инде ул кадәр мескенләнмәгез, Сөембикә Даутовна. Без сезнең нинди кадр икәнегезне күптән аңладык. Кайбер җитәкчеләрнең берничәсенә торуыгыз турында кинәшмәләрдә күп әйтелде. Мин алдамыйммы?

—Юк,—диде Сөембикә, башын аска иеп.

—Нәҗмиев абыең беркайчан да алдамый. Аның хәтере дә әйбәт.—Бу юлы аның иреннән сул як почмагы аскарак төште һәм кисәтүле елмаю билгесе пәйда булды.—Без сезне укыттык, ашыкмыйча гына күтәрдек, матур гына эшлисез. Бернинди катлауландырусыз ризалашырга кирәк.

—Кәрәм Нәҗмиевич, без бит инде бер-беребезне бик яхшы беләбез. Сез—теләсә кемне күндерә торган кеше. Ләкин мин, күпме генә үгетләсәләр дә, үз сүземдә кала торган кеше. Чөнки мин уйламыйча сүз әйтмәскә сездән өйрәндем.

—Салпы якка салам кыстырмыйча гына сөйләгез,—диде Нәҗмиев кырыс кына.

—Анысына да сез өйрәттегез. Кирәк икән ул.—Сөембикә торып басты.—Икебезнең дә вакытны юкка әрәм итмик.

—Димәк, аңлаштык...—Нәҗмиев тә торып басты.—Тик китәргә ашыкмагыз әле...—Ул өстәлендәге өч телефон аппаратының беренче секретарь белән сөйләшә торганының трубкасын күтәрде һәм:—Ул бит риза түгел, Минзаһит Усманович,—диде. Берничә секунд тыңлап торганнан соң, трубканы урынына куйды һәм Сөембикәгә:—Ул сезне чакыра,—диде.

Сөембикә авыр сулап чыгып китте, кабул итү бүлмәсе аша узып, беренче янына керде. Арсланов аны урыныннан торып каршы алды һәм башын кыйгайтып аңа карап торды.

—Ничек була инде бу, Сөембикә?

—Теләсә ни эшләтегез,—диде Сөембикә, нигәдер кинәт йомшавын тоеп.—Булдыра алмыйм... һәм гомумән...

—Нәрсә ул—гомумән?

—Белмим. Миңа китәргә мөмкинме?

—Юк, мөмкин түгел,—диде Арсланов кырыс кына.—Утыр әле, Сөембикә.

Ләкин Сөембикә басып тора бирде. Минзаһит салмак кына атлап аның каршына килде һәм, иңбашыннан тотып, үзенең өстәле каршындагы урындыкка китереп утыртты.

—Беренче секретарьның сүзенә карышмыйлар. Мин ул урынга бары сине генә телим.

—Ни өчен нәкъ менә мин?

—Бу сайлауларда бөтенләй башка ситуация. Бер мандатка берничә кандидат дәгъва итәчәк. Тавышларны санаганда, теләгән якка уйнатырга мөмкинлек ачыла.

—Ә мин нәрсә эшли алам?

—Сөембикә, аңла: җир йөзендә мин берәүгә дә сиңа ышанган кебек ышанмыйм,—диде Минзаһит кайнарланып.—Беләсеңме, Сөембикә, умартаны корт анасы тота. Барлык кортларның язмышы, бал җыюның да күләме аңа бәйле. Вакытлар уза, бервакыт шушы умартадагы кортлар акрын гына яшь ана әзерли башлыйлар. Аны әзерләп бетергәч, карт ана умартадан чыгып качарга тиеш була. Әгәр чыгып качмаса, аны яшь ана чагып үтерә. Аңладыңмы минем ни өчен сиңа ышанганымны?

—Сез мине Татарстан депутаты итмәкче идегез...

—Мин аны онытмадым, Сөембикә. Ләкин элекке кебек, без кемнең фамилиясен язсак, шуны сайлый торган заман узды.

—Шаяртам гына, Минзаһит Усманович. Мин элек тә ризалашмый идем.

—Ә менә бусына ризалаш.

Сөембикә бер сүз дә әйтә алмады, ул күз карашын әле Арслановның йөзенә күтәрде, әле аска, ялтырап торган өстәлгә юнәлтте, аннары бөтен көчен җыеп, башын чайкады.

—Бу бит миннән бигрәк синең үзең өчен кирәк.

—Минем өчен?!

—Үзем булганда, мин сине беркемнән дә рәнҗеттермәячәкмен. Кызың да югары классларга житеп килә бугай. Ярдәмемнән ташламам...

Сөембикә, тагын бераз торса, аңа карыша алмаячагын аңлады. Шуңа күрә кискен генә урыныннан торды.

—Зинһар мәҗбүриләмәгез, кулымнан килми. Эшемнән алыгыз, утырам да гариза язам.

—Ярый, ярый...—диде Арсланов, ике кулын күтәреп, кул яссысы белән нәрсәнедер басып куйгандай итте.—Ул чакта секретарь бул. Анысы кәгазь эше генә. Әгәр шушы пүчтәк нәрсәдән дә баш тартсаң... сүз таба алмыйм...

"Әгәр пүчтәк икән, нигә соң нәкъ менә мин кирәк?!"—димәкче булды Сөембикә, әмма теленнән бөтенләй көтелмәгән сүзләр ычкынды:

—Ярый... Сезнең хакка...

Ризалык биргәне өчен, Арсланов бүлмәсеннән чыгып коридордан атлаганда, үз-үзен тиргәде, әмма кабат борылып кереп баш тартырга соң иде инде.

***

Район Советына, авыл Советларына депутатлар исемлекләре төзү хуҗалык эшләреннән шактый нык аерды. Арслановны "Үрнәк"тән күрсәтергә булдылар. Оештыру бүлеге җыелышны бик яхшылап әзерләде. Баллы Төбәк культура йорты шыгрым тулы иде. Башта район үзешчәннәре кыска гына концерт күрсәттеләр. Аларга Сөембикә үзе җитәкчелек итте. Җыелышта Арсланов турында колхоз председателе Өлфәт Җәмилов бик матур итеп сөйләде. Урыны-урыны белән төчеләнү, арттырып җибәрүләр булса да, нигездә халык аны яратып кабул итте. Арслановны бертавыштан Татарстан Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр. Соңыннан Өлфәт Җәмилов аларны өенә алып кайтты. Чит кеше юк иде. Кәефле генә кайтканда Нәҗмиев:

—Әллә Гайса Батталовичның хәлен белеп чыгабызмы?—диде.

Арсланов аның бу тәкъдименә берсүзсез риза булды. Батталов аларны кочак җәеп каршы алды, бер басасы урынга биш басып, рәхмәтләр, әйтеп, күз ачып йомганчы карчыгы табын әзерләде. Арсланов белән Нәҗмиев аның сәламәтлеген сораштырдылар.

—Тфү, тфү, күз генә тимәсен. Теге вакытлардан соң, әллә нервыларым тынычланды, башның бөтенләй борчыганы юк,—диде ул, куанычын яшермичә.—Рәхәтләнеп ихатада йөрим, мал-туар карап, гомер уза да китә.

Алар табын янында туйганчы гөрләштеләр. Күптән инде өчәүләп утырганнары юк иде, әллә кайчангы тарихларны искә төшерә-төшерә, шактый гына мактанышып та алдылар. Аннары сүз сайлау мәсьәләләренә күчте.

—Бу сайлаулар шактый катлаулы булырга охшый,—диде Батталов, рюмкаларны тутырып.—Ул альтернатив кандидат дигән нәрсә бик хәтәр бит. Безнең халык буш вәгъдәгә алданырга гына тора.

—Менә мин дә шуны әйтәм,—дип аны куәтләде Нәҗмиев.—Инде ничә көннәр сөйләшәбез, Минзаһит Усмановичны бер әйбергә һич тә ризалата алмыйм.

—Нәрсә ул?—диде Батталов.

—Мин үзем альтернатив кандидат күрсәтеп эшне катлауландырмау

ягында.—Рюмкасын күтәреп, Нәҗмиев алар белән чәкештерде дә эчеп җибәрде.

—Җил син әйткән яктан исми шул,—диде Арсланов.—Синең белән минем башка Горбачев дигән адәм килде. Ике сүзнең берендә демократия ди. Ә халык колагын торгызып кына тынлап тора. Казаннан да шуны тыкырдатып торганнарын син яхшы беләсең. Бер очкыннан олы янгын чыгарга мөмкин.

—Мин хәзер ялдагы кеше.—Батталов Нәҗмиевнең чәнечкесе белән астан күренеп торган кимерчәкле итне калап, ана сузды.—Демократия менә шушының кебегрәк әйбер инде ул: кимерчәккә охшаган. Әйбәтләп чәйнисең, бер әйберсе дә калмый.—Алар өчәүләп күтәрелеп көлешеп алдылар.—Синең тешләрең әле атныкы кебек бит, Кәрәм Нәҗмиевич.

—Бу кимерчәкнең граммын да калдырыйм мин,—диде Нәҗмиев елмаеп.

—Без моны уенга бормыйк әле. Бу җитди мәсәлә. Барыбер кемнедер күрсәтергә туры киләчәктер...

Батталов, аның белән килешмәвен белдереп, баш чайкады:

—Ай-һай, Минзаһит Усманович,—дип сузды ул.—Кирәк микән андый әйбер?

—Мин дә шулай уйлыйм. Альтернатив кандидат мәҗбүри түгел.

—Во!—Батталов итле чәнечкесен Нәҗмиевнең борынына тигезә язып селтәп алды.—Күрсәтү теләге булмаслык итеп эшләргә кирәк.

Арсланов белән Нәҗмиев бер-берсенә карашып куйдылар. Картлачның сүзләре һаман да мәгънәле иде, шайтан алгыры.

—Бу сүздә резос бар,—диде Арсланов.

—Мин авыл кешесе,—дип дәвам итте Батталов.—Җәйгә чыксак, бөтен кайгы янгын чыгу иде. Салам түбә, бер очкын урамы белән авылны юк итә. Шуна күрә пожарныйлар көне-төне сакта торды.—Ул ялт итеп Нәҗмиевка карады.—Синең пожарныйларың ышанычлыдыр бит?

—Ышанычлы,—дип җавап бирде Нәҗмиев елмаеп.

Алар Болынкырга кайтып җиткәндә, ярты төн авышкан иде инде. Нәҗмиев, Арсланов машинасыннан төшеп калгач, декабрь аеның салкын һавасын сулап, үзенең капка төбендә шактый вакыт басып торды. Оста балыкчы кичтән җимен суга салып китеп, иртүк шул урынга килеп балык каптырганда ләззәтләнгән кебек куанды ул. Кәрәм инде әллә кайчаннан әзерләнгән яшерен планын бик нечкә итеп, сиздерми генә тормышка ашырып бара иде. Райкомда эшләгән һәркем беренче секретарьдан туйган кебек, ул да Арслановтан гарык иде. Ничә еллар буе ул аннан котылу җаен эзләде. Хәйләкәр төлке аучыны алдап баргандай, аны ялган юлларга да кертеп җибәргәләде. Әмма андый гына нәрсәләр беренчене урыныннан кузгата алмадылар. Биек кыяның читләрен җил-янгыр, кар, эсселек һәм суыклык ашаган кебек, аның йөзенә дә әлеге вакыйгалар өстәмә җыерчыклар салдылар салуын, әмма үзе кыя кебек тора бирде. Менә хәзер, демократия дигән нәрсә килеп чыккач, шушы күсәк белән әлеге кыяны җимерү мөмкинлеге дә туды. Дөрес, ул беренче урынына омтылмый, аның яшендә бу ахмаклык булыр иде. Ләкин юньлерәк беренче секретарь булганда, ул нервы бетермичә генә районны әле бер кадәр үз кулында тота алачак.

Икенче көнне иртәнге алтыда Нәҗмиев Арсланов бүлмәсенә килеп керде.

—Бүген район үзәгендә ветераннар Советы пленумы җыелганын сез беләсез инде,—диде ул күрешкәч.—Мин анда сайлаулар буенча чыгыш ясаячакмын. Алай-болай икенче кандидат турында сүз чыкса, сүзебез кичә сөйләшкәнчә булыр бит инде?

Арсланов махмырдан кызарган күзләрен бармак очлары белән сыпыргалады да башын аска иде.

—Минем һаман да ниндидер шигем бар,—диде ул шактый вакыт уйланганнан соң.—Янгын чыгармабызмы?

—Чыгармабыз, Минзаһит Усманович. Ныклап саклану чараларын күрербез. Чыга-нитә калса, су җитәрлек бездә.

—Ярый, бер икән—бер кандидат,—диде Арсланов, һаман да икеләнеп.

—Мина ышаныгыз. Сезне сайлату—ул минем шәхси бурычым.—Анын йөзе гаять житди төс алды.—Әгәр райкомга сезнен урынга башка кеше килсә, мин бер көн дә эшләмәячәкмен. Шулай булгач, үзегез анлыйсыз...

Ветераннар советы пленумында ин элек анын председателе Бәшировнын отчеты тынланды. Сорауларга жаваплар, ветераннарнын зар-мон белән тулы чыгышлары, аларнын үзләре генә түгел, бөтен ил күләмендә хәл ителә алмаслык мәсьәләләрне күтәрүләре—һәммәсе дә Нәжмиевка таныш иде инде. Алар эчләрен бушатып бетергәннән сон, ана сүз бирделәр. Ул алда зур политик кампания торганлыгын, анын әһәмиятен анлатканнан сон, кичә Баллы Төбәктә үткән жыелыш турында сөйләде, йөз дә житмеш сигезенче номерлы Болынкыр сайлау округыннан Татарстан Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп КПСС райкомынын беренче секретаре Арсланов кандидатурасы күрсәтелүен һәм бертавыштан хуплануын әйтте. Аннары сайлауларны оештыруга жентекләп тукталды. Ул сөйләп бетереп, президиумга барып житәргә дә өлгермәде, ин алгы рәттә утыручы Жаббар Саттаров күкрәге тулы орден-медальләрен чылтырата-чылтырата торып басты.

—Минем бер соравым бар иде. Ул башын президиумга борды.—Хәзер демократия заманы. Партия халыкны берничә кандидат күрсәтергә, шуларнын берсен сайлап алырга чакыра. Менә мин үзем бу янарышны бик хуплыйм. Шуна күрә иптәш Арсланов белән бергә альтернатив кандидатлар да күрсәтергә кирәк, дип саныйм. Примерно, менә әйтик...

Анын сүзен бүлеп, Нәжмиев трибунага юнәлде.

—Саттаров агай, сез һәрвакыт гаделлек өчен көрәштегез. Әле дә сез бар,—бу сүзләрен дә Нәжмиев залнын ачуын китерү өчен әйтте.—Әйдә, без юк белән баш катырмыйк. Өчәр-дүртәр мәртәбә сайлау үткәреп, мәшәләнеп ятулар булмады түгел бит. Демократиянен анын централизм дигән өлеше дә бар. Әгәр централизм онытылса, ул анархиягә әйләнә.—Зал умарта күче кебек гөжли башлады. Нәжмиевка шул гына кирәк иде. Ул берсеннән-берсе үтемлерәк сүзләр эзләде.—Кандидат күрсәтергә без барыбыз да мастер. Менә бүген районнын рулен тапшырырлык кем бар? Арслановтан башка кеше юк.—Болай дигәч, тагын залда шаулаша башладылар.—Райкомнын фикерен сезгә белеп китү кирәк булыр. Без шушы кичә күрсәтелгән кандидат белән чикләнергә, дибез. Эшне юкка катлауландырмыйк.

Шул вакыт залда Чукаеванын каракүл бүрекле башы калыкты һәм ул сажин адымнар белән трибуна алдына килде.

—Ник син авызны томалыйсын?!—дип йодрыгын Нәжмиевка селкеде ул.—Синен ул Арслановын—минем күршем. Ел саен өенә ремонт ясата, берсен бер елны ясыйлар, икенче елны жимереп ташлыйлар, тагын янарталар, ә менә минем өй түбәмнән су ага.

—Туктагыз әле, иптәш Чукаева,—диде Нәжмиев, ана таба шулай ук йодрыгын селкеп.—Сүз бит түбә турында бармый.

—Ах, бюрократ!—диде Чукаева, үзенен йодрыгы белән анын йодрыгын бәреп жибәреп.—Нинди иптәш Чукаева булыйм ди мин сина! Апа, диген, юньсез. Танымый да башладынмыни?

—Тукта әле, апа,—диде тавышын күтәреп Нәжмиев, аны тынычландырмакчы булып.—Демократия турында сүз барганда син монда корымланып беткән тышкы моржанны китереп тыгасын.

—Минем башка тыгар әйберем юк!—дип жикерде Чукаева.—Синен ник ялагайланганынны да беләм. Барлык бюро членнарына өйләрен ремонтлатып чыкты, йә гараж, йә тагын бер өй зурлыгында янкорма салдыгыз. Шул исәптән, син дә.

—Жыелышны алып барырга ирек бир инде, апа.

—Менә хәзер апа түгел мин сина. Мин хәзер иптәш Чукаева!

Шау-гөр килгән зал бердәм көлеп жибәрде.

—Иптәш Чукаева!—диде Нәжмиев, үзенен тәмам каядыр кереп батканына

көяләнеп.—Әйдә, бу нәрсәләрне очрашу җыелышына калдырыйк әле.

Чукаева отыры дәртләнә барды.

—Нәрсә, турысын әйткәч, үтегезгә тиямени?! Шул ук Арсланов сезнең барыгызга да каз оясы кадәр бүрекләр дә алып кигерде. Гади халыктан аерылып торсыннар, дип. Ә менә безнең башта нәрсә?—Ул бүреген салып, залга таба селкеп күрсәтте дә бөтенләй чыгып ук китте.

Янадан берничә кеше кандидат күрсәтү мәсьәләсенә тукталмакчы булсалар да, Нәҗмиев аларны тиз томалады.

Кичен Нәҗмиев, Арсланов белән баш төзәткәннән соң, шактый соңарып кайтты. Аның инде ашыйсы килми иде, кереп чишенәм дә авам, дип ишекне ачуга, залдан каршысына, кулларын биленә таянып, апасының килеп чыгуын күргәч, артына утыра язды. Ул шундук һөҗүмгә күчте:

—Минем йөземне каралтып, шуның кубызына биеп йөрмәсәң, эшсез калырмын, дип куркасыңмыни?

—Син ул минем йөземне каралтучы,—диде Нәҗмиев, ачуына буылып.—Әгәр башка кеше булса, мин сине милиция белән алып чыктырып, яптырып куя идем.

—Нигә, соң түгел бит әле,—дип чәчрәп аның каршына килде Гандәлифә.—Менә хәзер мин сиңа сугам, бар, илттереп яптыр.—Ул ике мәртәбә каты гына иттереп Нәҗмиевнең күкрәгенә төртеп алды. Аның болай да буыны сыекланган иде, стенага ук барып сөрлекте. Аларның арасына Нәҗмиевнең хатыны Разия килеп керде.

—Кайчанга кадәр дәвам итәр бу мәхшәр?!—ул калтыранып ике кулын, һавадан нәрсәнедер тотып алырга җыенгандай, бармакларын җәеп өскә күтәрде.—Сез бит туганнан туган балалары, оят түгелме сезгә?!

—Кара әле сөйләп торган булуын?—диде аңа таба борылып Гандәлифә.—Әле генә миңа кушылып шушы имгәкне сүгеп утырдың, хәзер бүтән сүз сөйлисең. Мин аны бот буе чактан бирле тәрбияләмәкче булып җәфаланам инде. Үләр вакыты житте, һаман кеше ясап булмады.

Нәҗмиев өстен идәнгә салып бәрде:

—Әнә пәлтәнең элмәген тек, мине сүгеп утырганчы,—диде хатынына, аннары юри ачу белән барып, шкафтан башланган яртысын алды да, борыныннан эчеп, өстәлгә шартлатып куйды.—Йә, нинди кеше ясамакчы буласыз инде сез миннән?—диде ул, апасы каршына килеп.—Әйт, нинди булырга кушасың, шундый булам!

—Культурасыз,—диде Гандәлифә.—Ике хатын-кыз алдында шешә борыныннан аракы эчеп торырга ничек оят түгел сиңа?

—Әйдә, вакланма, зуррак нәрсәләр турында сөйлә!

—Кирәк булса, әйтәм мин сиңа зуррагын. Син менә үз гомереңдә кемнәрнең генә башына җитмәдең инде. Кайсыларын, үзең югары күтәреп утыртып, үзең үк төртеп төшердең. Төшерә алмаганнарына тәлинкә тоттың, аларның һәр боерыгын үтәү өчен селәгәеңне агыза-агыза чаптың. Син үзең кая соң? Син бит ир кеше. Үз гомереңдә берәр сәгать булса да үзең булып яши алганың юк бит синең.

—Мин һәрвакыт үзем. Ә менә син чын агрессор!

—Мин—көрәшче, агрессор түгел! Ә син әртист, шамакай. Тфү, оят!—диде Гандәлифә, Кәрәмнең каршына ук килеп.—Балачакта ук кош ояларын туздыра идең. Синә жан иңгәндә, шайтаннар үз жаннарын салганнардыр.

—Ә синекендә елан ята, һәрвакыт чага торган.

—Ул еланны менә сез керттегез, сезнең шушылай яшәвегезгә түзә алмыйча яралган ул. Минем телем авылда кыз чагында иң йомшак тел иде. Миңа "баллы тел" дигән кушамат тактылар. Ә менә сезнең кебекләр аны елан угына әйләндерде.

Нәҗмиевнең хатыны калакка тамызып йөрәк даруы эчте һәм елый-елый бүлмәсенә кереп китте. Нәҗмиев, гадәттәгечә, чыгып китү өчен бүреген киде, пальтосына үрелде.

—Нәрсә, миннән качасың?—диде Гандәлифә карлыккан тавыш белән, аннары елап ук җибәрде.—Син минем ничек яшәгәнне дә белмисең бит.

Ашарыма бармы минем, кияремә бармы?—Ул озак итеп үкседе.—Минем бит сөйләшеп утырыр кешем дә юк. Ә син миңа бөтен кеше алдында җикерәсең.

Нәҗмиевка ул ничектер кызганыч булып китте. Авыз эченнән генә мыгырдап:

—Моржадан аккан су турында сөйли башладың бит,—диде.

—Ә син нигә килеп карамыйсың соң? Ник син аның акканын белмисең? Күр әле үзеңнең өйләреңне, ихаталарыңны. Миндә гомерем буе эшләдем, коймам селкенеп тора, түшәмемнән туфрак коела. Көчлерәк кеше этсә, абзарым да авып китә.

—Әгәр үзең юньле булсаң, бөтенесе дә эшләнер иде, апа. Син бит юньләп сорый белмисең. Гомер буе җитәкчеләрне сүгүдән башың чыкмады.

—Ярар, яшәгез,—дип Гандәлифә бүреген алып киде, пальтосын иңбашына салды, аякларына олтанлы итекләрен киде һәм рәнҗүле тавыш белән сөйләнә-сөйләнә чыгып китте:—Синеке дә, минеке дә калачак, теге дөньяда әнкәйләр янында очрашырбыз әле. Ни дип алдашырсың икән шунда? Син бит гомер буе алдаштың...

Нәҗмиев аның чыгып киткәнен, аяк тавышының ерагайганын верандада көтеп торды да, капка белән ишекне бикләп кереп, караватына ауды...

## 2

Ах, бу декабрь аеның озын төннәре! Сабирҗан Закирович менә бер атна инде яткан урынында әйләнә дә уфтана, уфтана да әйләнә. Йоклап булмас микән, дип стаканлап аракы да эчеп карады, йөрәк даруларын иртәдән кичкә кадәр алай тамчылап түгел, бөкесен ачып кына тамак төбенә җибәрде, ә барыбер җанының тынгы тапканы юк. Йокыдан гына түгел, ул ашау-эчүдән дә калды. Үз гомерендә нинди генә эшләр башкармады. Үлем хәлендә өч мәртәбә пычак астына керде. Үт куыгыннан таш алдырды, ашказанының яртысын кистеләр, чәрдәкләнгән аягына операция ясадылар. Берсендә дә бу дәрәҗәдә курыкканы булмады аның. Ничә көннәр бөтенесе пышын-пышын килә, күзгә күренмәгән сайлау алды афәте "Биектау" кешеләрен бер йодрыкка туплый бара. Райкомга сиздермичә генә алар сайлау алды җыелышы үткәрергә әзерләнделәр.

Бу мәрәкәне кем башлап җибәргәнен ул белми дә калды. Белсә дә берни дә эшли алмас иде. Хәзер менә бүген көндезге сәгать икегә кешеләргә җыелышка әйтелгән. Бернинди белдерү куймадылар. Әгәр район үзәгенә бу хәбәр барып җитсә, аның шау-шуы бик еракка китәчәк, шул ук вакытта Сабирҗанга күсәкнең иң олысы эләгәчәк иде. Арслановка альтернатив кандидат күрсәтү ул инде аның бүлмәсенә кереп, күкрәк сугып: "Син безгә лаек кеше түгел, без Мэлс Сабитовны сайлаячакбыз!"—дип кычкыру белән бер иде. Җыелыш тыныч кына үтеп, Сабитов кандидатурасы күрсәтелгән сурәттә дә, Нуриев үзенең бик авыр җәзага тартыласын аңлап тора. Мөгаен, аны инде эшеннән дә җибәрерләр. Башта бу фикер аның котын очырса да, соңыннан ул халыкка каршы барырга ярамаганын аңлады. Ана әле шушы кешеләр белән пенсиягә чыккач та күзгә-күз карашып гомер итәсе бар. Халыктан аерылып берни дә кыра алмыйсың. Кыен булса да, эштән дә китәргә туры киләчәк. Арслановлар аның алдан хәбәр итмәвен, кисәтмәвен зур хыянәт дип бәяләячәкләр. Аннары партия эшенең берәр тармагын тикшерерләр дә, шуны сәбәп итеп, гариза яздырырлар.

Иртәнге якта булса, җыелыш шома гына үтәсе иде. Әмма кичә совхозның иң хөрмәтле кешесе, беренче комсомол ячейкасын төзегән, утыз ел механизатор булып эшләгән, биш бала анасы Маһиямал карчык вафат булды. "Шайтан алгыры!"—дип кыбырсып куйды Сабирҗан. Әле аның бит чардуганын ясаучы егет кичә исергән иде, бүген ул нинди хәлдә булыр? Ярый әле кабер ташын Маһиямалның әтисе ягыннан туганы Заһит Фәхруллин, үзем ясатып алып киләм, диде. Җыелышны да уздырырга кирәк. Юк, йоклап булмый иде. Ул тагын, акрын гына торып, кече якка чыкты,

урта ишекне ябып, утны кабызды. Сайлау алды җыелышы документлары тутырылган папкасын алып килеп, күзлеген киде һәм, дөньясын онытып, эшкә чумды...

Иртән авыл өстен, ерактагы ак кар баскан басуларны алсу нурга манып кояш чыгуга, Наратбаш зиратында ун-унбиш кеше, калын кар катламын көрәп, кабер казый башладылар. Сәгать унбер тулганда, Мәһиямал Габдуллинаның мәетен кара-каршы бастырылган ике урындыктагы сай тартмага чыгарып салдылар. Ишек алды гына түгел, капка турындагы урам да халык белән шыгрым тулы иде. Кайгы митингысы башланганчы Мэлс та килеп җитте, ул, кара "Волга" машинасыннан төшеп, халык төркеменә килеп керүгә, элекке директорны тыгыз боҗра булып төреп алдылар, бер-бер артлы куллар кысылды, карт-корылар кочаклап ук алды. Аны сагынуларын әйттеләр, күз яшьләрен сөртеп, ана элекке эшләре өчен рәхмәт укыдылар. Бер үк вакытта диярлек район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы, аннары Нәҗмиев килеп җитте. Көн бик кырыс иде, кешеләрнең авызларыннан пар күтәрелә, кызарган борыннарын уалар, туктаусыз таптаналар. Авыл Советы рәисе Әфләтунова кайгы мәрәсимен ачып җибәрде. Район вәкилләреннән соң Мэлс, туганнары, Мәһиямал карчыкның кордашлары чыгыш ясадылар. Мәрәсим вакытында "тәне бик йомшак, тагын мәет булмагае", дип шомланучылар да күп булды. Җеназа артыннан халык төркеме тын гына зиратка юнәлде. Зиратта картлар укыганнан соң, мәетне кабергә индерделәр. Кырык минут вакыт узмагандыр, кап-кара балчык өеме калкып чыкты. Аның өстенә авыл халкының күз яшьләредәй тын гына, сирәк кенә бер-бер артлы эре кар бөртекләре төшеп куна башлады. Авыл өстенә иртүк җыелган болытлар, әйтерсең, шушы мизгелне генә көткәннәр иде. Мэлс бу күренешкә хәйран калып карап торды. Ул агроном чакта Мәһиямал Габдуллина әле тракторда эшли иде. Көнне дә, төнне дә белмәде, яшьләрдән берәрсе сыйфат бозса, көче җитәме-җитмиме, тракторыннан сөйрәп төшерде, ата-анасын калдырмыйча сүкте, аңардан механизатор халкы район җитәкчеләренә караганда ныграк курыкты. Моны курку дип тә булмый, басуларда ул авыл халкының уртак намусы кебек гомер буе йөргән, кем белә, киләчәктә рухы да шулай йөрер. Әгәр дә барлык механизаторлар да аның кебек вөҗданлы булса, басуларның уңышы күзгә күренеп артыр иде. Шушы уйларына батып атлаганда, ул Нәҗмиев белән партком секретаре Нуриевның һәм директор Шәймөхәммәтовның бер читтә нәрсә турындадыр кызып-кызып сөйләшкәннәрен, кулларын селтәп-селтәп җибәрүләрен күрде. Ул да булмады, теге икесе башларын иеп алдан киттеләр, Нәҗмиев, куып баргандай, аларның артыннан атлады. Мэлсның күңеленә килгән нәрсә, гаҗәттәгечә, нәкъ алдына килде дә басты: димәк, җыелыш буласын сизгәннәр, димәк, Нәҗмиев юкка килмәгән. Аны өзү өчен ул кулыннан килгән чараларның барысын да кылачак.

Нәҗмиев ике җитәкчегә дә бүре кебек ташланды:

—Син, карт ишәк,—диде ул Нуриевка, бармагы белән төртеп.—Ә син яшь ахмак. Икегез дә партия билеты белән җавап бирәчәксез. Хәзер үк райкомга! Минем арттан калмыйсыз!—ул шулай дип боерды да машинасына утырды.

Туктап, аларның машиналарына утырып юлга чыгуларын күргәч, үзе артка калып, сагалап кайтты.

Төштән соң авыл халкы культура йортына агыла башлады. Ике туларга биш минутта Мэлс та, Нәфисә үтүкләп куйган яна костюм-чалбарын киеп, җыелышка китәргә әзерләнде. Өйдән чыгып киткәндә, Нәфисә аны туктатты:

—Мин синең белән бармыйм,—диде ул сәер генә.

—Нигә?—диде гаҗәпләнеп Мэлс.

—Халык оятмас. Эреләнеп, "Волга"га киерелеп утырып килде, диярләр... Аннары...—Нәфисә Мэлсның күзләренә төбәлеп туктап калды.—Бу әйбергә ризалык биреп, ялгышмадың микән син, Мэлс?

—Юк,—дип җавап бирде Мэлс.—Алар бит башка җирдән кандидат

күрсәттермәячәкләр. Шуна каршы булса да, мина ризалашырга кирәк иде. Аның бит власте бүген бар, иртәгә юк. Кеше шул әйберне анларга тиеш.

Җыелышны авыл Советы председателе Әфләтунова ачып җибәрде. Тугыз кешедән президиум сайладылар, аның составына Мэлс Сабитов белән округ сайлау комиссиясе секретаре Сөембикә дә кертелде. Тиешле кешеләр Мэлсны тәкъдим иттеләр. Мактыйсылары мактап сөйләде.

Шунда кемдер залдан:

—Безнең директор белән партком кайда соң?—дип кычкырды.

—Аларны ашыгыч рәвештә райкомга җыелышка чакырып алдылар. Без кайтып җитмәсәк, үткәрегез, диделәр.

—Нәрсә, халыкны алдап торасың инде!—дип кычкырды сыер фермасы мөдире Мөкатдисә Заһидуллина.—Мин бит колагымның чите белән Нәҗмиевның аларга ничек җикеренгәнен ишеттем. Хәзер аларның иманнарын укыталар инде.

Соңыннан Мэлс, Татарстан Верховный Советына депутатлыкка сайланырга риза булуын әйтеп, кыска гына чыгыш ясады. Карар кабул итәргә әзерләнгәндә, ишек ачылып китте һәм аннан кызу-кызу атлап кереп килүче Шәймөхәммәтов, Нуриев һәм Нәҗмиев күренде. Алар иң алдагы рәткә барып утырдылар. Нәҗмиев Әфләтунова карарны тавышка куярга сүз башлауга, аны ишарә белән туктатты да трибунага менеп басты:

—Хөрмәтле иптәшләр!—дип башлады ул.—Бүген сезнең сайлау алды кебек мөһим кампаниягә җаваплы карап, бирегә җыелуыгызны партиянең район комитеты хуплый. Тик безнең бер үпкәбез бар: нигә инде Татарстан Верховный Советына альтернатив депутат күрсәтү кебек зур чараны бездән яшерен уздырырга? Райкомның бит әле халыкны мондый чаралардан тыйганы юк.

Шул чак алдан икенче рәттә утыручы сугыш ветераны Миңнеханов торып басты:

—Сез, иптәш Нәҗмиев, район ветераннар җыелышында кистереп әйттегез: альтернатив кандидат күрсәтелмәячәк, дидегез.

—Мин алай ук димәдем. Утырыгыз әле зинһар. Мин райком линиясен әйттем. Менә бүген Сабитовны күрсәтүегез мәгълүм булды. Бу сезнең хокукыгыз. Без дә аны хурламыйбыз. Тик мәсьәләнең асылын уйлап карагыз: сез аны сайлаган очракта, депутат мандатын күрше районга бирәбез, дигән сүз.

—Нишләп без үзебезнең мандатны ычкындырыйк?—дип кычкырды бер ир-ат.—Кире кайтарабыз без аны, Сабитовны. Без аны артканга җибәрмәдек бит.

—Ярый, җәмәгать,—дип Нәҗмиев кулын югары күтәрде.—Сез бик законный булгач, җыелыш та законлы тәртиптә узарга тиеш. Исемлегегездә өч йөздән артык сайлаучы кертелгән. Сезнең биредә яртысы гына. Шулаймы, Әфләтунова? Инде килеп, биредә сездә янә оешкан ПМК коллективы кешеләре дә утыра. Әле алар оешма буларак рәсмиләштерелмәгән, печатьләре дә юк. Димәк, тагын утыз-кырык кешегез кими. Кыскасы, бу җыелыш сайлаулар турындагы положениене тупас бозу булып тора. Сезнең кандидат күрсәтергә хакыгыз юк.

—Тартып төшерегез шуны трибунадан!—дип кычкырды кемдер арттан.—Без сине чакырып китермәдек!

—Без барыбыз да совет гражданнары, законны синен хәтле генә беләбез. Әфләтунова, давай, карарны кабул иттер!

Кемнәрдер аяк дөбердәтергә кереште, кемнәрдер ишекне шартлатып ачып чыгып киттеләр. Авыл Советы рәисе җыелышны тәртипкә салу өчен өстәлдәге графинга шыкы-шыкы китереп стаканны бәрергә кереште, ләкин зал һаман тынычланмады. Нәҗмиев, максатына ирешкәнен аңлап, үзе дә сизмәстән, елмаеп карап тора иде. Шул вакыт ПМК начальнигы Фәнис Сәлахов президиумнан торып басты да баһадирдай зур гәүдәсе белән Нәҗмиев янына килде:

—Иптәш Нәҗмиев,—диде ул тавышын күкрәтеп.—Ник сез безнен

коллектив членнарын мыскыл итәсез? Печатьләр, кемдер кул куясы кәгазьләр—алар барысы да сезгә кирәкле бюрократик әйберләр бит. Ә без барыбыз да—совет гражданнары.

Нәҗмиевнын ялкынга сибеп җибәрергә бензины әзер иде:

—Син, егеткәем, бик азынма әле,—диде ул, анын тавышын басып.—Бар әле, урынына утыр. Ул ПМКны без оештырдык, әгәр кирәк түгел дип уйласак, иртәгә таратып та куярбыз. Анладынмы?!

Залдан, Нәҗмиевны сөендереп, өч-дүрт ир-ат берьюлы сикереп торды.

—Иптәш Сәлахов,—дип кычкырды берсе.—Нәрсә анын алдында балачага сыман басып торасын? Чыгып киттек!

—Дөреслекне каян табарга белербез без!

—Әйе, кирәк булса, ЦКга житәрбез. Дөнья Болынкырга терәлеп калмаган.

Залдан тагын берничә төркем кеше чыгып китте. Нәҗмиев та урынына барып утырды.

Карарны тавышка куюнын мәгънәсе калмады. Гаепле кеше кебек, бик авырлык белән Нуриев торып басты:

—Иптәшләр, чыннан да жыелышнын кворумы житеп бетмәгән безнен. Зиратта йөрүләр дә комачаулагандыр. Килүчеләрнен төгәл исемлеген төзергә кирәк булачак, әйбәтләп әзерләник—бәйләнерлек булмасын.

Шунын белән халык таралды... Нәҗмиев, ишек янында Сөембикәне туктатып:

—Иптәш Сабитова, партком бүлмәсенә кереп чыгарсыз әле,—диде.

Машинада конторага таба барганда, ул Сөембикәне ничегрәк чыгырыннан чыгару турында хыялланып барды. Аны секретарьлыктан китәрлек дәрәҗәгә житкерергә иде. Кәрамнен тырышулары беренчене саклап калу өчен дип анлашылырлык булсын. Партком бүлмәсенә кергәч, ул Нуриевка бармак очы белән генә хәрәкәт ясады, тегесе, чиерткәнгә тәгәрәгән борчак кебек, ишектән чыгып юк булды.

—Утырыгыз, Сөембикә Даутовна,—диде Нәҗмиев, үзе партком секретаренын урынын биләде.—Яна ел якынлашканда, безгә бүләк әзерләдем, дисезме?

Нәҗмиев Сөембикәгә мәкерле караш ташлады.

—Нинди бүләк сөйлисездер—анламыйм...

—Кайнагагыз белән берләшеп, иптәш Арслановны әйләндереп төшермәкче буласыз, димәк?

—Аллам сакласын!—диде Сөембикә, көлемсерәгәндәй итеп.—Сез бит үзегез сайлаучылар жыелышларында катнашырга кирәк булачак, дидегез. Мине чакырдылар—килдем.

Нәҗмиев тә мыек астыннан елмайгандай итте, алдындагы кәгазьгә ручкасы белән тәртипсез сызыклар сызды.

—Мин барысын да иптәш Арслановка житкерергә тиеш булам.

—Житкерегез...—Сөембикә башын югарырак күтәрде.—Мин бернинди дә ярамый торган эш эшләмәдем. Ә менә сез сайлаулар турындагы положениене тупас боздыгыз.

—Сез аны ныклабрак укып карагыз әле. Әгәр үзегез генә төшенеп житә алмасагыз, элекке ирегезгә мөрәҗәгать итегез.

Сөембикә чәчрәп урыныннан сикереп торды:

—Сезгә әзрәк чама белергә кирәк! Үзегезнен апагыз белән адәм көлдергәнегезне онытмагыз.—Сөембикә кызу-кызу атлап чыгып китте, ишекне шартлатып япты.

Нәҗмиев башын чайкап куйды. Сабитованы котыртам, дип үзенен бакчасына таш төшерде. Ташнын да нинди генә әле! Ачуын басарга Нуриев кереп килә иде. Шәймөхәммәтов белән икесен райкомга алып кайтып, Арсланов белән алмаш-тилмәш туйганчы тиргәгәннәр, тагын шулай кылансагыз, гариза язарга туры килер, дип кисәткәннәр иде инде. Бүтән әйтер сүзе булмаса да, Нәҗмиев бу көе генә кайтып китә алмады.

—Син шушында гомер буе эшлисен, Нуриев,—диде ул бармак янап.—

Халыкның бозылуына син сәбәпче. Алар хәзер беркемгә дә баш бирми. Эшеңнән генә кит, аларның берсе дә сиңа сәлам бирмәячәк.

Нуриев башын иеп, кып-кызыл булып, тын алырга да куркып торды. Аннары Нәҗмиев, таякны артыграк бөгеп ташлаганын абайлап, сүзне капма-каршы юнәлештә алып китте:

—Утыр әле, Сабирҗан Закирович... Сиңа да катырак сүзләр әйтелде. Мондый чакта ычкына инде ул. Эшеңнән кууга да барып җитмибез.—Нуриев, куркынган күзләрен бераз күтәрә төшеп, аңа аптыраулы карашын юнәлтте.—Халыкка каршы бара алмассың. Чоры башка, әйбәтләп положениене өйрән, һәр пунктын туры китереп, җыелышыгызны җыегыз.—Шушы урында Нәҗмиев кинәт кычкырып җибәрде:—Матри, боларны мин сиңа әйтмәдем! Аңладыңмы?—Нуриевның сүз әйтерлек хәле калмаган иде инде, "әйе, аңладым", дигән мәгънәдә баш селкеп кенә куйды.—Шаулама, үзеңне саклыйм дисәң, ләм-мим беркемгә ычкындырма. Акрын гына үз линияңне алып бар.

Әйтергә теләгәннәрен сендергәч, саубуллашып та тормыйча, Нәҗмиев партком бүлмәсеннән чыгып китте.

***

Яна ел җитә башласа, иске ел елгырлана, койрыгын тоттырмый башлый. Арсланов Казанда кинәшмәдә бер көн вакытын югалтты. Икенче көнне яңа елга, сайлауларга әзерлек буенча көне буе хуҗалык җитәкчеләре белән аерым, партком секретарьлары һәм авыл Советы председательләре, секретарьлары белән аерым киңәшмә уздырырга, аннары Әлмәткә газ оешмасына чыгып китәргә туры килде. Менә бүген хуҗалыкларда йөрергә дип кенә торганда, иртәнге алтыдан кабул итү бүлмәсенә унлап кеше килгән булып чыкты. Ул бүлмәсенә кереп җиткәнче үк, зыр-зыр килеп, ике телефон берьюлы шылтырый иде. Бер тотам көн үтте дә китте. Сәгать өчтә утлар яндырып, инде секретарь кызга башка кеше кертмәскә кушып, ул өстәленә өелгән кәгазьләргә иелде. Шул вакыт ишектән дөпелдәп Чукаева килеп керде һәм, җил-җил атлап, аның каршына килеп басты. Арсланов, үзе дә сизмәстән, астан очлы таяк белән төрткәндәй, дөртләп сикереп торды.

—Исәнмесез, узыгыз,—диде ул, каушавыннан ни әйтергә белмичә.

Ветераннар җыелышында аның беркөнге чыгышын Нәҗмиев сөйләгән иде инде. Ниятенә кереп тотынса, ул ярты районны Арслановка каршы аякка бастыра ала. Сайлау кебек кайнар кампанияләр булмаганда, Чукаеваны зарарсызландыру зур проблема булып тормый. Әмма хәзерге ситуациядә ул ялгыш кагылсаң шартларга әзер торучы мина белән бер иде.

—Иптәш Арсланов, ни өчен сезнең работникларыгыз партия линиясенә каршы эш алып баралар?—диде ул, ике кулын Арслановның борын төбендә болгый-болгый.

—Зинһар утырыгыз әле, тынычлап сөйләшик.

—Ярар, утырыйк,—диде Чукаева, аңа буйсынып.

—Сез кемне күздә тотасыз?—дип сорады Арсланов.

—Кәрәм Нәҗмиевны. Беркөн ветераннар җыелышында тузга язмаган сүзләр сөйләп ята.

—Без инде аның хатасын төзәттек,—диде Арсланов, мөмкин кадәр ягымлы булырга тырышып.—Бәлкем чәй керттерергәдер?

—Кирәкми!—дип кычкырды Чукаева.—Син мине чәй белән алдый алмассың. Пешкән су минем үземдә дә җитәрлек. Ә менә пешмәгәне түбәдән агып утыра.

—Анысын да беләм. Төзәттерербез...

—Түбә генә түгел, абзар-куранын да рәте калмаган минем.

—Аларын да рәтләрбез.

—Әллә үзең рәтлисеңме?—диде Чукаева мыскыллап.

—Кушармын.

—Кайчан? Бер сүз белән җавап бир!

Арсланов бераз уйланып торды. Бик теләсә, ул иртәгә үк МСО начальнигын чакырып, Чукаеваның ихатасын ремонтлаттыруны оештыра ала. Ләкин моның икенче ягы бар, ул бит рәхмәт әйтәсе урынга: "Менә күрдегезме, сайланасы килгәч, Арсланов нишләде. Ничә ел ялынып йөреп, ремонтлатмаган иде, бер атна эчендә ялт иттеләр дә куйдылар",—дип бөтен Болынкырга сөйләп йөриячәк. Кешеләрне алып килеп, шуны күрсәтәчәк, бу инде сайлауга чын мәгънәсендә тискәре агитация булачак. Кылган игелеген белән Чукаева сина күсәк белән кундыргандай итәчәк. Шуна күрә ул:

—Бер селтәнүдә генә хәл итә торган булса, мин иртәгә, дияр идем. Яна ел алдыннан эш өстендә эш, һич житешеп булмый, диде.—Февраль айларында һичшиксез ремонтлаттырырбыз.

—Соңгы мәртәбә ышанып карыйм сина. Әгәр сүзендә тормасаң, ике арадагы койманы ботарлап, үземнен урам янына кагачакмын.

Чукаева чыгып та китәргә өлгермәде, Сөембикә килеп керде. Ул бик борчулы иде. Бер сүзсез Арслановның алдына урталай бөкләнгән кәгазь китереп салды. Ул анда үзен округ сайлау комиссиясе секретарьлыгыннан азат итүне сораган иде. Арсланов аптырап күзләрен аның ягына күтәрде:

—Бу нәрсә була соң инде бу, Сөембикә? Мин "Биектау"да Нәҗмиев белән телгә килгәнегезне беләм, ләкин бит аның минем өчен тырышканын син аңларга тиеш. Нигә инде гариза күтәреп керергә?

—Минем үземне Нәҗмиевтан мыскыллатасым килми.

—Ярый, ярый,—диде Арсланов, ниндидер бирешүчән тон белән.—Телисеңме, мин аны синнән гафу үтендерәм.

—Кирәкми мина аның гафуы. Мине азат итегез.

—Ачуланма, Сөембикә, булдыра алмыйм. Бу исемлек күптән Казанда расланды. Безне авыр хәлгә куйма инде син.

—Хәзерге вакытта халыкка шулай ташланмыйлар. Бу сезнең абруегызга суга.

—Менә бусын син дөрес әйтәсең,—диде Арсланов.—Аның артык тырышып ташлый торган гадәте элек-электән бар. Шулай да без аңа сабак бирик әле.

Трубканы күтәреп, Арсланов Нәҗмиевны чакырды. Кулына кәгазьләр тоткан Нәҗмиев шундук кереп тә житте.

—Сезнең беренче хезмәт нәтиҗәләрегез күренә дә башлады, Кәрәм Нәҗмиевич!—диде ул, Сөембикәнең гаризасын аңа биреп.—Без бик зур авырлыклар белән Брест солыхы төзедек. Ә сез аны җимерәсез.

—Кызган чакта була инде,—диде Нәҗмиев.

—Булган икән, Сөембикә Даутовнадан гафу үтенергә кирәк.

Ачудан Нәҗмиевның күзләре түгәрәкләнде, ул карашын әле беренчегә, әле Сөембикәгә юнәлтте. Ул мондый ук түбәнсетүне көтмәгән иде.

—Сез нәрсә, Минзаһит Усманович?!—диде ул, сүзләрен теш арасыннан гына чыгарып.—Әгәр райкомның оештыру бүлеге мөдире һәр кешедән гафу үтенә башласа...

Арсланов аны тупас бүлдерде:

—Хәзер дискуссия оештырабызмы?

—Оештырмыйбыз. Ләкин мин гафу үтенерлек гаебемне күрмим,—диде Нәҗмиев һәм кискен генә борылып чыгып китте.

—Кая әле мин сине "Әпипә"гә биетим.—Арсланов тагын трубкага үрелде, ләкин Сөембикә аны туктатты:

—Зинһар чакырмагыз, Минзаһит Усманович,—диде.—Ни әйтсәгез дә, ул миннән олы кеше. Ярый, мин секретарьлыкны алып барырмын. Шулай да халык бер нәрсәне бик ачык сизә бит.

—Нәрсәне?

—Сезне сайлату өчен райком бик нык тырыша. Альтернатив кандидат куйдырмауны да халык өнәми. Бу нәрсә сезнең хуплаудан башка эшләнми бит инде.

—Турыдан-туры әйтүең өчен рәхмәт. Менә мин чын-чынлап таянырдай

кеше син генә икәнлегенә тагын бер мәртәбә ышандым. Рәхмәт анысы өчен. Ә нишләргә соң?

—Гадел көрәш алып барырга кирәк. Әгәр ике кандидат күрсәтелсә, сез узмам, дип уйлыйсызмы?

—Әлбәттә, узмыйм,—диде Арсланов, тавышын күтәреп.—Минем ин хокуксыз кеше икәнемне беләсенме син? Барып чыккан алкашны да профсоюз, закон, суд яклый. Ә алар мине гаеплиләр генә. Мин бөтенегез өчен әшәке. Чөнки эш сорыйм, миннән дә сорыйлар. Мин сезгә генә түгел, үз-үземә дә әшәке. Мин үз-үземне якларга тиеш. Теләсә ничек...—Арсланов тынып калды. Сөембикә, аның уйларын аңларга теләп, бармагы белән мангаен жыерчыкландыра-жыерчыкландыра сыпырып утыра иде.—Ә бит гел игелеккә омтылдым. Кемнең әшәке буласы килсен? Гомер буе шушы ике аралыкта газапландым. Игелек белән яманлыкның уртасында. Минем урында булсалар, кайберәүләр кыргый ерткычка әверелерләр иде.

Сөембикә торып басты:

—Вакытыгызны алган өчен гафу үтенәм.

—Рәхмәт керүенә,—диде Арсланов.—Кул астындагыларның күпчелеге миңа каршы. "Әйе", дип баш селкесәләр дә, кесәләрендәге куллары йодрыкланган, янымнан чыгу белән мине чәйнәргә керешәләр. Шулай икән, мин гуманлы булып утыра алмыйм. Мин үз-үземне суяр дәрәҗәдә батыр да түгел...

Арсланов Сөембикәне ягымлы карашы белән озатып калды. Ярты сәгатьтән ул Нәҗмиевны үзенә чакырды. Ул гадәттәгечә түргә узмады, бүлмәнен яртысында туктап калды. Йөзе ачулы, ә гәүдәсендә нindидер салынкылык сизелә, үзе уң як тезен әле алга, әле артка калтыратып тора иде.

—Сез дә бик тиз жимерелә башладыгыз, Кәрәм Нәҗмиевич,—диде Арсланов, канәгатьсезлек белдереп.

Нәҗмиев аның шул сүзләрен көтеп кенә тора иде, дөртләп кабынып та китте:

—Гафу итегез, Минзаһит Усманович, теләсә кем алдында баш иеп, аклану сүзләре сөйләрлек булсам, миңа оештыру бүлеге мөдире булып утырырга да кирәкми. Ул үгетләү урыны түгел, үгетләү өчен әнә безнең пропаганда бүлеге Миңнуллин бар...

—Йә инде, йә инде! Нинди авырлыклар белән куйганны беләсең бит Сабитованы. Гафу итегез, дигән ике ялган сүзең житә иде.

—Минем андый сүзне беркемгә дә әйткәнем юк һәм әйтмәячәкмен дә.

—Син әйтмәсәң, менә мин әйтәм,—диде Арсланов йомшап.—Аңардан гафу үтенмәсәң, мин синнән гафу үтенәм.

—Рәхмәт,—дип куйды Нәҗмиев.

—Әйдә, утыр әле. Безгә бүгеннән үк эш башларга кирәк, "Биектау"да дим. Сезнең планыгыз юкмы?

—Коммунистлар белән сөйләшәсе булыр. Ул совхозның халкы бик үзенчәлекле. Теләсә каян жыелган ырдык-шырдык...

—Дөрес әйтәсең. Хәзер завларны, барлык инструкторларны жыеп ал. Бер генә коммунист та безнең сүздән чыгарлык булмасын.

Беренче яныннан чыккач, Нәҗмиев, беркемне дә кабул итмичә, уйланып утырды. Әгәр аның барлык әйткәннәрен төгәл үтәсәң, альтернатив кандидат күрсәтелмәячәк. Арслановның юлы туп-туры. Азагы да күренеп тора. Ә менә Кәрәмгә нишләргә? Бармаклары белән өстәлне шакылдатып, ул әллә нинди көй чыгарган кебек итте, теш төпләрен суырды, бүлмә буйлап йөреп килде. Үзе элек ничек башлаган булса, шуны дәвам итүдән башка чара юк иде: шартлатып сындырганчы бөгәргә! Барлык партия нормаларын, сайлау положениеләрен, сайлаучыларның хокукларын бозар дәрәҗәдә бөгәргә. Халык түзә алмыйча күтәрелсен.

Райком работниклары белән үткәрелгән киңәшмәдә мәсьәләне Нәҗмиев кабыргасы белән куйды: әгәр райком линиясен уздырырлык итеп эшләмәсәгез, кайтып та йөрмәгез, дип төгәлләде чыгышын. Киңәшмә бетүгә, аны ишек төбендә район сайлау комиссиясе председателе Жиһангиров көтеп

тора иде инде. Алар бергәләп бүлмәгә уздылар. Җиһангировның тәмәке төтененә котырганын белгәнгә күрә, Нәҗмиев мөштегенә ашыкмыйча гына сигарет тыкты, кабызып, тәмләп суыргач, төтенен ана өреп җибәрде. Гомере буе аптека мөдире булып эшләгән һәм һәр сайлау саен район сайлау комиссиясен җитәкләгән бу кешене сөйми иде ул. Югыйсә анардан бер авыр сүз дә ишетелмәс, хәтта коридордан узганда аның аяк басканын да сизмисең. Нәҗмиев тагын ике мәртәбә аның ап-ак шома йөзенә таба тәмәке төтене өрде, Җиһангировның ләкләк борыны, сиргәя башлаган җирән чәчләре беразга гына төтен эчендә югалып тордылар, аннары җептәй нечкә кысалы күзлеге ялтырап китте.

—Син, Миргали Фәттахович, "Биектау"дагы инцидентны ишеткәнсеңдер инде?

Җиһангировның беркайчан да кешегә туры карамаучы, туктаусыз уйнап торучы яшькелт-зәңгәр күзләре бер генә секундка туктап алдылар, аннары кабат хәрәкәткә килделәр.

—Әйе, ишеттем... Җыелышта катнашучылар саны җитмәгән.

Җиһангиров авызын ачкан килеш, ап-ак, озын тешләрен күрсәтеп елмайгандай итте. Аның шулай торуы гомер буе Нәҗмиевта ачу уятты. Ул аны тешләргә җыенучы кыргый җанварга охшатып карый иде. Аның тешләренең аклыгы ук бөтен кешенекеннән аерылып тора, халык сүзе хак булса, иртә-кич тешләрен сидек белән юа икән, диләр.

—Шуның белән эш бетте, дип уйлыйсызмы?

—Беткән, әлбәттә,—диде Җиһангиров.

—Аны ялган имзалар белән җыйналган чара, диделәр. Сезгә тикшерергә кирәк.

Җиһангировның авыз читләрендәге күренмәс челтәр җепселләре төсле нечкә вак җыерчыклар шактый тирәнәеп, иреннәренә таба бөрелделәр. Шушыларга маңгай уртасындагы дүрт сызык та килеп кушылды, алар бергә җыерылып, терәлә язып, Җиһангировның йөзен усал кыяфәткә керттеләр. Ачуланганда аның һәрвакыт шулай була. Тәмәке төтененең унай тәэсирен уйлап, Нәҗмиев аңа мул итеп тагын төтен җибәрде. Җиһангиров сикереп торды:

—Үткән сайлауларда сез мине соңгы мәртәбә дип ризалаттыгыз. Бусында инде тәмам сезнең ишекнең бусагасын таптап туйгач, бирештем. Хәзер мин имза тикшереп йөрергә тиеш буламмы?!

Нәҗмиевка, әлбәттә, аның имза тикшермәве кирәк иде.

—Сез кызмагыз әле, Миргали Фәттахович,—диде ул юри йомшак тавыш белән.—Сине кызыктан куймадык бит инде без. Сайлауларны синнән башка бернинди ЧПләрсез кем башкарып чыга ала? Йә, әйт?

Бу мактауга түзә алмыйча, Җиһангировның ап-ак тешләре тагын күренеп киттеләр.

—Арыдым мин. Элек мондый имза тикшерүләр булмый иде.

—Чөнки элек альтернатив кандидат дигән әйбер дә юк иде. Ярый, сиңа күрсәтмә кирәкми, тик артык тырышып ташлама. Демократия заманы икәнен онытмыйк.

Нәҗмиев аны бүлмәсеннән кул биреп озатты...

Кич эштән кайтырга инде киенеп маташканда, бүлмәгә "Биектау"ның директоры Шаймөхәммәтов килеп керде.

—Нәрсә бар?—диде Нәҗмиев, урынына утырмыйча гына.

Фаиз аңа хатыны ягыннан туган тиеш, берәр төрле шәхси үтенече бардыр, дип уйлады ул.

—Болай булса, мин эшли алмыйм, Кәрәм Нәҗмиевич!—дип кычкырып җибәрде Шаймөхәммәтов, йөзен җимереп.

Нәҗмиев аңа утырырга кушты, үзе дә, өстәл артына кереп, урынын алды.

—Ни булды?

—Ярты көн буе сезнең пропаганда бүлеге Миннуллин тәмам чыгырымнан чыгарды.

—Син аңлатыбрак сөйлә әле.

—Ул һаман шул җыелыш өчен инде. Сез әйткән сүзләр өстенә тагын әллә нинди гаепләр ташлый. Мин хатын урынына кул куйган идем, "син сайлаулар кампаниясенә саботаж оештырып ятасың, беренче секретарьга каршы оппозиция төзегәнсен", ди.

—Хатының урынына кул куйган иденмени?

—Куйган идем шул. Ә ул Казанда, укуда. Аннары синең яшерен колхозлар советында член булып торганыңны да беләбез, ди. Ачыклап бетергәч, суд алдына басачаксың, ди. Күп инде!..

—Совхозда тагын нәрсәләр бар соң?—диде Нәҗмиев кызыксынып.

—Нәрсә булсын, халык аптырашта. Күпләре: яңадан бер җыелышыгызга да килмибез, диләр. Берәм-берәм, төрлечә куркыталар. Мин эшли алмыйм бу хәлдә.

Нәҗмиев Шәймөхәммәтовның сипкелле, түгәрәк йөзенә шактый вакыт карап торды, тагын сигаретын кабызып, тирән итеп тәмләп суырды.

—Сине ул урынга кую өчен минем нинди юллар белән эш иткәнне син, Фаиз энем, белеп бетермисең. Хәзер син исәр Нәбиуллинның күрсәтмәләрен үтәп, чатыр чабарга тиеш идең. Син моның аермасын аңлыйсынмы?

Фаизның сипкелле йөзе кып-кызыл булды.

—Аңлыйм,—диде ул, башын аска иеп.

—Шулай булгач, син миңе игътибар белән тыңла. Миннуллинның куркытуларын оныт. Сиңа совхоз кешеләренең чын ышанычын яуларга кирәк. Мин дә, башкалар да куркытырбыз, төрлечә сүгәрбез, син бүтәнчә булмаганын аңлыйсың. Әнә абзаң миннән берничә генә адымда утыра, ул кушкач, кая барасың? Ә сез тыныч кына эшләгез.—Нәҗмиев, имән бармагын селкетеп, Фаизны үзенә чакырды, урыныннан торып, тегесе аның каршына килде.—Эшләгез элеккечә,—диде пышылдап Нәҗмиев.—Сезнең берниндә дә закон бозганыгыз юк. Халык теләгән икән, күрсәтсеннәр, партия шуны таләп итә, ил буенча шул бара. Ә без монда, бер кешенең сүзеннән чыга алмыйча, агымга каршы йөзеп маташабыз. Сез хаклы булачаксыз.

Алар икесе дә тураеп бастылар.

—Бу сүзләрне үлгәндә дә чыгарырга ярамаганын аңлыйсың...

—Аңлыйм,—дип пышылдады Фаиз.

—Түзә алмаслык кыен хәл килеп чыкса, тагын мөрәҗәгать итәрсең. Ә совхоздагы хәлләрне миңа әйтеп торырсың. Очрашу урыны—Зирекле күл. Беләсеңме син безнең Зирекле күлне?

—Әйе, беләм.

Нәҗмиев Фаизны озатып шактый вакыт узгач кына эштән кайтып китте...

***

Ирек ишек алдында кар көрәп йөри иде. Капкада Назыйм Әшрәфҗановның озын гәүдәсе күренүгә, ул көрәген читкә куйды.

—Мине сезнең янга аптыраганнан җибәрделәр,—диде ул күрешкәч.—Хәзер Наратбашта халыкны чын мәгънәсендә куркыту бара. Район сайлау комиссиясе члennары, райком инструкторлары, милиция начальнигы кешеләрдән сорау алалар, җыелышка катнашырга теләүчеләрдән кабат имза җыялар. Җыелышны уздыртмас өчен кан-мәмер киләләр. Ә кандидат күрсәтергә дүрт көн вакыт калды.

Ирек аның белән чыгып китте дә, Вафинның өендә тиз генә иҗтимагый үзәк члennарыннан алты-җиде кеше җыелып, бер катгый фикергә килделәр. Наратбашта кандидат күрсәтергә сайлаучылар саны җитми. Элекке җыелышта катнашкан кешеләрнең дә хәзер шактые ул адымны ясамаслык иткәннәр. Район үзәгендәге шул округка керүче катнаш азык заводы, юл бүлеге коллективларын Наратбашка кандидат күрсәтү җыелышына алып барганда, эш җинел генә хәл ителәчәк. Шул карарга килгәч, Вафин юл бүлегенә, Ирек катнаш азык заводына китте. Ирек барып кергәндә,

Хамматов түтенгә күмелеп тәмәке тартып утыра иде. Кул биреп күрешкәч, Ирек ана үзенең әле генә иҗтимагый үзәк вәкилләре белән үткәргән кинәшмә хакында әйтте. Ул җитәкләгән коллективның Наратбашта булачак җыелышта катнашу мәсьәләсен әйткәч, Хамматов тәмәкесен көл савытына куйды да уйга батты. Аннары кискен генә башын күтәреп:

—Сез моны барып чыгар, дип уйлыйсызмы?—дип сорады.

—Барып чыгачак,—диде Ирек.—Кандидат күрсәтү җыелышында кимендә өч йөз кеше катнашу кирәк.

—Сез мине анламадыгыз,—диде Хамматов.—Мэлс Сабитовның сайлануы барып чыгармы?

—Анысы инде халыктан тора,—диде Ирек.

Хамматов, күз карашын идәннән ерак почмагына төбәп, тагын хәрәкәтсез калды. Бармагы белән күлмәк якасына кереп, галстугын читкә тартты.

—Димәк, Арсланов калган очракта миңа көн бетә дигән сүз.

Хамматов кайсыдыр районнан гаиләсе белән күчеп килде, заводны төзеп бетерде, квартира алды. Сайлаудан соң шушыларның бөтенесен чәлпәрәмә китереп, аны Арсланов районнан кумас, дип кем ышандыра ала?

—Гаделлек халык ягында бит,—диде Ирек, бераз җанланып.—Без җиңәргә тиеш!

—Җиңү сүзе матур инде ул. Кайчакта аның азагы гына бик начар булып куя. Беләсезме, мин бит инде өченче мәртәбә районнан районга куылам. Менә шул гаделлек дигән һавадагы бик матур кошка кызыгып үреләм дә, кулымнан тотып артыма тибәләр.—Ул тагын сүзеннән туктап, уйланып торды.—Мин кайчандыр бер тотарга тиеш бит инде ул кошны. Әйдәгез, тәвәккәлләп карыйк.

—Яратам сезнең кебек кешеләрне,—диде Ирек, ана кул биреп.

—Югарыдагылар яратсын иде ул... Мин иртәгә коллективны җыеп сөйләшермен.

Ирек шундук Әхнәфкә шылтыратты. Ул эш урынында юк иде.

—Шайтан алгыры! Барып чыкмый бит әле бу,—диде Ирек сызланып.

—Нәрсә барып чыкмый?

—Миңа бит бүген үк Наратбашка барып, җитәкчеләрне күрергә кирәк, җыелышның көнен билгеләргә.

—Соң әйдәгез, икәү барып кайтабыз,—диде Хамматов.

—Сезне борчу булмасмы соң?

—Әйттем ич инде: гаделлек дигән кош артыннан мин җир читенә дә барырга риза...

3

Декабрьнең соңгы көннәре коточкыч салкын булды. Зәнфирә әтәч белән тавыкларны, аяклары өшемәсен дип, мунчага кертте. Ишек алдыннан әйләнеп кергән арада да суык чатнап борынга, битләргә, кулларга ябыша. Ирек чоланнан киез итеген эзләп алып керергә мәҗбүр булды. Кат-кат киенеп, китәргә дип ишек алдына чыккач та ул бераз басып торды. Күк йөзе чалт аяз, шулай булса да ул, салкыннан куырылгандай, зәңгәр төсен югалткан, аксылланып тора, кояш әллә ничек божраланып, колакланып чыгып килә. Морҗалардан күтәрелгән төтен югарыга төз багана шикелле сузыла. Табигать тып-тын, хәтта кошларның да очканы күренми; кимендә кырык градус, дип уйлады Ирек, Болынкыр урамыннан атлый-атлый. Очраган кешеләрнең бүрекләренә, шәлләренә, кашларына, пәлтә якаларына бәс сарган, борыннарыннан аксыл пар бөркелә.

Заводка барып җиткәндә, инде автобус кабызылган, аның бәсәргән тәрәзәләреннән берни күренмәсә дә, эшчеләрнең утыра башлаганын абайларга була иде. Ирек юлында очраган кешеләр белән кул биреп күреште дә Хамматов бүлмәсенә керде.

—Унбиш минуттан кузгалабыз,—диде ул.—Юл бүлегеннән дә шылтыраттылар, җыелып бетә язганнар.

Нәкъ билгеләнгән вакытта өч автобус тезелеп юлга чыкты. Ирек алдагысына утырды. Ләкин Болынкырны чыкканда ук аларны биш-алты милиционер туктатты. Документларны тикшерүче ГАИ начальнигы үзе иде.

—Кая барасыз бу кадәр халык белән ял көнне?—диде ул Хамматовка.

—Экскурсиягә,—диде Хамматов серле генә.

—Биредә Наратбашка, дип язылган, нәрсә, анда Эрмитаж юктыр бит?

—Экскурсия Эрмитажга гына ясаламыни?

—Кире борылыгыз,—диде ГАИ начальнигы.—Бүген көн салкын булу сәбәпле, автобусларга йөрү тыела. Казаннан шундый күрсәтмә.

Инде дөресен әйтмичә ярамый иде. Ирек арттан килүче ике автобусны да туктатып тикшергәннәрен күрде.

—Без сайлау алды җыелышына барабыз. Хәзер анда халык көтеп тора. Туктатырга хакыгыз юк,—диде Ирек ГАИ начальнигына.

—Сезнең үз бурычыгыз, минем үз бурычым.

—Сезгә беркем дә мондый күрсәтмә бирмәде.

—Ә сез каян беләсез, иптәш Сабитов?—ГАИ начальнигы ялан кулы белән бәсәргән керфекләрен, кашларын сөртеп куйды.

—Димәк, җибәрмисез?

—Шушы салкында юкка гына чыгып баскан дип беләсезмени безне?

Борылудан башка чара калмады. Ирекка бер тәвәккәл уй килде. Хамматовның колагына:

—Тегеләргә барып әйтегез, безнең арттан калмасыннар,—диде.

Хамматов кергәч, алар Болынкырга юнәлделәр.

Ирек урыныннан торып басты да автобуста утыручыларга йөзе белән борылды:

—Безнең ТИҮнең дүрт яшел флагы бар,—диде ул.—Шуларны күтәреп, райком каршына барырга кирәк. Арслановның үзен чакырып чыгарып сөйләшәбез.

—Дөрес! Аның кикриген шиндерергә вакыт!

—Ә эштән кусалар?—диде берсе куркыбрак.

Фикер алышу озак бармады. Барысы да Ирекнең тәкъдименә кушылдылар. Ул, автобусны Җаббар Саттаровның өенә туктатып, флагларны алып чыкты. Икесен арттагы автобустагы кешеләргә бирде һәм планны аңлатты. Райкомга якынлашкач, автобусларның өчесен дә күрше урамда калдырдылар да, флагларны күтәреп, җәяүләп, райком бинасына юнәлделәр. Иң алдан иҗтимагый үзәк членнары атлады. Менә алар райком каршына килеп туктадылар. Ирек, җиде-сигез кешене ияртеп, райком бинасына керде. Икенче катка күтәрелгәндә, аларның каршысына кулына кәгазьләр тоткан Нәҗмиев килеп чыкты.

—Ял көнендә нинди җилләр ташлады?—диде ул, барысы белән дә кул биреп күрешкәч.

Оештыру бүлеге мөдиренең йөзендәге шатлык галәмәтләрен күреп, Ирек моны нәрсәгә юрарга да белмәде. Нәҗмиев аларны җәзалау ләззәтенең якынаюыннан шатлана, дип уйлады ул һәм: хәлне аңлатып, үзләренең Арсланов белән очрашырга теләүләрен әйтте.

—Ну что ж,—диде Нәҗмиев, һаман да йөзенә ачу чыгармыйча.—Барысы да разумно. Минзаһит Усманович белән сөйләшәм. Ул сезне аңлар, дип уйлыйм.

Арсланов инде баядан бирле тәрәзәгә капланган һәм җиңелчә калтыраган куллары белән туктаусыз тәмәке тарта иде. Эченнән карар да кабул итеп өлгерде: "Чыгып сөйләшергә, нинди генә шартта булса да, шау-шуны басарга." Ул инде Наратбашта җыелыш әзерләнгәнен дә, анда кемнәр барасын да белә, мең төрле вариантта саклык чаралары эшләнгән иде. Ләкин менә яшел флаглар күтәреп, шушы кадәр халыкның райком каршына килүе Болынкыр тарихында, бәлкем СССР тарихында, беренче мәртәбә һәм моны оештыручы нәкъ менә Арсланов иде. Шушы уйдан аның тәннәре эсселе-суыклы булып китте. Әгәр бу хәл обкомга барып ирешсә, аны сайлауга кадәр дә тотмаулары ихтимал. Бу нинди сайлау булды бу?!

Минзаһитның егерме ел элек ташлаган тәмәкесен кабат тарта башларга мәжбүр итте бит! Бүлмәгә Нәҗмиев килеп керде:

—Ишек төбендә вәкилләр тора, сезнен янга керергә телиләр,—диде Нәҗмиев, артык дулкынланмыйча гына.

—Сез алар белән уртак тел табып булыр, дип уйлыйсызмы?—дип сорады беренче, өметсезлек белән.

—Аларның юлын бикләп кенә уртак тел табып була,—диде Нәҗмиев, кулларын йодрыклап.—Болар бит, Минзаһит Усманович, район оешмалары арасында иң өтәләүләре. Аның башкалары мондый юлга басмый да.

—Фәлсәфәнне ташла әле!—дип тупас кына бүлдерде аны Арсланов.—Безгә хәзер уртак тел табарга кирәк.

—Сез нәрсә, әллә алар белән сөйләшмәкче буласызмы?—диде Нәҗмиев, күзләрен алан-йолан уйнатып.

—Ә башкача нишлисең?

—Мин сезгә гомерем буе сокланып яшәдем, тәвәккәллегегез алдында баш идем, тик бу очракта, гафу итегез...—Нәҗмиев сүзен бүлеп, башын чайкап торды.—Бу сез түгел... бу сез түгел, Минзаһит Усманович!

—Йә, нишләп була?—диде Арсланов, Нәҗмиевның тел төбендә ниндидер отышлы нәрсә барлыгын чамалап.

—Алар бит сезне чәйнәп ташлаячак! Ишек төбегездә Ирек Сабитов басып тора. Сезнен җинелүегегез хакында иртәгә үк республика газетасында хәбәр бастырачак.

—Сузма, әйт!—дип кычкырып җибәрде Арсланов.—Алайса нишлибез?

—Берни дә эшләмибез. Таралсыннар. Җыелыш тагын сузылачак. Кирәк булса, милиция ярдәмендә таратырбыз, анысын үз өстемә алам.

Арслановның чырае бозылды, күз бәбәкләре биеште.

—Аннары Сабитовның мәкаләсе чыгамы? Аңламыйм мин сине, Кәрәм Нәҗмиевич, тәмам башымны катырдың,—диде Арсланов, ике кулы белән чигәсен кысып.

—Әгәр гаепле булсам, гафу итегез, әмма мин бер нәрсәне яхшы беләм: сезгә алар каршына чыгып баш иярг ярамый. Бу инде җинелү була. Әгәр кирәк дисәгез, райком составы белән бөтенебез чыгабыз, ләкин сез түгел.

Ул дулкынланып бүлмәдән чыгып китте, Арсланов аңа ут йотып карап калды.

Ул арада кабул итү бүлмәсендәге инструктор килеп керде.

—Керсеннәрме, Минзаһит Усманович?

—Юк,—диде ул тешләрен кысып.—Мин аларны бүген кабул итә алмыйм. Иртәгә төштән соң килерләр.

Инструктор шул хәбәрне әйткәч, Ирекләр халык алдына чыктылар. Урамда басып торучыларга ак бәс сарган, алар сикергәлиләр, битләрен уалар, ир-атларның сүгенеп-сүгенеп куйганы ишетелә.

—Арсланов безне кабул да итмәде, сезнен каршыга чыгудан да баш тартты,—диде Ирек гаепле кешедәй.

—Бәрергә дә керергә, ничу монда салкында катып торырга!

—Дөрес! Нигә ул халыктан кача?!

—Район үзәге кешеләрен җыеп, митинг уздырырга кирәк!

Ул арада чыжылдап зәнгәр билле яшел фургон килеп туктады, аннан биш милиционер сикереп төште. Алар кызу-кызу атлап, халык янына килделәр. Милиция начальнигының урынбасары капитан Галиуллин килә-килешкә Ирекка ташланды:

—Сез монда нинди демонстрация оештырып ятасыз?! Закон нигезендә мин сезне җавапка тартам!

—Ә ни өчен сезнең сотрудниклар җыелышка бара торган сайлаучыларны кире бордылар?—диде Ирек.

Ул арада берничә кеше Галиуллин янына сикереп килеп тә җитте.

—Җавап бирегез!

—Без монда эш юктан җыелмадык. Хәзер ничә сәгать буе буталып йөрибез.

Аларны өч милиционер килеп, читкә этеп алып китте.
Галиуллин тагын Ирекка ташланды:
—Кем сезгә яшел флаглар күтәреп чыгарга кушты? Бу бит политик акция!
—Дөрес әйтәсез,—диде Ирек.—Яшел флаг ул безнең татар милләтен саклау символы. Ә сайлаучыларны туктату политик акция генә түгел, партия линиясенә каршы акция булып тора.
—Санкциясез митинг үткәргән өчен сез нәрсә буласын беләсезме?
—Әле монда митингның исе дә юк,—диде Хамматов урынбасарга каршы.—Менә бу кешеләрне хәзер нишләтергә кушасыз? Ярты сәгатьтән җыелыш башлана.
—Мин бернинди җыелыш та белмим. Мин район территориясендә тәртип булырга тиешлеген, закон бозылмаска тиешлекне беләм.
Халык шаулашырга тотынды, аларның кайсысы райкомга таба омтылды, кайберләре Галиуллинны уратып алды. Кайсыдыр милиционер берсенең бүреген сугып очырып җибәрде. Теге егет милиционерны якалап ук алды. Ирек аларның арасына ташланды, егетнең кулын ычкындырып, читкә сөйрәде.
—Башны бетерәсең, син нишләгәненңне аңлыйсыңмы?—дип пышылдады ул аңа.—Баскан урыныңнан кузгаласы булма!
—Үзе ябышты! Мин—десантник,—диде егет, тавышын күтәреп.
Хафага төшеп, Ирек ике кулын да югары күтәрде.
—Иптәшләр, тынычланыгыз! Урыннарыгызга басыгыз әле,—диде.—Бернинди райкомга керү дә, митинг та юк. Хәзер мин сезнең исемнән үзәк сайлау комиссиясенә, партиянең үзәк Комитетына, КПСС өлкә комитетына өч телеграмма сугам. Безнең депутат сайлау хокукыбызны кысулары турында. Сез ризамы?
—Риза,—дип кычкырдылар бердәм рәвештә.
—Алайса таралабыз?!
—Таралырга ашыкмагыз. Мин үзем генә иптәш Арслановка кереп карыйм. Мин чыкканны көтегез.
Ирек кабул итү бүлмәсендә утыручы инструкторга өч адреска телеграмма юллаячагын әйтте. Инструктор җитез адымнар белән беренче бүлмәсенә кереп китте. Ул аңлатып бетергәнме-юкмы, ишектән башта инструктор, аннары чырае бозылган Арсланов күренде.
—Сез нәрсә оештырып ятасыз?!—дип кычкырды Ирекка чыгышлый ук Арсланов.
—Без хәзер таралабыз,—диде Ирек тыныч кына.—Соңыннан үпкәләштән булмасын, дип кисәтергә генә кердем.
Ул чыгып китмәкче булып борылуга, Арсланов:
—Туктагыз әле, Ирек Хәйриевич!—диде.
Ирек туктап артына борылды.
—Әйдәгез, аңлашыйк.
Алар бергәләп Арсланов бүлмәсенә уздылар.
—Утырыгыз,—диде Арсланов.—Нигә сез шулкадәр шау-шу тудырасыз?
—Шау-шуны без тудырмадык, без тыныч кына җыелышка барырга ниятләгән идек.
—Ну, ярый, анысы аңлашылды,—дип сүзне Арсланов икенчегә борды.—Кем инде шуның өчен ЦКга, обкомга телеграмма суга?
—Кызык фикерлисез сез,—диде Ирек, елмайгандай итеп.—Сезгә нишләсәгез дә ярый, ә гади халыкка телеграмма сугарга да ярамый. Бу ни була соң?
—Сүз ул турыда бармый.—Арсланов тотлыгып калды. Ни дә булса әйтергә кирәк иде:—Безнең әллә ничәшәр кандидат күрсәтеп, берничә мәртәбә сайлау үткәреп ятарлык мөмкинлегебез юк. Болай да эш муеннан.
—Ягез инде, Минзаһит Усманович, мин бит инде андый гына җимнәргә каба торган балык түгел.—Ирек сәгатенә карап алды.—Хәзер җыелыш башлана. Йә сез безне җибәрегез, йә мин телеграмма сугарга барам. Элемтә бүлеге начальнигына шылтыратып, аларны тоткарларга уйлый күрмәгез.

Телеграммалар күрше районнан да тапшырылачак.

Арсланов, тәрәзәгә башын борган килеш, янагын чәйнәп шактый утырды.

—Бик унайлы вакыт туры китердегез сез. Район җитәкчесен юк итим дисән, сайлаулар чорын файдалан инде син. Үзегез өчен дә, абыегыз өчен дә үч алырга ниятләдегез.

Ирек көлеп куйды:

—Әгәр шушы хәлләр килеп чыкмаса, ике ятып бер төшемә дә керми идегез сез минем,—диде ул чын күнелдән.—Мин беркайчан да үч алу белән шөгыльләнмәдем. Минем бердәнбер коралым дөреслек булды.

—Ә ник язып кына ятмыйсыз соң? Мондый ыгы-зыгы сезгә нәрсәгә кирәк?

—Әгәр дә чынлап сорасагыз, әйтәм. Моның ике зур сәбәбе бар: беренчедән, мин тормышнын уртасында кайныйм, язарга материал туплыйм; икенчесен сез аңлыйсыз—халыкка күпме вакыт сарык дип карарга мөмкин? Бу очракта, гафу итәсез, мин битараф кала алмыйм.

—Димәк, әгәр шушы кешеләр Наратбаштагы җыелышта катнашса, сез канәгатьләнәсез?

—Юк!—диде Ирек.—Халык—сарык, диючеләр урыннарында калырга тиеш түгелләр.

—Безнен районда алай диючеләрне мин белмим,—диде Арсланов, күзләрен кысып, керфек арасыннан карап.

—Алай диючеләр юк, ә шулай санаучылар бар.—Ирек кинәт эчкерсез, җылы тавыш белән:—Минһаҗит Усманович, сез бу сайлаулардан исән-имин котылырмын, дип уйлыйсызмы?—дип сорады.

—Мине атарга җыенмыйсыздыр ич?

—Үз вакытында гариза биреп кенә китегез, нервыларыгызны, йөрәгегезне саклар идегез.

—Анлашылды!—Арслановнын күзләрендә яшендәй ачулы чаткылар уйнады.—Мин циркта гы бер тәгәрмәчле велосипедта торучы кебек. Анда торунын үз законнары бар. Әгәр мин аларны кулланмасам, ягъни туктасам, егылам. Ә сез мина туктарга кушасыз. Мин ана, Сабитов, бөтен сәламәтлегемне биреп, гомер буе күтәрелдем. Сез мине атып төшерегез, аккош кебек. Анлашылдымы?

Ирек урынынан торды:

—Димәк, без килешә алмадык?—диде ул.

—Мин алай димәдем бит әле...

—Ул чакта юлдагы милиция постын алыгыз.

—Ярый, алырбыз,—диде Арсланов һәм, урынынан торып, кече бүлмәсенә юнәлде.

—Юк, Минһаҗит Усманович, мин барында әйтегез.

Арсланов туктап, Ирекка бик озак, җирәнгәндәй карап торды. Аннары телефонга барып номер җыйды:

—Хасбулатов, Наратбаш юлын ачыгыз,—диде ул җикергәндәй.—Әллә барып җитмәде? Немедленно бушатыгыз юлны! Понятно?!

Ирек анын трубканы куйганын көтте дә бүлмәдән чыгып китте. Милицияләр белән пәрмә-пәр талашып яткан кешеләр аны күргәч тынып калдылар.

—Хәзер барыбыз да, автобусларга төялеп, җыелышка китәбез,—диде Ирек.

## 4

Сабитов чыгып киткәннән соң, Арсланов, бүлмәсенә кереп, дару эчмәкче булды. Стаканга су салгач, авызына кабарга дип алган төймәне ачу белән идәнгә томырды да, суны түгеп, бер стакан аракы салды. Аны тын да алмыйча эчеп куйды, шул чакта нәрсәдер чәйнәп йотасы урынга үкенү тойгысын йотты. Бу—Ирекне партиядән чыгаруы өчен, Мәлсны эшеннән алырга тырышулары өчен үкенү иде. Әгәр шушы эшләрне

эшләмәгән булса, кече Сабитов йә редакцияне, йә берәр башка оешманы житәкләп утырган булыр иде. Кем белә, Арсланов өчен берәр китап та язар иде әле.

Ул тагын Нәҗмиевны чакырып кертте, хәлне аңлатты.

—Без үзебезнең кулдагы шансларны ычкындырдык,—диде ул.—Син Жиһангировка бер нәрсә куш...

—Нәрсә?—диде Нәҗмиев.

—Алар жыелыш документларын төшерергә тиеш булалар. Төрле сәбәп табып, алмасын ул аларны. Ике көн сузса, алар өчен полнейший провал.

—Ярый, мин сөйләшермен,—диде Нәҗмиев.—Безнең бит әле тагын бер вариант бар, Минзаһит Усманович. Ә нигә безгә тиз генә үзебезнең кешене күрсәтмәскә—сезгә альтернатив итеп?

—Ничек була соң ул үзебезнең кеше?

—Вакыты житкәч, үз кандидатурасыннан баш тарта торган кеше. Аңа биреләсе тавышлар сезгә кала.

Арсланов сүрән генә елмайгандай итте:

—Сине оештыру бүлеге мөдире иткәнем өчен мин кабат-кабат үземә рәхмәт әйтәм,—диде ул, эчендә өмет уянуын сизеп.—Шәп була бу. Тик андый кешене табарга кирәк бит.

—Табарбыз...

—Безнең вакыт бетте! Кайда андый кеше?

—Бар ул...

—Кем?

—Сезгә табына, тугрылыклы.

—Әйт инде тизрәк!—диде Арсланов түземсезләнеп.—Нәрсә син гыйшкын белдерә алмыйча интегүче карт буйдак кебек боргаланасың?

—Шәрифуллин,—диде Нәҗмиев тыныч кына.

—Шәрифуллин?!

—Әйе.

—Син аны миңа тугры дип уйлыйсыңмы?—диде Арсланов шикләнеп.

—Ә мин башка кеше күрмим. Ул инде сезгә каршы сыңар адым да атлый алмаячак, хәтта теләсә дә. Минем аның белән күп мәртәбәләр әңгәмә корганым бар. Сезне бик нык хөрмәт итә ул,—диде Нәҗмиев.—Мин әйтер идем, хәтта табыну дәрәҗәсендә.

—Ярый,—диде Арсланов.—Бусы бер вариант, ә башкасы?

—Башкасын сез әйтәсез инде, Минзаһит Усманович.

—Өлфәт Жәмилов ничек?

—Жәмилов—әйбәт әләкче. Әгәр без аны шундый югары урынга кандидат итеп күрсәтсәк, коммунистлар безнең йөзгә төкерер, район халкы кычкырып көләр. Һәр нәрсәнең чамасы бар.

Арслановның башында баядан бирле Нәбиуллин фамилиясе бөтерелә иде, Нәҗмиевның бу сүзләреннән соң ул аны әйтеп тә тормаска булды.

—Без план корып утыруын утырабыз. Шәрифуллин риза да булмаска мөмкин әле.

—Син инде аның белән үзең сөйләшеп кара, Кәрәм Нәҗмиевич,—диде ул.—Ситуацияне аңлат. Мин аңа “Авангард”ка барырга кушкан идем, киткәнче сөйләш әле.

—Хәзер,—диде дә Нәҗмиев юк булды.

Бүлмәсенә чыгып, ул тәмәке тартырга утырды. Зәңгәр төтенгә күмелеп уйларына чумды. Әгәр Шәрифуллин каршы килсә? Аның алдында торган иң кыен мәсьәлә шушы булачак. Чөнки беренчегә альтернатив кандидат булу ул инде аңа мылтык төзәгән кебек. Аны каптыруның бер юлын белә, тик бу хәтәр юл. Әгәр Шәрифуллин теленнән ычкындырса, Нәҗмиев райкомнан китәргә тиеш була. Ул Шәрифуллинның күзләрендә югарыга омтылу очкыннарын бик ачык сизә. Казаннан килгән кешеләр тирәсендә ничегрәк бөтерелүеннән, банкетларда нindирәк сүзләр әйтүеннән, кайсылары белән бик якын торырга, кайсыларыннан ераклашуыннан аның үзе утырган баскычтан түземсезлек белән өскесенә сикерергә теләвен чамалый.

Ул шушы уйлар белән икенче секретарь бүлмәсенә керде. Шәрифуллин кулына пальтосын тоткан, чыгып китәргә әзерләнә иде.

—Пальтонны куеп тор әле, Әхнәф Хәсәнович,—диде ул түргә узып. Секретарьны куркытмас өчен ул сүзне уйнатыбрак башларга булды.—Хәзер сез мина рәхмәт әйтәчәксез...—Анын ирендәре көлемсерәгәндәй булды, сул күзе серле генә кысылды.—Мин сезнең өскә әкәләле имән аударырга булдым.

—Анлатыбрак сөйләгез әле.

—Райком каршындагы шау-шу турында без сезнең белән киңәшкән идек инде. Һәрбер ызгыш нинди дер уңай нәтиҗә бирә. Минзаһит Усмановичка хәзер үзенә тагын бер альтернатив кандидат күрсәттерүдән башка чара калмады. Ләкин бу кандидат анын кешесе булырга тиеш. Мин тоттым да сезне тәкъдим иттем. Йә, рәхмәт әйтәсезме?

Анын бу сүзләренә Әхнәф илтифатсыз калды. Һәрхәлдә ул тыштан шулай күренә иде.

—Ышанычыгыз өчен рәхмәт,—диде ул битараф тавыш белән.—Мин үземнең абруйны төшерергә җыенмыйм әле.

—Ялгышасыз, Әхнәф Хәсәнович!—диде Нәҗмиев, имән бармагын анын йөзе каршында уйнатып.—Сез мине тыңлагыз әле. Бүген Сабитовны Наратбашта күрсәтәләр. Безгә билгеле булганча, берсекөнгә аны РСФСР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итәләр.—Бу сүзләрне ишетүгә, Әхнәфнең йөзе җанланып китте, моны Нәҗмиев аермачык күрде. Шуна күрә ул сүзен дәртләнеп дәвам итте:—Сабитов Наратбашлыларга отказ бирергә тиеш була, чөнки ана район Советы депутаты булмыйча ярамый. Шулай итеп сез икәү каласыз һәм бу сайлау Шәрифуллин файдасына бетәчәк.

Әхнәф бераз уйланып торды:

—Шулай булгач, монын үзе өчен әйбәт бетмәячәген Минзаһит Усманович аңламыймыни?

—Тс-с-с!—диде Нәҗмиев шыпырт кына.—Баш буталган чакта анын йокы тамырына басарга кирәк. Райкомга саф кан җибәрергә вакыт ич инде.

—Белмим, белмим,—диде Әхнәф, анык кына бер фикергә килә алмыйча.—Әгәр ул сизенсә?

—Сизенсә дә, анын өчен башка вариант юк. Альтернатив кандидат белән көрәшмәгән район җитәкчесе, дөресрәге, ул көрәштә җиңмәгән җитәкче бүгенге көн лидеры булып кала алмый. Кыскасы, минем тәкъдим мондый: сез башта ризалык бирмичә тартышкан булыгыз, аннары инде сынган булып кыланырга кирәк. Үз кандидатурамны барыбер алачакмын, диярсез.

—Ризалашсам, мин үз кандидатурамны барыбер алачакмын, Кәрәм Нәҗмиевич.

Нәҗмиев бу сүзләрне көтмәгән иде, әлбәттә. Ләкин Шәрифуллин үз кандидатурасын алган сурәттә дә Кәрәм бит очачак кына: димәк, икенче секретарь да анын кулына килеп капты, дигән сүз. Алар инде яшерен сүзләрен уртаклаша торган, гомуми максатлар белән эш итә торган әшнәләргә әвереләчәкләр. Ә инде ул сайлауларда откан сурәттә, теге имән Нәҗмиевнын үз өстенә дә авачак. Башынны эшләткәндә, бер үк нәрсәдән әллә ничә төрле отыш алып була.

—Анысы сезнең эш,—диде Нәҗмиев.—Минем киңәшне тоту-тотмау да сезнең эш. Пальтогызны салып куегыз. Хәзер ул сезне чакыртачак.

Нәҗмиев кереп, Шәрифуллин белән сөйләшүне әйткәч, Арсланов:

—Нигә карыша икән?—дип куйды.

—Ул бит сезнең җинәсене белә, Минзаһит Усманович.—Елмаюдан Нәҗмиевнын уң күзе нык кысылды.—Ризалашса, сезнең урынга нияте барлыгын күрсәтә. Абруй күтәрә торган нәрсә түгел ич инде бу.

—Башка кеше эзлибезмени?

—Минем уйлавымча, үзегез сөйләшсәгез, карыша алмас ул. Шәрифуллин сезне артык нык хөрмәт итә.

Нәҗмиевнын бу сүзләре беренченең күнеленә сары май булып ятты. Биш минуттан Әхнәф анын бүлмәсендә иде инде.

—Мин сезне уң кулым дип йөри идем, Әхнәф Хәсәнович,—диде Арсланов, аның күзләренә туп-туры карап.—Уңай җавап көттем, әмма Нәҗмиев куандыра алмады...

—Аңлагыз, Миңзаһит Усманович, сезнең кул астында эшләүче секретарь буларак кына түгел, гади кеше буларак та мин ничек шушы адымга барыйм? Сездәге тәҗрибә, тирән фикерләү, принципиальлек... Һәм мин, комсомолдан килеп эшли башлаган кеше, калай әтәч кебек, "Мин Арслановтан өстен!" дип кычкырам. Бу бит адәм көлкесе!

—Ягез инде, Әхнәф Хәсәнович, артык әдәбиятлаштырып җибәрмәгез. Сез моның кирәклеген аңлыйсыз. Ну, вакыты җиткәч, үз кандидатурагызны алырсыз. Халык аңламый калмас.

Әхнәф башын аска игән хәлдә тора бирде. Аның иреннәре кыймылдап куя, кашлары сикергәли, эчтән тирән дулкынланганы сизелә иде.

—Иртәгә җавап бирергә рөхсәт итегез,—диде ул, урыныннан торып.

—Булмый, Әхнәф Хәсәнович,—дип сузды Арсланов.—Бүген төштән соң җавап бирегез, вакыт кысылды.

***

Наратбаш культура йорты халык белән шыгрым тулган, кемнәрдер ишек төбендә тәмәке тартып торалар. Бөтен дөнья ак бәс белән капланган. Ирек белән Мәлс кочаклашып күрештеләр. Исемлек буенча бүгенге җыелышта өч йөз егерме җиде кеше катнаша иде. Аны партком секретаре Нуриев ачты һәм алып барды. Шушы кадәр озак әзерләнгән, мең мәшәкать белән җыелган җыелыш кырык минутта бетте дә китте. Мәлсны бөтен халык дәррәү аягүрә басып, озаклап алкышлады. Ризалык бирүен сорагач, ул трибунага чыкты:

—Бүген тышта утыз сигез градус салкын, ә минем өчен ул җәйге җылы җилләр исеп торган иген кырын хәтерләтә,—дип башлады Мәлс.—Бик тә сагынган икәнмен мин сезне. Миңа бу көннең җылылыгы тагын сезнең күрсәткән олы ышанычыгыз белән дә бәйле. Яшереп тормыйм, мин риза. Сайланаммы-юкмы, анысын әйтеп булмый, әмма ничек кенә булса да, мин сезгә кулдан килгән барлык ярдәмне күрсәтәчәкмен.

Зал гөрләтеп кул чапты. Шәймөхәммәтов белән Нуриев аларны бик ныгытып чәйгә кыстасалар да, Мәлс, кич минем әле тагын бер сайлаучылар җыелышына барасым бар, дип котылды. Ниһаять, алар Нәфисә әзерләгән табынга кайтып утырдылар, тормыш хәлләрен сөйләштеләр, Алмазның институтта әйбәт кенә укуына өчәүләп шатланыштылар. Ашап-эчеп туйгач, авылга кайтып килергә булдылар. Нәфисә машинага кереп утыргач:

—Зәнфирәне алабызмы соң?—диде.

—Өйрәнә торсын, алабыз,—диде Мәлс.

Бөтенесе дөбердәшеп, салкын аксыл пар ияртеп өйгә килеп кергәч, башта әтисе белән әнисе аларны танымый торды, аннары икесе дә бөтерелергә керештеләр, чишендерергә үрелделәр, кием-салымнарын элмәкче булдылар. Ул арада Нәфисә плитәгә чәй куйды.

—И, балалар, бүген әтиегез иртәдән бирле, кабыклы бәрәңге-кабыклы бәрәңге, дип җаныма тигәч, башка әйбер пешермәгән идем,—диде әниләре өзгәләнеп.—Хәзер аш салып җибәрәм.

—Юк, юк,—диделәр бөтенесе берьюлы.

Ирек белән Мәлс, бер-берсенә карашып алгач, хәзер керәбез, дип ишек алдына чыктылар.

—Күрәсенме, энекәш, әти белән әни нык бетерешкән бит,—диде Мәлс.

—Шулай шул,—дип куйды Ирек, башын аска иеп.

Алар абзар-кураны карап чыктылар, мал өенә башларын тыгып, сарыкларны санадылар, бәрәннәре белән унөч баш иде алар.

—Әти, нигә бу кадәр сарык асрыйсыз? Моны карап бетерергә дә кирәк бит,—диде Мәлс пальтосын элеп.

—И, улым,—диде әнисе.—Көздән бүлтереклләп калалар бит. Суярга кызганыч.

—Әйдәгез, сатыйк та бетерик,—диде Мэлс.—Үзебез исән чакта сезне иткә интектермәбез әле.

Сүзгә әтиләре дә кушылды:

—Алар да булмаса, үләргә кирәк бит,—диде ул, үпкә белдергәндәй.—Хәзер сез дә сирәк күренәсез...

—Ахырзаман житүе хактыр инде,—диде Мэлс, үз-үзенә сөйләнгәндәй. Нәфисә алып килгән каймак белән кабыклы бәрәңгене бөтенесе дә мактый-мактый ашадылар.

—Жиреннән микән, безнең бәрәңге бигрәк тәмле инде,—дип куйды Ирек.

Анын сүзен башкалар да хуплауга, әниләре:

—И, балалар, туган нигездә бөтен әйбер дә тәмле була инде ул. Менә әтиегезгә кияүгә чыккач, үзем өзелепләр дә сагына идем туган-үскән нигезне. Жиде чакрым ара бит, ул чакта сиңа машинасы бармы? Шул араны йә көне буе эшләгәннән соң кич белән, йә иртүк, йә көндез жай чыгарып, йөгерә-йөгерә урап кайта идем. Әй, тәмле дә була иде шунда эчкән чәй!

—Әллә ниләр эшләп йөргәнсең икән,—диде Хәйри елмаеп.—Аны шул чакта ук әйткән булсаң, илтеп кенә куйган булыр идем. Бүген дә рәхәтләнеп шул тәмле чәеңне эчеп утырыр идең.

Барысы да көлешеп алдылар.

—Хәзер инде мина мондагы чәй тәмле, андагысы түгел, карткаем. Балалар белән бергәләп.

Шулай гөрләшеп, үткәннәрне искә төшергәләп утырганнан соң, китәргә кузгалдылар. Барысы да, әниләренә кушылып, ул укыган догага битләрен сыпырып куйдылар.

—Кузгалдык,—диде Мэлс, урыныннан торып.

Ләкин Ирек, кулын абыйсының иңбашына салып, аны туктатты:

—Әз генә сабыр ит инде, абый,—диде ул, калтыранган куллары белән чәчләрен сыпырып. Каш астыннан гына әтисе белән әнисенә, башкаларга карап алды:—Мин үз өстемдә коточкыч авыр гаеп йөртәм... барыгыз алдында да... Йомшак кеше булып чыктым мин. Минем аркада күпме күз яшьләре, күпме хәсрәт...—Тамагына нидер тыгылып, Ирек туктап калды, өйдә чебен очкан тавыш ишетелерлек тынлык урнашты.—Кичерегез, булдыра алсагыз...

Гөлжамал лышык-лышык елый башлады. Хәйри башын күтәрде дә, һәрберсенә күз йөртеп чыккач:

—Без сине, улым, кичерәбез. Кичерми кая барасың,—диде.—Берүк онықларны ул афәттән саклагыз...

Сүзсез генә кузгалдылар, әтиләре белән әниләре аларны "Волга" машинасы күздән югалганчы, капка төбенә баскан хәлдә озатып калдылар.

Болынкырга кайткач, Ирек белән Мэлс икәү генә сөйләшеп алдылар:

—Мин синең өчен бик шат,—диде абыйсы.—Мондый сайлау тегермәненә килеп эләккәч, язуларың онытылгандыр инде.

—Эләгү бик әйбәт булды әле, барыбер берни дә яза алмый идем. Нидер кирәк миңа.

—Тормыш кирәк сиңа. Күзәтеп кенә барсаң да, кайбер вакытларда детективтан да кызыграк булып китә. Әгәр барып чыкса, бүген мине РСФСР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтмәкчеләр бит әле,—диде Мэлс, пышылдауга күчеп. Ризалык бирергәдер бит инде?

—Сүз дә юк,—диде Ирек елмаеп.

—Сиңа берәр эшкә дә урнашырга вакыттыр, энекәш.

—Әле бу сайлауның ызгыш-талашлары күп булачак,—диде Ирек.—Бәлкем район житәкчелеге дә үзгәреп куяр. Шуннан соң эш турында уйлармын, дип торам. Ә сиңа уңышлар, абый! Болынкырлылар синең өчен тавыш бирәчәк—бусына мин ышанам.

—Рәхмәт,—диде Мэлс.

5

Ул көнне участок сайлау комиссиясе председателе Назыйм Әшрәфҗанов, комиссия членнары, партком секретаре Сабирҗан Нуриев күрсәтү җыелышының документларын әзерләделәр, һәрбер кәгазь, һәр фамилия, һәр сан күздән җентекләп үткәрелде, имзалар куелды, һәр документ өч данәдә генә түгел, алты данәдә эшләнде. Дүшәмбе көнне иртүк Әшрәфҗанов белән Нуриев, участок сайлау комиссиясе секретарен алып, Болынкырга киттеләр. Аларны ишектә күргәч, Җиһангировның мангаена сизелер-сизелмәс сызылган җыерчыклары кәкрәешеп бер-берсенә якынаештылар.

—Тыңлыйм сезне,—диде ул, гәүдәсен күн артлы урындыгына ташлап.

Әшрәфҗанов:

—Без кичә кандидат күрсәтү җыелышы уздырдык...—дип башлауга, Җиһангиров аны кызыл учын өскә күтәреп бүлдерде:

—Ишеттек,—диде ул, кадак башына чүкеч белән суккандай.—Китерегез әле протоколларыгызны.

Ул, ашыкмыйча гына күзлеген шикәрдәй ак кулъяулыгы белән озаклап сөрткәч, документларны карарга кереште. Аның битләреннән, борын яннарыннан вак җыерчыклар, янчык бөрмәсенә охшап, ирен тирәсенә җыелдылар. Инде бетә язган сирәк чәчләре өстенә, нәрсәдәндер акланырга теләгәндәй, биш бармагын җәеп, сул кулының учын салды. Бик озак актарынды Җиһангиров, әйтерсең, ул аларны очлы борыны белән иснәп бара, ят ис эзли, туктап кала, тагын хәрәкәткә килә...

—Мин сезнең документларыгызны кабул итә алмыйм,—диде ул, кәгазьләрдә бер сәгатьтән артык актарынганнан соң.

Әшрәфҗанов болай да түзеп кенә утыра иде, шартлап сикереп торды:

—Нишләп кабул итмәйсең син аларны?!

—Шикләнәм,—дип, тагын кадак башына сукты Җиһангиров.

—Нәрсәсеннән шикләнәсең?

—Миңа син дип түгел, сез дип дәшәргә кирәк.

Әшрәфҗанов, аягын аерып басып, нәрсәгәдер текәлеп карагандай, аңа иелде:

—Бәй, син ничә сон?! Минем күзгә бер генә булып күренәсең бит,—диде ул, юри башын ангырага салып.

Җиһангиров баягы сүзне кабатлауны кирәк тапмады. Ул бары тик җыелыш кәгазьләрен анарга сузу белән чикләнде.

—Әйтегез, нинди кимчелеге бар?—диде секретарь хатын түземсезләнеп.

—Теге җыелышта да сайлаучыларның исемлеген төзегәндә, хәрәмләшкән идегез. Мин үз өстемә бу юлы да исемлек дөрес төзелгәндер, дип сезнең документларны кабул итеп, җаваплылык ала алмыйм.

—Шуннан?!—диде Әшрәфҗанов куркыныч тавыш белән.

Ләкин Җиһангиров өркә торган кешеләрдән түгел иде.

—Шуннан шул була,—диде ул.—Имзаларны кабат тикшереп чыгачакбыз.

—Тикшерегез! Ләкин без документларны синдә калдырабыз,—диде Әшрәфҗанов һәм ишекне түшәмдәге лампочкалар селкенерлек итеп дөпелдәтеп ябып чыгып китте.

***

Әхнәфне "Авангард" колхозыннан күрсәтергә булдылар. Җыелыш көндезге унга билгеләнде. Тугызынчы яртыдан өч автобус читтәге бригадалардан сайлаучылар ташыды. Күпме генә тырышсалар да, залда халык ике йөз илледән артмады. Нәҗмиев пышылдап кына шундагы якын бер танышына: "Син кемнәр килгәнне теркәп куй әле,—диде.—Киләчәктә кирәк булуы бар."

Җыелышны партком секретаре ачты: "Партия куйган демократик таләпләргә таянып, Татарстан Верховный Советына альтернатив кандидат

күрсәтергә карар кылдык",—диде... Әхнәф үзе президиумга утырды, үзе залда ни сөйләгәнен анламады. Әйтерсең лә аны ниндидер томан дулкыны тирбәтә һәм акрын гына югарыга күтәрә бара иде. Кемнәрдер сөйләделәр, кул күтәрделәр, соныннан аның ризалыгын сорадылар. Ул, сезнең ышанычны акларммын, диде, Үзәк Комитет башлаган үзгәртеп коруларны тормышка ашыру өчен гомеремне дә кызганмаячакмын, диде. Соныннан Нәҗмиев аны Батталов янына керергә кыстаса да, ул, вакытым юк, диде. Хуҗалар әзерләгән табыннан да баш тартты. Нәҗмиевкә кадәр кайтып, ул җыелышның әйбәт кенә узганлыгы турында Арслановка хәбәр итим, дип кергән иде, беренче котлап аның кулын кысты.

—Беләм, беләм, Нәҗмиев мина шылтыратты,—диде ул.—Инде безгә, Әхнәф Хәсәнович, матбугатта үз программабызны чыгарырга, аннары бергәләп тә, аерым-аерым да очрашу җыелышларына йөрергә туры киләчәк.

Әхнәф, солдат кебек төп-төз басып:

—Нәкъ сез кушканча булыр!—диде.

Бу—кандидат күрсәтүнең соңгы көне иде.

***

Шул ук көнне төштән соң Миргали Җиһангиров Наратбашка килеп төште. Ул, партком бүлмәсенә кереп, кандидат күрсәтү җыелышының документларын сорады.

—Миндә берниндн документ та юк,—диде Нуриев куркынып.—Алар Әшрәфҗанов кулында.

Бик тиз арада аны да чакырып китерделәр.

—Мина беренчел документларны бирегез,—диде Җиһангиров, аңа таба кулын сузып.

Әшрәфҗанов култыгындагы папкасын сул яктан уңына күчереп куйды.

—Мин барлык документларны да сезгә бирдем.

—Ә үзегездә?

—Анысында сезнен эшегез юк. Положение буенча нәрсә тиеш, сезнең кулыгызда.

—Ярый,—диде Җиһангиров ачу белән.—Иртәгә төштән соң сәгать икедә республика сайлау комиссиясе утырышына барабыз, сонармагыз.

Җиһангиров урыныннан купты да, кием элгеченә барып, бүреген киде.

—Ә нинди машинада барабыз?—дип сорады Әшрәфҗанов.

—Хәзергә әйтә алмыйм.

—Сәгать ничәдә кузгалабыз соң?

—Сәгать җидедән дә калмагыз,—диде Җиһангиров чыгып китешли.

Аның артыннан Әшрәфҗанов төкереп куйды. Ул кич белән, райкомга шылтыратып, Нәҗмиевтан да нәрсә белән, ничек китү турында сораштырды. Ул да кистереп кенә җавап бирмәде, Җиһангиров белән сөйләшегез, диде. Әшрәфҗанов эшнең кая таба барганын чамалады. Әгәр алар утырышка сонарып барсалар, күрсәтелгән кандидат регистрациягә алынмаячак. Ул бу хакта Нуриев белән дә, Шәймөхәммәтов белән дә сөйләште. Җидегә чакыргач, калдырып китмәс, дигән фикергә килделәр. Шулай да, авылның иң оста шоферын үз "Жигули"е белән Болынкырга илтергә, әгәр туры килсә, Казанга ук юл тотарга күндерделәр.

Иртән сәгать җиде тулганда, машинаны райком турында калдырып, Җиһангиров утыра торган бүлмәгә мендeләр. Аның ишеге бикле иде.

—Бәй, сез нишләп йөрисез?—диде аларны коридорда очраткан Нәҗмиев.

—Җиһангировны көтәбез,—диде Әшрәфҗанов.

—Мин бит сезгә аның белән кисеп сөйләшергә кушкан идем. Юк кына әйбердә буталасыз, понимаешь!—диде Нәҗмиев, тавышын күтәреп.—Аның Казанга киткәненә ярты сәгать бит инде.

Шофер белән Әшрәфҗанов аптырашып бер-берсенә карашып тордылар да йөгерә-атлый беренче катка төшеп киттеләр.

—Киттек Казанга,—диде Әшрәфҗанов.—Мәсьәлә аңлашылды...

Әле Болынкырдан чыкканда, ул кадәр сиздермәгән буран шактый көчәйгән иде. Юлны күрмәле түгел, артык кызу куып булмый, алар бер көйгә бара бирделәр. Бер сәгатьләп баргач, шофер машинасын туктатты.

—Ни булды?

—Тәгәрмәч тын җибәрде бугай.

Алар карагач, аптыраудан авызларын ачып каттылар, арткы шиннарның икесе дә тын җибәргән иде.

—Мин гомерем буе машинада йөрим, мондый хәл булмый, Назыйм абый,—диде шофер ярсып.—Әгәр юлда кадаклы такта яткан булса, алгы тәгәрмәчләр зарарланыр иде. Беләсенме, бу бит кул белән тишелгән, башкача була алмый. Без райкомга кергәч, берәр имансызы төртеп киткән моны.

Шофер, бер тәгәрмәчен салдырып, запасын куйды. Икенчесенен камерасын алыштырды. Бу эшләрне башкарганчы, онга салып тәгәрәткәндәй, ул ап-ак булып бетте. Әшрәфҗанов, булдыра алганча, аның киемнәрен бияләе белән сыпыргалады. Мең җәфа белән алар барып кергәндә, сәгать өченче егерме минут иде. Комиссия членнары Әшрәфҗановны шелтәле карашлары белән каршы алдылар, алар алдында Жиһангиров нотыгын тотып бетергән иде.

—Сез нишләп Жиһангиров белән барырга теләмәдегез?—диде җыелышны алып баручы.

—Нәрсә-ә-ә?!—дип сузды Әшрәфҗанов, тирләгән битләрен кулъяулыгы белән сөртеп.—Кем әйтә андый сүзне?

—Вакытында килмәдең бит, Әшрәфҗанов. Мин бит сина алтыда китәбез, дидем. Ә син, мин үзем барам, дидең.

Әшрәфҗановның ияге аска салынып төште, озын тешләре тырпаеп, бүлмәдәгеләрне буып ташлардай булып селкенделәр. Ул, сулышына буылып, сүзен әйтә алмый торды.

—Син нәрсә?!—дип кычкырды ул дәһшәтле тавыш белән.—Шушындагы кешеләрне алдап утырганың өчен хәзер мин сине буып ыргытам бит!—Ул шулай диде дә, көрәктәй кулларының бармакларын куркыныч тырпайтып, Жиһангировка таба атлады.

Жиһангиров тиз генә өстәл әйләнеп каршы якка утырды.

—Син чамалап, монда Болынкыр түгел,—диде ул, күзлекләрен елтыратып.

—Иптәшләр!—дип кычкырып җибәрде Әшрәфҗанов, кулларын күкрәгенә куеп.—Алдый бит бу кеше!

Комиссия членнары бер-берсенә карашып алдылар, алар Әшрәфҗановның шушы минутта йөрәге ярылыр дәрәҗәдә шашынып калуыннан дөреслекне аңладылар ахрысы.

—Әйдәгез, сөйләгез,—диде утырышны алып баручы.—Нәрсә булды?

—Зинһар бер стакан су бирегез,—диде Әшрәфҗанов.

Ул калтыранган куллары белән күкрәк кесәсеннән берничә сәдәф дару алып капты һәм бер стакан суны ике йотуда эчеп бетерде.

—Безгә Сабитовны кандидат итеп күрсәттермәс өчен райком белән менә шушы кеше инде әллә ничә көннәр төрлечә аяк чалалар.

—Ник сез яла ягу белән шөгыльләнәсез?—дип чәчрәп торды Жиһангиров.

Ләкин җыелышны алып баручы аны шундук урынына утыртты. Әшрәфҗанов башыннан алып азагына кадәр нәрсәләр булганлыгын, кичәниләр сөйләшкәннәрен, Жиһангировның берүзе "Авангард"ның ак "Волга"сында алдан китеп барганлыгын, хәтта райком алдына туктагач, үзләренең машинасының ике тәгәрмәч шинын тишеп җибәргәннәренә кадәр сөйләде. Ул шыбыр тиргә батты, аңа бер-бер артлы тагын ике стакан су салып бирделәр.

—Сезгә оят түгелме, иптәш Жиһангиров?—диде комиссия членнарыннан берәү.

—Аның сөйләгәннәренең яртысы уйдырма,—дип Жиһангиров сикереп торган иде, аны тагын урынына утырттылар.

—Биредә дәлилләр күз алдында,—диде җыелышны алып баручы.—Нигә

сез аларның, беренчел документларын сорап, башларын катырдыгыз? Шушыннан ук сезнең райком кубызына биегәнлегегез күренеп тора. Без сезне элекке сайлауларда да кисәткән идек. Ә бусында кылган гамәлләрегезне кискен гаеплибез.—Аннары ул Әшрәфҗановка борылды:—Ә сезгә күрсәткән ныклыгыгыз, принципиальлегегез өчен үзәк сайлау комиссиясе исеменнән рәхмәт белдерәбез. Тынычлап кайтып, хәбәр итегез: күрсәтелгән кандидатыгыз теркәлде.

Әшрәфҗанов аларга рәхмәт әйтеп чыгып китте. Урамда ул шактый гомер Җиһангировны көтеп торды, күп түгел, бер өч кенә минутка бугазыннан эләктереп, тын алдырмыйча интектереп торасы килде. Ләкин Җиһангиров сак иде, ул Әшрәфҗановның үз-үзен белештермәс хәлдә икәнлеген аңлап, комиссия членнары яныннан чыгу белән туалетка кереп бикләнде...

***

Мэлс Сабитовның Татарстан Верховный Советына депутатлыкка кандидатлыктан үзен алуы Арслановны башта борчыган иде. Аннары, сайлау алды кампаниясе башлангач, үзенең халык тарафыннан хупланачагына шиге калмады. Иң элек Арслановның сайлау алды программасын кат-кат яздылар, моны эшләүдә Нәҗмиев төп дирижер булды. Менә аның янына ул соңгы вариантны алып керде. Арсланов, кулына ручкасын тотып, бик игътибар белән тагын укырга кереште: "Урта мәктәпне бары тик "биш"ле билгеләренә генә бетергән, спортның барлык төрләре белән шөгыльләнгән... институтны кызыл дипломга тәмамлаган..."

—Дипломның кызыл түгеллеген сизмәсләрме соң?—диде ул, Нәҗмиевка төбәлеп.

—Һи-и-и, Миңзаһит Усманович! Сезнең дипломның төсен кем карасын? Ә ул ничек тәэсирле яңгырый!

Программада Арсланов беренче секретарь булып эшләгән чорда игенчелектә һәм терлекчелектә яуланган унышлар, төзелеш эшләре, салынган юллар—барысы-барысы җентекләп күрсәтелгән иде. Соңыннан аның социаль мәсьәләләр белән һәркөн шөгыльләнүе, мәдәниятне, сәнгатьне үстерүгә беркайда да күрелмәгәнчә зур өлеш кертүе әйтелә. Мәсәлән, ул, бер композитор белән шагыйрьне чакырып, район турында махсус җыр яздырган... Шул урынга җиткәч, Арсланов баш чайкап куйды.

—Бусы артыккарак китмәсме?—диде ул, ләззәтләнүдән авызын җыя алмыйча.

—Сез минем тәҗрибәгә ышаныгыз: май ботканы бозмый,—диде Нәҗмиев.—Халык сезнең башкарган эшләрегезне каян белергә тиеш соң?! Без еллар буе игенчеләр, терлекчеләр, социаль өлкәдә эшләүчеләр турында язып-сөйләп торабыз, ә беренче секретарь турында ләм-мим.

—Анысы шулай инде шулаен...

—Депутатлыкка кандидат итеп күрсәткәндә дә сөйләмәсәк, сезнең турыда халык каян белсен соң?—диде Нәҗмиев, аны йокы тамырына басып изрәткәндәй.

Биографиясе белән программасы район гәзитендә басылганнан соң, Арслановны кулын кысып та, телефоннан шылтыратып та күпләр котладылар, без сезнең кем икәнлегегезне белеп житкермәгәнбез икән әле, диделәр, һичшиксез, сезнең өчен тавыш бирәчәкбез, диделәр. Бу җылы карашны ул авылларга барса да, эш урыннарында булса да, нык сизеп торды. Шуның өстенә гәзиттә әледән-әле аны мактаган мәкаләләр чыкты. Гомер буе квартирага интеккән бер ветеран бары тик Арслановның кешелеклелеге, игелеклелеге аркасында гына квартиралы булуын язган. Район үзәк больницасыннан аның профсоюз комитеты председателе Арсланов житәкчелегендә ике яңа корпус төзелүе, медицина җиһазлары алынуы турында яза. Моннан тыш радио аша да, район гәзитендә дә гади игенчеләр, терлекчеләр, укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре аның кешеләргә булган җылы мөнәсәбәте, зирәк акылы турында язып чыктылар.

Очрашуларга үзе генә барган чакта, Арсланов халыкка сирәк товарлардан пакетлар өләшүне дә җайга салды. Төгәлрәк әйткәндә, бусы да Нәҗмиев кулы белән эшләнде. Кайбер очрашуларда мотоцикл, тегү, кер юу машиналары, хатын-кызларга кышкы күн итекләр, сепаратор кебек нәрсәләр дә сорадылар. Өч-дүрт көн эчендә Арсланов аларның барысының да теләген үтәүгә ирешә. Февраль аеның икенче яртысына чыккач, Чукаеваның өен ремонтладылар, абзар-курасындагы шактый нәрсәләрне алыштырдылар.

Сайлау алды кампаниясенең иң кызган чорында район буенча яшерен хәрәкәт башланды. Райком членнары, район Советы депутатлары исеменнән КПСС өлкә комитетының беренче секретарена хат әзерләнгән иде. Аны оештыручы "Биектау" совхозы директоры Фаиз Шәймөхәммәтов булды, хатны Ирек язды. Көн-төн аның йортына берәмләп кенә райком членнары, депутатлар килеп киттеләр, кичләрен берничә кешелек группа, шул хатны тотып, тагын авыллардан авылларга барып, имза җыю белән шөгыльләнде. Хатның эчтәлеге Арслановның партия җитәкчесе буларак үз-үзен акламавы, команда-административ ысуллар белән эш итүе һәм аны кичекмәстән эштән алуны таләп итүгә корылган иде. Район җитәкчеләре тагын эчләренә ут йотып йөри башладылар, кемнәрдер берсүзсез хатка кул куйса, икенчеләре, төрле сәбәпләр табып, баш тартты. Чөнки Арсланов калган сурәттә, ул кешеләргә районда көн бетәчәк иде. Менә бүген язгы юлдан үзенең УАЗигында Шәймөхәммәтов Баллы Төбәккә элдерә. Ул Җәмилов белән очрашырга сүз куешкан иде. Җәмилов аны үзенең эчке бүлмәсендә аш-су әзерләп, аракы куеп каршылады. Алар капкалап, кәефләнеп алгач, Фаиз ник килгәнен әйтте. Өлфәтнең, бу хәбәрне ишеткәч, чырае агарып китте.

—Соң син, энекәш, нишләп баш бетәрлек нәрсә белән йөрисең? Бу бит барып чыкмаячак,—диде.

—Әгәр дә без һәрвакыт дәшми утырсак, әлбәттә, барып чыкмас,—дип каршы килде аңа Фаиз.—Бозны кемдер кузгатырга тиеш бит инде.

—Шулаен анысы шулай, аның бит әле азагы да бар...

—Анысын инде һәркем дә белә.

—Кая, карыйк әле ул хатны.

—Өлфәт абый, ачуланма, кул куясыңмы-юкмы икәнен әйтми торып, хатны күрсәтмим.

—О-о-о, конспирация! Хатны укымый торып, кул куясыңмы-юкмы икәнен әйтеп булмый. Миңа ышанмагач, килмәскә идегез. Хуш иттек,—диде Өлфәт чыгарга әзерләнеп.

Фаиз каушап калды. Инде ул, бер атна буе йөреп, үзенә тапшырылган ун кешенең нибары алтысына кул куйдыра алды. Димәк, бусы да булмады, дип уйлады ул эченнән. Авыр сулап, ул ишеккә таба атлады.

—Тукта әле, энекәш, ярар, куярмын, китер хатыңны.

Фаиз шатланып, аңа хатны сузды. Өлфәт хатны зур игътибар белән, ашыкмыйча гына, күзлеген киеп, ручкасын уң кулына тоткан килеш укып чыкты. Аннары тиз генә кемнәрнең кул куюын күзеннән үткәрде, аның фамилиясе уртадарак иде. Кул куярга әзерләнгән кебегрәк итте дә тагын Арслановка каршы кешеләрнең фамилияләрен хәтерендә калдыру өчен, имзаларны карап чыкты. Аннары ручкасын өстәлгә атып бәрде:

—Юк, куя алмыйм,—диде ул, юри бүлмә буйлап йөрәгән тоткан хәлдә ухылдап йөри-йөри.—Йөрәгемә ябышты, нык каты язылган бу. Юк, булдыра алмыйм, күп еллар бергә эшләгән кешенең йөзенә ничек карыйм? Кимчелекләре юк түгел, кәнишне. Зинһар өчен мине гафу ит, энекәш.

Фаиз хатны алып кайтып китәргә мәҗбүр булды.

Ә икенче көнне иртән сәгать алты тулганда, Җәмилов райком каршында таптанып тора иде инде. Арсланов килеп җитү белән, ул аңа:

—Бик борчулы нәрсә бар бит әле, Минзаһит Усманович,—диде.

Арсланов кызу гына кереп барган җиреннән туктап калды.

—Тагын нәрсә?

—Сезгә каршы өлкә комитеты беренче секретарена хат язганнар. Бездән имзалар җыялар.

—Тукта,—диде Арсланов.—Урамда сөйләшә торган сүз түгел бу.

Алар парлашып райкомга кереп киттеләр...

Икенче көнне төштән соң Шәймөхәммәтов Чаллыга эш белән киткән иде. Райкомнан ярты көн буе шылтыратып аны эзләткәннәр. Иртән ул бүлмәсендә күренү белән, Арсланов исәнләшми-нитми өстәлгә китереп сукты:

—А ну, проходи, оппозиционер!—дип кычкырды.—Хәзер син мина сөйләп бир: минем өстән нәрсә сештырып йөрисен?!

Фаиз эшнең нәрсәдә икәнен шундук сизенеп алды.

—Мин сезнең ни сөйләгәнегезне анламыйм, Минзаһит Усманович,—диде ул, мөмкин кадәр тыныч калырга тырышып.

—Ох, сволочь! Синең мондый икәненне белгән булсам, мин бит сине инженер итеп тә эшләтми идем.

—Инженер белеме булгач, мин кем булып эшләргә тиеш соң?—диде Фаиз, һөҗүмгә күчәргә ниятләп.—Мин повар да түгел, мәктәптә балалар да укыта алмыйм.

—Әле син минем белән шулай сөйләшәсеңмени?!

—Ә сез ник минем белән шулай сөйләшәсез? Мин сезнең бакчагыздан кыяр урлап тотылган карак малай түгел. Әгәр дә тагын бер мәртәбә акырсагыз, гомумән, сөйләшеп тә тормыйм.

—Менә ничек сайрыйсын син!—диде Арсланов, сүзләрен теш арасыннан кысып чыгарып.—Сез ни генә кылансагыз да, мин беренче булып калачакмын! И твой поступок никогда не простится! Мин бит кемнәр кул куйганына кадәр беләм. Китер хатны.

—Миндә бернинди дә хат юк,—диде Фаиз, аягүрә басып.—Булса да, бирмәс идем.

—Ничего, синең кебекләрнең генә телен ачкан бар безнең. Сине анда заворг көтә. Күземнән югал!..

Аның кабинетыннан чыккач, Шәймөхәммәтовны, бильярд шары кебек, әле бер бүлмәгә, әле икенчесенә тәрткәли башладылар. Прокурор урынбасары белән дә очрашырга туры килде.

—Сез бер ел элек совхоздан өч мең ярым акча алгансыз. Торба өчен дип. Кайда ул торбалар?

—Ындыр табагы белән техника паркының түбә шиферы астына куелды.

—Ә акчалар кайда?

—Торба өчен бер оешмага түләдем.

—Кайсы оешмага? Документы кайда?

—Документсыз гына. Оешмасын да әйтергә ярамый.

—Иптәш Шәймөхәммәтов, сез үзегезнең кая кереп батканыгызны беләсезме?—диде урынбасар куркыныч тавыш белән.—Өстегездән ике җинаять эше ачыла: совхоз акчасын үзләштергән һәм торба урлаган өчен. Өч елдан сигез елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган.

Чакыртып сорау алулар сайлауларга кадәр дәвам итте.

Беркөнне Арсланов Нәҗмиевкә:

—Безнең Шәрифуллинның үз кандидатурасын алыр чагы җитте бит, ә ул онытты ахрысы,—диде.

—Нишләп алай икән, әйеме?—диде Нәҗмиев, аптыраган кыяфәт чыгарып.—Мин аның хәтеренә бүген үк төшерермен.

—Төшер, төшер,—диде Арсланов.—Артык сузарга кирәкмидер.

Нәҗмиев шундук икенче секретарь бүлмәсенә керде:

—Сезнең теге мәсьәләдә фикерегез ничегрәк соң әле?—диде ул, сүзне ерактан башлап.

—Нинди мәсьәләдә?

—Соң ни инде... кандидатурагызны алу мәсьәләсе.

—Ә-ә-ә,—дип сузды Әхнәф.—Үзем дә беләм, алырмын...

—Юк, мин ул кадәр бүген-иртәгә дип әйтмим, үзегез хәл итәрсез. Хакыйкать һавада, аның баскычы алтын, диләр бит.

Бергәләп Баллы Төбәк авылында булган очрашудан кайтканда, Арсланов

машинаның тизлеген акрынайтып (ул рульдә үзе иде), сүз башлады:

—Синең, Әхнәф Хәсәнович, миңа биргән вәгъдән бар иде бит.

—Беләм,—диде Әхнәф.—Мин сездән тәҗрибә алып йөрим, әле вакыт бар ич.

—Сез кире уйларга җыенмыйсыздыр ич?

—Сез нәрсә, Минзаһит Усманович?!—диде Әхнәф, тавышын күтәреп.—Шуны эшләсәм, мин ничек сезнең йөзегезгә карыйм ди, ничек сезнең кул астыгызда эшлим, ди?

—Әлбәттә,—диде Арсланов.—Тик артык сузарга ярамый. Халык конкрет бер фикергә килергә тиеш. Иртәгә гаризагызны язсагыз, әйбәт булыр.

—Ярый, шулай итәрмен,—диде Әхнәф.—Әйткән сүз—утырткан багана.

Кичен Әхнәф Фәһимәгә беренче белән булган сөйләшүне сүзен сүзгә җиткерде. Моны ишеткәч, хатынының күзләре ут булып яна башлады:

—Әллә алырга җыенасыңмы?—диде ул иренә, очып кунарга әзерләнгән күркәдәй якынаеп.

—Ә алмый нишлисең?—диде Әхнәф.—Шулай сөйләштек бит. Вәгъдә—иман.

—Вәт дурак!—диде Фәһимә, ике кулын түшәмгә таба сузып.—Вәт ахмак! Учына килеп кергән кошны ычкындыралармыни? Бу бит бәхет кошы!

—Минем аны асрарлык читлегем юк,—диде Әхнәф, битараф тавыш белән аны үртәп.—Минем кулда мантый алмый ул бәхет кошы.

Фәһимә аны ике җилкәсеннән тотып селкетергә тотынды:

—Син нәрсә?! Чынлап сөйлисеңме?!

—Чынламыйча. —Әхнәф кулына кәгазь белән ручка алды.—Менә хәзер сайлау комиссиясенә гариза язам.

Фәһимә аның кәгазе белән ручкасын бөтереп алып, ертып-сындырып ыргытты:

—Үтте бит гомерләрем шушының белән!—ул үкереп елый башлады.—Ахмак, дурак, куркак! Ниләр әйтим инде мин сиңа?!

Әхнәф, кычкырып көлеп җибәрмәс өчен үзен көч-хәл белән тыеп утырды. Көләсе килгән саен, йөзенә ачу чыгарырга тырышты. Ул инде күптән кандидатурасын алмаячагын хәл итеп куйган иде, бу эшне эшләү үзем өчен булмаса, район өчен кирәк, дип уйлый иде Әхнәф. Аннары ул бит әле адәм баласы, сайланган очракта хыялларын тормышка ашыру өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр ачылачагын да бик яхшы сизеп тора. Хатынын елаудан туктату өчен ул аның янына килде һәм юри битеннән үбеп алды. Аннары пышылдап кына:

—Алмам микәнни, карчык?—диде.

Фәһимә елавыннан шып туктады:

—Алмыйсың, әлбәттә!—диде ул кулларын чатый-ботый хәрәкәтләндереп.—Алмыйсың! Алмыйсың! Алмыйсың!

—Булды, булды, аңладым,—диде Әхнәф.

Аннары Фәһимә аны иркәләргә, сөяргә кереште, акыллы булуы өчен мактады, Болынкырда гына түгел, бөтен СССРда бердәнбер яхшы ир син, диде, әгәр сайлауда җиңеп чыксаң, патша кебек яшәячәкбез, диде. Синең үз гомереңә бер кимчелегең булды: властька кызыкмадың, диде. Әгәр син аңа кызыккан булсаң, әллә кайчан өлкә комитетында утырган булыр идең инде, диде. Аннары синең, диде, чит хатыннарга күз ата торган гадәтең бар, диде, ишкәгеңне тоткан сурәттә, көймәңне ялгыш агымга кереп китүдән коткарып булачак, диде, берүк Арсланов кыса дип, кире уйлый күрмә, диде, мин халыкны тыңлап йөрим, диде, кешеләр сиңа тавыш бирәчәкләр, диде...

## 6

Гомергә медпунктның бусагасыннан атлап кермәгән Заһитның ишектә күренүе Хәлимәне әллә нишләтеп җибәрде.

—Әйдә, уз, Заһит Җәләевич. Авырып китмәгәнсеңдер бит?

Заһит саран гына елмаеп куйды:

—Сәламәтлеккә зарланып булмый. Тагын бер илле-алтмыш ел яшәп була әле,—диде ул тимер тавыш белән.

Шунда аларның сүзе бүленде. Кызыксынудан бигрәк тынлыкны бозу өчен Хәлимә:

—Сыерынны сатып җибәргәнсең икән,—дип куйды.

—Ялгыз башыма кирәксенмәдем...

—Зәнфирә янына барганың юкмы соң?

—Тормыш сирәк-мирәк очраштыртгалый шунда,—диде Заһит һәм каушап, калтыранган куллары белән кесәсеннән зәңгәр конверт чыгарды:

—Мин аңа хат язган идем. Үзенә генә тапшыра алырсыңмы икән?

—Әлбәттә, тапшырырмын, Заһит Җәләевич,—диде Хәлимә.—Синең үтенечеңне җиргә салып таптый алмыйм мин. Турысын гына әйткәндә, өчегез дә бик якын миңа. Ләкин нишлисең бит, тормыш әллә нинди хикмәтләр чыгара да куя.

Аның сүзләрен ишетмәгәндәй, Заһит:

—Үзенә генә тапшырырсың инде,—диде дә саубуллашмый-нитми генә чыгып китте.

Хәлимә конвертка күз төшерде, аның тышына бер генә сүз язылган иде: "Зәнфирәмә." Конвертны өстәл астына салып куйгач та, Хәлимә шактый вакытлар уйланып утырды. "Өчегез дә якын" дип әйтсә дә, аның күңелендә Ирек аерым урын били иде. Иргә чыкты, ике бала алып кайтты, тик барыбер оныта алмады. Бәлкем җир йөзендәге берәр бөтенләй чит кешегә үзенең хисләре турында сөйләсә дә, аңа җиңелрәк булган булыр иде. Ләкин ул моны эшли алмады шул. Ирек Сөембикә белән яши башлагач, ничекләр генә бәргәләнмәде Хәлимә! Кулына китап тотса да, Ирек күз алдына килде. Кино яки спектакль караса да, һичшиксез андагы берәр геройны Ирекккә охшатты. Аның бу дөньядан кызык тапмавы бөтен кыяфәтенә чыкты. Йөзендә элекке якты нур сүнеп, әллә нинди сагышлы шәүлә генә калды. Күз төпләрендә җыерчыклар артты, чал чәчләре күренде, уң як ирен почмагыннан иягенә таба, яшерен яну билгесе булып, нечкә генә сызык сызылды. Мәңге кияүгә чыкмаска ант иткән Хәлимә кинәт антын бозды һәм шатланып бетә алмады. Авылның карт буйдагы Гыйлман ничә еллар буе аның артыннан йөрде. Хәлимәне күрер өчен Гыйлман юк чирләрен бар итеп, кыш көннәрендә күлмәкчән йөреп, салкын су эчеп булса да (боларны ул өйләнешкәч сөйләде), медпунктка килә иде. Өйләнешергә үзе дә ялварып, яучылар да җибәреп туйгач, Гыйлман өметен өзеп, кул селтәгән бер мәлне, Хәлимә аны урамда очратып, ярды да салды:

—Әйдә, Гыйлман, интекмик. Әгәр синең үтенечләреңне кире кага килүемне кичерә алсаң, мин уртак тормыш корырга риза,—диде.

Алар бик матур яшәп киттеләр. Хәлимә бәхетле иде, ләкин үзенчә бәхетле иде. Ирекне яратуы ничектер югарыда, җиһанның илаһи бер биеклегендә калды. Шуның өстенә ул Зәнфирәне дә үзенең кызы кебек яратты. Чыннан да сәер булды шул аның яратуы.

***

Хәлимә икенче көнне медпунктта гөлләргә су сибеп йөргәндә, Заһитның күршесе Сәлимҗанның алтынчы класста укучы малае йөгереп килеп керде. Аның кулында нәкъ кичә Заһит биргән төсле зәңгәр конверт иде.

—Заһит абый сиңа тапшырырга кушты,—диде малай, борынын лышык-лышык тартып.

—Кайчан бирде соң ул аны?

—Иртүк бирде, озын тәнәфестә илтерсең, диде.

Малай чыгып киткәч, Хәлимә кувшинын куйды да, аны-моны уйламыйча, конвертны ачты һәм эченнән бер кисәк кәгазь алды. Беренче

юлларын укуга ук, сулыш алудан калды: "Хәлимә, син бу хатны укыганда, мин бу якты дөньядан киткән булырмын. Зәнфирәне дә, башкаларны да әллә нинди фаразлар белән борчыма. Минем үлүемнен сәбәбен Зәнфирә белән сез генә белерсез. Син килгәндә, ишек киереп ачык булыр—бу "мин юк" дигән сүз булыр. Минем бүлмәдә ут янар—ул да шуны раслар. Курыкмыйча кер. Уку белән бу хатны ертып ташла..."

Ул конвертны хаты белән бергә куллары авыртырлык дәрәҗәдә чытырдатып учына кысты, як-ягына каранды, аның кулында гүя Заһитның йөрәк тибеше иде. Ул шул минутта ук йөгерә-атлый аның өенә ашыкты. "Бәлкем әле исәндер, бәлкем акылына килгәндер, ул андый эшне эшли торган кеше түгел", дип уйлады ул.

Хәлимә баскычны атлап керүгә өй ишегенең ачык икәнен күрде. Аның йөрәге туктаган кебек булды. Ул ашыга-кабалана өйгә керде. Уң яктагы түр бүлмәдән ут яктысы күренә иде. Хәлимә, тез буыннары йомшап, аркасы белән стенага сөялде, үлем тынлыгы урнашкан өйдә үзенең сулыш алганын гына ишетте. Тын алырга куркып, ул ут яктысы төшкән бүлмәгә үтте һәм майкадан килеш чалкан яткан Заһитны күрде. Аның сул кулы асылынып төшеп, идәнгә тигән иде. Әле һаман да өметен өзмәгән Хәлимә барып аның пульсын капшады—йөрәк тамыры типми иде. Атылып-бәрелеп, ул кешеләр чакырырга чыгып йөгерде...

***

Зәнфирәнең больница бухгалтериясеннән акча аласы бар иде. Ул керү белән, бухгалтериядәгеләрнең үзенә бик сәер итеп карауларын тойды. Кассир хатынының акча санаганда куллары калтыранды һәм ул Зәнфирәгә куркынып карап:

—Хәлләрегез ничек?—дип сорады.

Гомергә сөйләшмәгән кешенең шундый сорау бирүе Зәнфирәне гаҗәпләндерде һәм ул, нәрсәдер урлаганда тотылган кешедәй, артына борылып карады. Бүлмәдәгеләрнең бөтенесенең дә күзе аңарда иде. Зәнфирә берни аңлый алмаудан гаҗиз булды.

—Сез авылга, медпунктка шылтыратыгыз әле... Хәлимәгә...—диде кассир хатын.

Зәнфирә шундук, күнеле нидер сизенеп, медпунктның телефон номерын җыйды.

—Исәнме, Хәлимә апа?—диде ул кабаланып.

Ләкин Хәлимә исәнлек биреп тормады.

—Ни бит, Зәнфирә...—аның тавышы тотлыгып калды.—Заһит...

—Нәрсә Заһит?!

—Бүген төнлә... Заһит үлде...

Зәнфирә бухгалтериядән чыгып йөгерде. Ул нишләргә белми иде. Аннары кабат йөгереп керде, кабат телефоннан номер җыйды.

—Ни булды соң, Хәлимә апа?!—диде ул кычкырып.

—Йөрәк, диләр.

Зәнфирә күзе-башы тонган хәлдә авылга чапты...

Заһитны җирләгәндә, аның туганнарының әйткән сүзләре, аркасына пычак кадагандай, йөрәгендә мәңгегә калды:

—Ничек оялмый?!

—Башына шул гына житте... Әүлия иде бит...

Зәнфирә аны җирләгән көннәрдә генә түгел, янадан, улы Зирәкне Казанга озаткач, кабат Ирек янына кайткач, кешеләргә күзен күтәреп карый алмады. "Башына шушы гына житте!" Бу сүзләр, канга салынган утлы энә кебек, минут саен аның йөрәген яндырып үттеләр. Ул Заһитның үзенә язып калдырган соңгы хатын яшеренеп кенә укыды да елады, укыды да елады...

7

Арсланов беркөнне Казанда киңәшмәдә булды. Шунда кунып, икенче көнне Казан арты районнарында семинарга йөрде, эт булып арыпталчыгып, төнлә генә кайтты. Иртән эшкә килү белән Нәҗмиевтән яңалыкларны сорады, Шәрифуллинның әле һаман кандидатурасын алмаганлыгын белгәч, аптырап китте.

—Ул бит миңа икенче көнне үк гариза язам, дигән иде.

—Миңа да шулай диде. Онытты мы икән?.. Үзем сөйләшимме соң?

—Юк, үзем,—диде Арсланов.

Аннары телефон шылтырап бүленде, ахырда ул кабул итү бүлмәсендәге секретарьга беркемне дә тоташтырмаска боерды һәм Шәрифуллинны чакырырга кушты. Икенче секретарь белән алар елмаеп, кул бирешеп күрештеләр. Район хәлләре белән кызыксынганнан соң, Арсланов:

—Син, Әхнәф Хәсәнович, нишләп гаризаңны язмадың? Сайлауга бит бер атна вакыт калды,—диде.

Шәрифуллин башын иеп шактый вакыт сүзсез торганнан соң:

—Мин бүтәнчәрәк уйга кердем бит әле, Минзаһит Усманович,—диде.

—Нинди уй?—Арслановның шикләнүдән яңаклары тартышып куйды.

—Уйладым-уйладым да... мин әйтәм, икебезгә дә гаделлек кирәк бит...

Арсланов учы белән шапылдатып өстәл сукты:

—Син сузма!—диде ул кискен тавыш белән.—Нинди уйга кердең?

—Сайлаулар бит ачык күрсәтәчәк. Халык миңе ничегрәк бәяли икән? Шуны бик тә беләсем килеп китте...

—Син, Шәрифуллин, бөгештермә! Без алай сөйләшмәдек!

—Сез барыбер үтәчәксез ич,—диде Әхнәф, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.—Кызык өчен көч сынашып карыйк.

Арсланов сикереп торды, аның яңакларына, муенына кызыл тимгелләр бәреп чыкты. Кулына каяндыр килеп эләккән блокнотны калтыраган бармаклары белән тарткалап өстәл башына ыргыткач, усал тавыш белән:

—Бирермен мин сиңа кызыкны!—дип кычкырды.—Бу ни дигән сүз?! Син монда кәмит оештырып утырма!

Әхнәф тә аягына торып басты:

—Нәрсәдән куркасыз соң сез, Минзаһит Усманович? Сез бит безне гаделлеккә өйрәтәсез.

—Гаделлек андый булмый ул. Без ирләрчә сүз бирештек. Халык ул, туганкаем, кем күбрәк эшләгән, шуны сыза. Шул гаделлек буламы?

—Нишләп сызсыннар, сызмыйлар...—дип куйды Шәрифуллин акрын гына.

—Житте!—дип җикерде Арсланов.—Хәзер үк чыгасың да язасың!

Шәрифуллин башын иеп чыгып китте.

Арсланов шундук Җиһангировка шылтыратты:

—Миргали Фәттахович, Шәрифуллин хәзер кандидатурасын алуны сорап гариза яза. Тиз генә шуны кереп алыгыз әле.

Ярты сәгать уздымы-юкмы, Җиһангировның ишектә гәүдәсе күренде.

—Булдымы?—диде Арсланов, тәкать тота алмыйча.

—Юк, иптәш Арсланов, бүлмәсен бикләп чыгып киткән ул.

—Кая чыгып киткән?!—дип кычкырды Арсланов, тәнен пычак белән кискәндәй ачы итеп.

Җиһангиров бер сүз дә әйтә алмады, аптыраудан җилкәләрен генә җыерды. Читтән караганда, шушы рәвешле хәрәкәтсез басып торуы белән ул бакча карачкысын хәтерләтә иде. Арсланов шундук секретарь кызны чакырып кертте:

—Шәрифуллин кайда?

—Белмим,—диде секретарь.—Бүген мин булмыйм, диде ул.

Арсланов, чыгып китегез, дигән мәгънәдә аларның икесенә дә кул селтәде. Бүлмәдә ялгызы гына калгач, ул аты-юлы белән сүгенеп куйды: "Вәт шымыкый! Миңа ышан син аңа,—дип әрле-бирле йөрде ул

бүлмәсендә.—Димәк, бу чынлап торып сайлауда катнашырга уйлаган." Монын үзе өчен һәлакәт булып бетү ихтималын Арсланов менә шушы минутта бөтен кискенлеге белән тойды. Нишләргә? Кемне ярдәмгә чакырырга? Ничек аны ул уеннан кайтарырга? Бу сорауларга ул бердәнбер дөрес җавап тапты: хатыны аша. Алтын таулары вәгъдә итеп. Әгәр дә алай булмаса, куркытып, өркетеп, ирен теге ахмак фикереннән кайтартырга! Юкса икегез дә районнан очачаксыз, диярга. Нәҗмиевкә дәшеп, ул шушы фикерләрнең барысын да җиткерде. Хатынын чакыр, диде, ул хатынны усал дип әйтәләр, диде, чамалабрак сөйләш, диде. Әгәр кандидатурасын алса, сайлаудан соң ук район Советы башкарма комитеты председателе итәчәкбез, диген, диде. Аны ярты сәгать буе сүзсез тынлап торган Нәҗмиев, үз бүлмәсенә чыкканда, шартларга җиткән иде. Ул ишеген кысыбрак япты да шаркылдап көлеп җибәрде. "Молодец,—диде ул үз-үзенә.—Менә хәзер утлы табага баскан мәче кебек сикерер вакытың җитте!" Табаны һаман кыздырырга кирәк иде. Ярты сәгатьтән аның бүлмәсенә күзе мангаена менгән Фәһимә килеп керде. Нәҗмиев аны елмаеп каршы алды, алдан кисәтеп куюы буенча икесенә дә лимон салынган чәй керттеләр.

—Ну, хәлләрегез ничек?—диде Нәҗмиев, стакандагы шикәрне болгатып.

—Рәхмәт, әйбәт,—диде Фәһимә, әмма үзенең күзләре борчылудан биешәләр, куллары калтырый иде.—Әллә бер-бер хәл булдымы, Кәрәм Нәҗмиевич?

Нәҗмиев барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде. Аннары болай дип өстәде:

—Беркемгә дә чыгармаска сүз бирсәгез, мин сезгә бер киңәш әйтәм.

—Үлгәнче чыгармам,—диде Фәһимә.

—Ул чакта эш болай тора: Әхнәф Хәсәнович, нинди генә куркытулар булса да, кандидатурасын алмасын. Дөреслек аның ягында. Халык аның өчен тавыш бирәчәк.

Фәһимә рәхмәт әйтеп чыгып китте.

Төшлеккә кайткач, ул күкәе тәмам килеп җиткән тавык хәлендә Әхнәф тирәсендә бөтерелде дә Нәҗмиевнын үзен чакыртуын,ниләр сөйләшкәннәрен—барысын да тезеп чыкты.

—Халык минем өчен тавыш бирәчәк, дидеме?

—Шулай диде.

—Алайса чигенү юк, карчык!

***

Минзаһитнын үз гомерендә бер генә мәртәбә дә бу кадәр бастырылганы булмады, ул төне буе саташа торгач, тәмам җенләнеп бетте, имеш тә аны шәп-шәрә килеш мәет юа торган калай колашага салганнар. Ак халат кигән аптека мөдире Җиһангиров борынын сузып килеп аны исни дә "әле тонып бетмәгән икән", дип китеп бара. Бер ягында Чукаева чуар мәче баласы тотып тора, аның өчлы койрыгын Минзаһитнын борын тишекләренә алмаш-тилмәш тыга да ала, тыга да ала. Ул койрыкның зәһәр әчесеннән Минзаһитнын күзеннән яшьләре атылып чыга. Икенче якта Нәҗмиев белән Батталов икесе дә озын шүре тотканнар, шуның бер башын йомрыдагы сабын суына манчып алалар да икенче башыннан өреп күбек чыгаралар. Күбекләре өйгә сыймаслык олы булып кабара, бер-берсенә терәлә дә шартлый, сабын тамчылары Минзаһитнын чыраена лачкылдап төшәләр, күзен әчеттерәләр. Ул арада анын янына килеп сөйләшә башлыйлар:

—Кайсы төшенә тыгып кабартабыз бу имгәкне?—ди Батталов.

—Бүксәсен тиш,—ди тегесе.

Батталов тырнагы төшкән имән бармагы белән Минзаһитнын кендегенә баса, бармагы камырга баткан шикелле керә дә китә. Ул шүресен шунда тыгып өрергә керешә, Минзаһитнын эче тартылып күбә, үпкә-йөрәкләре, бавыр-бөерләре, үт куыгы таштай кабара. Бик озак авырттырып өргәч,

"уф, тыным бетте, хәзер син өр", ди Нәҗмиевкә. Тегесе Минзаһитның эченә учы белән шап-шоп сугып карый да "житмәгән әле мона", дип шүрәдән өрә башлый. Эченең сызлавына Минзаһитның чыдамы калмый, өргән саен бөтен җиреннән пыслап һава чыгып ята. Батталов: "Болай булмый, нипель куярга кирәк, тыны чыгып бетә моның!"—дип чабулап йөри. Минзаһит тилмереп аңа карый, "өрмәгез, шартлыйм бит хәзер", дип кычкырмакчы була, әмма теле әйләнми. Ул кинәт карангылыкка оча, күзен ачуга, үзен шул ук колашада күрә, корсагы бәбәйләгән хатынныкы шикелле бушап калганын тоя. Ун кулына беләк буе кәкре пычак тоткан Нәҗмиев, аның өстенә иелеп, көпшә төсле шома әйберләрне алып үзенең җилкәсенә элә. Минзаһитның эче жу-у итеп китә: Нәҗмиев аның эчәгесен савып маташа ләбаса! Шул чак Лираны култыклап Шәвәлиев килеп керә, "мина йөрәге кирәк иде", ди. "Йөрәген хатын-кызларга өләштек", ди Батталов. Шунда Чукаева мәче тоткан кулы белән якалап, Нәҗмиевны җилтерәтә: "Син бюрократ, ник миңа колагын бирмисең?!" дип кычкыра. Минзаһит: "Инде ничә еллар колак итемне ашадың, туймасаң-туймассың икән, дәжжал!—дип аңа тотып ябышмакчы була, әмма Нәҗмиев пычаклы кулы белән аның күкрәгенә баса да: "Тик ят, кабих, хәзер төтенсез авылга аткарабыз сине!" ди. "Нишләп мине генә, альтернатив кандидат кирәк!" дип буылып кычкыра Минзаһит. Җиһангиров тагын пәйда була, ләкләк борынын аның бүксәсенә тыгып, бик озак иснәнә, аның боз кебек салкын тыныннан бала йоннары кабара. Җиһангиров кулындагы җиз комганнан аның корсагына келәй кебек куе нәрсә агыза башлый, "шушлай бальзамласаң, мәет озак саклана", ди. Шунда Маһиямал Габдуллина белән Заһит Фәхруллин кабаланып килеп керә, "Иптәш Арслановны Маһиямал түтинең трактор арбасына салып, үзебезнең мәктәп музеена алып китәбез", дип Фәхруллин тимердәй кулы белән Минзаһитның беләгеннән эләктереп тә ала. Шул чак Шәвәлиев: "Йөрәген бирмәдегез, аның Лирасы белән танавы миңа тиеш!"—ди дә Минзаһитның борынын шытыр-шытыр чәйнәргә тотына...

Авыртуга чыдый алмыйча, Минзаһит кычкырмакчы булды, ләкин төкерегенә тончыга-тончыга чәчрәп сикереп торды, йөрәге шашып тибә иде. Борынында әллә үрмәкүч, әллә башка нәрсә кыймылдаганы сизелде һәм ул түшәмне күтәрерлек итеп төчкереп җибәрде. Аның ике күзе атылып чыгарлык булып башы авырта, үзе шыбыр су иде. Аскофен, цитромон эчүнең дә юньләп файдасы тимәде. Эшкә китәргә әзерләнгәндә, телефон шылтырады. Шылтыратучы Өлфәт Җәмилов иде.

—Минзаһит Усманович, безнең колхозда һәр йортка диярлек листовкалар таратып чыкканнар.

—Нинди листовкалар?

—Сезгә каршы.

—Немедленно жыеп алыгыз!—дип кычкырды Арсланов.—Хәзер үк райкомга китерегез!

Иртәнге чәен дә эчмичә, пальтосын эләктерә-эләктерә ул урамга чыгуга сөртенеп китте: капкага, ике якка сузылган коймага чуп-чуар итеп кәгазьләр ябыштырылган иде. Ул моның шундук әлеге Җәмилов әйткән листовкалар икәнлеген аңлады. Тырнап кубарырга маташса да, берсен дә кубара алмады, анда ул бары тик эре хәрефләр белән язылган берничә сүзне генә абайлады: "Райондашлар! Ялгышмагыз! Тавышларыгызны бозыклык юлында барып чыккан, халык хисабына көн күрүче, инде күптән партиядән куылырга тиешле, агач җитәкче Арслановка бирмәгез!!! Әгәр район тормышын үзгәртик, дисәгез, партия райкомының икенче секретаре Ә.Х. Шәрифуллинны депутат итеп сайлыйк!" Арсланов листовкага төкерде дә китеп барды. Ләкин аның атлавы атлау булмады, урам буйлап коймаларга, капкаларга шундый листовкалар ябыштырылган иде. Ул эш бүлмәсенә барып кергәндә, зырылдап телефон шылтырый иде инде. Шылтыратучылар барысы да шул турыда хәбәр итәләр, районның иң ерак авылларында да листовкалар ябыштырылган, почта тартмаларына салынган, хәтта газеталар

белән бергә таратылган булып чыкты.

Арсланов котырынып Хасбулатовка шылтыратты, ләкин ул эшенә килмәгән иде әле. "Интеллигент сволочь!"—диде ул авыз эченнән генә һәм аның өенә шылтыратты.

—Хасбулатов! Син беләсеңме, что творится в районе?

—Юк...—дигән куркынган тавыш ишетелде трубкада.

Арсланов сүгенеп җибәрде.

—Чык син хатының кочагыннан! Бөтен районны листовкалар белән тутырганнар. Берегез дә калмасын, берәмләп җыеп бетерегез!—ул трубкасын ачу белән ыргытты.

Ул арада Өлфәт Җәмилов авылдан җыештырган ун-унбиш листовканы тотып килеп керде. Үзенә каршы язылган бу яла ягуны укыгач, Арсланов агарып китте, эчке бүлмәсенә кереп, әллә ничә даруны берьюлы эчте. Яла ягу түгел иде шул бу, дөресен язганнар, кабәхәтләр! Бу халыкка ни җитми торгандыр? Инде тынычлап кына яши башлыйсың, нәрсә булса да китереп чыгаралар. Арсланов алар авызы белән ашыймы, алар аягы белән йөримe, алар кулы белән кочамы? Кемнең кемдә эше бар? Беренче секретарьның өе, йорт-курасы, машинасы башкаларныкыннан начаррак булсын, дигән закон бармы? Беренче секретарьның хатынына РСФСРның атказанган укытучысы дигән исем бирмәскә, дигән күрсәтмә бармы? Беренче секретарьның туганнары, якыннары, бернинди эшкә урнашмыйча, урам себереп, оешмаларның идәннәрен генә юып яшәргә тиешләр, дигән закон бармы? Ул бүлмәсе буйлап, бу дөньяны яраткан кешедән башлап, партиянең барлык югары инстанцияләренә кадәр тозлап-борычлап сүгеп чыкты. Әнә бит ни дип язганнар: "Район газетасы, җирле радио тулысынча Арслановның шәхси рупорына әверелде. Редактор Хасбулатова һәр санда аны мактый торган материаллар урнаштыра. Беренче секретарь районны текә күтәрү белән бергә, композитор да булган икән: Болынкыр турында җыр чыгарган!.."

Шикләнде бит Арсланов, шул кадәр шикләнде. Нәҗмиев салган май ботканы бозу гына түгел, хәзер Арсланов өчен чын мәгънәсендә агуга әверелде. Иртәгә район үзәгендә соңгы очрашу. Сайлаучыларның яртысы Болынкырда яши. Димәк, әле листовкада язылган сүзләрне, халык белән күзгә-күз карап сөйләшкәндә, юкка чыгарып була. Шушы минуттан бүлмәләрне бикләп, листовканың һәр язылган сүзен кире кагарлык дәлилләр эзләргә! Ничек булса да акланырга!

Кинәт аның башына искиткеч акыллы фикер килде: иртәгә бит газета чыгасы көн. Бу листовкаларны юкка чыгарып, интервью басарга! Бик тиз генә Хасбулатованы чакыртты. Ул килгәнче, Нәҗмиевны, пропаганда бүлеге Миңнуллинны, райкомолның беренче секретарен, райкомның гомуми бүлек мөдирен бүлмәсенә чакырды. Алар барысы да, Хасбулатова килеп җиткәнче, башларын иеп, сүзсез утыра бирделәр.

—Нәрсә, мәет саклаган сыман башыгызны идегез?—диде Арсланов, ачулы карашын алар өстендә йөртеп.—Мин әле үлмәгән, исән! Менә бу пасквильне ничек юкка чыгару турында уйларга кирәк!

Аның сүзен бүлеп, ишектән кулы белән чәчләрен сыпыра-сыпыра прокурор килеп керде. Арсланов тагын листовкаларны селкеде:

—Кемнәр эше бу? Дорогой прокурор, нинди подпольный оешмалар яшәп ята безнең районда?! Бүген үк табыгыз һәм барысын да закон тәртибендә җавапка тартыгыз!

Прокурор чыгып киткәндә, ишектән кереп килүче Хасбулатова белән җинелчә генә бәрелешеп алды. Арсланов ана мөрәҗәгать итеп:

—Иртәгә чыгасы газетагызга, менә бу пасквильне юкка чыгарырлык итеп, райкомның элекке абруен саклау максатларында зур материал урнаштырырга кирәк,—диде.

—Безнең газета җыелып беткән бит инде,—диде Хасбулатова, сөрмәле күзләрен матур итеп Арслановка төбәп.

Ул чак кына сүгенеп җибәрми калды.

—Тулса—бушатыгыз!—диде ул тавышын күтәреп.—Чиләкләп бушатыгыз, сәнәкләп бушатыгыз, сопковой белән көрәп төшерегез, аңлашылдымы?!

—Аңлашылды...—дип пышылдады Хасбулатова.

—Шушы минуттан сез барыгыз да эшкә керешәсез. Язгач, миңа күрсәтерсез.

—Редакцион мәкалә итәбезме?—диде Хасбулатова, блокнотына ручкасының очы белән төрткәләп.

—Юк, беренче секретарь белән интервью. Интервью алучының фамилиясен күрсәтмәгез. Безнең корреспондент—бетте-китте.

Бүлмәдәгеләр дөбер-шатыр атлап, дәррәү чыгып киттеләр. Арсланов һава җитмәүдән галстугын тартып куйды, барып форточканы ачты. Тыныч кына кар төшеп торган урамга карады. Март кергән, яз җиткән, адәм баласының күңелендә мондый чакта шатлыклар була торган иде. Их... Ул язгы очынулар! Казлар канатларын кагына-кагына язгы суда чәпелдәгән кебек, күңелләрне көне-төне дәртле ашкынулар дулкыны сугара, язгы ташкын булып, өмет-хыяллар килә иде. Нигә соң бу хәзерге язларның көмеш гөрләвекләре юк? Нигә соң ул гөрләвекләр урынына ут кына ага? Элекке тормыш ямьнәренең мәңгегә китүе шушы микәнни?!

8

Ирекне беркөнне кич район Советы башкарма комитетына чакырдылар. Гаскәров кушуы буенча, диде дежурный. Ул, анык кына бер фикергә килә алмыйча, аптыраулы уйлар кочагында үзенә бик таныш булган бинага килеп керде. Гаскәровның кабул иту бүлмәсендә аны күрү белән секретаре Ирекне депутатлар гражданнарны кабул итә торган бүлмәгә алып килде һәм, шушында керегез, сезне көтәләр, диде. Анда юка гына гәүдәле, җирән чәчле бер кеше утыра иде.

—Узыгыз,—диде ул кул биреп.—Саматов булам.

Ирек шикләнеп кенә урындыкка утырды.

—Мин Бөгелмәдән килдем, дәүләт куркынычсызлыгы комитетыннан. Безгә кайбер мәсьәләләр турында сөйләшеп алырга кирәк иде.

—Рәхим итегез, мин әзер,—диде Ирек.

—Безгә хәбәр итүләренә караганда, сез райком каршына өч автобус белән ике коллективта эшләүче кешеләрне алып килгәнсез. Дәүләт органнарына каршы чыгышлар булган, хәтта милиция работнигына кул күтәрүгә кадәр барып җиткәннәр. Сез шушыны раслыйсызмы?

—Әйе, без җыелып килдек,—диде Ирек.—Тик дәүләт органнарына каршы чыгышлар булмады; ә милиционерга килгәндә, ул үзе башлап кул күтәргән.

—Сез бит моны аклану өчен генә әйтәсез. Ә сүзләрегезне расларлык берниндн дәлилегез дә юк.

—Бар,—диде Ирек.—Әгәр дә милиционерның якасыннан алган кеше гаепле булган булса, аның өстеннән шул көнне үк җинаять эше ачылыр иде. Бу үзе дәлил түгелмени?

—Ярый, без аны тикшерербез әле,—диде Саматов.—Тагын сезнең партия органнары өстеннән хат язуыгыз мәгълүм булды. Бусын таныйсызмы?

—Язмадым,—диде Ирек, аның күзләренә туп-туры карап.—Сез миңа ничек гаеп ташлый аласыз?

—Стиле сезнеке.

Ирек көлеп куйды:

—Сез минем стильне беләсезме?

—Без барысын да беләбез.

—Алайса, күрсәтегез хатны.

—Ә нигә аны күрсәтеп торырга? Өегездә бер данәсе бардыр ич?

—Әйе, мин язган әйберләремнең бер данәсен саклыйм. Тик нишләптер миндә андый хат юк. Ышанмасагыз, кереп тентегез.

Ирек телен тешләп туктап калды. Соңгы сүзне ычкындыру һич тә кирәкми иде.

—Анысы да ерак йөрмәс,—диде Саматов.—Әле без сезнең белән бер генә очрашмабыз. Яратам мин иҗат кешеләре белән әңгәмә корырга. Нәрсәләр өстендә эшлисез соң әле?

—Менә сез әйткән демонстрацияне оештырдым, хат яздым.

Анын бу сүзләрен Саматов саран гына елмаеп, бөтенләй ишетмәгәндәй, колак очыннан гына үткәреп җибәрде. Аннары сәер генә теш төбен суырып куйды да, туп-туры карап, болай дип сорады:

—Минзәлә театры сезнең пьесагызны нишләп чыгармады?

Бу сорау чыннан да Ирекне хәйран калдырды.

—Каян беләсез?!—диде ул, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

—Әйттем ич мин сезгә: безгә бар нәрсә дә билгеле. Йә, нишләп чыгармадылар?

—Ник кирәк соң ул сезгә?

—Бәлкем ярдәм итәрбез...

—КГБның иҗат кешеләренә ничегрәк ярдәм иткәнен яхшы хәтерлибез инде без.

—Ерак тарихка китмик, мин җавап көтәм.

—Ә мин куелмаган әйбер турында сөйләшергә теләмим.

—Сөйләшмичә булмый. Сезнең язганнарыгызда, шул исәптән әлеге пьесагызда СССРның иҗтимагый строе борчый, канәгатьләндерми ул сезне.

—Гел канәгать булып торганда, үсеш булмый, дип өйрәтте безне партия.

—Киләчәктә дә шундый эш алып барырга уйлыйсызмы?

—Белмим.

—Мин сезне кисәтеп куям: кабатланса, чаралар күрәчәкбез. Ә мин чакыргач, соңара торган булмагыз.

—Тырышырмын,—диде Ирек чыгып киткәндә.

Ирektән соң Саматовка Шәймөхәммәтов керде. Ул сәгать ярым буе теге хатны кем язганлыгы, кемнәрнең кул куюы турында белергә теләп, анын җанын талкыды. Төн уртасында Фаиз председательләр советының яшерен утырышын җыярга мәҗбүр булды. Мэлс киткәч, анын җитәкчесе булып ул калган иде. Ярты сәгать шыпырт кына сөйләшеп, бер фикергә килделәр: КГБ вәкилләре монда чакта имзалар җыюны туктатып торырга.

Катнаш азык заводы, юл бүлеге җитәкчеләрен, аерым коммунистларны, берәм-берәм йә прокуратурага, йә милиция бүлегенә чакырып, төрлечә куркытулар, янаулар башланды. Ирекка да Саматов янында ике мәртәбә булырга туры килде. Шуннан соң ул бер әйберне аңлады: хатның барлыгын беләләр, кем язганын чамалыйлар, әмма анын үзен күргәннәре юк. Димәк, куркытулары нигезсез, кемнең дә булса сынып, ачылып ташлавына өметләнәләр. Үзенең бу фикерен ул Саматов чакырган җитәкчеләрнең барысына да әйтеп чыкты.

***

Иртән капкадан чыкканда, Арсланов әллә нинди курку тойгысы кичерде, башыма сукмыйлармы, дигәндәй, як-ягына каранып алды. Иң элек коймаларга күз төшерде, өченче көн ябыштырылган листовкалар кырып алынган, яңалары күренми иде. Ул райкомга таба атлаганда да як-ягына карап, күзәтеп барды, һәр кәгазь кисәген укып үтте. Кичәге шәйгә юка фуражка, юка костюм-чалбар гына киеп чыккан иде, төнлә нык суыткан булып чыкты, җитмәсә каршыга нечкә-ачы җил исә, күк йөзен болыт каплаган. Кичтән аяк астында лыштырдап торган кар бүген пыяладай каткан, атлаган саен табан астында шатыр-шотыр килә. Бүгенге көннең нинди буласын әйтеп булмый, ләкин Арсланов өчен җинел булмаячак. Ул культура йорты каршына эленгән зур белдерү алдына тукталды, анда бүген кичке алтыда Шәрифуллин белән икесенең сайлаучылар белән очрашуы турында язылган иде. Иртән эшләрне оештырып җибәргәч тә, бүлмәсенә бикләнеп, бары тик шушы җыелышка гына әзерләнергә ниятләгән иде ул. Райкомның ишеген атлап керү белән дежурныйдан:

—Бүгенге район газетасын китерделәрме?—дип сорады.

Унай җавап алгач, икенче катка кабаланып менеп китте. Кабул итү бүлмәсенең өстәлендәге газетаны алды да, ишекне ачып, үз бүлмәсенә үтте, утны яндырды һәм, өстен дә салып тормастан, интервьюны укып чыкты һәм җинел сулап куйды. Ышандырырлык, дәлилле язылган иде мәкалә. Әлбәттә, моны эшләүдә Нәҗмиевнең хезмәте зур булды. Аның бүгенге очрашуда сөйлисе чыгышының нигезенә дә шушы интервью ятарга тиеш, өскә Арслановның моннан ун ел элек төшкән бик матур рәсеме дә бирелгән, ул аңа сокланып карап торды. Табигать чибәр дә итеп яраткан инде аны: чиста киң маңгай, ихтыяр көчен белдереп торучы калын кашлар, туры борын, артык зур булмаган авыз, озынча йөз—болар һәммәсе дә табигать тарафыннан нәкъ кирәк кадәр генә алынып, тиешенчә урнаштырылган. Дулкынланып торучы чәчләре дә куе. Ул, үзе дә сизмәстән, ял бүлмәсенә кереп утны яндырды һәм көзгегә карады. Элекке Арслановтан бик аз нәрсә калган шул, тормыш җилләре чәчләрнең дә шактыен өзеп алып киткән, иреннәр дә күкшелләнеп тора, кашларның да чаларган төкләре күренә, күз төпләрендә капчыклар, маңгайда җыерчыклар... Чигә чәчләренә дә шактый гына көмеш сарган. Ул, авызын бераз ачып, ирен читләрен җәеп, тешләрен дә карап алды. Тешләр дә, коелмасалар да, ничектер төсләрен җуйганнар. Юк, ун ел элек булган Минзаһит сиздерми генә кайдадыр калган. Бусы инде аның олыгайганы, тегесенә караганда шактый бозылганы, картайганы, этләшә торганы... Җитмәсә эче авырта.

Төшкә кадәр ул сайлаучылар белән очрашуга әзерләнә алмады. Көндезге ашны ашагач, диванга барып ятты һәм сәгать икеләрдә генә саташып уянып китте. Бөтен тәне су булган, уттай яна иде. Үлчәп карагач, температурасының утыз тугыздан артып киткәнлеге беленде.

—Мин сиңа әйтә килдем, яланөс чыгып йөрмә, калынрак киен, грипп эләктерәсең, дидем. Ә син тыңламадың,—диде Хәят, аңа дарулар сузып.

Аларны эчеп, ярты сәгатьләп ятса да, нәтиҗәсе булмады. Тәне кызышу белән бергә бизгәк тоткандай калтыранды, тамагы кипте.

—Ашыгыч ярдәм чакыртыйк,—диде Хәят, телефонга барып.

—Кирәкми.

"Авырган, ашыгыч ярдәм чакырткannar", дигән сүзне ишеттерәсе килми иде аның. Бер көннән соң аның өчен тавыш бирергә тиешле сайлаучы әлеге хәбәрне ишеткәч, һичшиксез, "картайган инде, җиткән мона", диячәк. Бераздан Хәят аның янына килеп, кулындагы кечкенә ак кәгазьдәге төргәкне сүтеп җибәрде. Аның эченнән биш-алты кузак кызыл борыч килеп чыкты.

—Менә шушыны сөткә салып кайнатып эчсәң, температураң да калмый, чирең дә бетәчәк,—диде Хәят.

—Кем әйтә?—диде Минзаһит, ачуы килеп.

—Соң ул билгеле әйбер бит инде, Чукаева бирде.

—Тапкансың алыр кеше,—диде Минзаһит.—Ул карчыктан юньле әйбер алырсыңмы?

Хәят акланырга кереште:

—Нигә алай дисең? Әле ремонтлар ясаткач, беркөн рәхмәтләр укып торды. Аннары аның үзенең гомер буе дару эчкәне юк...

Минзаһит аны тупас бүлдерде:

—Ә нигә дару эчсен ул? Чирне куркытырлык кешегә даруның кирәге юк.

—Эчмисеңмени?

—Юк,—диде Минзаһит.

Әмма бер сәгать үтүгә, температурасы кабат күтәрелә башлады. Иң хәтәре—башның авыртуына түзәрлек түгел иде. Туктаусыз төчкертеп, борыннан да ага башлады.

—Әллә спирт эчеп карыйм микән, бал болгатып?

—Соң син акылыңдамы?—диде Хәят.—Кич белән очрашуга барасың бар, аның исе бетәмс? Кайнатыйк шушыны.

—Ярар, теләсәң нишлә,—диде Минзаһит, теләр-теләмәс кенә ризалашып.

Хатыны дәртләнеп ярты литрдан артык сөт салды, аңа борыч кузакларын ваклап тутырды, сөтне плитәгә куеп, болгата-болгата ун минут кайнатты, аннары, Чукаева кушканча, чүпрәккә төреп, тагын ун минут тонәтте. Сөтне ачкач, аның шактый кызарганын күрде. Сөзгеч аша уздырып, пыяла банкага салды да кайнар килеш иренә тоттырды.

Минзаһит күзләрен чытырдатып йомды да, ни булса да булыр, дип эчеп җибәрде. Әллә эчте, әллә голт-голт итеп кайнар ут йотты—берни дә аңларлык түгел иде. Банка төбендә бер кашык сөт калгач, аның түземе бетте—ул, кулларын селтәп, банканы өстәлгә атып бәрде.

—Ят, ят тизрәк!—диде Хәят, аны мендәренә аударып һәм өстенә мамыктан сырып эшләнгән зур кызыл юрганын китереп япты. Юрганның итәкләрен куллары белән һава кермәслек итеп Минзаһитның астына кыстырып чыкты.

Ире әлегә кыймылдамый иде, шуңа күрә ул файдасы тияр, дип тагын бер юрган алып килде, анысын да ябып томалап куйды. Минзаһит тешен кысып, ни булыр микән, дип ята бирде. Аңа инде үзенең тәне генә түгел, эчендәге бөтен нәрсә кайный, эчәкләре-ашказаны дөрләп яна, бавыры-бөерләре күмергә әйләнә кебек тоела иде. Шыбыр тир булып, тончыга язып, ике юрган астында пышлыга башлагач, ул юрганның бер читен күтәрде, иркенләп сулыш алып җибәрде. Аннан кергән һава, юрган эчендәге белән чагыштырганда, бозлы салкын җил кебек иде.

—Ачма инде, бөтен эффектын бетерәсең бит,—диде хатыны, теге тишекне томалап.

Минзаһит тагын түзәргә булды. Ни гаҗәп, бервакыт ул онытыла башлады, ул инде авыртуын тоймый, бары бөтен җире чәнчә, яна иде. Ниндидер хәлсезлек астында исәнгерәп, шактый вакыт ятты, әллә йоклады, әллә саташты, әллә бу дөньядан теге дөньяга күчте. Аннары кинәт тыны кысыла башлады. Минзаһит ике юрганын да берьюлы атып бәрде һәм сикереп торды. Сикереп тә торды, башы әйләнеп китеп, гөрселдәп идәнгә дә ауды.

—Ни булды?—диде Хәят, аны иңбашыннан тотып күтәреп.

Йөрәгенең чәнчүенә түзәрлек түгел иде. "Инфаркт... инфаркт...—диде үз-үзенә Минзаһит.—Үтерделәр..."

—Су!.. Су!..—дип хырылдады ул.

Хәят йөгереп барып су алып килде. Ул ярты чүмеч суны тын да алмыйча эчеп бетерде. Ләкин хәле түзәрлек түгел иде, эченең януына чыдый алмыйча, бүлмәдән бүлмәгә йөгерә башлады, гыж-гыж сулаганы, ухылдаганы шомлы булып бөтен өйгә яңгырады. Нишләргә белмичә, Хәят аның артыннан йөгерде. Шул чак Минзаһит шашынып туктап калды: беркөн күргән төше күз алдына килде дә басты. Ул тешләре шакы-шокы килгән килеш, күзен кан баскан үгез төсле, башын Хәяткә борды да куркыныч итеп пышылдады:

—Фәхруллинның тәне йомшак булганмы?

Хәят аның ни әйткәнен аңламады.

—Нинди Фәхруллин?

—Баллы Төбәк мәктәбе директоры,—диде Минзаһит еламсырап.

Хәятнең йөрәге туктагандай булды. "И, Ходаем, саташа ук башлаган бит бу. Алмашыну чире нәселләрендә бар бит",—дип уйлады.

Авызына мәче баласы койрыгы тыгып торган Чукаеваны да Минзаһит янәшәсендә күргәндәй булды. Ул, кинәт борылып, Хәятне җилкәсеннән эләктереп алды.

—Син миңа Чукаеваның сихерләгән борычын эчердең. Сез мине үтерергә теләдегез!—диде ул.

Хатынын этеп җибәрде дә стенадагы китап шкафына үрмәләп менеп китте. Башы дөпелдәп түшәмгә тигәч, тагын аска сикерде.

—Уһ-уһу!—дип үкерде ул.—Бөтен эчем янып бетте. Нигә ашыгыч ярдәм чакырмыйсың?!—Бу сүзләр Минзаһитның соңгы сүзләре булды.

Ул инде идәндә үрмәләп, тәгәрәп йөри башлады, авызыннан алсу күбек акты. Ашыгыч ярдәм машинасы шактый көттереп килде. Аңа укол арты укол ясадылар. Минзаһит боларның берсен дә әллә сизмәде, бары тик "у-

һу-һу", дип үкерде дә ыңгырашты гына. Әз генә тынычлану белән, медсестра врач чакырды. Күп тә үтмәстән, өч врач килеп керде.

Минзаһит уһуһулап ятканда, район культура йортында очрашу җыелышы башланган иде инде. Җыелышны алып баручы Арслановның авырып китүе турында әйткәч, зал шаулашып алды:

—Беләбез без аның ник авырганын!

—Монда чыгып ни әйтә алсын ул?!

Халыкны көч-хәл белән тынычландырдылар. Иң элек Әхнәф Шәрифуллинның ышанычлысы чыгыш ясады, аннары, берничә кеше залдан кутәрелеп, аның өчен тавыш бирергә чакырды. Әхнәфкә төрле сораулар яудырдылар.

—Әгәр сез депутат булсагыз, беренче эшегезне нәрсәдән башлар идегез?— дип сорады бер сайлаучы.

—Яңа балалар бакчасы салудан,—дигән җавапны ишеткәч, зал гөрләтеп кул чапты.

Район үзәге халкының иң авырткан урыны шул иде. Ике бакчага бала нормадан өч мәртәбә артык җыела, тәрбиячеләр аларны карарга житешә алмыйлар, шуңлыктан балаларга салкын тия, аналар туктаусыз авыру бала карап өйдә ятарга мәҗбүр.

Тагын берәү:

—Арсланов сезгә үз кандидатурагызны алырга кушкан, диләр. Бу хакмы?—дип сорады.

—Андый нәрсә булмады, иптәшләр,—дип җавап бирде Әхнәф.

—Ә сез беренче секретарь турында таратылган листовканы укыдыгызмы? Аңа мөнәсәбәтегез нинди?

—Ул листовкада дөрес фикерләр әйтелгән булса да, мин аны хупламыйм. Кандидатларга карата тупас сүзләр белән, урам хатыннары талашканча ябырылу әдәплелек кысаларына сыймый. Алдагы сайлауларда мондый нәрсәләр кабатланмас, дип уйлыйм. Күпләр житәкчеләрне берниңди ялгыш адым ясамаска тиешле кешеләр итеп күз алдына китерәләр. Ләкин без дә фәрештә түгел бит, иптәшләр. Ә инде ялгышларыбыз бар икән, аларны кешечә, әдәп кысаларына сыя торган юл белән тәнкыйтьләргә кирәк.

—Ә ул ялгышлар әдәп кысаларына бөтенләй сыймаса?!—дип кычкырды берәү.

—Ул чакта да тәнкыйть әдәпле булырга тиеш,—диде Әхнәф.

Халыкның шактый сорауларына Арслановның ышанычлыларына да җавап бирергә туры килде.

## 9

Сайлау көнне иртүк Минзаһит Хәяткә ун сум акча сузды.

—Берәрсенә бир әле, минем исемгә дога кылсын,—диде ул читкә карап.

—Акылыңа кил, Минзаһит!—диде Хәят күзләрен шакмакландырып.— Икебезнең дә башны бетерәсең киләме әллә?!

—Киресенчә, коткармакчы булам. Может файдасы тияр...

Шулай диде дә чәй дә эчмичә чыгып китте. "Жинеләюе хак,—диде Хәят үз-үзенә.—Сайлаудан соң Әмиров белән кинәшмичә булмас. Әнә бит Батталовниләр кыланып бетмәде. Нәсел чире кабатланмый калмый шул ул..."

Арсланов көне буе бүлмәсендә утырды. Ул хәтта төш вакытында да өенә кайтмады, ашыйсы да килмәде, кофе эчте дә кофе эчте. Халыкның сайлауларга килүе бик актив иде. Бюллетеньнәрне саный башлагач, ул бүлмәсендә әрле-бирле йөрде, сайлау нәтиҗәләрен туктаусыз Казанга хәбәр итеп торды.

Сайлау нәтиҗәләре Арслановны бәреп егарлык булды: аны яклап барлык сайлаучыларның утыз тугыз проценты тавыш биргән иде. Милиция начальнигы белән редактор икесе дә район Советына депутат булып сайланмадылар. Нәҗмиев тә ниндидер тылсым белән өч тавыш хисабына

гына үтә алган. РСФСР Верховный Советына күрсәтелгән сигез кандидаттан Мәлснең икенче тур сайлауларга узганлыгы турында хәбәр алынды. Ул көнне Минзаһит таң атканда гына, ике аягына гер ташлары аскандай, көч-хәл белән атлап кайтып ауды.

***

Унберенче класста укый торган ул малай бүген тагын Айгөлгә иярде.
—Бер генә минутка тукта инде,—диде ул, Айгөлнең зәңгәр куртка җиңеннән эләктереп.
—Кит әле, Илшат абый.
—Тукта инде, бер ручка күрсәтәм. Менә болай итеп күтәргәч, эчендә кеше йөри башлый.
—Кирәк түгел, эчендә кеше йөргән ручканны эчеңә бәйлә.
—Сабитова, кырагай кыз син?! Шушы ручканы бүләк итәм мин сиңа,—диде Илшат, ручкасын сузып.
—Кирәкми берниең дә!
—Әгәр туктамасаң, карга төртәм дә егам.
—Ектырды диярләр!—Айгөл аңа телен чыгарып күрсәтте дә койма буйлап йөгерде.
Илшат җепшек кар йомарлап ыргытты, ул анын колак яныннан гына очып китте. Бәләкәй капканы ачып, Айгөл Чукаеваларга кереп китте. Илшат, капка төбендә сикергәләп, койма өстеннән:
—Мин беркая да китмим, чыкканыңны саклап торам,—диде.
Айгөл анын үзенә кар ыргытты да йөгерә-йөгерә баскычка килеп җитте. Ул арада ишектән Чукаева килеп чыкты.
—Гандәлифә әби, кара әле әнә теге малайны, гел минем арттан калмый,—диде Айгөл, күзләрен елтыратып.
—Яратадыр ул сине.
Гандәлифәнең күзендә серле шәүлә чагылып китте.
—Ни сөйлисен, әби?!
—Бәй, куып җибәриммени?
—Әйе,—диде Айгөл акрын гына.
Ул арада аягына гәлүш элгән, күлмәкчән Гандәлифә капканы ачып җибәрде һәм егеткә:
—Бар әле, апаем, ычкын!—дип кычкырды.
Тегесе шундук юк та булды. Чукаева рәхәтләнеп, авызын зур ачып көлеп җибәрде:
—Ха-ха-ха! Күрденме әбиеңне! Син бигрәк җебек, балакаем.
—Әйе шул,—дип пышылдады Айгөл.
—Әллә син мине чынлап кычкырды, дип беләсеңме?—Айгөл авызын ачып, аңа сораулы караш ташлады. Аңа җавап итеп, Чукаева болай диде:—Минем бөтен куанычым кычкыруда. Кычкыруның ни икәнен әйтимме?
—Әйт...
—Беркемгә дә әйтмәскә сүз бир.
—Честное комсомольское!
—Әйдә, өйгә кергәч әйтермен.
Гандәлифәнең чәй эчеп утырган чагы булган икән, ул Айгөлне дә өстәл янына утыртты.
—Әйт инде, Гандәлифә әби...
—Кычкыру—минем ирем ул,—диде Гандәлифә һәм рәхәтләнеп көлеп җибәрде:—Ха-ха-ха! Син миңа аптырап карап торма, кызый, мин чынлап әйтәм. Хатын-кызның терәге—анын ире. Ә минеке—үземнен тавышым. Кирәк булганда, ир хатынын яклый, аны кыерсытырга юл куймый, ә мин үземне тавышым белән яклыйм. Мәңгегә загслы без. Кем кайчан өйләндерде, дип сора син.
—Кайчан?—дип куйды Айгөл, алдындагы чәен кабып куеп.
—Әле ул чакта синең әниең тумаган да булгандыр. Мин синнән дә җебек

идем, ялгыш әйтәм, хәзер дә җебек.

—Юк, сине күргәч, калтырап торалар, Гандәлифә әби.

Чукаева тагын көлеп алды:

—Тавышымнан гына куркалар шул алар. Әйтәм бит: мин синнән дә җебек. Ә тавышым белән кайчан өйләнешкәнне мин сиңа сөйләрмен әле, Казанда булды ул. Бик күп еллар элек. Шуннан соң апаңа бөтен кеше сәлам бирә башлады...—Ул тәмләп варенье капты, чәен йотып куйды. — Бүген килеп йөрмә, дигән идем бит.

—Киләсем килде,—диде Айгөл.

Аларның классы карт-корыларга шефлык итә, өч иптәш кызы белән Айгөл Чукаева янына килеп йөри иде.

—Сарыкларның астындагы тиресен ыргытып бетерим, дигән идем.

—И, балакаем, өстеңне дә алыштырмагансың. Бу киемнәреңә сарык исе сеңәр бит.

—Ә мин аның исен бик яратам.

—Син яратасың да, егетләр яратмас бит.

Айгөл кып-кызыл булды. Чәен эчеп бетергәч, ул ишек алдына чыкты. Ул арада Чукаеваның ата казы ысылдап аңа килә башлады. Кулына каяндыр бер чыбык алып, Айгөл аны көчкә куркытты. Айгөлнең кызыл свитерын күргә, сарыклар, бер-берсен таптый-таптый йөгерешеп, бер почмакка өелештеләр. Шул чак Чукаева чыгып:

—Хәзер, кызым, ашыкмый тор, мин аларны ябармын,—диде.

Ата каз нидер сөйли-сөйли аңа каршы китте, әллә инде Айгөлнең керүе турында әләкләде.

—Беләм, беләм,—дип казның башыннан сыпырды Чукаева.—Сиңа чыбык белән суктымыни? Әллә авыртты?—Каз аның сүзен аңлагандай, әбисе сөйләгәндә га-га-га килеп зарланды.—Ярар, ярар, янадан сукмас, бар инде, бар.—Каз, аның әйткәнен аңлагандай, читкә китте. Чукаева абзар эченә кергәч, сарыклар аны сырып алдылар, шуны көткәндәй, ул аяк астындагы саламга чүгәләде. Сарыклар бәрәннәре-ниләре белән аның битләрен ялый, кулларына, башына үреләләр, ә Чукаева сөйли дә сөйли.— Курыктыгызмыни? Ул бит сезгә тими. Ул сезнең урыныгызны чистартырга килгән. Бик әйбәт кыз ул. Янадан курыкмассызмы соң?—Шулай сөйләшә-сөйләшә, ул аларны абзарның икенче ягына алып керде һәм капканы ябып куйды. Бәрәннәр, койма ярыгыннан башларын тыгып, һаман аңа үрелделәр. Ике олы сарык, ул бүлемтекнең киртәсенә ал аяклары белән басып, өстән карап тора башладылар, чиратлашып, бә-бә-бә, дип кычкырып алдылар.

Ул арада абзарның кайсыдыр почмагыннан Чукаеваның карт мәчесе килеп чыгып, аның аягына ышкына башлады.

—Гандәлифә әби, син сарыклар, казлар белән ни сөйләшәсең соң?

Ул элекке килгән чакларында да аның кош-корт белән, сарыклары, казлары, тавыклары белән туктаусыз сөйләшүенә шаккатып китә иде.

—Барысын да сөйләшәм.

—Ни соң ул барысы да?

—Синең белән сөйләшкән кебек,—диде Чукаева.—Алар белән кешеләр белән сөйләшми торганнарны да сөйләшеп була. Кеше сине аңламый, ачулана, мыскыл итә, ә алар бөтенесе дә аңлыйлар. Сине тыңлап, башларын селкеп торалар. Мин аларның акыллы күзләреннән ни сораганнарын, ни әйтәселәрен белеп торам. Игътибар белән тыңласаң, аларның чирләгәнен дә белеп була. Алар үзләре дә шулай: минем чирләгән вакытымда өстемә сикермиләр, мине сөзеп уйнамыйлар, беләләр, хәлемә керәләр. Мал бит ул ачуланып караганны да, төксе эндәшкәнне дә яратмый.

Айгөл аның сүзләрен авызын ачып тыңлады.

—Алар белән сөйләшкәнче, кешеләр белән сөйләшәсең, әйбәтрәк түгелмени?

—Алай түгел шул, балакаем. Кешеләр көннәр буе бер-берсе белән сөйләшәләр, ә мал-туар, кош-корт безне сагынып тора. Аларның күбесе ятим бит. Менә сыерны гына ал, бармы аның әти-әнисе? Кыска гына гомерендә аның да иркәләнәсе килә бит. Ә шуны хуҗасы кыйный, көтүчесе

чыбыркы белән яра. Усал сыерлар сөзә. Бәхетлеме ул? Бозавын сөясе килмиме әллә аның? Юк, кешеләр аны бозавыннан аералар. Менә шул гөнаһыбызны каплау өчен булса да иркәләүгә бик мохтаҗ алар бичаракайларым. Сыерның күзләренә генә кара син: анда бер шатлык та юк, гел моң гына. Ходайның бер көнендә егып суясыларын да белә ул. Суярга бер-ике көн кала сизенә, елый-елый якты дөнья белән хушлаша. Ат та шулай. Мин менә иртән тору белән ишек алдындагы чирәмнәрне башларыннан сыпырам, бакчама кереп агачларга дәшәм, гөлләрем белән сөйләшәм, керфекләренә бармакларымны тигерәм, алар миңа тавышсыз гына рәхмәт әйтәләр. Әгәр шулай булмаса, авыртып торган йөрәгем җиңеләеп китмәс иде. Рәхмәт, диләр алар, ярый әле килден, безнең берүзебезгә күңелсез иде, диләр, бар икәнебезне, исән икәнебезне карап чыктың, диләр. Үсемлекләр йөри алмый, алар бигрәк ялгыз.

—Ә бит алар кешегә буйсынганнар, үзләрен һәлак итәргә ирек бирәләр.

—Алар кешедән әшәкелек көтмиләр, балакаем. Алар беркатлы, ә кеше дигәнең бик мәкерле, мәрхәмәтсез, сабый баланы алдавы ни тора? Ә мал-туар гомер буе кешегә һаман ышана, бездән һаман рәхим-шәфкать көтә. Менә мин алар белән көндез сөйләшәм—мин алар өчен кояш, мин алар янына төнлә дә кереп сөйләшәм; мин ул чакта ай булам. Әллә сиңа рәхәт түгелме маллар, кош-кортлар белән?

—Рәхәт шул,—диде Айгөл.—Аларның миңа карап торулары ошый. Тик алар миннән куркалар.

—Алар белән ник рәхәт икәнен әйтимме?

—Әйе.

—Алар сиңа ышаналар. Менә шуларның ышануын күрү рәхәт тә инде. Ышану дигән әйбер бик олы нәрсә ул.

Икесенә ике сәнәк алып, алар сарыклар утарындагы тиресне өемгә ташый башладылар. Айгөл үзе эшләде, үзе Гандәлифә әбисенең сәерлеген аңларга тырышып баш ватты. Болынкырда аңардан курыкмаган кеше юк бугай. Аның усаллыгы аркасында әллә кемнәрне эшләреннән алып бетергәннәр. Әллә ул Айгөл килгәндә генә йомшак булып күренергә тырыша микән? Әнә бит аның йөзе ничек кырысланды, сөйләгән чакта нинди ягымлы иде. Бөтенләй икесе ике кеше. Бер үк йөз, бер үк күзләр, бер үк иреннәр югыйсә. Бая ягымлы булып, нур бөркеп торган җыерчыклар, кара, ничек тирәнәйделәр, кырысландылар, әйтерсең лә чалт аяз күк йөзен кинәт болыт каплады. Юк, ялгыша Айгөл. Әгәр дә ул килгәндә генә яхшы булып кыланса, анардан мал-туарның, кош-кортларның да коты алынып торыр иде. Серле зат иде Гандәлифә әби. Аның серләрен ачу өчен әле Айгөлгә ул сөйләгәннәрне тагы күп мәртәбәләр тыңларга кирәк иде...

## 10

Сугыш беткәч, батыр күбәя, дигәндәй, сайлауларда Арслановның Татарстан Верховный Советына депутат булып сайланмавын ишеткәч, халык арасында, болай булгач, аны беренче секретарь итеп калдырмаячаклар инде, дигән фикер яшен тизлеге белән таралды. Шуның белән бергә теге яшерен хатка кул куйдыру шактый җиңелләште, элек катгый рәвештә баш тарткан кешеләр дә икеләнмичә имза куйдылар. Ләкин халыкны хәйран калдырган тагын бер нәрсә булды. Райком тарафыннан бик ныклап әзерләнеп, яшен тизлегендә җыеп, яшен тизлегендә үткәрелгән район Советы сессиясендә, төрлечә болгата торгач, көч-хәл белән бер тавыш ясау аркасында Арслановны район Советы башкарма комитеты председателе итеп сайлауга ирештеләр. Бу инде аның райкомның беренче секретаре булып калу ихтималы бик тә зур, дигән сүз иде. Моны аңлагач, Фаиз Шәймөхәммәтов председательләр советын тагын җыйды. Зур күпчелек райком членнары, депутатлар инде хатка имзаларын куйганнар иде. Шәймөхәммәтов җитәкчелегендә бер партком секретаре, бер авыл Советы председателе, катнаш азык заводы директоры Хамматов, хатны алып, өлкә

комитетына киттеләр. Беренче секретарь аларны чиратсыз кабул итте, хат белән танышып чыкты һәм бик җентекләп, райондагы эшләрнең барышы, халыкның тормыш-көнкүреше, ихтыяҗлары турында сораштырды.

—Кайтыгыз, тыныч кына эшләгез,—диде ул, аларны озатып.—Без монда кинәшербез.

Бер атнадан Болынкырга КПСС өлкә комитеты секретаре һәм бер инструктор килеп төште. Алар ике көн буе халык белән очраштылар. Өченче көнне төштән соң партия райкомының оештыру пленумы үткәрелде. Ул нәкъ сәгать икегә билгеләнгән иде. Райком членнары, Батталовтан кала, барысы да җыелып бетте. Бер генә чит кеше дә кертелмәячәк, ябык пленум үтәчәк, дип конференц-залның ишеге төбендә өч-дүрт инструктор сакта торды. Вафин, Саттаров кебек актив коммунистлар, Ирек һәм иҗтимагый үзәкнең унлап члены, әллә ничә мәртәбә ишек кырына килеп карасалар да, аларның берсен дә уздырмадылар. Ике туларга ун минут кала, Чукаеваның баскычтан күтәрелеп килгәне күренде. Ишектән тиз генә кереп китәм дигәндә, аны да туктаттылар.

—Нишләп кертмисез?—диде ул кычкырып.

—Райком членнары гына катнашырга тиеш. Гади коммунистлар кертелми,—диде Миннуллин, аның каршына чыгып.

—Кая обком секретаре?—дип сорады Чукаева.

Ирек аңа беренче бүлмәсенә таба ишарәләде. Чукаева эре адымнар белән шунда кереп китте. Анда Арсланов, өлкә комитеты секретаре һәм инструкторы ни турындадыр сөйләшеп торалар иде.

—Исәнмесез?—дип килеп керде Чукаева.—Ни өчен гади коммунистларны пленумга кертмисез? Бу нинди яшерен эш, понимаешь?! Ветераннар ишек төбендә калтырап торалар, оят, валлаһи!

Өлкә комитеты секретаре Арслановка усал караш ташлап куйды.

—Мин сезгә андый күрсәтмә бирмәдем ич,—диде. Аннары инструкторга ымлады:—Барыгыз, теләгән кешеләр керсен.

Шулай итеп, ишек төбендә җыелган барлык кешеләр, Чукаева артыннан кереп, буш урыннарга утырдылар. Нәкъ икедә пленум башланды.

—Кызганычка каршы, бүгенге пленумда безгә шактый күңелсез нәрсәләр турында сөйләшергә туры килер,—дип сүз башлады өлкә комитеты секретаре. Аның кызыл галстугы шушы эше өчен оялткандай, ут яктысында чагылып, битләренә кадәр кызарта иде.—Сезнең районнан өлкә комитетының беренче секретаре исеменә райком членнарыннан, район Советы депутатларыннан имзалар куелган хат алынды. Ул эшләгән елларда район экономикасы да гел үк йомшаган дип булмый. Әмма иптәш Арслановка башкалар фикере белән санлашмау, хуҗалык җитәкчеләренең вазифаларын үзенә алырга тырышуы комачаулый. Райондагы һәрбер уңыш гел аныкы гына дип игълан ителә, һәрбер уңышсызлык өчен район Советы башкарма комитеты һәм авыл хуҗалыгы идарәсе гаепләнә. Партия, ил тормышында саф җилләр искәндә, демократияләштерү юлында үзгәртеп корулар барганда, мондый стиль эшкә җитди аяк чала. Шәхси әңгәмә вакытында Арсланов үз гаепләрен таныды һәм эштән җибәрүләрен сорап гариза язды.

Өлкә комитеты секретаре сөйләгәндә, Арсланов нәрсәдер язгандай итеп алды, йөзенә кызыл тимгелләр чыкты. Аның дулкынлануын яшерергә тырышуы, соңгы тамчы ихтыяр көчен туплап утыруы сизелә иде.

Өлкә комитеты секретареннан соң аңа сүз бирделәр. Трибунага чыккач, ул ничектер мескенләнгән кебек калды.

—Мин залда сөенеп караучы йөзләр күрәм,—диде ул.—Кайгыручылар юк кебек. Димәк, халык мин киткәнгә куана. Ике дистә елдан артык эшләп, күрәсең, начарлык кына кылганмын. Ашказанына язва, йөрәк чире, нервы чире алулар үзем өчен генә булган икән. Шулай да биш еллык планнарны нигездә үтәп бардык. Аны эшләп караган кеше үзе генә белә. Кадрларны алыштырырга да, партия җәзасы бирергә дә туры килде... Характерымның чатаклыклары бар, кызып киткәндә, ялгыш адымнар да ясыйм. Миннән соң килгән кеше хаталарсыз эшләсен инде...

Чукаева Арслановны тәнкыйтьләргә дип махсус килгән иде. Ул аның пар җирләрен бетереп, гектар биремен арттырып күрсәтеп, ялган күрсәткечләр белән уйнавын фаш итәргә теләде. Әмма Арслановның шушындый чыгышы аны икеләнергә мәҗбүр итте. Шунын өстенә бер-бер артлы трибунага менеп, кем ничек булдыра ала, аны тәнкыйтьләргә тотындылар. Гандәлифәне иң хәйран калдырганы Өлфәт Җәмилов чыгышы булды.

—Арсланов эшли башлаганда бик гадел иде,—диде ул.—Аннары ул тәмам бозылды. Ул ялагайларга, әләкчеләргә юл ачты. Шул юл белән күпләр житәкче урыннарга үрләделәр. Иң гадел житәкчеләрнең берсе булган Шәвәлиевның дәрәҗәсе күтәрелә башлагач, беренче секретарь аны районнан ук куды. Ялагайларга акчасы да бирелә, фуражы да кайта, разнарядка буенча ашламасы да мул бирелде. Ә безнең кебекләре үзләренең гадел көчләре хисабына житәкчелек итәләр.—Җәмилов башын әле уңга, әле сулга боргалады, әле президиумга, әле залга карады. Кая гына караса да, ул үзенә теләктәшлек таба алмады. Артына таба башын боргач, ахырда сүзен шул хәлендә дәвам итте:—Сез миңа үпкәләп карап утырмагыз, Минзаһит Усманович, менә мин өч катлы бер йортны һаман планга керттерә алмыйм. Сезгә мөрәҗәгать итмәдем түгел бит. Аннары шунысын да әйтим, соңгы елларда ите-балы кирәк булса да, шылтыратып, акчасыз гына ала торган иттегез.

Шулчак залдагы урыннардан берәү аның сүзен бүлдерде:

—Син ни өчен өлкә комитетына язган хатка кул куймадың? Хәзер үзен Арслановны хурлыйсың.

—Әйтәм, хәзер әйтәм!—дип башын тагын да җәһәтрәк болгый башлады Җәмилов.—Әгәр мин дә кул куйсам, яшь житәкчеләр миңа ияреп, берни уйламыйча, имзаларын сырлаячак иде. Кем белә, бәлки мин ялгышырмын. Мин, гадел булсын, дидем. Мин гаделлек өчен гомеремне бирергә әзер.

Аның бу сүзләреннән зал күтәрелеп көләргә тотынды. Шулчак Чукаева торып басты да, кычкырып:

—Трибунадан төш, иблис!—диде.—Миңа сүз бирегез әле!

Рөхсәт алгач, ул трибунага чыгып басты да йөзен аска иеп иснәгәндәй итте, аннары борынын жыерып, читкә борылды һәм:

—Фу, әшәке исе һаман килеп тора,—диде.

Зал пырхылдап көлеп җибәрде һәм гөрләтеп кул чапты. Шуннан соң ул тирән дулкынланып сөйләп китте:

—Мин бүген, иптәшләр, бөтенләй бүтән нәрсәләр турында сөйләрмен, дип килгән идем. Уйларым чуалды. Шуңа күрә чыгышым буталчык булса, гафу итәрсез. Сезнең каршыгызда гомер буе райком белән көрәшкән, шунын аркасында ару гына урыннардан колак каккан карт коммунист басып тора. Нәрсәләр өчен каян алып атылганымны сөйләп тормыйм, өлкәнрәкләр беләдер. Тик шунысын гына әйтеп үтим: район орлыкчылык инспекциясе начальнигы эшеннән мине терәлеп торган күршем Арсланов алып атты. Мин аны шул чакта ук аңладым. Башка чарасы юк иде мескеннең: күз буяп, орлыкларның сыйфатын әйбәт итеп күрсәтмәсә, эш харап. Менә сез, залда утыручылар, барыгыз да кечкенә орлыктан барлыкка килгәнсез. Орлыгы нинди—кешесе шундый. Ә гомер буе начар орлыкны әйбәт дип күрсәтеп отчет бирү дәвам итә. Кешеләр арасында эшләр тагын да хәтәррәк. Орлык хуҗалыкта берничә партиягә аерыла, ә кешеләр бөтенесе бер партиядә. Орлык җансыз кебек, әмма аның җаны кабык эчендә. Бикле хәлдә саклана. Туфракка төшеп, дымы-җылысы булгач, ул шытып, үсеп китә. Халык та шулай. Халык та берничә партиягә керергә тиеш.

—Сез тикшерә торган мәсьәләдән читкә киттегез, иптәш Чукаева,—дип бүлдерде аны өлкә комитеты секретаре.

—Ә-ә-ә, килеп төртелдемени?!—диде Чукаева аңа борылып.—Менә халык күз алдында сезнен системагыз: дөреслектән куркасыз. Бер генә партия халыкнын авызын томалау өчен иң кулае инде ул.

—Сез кулыгыз житмәс нәрсәләргә үрелмәгез әле, йә абынып куярсыз,—диде секретарь кисәтүле тавыш белән.

—Куркытмагыз! Богауларымнан тыш минем югалтыр әйберләрем юк. Нәкъ Маркс бабай әйткәнчә. Үзегезгә ошамаган фикерне бер дә яратмыйсыз. Менә сез, шушы кадәр халыкның күзенә карап, Арслановны үз теләге белән гариза язды, дидегез. Нигә аны көчләп гариза яздырдык, димисез? Без орлыкларны гомер буе фракцияләргә аердык. Ленин вакытында партиядә фракцияләр бик югары бәяләнгән. Әгәр шундый тәртип булса, Арсланов бүген мондый хәлгә төшми иде. Астан тәнкыйть юклыгын сизгән житәкче ачык кибет янында калган каракка әйләнә дә куя. Каравылчы юк, күрүче юк—жаның теләгәнен кер дә ал. Гомер буе шулай булсын әле сиңа—бозылмыйча кая барасың... Хәзер безгә бер кешенең гади әшәкелекләрен тикшерәбез кебек тоела. Туганкайларым, нишләп соң ул әшәкелекләр аңа ябышканнар, ә миңа түгел? Бусы бер. Икенчедән, аныкымы соң алар? Агачның кәүсәсенә ботаклар өскә карап үскән кебек, ник алар шулай тезелгән? Бу бит система...

Пленумда тагын бик күпләр чыгыш ясады. Изабелла Хасбулатова райком членлыгыннан һәм редакторлыктан азат ителде. Хасбулатов райком членлыгыннан чыгарылды, аның эштә калу-калмау мәсьәләсен хәл итүне югары органнарга йөкләделәр. Нәҗмиев үз гамәлләре өчен гафу үтенеп, чыгыш ясап, аңа учет карточкасына язып шелтә белдерү белән чикләнделәр. Партия райкомының беренче секретаре итеп бертавыштан Әхнәф Шәрифуллин сайланды.

***

Сөембикә пленумнан нишләптер башы авыртып, йөрәге чәнчеп кайтты. Кызы Айгөл кич мәктәпкә дискотекага дип китте. Ул, йөрәк дарулары эчеп, чишенмәгән көе генә караватына менеп ятты. Ләкин күпме генә ятса да, йоклый алмады. Күңелен нәрсәдер актарды, телгәләде, гүя ул ниндидер олы җинаять эшләп, кан коеп кайткан иде. Шулчак ишек шакыдылар. Аягына йомшак чүәкләрен киеп, Сөембикә чыгышлый утны яндырды һәм тышкы ишеккә килде:

—Кем бар?—диде ул.

—Мин бу, Сөембикә.

Ул Арслановның тавышын шундук таныды һәм, ни эшләргә белмичә, ник икәнен дә белмичә, ишекне ачып җибәрде.

—Сез нишләп йөрисез, Миңзаһит Усманович?!

—Мин сине күрергә килдем, Сөембикә,—дип пышылдады Минзаһит.—Мин "Волга" белән. Ярты сәгать вакытыңны бир миңа.

—Сез нәрсә?! Минем хәзер кызым кайтып керәчәк.

—Шуңа күрә әйтәм дә бит. Мин исерек түгел. Мин синең кызгануыңны гына телим. Мин берни дә теләмим.

—Хәзер күршеләр күрә, китегез.

Арслановның күзләре сәер булып елтырап алдылар:

—Әгәр син аңларга теләмисең икән, мин китәм. Ләкин иртәгә Ык елгасы төбеннән табарсыз, "Волга" машинам белән бергә.

—Сез коточкыч сүзләр сөйлисез.

—Әйе, коточкыч. Ә бер карасаң, бик җиңел дә. Ләкин син чыксаң, мин әле ул җиңел юлны сайламам, миңа син китергән газап кадерлерәк. Машинада көтәм, Сөембикә.—Ул кызу-кызу атлап чыгып китте.

Машина ишегенең шартлап ябылганы ишетелде. Сөембикә йөгереп өйгә керде дә урындыкка утырды. Нишләптер бармаклары белән чәчләрен араларга тотынды. Аның башы эшләүдән туктады. Ул акылы белән яхшы белә: аның Арслановка бернинди бурычы да юк, түлисе түләнгән, аласы алынган. Тик нишләп соң ул аңа карыша алмый? Югыйсә бит ишекне ябып кына куясы. Ләкин Сөембикә моны эшли алмаячагын ачык тойды. Аны үз гомерендә беркем дә Арсланов кебек иркәләмәде, беркем дә алай

ярата алмады. Бәлкем аларның очрашуы очраклы булмагандыр? Ул шушыларны уйлый-уйлый киенеп бетте. Утларын сүндереп, ачкычны яшерен урынга куйды да "Волга" машинасының алгы ишегеннән кереп утырды.

—Рәхмәт,—дип пышылдады Арсланов, янындагы баганадан төшкән яктылыкта Сөембикә аның күз читеннән елтырап яшь бөртеге тәгәрәп төшкәнен күрде. Арсланов машинаны кабызды һәм урам буйлап алып китте.

—Без кая барабыз?—диде Сөембикә куркынып.

—Белмим.

—Алайса мин төшәм.

—Син төшә алмыйсың инде.

Сөембикә аңа куркынып карады:

—Бу ни дигән сүз?

Арсланов елмайгандай итеп куйды:

—Борчылма, мин синең эш урыныннан төшә алмавың турында әйттем.

Ул машинаны Болынкыр читендәге зиреклек буена туктатты.

—Минем синнән кинәш сорыйсым килә. Үземне мин ничек аерып алыйм?

—Нәрсәдән?

—Синнән, Сөембикә.

—Унсигез яшьлек кызлар, егетләр сөйләшә торган мондый сүзләр миңа күптән тәэсир итми, Миңзаһит Усманович.

—Ә мин чынлап сорасам?

—Чынлап сорасагыз, чарасын беләсез ич: ераккарак китү.

—Китү... Дүрт хәрефле сүз. Ә шушы гамәлдә күпме газап, күпме бәргәләнү ята... Сөембикә!—Ул кинәт Сөембикәнең кулын тотып алды, аның бармаклары калтырый һәм уттай яна иде.—Әйдә, Казанга китәбез, мин синең өчен күптән квартира әзерләдем.

—Бу хакта сүз дә булуы мөмкин түгел.

—Әйе шул,—дип килеште аның белән Арсланов.—Мин карт бит инде. Тик шуны бел: син миңа хатын-кыз буларак түгел, фәрештә буларак кирәк. Синең алда ике юл бар: берсе—монда, көне-төне башны-күзне тондырып чабу, ялгызың бала үстерү, аннары аны укырга кертергә алып барып, кире борылып кайту, квартираң тузып, ремонт уздыру мәшәкатьләре, йөрәк-нервы чирләре кузгалу; икенчесе—Казан; дәрәҗәле урын, дан, кызыңның укып зур кеше булуы, япь-яшь сөяркәләр...

—Ник сез мине мыскыллыйсыз?!—диде Сөембикә, тавышын күтәреп.—Әгәр шуның өчен чакырган булсагыз, сөяркәләрегез үзегезгә булсын...—Ул ишекне ачты.

Арсланов, җәһәт кенә үрелеп, ишекне кабат япты:

—Мин сине түгел, үземне мыскыллыйм. Тик син миңа кирәк. Янымда булсаң, шул җитә. Шуның өчен мин сиңа бөтен тырышлыгымны, җанымны бирәчәкмен. Курыкма, мин бит бергә яшәү сорамыйм. Бары тик бик әрнегән чагында бер очрашып сөйләшсәк, шул җитә.

—Гафу итегез, Миңзаһит Усманович, сезне бүген яралы күңелегез ялгыштыра. Сез ничә еллар утырган урыныгызны югалтудан чыккан әрнү бу.

—Әйе, власть—уен,—диде Миңзаһит салкын тавыш белән.—Үзеңне өстәгеләргә дә, астагыларга да сатасың.

—Китәргә теләмәдегез бит.

—Әйе, аңардан китүе авыр. Менә мин синнән котыла алмаган кебек. Кем син? Әллә минем үзем, әллә инде минем үземнән дә артык. Минем беркемгә дә серемне ачканым юк иде. Мин бер генә хатынга да мондый тәкъдим ясамадым. Әгәр карышсаң, өрәгем гомер буе сине эзәрлекләр.

Арсланов машинаны кузгатты. Кайтып җиткәнче алар бер сүз дә дәшмәделәр. Капка төбендә машинаны сүндергәннән соң гына, ул:

—Мин уйнап йөрмим, Сөембикә,—диде.—Сине барыбер алып китәм. Көчләп, урлап булса да...

—Сез мине әйбергә хисаплыйсыз...—диде Сөембикә әрнүле тавыш белән.—Әйе, кайчандыр әйбер дә булганмындыр, ләкин хәзер юк! Беркайчан да!..

—Ә син күзләренне ачыбрак кара: безнең тирә-юнебездәге әйберләр һәммәсе дә берни дә түгел. Менә кара...—Ул йодрыклары белән машинаның рулен, приборлар щитын дөпе-дөпе төйде, өстендәге костюмын, чалбарын йолыккалады.—Болар әйбер түгел, болар бөтенесе дә бушлык, ә менә бер елмаю—иң бөек әйбер. Бер күз карашы—җирдә иң кыйммәтле әйбер!.. Суга да батмый, утта да янмый, беркайчан да искерми дә.—Ул бераз гына тынып алды.—Ә бәлкем чыннан да әйбер түгелдер... Бәлкем электр тогыдыр... Белмим...

Сөембикә аның руль тоткан кулының сыртын җиңелчә генә кысып куйды:

—Хушыгыз.—Ул машинаның ишеген тавышсыз гына ябып чыкты да кызу-кызу өенә кереп китте...

## 11

—Беренче эш көнегез белән котлыйм,—диде Нәҗмиев, Әхнәф бүлмәсенә кереп һәм аның кулын кысып, озак итеп селкеп торды.

Алар икесе дә утырдылар.

—Ну, пленумнан тәэсирләрегез ничек?—диде Әхнәф, аның күзләренә туп-туры карап.

—Файдалы булды, дип уйлыйм. Тәнкыйть конфет түгел, түзәргә туры килә,—диде Нәҗмиев, сул күзен кысып.—Эш өчен дип, халык өчен дип, кайчакта упкынга сикергәнне дә сизми калабыз шул.

—Арымадыгызмы соң?—Әхнәфнең бу соравы Нәҗмиевны сагайтып җибәрде, ул нишләптер елмаюга елмаю белән җавап бирми иде.

—Әле арыдым дип әйтә алмыйм,—диде сак кына.—Яраткан эш арытмый ул.

—Әйе, үз эшегездә сез оста дирижер кебек... Шулай да кичерегез, мин сезгә ялга чыгарга тәкъдим итәр идем.

—Мин чираттагы ялымны бөтен кешедән соң, ноябрь айларында гына алырга яратам.

Менә шушы урында Әхнәф сәер генә елмаеп куйды:

—Гомумән ялга чыгу турында әйтәм мин.

—Мине Арсланов кешесе дип курыксагыз, ялгышасыз.

—Сез беркем кешесе дә түгел. Әгәр сайлаулар вакытында миңа ачылмаган булсагыз, мин сезгә кагылмаган да булыр идем.

—Сезгә зыян салдыммыни? Без уйлаганча барып чыкты бит.

—Барып чыкмаса, сезнең башка вариантларыгыз бар иде... Куркыныч кеше сез, Кәрәм Нәҗмиевич. Әгәр эш кирәк дисәгез, табарбыз. Ләкин райкомда сезне калдыру мөмкин түгел.

—Райкомда булмагач, миңа кирәк түгел.

—Без сезгә тынычрак, акчалырак урын тәкъдим итә алабыз.

—Рәхмәт. Оркестр кирәк миңа...—Нәҗмиев торып чыгарга борыла башлады да кабат туктап калды.—Сезгә бер генә үтенечем бар, ялварып сорыйм: зинһар мине үз теләге белән китте, диегез. Ә эшемне кемгә тапшырыйм?

—Һәр нәрсәнең үз чираты бар, Кәрәм Нәҗмиевич,—диде Әхнәф һәм, сүзнең беткәнен аңлатып, телефоннан номер җыя башлады...

***

Ирек кичкырын Ык буена төшкән иде. Җил көчәйгәннән-көчәя барды, көнчыгыштан кубарылып кара болытлар күренде, әле язгы болганчыклыгы да бетмәгән Ык суы, шул болытлар астына кояш

кереп качкач, каралып китте. Бала йоннары кабарып, Ирек тәннәрен жыерып куйды. Өч көн инде жил котыра, әмма янгыры юк. Халык түземсезлек белән янгыр көтә. Сыртларын кутәреп килгән дулкыннар, сикереп чыгарга теләгәндәй, ярга бәреләләр. Ирек сәгатенә карап алды, Зәнфирәнең эштән кайтыр вакыты да житкән иде. Ул ямьсезләнеп, шаулапкайнап торган чытык йөзле Ык өстенә тагын бер карап алды да кайтып китте. Муенын өттергән салкын жилдән саклану өчен плащ якаларын кутәрде, эшләпәсен батырыбрак киде. Капка турына житкәч, тыкрык башыннан кайтып килүче Зәнфирәне күрде. Зәнфирә килеп житәр-житмәс:

—Райкомнан шылтыраттылар, сине Әхнәф чакыра,—диде.

—Кайчанга?

—Бүген алтыга. Әллә эш бирә микән?

—Минем бит әле эш сораганым юк...

Юынып чәй эчкәннән соң, Ирек райкомга китте.

Зәнфирә ашамады, эчмәде, Ирек китү белән чоланнан Заһитның хатын алып керде. "Зәнфирәмә..." Инде ничәнче мәртәбә укый икән инде ул аның хатын? Анда язылган һәр сүз күптән Зәнфирәнең хәтеренә кара күмер белән уелган. Жидесен, кырыгын уздыргач, хәле жиңеләер дип көтте, әмма өмете акланмады. Йөзенә сарылык инде, күзләре тоныкланды, борыны мәетнекедәй очлаеп калды. Эшкә баргач, йә булмаса танышлары очрап хәленә кергәндә, ул рәхмәт әйтәсе урынга эчтән ярсыды, аларга рәнжеде, шулай кылануына үзеннән жаны бизде. "Әллә Заһитның жаны минем эчемә кереп утырды микән?" дип уйлады коты очып. Ул эшендә авыруларга әллә ничә мәртәбә бер дару урынына икенче дару бирә язды һәм, шуннан өркеп, шприц белән дару суырта башласа, дару төймәләре өләшә башласа, аларның өстенә язылган язуларны кабат-кабат карады, шулай мәшәләнеп, процедураларны соңартты, кисәтү-шелтәләргә дучар булды. Бүлек мөдире белән өлкән шәфкать туташы аңа ял тәкъдим иттеләр, ләкин Зәнфирә баш тартты. Әгәр өйдә утырса, ул акылдан шашасын чамалый иде, шуңа күрә бөтенесен эш белән басарга, һәммәсен онытырга теләде.

Бүген ул катгый карарга килде: бөтенесен дә яндырырга! Көчәйгәннәнкөчәя барган бу газаплары, мөгаен, аның васыятен үтәмәүдәндер. Көйрәгән күзләре белән ул соңгы мәртәбә иренең хатын укырга кереште:

"Зәнфирәм!

Кеше үзенең һәр гамәле өчен кайчан да булса түли. Менә минем дә хисап тотар чагым житте. Гомеремнең шушы фажигале чигендә шактый нәрсәләрне яңача күрә башладым.

Без, кешеләр, ни соң без? Бер карасаң, туфрак кебек. Анда һәммә нәрсә үсә. Әллә янган ялкынмы? Жирдән бәреп чыккан чишмәме? Төгәл әйтүе кыен. Моның әһәмияте дә шуның кадәр генә. Чөнки күреп, тотып карап була торган кеше төп жисем түгел. Бөтен хикмәт ул жисемнең эчендә һәм тышындагы иксез-чиксез галәмдә. Хәзер шуны аңлатырга ниятлим.

Мин бәләкәйдән үк үлемнән коточкыч курыктым. Ул хакта уйласам, тыным кысыла, йөрәгем туктый, тамырларыма боз салкыны йөгергәндәй була иде. Шуңа күрә сәламәтлегемне саклау өчен барысын да эшләдем, үз дигәнемә ирештем дә: гомер буе томау да төшкәне юк. Утыз икешәр килограммлы ике герне кулларымда уйнатканымны син сокланып карап тора идең. Кимендә йөз яшькә житәчәгемә әз генә дә шикләнмәдем. Мин, өч сәгатьтән үләсен белгән кеше дә аны һич югы өч көнгә сузу өчен көрәшергә тиеш, дигән уй белән яшәдем. Кеше беркайчан да үлем белән килешмәскә тиеш! Аның каршында тез чүгү—әхлаксызлык! Минем карашларым шундый иде. Һәм син аларны әйбәт беләсең. Гел көтмәгәндә, кинәт мин үз гомеремә үз ихтыярым белән чик куярга ният кылдым. Ни булды? Башка сыймаслык бу рәхимсез гамәлне кылучы минме соң? Әйе, мин һәм үз акылымда. Ләкин бит мин тумыштан, бөтен вөжүдем белән үз гомеремә тукынудан мәхрүм ителгән кеше. Димәк, моңа кадәр үземне белмәгәнмен булып чыга. Үземне генә түгел, сине дә белмәгәнмен икән. Мин бит, Зәнфирәкәем, сине мәктәптә укыган чагыңнан ук яраттым. Һәр

гамәленне, һәр адымынны күзәттем, йөрәгемә беркетеп, "З" исемле калын дәфтәргә язып-теркәп бардым. Сине шашып яратуымны мәктәптәге эшем, хуҗалыктагы мең төрле мәшәкатьләр белән бастым. Өйләнешеп бергә яшәгәндә, икебезнең бер тән, бер җан булуыбызга әз генә дә шикләнмәдем. Менә хәзер генә янәшәмдә мин белмәгән олы, серле, мин аның эченә күз дә сала алмаган галәм булганлыгын аңладым. Мин ул галәмнең эченә түгел, тышына да керә алмаганмын...

Икебез хакында уйланган саен хәйран калам. Мең сораунын берсенә дә җавап юк. Хәзер соң шул, ә гомер буе, көн саен уйланырга кирәк булган! Ул чакта бәлкем сораулар да кимер, олы фаҗига да булмый калыр иде.

Кешеләр, шул исәптән, мин дә тышыбыз, кабыгыбыз белән генә яшибез ахрысы. Ул кабыкнын эчендә бер галәм, тышында тагын иксез-чиксез җиһан барын онытабыз, аларнын эченә керә алмыйбыз. Ә бөтен бөек мәгънәләр шулар эчендә. Менә шуна күрә хәвефле адымнар ясала, яшәвебез аңлаешсызрак була бара.

Мин үлем турында яздым инде. Тагын минем өчен уйларга да куркыныч нәрсә кеше үтерү иде. Башка кешенең җанын кыюны, нинди генә максаттан эшләнсә дә, мин вәхшилек дип кенә кабул иттем. Гомер буе шушы гаделсезлек хакында мин тетрәнеп уйлана идем. Бервакыт миннән китәчәгеңне әйткәч, сине юк итү теләге уянды. Әйе, син аның янына киткәч, ул теләкне тормышка ашыру өчен өлгереп життем. Элекке Заһит каядыр юкка чыкты, минем уйларым, эш-гамәлләрем белән икенче Заһит идарә итә башлады. Әле бусын беркадәр аңлап була. Чөнки бергә яшәгәндә, ташлап китәрсең, дигән уй башыма да кереп карамады. Мин синең дөньяңны бала вакытыңнан ук пыяла колбага салынган чиста суны күргәндәй күреп тордым. Мин бары бер нәрсәдән—үлемеңнән генә курыктым. Бигрәк тә син авырып, Казанда дәваланып кайткач. Синең гомереңне озайту өчен җан аттым. Бу минем бердәнбер максатыма әверелде. Сине шулкадәр яраттым микәнни?!

Теге вакытта өегездә, дәфтәрләрне алырга дип кергәч, мин Ирекне үтерүгә дә бик якын идем. Мендәр астында ул инде бәргәләнә, карыша алмый башлаганда, ничектер чигендем. Соңрак, исән калганын белгәч, шуңа куануымны белсәң! Мин бит көнчелектән тулысынча мәхрүм. Синнән дә, Ирекстән дә, башкалардан да көнләшмәдем. Ә сине нык кызгандым, хәзер дә кызганам. Ләкин кызганган кешеннең гомерен өзеп буламы? Инде бер мәртәбә икегезнең арагызга кердем бит. Шул хәлемдә дә кул күтәрергә әзер идем. Мин әле Зирәгебезне дә кызгандым. Ни өчен ул әнисен югалту фаҗигасен кичерергә тиеш? Ләкин улыбыз турындагы бу уйларым ерактагы яшен кебек уйнап кына алды да юкка чыкты. Күрәсең, мин чыннан да бүтән Заһит, аның әтисе түгел идем.

Бераздан мин үземнең сезнең арагызда артык икәнемне аңладым һәм шушы юлны сайладым. Тора-бара мине өчебезнең гомерен берәм-берәм кисү уе кызыктыра башлады. Әүвәл бу ниятләрнең һәркайсы мине шашар дәрәҗәдә хәвефләндерсә, соңга таба мин әлеге гамәлләремне ничегрәк тормышка ашыру турында салкын кан белән фикер йөртергә тотындым. Кайда соң элекке мин?! Кая югалдым? Әгәр бу мин икән, ни рәвешле шушы дәрәҗәдә үзгәрдем? Минем соңгы вакыттагы ниятләрем гомер буе инанган тормыш фәлсәфәмне, бөтен яшәү, уйлау, кичерү рәвешемне тар-мар итеп, нәкъ шуларнын капма-каршысына ничек итеп китереп житкерә алдылар?! Кеше ничә мәртәбә шулай капма-каршы якка үзгәрә ала? Мин бит гипноз астында йөрмим. Анда да кеше үзенең төп карашларына каршы бармый, диләр. Минем эчке галәмем белән тышкы галәмемә ни булды? Бер сүз белән: бөтенесенә мәхәббәт сәбәпче, дип җавап биреп була, әлбәттә. Күп баш вата торгач, мин шиккә дә төштем: чыннан да бармы икән соң ул? Сине өзелеп яратам һәм үтерергә әзерләнәм. Ә үзем? Тормышны минем кебек яратучы кешеләр бик аздыр бу дөньяда. Үзем ук шул тормышны ташлап китәм. Монда мине әйләндереп салган бер нәрсә бар барын. Ул—кешеләр күзе алдында ким булып яшәргә теләмәү. Мин моны күтәрә алмаячак идем. Бу

үз-үземне артык яратудандыр да бәлкем. Алай дисәң, үз-үзен шул дәрәҗәдә яраткан кеше гомерен чикләргә сәләтсездер. Бу адымны кызулык белән бер селтәнүдә ясамавымны сиңа җиткерәсем килүдән язам. Монда дуамаллыкның эзе дә юк. Әмма серле мизгелләр артканнан-арта.

Мизгел саен капма-каршы үзгәреш, әверелеш. Элекке син белгән мин ерақта, томан эчендә калдым. Әллә тотрыклы өлешем гел юк микән? Судан утка, җирдән һавага туктаусыз әверелү әкияттә генә була. Тик тотрыклы вөҗүдтән башка була алмый. Әгәр шулай икән, аны ни нәрсә шул кадәр җимерә, үзгәртә ала? Гомер үребезнең түбәсенә таба җитәкләшеп күтәрелгәндә, син, башыңны югылтып, кинәт кенә читкә ташландың. Моның сәбәбен аңа булган мәхәббәтең, диден. Ә бит адәм балалары гомер-бакый үзләренә кирәк әйберләрне уйлап чыгарганнар. Шундый очрак түгелме икән бу? Әгәр чыннан да мәхәббәт булса, ул баштук җинәр иде. Ә син мине сайладың. Минем мәхәббәт җиңгән булып чыга түгелме соң? Әгәр мин сиңа өйләнмәсәм, гомеремне өзүгә дә бармас идем. Бөтенесе бер адымнан китте: минеке—һөҗүм, синеке—чигенү адымы. Җәза шуның өчен. Яман шеш сыңар күзәнәктән башлана. Кечкенә әйбер—иң зур әйбер. Мин бу хакыйкатьне балачактан ук аңладым һәм, янәсе, бик отышлы файдаландым. Мин үз алдыма авылда кешеләрдән берничек тә аерылмаучы иң гадел, иң тыйнак тормыш белән яшәү максатын куйган идем. Киресе килде дә чыкты: мин авылның иң бай кешесенә әвереллдем! Нинди кануннар башкарды моны?

Мин тормышта үз эземне калдырырга тиеш кеше идем. Барып чыкмады. Кешеләр дөрес яшәми, алар әйберләрне генә түгел, хис-тойгыларын, гомерләрен җилгә очыралар. Мин аларны эчемнән хөкем иттем һәм исрафсыз яшәргә өйрәтергә алынмакчы булдым. Тик нишләптер ул уемнан кире кайттым. Әллә аларның үземнән акыллырак яшәвен күпсендемме икән? Әйтә алмыйм. Мина яшерен алып барган үз тормышым үтә дә кадерле иде. Мин ул тормышны беркемгә дә ачмадым. Хәзер дә шуны телим.

Мин синсез яшәмәкче булып карадым. Бер башына сулы чиләк асылган көянтә белән кеше көлдереп күпме барасың? Югыйсә, көч-куәтем егерме яшьлек егетләрнеке кебек! Дәрт-дәрманым ташып торганда, сиңа кызганып карамасыннар икән лә ул!

Мин куркаклыгым аркасында китмим. Кеше үлгәннән соң да аңардан нидер кала. Аллага ышанмасам да, анысына ышанам. Мин тиздән үземнән ни калганын тоячакмын. Мин кешенең биологик яшәешен ярыйсы гына өйрәндем, аңладым. Ә менә үлгәч кала торганы—сер. Без әле җиһанның кайсыдыр почмагында очрашачакбыз. Синен елмайганыңны, көлгәненне, сөйләшкәненне күрәсем килә. Шушыңа ышанганга күрә, курыкмыйча, бөтенесен әзерләп бетереп китәм. Иртәгә иртән мин үзем гомер буе баш ваткан серле күренеш белән очрашачакмын. Дөресрәге, миннән шул гына калачак. Ни ул минем субстантым?!

Зәнфирәкәем! Мин синең алдыңда баш иям. Син җиңдең. Сонарып булса да, юлыгыздан китәм. Кичерә алсаң, кичер... Үтенеп сорыйм: улыбызга дөресен әйтмә, җаныма җәһәннәм утлары салма. Минем үлемемнең чын сәбәбен белә алмаячаклар. Мондый очракларда "йөрәк туктаган", дип языла. Бу хатны теге дәфтәрләр белән бергә яндыр. Әгәр шушы теләгемне үтәмәсәң, рәнҗеп ятармын. Хуш, күз нурым! Бөтен җиһанда сине генә яратучы Заһит абыең."

Зәнфирә, чиләгенә туз, чыралар, коры әрдәнәләр салып, ындыр артына чыгып китте. Яшел чирәм инде баш калкыткан. Күп тә үтмәс, бәбкә үләне, бака яфрагы, ак әрем, әнис, меңъяфрак, сарут, һиндыбалар чәчәккә бөреләнер, яр буйлары аларның исерткеч исенә күмелер. Зәнфирәгә киемнәрен тарткалаучы бу усал җилне, дөм орынган болытларны Заһит рәнҗеп куалыйдыр шикелле тоелды. Ул чыраларны, әрдәнәләрне үләнсезрәк җиргә салып, асларына туз тыкты һәм кабызып җибәрде. Коры агач кисәкләре корымлы зәңгәрсу төтен чыгарып кабынып киттеләр, пырлап яна башладылар. Ялкын телләре төтеннән арынгач, Зәнфирә иң элек әлеге хатны, аннары төрлечә ботарлап, ерткалап дәфтәрләрне шул ялкын өстенә ташлый

башлады. Кәгазьләр янып, кара күмер хәленә килделәр дә, читләрендә кызыл утлы каймалары сакланган хәлдә, яшел чирәм өстеннән каядыр шудылар, күтәрелеп очтылар, күздән югала бардылар. Кайберләре шушы ялкыннан китмәде, күтәрелмәкче булып калкына-калкына янды да янды...

Зәнфирәнең күзләрен элпә каплады. Заһит та кеше иде бит. Үтелгән еллар, шатлыклы һәм шатлыксыз көннәр бик тә кызганыч иде. Әйтерсең лә ул еллар кәгазь кебек янганнар да янганнар, яшел чирәм өстеннән утлы кара яфраклар кебек йөгерешкәннәр, вакыт эченә кереп югалганнар... Учакның сүрелә башлавын күреп, ул дәфтәрләрне ерткалавын дәвам итте, "бүген житмеш бер мең секунд бушка очты...", "Литры егерме ике тиеннән утыз литр бензин...", "Эш хакы ... сум". Күз яшьләре арасыннан Зәнфирә алдагы сүзләрне таный да алмады, бу язылган әйберләрнең, андагы бәяләрнең, үлчәнгән секундларның хәзер инде бернинди дә әһәмияте юк иде. Алар һаваны рәшә кебек дөрелдәтеп торучы ялкынга әвереләләр дә, усал җил ул кайнарлыкны шундук еракларга алып китә, аларны куып тотарга теләгәндәй, күмерләнгән кәгазь ертыклары чирәм өстеннән йөгерешәләр.

Күз яшьләрен сөртә-сөртә, Зәнфирә тагын кәгазьләр ташлады, аларның янган кисәкләре тагын кара кошлар кебек читкә оча бирделәр. Заһит та кеше иде бит... Аның үткән гомере, өзелгән гомере өчен рәхәтләнеп елады Зәнфирә...

Заһит хакында алар Хәлимә белән күп мәртәбәләр сөйләштеләр. Соңгысында Зәнфирә:

—Аның мондый адымны ясавына мин һаман да ышанып бетә алмыйм,—диде, яшь тулы күзләрен мөлдерәтеп.—Ул моны эшли торган кеше түгел иде. Бу—нииндидер шайтан, җен гамәле.

—Ә мин аның серен таптым,—диде Хәлимә.

—Нәрсә ул, әйт?

—Заһитка язмыш үз гомерендә беренче мәртәбә күсәк белән орды. Ул, корычтай кеше, шартлады да сынды. Заһит гомер буе тигез юлдан атлады. Язмыш ана мона кадәр каныга, кул тигерә алмады. Әгәр баштан ук аны кыйный-кыйный килсә, ул түзәр иде. Заһитның сыгылмалылыгы булмаган...

Бәлкем Хәлимә апасының бу сүзләре дөреслеккә туры да киләдер.

Кинәт кургаштай авыр болытлар арасыннан кояш күренеп китте. Ул карадан киенгән хатынның, кеше яшәми торган утрауга ялгыз эләккән бәндә кебек, нишләп учак ягуын аңламыйча карап торды. Ул хатын да кеше иде, әмма ул бер генә мәртәбә дә йөзен өскә күтәрмәде. Йөзен чытып, кояш болыт арасына качты...

***

Райкомның ишегеннән керүгә, Ирек аптырап китте: биредә бөтен җиргә цемент, кирпеч, башка төзү материаллары таратылган, аяк астында ком, известь тузаны. Ул икенче катка менде, әмма беренче секретарь бүлмәсенә керү насыйп булмады: аның бүлмәсенә чыга торган ишеге стенасы белән бергә сүтелгән иде. Ирек аптырап борылып чыкканда, аны Әхнәф каршылады:

—Бүлмәне бераз зурайтырга, үзгәртергә булдым әле,—диде ул елмаеп.—Шушындагы үзгәрешләр бөтен район буенча таралырлык булсын.

Ул үзе аста өченче секретарь бүлмәсендә утыра икән. Шунда кереп чишенгәч, Әхнәф акрын гына сүз башлады:

—Көннәр ничек тиз уза!—диде ул, гаҗәпләнгәндәй баш чайкап.—Эшли башлаганга бүген бер ай. Әле ныклап уйланырга да, нииндидер планнар корырга да вакыт тимәде. Тик мин бер нәрсәне аңладым: синнән дә якын кешем минем булмаган һәм юк икән. Рәхмәт сиңа...

—Мин әлегә рәхмәт әйтерлек берни дә эшләмәдем.

—Эшләдең, Ирек. Әгәр сез булмасагыз, Арсланов элеккечә үк шоп-шома гына сайланачак иде. Зур эш башкардыгыз сез. Миңа синең ярдәмең кирәк.

—Мичәүгә җигәргә уйламыйсыңдыр бит?

—Редактор урыны буш. Әллә тәвәккәллисеңме?

—Син минем партиядән куылганны оныткансың ахры.

—Ә мин ул хакта өлкә комитетында сөйләшеп кайттым, кабат алабыз сине.

—Ышанычың өчен рәхмәт, Әхнәф,—диде Ирек ихлас күнелдән. —Тик мин кабат кермәм инде анда.

—Нишләп?

—"Кеше табигате турында этюдлар" дигән хезмәтендә Мечников бер әйбер язып калдырган. Безнең тәннең йөздән артык өлеше бөтенләй диярлек кирәксез, хәтта зарарлы икән. Партия дә шулайрак түгелме икән ул?

—Бу сүзләрне башка берәү әйтсә, мин аңа сугар идем,—диде Әхнәф, күзләрен ачулы елтыратып.—Син булганга гына гафу итәм.

—Гафу итсәң дә, кабат кермәячәкмен партиягә.

—Ярый алайса. Димәк, редакторлык мәсьәләсе дә төшеп кала,—диде Әхнәф.—Минем эчемне пошырган тагын бер әйбер бар... Синең шул Ык буендагы кечкенә өйдә яшәвең. Без Арсланов йортына күчәчәкбез, ә сез безнекенә күчегез.

Ирек шактый вакыт дәшми утырды, бармакларын өстәл өстендә биетте.

—Рәхмәт, Әхнәф. Аннары... бурычлы булу хәтәр нәрсә ул...

—Нинди бурыч?!—диде Әхнәф, тавышын күтәреп.—Син бит иҗат кешесе, тиешле шартлар кирәк. Мәңгегә анда калырга җыенмыйсыңдыр ич?

—Кем белә инде?—дип куйды Ирек.—Истән чыкмый анда минем күргәннәрем...

Янәшәсендәге тумбочканың астын ачып, Әхнәф туралган тозлы кыяр, тавык итеп чыгарып куйды, затлы аракы алды.

—Минем бүген тарихи көн,—диде ул елмаеп.—Мин беренче булып эшли башлагач, дустым Ирек белән тәүге мәртәбә очрашабыз. Мондый тарихи моментны юмыйча ярамас.

—Әхнәф, миңа салма,—диде Ирек, урыныннан ук торып.

—Йә инде? Бер рюмкадан дөньяның чите кителмәс.—Ул, өстәл астына үрелеп, көрән төстәге озынча балчык шешә алды.—Рига бальзамы белән эчсән, берничә айга илһам киләчәк.

—Мин булдыра алмыйм...

—Син нәрсә, дустым? Өч әйбер тәкъдим иттем, өчесеннән дә баш тарттың. Сыйларга ниятләдем, анысына да каршы киләсең. Элек син мондый тискәре түгел иден,—диде Әхнәф, күзләрен уйнатып һәм рюмкаларга бальзам, аннары аракы салды.

Чәкештергәч, Әхнәф эчеп җибәрде, Ирек рюмкасын өстәлгә куйды.

—Бер рюмкадан артык эчмәссен, бусын тот инде,—диде Әхнәф.

Ирек көлемсерәп баш чайкады:

—Бу агу беркайчан да бер белән туктатмый.

Шул вакыт күк күкрәп җибәрде, ләйсән яңгыр яварга тотынды.

—Аягың җиңел булды,—диде Әхнәф, куанычыннан тәрәзәләрне ачып җибәреп.

Алар тәрәзәдән кергән хуш исләрне комсызланып иснәделәр. Озон исе, тәрәзә каршында үсүче, инде бөреләрендә язгы сүл йөри башлаган каен, юкә, карагай агачлары, язгы туфрак, черегән, әчкелт яфрак исләренә кушылып, башларны әйләндереп җибәрде. Бераздан өйләрнең тәрәзәләрен, калай түбәләрне алсуландырып, кояшның соңгы нурлары таралды, урамга озын күләгәләр сузылды.

—Кояш баеп маташа,—диде Әхнәф уйчанланып.—Ә миңа нишләптер кояш чыгып килгән кебек.

—Миңа да шулай,—диде Ирек.—Бик дөрес чагыштыру таптың.

—Минем янда күбрәк йөр син. Андый чагыштыруларны җыеп, китабыңа кертә барырсың,—диде Әхнәф көлеп.

Яңгыр туктагач, Әхнәф аны озата чыкты. Алар ингә-иң торып, ашыкмыйча гына урам буйлап атладылар һәм кинәт, сүз берләшкәндәй, икесе дә туктап калдылар.

—Ник туктадың?—дип сорады Ирек.

—Ә син?

—Безне бит яңа ел чыршысы туктаткан!—Ирек иске культура йорты алдындагы мәйданга таба атлады.—Менә бит аның урыны...

—Әйе шул...

Икесе дә башларын иеп тынып калдылар.

—Зәнфирә килгән елны ничек матур каршылаган идек,—диде Әхнәф, уйга батып.—Гөлнараларда аулак өй иде... Хәтерлисенме?

—Хәтерләмәгән кая! Зәнфирә бакчада тау шуганда аягын каймыктырган иде.

—Ә минем хәтердә аның көнләшүе уелып калды.

—Кемнән?

—Сөембикәдән... Ул сине сөйри дә танцыга алып чыгып китә, Зәнфирә кып-кызыл булып басып тора, көнләшүе бөтен йөзенә язылган. Житмәсә Арслановның Рашаты килеп бәйләнә мескенгә...

—Ә Фәһимән көнләшмәдеме? Амортизация өчен дип, кич больницага мине алып бардың бит. Баласын тоткан килеш, яшьле күзләре белән ничек карап калды.

—О-о-о, искә төшермә!

—Бөтенесе дә әле менә бүген генә, хәзер генә шикелле.—Ирек авыр итеп сулап куйды.—Гөлнара инде күптән кара жир куенында. Әминәне Казанда, диләр.

—Мин аны күргәлим. Совмин аппаратында эшли. Гел элеккечә шыр-мыр, авызы колагында, әллә каян кочакка ташлана, дөньясына төкереп тә бирми.

Хатирәләр йомгагын сүтә торгач, вакыт шактый узды. Шәфәкъ нурлары яктысында сизелер-сизелмәс кенә булып салават күпере чыкты.

—Без яшь чакларда салават күпере кич чыкмый иде, әйеме, Әхнәф?

—Шулай бугай шул. Бер дә мондыен хәтерләмим...

Алар әллә ничек, пышылдап саубуллашкандай, тып-тын гына аерылдылар. Ирекне Зәнфирә капка төбенә үк чыгып көтеп тора иде.

—Ирек, безгә әллә нинди кеше килде.

—Нинди?

—Белмим, ул синең кайтканыңны көтеп утыра. Исерек бугай.

Ирек атылып өйгә керде, утны яндырып жибәрде. Өстәл каршындагы урындыкта озын гына гәүдәле кеше күзләрен йомып, йоклап утыра иде. Аның башы пеләш, пеләшенең кайбер урыннары тырналып, кутырлап беткән, чал чәчләре колагын каплап тора, битләре тирән жыерчыклар белән сызгаланган.

—Сез кем?—диде Ирек, аның каршына ук басып.

Кеше күзләрен ачты һәм ике мәртәбә ютәлләп куйды. Шулчакта Ирек аның авызы тулы алтын теш икәнен күреп калды. Ул әллә ничек сәер итеп елмайгандай итте, аның тешләренең елтыравы Ирекнең тәнендә нишләптер бала йоннарын кабартты. Ниһаять, ул аны таныган кебек булды, әллә охшаган гынамы? Ләкин аңа шикләнерлек урын калмады. Сул кулын күтәреп, кеше бармакларын аерды: аның имән бармагы өзек иде. Әйе, Ирек ялгышмады: бу кеше—Рашат иде...

Ул лач итеп бер учына төкерде дә икенчесе белән ышкырга керешге һәм боздай тоныш күзләрен Ирекка төбәп, алтын тешләре арасыннан гырылдык авазлар чыгарды:

—Әллә танымыйсың? Әрвахларны танымыйлар шул.

—Таныйм...

—Ник кайттың, дип сора, таныгач.

—Ник?—диде Ирек, үзе дә сизмәстән аңа буйсынып.

—Дөньягызны яулап алырга!..

Рашат жан өшеткеч тавыш белән көлеп жибәрде...

*Икенче китап тәмам.*



**Рәмис Аймәт**

## ЧИКЛЕ ЧИКСЕЗЛЕКТӘ

***

**Алдымда—**
**ЧИКЛЕ ЧИКСЕЗЛЕК!**
**ИРЕКСЕЗ ИРЕК!**
**Тирбәлә дә, мираж булып,**
**Югала эреп.**

**Югала...**
**Китә...**
**Әйләнеп**
**Кайта ул кабат.**
**Кайта да... керсез җанымда**
**Суга ул набат.**

**Гүләп тора Җир һәм Күкләр**
**Вакыт чигендә.**
**Кем соң дәшә: "Кич чикләрне,**
**Кич син, чигенмә!"**

**Читлегеннән атылыплар**
**Чыгар күк йөрәк.**
**Алдымда—**
**ЧИКЛЕ ЧИКСЕЗЛЕК!**
**ИРЕКСЕЗ ИРЕК!**

**Мин атлыйм, сузып кулларым,**
**Офыкка таба.**
**Уфтанып, канлы офык та**
**Капкасын яба.**

---

Рәмис АЙМӘТ (1968) — *шагыйрь; "Шомырт салкыннары" исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

Багамын тутырып күкләргә,
Мәрхәмәт сорап.
Йозакта күк капусы да.
Үрелергә?.. Ерак!..

Яулап алган бар тарафны
Бөек Үксезлек.
Алдымда—
ИРЕКСЕЗ ИРЕК!
ЧИКЛЕ ЧИКСЕЗЛЕК!

## Сүнү

Сөембикә манарасы кебек.
Авып бара шәмем, шәмгенәм.
Ак шәмемнең кара күләгәсе
Нидер ятып уйлый шым гына.

Авып бара шәмем...
Башкаенда
Нинди уйлар?..
Куя калкынып...
Сүнеп барган минем хисләрем күк,
Сүрәнәя бара ялкыны.

Сүрәнәя бара, ак күмергә
Әверелә бара бәгыре.
Шәм-манарам очларына менеп,
Ташланырга әзер Шигырем.

## Хәрәкәткә мәдхия

*Хәрәкәттә—бәрәкәт.*
Татар халык мәкале

Туйдырды ла, зират тынлыгыдай,
Музейларның үле тынлыгы.
Хәрәкәткә сусап сулды җаным,
Сагындырды тормыш чынлыгы.

Дөнья матур—хәрәкәттә генә:
Чишмә гүзәл челтерәп акканда,
Диңгез—мәгърур,
шанлы хаким кебек,
Күбекләнеп ярга какканда.

Таң—илаһи, чәчәк таҗларында
Биегәндә бәллүр саф чыктай.
Хатын-кыз да бөтереп ала җанны
Зыр-зыр әйләнгәндә орчыктай.

Пыскыганда?
Дөрләгәндә генә
Учак теле әйтә үз сүзен.
Кеше дә бит дөрләгәндә генә
Җирдә калдыра ныклы үз эзен.

Бу яшәүнең һәрбер мизгеле дә
Хәрәкәттә генә матур ул!
Сәях җаным киерә җилкәннәрен—
Сәфәр кирәк миңа!
Сәфәр!!
Юл!!!

Сәфәр кирәк миңа!..
Дулкын белән—
Чынлык белән калу күзгә-күз.
Бу хәяттә бары шул чагында,
Шул мизгелдә генә үзем—үз.

## Синең килүең

…Син киләсең!..
Сизәм.
Баскан саен
адымнарың
кыңгырау чәчәгедәй куя чыңлап.
Баскан саен
һәрбер адымыңнан,
һәр ымыңнан
җир яшәреп кала.
Ә мин көтәм,
көтәм килүеңне,
һәрбер адымыңның
серле чыңын тыңлап.

Син киләсең!..
Бу—Син!..
(Юк, ялгышмыйм).
Аккош кебек канат кагышыңнан
ак болытлар куйды сискәнеп.
Тоям, тоям
Синең тарафлардан
Җылы, назлы җилләр искәнен.

Елмаюың,
алсу кояш булып,
күтәрелде офык артыннан.
(Синең сулышыңмы?
Кагылды миңа серле агым…)
Йөзләреңнән иңгән бәллүр нурдыр
ала күз явым?!.
Мин үзем дә,
Таң кошыдай кунып сайрарга дип.
шушы нурга—Сиңа тартылам…

## Җәйнең соңгы җыры

(элегия)

Соңгы җырын җырлый-җырлый җәем
Кереп бара моңсу йортына.
Нидер оныткан мы? Борыла да,
Борыла да карый артына.

Артта кала узган гомерләр күк,
Тезелешеп кала богыллар…
Юк, моңайма, җәем, синең өчен
Үкси-үкси, әнә, көз елар.

Алда инде киң колачын җәйгән
Кара көзнең салкын куены.
Карашларны камаштырып ала
Көйсезләнгән төсләр уены.

Китә җәем… дәшми-тынмый гына.
Тәкъдир белән булмый булышып.
Көз иңенә барып сарыла күк
Чәчәкләрнең соңгы сулышы.

Арган мәллә? Хәлсез адымнары
Бер көчәя, әле бер тына.
Нидер оныткан мы? Борыла да,
Борыла да карый артына…

## Яратканга

Кояштан да яктырак вә
Саф, садә булыр ул Көн.
Оялыплар гына безгә
Кулларын сузар Ак төн.

Айның көмеш нурын чиртеп
Моңлы көй уйнар җилләр.
Тирбәлеп моң-бишегендә
Күкләргә ашар Җирләр.

Әйләнеп кайтыр язлар да,
Карамый кыш, күзләргә.
Мәңгелек язны күрерсең
Багып минем күзләргә.

Укырсың син күзләремнән
Бар җиһан балкышларын.
Беркатлы гонаһларымны,
Үкенеч, ялгышларым...

Җырын сузар гөрләвекләр;
Якыннан, ерактан да.—
Мин сине ятратканга бу,
Син мине ятратканга.

Хәбәр йөрер. Бөтен дөнья
Безнең Сөюне ятлар.
Ул таңда ич сиреньнәр дә
Биш таҗлы чәчәк атар.

Ак болыт, ап-ак биләүдә
Тирбәлеп япа-ялгыз,
"Мең дә бер кичә"не сөйләр,
Сүнгәнче соңгы йолдыз.

Дөрләр Сөю, инде тәмам
Сүрелде дигән җанда...—
Син мине яратканга бу,
Мин сине яратканга.

## Хушлашу

Китәм... Китәм...
Кабат кайтырмынмы?
Сагындырырмы бер бу яклар?
Сүнеп барган өметемдәй, ярда
Сүнеп бара соңгы учаклар.

Ут алыйммы учак төпкеленнән,
Сүнсенме ул әллә мәңгегә?
Ни булса да... беркөн онытылырбыз—
Искә алыр сагынып кем генә?!

Юк, сурәтем чишмә күзенә,
Үз эземә дә сеңеп калмасын.
Төн карасы йоткан сынымны да
Соңгы ялкын үрелеп ялмасын...

Кай тарафка юлым? Һич белгән юк.
Кая барам? Берни аңламыйм.
Сыкрый-сыкрый, бары, дөньясына
Әрнүләрем белән кул яныйм.

Нәрсә көтә? Ниләр көтә анда?
Кай җирләрдә эчәр суларым?
Кайсы тарафларның һаваларын
Күкрәгемә тутырып суларсмын?

Мин сөрәсе чирәм җиргә тамар
Көтә мәллә кайнар тир тәме?
Беркем су кермәгән елгаларның
Йөгерек дулкыннары көтәме?

Кабат кайтырмынмы? Искә алып:
"Бар иде, дип, безнең шул чаклар..."
Сүнеп барган өметемдәй, ярда
Сүнеп бара соңгы учаклар...

Кыям Миңлебаев

# АКЫЛЛЫ АТЫН МАКТАР...

РОМАННАН ӨЗЕК

## Кое сиртмәсе

*...Туган иленнән,*
*суы-җиреннән*
*аерым кеше*
*тере димсез—*
*атлап йөргәч тә?..*

Равил Фәйзуллин

*Үзе кеше булганлыктан,*
*мең газап белән ерып чыккан...*

Әнием сүзләре

Картая-картая гына кулны артка куймаска, бөкшәймәскә, гәүдәңне төз тотып атларга тырышыла икән. Көязләнү түгел инде бу, һич юк! Фәкать җитмеш төрле чир (аның барчасын үзенә дәшеп алырга остарган картлык) өстеңә ябырылгач, шуларның кайсыберләренә бирешмәскә маташу галәмәте инде ул.

Ә яшь чакта аны-моны уйламыйсың.

Кайтып киләм шулай Түбән очтан зур урам буйлап, кулны артка куеп. Көн аяз. Кичке як. Урамның кыл уртасыннан, ялан аякларым белән каткан кара үзле балчыкны шап та шоп яңгыратып, шул музыканы тыңлап кайтып киләм. Сулга борылып, Фатыйхлар йортына йотылып карап барганда, уң ягымнан кемнеңдер исемем белән дәшкәнен ишетәм.

Ялт кына борылып карасам—Нурулла әбзәй икән. Әтиләре тегермән тотарлык бай булгач, хәзер алар да, безнең кебек үк, балчык ызбасына калганнар. Урам яктагы тәрәзәләре кеп-кечкенә. Шул кечкенә генә тәрәзәдән Нурулла әбзәй миңа кул изи. Нинди дә булса йомышы бардыр инде, кермичә дә ярамас дип, Әрмән Нәсибенең капкасыз-курасыз кукыраеп утырган ызбалары ягына бордырып аламын.

Кыюсызлык миңа әллә тумыштан ук килгән, әллә инде фәкыйрьлек белән бергә үземне бөтереп алган, һәрхәлдә, гомер буена шуннан арына алмадым. Ул чагында исә, керү белән, бусага төбендә туктап калдым. Ни рәвешле исәнләшкәнем хәтердә юк, мәктәптә укымагач, биш-алты яшемдә бик рәсми сүзләрне үзләштереп өлгермәгән идем әле.

Тәрәзә буендагы бәләкәй генә өстәл янында ашап-эчеп утырганнарын күргәч, бөтенләй үк югалып калдым—күзгә күренмәгән ниндидер бер сихри көч гүя минем

---

*Ахыры. Башы 5 санда.*

аякларымны кадаклап куйды. Олылар ачык чырай белән сәламемне алып, узарга ничек кенә кыстамасыннар—кузгала да алмадым. Нурулла әбзәй гәрчә үземнән унбишегерме яшькә олырак булса да, минем хәлне бик тиз аңлап алды. Җитез генә урыныннан купты да, өстәлнең яртысын алып, кукыраеп утырган түм-түгәрәк күпшек калачны күкрәгенә терәп бер телем кисеп алды, яныма балкып килеп, ике кулыма тоттырды:

—Мә, аша, Кыямдин!

Хуш исле күпшек калач көн дә эләгә торган нәрсә түгел, рәхмәтләр әйтеп вакытымны әрәм итеп тормадым бугай, тизрәк өйгә йөгердем. Шундый зур күчтәнәчне берүзең ашамассың бит инде, җитмәсә кеше алдында, авыз кутәреп...

Нәсип бабай үзе юл йөрүне бик өнәп бетермәгәнгәме, Нурулла әбзәй кече яшьтән безнең эти белән юл йөрергә, ягада эшләргә өйрәнеп киткән. Әле менә каяндыр кайтып кына төшкән чагы икән. Тәгәрмәчтәй калачны күкрәгенә терәп, җәлләмичә зур итеп кисеп алулары әле дә күз алдымда, ул хуш исле калачның тәмен һич онытасыларым юк. (Җаннары җәннәттә булсын юмарт авылдашларымның!)

Икенче бер вакыт колхоз амбары янында олауларга капчык-капчык ашлык төйиләр. Иләмсез зур үлчәү бушап торган арада яшьләр шунда үлчәнәләр. Мин бер читтәрәк кыюсыз гына басып торам. Нурулла әбзәй мине беләгемнән тотып, үлчәүгә китереп бастырды, үзе ук шалт-шолт китереп үлчәде.

—И-и-и! Кыямдин биш пот икән ләбаса! Барыгыздан да авыррак!..

Бер читтә базымсыз гына, кызыгып, басып торуымны күрә белгән дә күңелемә хуш килердәй сүзне тапкан бит әле! Шаяртып әйтүен белсәм дә, авызым ерылган иде шул, ерылган иде...

Кече Чынлы урамында әле кайчан гына гөрләп торган йорт урынында калган—коймасыз-капкасыз йортыбыз да, идәнсез-нисез балчык ызбабыз да читтән караганда ничек күренгәндер инде—анысы бер Ходайга мәгълүм. Турыбыздан узган чакта шактый кешенең авызы ерылгандыр. Анысы бик табигый хәл. Әмма безнең күршеләребез хәлле генә яшиләр иде. Әйткәнне эшләп, кушканны тыңлаучылар вакытында колхозга язылып, агач өйләрендә яшәп калдылар.

Янәшә күршеләр инде ул Сәнәт абзыйлар. Бер-беребезгә кергәләп йөрибез. Таба ашлары, көсәл-мөсәл пешергәндә берәү дә үзенең күршеләрен сыйламыйча калмый. Ат янында йөргәч, әтиебезгә булышкалагач, үзен тәмам үсеп житкәнгә санаучы абыем, авыз ерып:

—Алия әбинең мөсәлен мәче генә ялый ала торгандыр, кашыкка да эләкми, үзе яман әче була,—дип бәяләсә дә, бала-чага бер дә инде кимен куймый, хәзер ашап бетерә иде.

Хәер, чынлап уйлап карасаң, алай ук көнләшерлеге дә юк инде күршеләрнең уңганлыгыннан. Сәнәт абзыйның өйдәгеләргә:—Бүген ял итик, иртәгә сукмабыз,—дип бер генә “сугарбыз” сүзен ялгыш әйткәне авыл эчендә мәзәккә әйләнгән.

Ут күршеләребездә йорт хуҗасының бәясе ни дәрәҗәдә булганын әйтүе кыен. Чөнки бала-чага телендә аның карчыгы Алия әбинең генә исеме йөри иде. Шыңгырдап торган буш өйләрендә мичләре нинди генә зур булмасын—барыбер хуҗабикә үзе аңардан юанрак булгандыр сыман.

Ничектер шулай күрше-күлән агайларының әңгәмә вакытында урамыбыз хатыннарын телгә алганы колакка эленгән. Кемдер Алия әбинең исемен әйткәч, Адиҗанның әтисе Минач абзый:

—Алияне аны дәңгәл ясап, шуып уйнарга гына ярый,—дигән иде.

Гәрчә ир-ат аны әрҗә яки ләгән ише нәрсәгә тиңләп, төбенә боз катырып, тау шуарга гына яраклыга чыгарса да, хәлләр бүтәнчәрәк иде шикелле. Әнә шул кортка иренә генә түгел, балаларына да эш таба иде. Иң олы уллары Сибатулла—әтисе белән бергә ир-ат эшен башкарса, Алиуллага йорт эшләре, ягъни бүтән гаиләләрдә хатыннар башкара торган вак-төяк мәшәкать йөкләнгән: идәнне ул юа, аш-суны ул кайгырта...

Өченче бала Мәгъсүмә атлы чибәр генә кыз булып, өйдә ул хан кызыдай кыланырга хаклы иде. Төпчек малай Хасиятулла—йомышка чабу өчен кулай иде бугай.

Бермәлне шулай моның әнисе:

—Хасиятулла, кабартма яратасыңмы?—дигән сорау куя.

Малай аны-моны уйламыйча гына:

—Абартма ник яратмыйм, абартма яратам,—дип ычкындыра.

—Яратсаң, әнә Ләйли әптәң кабартма пешергән, безгә кайчан кертә, әллә кертә, әллә юк бит әле. Үзләре ашап бетергәнче, кер дә кабартма алып чык.

—Ярый, абартма алып чыгам.

—Син диваналанып алай сорама, Васби әбиеңнең киез катасын биреп торыгыз әле, диген.

Җәй уртасында күрше малае әбиебезнең киез катасын сорап торса, барыбызны да гаҗәпләндергән булыр иде, әмма Хасиятулла, мөгаен, йомышын йомышлауны онытып җибәргәндер, исендә фәкать бер генә тәмле ризык булгандыр, бусаганы атлап керү белән:

—Абартма биреп торыгыз әле,—дип ярып сала.

Әни белән әби сер бирмәсәләр дә, абыйлар шаркылдап көлеп җибәрәләр.

—Кабартма яратасыңмыни, Хасиятулла?

—Абартма яратам шул...

Әни тиз генә бер савыт булары чыгып торган тәмле ризыкны кулына китереп тоттыргач кына, Хасиятулланың хәтере яңарып китә дә, оялып, башын аска төшерә, кулларын артка яшерә:

—Иез ата биреп тормассызмы дигән идем лә...

Әни аңа йомшак кына:

—Хәсиятулла, киез катага башка вакыт керерсең, бик ашыгыч түгелдер бит әле, хәзергә җәй,—ди.—Менә бик тәмле кабартма пешердем, сезгә кертергә генә тора идем әле. Ярый, үзең кердең, кайнар көе алып чыга күр инде,—дип тә өсти.

Алия әбинең үзенең төп эше түр тәрәзә янынарак богыл сыман утырып, узганбарган белән әңгәмә корудан гыйбарәт. Күпер үзебезнең урамда булгач, аргы якка чыгучыларның да ниндирәк йомышлар йомышлап йөрүен белмичә калмый, аръяктан килүчеләрнең дә һич кимен куймый.

Алия әбинең "фокусы", гомумән, безнең авыл халкына хас кыланыш түгел инде анысы. Әмма ләкин булган хәл бит, булган хәл. Гомер буена бер мәкерле гайре табигый хәл буларак уелып калган.

Өйдә утырганда урамның ни дәрәҗәдә суык икәнен бер дә белмисең бит аны. Фатыйх, Адиҗан белән бергә үзебезнең урамда шактый озак уйнап йөрдек. Карда аунагач, безнең инде бишмәтләребез шакырдап катты, авыз-борыннарыбыз туңды, бармакларыбызны кыймылдата алмаслык бер хәлгә төштек. Шулай да таралышасыбыз килмәде. Берәрсенә кереп, җылынып чыгарга ниятләдек. Кемнәргә керәбез? Алия әбиләргә! Аларның өйләре хәтсез зур. Зәмһәрир суыкта куып чыгармас әле. Әнә бит нинди тәмле телле...

Чынлап та, күрше карчыгы түрдә утырган җиреннән татлы сүзләр белән каршы алды үзебезне:

—И-и-и! Егетләр килгән икән! Бездә шул кызлар гына. Урамга чыгарга да куркып торабыз әле. Сез бик батыр икәнсез, суыктан курыкмагансыз.

Безнең инде түбәбез түшәмгә тиде. Бусага төбендә торабыз таптанып, борыннарны лышкылдатып. Алия әби түрдә бик җәелеп, җайлы утыра иде бугай, урыныннан купмады. Фәкать буй җиткән кызына өйалдыннан ярты потлы герне алып керергә кушты. Аңлаганмы ул җитү кыз бала әнисенең хәйләсен, әллә юкмы—хәзер инде әйтүе читен, әмма ул кушканны карусыз үтәде. Түм-түгәрәк ап-ак герне безнең алдыбызга тукылдатып китереп утыртты.

Сабыйларның психологиясен белә иде күрше карчыгы, бик яхшы белә иде. Ул безнең нәкъ мин-минлегебезгә кагылышлы сорау куйды:

—Йә, кайсыгыз батыррак икән? Кайсыгыз теле белән шушы герне ялый ала?

Батырлык дигәндә, малайларны куш инде син. Без өчебез дә батыр идек, берберебезне этә-төртә әлеге туң герне яларга ашыктык.

Нәрсә булганын аңларлык акылым юк иде әле—телемне куырып алгандай булды, җитмәсә, җибәрми бит әле, каһәр! Мең бәла белән кубарып, нинди хикмәтле хәлгә, нинди бәлагә дучар ителүемне аңларга теләгәндәй, мөлдерәп тулган яшьле күзләремне түрдә ихахайлап, бот чабып утыручы корткага төбәдем. Нәрсә эшләргә кирәген дә, үземнең нишләгәнемне дә белештермичә, урамга атылдым. Артымнан ук дусларым да атылышып чыктылар. Без бер-беребезгә күтәрелеп карарга да базмадык, батыр булмавыбызны, хурлыкка төшкәнебезне аңлагандай, боегып калдык. Авыз ачып сүз әйтерлек хәлдә түгел идек—һәркайсыбызның авызы тулы утлы күмер булып, гүя ул

күмерләр әле бер якка, әле икенче якка тәгәрәшә иделәр...

Ә менә күршеләребезнең бер истәлекләре андый вак-төякне бөтенләй онытырды: шул ук елны алар гаиләләре белән Ташкентка китеп бардылар, анда кыш булмаганга, кул чаналарын безгә калдырдылар; аның тар гына табаны шомарып беткән һәм хәйран шәп шуа—ярдан утырып китсәм, инешнең аргы ягына җилдерә иде.

Сәнәт бабайларның түбән ягында Аймәтдин абзыйлар. Аның үзен гаять кыюсыз, юаш кына, гәүдәгә малай-шалай сымаграк бер кеше буларак хәтерлимен. Кызгылт-сарыга анда-санда чабата-чабата ак таплар төшкән байталлары да гаять юаш булып исемдә калган. Хәер, мал иясенә охшамаса, хәрәм була, диләр бит әле, бу очракта аларның юашлыгы бер үк чамада булган бугай. Басуга барырга чыккач, берзаман хуҗасы атын бераз кызуларга үгетләп:

—На, хайван, Алла теләсә, барып та җитәбез инде,—ди икән. Аймәтдин бабайның карчыгы Хәлимә әби дә усаллардан түгел иде. Каратут чырайлы ул кортканың өйләрендә яисә йортларында дөнья бетереп эшләп йөргәне әле дә күз алдымда. Ул бичара әледән-әле тамак кырудан гомере буе арына алмады. Мондый хәлне, килен булып төшкәч, тел яшереп яшәгән чагында, саран каената сизмәсен өченгә шырпы сызган саен йөткергәндәй тамак кырырга күнегеп калган икән, дип аңлаталар иде.

Бу асыл күршеләребезнең Фатыйма, Гелметдин, Миңсара, Аязетдин атлы балалары булганы мәгълүм. Олы кызлары гомере буе авырудан арына алмады бугай. Олы уллары Ватан сугышында һәлак булды. Кече кызлары Миңсара хәйран чибәр иде; авылга тракторлар кайта башлагач, аны тракторчыларга аш пешерүче итеп билгелиләр. Кызганыч ки, берәр елдан артык эшләү насыйп булмады бичаракайга. Хәтерем алдамаса, кыз баланың фаҗигале үлеме сәбәбен суд тикшерүчеләре дә ачыклый алмадылар...

Аяздин әбзәй генә гаиләдәге фаҗигаләрнең үчен алырга ниятләгәндәй, озын гомер кичерә: сугыштан исән-сау кайтып, Нурлыбаян исемле мөлаем генә кызга өйләнеп җибәрә һәм колхозда озак еллар буена бухгалтер булып эшли. Аяздин әбзәйләр береннән-бере чибәр һәм уңган өч бала үстерәләр. Уллары замана техникасын авызлыкласа, кызлары Әлфия дә сынатмый—элемтә өлкәсендә үзен күрсәтә.

Урамыбызда гына түгел, авылыбыз күләмендә үземнән өлкәнрәкләр белән аралашканга, мөгаен, Аяздин әбзәй иң якыны, күңелемә аеруча хуш килгәне булгандыр. Үзем әле яр буенда үзле балчык әвәләргә өйрәнеп кенә килгәндә—ул миңа бер трактор ясап бүләк итте. Малайлар узышканда нигә катнашканмындыр инде—һич аңлый алмыймын. Шунда иң ахырдан килгән чакларымда Аяздин әбзәй өлкәннәр алдында гел мине яклады:

—Кыямдин ашыкмады гына, шуңа ул арткарак калды. Аның аякларын ничек алдырганын күрдегезме соң? Сабан туендагы чабыш атлары сыман, бәкәлләрен бер-берсенә тидереп йөгерә бит Кыямдин. Иң оста чабучы ул!—дигән булды.

Белеп торам инде чын күңелдән, үзе дә ышанып сөйләмәгәнен. Кәкре аяклы икәнемне күреп торалар лабаса. Әмма шулай да җанга рәхәт. Яклаучым бар, күрше егете үземне рәнҗетергә ирек бирми.

Бәләкәй чагымда бик хәйләкәр идем. Әйтик, менә берзаман аларның ихаталарында Аяздин әбзәй:

—Кыямдин, син урысча беләсеңме?—дип кызыксына.

"Белмим" дигәнне үтерсәләр дә әйтәсем юк. Хәйләгә керешәмен:

—Берсәк беләм,—дигән булам.

Каян белмәк кирәк инде дүрт-биш яшьлек авыл малаена икенче телне? Шулай да сер бирмим бит, әй!

—Белсәң, алайса әйт әле, "чава" (чего)—нәстә?

Мәктәп малаеның урыс теле дәресендә "кто-что, кого-чего"ларны өйрәнгәне миңа мәгълүм булмаган кебек, әлеге сүзне дә белмәвем хак. Әмма бирешмим бит, хәйләлим:

—"Чава"мы? "Чава"... нәстәгә дә бара ул,—дим, күземне дә йоммыйм.

Әлеге сүзнең мәгънәсен белмәү сәбәпле, ул нинди сүзгә дә бара, мәгънәсе төрле аның, дигән бер уйдырма фикер әйтеп ташладым инде, югыйсә. Ә менә урысча бу сүзнең мәгънәсен белгән күршемнең күзе шар булды: беркатлы дустым аны... үзе белгәнчә кабул иткән.

—Кыямдин! Син урысча беләсең икән бит!—дип кычкырып җибәрде.

Хәйлә капчыгы буларак, мин инде: "Тисә—тиенгә, тимәсә—ботакка", дип кенә

җибәргән угымның "тигәнен" күреп, шундук эреләнер булдым, аның ише вак-төяккә әллә ни исем китми әле, дигән бер кыяфәт белән, ике кулымны да кесәгә тыккан көе, өлкән дустымны пошамага калдырып, ашыкмыйча гына өйгә табан атладым.

Икенче хәйләм дә Аяздин әбзәй күз алдында булды. Көннәрдән бер көнне ул:

—Кыямдин, синең избачка барганың бармы?—дип кызыксынды.

—Юк,—дип турысын әйткәнемне ишеткәч:

—Әйдә үзеңне избачка алып барам!—дип тантаналы төстә әйтә куйды.

Һәй, "избач" дигәнең безнең тыкрык башындагы китапханә икән лләбаса, избачитальня, имеш инде. Китапларның күплегенә иң әүвәл хәйран калдым. Аннары өстәл артында малайларның шашка уйнап утырганын күреп, исем-акылым китте. Моңарчы гомеремдә дә (миңа бит дүрт-биш яшь!) күрмәгән әлеге уеннан күземне дә ала алмыйча, катып калдым. Күңелдә бертөрле дә усаллык яисә явызлык ише нәрсә булмагач, авызым үзеннән-үзе әллә ачылган, әллә ерылган ук инде.

Минем авыз ерып торганымны каршы якта уйнап утыручы малай үзенчә аңлады бугай:

—Түлке син аңа әйтмә!—дип кисәтте.

Беренче күргән уенда хәтта әле бик-бик теләсәм дә акыл өйрәтә, киңәш бирә алмас идем. Тик инде моны сиздермәдем, беркатлы булып күренергә исәбем юк иде.

—Курыкма-а-а, әйтми-и-им!..—дигән булдым.

Шунысы кызык, җиңгәннән соң бервакытта да ул урында калмый торган идем. Бу юлы да икенче яктагы өстәл янында китаплар биреп торучы хуҗабикәгә табан китеп бардым. Ул апа мине язып, Габдулла Тукайның сабыйларга атап язган шигырьләре җыентыгын өемә биреп җибәрде. Бу минем китапханәдән алып укыган иң-иң әүвәлге китабым иде. Хәйран гына яратып укыдым. Ялгышсам, гафу кылгайсыз, шул чаклардан бирле күңелемдә сакланганча китерәм:

*Йоклый ул, төш күрә,*
*Төшендә дә тычкан-күсе*
*халкы белән эш күрә...*

Шагыйрьнең әнә шундый табышына сөенеп, тәмам хәйран калганым әле дә хәтеремдә. Аннан бирле, алтмыш-җитмеш ел эчендә, меңнәрчә китапны укырга алган иң әүвәлге этәргечем әнә шул китап булуы, авызым Тукай шигърияте белән ачылуы хак. Аның шигырьләре күңелемә хуш килгәч, янә дә ике-өч китабын алып укыдым. Мөгаен, болары бераз калынрак булгандыр, чөнки шигырьләренең күплегенә хәйран калып: "Нихәтле исем куйган бит! Минем шигырьләремә юньле исем дә калмаган бит!"—дип хафага төшкәнем хәтердә. Ихтимал, үзем "көй" дип чыгарган һәм авыз эченнән генә көйләп йөргән нәрсәләр шигырь түгел микән, дип уйлануларым нәкъ әнә шунда башлангандыр... Ә бит аннан соңгы алтмыш-җитмеш ел эчендә шагыйрьләребез дөнья чаклы гүзәл тезмә әсәр иҗат итте; аларга сокланып, ә инде үзем язганнарына объектив бәя биреп, берсен генә дә матбугатта чыгармаска акылым җитте, хәзер инде шуңа сөенәм...

Инде чәчләребез агарып беткәч тә, мин авылга кайткан саен Аяздин әбзәй белән күрешмичә калмый торган идек. Туганың кебек якын кешең белән чәй табыны янында бер-береңне бүлә-бүлә гәпләшеп утырулар сагынып сөйләргә генә калды бугай: берәр ел гына элегрәк карчыгы дөнья куйгач, Аяздин әбзәй тиз арада түшәгеннән күтәрелә алмаслык хәлгә төшкән иде, менә әле без авылга җыенган көннәрдә үзе дә бакый дөньяга юлланган. Җаннары җәннәттә очрашсын!

Дөнья көтү яшьләргә кала...

Аяздин әбзәйләрнең түбән ягында, инешкә якын ук Халиулла җизниләр яши иде. Мин белгән Васби әбиебезнең ике кызы булып, Зәйделгаяны югары урамдагы Хәлим җизнидә, Нурлыбәян атлысы үзебездән ике йорт аша гына Халиулла җизнидә кияүдә иде. Бәян әптәйләр, вакытында колхозга кереп, йорт-җирләренә бертөрле дә каза китертмәделәр.

Өйләре бик ямьле, бик иркен булып, бала-чага янына уйнарга шунда җыела торган идек. Әнисә апа, иң олы кызлары бездән бераз өлкәнрәк булса да, ыбыр-чыбырның мәш килүеннән кызык табып, уеныбызга катышып киткәнен сизми дә кала иде. Аңардан соң туган Нәҗипләре кышкы суыкта әнисе белән бергә чана тартып юлга чыккач, салкын тидереп, фаҗигале төстә малай чагында ук дөнья куя. Сәгыйт, Нурулла, Сәмигуллалары нәкъ минем тиңнәрем булып, уеннарның кимен куймый идек. Төпчек кызлары Рәйсә

ул чагында әле без шаярганны бишектән генә карап ята иде.

Сугышка чаклы ук ул туганнарыбыз ерак Әстерханга күчеп киттеләр. Өйләре әйтеп бетергесез матур иде, сатканнар булса кирәк, йорт урыннары бушап, гаҗәеп тәмле сулы коелары гына, озын сиртмәсен тибрәндереп, ялгызы гына моңаеп торып калды.

Олыгая төшкәч, Хәлиулла җизниләр парлашып кайтып киттеләр. Әниебез исән-сау иде әле, айга якын бергә-бергә, аралашып, рәхәтләнеп сәйран кылып йөрделәр. Бәхилләшүләре булган икән газиз кардәшләребезнең: шул кайтуларыннан соң озакламый бере арты бере дөнья куйдылар...

Күрешергә дип, Әнисә ападан кала, барысы да калавылга кайтып киттеләр. Төпчек кызлары гына кыюрак та әрсезрәк булып чыкты: кияве Ризабик белән елның-елында, бер-ике чемодан "мадор" алып, пароходка гына утырып кайтып китүләрне эшкә дә санамады.

Абыебыз алар янына барып урнашкач, кайткан саен чакырып киткәч, ике-өч тапкыр үзем дә аларга кышын поезд белән барып, сыйланып кайткаладым. Абыйларның да, туганнарның да ни рәвешле көн итүләрен үз күзем белән күреп, алар өчен сөенеп кайттым.

Хәзерге көндә безнең абый тугызынчы дистәнең икенче яртысына авышты. Әнисә апа да күп калышмый бугай. Рәйсә дә алтмышларны узды инде, оныкларын караштыра.

Абыйның саулыгыннан зарланганы булмады булуын. Тик менә соңгы ике-өч ел эчендә күзләренең рәте бетте—буяулар белән эшләүнең тәэсире ахры бер сиздерүе хак. Дөньялар үзгәреп китүнең иң зур аянычы шунда ки—беркая барып булмый, бик сагынган кешеңне дә бер күрергә гаҗиз булып гомер кичерәсең...

Гәрчә безнең заманда ир-егетләр беренчелекне яулап, кыргый җанварлардай, бугазга-бугаз ябышмасалар да, бер-береннең кимчелеген күрсәтүдә һич кимен куймыйлар.

Каладан кайткан кичтә үк үземне ат араннары янына алып киттеләр. Эш атларын алар шулай һәркөн Түбән очка фермага төшерәләр икән. Минем кулыма башын аска игән, карсаграк буйлы шомырт-кара елдым гына бер алашаның тезгенен тоттырдылар.

—Юаш ул, бер дә курыкма!

—Атланырга да җайлы!

—Дулый торган гадәте дә юк...—диештеләр. Әмма үзләренең әйтеп бетермәгән серләре барын күзләреннән сиземләве читен түгел иде.

Бер дә каршы килмәдем. Әүвәл сикереп түшемә яттым, аннары җайлап кына атландым. Шунда гына үземә сылаган бу атка ни сәбәпле Темарук дигән кушамат тагуларын аңлап алдым: бу алдакчының җилкә калкымы бөтенләй юк диярлек икән дә аңа беркем атланмый, ә инде атланган тәкъдирдә—юыртып китә дә эһ дигәнче башы аркылы ыргыта икән...

Андый чакта бер дә сер бирмичә, йә баш, йә мал, дип тәвәккәлләми хәлең юк. Сынатмаска гына кирәк. Ничек тә көлдермәскә. Шәһәр малае атның ни икәнен белми, безнең кебек атланып йөрүләр төшенә дә кермәгән, дип кинәнсеннәр әле. Темарук үзен башы аркылы мәтәлдерсен, дип өметләнсеннәр әле. Тик миңа һич тә сынатырга ярамый. Сынатасың икән инде—Миңлебай Сәләхенең малае дигән данны күтәреп йөри алмаячаксың.

Алашаның Темаруктай алдашу холкын абайлап алгач та, кәкре аякларым белән ипләп кенә атымның ал аякларын кочтым. Башкалар юыртып киткәч, минем атым алардан калышмау ягын карады: муенын иеп кенә, тигез адымнар белән юыртып алып китте.

Дусларымны кызганып куйдым: артларына борылып карый-карый муеннарын кәкрәйтеп бетерәләр инде бичаракайларым!.. Тик менә күпме генә көтсәләр дә, үземнән көләргә ирек бирмәдем—берни белмәгәндәй юыртып барудан туктамадым, мәтәлчек атарга һич кенә дә уйламадым.

Икенче тапкыр үземнән көләргә җыенулары Тәкәнеш районында булды. Урак өсте. Мине вәкил итеп җибәрделәр: күз-колак булырсың, янәсе, уңган-булган игенчеләрне бимазалап торырсың, ялкауланырга ирек бирмәссең.

Колхоз дигәнебез бәләкәй-бәләкәй генә ике авыл-бригададан гыйбарәт иде. Рәис үз авылында калып, мине икенчесенә җибәрүне кулай тапты: шунда күз-колак булырга кушты. Мәзәккә җиткәнче янә бер маҗара булып алган икән әле. Яңгыр коя да коя.

Комбайннарыбыз җир бераз кипкәнне көтәргә мәҗбүр булдылар. Шунда рәис белән икәүдән-икәү киңәшләштек тә елга-ерынтыдан урак яисә чалгы белән кыркып чыгарга, ашлыкны суктырып, шунда төшкән хезмәт көннәренә әз-мәз бүлеп бирергә ниятләдек. Әлеге тәвәккәл адымыбызны берәрсе хәбәр иткәндер, үзебезне чаккандыр, дигән фикердән ерак торамын, шулай да...

Шулай да колхозчыларга икмәк бүлеп торган җиребезгә райкомның икенче секретаре килеп төшмәсенме! Күрде безнең шөгылебезне, сүзсез дә аңлады. Мине бер читкәрәк алып китте дә иплән кенә төшендереп бирде:

—Беренче икмәк, яңа алган уңышның беренче бөртеге, килограммы, центнеры, тоннасы—бары тик дәүләткә тапшырылырга, түкми-чәчми дәүләт амбарларына озатылырга тиеш бит.

—Җир бераз кипшенгәнче дип кенә елга-ерынтыдан урак белән урдылар. Комбайннарыбыз әлегә тик тора, ныклап торып уракка төшә алганыбыз да юк бит әле...

—Теләсә нинди шартларда беренче бөртекләр элеваторга озатылырга тиеш. Сез бит партиянең өлкә комитеты вәкиле. Сезнең әлеге кырын эшегезне өлкә комитетында белсәләр, үзегезгә рәхмәт әйтмәсләр...

Райком секретаре өлкән яшьтәге,дөнья күргән кеше иде, җәнҗал чыгармады, җаны җәннәттә булсын!

Мәзәк дигәнебез онытылмасын әле.

Әкренләп җирләребез кипшерә башлады, комбайннарыбыз эшкә кереште. Бригадабызда икәү алар. Миңа берсеннән икенчесенә очып кына барып кайтырга кирәк булды. Җәяүләп озакка сузылачак. Бригадирның атын сорап торырга ниятләдем. Ә аның ике-өч яшьлек аты иясеннән гайре беркемне белми, кәҗә бәтиедәй аңа тагылып йөри.

—Хуҗа абый, атыңны биреп тормассыңмы теге комбайн янына барып кайтырга?

—Ал соң!..

Җавап кыска булды, бик җиңел бирелде. Тик менә ул "кәҗә бәтиен" ни рәвешле кулгаияләштерергә икәнен һич белгән юк, менә анысы бик үк җиңел булмас, ахры...

Бәләкәй генә буйлы бригадир агач ияр кашына бәйләгән тезгенне чишеп, кулыма тоттырды. Үзенең авызы ерылган. Хәер, туктаган комбайн янындагы өч-дүрт механизатор да, обком вәкиленең булдыксызлыгыннан көләргә әзерләнделәр.

Тезгенне сул кулыма урап, уңы белән акрынлап кына атның маңгаендагы йолдызын кашыган булам, ул арада иплән кенә тезгенне башына кигезәм, муенын, сыек кына ял астын сыйпаштырам да, җаен туры китереп сикерәм дә күкрәк белән ияргә ятам соң. Хуҗаны гына хуҗасы дип таныган яшь ат әүвәл өркүдән читкә тайпылды, аннары тыпырчына-тибенә башлады, алай да берни майтара алмагач, арт аякларына күтәрелде. Ул арада мин ияргә ныклап береккән, өзәңгедәге аякларым белән дерелдәвек гәүдәсен кысып өлгергән идем инде. Бил каешымны суырып чыгардым да кире беткән хайванның камытлыгын кашып алдым. Әле генә чит-ят әдәмне чөеп ташларга маташкан малкай башта аптырап калды, аннары элдереп алып китте. Тезгенне бушатып, аңа кушаяклап чабарга ирек бирдем, юлдан унга каерып, үргә табан юлладым.

Механизатор егетләр көләргә дип авызларын киң итеп ачкан хәлдә басып калдылар—Миңлебай Сәләхенең улыннан көлү үзләренә, ай-һайла, насыйп кына булмады бугай.

Беренче мәхәббәт дигән кебек...

Иң әүвәл үз белдегем белән әмәлләгән, үз кулым белән ясаган нәрсә нәкъ менә скрипкә булгандыр. Аның чынын Фатыйхларда күргәнем дә, тотып караганым да булмады түгел, булды. Анысы хак. Әмма ясарга тотынгач... Шунда гына аңладым мин Рәхимҗан әбзәй скрипкәсе шикелле иттереп һич тә ясый алмаячагымны. Хәтта әле бер пот тоз ашаган тәкъдирдә дә. Шуннан мин моны гадирәк иттерергә ниятләдем. Тавышы ул чаклы ук матур чыкмаса да ярар, чынлавында бераз моң булса, шул җитә язар, дидем. Иң әүвәл сызгычын әмәлләдем: чыбыркы сабы юанлыгы тал чыбыгын пәкем белән кисеп алдым да, аны җәя шикелле бөгеп, шул таякка ат койрыгыннан алынган кылларны тарттырып куйдым. Җәя шикелле дигәч тә, алай ук кәкре итмәдем инде, кылы таяктан бераз аерылып торса, бик житкән. Иң кыены тартмага муенны кадаклап кую булгандыр. Фәкать ышанычлы, тотрыклы бер бөтен итәргә хәлемнән

килмәде... Шуннан тоташ бер такта кисәгенең эчен каезларга тотындым. Бакыр чыбыкны каян табыштырганымны (дөресрәге, нәрсә җимергәнемне) һич хәтерләмим, тик инде карап торышка гына скрипкәгә беркадәр охшаган бер нәрсә килеп чыкты бугай.

Шул вакыттан соң шактый агач юнылгандыр, тик менә ул "уңганлыгым" еш кына кулымны канату белән очлана торган иде...

Үзем генә әмәлләгән тимераяктан бер дә инде уңмадым—калавылда чакны, ун яшемдә шуның белән матавыкланып, шуарга өйрәнә алмадым шул, алмадым...

Беренче чаңгымны да үзем юнып ясадым. Авылга кайтып, алтынчыда укыган чакны карлар ява башлагач та, чаңгыда йөрүнең дәртенә керештем. Хәер, аның борынын кәкре, билен сыгылмалы итү дә, әлбәттә инде, хәлемнән килмәде, шулай да юнып шомарткач, килешле генә, бер-беренә бик тәңгәл чаңгылы булдым шул. Бәрәңге бакчабызның аргы башыннан сөзәк кенә тау башлана иде, өр-яңа чаңгым шуннан ярыйсы ук җилле төшәргә өйрәнде. Чаңгы юлым кыйгачлап инешкә хәтле сузылса да, башка җирләрне дә урап кайтырга, тирән чокырның ярыннан төшәргә әнә шул кышны остардым бугай. Бер дә егылмыйча гына калмаганмындыр инде анысы, тик чаңгымның сынганы булмады. Тигез җирдән төшүләр туйдыра башлагач, әлеге дә баягы кыйгач юлыма агач көрәк белән кар өеп, үземә күрә трамплин шикелле тау ясап ташладым. Өйдә утырып кына яхшы шуарга да, трамплиннан оста сикерергә дә өйрәнә алмыйсың бит ул. Ә менә яшь чагыңда өйрәнгән һөнәрең шактый олыгайгач та ярап куя икән ул. Шуннан соң егерме-утыз еллап вакыт узгач булган бер-ике хәлне читләтеп үтәсем килми.

Ял көннәрендә чаңгыда йөрмәгән чагым калмагандыр. Бермәлне шулай хатыным, улым белән өчебез дә чаңгы кидек тә бакчабызга, Карьер ягына юлландык. Ашыкмыйча гына бакчага барып җиттек, өебез дә, аерым-аерым кукыраешып торган кухнябыз да, беседкабыз да тыныч кына торалар, алмагачларга да куяннар зыян салмаган. Үз кулым белән пөхтә генә итеп корылган бу дача хуҗалыгына, хосусый байлыгыбызга сокланып туйгач кына, ул арада тегене-моны эшләп ташлагач та, кайтырга чыктык. Бая урман эченнән барган булсак, хәзер менә гаҗәеп тирән чокырның кыл үзәгеннән хозурланып шуа-шуа кайтып киләбез. Шунда бер дивана уй килмәсенме ир-егетнең башына! Күз салам югарыга—иң биек җире, аннан ары тау сөзәкләнә бара, үзәнгә әверелә. Үземнекеләргә:

—Сез бераз бара торыгыз, артыгыздан куып җитәрмен,—дим.

Тик инде әтисе шундый биек тауга менеп киткәндә, ваемсыз кала димени балачага! Тыныч кына юлын дәвам итсә, егет буламыни ул, Сәләхетдин оныгы була димени! Икесе тиң авызларын ачып, мине карап-күзәтеп торалар болар. Менеп җиттем тауның башларына. Күз саламын түбәнгә—анда сөеклеләрем сөенеп карап торалар. Әгәр шунда берәр күрәзәче килеп, хәзер имгәнәсең, аягыңны яисә кулыңны сындырасың, дисә дә, аның сүзенә колак салмас идем—егетлегемә сокланып та масаеп, текә таудан төшүемне көтеп торган газизләрем янына ургылыр идем.

Тәки тәвәккәлләдем бит, әй! Хәтта әле андый чакны әйтелә торган "Йә баш, йә мал" дигән сүзләр дә килмәде күңелемә, тоттым да чак кына кыйгачлап төшеп киттем. Түбәнгә төшкәндә әллә тиз йөрешле поезд, әллә самолет кызулыгына басканмындыр, әле түбәнгә, чокырның үзәгенә исән-имин төшеп җиткәч тә һич туктый алмыйм, менә хәзер йөрәк парәмне бәреп егарга тиешмен дигәндә, улыма җитәрәк сул ягыма аудым. Шуннан соң бакчага барган саен, җәен-көзен әлеге тау башыннан упкынга карап, баш чайкый торган булдык. Хатыным:

—Шулчаклы да тәвәккәл булырсың дип уйламаган идем, каршы да тора алмадым, туктатырга кирәк иде үзеңне...—ди.

—Үткән эшкә салават, дөнья көтә диваналар,—дип өстимен.

Янә дә бер диваналыгым (истә калганы, диюем, чөнки андый хәлләр, чаңгы сындырулар шактый булды бугай) язга табарак җылы бер көнгә туры килде. Әлбәттә, ял көне. Үзем генә чаңгы белән сәфәр кылам. Тимер юл буйлап җайлы гына киләмен дә парк янына җитәрәк өскә менәмен. Чаңгы юллары шомарып беткән, бозга әйләнгән. Менә берсе паркның ачыграк урыныннан түбән төшә. Мин, әлбәттә, шуңа каерам. Тавы сөзәк кенә, җан рәхәте, дип сокланып, уңга-сулга чайкалып кына юлымны дәвам иттергәндә, тизлегем торган саен арта бара икән ләбаса! Уңга да, сулга да борылырлык түгел—анда агачлык. Моның берәр очы-ахыры булырдыр бит, дип кибернетик

тизлектә фикер йөрткән арада ни күрим—алда биек трамплин! Нишләргә? Котылып калу өчен фәкать уңгамы, сулгамы егылып өлгерерлек әле болай үзе, тик аннан даниләр килеп чыгасын алдан әйтүе кыен, әллә чаңгың сындырасың, әллә муеның.

Тәвәккәл—таш яра, дип үз-үземә дәрт өстәгәндә, мин инде бөкшәя төшеп, ике таягымны да артка чөеп, трамплинның сыртына якынлашып киләм икән ләбаса. Ул да булмады, сират күпере үземне күккә чөйде. Моннан егылсам, каярак төшәрмен икән, дип йомшаграк урын эзләгәндәй, түбәнгә күз салсам—анда бәп-бәләкәй күренгән чаңгычылар башларын артка чөеп, минем якка төбәлгәннәр... Һәй, дивана, траекториядән читкә тайпылып була димени! Бер тәвәккәлләгәч, хәзер очасың инде менә, биектән очасың, югарыдан очасың—кешеләр бәләкәй булып күренә, хәзер инде алгарак авышу зарур, сыныңны турайтсаң да була, чаңгыңның да башын ныграк күтәр, төшеп кадалмаслык иттер! Үз-үземә усал гына әмерләр бирә торгач, тәки төшеп җиттем бит иплә генә. Шундук алга ургылдым. Ә инде инерциягә каршы бармагач, ул да мине мәтәлчекләр аттырмады, чаңгымны да, муенымны да сындырмады—аяк өстендә саклап калды. Күзне каплаган дымга килгәндә, яшь түгел ул, хәтта шатлык яше дә түгел, фәкать һаваның сафлыгы-салкынлыгы гына иде...

## ...Саламнан тәртә ясап, чикерткә җиккән чаклар

**(Гомерлек дустым сөйли)**

*Теле барлар—халык булган,*
*теле юклар—балык булган.*

Татар халык мәкале

*Дәртләнеп тә янып яшәү*
*безгә зарур,*
*дәртләнеп тә янып эшләү -*
*иҗат итү безгә зарур.*

Жорже АМАДО

Мин аны беренче тапкыр китап базарында очраттым. 1944 елның августы иде. Мәктәптә укулар башланганчы малайлар барысы да үзләренә кирәкле дәреслекләрне табарга өметләнеп килгәннәр. Теге мишәр малае да китап эзли икән. Сигезенчегә татарча язылган китаплар кирәк икән үзенә. Авыл малайлары гадәттә беркатлырак булучан бит. Шәһәрдә бөтен мәктәпләрдә урысча гына укыганны белми торгандыр, аңа татарчасы кирәк дәреслекнең, татарчасы! Мин инде үземә ярардайларын табыштырып куйган идем: бөтенләй дәреслексез калмыйм дип, әүвәл урысча язылганнарын алып куйдым да, аннары очраган саен татарчаларын да сатып алгаладым. Бу малай авыз ачып калгандыр инде, югыйсә очраган бер кешедән үзенә кирәкне белешмәс иде. Минем янга да килде.

—Сиңа нигә дәреслекнең татарчасы, ярамаганмыни урысчасы, әнә ич, ал да кит,—димен.

—Юк шул, мин авылда гел татар китапларыннан укыдым, анда җидене бетердем, хәзер инде сигезенчегә...

—Нindиләре юк соң әле?

—География бик кирәк!—дип, зәңгәр кәпәчен төзәтеп куйды.

Мишәрчәләп сөйләшүче, кысыграк күзле, зур авыз-борынлы бу малайның әллә үҗәтлеге, әллә мескен хәлдә калуы ныграк тәэсир итте инде—мин аңа үземдәге китапларның татарчасын бирергә, үземә урысчасын гына калдырырга булдым.

—Узган атнада кырык сумга алган идем мин географиянең татарчасын. Бик кирәксенсәң, бирми дә булмас,—димен.

—Иллене түләргә дә риза!—ди бу, дәртләнеп.

—Артыгы кирәкмәс. Тик ул өйдә бит, иртәгә китерермен,—димен.

Кай арада мишәр малаеның йөзе үзгәрде:

—Мин иртәгә шәһәргә килә алмыйм шул...—диде һәм төшендереп бирүне дә кирәк тапты бугай:—Дәрбишкәдә яшим бит,—дип тә өстәде.

—Алайса, иренмәсәң, Пләтәнгә хәтле минем белән барасың,—димен.

Иренә буламыни, кирәкле әйберен вәгъдә иткәндә—мишәр малаеның табак битенә елмаю җәелде. Пләтәнгә җиткәнче эһ тә итмәде, авылдагы сыман, чалбар өстенә чыгарып салган сары күлмәген җилфердәтә-җилфердәтә, кәкре аякларын еш-еш алдырып, минем белән янәшә атларга, калышмаска тырышты. Безнең ишегалдына кергәч, күршеләрнең янбакчалары коймасы янында минем икенче каттан төшкәнне көтеп торды. Гаҗәеп калын география китабын ике куллап алды ул, шундук ачып та карады. Морадына ирешкәч, кош тоткандай сөенгәне хәтеремдә. Әнә шул елмаюыннан танып алдым мин аны, беренче сентябрь көнне үзебезнең сигезенчедә күргәч. Яланбаш бит инде класста, зәңгәр кепкасын салып, партасы эченә яшергән иде. Зур кара сумкасына (портфель-мазар түгел, солдатларча җилкә аша асып йөри торган алагаем сумка) барлык китапларын тутырган. Ул сумкасы парта эченә сыймагач, китапларын берәм-берәм чыгарып куйды. Арада миннән алган теге калыны да күзгә чалынды. Укулар башланганчы килеп, расписаниене язып алмаганы күренеп тора: бүген география дәресе юк иде.

Ул малай Кече Чынлы дигән мишәр авылыннан чыгып, Дәрвишләр калавылында яшәп ята икән. Элекләре анда татар сыйныфлары булып, сугыш башлангач, бишенче малайларын-кызларын урысча укырга мәҗбүр иткәннәр. Анысына ияләшеп җиткәч кенә, атасыз калган гаилә өчен ике еллап авылга кайтып яшәү кулай табыла—анда янә үзебезнең телдә укуын дәвам иттерә.

Яңадан Казанга килгәч, ана телендәге мәктәпне эзләп таба. Әнә шул рәвешле безнең "ирләр мәктәбе" дигән уникенчебезгә килеп эләгә. Ир балалар ана телендә белем ала торган соңгы мәктәп әнә шул булгач, монда килмичә кая барсын! Мин үзем дә Пләтән башында, күршебездә яшеллек эчендә утырган җидееллыктан соң менә монда килергә тиеш булдым. Кызык инде: беренче-дүртенче сыйныфларны унөченчедә тәмамладым да хәзер гүя кирегә түндем—уникенчегә кереп, сигезенче-унынчыны очлыйсыларым бар...

Сугыш әле бетмәгән, Кабан күле буендагы бу мәктәпнең дүрт катлы мәһабәт бинасында әле һаман госпиталь булып, мәктәп үзе элеккеге Күл буе мәдрәсәсенең карасу кызыл кирпечтән узган гасырларда ук коелган ике генә катлы бинасында кысан шартларга түзеп торырга тиеш иде.

Военругыбыз җиңелчә яраланып кайткан бер солдафон иде. Әнә шул безне сафка бастырды да, хыялында үзен солдатлар сафы алдыннан йөргән сержант итеп күз алдына китерде бугай, калавыл малаеның каршысына килеп туктады да:

—Иртәгә үк чәчеңне алдырып киләсең! Штобы шоп-шома булсын! Алдырмыйсың икән, үзем кыркам, бүген үк кайчы әзерләп куям,—диде.

Әлбәттә, сафта сөйләшергә ярамаганы һәркайсыбызга мәгълүм иде, мишәр малае авызын да ачмады. Тик шунда башка малайларның авыз ерулары ошамадымы, укыту-тәрбия эшенә алынган военрукның шулай тупас әмер бирүе бик нык рәнҗеттеме, әллә инде үсмер егетнең чем-кара бөдрә чәче бердәнбер куанычы-байлыгы булып, аңардан да ваз кичәргә исәбе юк идеме—ничек булса булды, мәктәп белән ул шундук саубуллашты.

Хәер, мәктәп минем үземә дә әлләни ошамады. Бүлмәләрнең кысанлыгымы, сигезенчеләрне җитәкләгән укытучы хатынның баерак малайларга ярарга тырышып, алтын тешләрен ыржайтып елмаюын күтәрә алмадыммы, көн итүләре бигрәк кыен булуы тәэсир иттеме—тәгаен әйтүе кыен, тик инде, мәктәпне бөтенләй үк ташламасам да, укуга суына төштем. Барган чакны барып, бармаган көннәремдә йә әнигә булыштым, яисә ипекәй табыштырып, вак-төяк эшләр башкарырга мәҗбүр булдым. Нәтиҗәсе әлләни көттермәде—сигезенчедә икенче елга калдым. Сугыш туктап, атасыз калгач, үги абыем фронттан кайткач, өйдәгеләр минем алга иң зур бурыч итеп унны бетерү вазифасын куйдылар. Әни болай да башы-аягы белән мәшәкатькә чумган, минем өчен дә күз яше түкмәсен, дип кенә, мәктәпне тәмамлап чыгарга вәгъдә бирдем. Ана телендә, бөтен шәһәр буйлап көндез чыра яндырып эзләсәң дә, башка мәктәпне таба алмагач, әлеге дә баягы шул ук уникенчегә юнәлдем.

Безнең шикелле бер малай укырга-язарга да юньләп өйрәнә алмыйча, яңа уку елында тагын беренчегә кереп утыргач, укытучылары кара тактага хәрефләр язып, аларны ничек укырга икәнен аңлата башлагач, түзмәгән:

—Апа, апа, бу бит безнең былтыргы "а"!—дип кычкырып җибәргән, имеш.

Теге бөдрә чәчле мишәр малаен күргәч, үземә иш тапкандай, аның янына килдем дә:

—Нихәл, географ?!—дип, кул биреп күрештем.

Бүтән малайлар аны белми иделәр, үземә аптырап карадылар:

—Каян беләсең син аны?—диештеләр.

Чөнки мишәр малаеның кыяфәте башкалардан аерылып тора иде. Мин аны үз итеп:

—Без бит аның белән хан заманында җир сукалап, бодай чәчкән идек,—дидем.

Һич югы берәү шулай үз иткәч, мишәр малаеның авызы ерылды, тигезле-тигезсез тешләре күренде. Соңра миңа шунысы мәгълүм булды. Чәчен алдырасы килмичә уникенчедән киткәч, иң әүвәл, әнисеннән фатиха алып, туган авылларына юнәлгән. ТБУМны тәмамлаганнан соң җиде-сигез чакрымдагы район үзәге Шәйморзага йөреп укыйсы икән. Әүвәл ике-өч сабакташы белән шунда йөреп маташкан. Көн саен ун-унбиш чакрымны узулар аны ялыктырмаган, фәкать әнисенең апаларында яшәү тора-бара аңа авырга килгән—ишле гаиләдә аңа җылы мөнәсәбәт булуга да карамастан, ул үзенең артык җан икәнен абайлаган.

Октябрь бәйрәмнәреннән соң ул Казанга әйләнеп кайткан. Калавылда ул чакларда ук инде урта мәктәпләр икәү-өчәү булып, фәкать урысча гына укырга җай бар икән. Артык ашыкмыйча гына, яңа еллар узгач кына, йөз дә беренче мәктәпкә, элек үзе белән бергә укыган малайлар-кызлар янына, сигезенчегә барып кергән. Ярты ел эчендә иптәшләрен укуда куып җитүнең өметсез фал икәнен дә аңлый инде югыйсә, тик инде тырай тибеп йөрмәс өчен генә, ирекле тыңлаучы сыйфатында "укып" йөргән.

Гәрчә кайбер фәннәрдән ипле генә барса да, төгәл фәннәрдәге өр-яңа материалны да, урыс телендә үзе өчен ят булып яңгыраган терминнарны да ныклап үзләштерергә дә, физика-математикадан буразнага төшәргә дә өлгерми—уку елы тәмамлана. Үз авылында ана телендә җидене мактау кәгазьләре белән очлаган була торып та, зимагурлыгы-дәрвишлеге аркасында сигезенчене җиңеп чыга алмый—икенче елга кала...

Әллә инде зимагурлык мишәр малаеның канына сеңгән, милләтебезгә хас әлеге сыйфат әллә инде гомерлек юлдашы— белмәссең. Ихтимал, шулай дадыр... Моның мисаллары әле киләчәктә дә сизелгәләр. Сыныкка сылтау итеп кенә, яшәү шартлары авыр иде, башкача булдыра алмагандыр, дип котылырга, дустыңны акларга маташу һич тә егетлек булмастыр. Аның язмышындагы кискен борылышлар нәкъ менә үзенең зимагурлыгы-дәрвишлеге аркасында килеп чыгадыр. Чат дөресе шулайдыр...

Бәрәңгеләр үстереп, утыннар хәстәрләп йөри торгач, яңа уку елы якынлашканны ничектер бөтенләй абайлап та өлгерми. Нәкъ шул чагында, йөз дә беренченең сигезенчесенә кереп укырга әзерләнеп, дәреслекләрне барлап ятканда гына, егетебезгә нидер була бит, әй! Күктән аваз ишетелде, фәрештәләр сиздерде, дип әйтү бүгенге көндә, ихтимал, иң кулае булыр иде. Тик ул чеп-чи ялганнан, күз буяудан ары китмәс иде.

Дәрвишләр калавылында яшәүче халык, Казан белән чагыштырганда, ныграк урыслашып өлгергән иде. Татар малайларының үзара сөйләшкәненә колак салсаң, чәчең үрә торырлык иде. Укучым хаталана күрмәсен, без үскәндә сүгенү сүзләре хәзергечә ике сүзнең берендә әйтелми иде. Тик инде саф ана телендә матур итеп сөйләшкәнне дә бөтенләй ишетмәс идең. Ана теленә урыс сүзләрен катнаштыру чире берәүне дә читләтеп үтми. Ул чагында ешрак Мансур һәм аның энекәше Әмир белән аралаша. Сүзләрне гел бутап бетерәләр инде менә. Гәрчә татар әдәбиятын үлеп яратса да, ана телен бозуга һич каршылык күрсәтә алмый гына бит мишәр малае. Иң читене үз-үзеңне җиңү, диләр бит. Каян тапкандыр шундый көчне, анысын төгәен әйтүе кыен. Фәкать көннәрдән бер көнне чатнатып урысча:

—Кыям, дальше так нельзя!—ди.

Әнә шул сүзләр агым уңаена тыныч кына йөзүенә чик куя.

Урыс мәктәбеннән кирәкле кәгазьләрен ала да яңадан әлеге дә баягы бердәнбер милли мәктәпкә юнәлә. Чәч мәсьәләсе ничегрәк хәл ителгән булыр иде, анысын хәзер фараз кылып торудан файда юк: ул арада сугыш бетеп, военрук эшенә элеккеге офицерны куеп, абзыйны... завхоз итеп "күтәргәннәр" иде инде.

Күл буе мәдрәсәсендә әлләни озак җәфаланмадык. Сугыш туктагач, уникенче мәктәпнең төп бинасыннан госпитальне каядыр күчереп, янә үзебезгә бирделәр.

Җиңнәрне сызганып, бөтен мәктәпне юып чыгардык, дару-мазар исеннән тәмам арындырдык. Ул заманнарда машиналар күп түгел, автобуслар гел юк, Дәрвишләр калавылыннан Казанның үзенә фәкать Арча поезды белән иртәнге биштә китеп, кичке тугыз тулгандарак кайтып житү мөмкинлеге бар иде. Беренче көннәрдә моңа җайлашуы кыенгарак килә мишәр малаена. Кайтырга чыкккач, утырган жирендә ничектер оеп китә бу. Уянып, тәрәзәгә күз салса—бөтенләй таныш түгел җирләр.

—Әми тавын уздыкмы, әллә Дәрвишләр станциясенме?—ди икән.

—Тот капчыгыңны! Киндерледән кузгалып киттек ләбаса,—диләр.

Тамбурга чыгып, баскычка төшә дә сикерергә әзерләнә: юл буена утыртылган тимер багана турысыннан узу белән, йөгереп китәргә җайлашып, алга таба сикерә. Дүрт-биш чакрымны атлый-йөгерә торгач, дөм караңгыда кайтып керә шул. Әниләре борчылып торганын да аңлый инде егетебез, тәпи-тәпи, ягъни утырып-җәяү кайтуына да гарьләнә. Үз-үзенә хәтәр нык ачуы килә. Шуннан соң сигез ел дәвамында кая ул калгып китүләр дә кая ул авыз ачып станцасын үтүләр яки иртәнге якта соңга калулар!

Яугирләр, сугыш чукмарлары малай-шалайдан чыга бит инде, анысы бәхәссез. Малайларның шактые бәйләнчек, шәфкатьсез, үзеннән көчсезрәкләрне адым саен рәнҗетүчән, алардан көләргә, мәсхәрә итәргә яратучан. Уникенче мәктәпкә килеп төпләнгәч, сигезенчеләр дә Мишәр-Кәбәй дип аның күзен дә ачырмыйлар, шундыйрак бер кәмит күрсәтергә ниятлиләр. Төптәнрәк уйлап карасаң, кеп-кечкенә буйлы, калавылдан поезд белән килеп, көннәр буе ач утырган йолкыштан үч алырга урын да юк, өс-башыннан да көнләшерлек түгел иде инде. Ир балалар мәктәбе булгач, кызкыркынны да бүлешәсе юк, нигә каныкканнарын һич аңлый алмадым. Хәер, сират күперен һәркем үз гомерендә әледән-әле кичәдер инде, кичүгә дучар ителәдер...

Зур тәнәфестә, карыйм, малайлар моны уратып алалар. Божра эченә, күн бияләен кия-кия, Швейк дигән кушаматлы, гаять житез һәм елгыр малай керә. Әһә, бокс белән алдырырга, мишәр малаен тукматырга икән исәпләре! Әнә бит авызлары хәзер үк ерылган. Судьясы да табылган, шуның гына яңгырап ишетелә тавышы—үзенә күрә көч бирә инде көчлегә, елгыр малайга. Мәсхәрәле караштан гайре берни юк тегесенең ягына: читтән килгән йолкышны әлеге кукыраеп торган, шпорларын чыңлатып йөргән әтәчтән бер дә ким булмаган Швейк кулы белән дөмбәсләргә ажгырып торабыз һәркайсыбыз. Еллар узгач булса да әйтмичә ярамас чын-дөресен: әлеге шаукым бөтереп кенә алды барчабызны, мин үзем дә экзекуциягә каршы чыкмадым, авыз ачып ичмасам бер сүз әйтмәдем шул, әйтмәдем...

Ул арада боксерыбыз, тыпыр-тыпыр биегән сыман аякларын еш-еш алыштырып, кәмитче шикелле тегенең өстенә килә дә башлады. Кулларын хәйран оста йөртә бу, мөгаен, бокс түгәрәгенә дә йөри торгандыр әле, дип уйлап алдым. Башкалар да соклануларын яшермичә, елмаешып көтә бирделәр. Сокланмаслык түгел иде шул: мәһабәт сынлы Швейгыбыз кулларын тагы да житезрәк йөртә, бигрәкләр инде саллы селтәнә башлады—теге йолкышка инде сул кулы белән генә елгыр егетебезнең кулларын читкә тибәреп, суктырмый калулар торган саен кыенлаша барды.

Әмма ул чагында барчабыздан да йолкышрак-фәкыйрьрәк мишәр малаеның халәтен, ниләр кичергәнен беребез дә белмәде һәм белергә дә теләмәде. Безнең максатыбыз бер генә—тизрәк шуны тукматып ташлау, туйганчы бер көлү, шаркылдау иде. Ә теге йолкышның күңелендә, мөгаен, өермәләр котыргандыр: ачуы кабарганнан-кабаргандыр, ләкин бу ачуы аның каршысында биеп торган кәмитчегә генә түгел, бәлки әле үзенә экзекуация оештырган өчен безнең барчабызга да, алай гына да түгел, янә килеп Дәрвишләр калавылында үз ана телендәге мәктәпнең киләчәгенә балта чабучыларның барысына да, иртә таңнан алып караңгы төнгәчә мәктәп саклауга, бер телем әпәйгә тилмереп яшәүгә үзен дучар итүчеләрнең һәммәсенә дә, хәтта әле сугыш башлап, бомбалар ташлап, үзен ятим калдыручы фашистларга да җан ачулары килгәндер, һәм әнә шул гайрәтләнү аңарга кодрәт вә куәт биргәндер. Югыйсә... рингта хәлләр шулчаклы ук тиз үзгәрер дип өметләнерлек тә түгел иде бит.

Болай булды.

Кәмитченең ике куллап хәйран җилле төйгечләргә маташуын сул кулы белән кире тибәрә торгач, Швейкның артыграк мавыгып, остарып китүен күреп, мишәр малае бөтен гәүдәсен алга ташлап, барлык ачу-гайрәтен уң кулына туплап, бар ярсуы белән күкрәк читлегенә берне китереп тондырган иде—әле генә шау-гөр килеп торган бүлмәбездә чебен очкан тавыш та ишетелерлек булды; мәгәр чебен-фәлән күренмәде,

фәкать барча кәмит карарга яратучыларның күз алдында кәмитчебез үзе гөрселдәп идәнгә ауды.

Бу хәлне күреп, без һәммәбез телсез калдык. Без бит аны бокснын нинди нәрсә икәнен дә белми инде, авыл гыйбады дип тора идек, ә ул әнә бер селтәнү белән боксчыны әллә кайларга чөеп кенә очырды!

Иң әүвәл "судьябыз" аңына килде һәм кәмитченең күпме ятканын саный башлады, унга чаклы санагач, нәкъ менә чын турнирдагы сыман иттереп, җиренә җиткереп:

—Нокаут!—дип игълан итте һәм теләсә-теләмәсә дә мишәр малаеның кулын югары күтәрде.

Әнә шул рәвешле мишәр малае бер сугуда бөтен мәктәп күләмендә авторитет яулады. Бүтән бәйләнүче күренмәде.

Директорыбыз Кәрим абый Хәмитов дигән зыялы агай иде. Мәһабәт гәүдәле, сыек кына чал чәчле, мөлаем йөзле, искиткеч дәрәҗәдә миһербанлы-шәфкатьле бер гали зат иде. Ихтимал, укытучыларга ул таләпчән дә, кырыс та булгандыр, әмма берәүне дә рәнҗетмәде шикелле.

Әйтик, унынчыда укыганда ул безнең янга үзе генә кереп, дөнья хәлләренә кагылышлы гәп корып җибәрер иде. Аның янында без үзебезне гаять иркен тота идек, аңа ышана һәм чиксез ярата, хөрмәт итә идек. Бер-ике укытучының белем ягы сай булуын, дәреслекне алдына куеп, шуңа карап кына "аңлатуын" чишкәч, юмарт һәм акыллы елмаю белән елмайды да:

—Бик дөрес, егетләрем, хәлләр шулайрак шул. Үзем дә бик яхшы беләм, һәр укытучының ничек сулаганын да, ни рәвешле дөньясын алып барганын да бик белеп торам. Тик инде укып надан калган укытучыларны бүген куып чыгарсаң, алар кая бара?..—диде.

Кәрим абый куе зәңгәр күзләренең карашын, уңайсызланып кына, өстәл өстендә яткан саллы кулларына төшерде. Ирексездән без дә тынып калдык, үзебез хөрмәт иткән дәү кешенең уйларын бүлдерергә җөрьәт итәрдәй берәү дә табылмады. Ул заманнарда әле әдәп дигән нәрсәдән мәктәп балалары бизмәгән иде. Без директорыбызның акыллы сүзен көттек.

—Болай бит ул, егетләрем. Кеше егерме-утыз ел буена, әйтик, математика укыткан. Шәһәрдәме, авылдамы ул үз фәнен үзе белгән телдә укыткан. Яхшы укытучымы ул, урта кулмы, әллә инде бөтенләй үк өтә балакмы—анда түгел хикмәт. Ул сезнең кебек балаларны үзебезнең ана телебездә укыткан, гомерен шуңа багышлаган бит инде. Хәзер аны әлеге эшеннән мәхрүм итсәң, начар укытучы дип, куып чыгарсаң, ул кая барырга тиеш була? Казаныбызда калмады лабаса татар мәктәпләре! Без иң соңгысы!..

Директорның сүзләре шактый кырыс яңгыраса да, шундый олы гәүдәле кешенең кыяфәте әллә ничек куырылып китте, без аңарга туры карарга оялдык, үзебезне гаепле итеп сизгәндәй булдык. Ирексездән кызарышып утырдык.

—Инде менә үзегез уйлап карагыз, егетләрем. Үз һөнәрен бик әйбәт үзләштергән, гомер буе ана телендә сезнең кебекләргә белем биргән укытучы, әйтик, шул ук математиканы икенче бер телдә, әйтик, урысча укытырга алынырмы? Юк, алынмас акылы булган бәндә. Чөнки математиканың да, бүтән фәннәрнең дә һәр телдә үзенең төшенчәләре, үзенең терминнары бар, шунсыз фән була алмый.—Директор куе зәңгәр күзләрен өстебездән йөртеп чыкты.—Хәзер әйтегез инде, гвардиячеләрем, татар мәктәбеннән сөрелгән укытучы нәрсә эшләргә тиеш була? Заводка барсынмы ул, базарга сату итәргә юнәлсенме? Нәрсә дә булса эшләргә, бала-чагасын ашатып-эчертеп яшәргә, аларны тәрбияләргә тиеш ич инде ул! Бигрәк тә ире сугышта һәлак булып калса яки гарипләнеп кайтса?..

Гәрчә унынчының соңгы айларын укысак та, һәркайсыбыз үзен бик-бик акыллы дип хис итсә дә, мондый тормышчан сорауга җавап таба алмадык. Без мондый катгый сорауга әзер түгел идек әле. Кәрим абый Хәмитов шул рәвешле безне, акрынлап кына, уйланырга өйрәтте.

Тырыша-тырмаша торгач, унынчы сыйныфны да "кимереп" бетерергә җыенган чагыбыз. Яңа ел каникулыннан соң—финиш та күренә башлады бугай. Ник дисәң, егетләребез уянып киткәндәй булды:

—Выпускной вечер ясыйсы иде бит...

—Без кешедән киммени?

—Безгә дә ярар иде ул, мәктәпне бетергәч, бер селкенеп алу!
—Әйе, мәктәпнең ун ел буена үзебез җыйган тузанын каккалау!
—Тик менә сәмәнне каян табасы?
—Әйе-е-е, аңа шактый сәмән кирәк булыр инде...
—Җыябыз аны, акчаны!
—Әйттең сүз! Минем маман болай да өч малай үстерә. Эшли-эшли бөкересе чыкты инде. Теләсәгез нәрсә диярсез, егетләр, мин аңардан акча сорый алмыйм.
—Безнең өйдә дә кытлык инде анысы.
—Мин дә сәмән китерә алмыйм.
—Нишләргә генә кала соң?
—Нишлибез?

Әллә көнозын мәктәптә булып, төрле җәмәгать эшләрен дәртләнеп башкарганга, әллә күбебездән бер генә яшькә өлкәнрәк икәнен белгәнгә, үзеңнән бер көн элек туганнан акыл сора, дигән мәкаль исебезгә төшеп, әллә инде көчлерәк һәм тәвәккәлрәк икәненә бертөрле дә шик калмаганга, шулчагында һәммәбезнең күзе ирексездән минем дустыма төбәлде. Ә инде аның акча табыштыруга кагылышлы фикерен ишеткәч, егетләремнең колаклары торды.

—Без берәр спектакль куя алыр идек инде куюын...
—Ничек итеп? Кем өйрәтә безне театр уйнарга?
—Анысы авыр эш түгел аның. Үз өстемә алам. Аз-маз уйнаганым, сәхнәгә чыгып селкенгәләгәнем булды вакытында...
—Ярый соң алайса. Өйрәт белгәнеңне!
—Тик менә хатын-кыз ролен кайсыларыбыз башкара алыр икән? Минем үземнән булмый анысы...
—Һәй, туган, бер дә кайгырма аның өчен! Сиксәненченең кызлары, әнә, безнең ишегалдында гына торалар.
—Без ул мәктәпкә кергәләп тә йөрибез. Бер сызгырсак—хәзер килеп җитәләр ул артисткалар.
—Ярый, алайса, иртәгә сызгырырсыз—шушы вакытка чакырыгыз үзләрен.

Аптырашып калдык барчабыз да. Кымшанмыйча да, тыныч кына утырган дустымниләр генә мәтәштерергә җыена икән? Спектакль хәтле спектакльне ни рәвешле башкарып чыкмакчы була икән бу мишәр малае? Көчлесен көчле инде үзе, тик монда физик көч белән алдырып булмас бит, осталык кирәк, осталык!.. Әле әнә үткән ел музыка училищесеннән Әухәди абый скрипкәсен күтәреп безнең янга килеп йөргәләде дә бит—берни булдыра алмады. Нияте изге иде инде югыйсә—үзебезне скрипкә уйнарга өйрәтмәкче иде. Тик менә берни майтарып булмасын аңлады, күрәсең. Бердән, һөнәргә сабый чактан гына өйрәтеп булганы һәркемгә мәгълүм; икенчедән, скрипкә сатып алырга беребезнең дә хәленнән килмәде. Атнага бер-ике мәртәбә скрипкәне кулыңа алып кына әлеге нечкәбилдән берәр төрле моң чыгарырмын дип уйласаң, бик нык ялгышасың. Аюны да биергә бит унсигездә өйрәтмиләр...

Хәер, безнең сабакташыбыз теге музыканттан үҗәтрәк бугай бит әле. Мактанчык булса да, кызыксынмаган нәрсәсе юк үзенең. Скрипкәне дә иң иплә тота белгән егет шул булды. Әухәди абый да мактады үзен. Көйне дә чыгарып маташкан иде инде югыйсә, тик менә скрипкә сатып алырлык сәмән таба алмаган шул, таба алмаган... Югыйсә үзе, әллә кайлардан акча табыштырып, урысча китапларга—Лермонтов белән Белинскийга язылган, беренче томнарын алгач, безгә дә күрсәтте. Лермонтовына кызыгып, мин дә барган идем дә бит Баумандагы ул китап кибетенә—язмадылар, соңга калдың, диделәр. Дустым шунда ук "Рус теле сүзлеге"нә язылды. Мине дә кыстап караган иде—батмады: ул унҗиде томлыкны кая куеп бетермәк кирәк?!

Әнә шул мактанчык дустым чыгарылыш кичәсенә акча эшләргә алынды. Аптырагannan инде, һич тә ирекле көннән түгел. Ятып калганчы атып кал, дип кенә алынды бу эшкә. Беребезне дә читтә калдырырга түгел икән исәбе. Әнә бит сиксәненче кызларын да сыйныфлары белән дәштерде, берән-сәрән генә түгел.

Чакырган җиргә килделәр тегеләре дә, һич кыстатып тормаганнар, унынчыдагылар барысы да җыелышып килгәннәр дә утыралар әнә тезелешеп: берсеннән-берсе чаярак та гүзәлрәк, әмма үзләре инде, ир балалар мәктәбенең ишеген беренче кат ачып, бусагасын әүвәле мәртәбә атлап узганнар икән, бигрәкләр тыйнакланып утыралар. Кунак булсаң—тыйнак бул, дип әбиләре үзләрен өйрәтеп җибәргән төсле. Күзләрендә

генә—дәрт вә ялкын. Сабыр итик әле, сәхнәдә күрсәтәсегез бар һөнәрегезне, тамашачы алдына чыккач, тыйнакланып кына артык дан казана алмассыз! Ә бит данга сусамаган артистны күз алдына китерүе дә читен.

Химия кабинетына кереп утырыштык. Мишәр егетенең Хәлимә апа белән борчагы пешә, үзе югында укытучы апа аны бик рәхәтләнеп бүлмәсенә хуҗа итеп калдыра иде. Әнә бит хәзер дә Хәлимә апаның бәләкәй генә өстәле артына ике дә уйламыйча кереп утырган да, чем-кара бөдрә чәчен төрле якка тузгытып, табак битен урталайга ярып төшкән бөркет борынын уңлы-суллы йөртеп, әңгәмәне башлап та җибәрде. Һич оялып яисә тартынып тору юк анарда. Каян күргәндер чын режиссерның ниләр кыландырганын, әллә бәлкем бөтенләй дә хәбәрдар түгелдер, тик инде һич тә кимен куймый. Миңа калса, театрда эшләүче кайсыберләрен уздырып та җибәрәдер әле.

Иң әүвәл концерт бүлеген хәл итте—кемнең җыр яки бию осталыгын, шигырь сөйләргә яратуын ачыклады. Боларның һәммәсен кәгазьгә теркәгәч кенә, тагын әле яңа номерларның, бигрәк тә парлы җыр яки парлы биюләрнең өстәлүе ихтималын искәртеп куйганнан соң гына, "режиссерыбыз" спектакльгә күчте. Ике-өч пьеса тәкъдим иткән иде, кунакларыбыз "Беренче театр"ны хупладылар. Без дә каршы килмәдек, әлбәттә: бердән, алар кунак булса, икенчедән, чибәр кызлар; өченчедән, классиканы җиренә җиткереп уйнавы кыенлыкка кыен да бит, ичмаса уйнарлыгы бар, образлар ныклап ачылган, аңлаешлы, ярылып ята.

Ул арада кызларыбыз кунак булып килүләрен истән үк чыгардылар, ахры, шактый гына кыюланып өлгерделәр: әледән-әле яңа номерларны яудырып кына торалар. Шулай да күзләрендә һаман сынаулы караш, ничектер шикләнебрәк карау сизелә иде. Соңыннан белдем: алар халкы һәрбер яңалыкны шулай сагаеп та гаҗәпсенеп кабул итә, ышанырга да әзер, ышанган сыман кылана да, әмма нык лабрак сыный әле үзенне, бик үк иманы камил түгел.

Кызларыбызның җыр-биюгә оста икәнлекләре күренеп тора, әмма спектакль эше нәрсәгә берсененң-бер катнашканы юк икән. Шуны белә торып та үзләрен сәхнәгә алып менәргә, яңа һөнәр өйрәтергә әзер әлеге дә баягы куе бөдрә чәчле, клоунныкыдай зур ук борынлы егетебезгә олуг өметләр баглап, аның кысыграк коңгырт күзләренә текәлгәннәр. Көнләшеп үләрсең, әй! Җитмәсә бит әле рольләрне бүлгән чагында ират рольләренең гүя һәркайсын режиссерның үзеннән уйнатырга иде исәпләре, берсенберсе бүлә-бүлә:

—Үзең уйна инде, үзеңә ал!—дип кенә торалар. Һәммәсе дә бер күрүдә үзенә гашыйк булганнар, диярсең.

Тик алдатмады мишәр егете, сүзләренә һич тә колак салмады. Аның йөргән кызы бар! Яңа ел алдыннан мәктәпкә дә ияртеп килгән иде әле үзенең җирән чәчле, яшькелт күзле Кларасын. Ул кыз Вера Андреевна белән озаклап серләшеп тә алды бугай әле.

Дустың режиссер булгач, рольсез калмыйсың икән, шунысын аңладым, чөнки иң әүвәл Хәмзә байны миңа тапшырды:

—Бу роль аңа бик килешә, оста уйнарга тиеш,—дигән булды.

Авыз ачып каршы сүз әйтүче күренмәде. Миңа рольнең саллысы эләкте. Һәркайсыбызның холкын-табигатен яхшы белгәнгә, кем нинди рольне башкарырга тиешлеген аермачык күзаллый-шәйли иде бугай. Кызларга да персонажларның үзенчәлекле якларын төшендереп бирүне үзенең бурычы санады.

Мәзәк бер хәл инде: спектакльгә дүрт-биш кенә кеше катнашса да, барыбыз да эшкә җигелдек, безнең арада моңарчы булмаган татулык һәм бердәмлек хөкем сөрде: кем билетлар язып, аларга мәктәпнең мөһерен суга, кем ул билетларны сатып торачак, кемнәр ишек төбендә контролер булачак, кемдер гардеробта кием кабул итәчәк; икенче берәүләр исә игълан әмәлләп, аны "Чаткы" (хәзерге "Тукай") кинотеатры янына коймаларга ябыштырып йөриячәк... Бай белән ярлы аермасы калмады—чыгарылыш кичәсен үткәрү өчен мая туплау идеясе һәркайсыбызны бөтереп кенә алды.

Әлеге хәлне күреп, иң нык, самими сөенү белән сөенгән зат сыйныф җитәкчебез Вера Андреевна булгандыр. Әдәбият дөньясы белән рухланып, безне әниләребез кебек үк яратучы бу изге зат, әлеге сират күперен бердәм кичсәләр, дәүләт имтиханнарында шулай ук сынатмаслар әле егетләрем, дип өметләр баглагандыр, бичаракай.

Гвардиячеләренең биниһая активлашуын күреп, директорыбыз да сөенгәндер инде, сөенми булмагандыр. Тик олы дәрәҗәле җитәкче берни сиздермәде. Спектакль буласы көнне, умарта оясыдай гөжләп торган бинада минем дустымны очратып:

—Мин... кичен килеп йөри алмам инде. Мәктәпне сиңа ышанып тапшырам, игътибарлы бул...—дип кенә әйтергә онытмый. Кабинетына да чакыртмый режиссер-вожакны, укытучылар бүлмәсенә дә дәштерми, фәкать очраклы рәвештә коридорда күреп кенә колагына киртләп куя. Тәрбиянең әнә шундый ысулы теләсә нинди вәгазеңнән өстенрәк вә үтемлерәк, һәм берәүгә генә тәэсир итми, бәлки барчабызны уяу булырга чакыра иде. Һәрхәлдә, мин үзем җанымны бирергә дә риза булганмындыр, фәкать Кәрим абыйның дустыма шундый зур ышаныч баглавын ничек тә акларга, аның йөзенә кызыллык китермәскә иде исәп. Спектакль көне якынайганда дүрт катлы мәктәпнең аскы катын тулаем диярлек алып торган спортзалны һәйбәтләп юып чыгарабыз, кайсыбыз-каян такталар табыштырып, сәхнә әмәллибез. Әлеге әзерлек эшләрендә дә режиссерыбыз, җиң сызганып, һәммәбезгә үрнәк күрсәтте. Беребез дә читтә калмады, ялкауланмады—эшне печеп эшләдек. Аннары тамашачыларга дип озын эскәмияләр кертеп куйдык.

Үзебез дөнья җимертеп репетицияләр үткәрәбез, тамаша залын хәстәрлибез, тик менә шөбһә дә шик үзенекен итә—күңелебезне өметсезлек корты кимерә: килерме халык, әллә юкмы?..

Бүген үзебездә уйнасак, иртәгә сиксәненче мәктәпкә барасыбыз. Анда ничегрәк килеп чыгар?.. Начар даныбыз таралса, театр уйнау түгел, мәктәбеңне ташлап качарсың!..

Халык җыелмас, дип шүрләбрәк торган идек, агылды гына яше-карты. Ни әйтсәң дә, Иске Татар бистәсендә халык тамаша карауны үлеп ярата шул. Егетләрнең йөзләрендә елмаю, кызларыбыз биеп кенә йөриләр. Тагын да чибәрләнебрәк киткәннәр шикелле.

Программабызда иң әүвәл концерт иде. Кызларыбыз сәхнәдә очып кына йөрделәр. Гап-гади җырларында исә һәркемне уйландырырлык моң, яшьләрне җилкендерерлек дәрт иде. Күр әле, күр, бу парлы биюне кай арада өйрәнеп өлгергәннәр? Килешле генә чыга бит, әй!

Беренче бүлек барган арада егетләрнең кайсын да булса алмаштырып, күз-колак булгандай буталып йөрсәк тә, спектакль вакытында үзебез дә артист идек: йә сәхнәдә, йә сәхнә артындагы бүлмәдә юандык.

Бик матур башкарып чыктык бу тамашаны: халык ду кубып кул чапты. Фәкать икенче көнне генә сәер бер хәлгә дучар булган минем дустым. Тамашадан җыелган акчаны тиененә чаклы, сберкассада счет ачып, шунда тапшыргач, артыннан ике малай килә икән моның. Үзләре нидер мыгырдыйлар, үзләре тыела алмыйча көләләр.

—Нәрсәдән көләләр икән, дисәм—миннән көләләр икән, Хәбибрахман булып уйнавымнан,—дип сөйләде мишәр егете.—"Биш тиен дә биш тиен—була унбиш тиен..."—диләр дә бөтен урамны тутырып көләләр. Моннан дүрт-биш ел элек авылдагы шикелле үк, артыма тагылганнар да көлепме-көләләр! Һәй! Артистларның да язмышына кызыгырлык түгел икән...—дип көлдерде үзебезне.

Шулай да җыйдык без чыгарылыш кичәсен уздырырлык малны ике-өч пьеса куеп. Көне җиткәч, кенәгәдә җыелган маяны "режиссерыбыз" тиененә чаклы кайтарып тапшырганнан соң, кичәгә әзерлек эшен иптәшләребезнең әниләре, уңганрак апалар бик рәхәтләнеп үз кулларына алдылар.

Әүвәл безнең мәктәптә, аннары кызларда уздырдык әлеге кичәне. Саубуллашу кичәсен зур залларда, сый-нигъмәт тулы өстәлләр янында башлап, таңны урам урап каршыладык.

Гомергә истә калырлык вакыйга булды бу. Дәрвишләр бистәсеннән таң тишеге белән килеп, кичке караңгыда гына Арча поезды белән өенә кайтып ничәмә-ничә ел буена белем эстәгән, дөресрәге—кыен ашаган дустымның әнә шул егетлеге һәммәбезне һөнәргә өйрәтеп кенә калмады, бәлки әле йөрәкләрдә ышаныч вә дәрт уятты—дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшыруга әйтеп бетергесез бер этәргеч булды.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң без кисәк кенә эшсез-шөгыльсез калдык. Югары уку йортына барып кергәләгәнче ике кулыбызга бер эш табасы, өс-башыбызны бераз юнәтәсе, рәткә китерәсе бар иде. Гәрчә аңа кадәрле үк һәммәбез дә балигъ булып алган булсак та, аттестатлар алу гүя безне иң әүвәл эшкә яраклы затлар итеп тануга тиңләде.

Бернинди кереме булмаган, берәүгә дә өмет багламаган егетләр биш-алты кеше

идек. Һөнәребез юк, аны аласы бар, бүген көн итүне кайгыртмыйча ярамый иде. Көчебезне сынап карарга ниятләдек.

Иртә таңнан безнең өйгә җыелу барыбыз өчен дә уңайлырак сыман тоелды: ул чагында халык, гомумән, бер тирәдәрәк яши, кара бөдрә чәчле дустым исә поезд белән килеп, Вахитов станцасында төшәргә күнеккән, Плөтәнгә җитүе бик ансат иде. Бакалтайдан башларга ниятләдек без тәүге хезмәт юлыбызны: ул чагында әле зур елга портын кору өчен проектлар да төзелмәгән булгандыр, шәһәрнең үзәгенә якынрак, һәм баржалар Усиядән битәр әнә шунда туктый иде.

Үзебезнең бригада исеменнән сөйләшүләр алып бару өчен әлеге дә баягы кара бөдрә чәчле мишәр егетен сайладык.

Конторларга ул гына кереп, эшнең күләмен һәм хакын килешеп, соңыннан әҗерен алып, кыскасы, бригадир булып ул гына йөрде. Беренче итеп үзебезгә әлерәк кенә килеп туктаган, тау хәтле утын төягән бәләкәйрәк сай баржаны бушату эшен ышаныл тапшырдылар. Безнең өчен арада бер иплесе һәм җиңеле әнә шул булгандыр, мөгаен. Буең озын, син безгә төяп торырсың, дип көлештеләр дә, мин инде метрлы коры бүрәнә кисентеләрен һәркайсының рюкзак сыман итеп бауларын иңнәренә кигән "мендәрләренә" салып җибәрергә тиеш идем. Авыр эшкә юньләп күнекмәгән егетләремнең дәрте сүрелә, адымнары торган саен акрыная барды. Шулай да сынатмадылар. Көндез кояш галәмәт кыздырган арада су коенып, аз-маз капкалап алдык. Ялга тугарылганнан соң кабат эшкә тотынулары җиңел түгел икән. Әмма без бирешмәдек, эңгер-меңгердә инде баржаның төбенә җитә яздык. Аскы рәткә иң саллы кисентеләр төшәлгән иде, егетләр аның һәркайсын өчәүләшеп күтәреп сала торган булды, без инде өчәүләшеп югарыга ташыдык.

Көне буе эшләгәнебез өчен бригадир контордан ярыйсы гына акча алып чыккач, ару-талуыбызны, тир-тузаныбызны Идел суына агызып җибәргәч, үзебезне Горькийның Челкашына тиңләп, күтәренке күңел белән таралыштык. Әмма икенче көнне челкашлар соңарыбрак җыелдылар да ул көнне шәһәр гизеп, бераз ял итеп алырга килештек. Эшләми эшләгән яшьләргә теге баржа авыргарак килде шул, үзен нык сиздерде, сөяк-саякларыбызны авырлык белән генә кыймылдата алырлык хәлгә төштек.

Тик инде челкаш дигән кушаматны акларга кирәк иде, һәм без баржа бушатырга көн саен йөрергә күнегеп киттек. Чыныгу алгач, бирешергә уйламадык та. Ул арада кояшта кызынып өлгердек. Гәрчә кояш һәммәбезгә үзенең нурларын тиң сипсә дә, арабызда Нариманның тәне тизрәк каралып өлгерде. Ә бер көнне иртән безгә конторда, баржа ике-өч сәгатьтән генә килеп җитә, дип хәбәр иттеләр. Инде нишләргә? Тәмәке тарту, аракы эчү, кәрт сугу ише нәрсәләр без яшь чагында әле модага кереп җитмәгән иде. Өйләребезгә таралышмыйча гына, яр буенда кызынып ятарга, су коенып алырга ниятләдек.

Унган Таһирыбыз сумкасына сабын белән мунчала да сала килгән икән, шундук Нариманның аркасын юарга тотынды, озак та узмады, кычкырып көләргә тотынды:

—Карагыз әле, карагыз, егетләр, безнең кояшта янган Челкашыбыз негр түгел икән ич!

Без дә алар ягына борылып карадык, безнең дә авызларыбыз ерылды. Нариман гына аптырашта калып, су уртасында басып тора бирде.

—Булмаса булган икән, син инде, Нариман, берочтан битеңне дә сабынлап юып ташла!—дибез.

Ул көнне безгә баржаның яртысын гына бушатырга туры килде: икенче яртысын карт грузчиклар алды, иртәдән бирле безнең белән бергә көттеләр, Идел өстеннән күзләрен дә алмыйча, махра көйрәттеләр. Берсе хәтта өстебезгә карап:

—И-и-и, бәхетсез оланнар... Тушы яшьтән имгәнәсез, биртеләсез бит, бичаралар...—дип, сакал-мыек баскан йөзен чытканы да күз алдымда.

Янә ике-өч көнебез эшсез үткән иде, һәркөн килеп йөргәч, күзенә чалынганбыздыр, мөгаен, конторның хисапчысы, чал мыеклы агай үзебезне аргы баштагы килбәтсез бер иске баржа янына иярте алып барды:

—Тик торганчы тун итәгең уа тор, дисәгез, оланнар, шушы Николай патша тагарагы төбендә бурсып яткан бүкәннәрне бераз кымшандырып карамыйсызмы, диюем. Бик авырлар икән, димәсәгез генә инде, хан заманыннан бирле ята-ята алар шактый акыл да, авырлык та җыйган булсалар кирәк. Мин үзегезне әйбәтләп

бәхилләтер идем, булдыра алсагыз, кәнишне...

Картлач сорауны барыбызга караган хәлдә бирсә дә, без бригадирга текәлдек. Ризалык бирергә яисә кире кагарга аның гына хакы бар иде. Мишәр егете, кәкре аякларын еш-еш алдырып, кай арада баржаның трюмына төшеп тә менде. Кыяфәте кырыс иде, җитди иде.

—Ярар соң, тырай тибүдән безгә сәмән килмәс!—диде һәм:—Аларны каярак өярбез икән соң?—дип картлачтан сорап куйды.

—Әнә шушы кашлакка чыгарып җиткерсәгез, хәйран кулай урын инде!

Һәркайсы метрдан кыскарак булса да, картлач әйтмешли, хан заманыннан бирле ята-ята, акыл җыеп кына калмаган, бәлки әле дым тартып, чиләнеп беткән, беләүгә әверелгән иде. Көч-хәл белән генә кымшандырып, үзләрен чыгарып бетергәләгәнче, тәмам хәлдән таеп, мәзәк сөйләшү түгел, кирәкле сүзебезне дә әйтә алмаслык хәлгә төштек.

Күтәрә алмастайны бездән күтәртергә алынып, бригадирыбыз хаталанды бугай. Чөнки нәкъ әнә шуннан соң челкашлар командасы таркалды. Гәрчә үзебезгә тияреннән артыгын түләсәләр дә, Корбангали белән Таһирҗаныбыз иртәгесен күренмәде. Бригадир үзе, гадәтенчә, таң тишегеннән килеп җитте, бераз көттереп булса да Нариман күренде.

Бакалтайда бүтән эш күренмәгәч, бераз иптәшләрне көткән арада киңәшләшеп алдык та, вагон-мазар төяргә яки бушатырга булмасмы дип, тимер юл вокзалына барып карарга ниятләдек. Юл уңаенда Таһирҗаннарга сугылган идек тә, ник килгәнебезгә үкендек: аның үги анасы, алпавыт бияседәй гәүдәсен биеткәләп алды да:

—Безнең улыбыз андый гына малга мохтаҗ түгел, үзегезгә булсын акчагыз!—дип, өеннән үк сөреп чыгарды.

Шуннан инде без, сөмсеребез коелып, Корбангалиләргә күренеп тормадык. Вокзалда безгә дигән эш табылмады. Яшькелт фуражкалы бер абзый, “Локомотив” ягына ымлап:

—Ул тирәдә тәгаен морадыгызга ирешерсез...—дисә дә, анда барган чагында Нариманыбыз нишләптер аксый башлады, арткарак калды. Без инде туктап-нитеп тормадык, үзара карашып алдык та җилле генә атлавыбызда булдык.

Анда безне гүя көтеп торганнар: шундук ташкүмер төягән иләмсез озын вагон янына алып бардылар да аны бушатырга куштылар, бәясен дә әйттеләр. Ул арада Нариманыбыз да килеп җитте, безнеке шикелле үк соскылы көрәкне алды да шыксыз вагонга озаклап карап торды. Алай гына торып арыгач, көрәгенә таянып, безнең ни рәвешле күмер бушатканыбызны, күмер тузанының авыл мунчасыннан чыккан төтен сыман мул булып кайсы тарафларга табан очканын шактый гына күзәтеп торганнан соң:

—Мин коенып менәм әле,—дигән булды, көрәген аяк астына ташлап, су буендагы әрәмәлеккә юнәлде.

Нариманның сызачагы безгә сер түгел иде.

Иләмсез зур вагонны бушатып, тал чыбыкларыннан үзебез ясаштырган себеркеләр белән себергәләп, җәяүләп турыдан гына безгә кайтып җиткәндә, төн иде инде. Ишекне Гаяз абый ачты. Без икенче катка менеп, утны яндыргач, шаркылдап көлеп җибәрде. Безнең аптырашып торганны күргәч:

—Әллә сез шәһәр мичләренең морҗаларын чистартып йөрдегезме? Шулчаклы каралырсыз икән! Юыныгыз тизрәк!—диде.

Шунда гына дустымның тешләре генә күренеп торганын абайлап алдым, абыйга кушылып көлә башладым. Минем кыяфәткә карап, дустым да елмаймыйча булдыра алмады.

Челкашлык эпопеясе әнә шулай тәмамланды бугай.

Янә дә бергә-бергә авыр эштә чыныгуыбыз университетның беренче курсыннан соң булды. Факультетның барлык студентын Биектау районындагы бер колхозга алагаем буа—плотина корырга җибәрделәр. Безнең группада кайберәүләр, сыныкка сылтау табып, андый авыр эшкә бармау ягын карадылар, тик инде без үзебез рәхәтләнеп бардык, иренмичә эшләдек. Туфракны бер урыннан көрәк белән казыйсы да, аны тачка яисә носилкага төяп, икенче җиргә өясе иде. Әһ тә итмәдек, ару-талуның ни икәнен дә белмәдек, кояшның эссесендә айга якын “кызынып” кара янып чыктык. Биш-ун минутлык ял вакытында исә бокс ярышлары уза, дөресрәге, минем дустым

дүртенче курсның төп шикелле таза бер студенты белән көннен-көнендә көч сынаша иде. Гаҗәпсенәм инде шуңа карап: ял да кирәкми аңа, чуртым да, эшнең һәрчак авыррагына алыныр, ал-ял белмәс, дәртләнеп эшләр, һәркайсыбызга үрнәк күрсәтер иде. Өстәвенә әле бокска, ягъни дөмбәсләшүгә, кул сугышына атлыгып торыр, анда да һич кимен куймас иде.

Шундагы уңганлыгыбыз ошады, ахры, икенче курс егетләре дустым белән икебезне, буа эше беткәч, урман эшенә дәштеләр. Без каршы килмәдек, вәгъдәләштек тә Арчадан ары Курса урманына юлландык.

Бишәү идек без. Тәҗрибәсе бар, усаллыгы да җитәрлек, дилбегәне кыска тотар дип, минем дусны бригадир иттеләр. Кайчан эшнең ниндиен башкарасы барын шундагы хуҗалар белән ул хәл кыла, эшнең ничә көнгә сузыласын үзе чамалый. Безгә кичтән шуны аңлатып куя да, иртә таңнан күмәкләшеп эшкә ябышабыз.

Катнаш урманга барып, анда икешәр метрлы бер чама киселгән бүрәнәләрне, машинага төяп чыгарырга якынрак булсын өчен, юл буена ташыйбыз. Ул машиналар тимер юл янына кайтаргач, бушатабыз. Вагонга төяр өчен җайлаштырып өябез. Вагоннарга төйибез, озатабыз. Санап кына бетереп буламыни урман хуҗалыгының эшләрен...

Мәгәр безнең тамак ягы хөрти иде. Шәһәрдән юлга чыкканда алып килгән ризыкларыбызны бетергәч, күрше авылга барып, он сатып алып кайтабыз да, шуны солдат котелогына салып боламык пешерәбез, Арчаның үзенә поезд белән барып, арыш ипие юнәтәбез. Беребезнең дә аш-су эшенә осталыгыбыз булмау бәласедер инде, югыйсә такы-токыга төшмәс идек...

Көне буе авыр эштә булып, юньләп сөйләшергә дә вакытыбыз калмый торган иде. Кичке аш вакытында минем дустым җәелеп китеп сайрарга гына тотына инде, ул арада егетләр кашыкларын котелок эчендә биетеп тә өлгерәләр. Тел бистәсе аңына килгәндә, котелокның төбе ялтырап күренә торган була иде. Хәер, тел бистәсе бер ул гына түгел, Риво да сайрарга ярата, алар бер-берсенә тиң иделәр. Тик инде арыганнан соң минем авыздан бер генә сүз дә тартып ала алмассың. Марсель дә тып-тын утыра. Ә менә Фрицебез хәйлә капчыгы булып чыкты. Бригадир сайраган арада, агач кашыгын ипле генә йөртеп, түбән караган көе, әледән-әле:

—Һе!.. Күр инде!.. Һе!..—дип кызыксынгандай кылангалап утыра.

Сөйләгәненне тыңламасалар, туктыйсың бит, ә монда сине, имештер, игътибар белән тыңлыйлар. Хәер, ике-өч тапкыр ач калганнан соң әүвәл Риво сайраудан туктады, аннары дустымның сүзе бетте. Ул да үзенең маҗараларын палаткага кереп сузылгач сөйли торган булды. Тик анда инде көне буе агач эшеннән арып-талып арынган егетләребез, печәннең хуш исләреннән исереп, шундук йокыга тала торган иде. Минем белән янәшә палаткага сыенып ятучы дустым да, сөйләүдән туктау белән, тетелеп йоклап китә иде.

Иртән җидедә уянып китсәм, ул инде коедан сулар алып кайткан, юынып, учак тергезгән, котелок белән чәйне кайнатып өлгергән була иде. Сугышлар беткәнгә дүрт-биш ел булса да, без әле урман хуҗалыгында икешәр клиндер белән чәй эчеп канәгатьләнергә тиеш идек.

Уңганлык барыбызда бер үк дәрәҗәдә булмагандыр инде булуын, төрлебез төрлечә эшләгәндер. Бригадир белән фәкать Риво гына ярышса ярыша алгандыр. Без Марсель белән күпме генә тырышсак та алардан калышканбыздыр. Ә инде Фрицебез тырышмый да, эленке-сәленке эшләүдән узмый. Бүрәнә янына икәүләшеп киләсең икән инде, ул сиңа юл бирә дә читкәрәк китеп, авызын ачып, синең нинди авырлык белән иңбашыңа алганны күзәтеп тора. Ичмасам, кымшанмый да, гүя авызы белән сиңа карый, авызын ачып әйләнә-тирәне караштыра.

Гаҗәеп хәл инде! Шушы Фрицнең атасы бер дигән балта остасы икән. Кулына үзе кайраган балтасын алса, өй җиһазлары ише теләсәң нәрсәне коеп кына куя икән. Хәтта әле балтасы белән малаена карандаш та очлап биргәләгән. Фрицнең булдыксызлыгын да, күбрәк бүтәннәрнең артына посып, алар эшләгәнне авызы белән карап торырга ятаруын да абайлап, башын селкеп үзенең гаҗәпсенүен белдергән һәм:

—Хәлеңнән әлләни килми, улым... Син инде минем һөнәрне дәвам иттерә алмассың... Һич югы тырышыбрак укы да галим-голәмә арасына үтеп керергә тырыш... Заманча яшә, камсамулына да кер, партиясенә дә... Берәр түрәнең кызына өйләнә алмассыңмы... Шулай гына биетә алыр идең һәмәкиен "әпипә"гә...—дип васыятен әйтеп калдырган, имеш.

—Шулай да ул синең намуслы булуыңны өметләнгәндер әле.

—?!.

Яхшыдан яман туган бәндә боларны безгә үзе сөйләде. Ихтимал, эшләгәндә тырышлык күрсәтмәвенә дәлил эзләгәндер әле. Тик инде иптәшләренең тырышуын күрү дә, бригадирның кырыслыгын, таләпчәнлеген тою да аның холкын һич үзгәртә алмады. Әллә бәлкем, үзгәртергә теләмәгәндер—белмәссең кешене, һич белмәссең...

Көннәрдән бер көнне безгә яңа кайтасы бүрәнәләрне иплерәк урнаштыру өчен бер өем ваграк агачларны—икешәр метрлы каен, усак, имән казык-кураларны ышыграк урынга күчерәсе булды. Үч иткәндәй, Риво яңа урын белән мәш килде. Марсель белән без икәү өемнең ике ягына чыктык та һәр усакны, каен, имәнне ике башыннан тотып, җилле генә күчерә башладык. Фрицебез бригадирга тап булган, шуның белән парлашып эшли башлаган. Без моның шулай икәнен мишәр егетенең яман каты кычкырып кызуларга кушуыннан аңыштык.

—Күрмисең мәллә машиналар кайтканын?!—дип өстәде бригадир.

Борылып карасак, ни күрик, урман авызыннан чыгып, ике машинабыз да тузан туздырып юл буйлап төшеп килә икән ләбаса!

Фриц кенә гүя берни күрмәде, берни ишетмәде, эленке-салынкы гына кыймылдап, бригадирны көттереп кенә, колгаларның икенче башына ябышты. Бу үле туган бәндәнең акрын кыймылдавына, күрәләтә ялкау сатуына, мөгаен, мишәр егетенең тәмам гайрәте чиккәндер. Менә ул ярыйсы ук саллы караманың авыр башыннан алды да парының килеп җиткәнен, кулына алганын көтә башлады, тегенең бер дә ашыкмаганын, уң аягын алганчы сул аягын эт ашаганын күреп торды да, мыжгырдавына тәмам сабыры текәнеп, кулындагы караманы гайрәтләнеп тә дәртләнеп югары күтәрде һәм тегенең өстенә тондырды.

Без өчебез дә, үтерә инде, дип ахылдап куйдык, әмма нәкъ шул мизгелдә Фрицнең житезлегенә хәйран калдык—ул ялт итеп артка чигенде һәм... исән калды. Безнең беребез бер сүз әйтмәде. Урман ягыннан ыжгырып кайткан машиналар гөрелтесе ишетелә, юл тузаны гаять югары күтәрелә иде. Бригадир янына Риво атылып килеп җитте, эшебез очлануга табан юлланды. Әлеге вакыйганы ахырдан да телгә алучы булмады.

Ай буе эшләгәннән соң, контордан престка тапшырасы кәгазьләрне алып, кичке якта эшебезне йомгакладык та иртәнге сигезләрдә үк поезд көтәргә кашсу җиргә чыгып утырдык. Ни хикмәттер, ике-өч малай безгә табан елышты. Бу татар малайларының яныбыздагы сумкаларга мыштым гына күз салгалауларыннан боларның кесә караклары икәнлегенә һичбер төрле шик-шөбһә дә калмады. Боларны дустым да "таныган" икән: менә ул, башын күтәрмичә генә:

—Болытлар куера...—дип куйды.

Мин моңа каршы:

—Бар шул болытлар, хәерлегә түгелдер,—дип җавап кайтардым.

Юлдашларыбыз, әлбәттә инде, Эзоп телен аңламады, алар гына түгел, бурлар үзләре дә башларын күтәреп күккә күз салдылар. Әллә Марсель инде, әллә икенче берәү, көлемсерәп:

—Шуны да болытка санасаң...—дип акыл сатарга уйлаган иде, бригадир дилбегәне кыска тотты:

—Яңгыр яуганнан соң башны ташка органчы, сакланыйк, егетләр, аң булыйк. Алыгыз сумкаларыгызны,—дип, урыныннан кузгалды. Без бераз ышыграк урын сайлагандай кыландык, юлдашларыбызның "байлыгына" елыша башлаган кәкре куллы малай-шалай авызын ачып, нәүмизләнеп калды.

Казанга кайткач, Зур Кызыл урамындагы ул трестны бик тиз таптык. Иркен ихатада дүртебез көтә калды, бригадирыбыз конторга юлланды. Ун-унбиш минуттан ул, авызы ерылып, уч тулы акча алып та чыкты. Җайлырак сумка өстенә салып, безнең алда санаганнан соң, бишкә бүлә башлады. Марселебез:

—Бригадирга күбрәк тиеш, һәммә җирдә шулай каралган, шундый гадәт,—дисә дә, минем дустым көлде генә:

—Без бишебез дә тиң эшләдек, тигез бүлү гадел булыр. Сезгә рәхмәт, егетләр, бигайбә!—дип алыш-бирешкә нокта куйды.

Университетны тәмамлар алдыннан бөтен группаны Дәрвишләр калавылына кунакка чакырды ул. Кызларны-малайларны җыеп алып килү бурычын, әлбәттә инде,

миңа йөкләде. Әлләни сый-нигъмәтләре булмаса да, ачык чырай—такта чәй дигәндәй, бигрәкләр инде менә күңелле булды. Катнаш урманга алып барды үзебезне, тирән чокырларны күрсәтте—анда йөгереп түбән төшүләр, өскә карап, тавыш бирүләр кызык тоелды; алып керде үзебезне каеннар арасына—куышып уйнап алдык. Май аенда табигать искиткеч ямьле бит ул, күрмәгән, сокланмаган җирләребез калмагандыр. Гаять күтәренке күңел белән җыйнаулашып кичке поездга төялешеп бик соң гына кайтып киттек.

Сабакташларыбызның һәркайсы бай холыклы, үзенчәлекле иде. Кызларыбыз да, егетләребез дә.

Әйтик, Рәсыйхыбызның тавышы гаҗәеп моңлы иде. Ул кинофильмнардан ишеткән теләсә нинди җырыңны отып алыр да зур мәшһүрлек казанган тенорларың сыман, тәмам җиренә җиткереп башкарыр иде. Тик инде аеруча яратып җырлаган җырлары Мөслимендә сабый чакларында ишеткән озын көйләр булгандыр. Аның тавышына үзебезнең әнә шул моңлы көйләр күбрәк килешә иде. Берәр җитди лекциядән соң, профессор чыгып киткәч, Рәсыйхыбыз җырлап җибәрсә—башларыбыз фәнни терминнардан арынып, күңелләребез җиңеләеп кала торган иде.

Икесе дә бер үк районда эшләгәч, әледән-әле очрашып торалар. Иң әүвәл күрешүләре бигрәк истәлекле була. Мишәрстанда үскән егетебезне үзенең Мөслименә кунакка алып китә җырчы егет. Хәер, ул вакытларга инде Рәсыйх башлы-күзле булган, хәтта ике-өч баласы да бар иде бугай. Бала-чагасы белән ул Иске Кәшергә барып урнашкан, хәзер ике тәгәрмәчле арба җигеп, сабакташын туган авылына алып кайтып, туган-тумачасы, әти-әниләре белән таныштырырга уйлаган.

Дустыбызның ихлас ачык күңелле әтиләре белән күрешеп өлгерер-өлгермәс, мишәр егете бу төбәктә халыкның гаять киң күңелле һәм җор телле икәнлегенә инана—Әкмәл абзый хәтәр җитди кыяфәткә кереп:

—Нишләрбез икән, карчык, башыбызга бәла төште бит әле—синең әнә теге чуар тавыгың әтәч булып кычкырды! Үз колагым белән ишеттем, әй!—дигән сүзләреннән аптырап кала.

Бу яклардагы халык теленең байлыгын әле юньләп абайламаган, сикәлтәле юлларына аңарчы юлыкмаган яшь укытучы, әлбәтә, мондый сәер сүзгә аптырап кала, фәкать Әкмәл абзыйның карасу-коңгырт күзләрендә очкынланган наянлыкны шәйләп алгач кына, аз-азлап гыйбарәнең серенә төшенә башлый. Бәрәч, шуннан башлана икән ләбаса Казаннан килгән кунакны сыйлау! Әнә шул "әтәч булып кычкырган" тавыкның ите ни дәрәҗәдә тәмле булгандыр, анысы инде еллар төпкеленә төшеп югалган, әмма авыл картының авызыннан ишетелгән сүз ихлас гыйбрәтле булган. Һәрхәлдә, әлеге сүзнең әйтелү рәвешен дә, аны әйткән чагында Әкмәл абзыйның чыраендагы хәйләкәр елмаюны да, карчыгының аптыраган бер самими кыяфәт белән бот чабып куюын да, "Инде ни хәлләр генә итәрбез икән инде, Ходаем?!" дигәнен дә ничекләр онытасың ди инде!

Ана теленең байлыгы нефть катламнарыннан да тирәндәрәк ятканын абайлау мишәр егете өчен зур сөенеч, олуг ачыш була—хикмәтле гыйбарәләрне өйрәнүләре нәкъ әнә шуннан башлана. Гомумән, Сарман-Мөслим төбәгенең халкы арада бер кече күңелле, гаҗәеп дәрәҗәдә самими, хәйләсез булып чыга, аның сөйләшү рәвеше дә, зирәклеге дә, тел байлыгы да читтән килгән яшь укытучыны хәйран калдыра.

Без Казанга күчкәч тә, ара-тирә очрашкаладык моңлы Рәсыйх белән. Юл чыгып, калага килә-нитә калса, безне күрмичә китми иде Мөслим егете. Иң әүвәл нәшриятка сугыла, бөдрә чәчле сабакташыбызга заманалар бозылганын сайрый, күңеленә тулган моң-зарын бушата.

Килеп керә бервакыт өсте-башы тузгыган хәлдә. Атна буена юынмаган, бик нык йончыган хәлдә. Аптырамас җиреңнән аптырарсың, мәктәп директорын шундый кыяфәттә күргәч. Мишәр егете, хафаланып, утырган җиреннән сикереп тора, кунакны иңнәреннән алып, утырта ипләп кенә каршысына.

—Йә, ниләр булды? Сөйләп җиппәр ашыкмыйча гына.

—Ашыгасы-нитәсе калмады, саубуллашырга килдем синең белән, бәхилләшергә... Атна-ун көннән килеп йөри алмам сезнең тирәләргә—рәшәткә артына кертеп утырталар үземне өч елга...

—Берәрсен чәнчеп үтердеңме, сугып имгәттеңме? Нинди зур гөнаһың бар закон алдында?

Җавапны тиз генә ишетә алмый мөхәррир кеше. Әмма ашыктырырга да уйламый.

Графиннан агызып, стакан белән кайнаган салкын су куя дустыбыз алдына. Шуны актык тамчысына хәтле эчеп бетергәч кенә, сүнгән күзләрендә очкыннар күренә, башын күтәреп, сөйләргә керешә Мөслим егете:

—Мәктәп бик искергән иде безнен. Төртсәң аварга тора иде. Әүвәл сипләтергә дип кенә килешкән идек, ләкин бит бабайлар, искегә тотынма, искегә тотынсан—исең китәр, дип бер дә белмичә генә әйтмәгәннәр. Бер очына тотынган идек озын бинаның аскы ниргәләрен алыштырырга дип, андагы хәлне күргәч, балта осталары башларын селкеп тордылар да, моны игә китереп булмый, диештеләр.

—Син директор гына бит, осталарга баш түгел. Йә, нишләттең инде үзләрен?

—Нишләтәсе юк аларны, балта-мазар ише нәрсәләрен култык асларына кыстырдылар да китеп бардылар.

—Сиңа нишләргә кала инде?

—Җыйдым педсовет. Авылдагылар барысы да килде, рәхмәт үзләренә, отпускада мин, диючесе булмады.

—Димәк, яраталар үзеңне, хөрмәт итәләр.

—Югыйсә бертавыштан карар да кабул итә алмас идек. Мәктәпкә яңа бина салырга килештек. Шул ук көнне кердем РОНОга.

Аңлатып бирдем нинди мөшкел хәлгә төшкәнебезне, күрсәттем үзләренә педсовет карарын. Яздырдылар зур итеп гариза. Бирергә булдылар күп итеп акча.

—Хәлеңә кергәннәр икән әле.

—Анысы шулай. Тик абзаң РОНОдан акча кайчанрак булыр икән, дип көтеп ятмады, урманнан озын-озын бүрәнәләр кайтартты.

—Үз кесәңнәнме инде анысы?

—Отпускнойлар да калмады, хатынның оланнарга өс-баш юнәтергә саклап торганнары да китеп барды. Аннары мәктәпкә РОНОның банктан күчерткәне ярап куйды тагы. Югыйсә минем кесәдә җилләр уйный башлаган иде инде...

—Үз акчаңны теләсәң ничек тота аласың да бит, дәүләтнеке һәммәсе дә исәптә. Аның белән шаярырга ярамый. Отчет бирәсең бар, кая күпме тотканыңа кәгазь кирәк, справка!

—Бәй, ник син боларны башта ук әйтмәдең?

—Күрешмәдек бит, дустым, икебезнең дә, имештер, эше күп... эшем кешеләре, янәсе!

—Мәктәпне ай ярым эчендә салып бетерәбез дигәндә, РОНО миннән кәгазьләр даулый башламасынмы! Каян алыйм ди мин ришвәт биреп кайтарткан бүрәнәләр өчен справка? Кәгазь кирәк дисәң, әүвәл планга керттерәсе, аннары ул планнарны раслатасы, ким дигәндә ике-өч ел көтәсе бар бит. Ә миңа бүрәнәсе, башкасы менә бүген кирәк иде, бүген!

—Әйе, капкансың икән...

—Җитмәсә бит әле мәктәпнең бухгалтерына да әйтеп куйганнар, справкасыз бер тиен бирәсең икән, үзең җаваплы буласың, дигәннәр.

—Ул исәп-хисап эшендәгеләр безнең шикелле кабаланмый инде, анысы хак.

—Үземдә укыган кыз бала эшли бухгалтер булып. Абый, сиңа менә җаным да жәл түгел, акча гына сорама, ди, күзе тулы яшь. Үскәнем, миңа бит синең җаның кирәкми, акча кирәк, дим. Шуннан киңәшләшә бу үзенең РОНОдагы хуҗалары белән. Кәгазе булмаса, икенче имза куйдыр директорыңнан, дип акыл өйрәткәннәр үзенә.

—Син куйдыңмы?

—Ике атнадан яңа уку елы башлана, минем әле бетерәсе эшләр муеннан...

—Ишкәнсең икән ишәк чумарын!

—Шулай килеп чыккан шул, дускай. Тик менә беренче сентябрьгә хәтле мәктәпнең түбәләрен яшелгә буятып, ишекләрен киң итеп ачып каршыладык балаларны. Хәзер инде үләргә дә әзер, өч ел утырырга да... Мин ул сабыйларның күзләрендә куаныч нурлары күрдем!..

—Анысын очлап чыккансың, мә бишне, молодца Прошка! Андый да зур бәхет һәркемгә тәтеми, анысы хак, сүз дә юк. Тик менә хөкем итүчеләргә шуны төшендереп бирә алмагансың, шунысы аяныч...

—Ике дә сөйләшмиләр анда. Педсовет карарларын "филькина грамота" гына диләр.

—Син бераз утырып тор, дустым. Киңәшләшеп керим әле телефоннан.

Мөхәррир бик тиз әйләнеп керә. Ишектән үк:

—Дөнья кысыр түгел бит,—дип, сөйләшкән сүзләрен аңлата башлый.—Берәр сәгатьтән шул эшләрне бик яхшы белүче игелекле абзый киләсе. Бөтен кәгазьләреңне алып калырга кушты. Нәтиҗәсен иртәгә белербез.

Икенче көнне кичке якта Рәсыйхыбыз, адәм кыяфәтенә кереп, үзе фатир төшкән кардәш тутасын да ияртеп, балкып та нурланып килеп керә мишәр егетенең өенә. Керә-керешкә үк тезеп китә үзенең сөенечен:

—Кассациягә бер атна вакыт бар иде әле. Бик тиз тоттылар. Синең аркада инде, югыйсә, мин кемгә кирәк?—дип сөйләргә тотына.

—Бер дә алай түгел. Гаиләңә кирәк син үзеңнең. Яшь буынга шулай ук кирәгең зур. Аларны синең белән без кайгыртмасак, тагын кемнәр кайгыртыр?! Йә, нәтиҗәсе ниндирәк инде?

—Шартлы рәвештә ике ел итеп калдырдылар. Анысы авырга килми аның.

Хуҗабикә, елмаеп та балкып, ул арада табын хәстәрли. Иркенләп бер сайрашып, хуҗаның затлы коньягы белән сыйланып утыралар. Кунак ханым гына әледән-әле:

—Әйттем мин Рәсыйхка, ичмаса алыйк берәр күчтәнәч, дидем. Үзеңә шундый зур яхшылык эшләгән кешегә буш кулыңны селкеп кил дә сыйланып утыр имеш инде...—дип ризасызлыгын белдергәч, Рәсыйх, көлеп:

—Син бит хуҗаның холкын белмисең. Шешә күтәреп килгәнеңне күрсә, икенче каттан тәрәзәдән атар үзеңне,—дип төшендереп бирә.

Кызганыч ки, Рәсыйхыбызның дуамаллыгы, башбаштаклыгы еллар үтү белән дә һич кимеми, шуның нәтиҗәсендә киң күңелле дустыбызның язмышкае бик тә инде аянычлы рәвештә очлана...

Сарманның халкы әдәпле дә чибәр бит аның. Казаннан килгән яшь укытучы белән һәркайсы исәнләшә. Әүвәл бу хәлгә аптырап кала егетебез, әмма тора-бара аңлый башлый. Гәрчә ул үзе беркемне диярлек танымаса да, авыл халкы аның урыс теле укытырга, балаларга белем бирергә килгәнлеген белә, әнә шуңа күрә сәламли, хөрмәт итә.

2 сентябрь көнне дәресләр беткәч, мәктәпнең капка төбендә яшь укытучыны атылып торган кара күзле, каратут кырыс чырайлы, кабарынкырак иренле, төз гәүдәле, ир-ат кулыдай нык куллы бер апа килеп сәламли, хәтта әле кул күрешә:

—Бер дә гаҗәпсенмәгез, мин Хәниф Хәйруллинның әнисе булам,—ди бу.

Шунда гына яшь укытучының йөзенә елмаю чыга. Университетка бездән бераз соңрак кергән Хәнифнең егетләр өчен артыграк нәфис вә чибәр булуы тулаем әнисеннән икәнне шәйли.

—Үшән директорыгыз фатирга үзегезне крәстиән йортына урнаштырганны ишетеп килдем. Анда халык мыжлый ич, анда ничек яшәсен укытучылар? Әйдәгез фатирга үзебезгә! Хәнифем белән Фаязым урынына булырсыз.

Хикмәт шунда ки, Алабуга педагогия институтында белем алган физика укытучысы белән әдәбият укытучысын фатирга крәстиән йортына урнаштырган булалар. Гади халык белән аралашу күзлегеннән чыгып караганда, бик өметле урын булса да, укытучылар өчен әлләни кулай түгел: көне-төне юлчылар килеп-китеп йөриләр, шунда тамак туйдыралар, кычкырып сөйләшәләр... Анда син дәрескә әзерләнү дигән нәмәкәйне бөтенләй башыңа да китермә, ярый әле шунда бераз черем итәргә җайлаша алсаң...

Яшь укытучыларның кайда яшәп ятканын ишеткәч, үткен холыклы, гаять чая Җамал апа аларны үзләренә алырга килә. Тәвәккәл вә кырыс ханым, аларның ай-ваена карамыйча, шундук өенә алып та кайта.

Җамал апаның әнисе—үзе бер тарих икән. Яшьлегендә урыс алпавыты утарында эшләп бөкересен чыгарган. Октябрьдән соң утарга күрше авыллар халкы ябырылып, канэчкеч байның барлык милкен талаганда, янып яткан араннан котлары алынган мал-туарны чыгара, иләмсез дәү айгырның башына нукта салып, җитәкләп кенә авылына алып кайта. Матур гына эшләп көн күрә, әлбәттә, бала-чагасын тәрбияләп үстерә. Имештер, берзаман сорыйлар моңардан күршеләре:

—Әби, сызгыра беләсеңме?—диләр икән.

—Минем инде тешләрем дә төшеп беткән, ничек итеп сызгырыйм?—ди икән.

—Әби, Җамалың Гыйздуллага ябышып чыкты бит, әле генә инеш буйлап элдерттеләр,—дигәнне ишеткәч, әбкәй, имештер, сызгырып җибәргән икән.

Хәзер әнә шул әбкәйнең чәйне шикәр урынына суган кабып эчүенә дә, бүтән төрле гадәтләренә дә сәерсенеп, уңган-булганлыгына, чаялыгына, холкының ясалма усал, чынында исә мәрхәмәтле-шәфкатьле булуына сокланып бетә алмыйлар яшь укытучылар. Әнә шул уңган хуҗабикәләр пешергән ашларны мактап-мактап ашыйлар, сөйләгән мәзәк вә гыйбрәтле хәлләрне кәгазьгә теркиләр.

Әле ярый университетка юлыкканбыз. Шуның өчен Ибраһим Нуруллин белән Рашат Гайнановка мең рәхмәт. Уникенче мәктәпкә килеп, сораштыра торгач, әдәбиятны ихлас яратучы егетләрне эзләп тапканнар, безне үгетләделәр. Йөзләренә кызыллык китермәдек инде болай үзе, китермәдек. Биш ел буена бихисап фәнне өйрәндек тә кемнәр белән генә аралашмадык, тау хәтле китап укымадык...

Әнә шул укыганда файдасы тиеп куя ул филология белеменең. Бүтәннәр әсәрнең эчтәлегенә мөкиббән киткән чакта, син авторның тел байлыгына, язу рәвешенә, гуманистлыгына сокланасың, лаеклы бәяңне бирәсең. Акны карадан аера белү, гүзәллекне тану-соклану меңләгән укучыга дөрес юнәлеш бирү, әдәбият вә сәнгатьнең гыйбрәт икәнен сиздерү генә дә түгел бит әле, үзеңә ләззәт алу, рухи байлык өстәү дә бит әле. Ничектер яшәве рәхәт булып китә, әйләнә-тирәңә күңел күзе белән карарга, ямьлегә сөенә белергә өйрәнәсең, тәңкә вә тиен артыннан куучы карьеристлардан көлеп, читкә тайпылып, мохтаҗларга кадәри хәл булышасың, ярдәм кулы сузасың.

Сугыштан соң узган биш-ун ел эчендә милли мәктәпләрнең хәле үзгәрде, әйбәтләнде, дип әйтү көндәлек тормышка, чынбарлыкка күз йому булыр иде. Әйе, әзме-күпме үзгәреш сизелде, әмма ул үзгәреш милли мәдәниятләрнең хәлен әйбәтләндерү юнәлешендә түгел, бәлки әле югарыдан басым ясап, ул басымны елдан-ел көчәйтү һәм барысын да бер калыпка сыйдыру юлында эшләнде. Татар халкының башына төшкән бәлане, гадәттә, Сталинга сылыйлар. Дөрес анысы, юлбашчы булсаң, халкың мәнфәгатен кайгыртып гомер ит. Ә инде үз халкыңа террор оештыру—иң зур вәхшилектер. Явыз Иван белән Петр патша үзләренең варисларын юк итүгә барып житкәннәр, анысы шулай. Монда бит заманалар үзгәргән, халыклар дуслыгы игълан ителгән, идеология әнә шул юнәлештә чәчәк ата. Нигә кирәк булды икән илдә бер генә милләтне үсендереп, бүтәннәрне рәнҗетү вә кимсетү?

Миңа утыз елдан артык мәгариф өлкәсендә казганырга туры килде—“Совет мәктәбе” (“Мәгариф”) журналын чыгаруда хәлдән килгәнчә эшләдем. Ошбу өлкәдәге хәлләрнең торышы, андагы “яхшы якка” үзгәрүләр һәммәсе минем күз алдымда барды—йөрәгемнән каннар саудырды...

Ленин бабай заманыннан ук башланган урыслаштыру, бүтән милләтләрнең—“вак халыкларның” мәнфәгатен кыса бару Сталин заманында да туктамады, ул үлгәч тә дәвам итте. Әле көчәя төште, дияр идем...

Иң аянычы шунда ки, зур гына урында утыручы үзебезнең татар агайлары, креслоларын саклап калу бәрабәренә, милли мәктәпләрне берәм-берәм бетерү юлына бастылар. Мәскәү, гомумән, сатлык ханнарны да, сатлык җаннарны да үсендерде—мактаулы исемнәр, орденнар бирде. Һәм шулар кулы белән милләтебезне тәмам буып үтерүгә өмет баглады. Димәк, сугыштан соңгы елларда, ярты гасыр буена, татар агайлары, милли мәдәниятебез намена, халыкның киләчәген сатып, олы урыннар яуладылар, зур-зур дәрәҗәләргә ирештеләр.

Шул ук вакытта совет идеологиясе халыкның күзен буяу галәмәтен хәйран оста үткәрә иде. Милли мәдәниятне үстерү лозунгысы нигезендә, кайчандыр шәрык факультетлары гөрләп торган Казан университетында... татар теле һәм әдәбияты кафедрасы оеша. Гәрчә түрәләр моны күз буяу максаты белән генә эшләсәләр дә, андагы укытучыларны гына түгел, бәлки әле студентларның да һәркайсын бик нык күзәтү астына алсалар да, “ЧП”лар оештыргаласалар да, кафедраның активлыгын сүндерү-сүрелдерү аларга насыйп булмый.

Соңыннан мәгълүм булды: татар бүлегендә укучы һәр студент, һәр “милләтче” катгый күзәтү астына алынган, һәр курста үз әләкчеләре “укыган”, провокация оештырып, берниндн гонаһлары булмаган талантлы яшьләрне репрессияләүгә чаклы барып житәләр.

Аптырагач-йөдәгәч, әлеге кафедраны ачып хаталануларын аңлагач, шаулап барган поездны кирегә борырга, ягъни иплә генә эшләп килгән кафедраны ябарга карар кабул итәләр. Дәлилләре чынбарлыкка туры да килә бит, әй! Мәктәпләрдә (ил күләмендә!) татар теле һәм әдәбияты бик аз укытыла, андый мәктәпләрдә ана теле укытучыларын

Казанның педагогия институты әзерләп чыгара, шулар бик җиткән, Казан университеты укытып чыгарган татар теле һәм әдәбияты белгечләренең кирәге юк, аларны эш белән тәэмин итү мөмкин түгел!

Университеттагы татар теле һәм әдәбияты кафедрасын ябарга җыеналар икән, диган хәбәрне ишеткәч, шунда укып чыккан журналистлар генераль сәркәтипкә хат язалар, ул хатка тәмам җиренә җиткереп, исем-фамилияләрен дә яздырып, куллар куйдыралар.

Яңа патшага ышану гадәте без туганчы туган шул, каныбызга сеңгән. Явызлыкны үлгән патшага оста гына сылагач, яңасы илдәге халыкларга иминлек китерердер, дип өметләнәләр. Мәскәүнең вак-төяк чиновнигы ул хатны Татарстанның өлкә комитетына җибәрә—башбаштаклыкка юл куймаска әмер бирә. Тикшерүне бер түрәгә тапшыралар. Кул куючылар 28 кеше булып чыга. Аларның барчасын теге түрә үзенең иркен кабинетына җыйдыра, милләтпәрвәр булып кылана, бернинди шикләнү-сагаюга урын калдырмый: әңгәмәне саф татарча алып барырга тәкъдим итә; стенографистка-мазар чакыртуның, беркетмә-фәлән алып баруның кирәге юклыгын, гап-гади сөйләшеп утыру икәнен төшендереп бирә; фәкать чыгыш ясар алдыннан һәркем үзенең исем-фамилиясен, кайда кем булып эшләгәнен тулысынча һәм аерымачык итеп әйтергә тиешлеген искәртә. Безнең халык техникадан ерак бит, боларның барысы да тасмага яздыру өчен түгел микән, дип берәү дә шикләнми. Сайрапмы-сайрый халык, университетның кафедрасын яклау белән генә дә чикләнми, бәлки әле һәркем үзен борчыган мәдәният мәсьәләләрен дә хәл итеп булмасмы, дип өметләр баглый...

Мин үзем әле Казанга кайтып җитмәгән идем, ә дустым, әлбәттә, әнә шул "егерме сигез комиссар" исемлегенә эләгә. Фәкать хатыны бервакыт пропагандистлар җыенынннан бик нык дулкынланып кайткач:

—Казанда милләтчеләрнең яңа төркеме астыртын эшләр алып бара икән! Безгә аларның үз авызларыннан чыккан сүзләрне укып күрсәттеләр! Шаклар катарсың! Милләтчеләр...—дип сайраганны ишеткәч кенә, тупас рәвештә:

—Бик белеп тор син, коммунист-пропагандист, "илгә зыян китерергә әзерләнгән" әлеге егерме сигез милләтче арасында синең ирең дә ба-а-ар!—дип бүлдерергә мәҗбүр була.

Яздырып алулары тарих өчен кирәк булгандыр инде. Мәгәр яшьлек дәрте белән янган шул "егерме сигез комиссарның" ул талпынуы уңай нәтиҗә бирә бит, әй, кафедра ябылмый кала, үскәннән-үсә бара, әүвәл икегә бүленә, тора-бара факультетка әверелә. Милли мәктәпләрне бетерү юлын куганда, татар теле дәресен атнага бер генә калдыргач, татар теле укытучылары чынлап та кирәкми—һәр мәктәпкә бер укытучы бик җиткән. Урысчаны әйбәтрәк белгән студентларны урыс телен һәм әдәбиятын укытырга җибәрү фикере кулай табыла.

Кемне кая эшкә җибәрү мәсьәләсе хәл ителә торган көн. Дустым күренми дә күренми. Нишләптер минем янга да сугылмады, университетка да һаман килми. Иртә таңнан күренмәгәч, кызларыбыз аны, өйләнеп йөри икән, дип чыгарган. Барысы да ышангач, бу фикергә мин дә каршы берни әйтмәдем: кызлар халкына килешә ул көнләшү.

Коридорның аргы башыннан чайкала-чайкала салмак адымнар белән килүен күргәч, каршысына ашыктым. Сүзем ике булды:

—Хәзер син комиссиягә керәсең. Мин кереп чыктым инде. Ворошилов районына укытучы кирәк иде, шуны алдым. Ник дисәң, узган ел абый шунда бер ай эшләп кайткан иде, халкы бик әйбәт, дип сөйләгән иде. Сиңа Сарман районында урын бар, шуны алырсың. Күршеләр алар, якын гына. Монда кызлар сине, өйләнеп йөрисең, дип чыгарганнар. Котласалар—аптырап калма бер дә, рәхмәт әйтергә онытма үзләренә.

Дустым сынатмады: иптәшләрнең тәбрикләп кулын кысуга рәхмәтләрен тезде, эшкә Сарман районының Иске Кәшер урта мәктәбенә барырга ризалык биреп чыкты. Ахырдан кызлар сөйләделәр: аңа Казанның беренче мәктәбен дә, Татарстан һәм Башкортстанның тимер юлчылары балаларын укытуны да тәкъдим итеп караганнар, тимер юлчыларда хезмәт хакы артыграк, дип тә кызыктырмакчы булганнар—ул сүзеннән кайтмаган, нефть чыга торган төбәктә эшләргә нияте барын белдергән.

Икенче көнне иртә таңнан Рәсыйх Кәшапов эзләп тапты үзебезне. Гадәттә елмаймыйча сөйләшә алмаган дустыбыз борчулы, җитди иде.

—Кичә кич, үзебезнең Мөслимгә якынрак эш юк микән, дип министерствога барып

белешкән идем. Сарманның үзендәге мәктәпнең урыс классларына әдәбият укытучысы бик кирәк икән. Мин анысына ук тәвәккәлләмәдем. Синең урысчаң яхшырак бит, ал син шул Сарманның үзен, Иске Кәшереңдә тоташы белән татар мәктәбе, анда урыс телен мин укытыр идем.

Дустымның бер бик әйбәт үзенчәлекле ягы бар: ашыгып эшләү, гомумән, аның холкына хас күренеш булмаса да, гәрчә һәр эшен җиренә җиткереп, печеп эшләргә яратса да, берәр төрле кискенрәк карар кабул итәргә аны куш: сорауны ишетеп бетергәндә—аның инде җавабы әзер дигән сүз. Гази Кашшаф үзен "Совет әдәбияты" журналына эшкә чакырганда шул ук мизгелдә тәкъдимне кире какса, хәзер менә сабакташыбыз Кәшапов туган авылына якынрак эшкә кайту җае чыгып торуын әйткәч, ике дә уйламады:

—Ничегрәк җайларбыз икән соң аны?—дип үзе үк сорау куйды.

Рәсыйхыбызның ярыйсы ук зур авызы шунда гына җәелде:

—Син риза булсаң, барабыз да хәзер үк министерствога, анда хәлне беләләр, кичә мин аларга аңлаткан идем, бүген ул кәгазьләрне үзгәртеп язарлар, бездән кул кына куйдырталар да юлламаларны биреп үк җибәрәләр.

Мин дә сүзсез калмадым:

—Алайса без бер тирәдә өчәү булабыз!—дидем.

Янибызга Бах килеп ята иде, Касыймов Эдуард:

—Ялгышасың, без анда дүртәү булып квартет оештырабыз,—диде.

Яшь һөнәрмәннәр булып мәктәпкә эшкә барабыз бит инде, укучылар алдына затлырак киенеп бару кирәктер дип, юллык сәмәннән икебез дә ательеда соры костюм тектердек, аңа университет значогын тагып җибәрдек. Факультетның чыгарылыш кичәсен "Татарстан" (хәзерге "Совет") ресторанында уздырдык. Шунда минем җан дустым аз-маз коньяктан авыз итте. Аңарчы төрле мәҗлесләрдә эчерергә тырышып кыстасалар: минем норманы әтием эчеп бетергән, дип, университетны тәмамлаганчы авызына сыра да капканы булмады. Хәер, аннан соңгы 40-50 ел эчендә чак-чак эчсә дә, шактый ук шешәнең башына җиткәндер инде үзе...

Эшкә без уку елы башланыр алдыннан гына барырга булдык. Чаллыга кадәр пароходка алдан ук билетлар алып куйган идек, Усиянең челкашларга яхшы таныш сукмакларыннан багажларыбызны мең бәла белән ташыдык. Икебездә дә иң зур йөк китап тутырылган әрҗәләр булгандыр, центнердан артып киткәч, сездерә инде ул егет чагында да, штангист булсаң да. Әдәбиятның теориясенә багышланган, классикларның иҗатын яктырткан китапларны да алмасаң, авылданиләр генә кыла алырсың икән? Ә безнең ниятебез авыл малайларына, авыл кызларына тотрыклы, ныклы белем бирү иде. Яшь идек без, белемле идек, дөньяны үзгәртеп корырга җыенмасак та, вакыт вә көчебезне җәлләмичә хезмәткә чумарга әзер идек.

Чаллының текә ярыннан да әрҗәләрне үзебез менгездек. Ул чагында автобусмазар йөрми иде әле, йөк машиналарына утырып барырга иде исәп. Сарманнан элеваторга ашлык китергән машинаны табып, дустымны шуңа утыртып җибәрдем. Теләнче Тамактан машиналар иртәнге якта гына булган да кичен килмиләр икән.

—Монда турыдан гына менәсе, хәзер илтеп куя үзеңне,—дип мине атка утырып барырга күндерделәр, әйберләремне арбага салырга булыштылар.

Җирән сакаллы авыл агаеның хикәятен тыңлый-тыңлый, дыңгырдавык юлдан бара торгач, Теләнче Тамагына җиткәнемне сизми дә калдым. Авыл уртасында горурланып утырган мәктәп бинасына китереп җиткергәч, мин агайны бәхилләттем, рәхмәтләр әйтеп, шунда төшеп калдым. Ул кичне мәктәптә генә бераз черем итеп алу белән канәгатьләнергә туры килде.

Авыл җирендә хәбәр бик тиз йөри бит ул: яңа укытучының ат белән килүе чыбыксыз телефоннан кай арада таралып өлгергән дә, сәгать җидедә үк директор ханым мәктәпкә килеп тә җитте, мине кабинетына чакырды. Кырык-илле тирәсендәге хуҗабикә үзен гаять җитди тотарга тырышты: кәгазьләрем аны, мөгаен, күбрәк кызыксындыргандыр, чөнки минем юл мәшәкатьләрен ничегрәк кичерүем, хәлəхвәлем рәсми танышу кысаларына керми иде, һәм ул андый вак-төяк белән кызыксынып тормады.

Мине үземнән ике-өч кенә яшь олырак Володя исемле, сары чәчле, ачык чырайлы егет янына, сыер савучы бер апа йортындагы бәләкәй генә бүлмәгә өйдәш итеп урнаштырдылар. Мәктәптән ерак түгел, дәрескә йөрүе хәйран җайлы булачак иде.

Беренче якшәмбедә үк дустым минем хәлне белергә дип киләсе иде, иртәдән бирле шуны көтәсе булдым. Район үзәгендә тиз генә таба алмавы бар, эзләп йөрмәгәе дип, олы юлга чыгып каршыламак булдым. Володя белән бергә-бергә сөйләшеп әрле-бирле ике-өч сәгать йөргәннән соң, берәр ашыгыч эш тоткарлагандыр инде, дип, кәефем кырылып кына, кайтырга дип борылган гына идем, дустым, авызын ерып, Теләнче Тамак ягыннан үзе килә түгелме соң?!

Аны күргәч, тәмам аптырап калдым. Шулай да Володяның, нишләп йөрсен ул бердән-бер ял көнендә ял итмичә, дип шик белдерүе расланмавына сөенеп бетә алмадым. Дуслыгыбызның ныклы булуы эшли башлавыбызның беренче атнасында ук расланды. Иске дустымны яңасы белән дә таныштыргач:

—Әйт дөресен, самолет белән күктән килеп төштеңме, әллә инде күз буып, янибыздан күренмичә узып киттеңме?—дип бәйләндем.

Дустым беркайчан да сорауга җавапны шундук бирергә ашыкмый, үзе әйтмешли, прелюдиядән соң гына син көткән җавапны ярып сала. Бу юлы да ерактан алдырып кына кирәген әйтер булды:

—Минем Чынлыдан Казанга килгән туган-тумача Дәрвишләр калавылына Арча поезды йөргәнне белә, көне буе шул поездны көтсә-көтә, шуңа утырып кына килә. Арча кырыннан ат юлы барын белми дә, белергә дә теләми. Безнең баракны да ул фәкать станцадан гына таба ала...—диде, әмма без көткән җавапны бирергә ашыкмады.

—Синең барагыңның Сарманга нинди катнашы бар соң?—дип үземә кирәкле җавапны тизрәк ишетәсем килгәнне сиздердем.

—Мин бит әле, сезнең кебек, урыс теле укытучысы гына түгел, мин бит әле мишәр егете дә. Володяга аңлаешлырак булсын өчен, төшендереп бирим: яһүд сымаграк хәйлә капчыгы була бу абзагыз. Сарманда фатир хуҗаларымнан сораштыруны кулай санап, Теләнче Тамагына каян нинди юллар барын белештем. Олы юлга чыкмыйча, Нөркәй аша суктырсаң, биш-ун чакрымга якынрак икән ләбаса! Әнә шул туры юлдан элдерттем генә. Килеп төшсәм—сез мине олы юлдан көтәсез, имеш. Ул юлдан, боерган булса, машина алып җибәргәч, йөрербез. Хәзергә әле тәпи-тәпи, якынрак юлдан суктырабыз аны.

Беренче якшәмбедә минем янга килеп кенә калмаган бу тынгысыз җан, уку елын, хезмәт юлын башлап җибәргән көндә үк Иске Кәшергә җәяү барып, дустыбыз Рәсыйхны тәбрикләп кайткан. Яңгырга эләгеп, өсте-башы манма су булган.

Гәрчә Рәсыйхның карчыгы Флера, безнең өчен генә йөрмәс иде, Казан кызын күрергә килгәндер әле, дип акыл сатса да, ялгыша ул, дуслыкның кадерен белеп җиткерми, аның хатын-кыздан өстенрәк йөргәнен дә шәйләми, уртак дустыбызның холкын аңламый, үзләре өчен җан атып йөргәнен һич кенә дә күз алдына китерә алмый. Һәркемне үз бизмәненә салып үлчәү җиңеллеккә җиңел дә бит, дөреслеккә тәңгәл килмәве бар...

Әнә шул рәвешле без әледән-әле күрешә торган булдык. Йә ул килә, йә мин барам. Әйтик менә, Октябрь бәйрәменә мин барып чыгарга вәгъдә биргән идем. Дустым өйдәштә яшәгән йортта уздырырга килешкәннәр бәйрәмне. Яшь укытучылар җыелып та өлгергән, мине көтмәскә тәкъдим итеп караганнар:

—Мондый ачы җилдә, коеп яңгыр яуганда ничек килсен инде ул?!—дигәннәр.

Мишәр егетенең сүзе бер генә икән:

—Яңгыр түгел, ник шунда кар ямый, кар гына түгел, ник шунда таш ямый—дустым барыбер килмичә калмый!..

Сарманга җил-җил атлап, плащ чабуларын җилфердәтеп, мин барып җиткәндә, кунакларын иярттеп, дустым каршыларга чыккан иде инде. Колачын киң җәеп, үземне кочаклап алды.

Уникенче мәктәптә ачлы-туклы, интегеп укып йөрүләребез дә, чал университетка кереп, белем эстәвебез дә, авыл җирендә балалар укытуыбыз да, Казанга кайткач матбугат өлкәсендә чиләнүебез дә, иҗади казгануыбыз да, башлы-күзле булгач гаиләдә кичергән чатаклыкларыбыз да, кайгы-хәсрәтебез, куаныч-шатлыгыбыз да—һәммәкие бергә узды, әлхамделилла, гомер буе дуслыгыбызга көя төшмәде.

Сарманга барып төшкән кояшлы бер җәйге көндә очрата ул Вераны. Тарих фәнен укытырга җибәргәннәр икән үзен, юрфакны тәмамлаганнан соң... Зифа буйлы, чандыр гәүдәле, сап-сары чәчле, күгелҗемрәк соры күзле, үтәли күрүчән карашлы. Садә елмаеп, үзенең исемен әйтеп, сузган кулы егетнең игътибарын аеруча җәлеп итә.

гаҗәеп нәфис бармаклары аның холкы тугрылыклы, гадел һәм кешелекле икәнлеген раслый.

Сарман урта мәктәбендә урысы-татары бергә укый. Өр-яңа соры костюмының күкрәгенә университет значогы тагып килгән яшь укытучыга, әлбәттә, эшнең саллырагын—урысча укучыларның сигезенче-унынчы сыйныфларында урыс әдәбиятын алып бару вазифасын йөклиләр. Әлеге сыйныфларга белем бирүче яшь укытучылар ничектер аның белән бик теләп аралаша, дәртләнеп эшләүче бөдрә чәчле, эчкерсез, киң күңелле егет тирәсенә туплана. Озак еллар буе шунда укыткан һәм район үзгендә тупләнгән укытучылар, әлбәттә инде, пенсиягә хәтле бер урында эшләү ягын кайгырталар һәм директорның сүзеннән чыкмыйлар. Ул исә үзенең акыл шәрифләре, холык-фигыле мөмкинлекләреннән чыгып, хан ук булмаса да, үзен хуҗа итеп күрсәтергә тырыша икән. Сарман төбәгендә нефть күренми иде әле. Бертөрле эш тә юк. Газета редакциясендә дә нибары биш-алты бөртек кеше эшли. РОНОда үз штаты. Мәктәп берәү генә. Үзсүзле директорның көен көйләми хәлең юк: моннан да кусалар—кая барырсың, нинди эш табарсың?! Һәркайсының йорт-җире шунда, балачаганы ачтан үтермәссең ич инде! Сарманга беренче тапкыр аяк баскан укытучылар үзләрен бик иркен тоталар да бит... Алар чанасына утырып, дәреслекне эзли башласаң, көләрләр үзеңнән: атның азгыны тайга ияре, диярләр. Пенсиягә дә күп калмады, түзәргә кирәк, язмыштан узмыш юк...

Читтән килгән һәм ике-өч елдан китү ягын караган яшьләр исә мондый хәлгә көлемсерәп карыйлар, гаделлекне яклап теләсәң кем белән бәхәсләшергә риза иделәр. Үз фәннәрен әйбәт үзләштергән, дәртләнеп эшкә керешкән яшьләр дәресләрен мөмкин кадәр кызыклырак итәргә, яшь буынга тирәнрәк белем бирергә омтылалар.

Мәктәптә хөкем сөргән гаделсезлекне яшьләр педсовет җыен-утырышларында турыдан-туры тәнкыйтьли башлагач, директорның "ә" дигәненә "җә" дип кенә торырга күнеккән карт укытучылар бик тә сәерсенеп калалар. Гәрчә яшьләрнең үз мәнфәгатьләрен кайгыртмыйча, мәктәпкә җанлылык алып керүләрен күрсәләр дә, гаделлекне яклап түрәләргә турысын әйтергә җөрьәт итүләренә күңелләре белән тулаем кушылсалар да, авыз ачып сүз әйтмиләр, күз йомып калу ягын карыйлар, битарафлык чиген атлап уза алмыйлар.

"Курыкма дошманнан—ул сине үтерә генә ала; курыкма дустан—ул сине сата гына ала; син курык битараф заттан—андыйлар үтерми дә, сатмый да, тик инде җир йөзендәге барлык үтерү-сатулар нәкъ әнә шундыйларның дәшми-тынмый гына ризалык бирүеннән чыгып башкарыла", дигән гыйбарәне Бруно Ясенский соңгы романына эпиграф итеп алган. Сарман укытучылары коллективы әнә шуның, битарафлыкның ачык мисалы була. Шуңа күрә яшьләргә кыен ашарга туры килүе табигый. Үзенең кул астында эшләүчеләрнең "ләббәйкә" дип кенә торуларына күнеккән директорга тәнкыйть сүзләре ишетү дә, әмерен үтәмәү дә Совет кануннарын бозу булып күренә. Урыс әдәбиятын укытучы куе бөдрә чәчле егетнең бөтен район коллективы алдында, трибунага чыгып, райком белән исполком җитәкчеләрен "утлы табага бастыруы", мәктәп директорын тетеп гәзиттә фельетон язып чыгуы аның акылына сыймый, әлбәттә.

Дустым Сарманда, үзем Teләнче Тамагында бер ел эшләп кайтканнан соң, без аның белән ике көннең берендә күрешә торган булдык. Калавылга мин әллә нигә бер генә барып чыгам, дустым үзе минем янга иртәнге якта килә дә, шәһәр гизеп йөргәннән соң, кичке якта гына кайтып китә торган иде. Бездә эчеп-исереп яки болагайланып йөрү гадәте юк иде. Ничектер модага ияреп китмәдек шикелле.

Ул арада калавылга инде сәгать саен автобуслар йөри башлаган, дустымның эшләре җиңеләйгән иде. Шулай бервакытны автобуска керсә, анда кайчандыр үзе үлеп гашыйк булган, чибәрлегенә таң калып, Идеал дип йөргән, безнең белән бер заманнарда урысча гына укыган һәм шул телдә генә аңлаша алган туташка тап була.

Идеал белән аларның аралары үз вакытында гаять якынаеп китә. Мишәр егете йөргән кызының өенә дә баргалый, аңарчы ерактан гына күреп йөргән әтисе заводта зур дәрәҗәле конструктор була торып та, искиткеч тыйнаклыгы белән егетебезне хәйран калдыра. Ә менә остабикәгә тартымрак әнисе берәзлексез сөйләргә әзер, кызы кебек үк чибәр дә чая ханым татарча да сөйләшә икән, үзенең белмәгән нәрсәсе юк икән.

Бервакытны шулай әңгәмә барышында:

—Сәгыйть Фәйзуллин без яшь чакта беренче татар зыялысы иде, аңа гашыйк булмаган кыз калмагандыр...—дип дустымны хәтта әле гаҗәпкә дә калдыра. Бәй, безнең остазыбызны яхшы ук белгән икән ләбаса!

Идеал белән аралары шул рәвешле матур гына якынаеп вә үрелеп барган, калавылда аларның йөргәннәрен бөтен кеше белгән, дуслары сөенгән заманда аянычлы бер вакыйга булып ала.

Бергә-бергә Яңа елны университетның зур залында, түшәмнәргә тиеп торган зиннәтле чыршы янында уйнап та биеп каршылый болар. Хәйран күңелле була. Казан урамнарына төне буе яуган кар өстенә үзләренең аяк эзләрен калдырып шактый ук йөргәннән соң, кызның яшәгән фатирына сугылып, аннан өенә алып кайта торган сумканы эләктереп чыга да тимер юл вокзалына юнәлә болар. Егет үзе көн саен килеп тә кайтып йөргәч еллык билетны алдан ук алып куйган була, кызына тиз генә билет алып чыга да, Казан-Арча поездының бушрак бер вагонына кереп урнашалар, дустанә гөрләшеп кайталар да, егет өенә хәтле бик рәхәтләнеп озатып куя үзенең Идеалын. Яңа елны шулай бергә каршы алулары киләчәк өчен үзенә күрә символика буларак кабул ителергә тиеш иде кебек тә бит, киресенчә килеп чыга...

Мөгаен, Идеал әнкәсенә Яңа ел манзарасын сөйләгән чагында, сүз уңаеннан гына, егете билетны бик тиз алып чыгуын да телгә алгандыр. Шуннан моның әнисе, бухгалтерия хезмәткәре, сәмәннең кадерен белгән кеше, бер танышы аркылы билетның хакын җибәрә. Гайрәтең чикмәслекмени! Бердән, ул әдәпле вә инсафлы, остабикә дәрәҗәсендәге ханым Кызының йөрәк серләренә тыкшына; икенчедән Егетне кимсетә, гүя сәдака җибәрүе белән хәерчегә чыгара!

Миңа калса, әлеге вакыйгага Идеалның бернинди катнашы булмагандыр, ул һич тә егетне кимсетергә яисә рәнҗетергә теләмәгәндер, ихтимал, әнкәсенең әлеге "өлгерлеген" бөтенләй дә белми калгандыр. Әмма зирек тәртәле егетебез йөргән кызы белән сөйләшеп-аңлашып тормый, ике арадагы күперне тота да яндыра...

Икенче бер шартларда яшәсә, моның ише вак-төяккә, мөгаен, бер дә исе китмәс иде. Тик инде гаиләләре фәкыйрьлектә гомер кичерүгә дучар ителгәнлектән, әлеге мәсьәләгә бик-бик четерекле килә. Шуңа күрә кечтеки генә рәнҗетүне дә күңеле күтәрми, йөрәгендә дөрләп янган ялкынга, күзен йомып, су сибә. Күңел түренә икенче берәү кереп урнашкач исә, Идеал аңа бөтенләй чит кешегә әверелә, аның белән һичбер дулкынланусыз, тыныч кына гәпләшеп кайта. Шунда Идеалның янып торган кара күзләре елмаеп та сихерләп каравын һәм:

—Уку-уку дип гомеркәең үтеп киткәнен дә сизми калуың бар. Инде җитте, укулар бетте, аспирантураларда укып, карт кыз булып калырга җыенмыймын. Гомернең яңа баскычына сикерергә, менә хәзердән кияүгә чыгарга кирәк, вакыт бик җиткән! Син ничек уйлыйсың бу хакта? Кияүгә мин фәкать бер кешегә, яшьлегемдә үземне гашыйк иткән егеткә генә чыгасым килә,—дип, бик мәгънәле итеп өздереп каравына һич тә исе китми, чит бер туташның эч серләрен тыныч кына тыңлавын белә. "Аңламый" дустым аның тел төбен, йөрәгенә якын кабул итә алмый аның сүзләрен—егет икенче берәүгә үлеп гашыйк.

Атна-ун көннән исә өйләнеп җибәрә дустым. Кайчандыр яратып йөргән мәгъшукасын түгел, бәлки бүген үлепләр сөйгән кызын ала. Кирегә кайту, артка чигенү гадәте юклыгын янә бер кат исбатлый.

Дустымның мәзәк итеп сөйләрлек хәлләре баштин ашкан. Әйтик, нәшриятта эшләү дәверендә ул озак еллар партбюрога сайлана. Гадәттә бит беренче скрипкәне кулга төшерергә омтылучылар булып тора, дустыма шуның урынбасары да бик җиткән. Үз мәнфәгатьләрен кайгыртмый ул, берәрсен рәнҗетеп-чукып ташламагайлары, дип борчыла, шуңа юл куймаска тырыша. Халык җитди. Әхлак мәсьәләсенә килгәндә һич тә шаярып сөйләшмиләр. Аңарчы да рәнҗетелгән күренекле прозаик, онытылып китеп, партбюродагы бер ханымга усалрак, әмма образлы сүзләр әйткән. Гайбәтче-булдыксыз хатыннар моның шул сүзләренә ябышканнар. Әһә, бу әдипкә партия юлыннан каты шелтә чәпәсәң, мин кем дип, борын чөеп йөри алмас иде, дип этлек эшләргә хыялланалар икән. Моны тиз генә хәл итмәкче булалар. Җыелышны дустым алып барасы икән. Сөйләшеп куйган теге әдип белән:

—Минем янда гына, авызыңа су кабып утырасың. Калганын үзем карармын.

Әгәренки авыз ачып, берәр сүз әйтәсең икән—үпкәләмә, эшне бозасың,—дигән.

Халык җыелышкач, минем дус башта ук гаепле коммунистның нинди зур талант иясе булуын да, әләкчеләр тырышлыгы аркасында "халык дошманы" дип Себер сөрелгәнен дә, еллар үткәч акланганын да, бүген исә татар халкының үткәнен тасвирлауга багышланган роман иҗат итүен дә тәфсилләп кенә исләренә төшерә һәм үзенең тәкъдимен әйтә: әдәпсезлек күрсәткән өчен шелтә белдерергә...

Җыелышка бит юнәлеш бирү генә кирәк. Исәп кенәгәсенә теркәп каты шелтә бирелми кала.

Икенче юлы партбюрода зур шагыйрьнең эчеп-исереп йөрүен фаш итеп, фикер алышып утыралар. Бер хатын сайрый эчүчелекнең нинди зур зыян китерүләрен, икенчесе чәчә үзенең зәһәрен. Болар икесе дә коммунистка бик рәхәтләнеп каты шелтә бирерләр иде дә исәп кенәгәсенә теркәтерләр иде. Күрә дустым, бюрода артыграк акыл саталар, кешене өзгәләп ташларга әзерләр. Бу юнәлешкә чик куймыйча ярамас, дигән фикергә килеп, сүз ала:

—Мөнип абый, сез бит балалар әдәбиятында әйдәп баручы шагыйрь, дистәләрчә әйбәт китап чыгардыгыз, фәлән-фәлән җырларыгызны бөтенебез ярата, алар халык җырлары дәрәҗәсендә. Ә үзегез, шундый талантлы шагыйрь була торып та көпә-көндез эчеп йөрисез, болагайланасыз. Минем шулай эштә исереп йөргәнемне күргәнегез бармы?

—Юк, сине алай күргәнем юк.

—Күрмәссез дә! Ә бит беребез дә әүлия түгел. Мин дә эчәм. Атна азагында, дус-иш белән. Тик инде иртәгесен баш төзәтүнең ни икәнен белмим, икенче көнне ял итәм, атна буе эштә булам, исереп йөрергә вакыт калмый...

Шулчак партбюро әгъзалары көлешә башлыйлар:

—Син бит Мөнипне тәнкыйтьләмисең, ничек эчәргә икәнен өйрәтәсең,—диләр.

—Соң бит, шундый шәп шагыйрь булып, шушы яшькә җитеп, юньләп эчәргә дә өйрәнмәгән. Шуның өчен үзенә шелтә белдерү дөрес булыр. Исәп кенәгәсенә-фәлән кертмичә генә...

Шушы хәлне сөйләгәч, мин дә көлмичә түзмәдем.

—Ичмасам, рәхмәт әйттеме үзеңә?—дип кызыксындым.

—Әйтте. Икенче көнне үк. Коридорда тотты да үземне, синең коньяк яратканыңны белдем, минем бер дус зур складта эшли, үзеңә искиткеч шәп коньяк алып килим әле, бир ун тәңкә, дип, сәмән алып китте.

—Китердеме соң? Нишләптер миңа күрсәтмәдең ул затлы шешәне.

—Үземнең дә күргән юк әле. Ике-өч ай гына вакыт узды, таба алмый торгандыр...

—Көт син алкаштан изгелек! Утырткан ул үзеңне. Рәхмәте шул булсын.

Янә мондыйрак хәл була.

Нәшрият халкына бакча бүлеп бирәләр. Займищеда. Коллектив шунда ук эшләүче Зиннур дигән балалар язучысын бакчачылар идарәсенең рәисе итеп сайлап куя. Тыйнак та тырыш егет икән үзе, кай арада эшне җайга сала теге, кайларгадыр барып, җыелган акчага күп итеп койма баганасына ярарлык казыклар, такталар кайтартып аудара. Нәшриятнең үзендә эшләүче мыштым егетләр ул өемнән шактый гына материалны шудыралар. Кайсы мыштымнарның кулы кәкре икәнне белгән хәлдә, коллектив хәзинәсен сакламаган өчен, әлбәттә, Зиннурны тиргиләр, материалны аңардан таптыралар. Сугышта контузияләр алган рәис егеткә шул җитә кала, атычуты белән әйтеп сүгешә бу халык белән. Әлеге хәлдән соң нәшрятнең яңа хуҗасы Зиннурны, гомумән, эштән куарга приказ чыгара, партия юлыннан каты шелтә бирүне таләп итә.

Җыелышта минем дус әлеге егетне яклап, директорга каршы чыга. Балалар өчен язган хикәяләрен үзе редакцияләгән була, шуңа күрә иҗатын иркенләп сөйли. Мактаудан соң бакчачылар башлыгының тыйнаклыгын, коллектив өчен янып йөргәнен, нәшриятта кайберәүләрнең үз мәнфәгатен кайгыртып яшәгәнен искәртә дә Зиннурның фронтта алган партбилетына кагылмау, эштән куылгач, бер гаеп өчен, хәтта ул гаепле булган очракта да ике төрле җәза бирмәү дөрес булыр, дип бара. Хуҗаларга яраклаша белми шул дустым, яраклаша белми...

Менә хәзер соңгы елларда Зиннур бөтенләй күзгә-башка күренмәгәч, дустым аны белгән кешеләрдән сораштырып карый. Нинди хәлдә икәнен дә, үлгәнме, әллә исәнме икәнлеген дә беркем белми. Нәшрияттан китапларын, шәхси эшен таптыра,

энциклопедиягә кертү өчен мәкалә яза. Моның белән генә канәгатьләнмичә, китә Яңа Аракчинога әдипнең өен эзләп. Әлеге калавыллар ул арада Казанга кушылып, урам исемнәре үзгәреп беткән булып чыга. Каян тапмак кирәк! Сәгатьләр буе сорашып йөри торгач, ниһаять, игътибарлы затларга юлыга, алары фәлән кешеләрдән белешә-нитә торгач, андый язучыны әле кичә-бүген күрүчеләр, хәтта өен белүчеләр дә табыла.

Зиннурны туры китерә алмыйча, хәбәрләшергә язу язып калдыргач, исән икәнлегенә ышанып та сөенеп кайтып китә соң. Әмма тегеннән хәбәр юк та юк. Тагын китә бу өенә. Күрешеп сөйләшәләр. Бер юньсезе моның повестен кире каккач, кайнар канлы кеше беткә үч итеп тунын утка яккан булып чыга—беркемгә берни кирәкми, дип, язуны ташлаган, бөтенләй ваз кичкән.

Шулай да повестен эзләп таба, биреп җибәрә. Укып чыга дустым. Әйбәт язылган нәрсә икәненә инангач, журнал мөхәрриренә мактап сөйли. Теге дә кызыга. Кереш мәкалә язып, кульязманы китерергә куша. Игътибар күрсәткәч, язмыйча каласыңмыни, бик яза дустым.

Янә бер елдан журналны күтәреп барса, Зиннурыбыз хәл эчендә ята икән ләбаса. Дустымны шәйләп тә бетерми, повестенең басылып чыкканын ишеткәч:

—Сине фәләнев фәлән җибәргәндер инде...—дип сөйләнә.

—Бу мин бит инде, Зиннур, танымыйсыңмыни?—дигәч, әдип тә балкып куя:

—Гонорарның яртысы—синеке, бырат! Син булмасаң, моның дөнья күрәсе юк иде,—ди.

—Зиннур, дускаем, акчага кызыгып йөрүем түгел. Һич тә! Минем роль юк монда, повестең шәп, аны син язгансың, бөтен гонорары үзеңә.

—Хәзер андый заман түгел бит...

—Кеше хакына керәсем юк, тиенең дә кирәкми. Исән-сау булуыңа шатмын, бер күрешү—үзе бер гомер. Аягым җиңел булсын!..

***

Кызганыч ки, Советлар заманында милли мәктәпләр бетерелеп, барча халык фәкать урысча гына укып белем алу нәтиҗәсендә, бик күп кеше ана телен өйрәнүдән мәхрүм ителде... Ә бит дөньяда бер хакыйкать яшәп килә: үзеңнең ана телеңне белми торып, син бүтән бер генә телне дә өйрәнә алмыйсың, берсен дә юньләп белмәячәксең.

Дөрес, уку-укыту эшләре фәкать урысча гына алып барылгач, шактый ук талантлы яшьләребез урысча тезмә яки чәчмә әсәрләр иҗат итәргә керешәләр. Тик инде, урысча гына яза торган яһүд, казакъ һәм башка халык вәкилләре кебек үк, урысча язган татар язучылары да ул әдәбиятка әлләни зур файда китерә алмыйлар. Моның сәбәбе: образлы фикер йөртү—милли сыйфатларга бәйле. Ә бу сыйфатлар һәр милләтнең канында, бик-бик тирәндә ята. Яһүднең әлеге милли сыйфатлары борын-борыннан килгән кебек, татарның яки урысның да ата-бабадан килә. Синең геннарыңнан татар каны килгән икән, телисеңме син, теләмисеңме—фәкать үзеңнең ата-бабаңа хас сыйфатларга таянып кына образлар тудыра аласың, образлы фикер йөртә аласың, геннарыңда яткан сыйфатларны җанландырып, тагын да ныграк үстерүгә һәм баетуга, образлырак иттереп тасвирлауга ирешә алачаксың.

Ә инде син үзеңнең ана телеңдә уку, язу, фикер йөртү, бигрәк тә образлы фикерләү мөмкинлегеннән мәхрүм ителгәнсең икән—бу иң әүвәл синең үзең өчен олуг фаҗига. Милләт өчен дә талант иясен югалту—зур фаҗига.

Милләтне милләт итеп саклап килгән нәрсә, әлбәттә, ана теле. Мәктәпләрне бетерү, "вак халыкларны" саф ана телендә белем алудан мәхрүм итү—әнә шул халыкларның үсүенә, киләчәгенә балта чабу, аларны иң зур байлыкларыннан аеру, бәхетсез язмышка дучар итү дигән сүз. Аларны урыслаштыру һич мөмкин түгел, алар фәкать ике арада калган манкорт кына була алалар.

Һәркайсыбыз өчен саф ана телен белү, миңа калса, иң зур байлык. Дөньяда яшәвеңнең төп мәгънәсен нәкъ әнә шул сыйфат билгели. Бүтән телләрне өйрәнү, бөтен нечкәлекләренә төшенү-үзләштерү фәкать ана телен әйбәт белгән очракта гына мөмкин. Үз телеңнең байлыгына чын-чынлап хуҗа булмый торып, башка бер

телнең тирәндә яткан байлыгына гомереңдә дә үтеп керә алмаячаксың. Ә инде мәктәптә, университет яки институтта урысча гына белем алган тәкъдирдә, кызганыч ки, син үз телеңне дә белми каласың, урысчаны да юньләп белмәячәксең. Чөнки синең өйрәнгәнең халыктан түгел, фәкать китаплардан укып алган белем генә. Бездә ул куян шулпасының шулпасы буларак танылган.

Ә инде син, татар телен белмәгәнгә генә урысча "блям" дип саныйсың икән—анысы синең үз эшең, саный бир. Укып надан калучылар бер син генә түгел.

Ә инде син, үзеннең ана телеңне әз-мәз генә, ипи-тозлык кына белгән өстенә, урысча гына укыганыңны бик зур дәрәҗәгә санап, аны да юньләп, тирәнтен өйрәнә алмаган хәлдә, мин двуязычный, ике телле, дисең икән—бу инде синең үзең өчен зур фаҗига...

Илленче еллар азагында, Муса Җәлилнең исеме бөтен дөньяга мәгълүм булган бер заманда, халыкара вагонда кайтучы дустымнан урыс зыялылары:

—Сезнең Мусагыз Мәскәүдә укыган бит. Ул шигырьне дә урысча язгандыр инде?—дип сорашкач, мишәр егете җавапны кыска тота:

—Үзен хөрмәт итүче һәркем фәкать ана телендә генә иҗат итә!—дип өздереп әйтә, бәхәскә һич урын калдырмый.

Гәрчә үзе шигырьне ике телдә язгаласа да, әдәби әсәрләрнең яки фәнни телдәге кульъязмаларның татарчасын да, урысчасын да хәйран оста, җиренә җиткереп редакцияләсә дә, мәктәптә генә түгел, университетта урысча лекцияләр укыса да, мин дустымның үз авызыннан "ике телле" дигәнне һичбер вакыт ишеткәнем булмады. Моның сере бик гади: ул үзен туган халкыбызга хезмәт итәргә тиеш, дип саный, фәкать ана телендә иҗат итә. Хәер, язып яткан шигырьләрен һәм ике повестен ташлап, бүгенге көндә әһәмиятлерәк эшкә башы-аягы белән чума—әдәби тәрҗемә өлкәсендәге башбаштаклыкка чик кую дәрте белән яна башлый. Менә шунда инде аның һәр ике телне дә төпле белүе бик тә ярап куя. Аның изге ниятен кордашлары яклап чыга, шул рәвешле уңганнар командасы оеша, яңа мәктәп барлыкка килә, әдәби тәрҗемә мәктәбе. Талантлы яшьләрнең безгә кушылуы инде табигый бер хәл.

Әмма сүзгә-сүз аударучыларны да, оригиналны үзләренчә иректә төстә кыландыручыларны да трибунага чыгып яки матбугат битләрендә сүгү бер хәл, ничек эшләргә ярамаганын исбатладың да диик, ә менә ничек тәрҗемә итү кирәклеген кем күрсәтеп бирер безгә? Менә шунда инде "Хәсрәт дәрьясы"ның дөнья күрүе һәммәбез өчен дә әйтеп бетергесез үрнәк булды. Моңарчы яшәп килгән, тәмам чәчәк аткан халтурага әнә шул тәрҗемә, дөресрәге саф ана телебездә язып чыккан роман киртә куйды, ничек эшләргә икәнен өйрәтте.

Дустымның берәүдән дә көнләшмичә яисә күпсенмичә, иҗади теләктәшлек дәрте белән януы барчабызны гаделлеккә этәрде. Һәммәбез дә тәрҗемәгә иҗат эше дип карый торгач, намус белән көчебезне түккәч, бер-бер артлы матур вә камил, кабат-кабат укырдай китаплар күренә башлады. Эзлексез һәм гадел фикер алышулар, бер-береңә теләктәшлек күрсәтүләр, кульъязманың һәркайсын яхшыртырга омтылулар, әлбәттә, үзенең нәтиҗәсен бирде—утыз-кырык ел эчендә безнең иҗат командасы татар әдәбиятын баетуга сизелерлек өлешен кертте.

Дустымның холкына ләббәйкә дип торучы мин түгел. Мәгәр... дуамаллыгын бетерергә күпме генә тырышсам да, уңыш казана алмадым бугай. Сүземә колак та сала кебек инде югыйсә, әмма бар халыкны үзе шикелле намуслы, мәрхәмәтле итәргә омтылуы эшне боза да куя. Нигә кирәк иде инде аңа тәнкыйть мәкаләләре, фельетоннар язу? Әллә син мәктәп директорын акылга утыртырмын дисеңме? Бүтән коллективларда хәлләр әйбәтрәкмени? Директор үз мәнфәгатен каермаса, директор да булмый, андый зур титулга ирешә дә алмый бит ул. Дөньяны төзәтеп булса икән фельетон язып кына...

Зирек тәртәле булуы аркасында кеше үтерә язуын кая куясың? Мәктәптә Швейкны акылга утыртуы бер хәл, студент чагыбызда кызып китеп, колга белән тондыра ич бер хәрәсәнгә! Үтергән булса—утыртып куялар иде бит үзен, ә инде гариплэтсә—гомер буе тегеңәр пенсия түләтәчәк иделәр. Еш кына ярсуыңны тыярга туры килә шул, бүтәннәрнең холкы-фигыле белән бер дә исәпләшми генә яшәп булмый бу дөньяда...

## Ахырзаман

*Курыкма үлемнән,*
*курык файдасыз гомердән.*

Татар халык мәкале

*Кара син, ә, һаман кабаланып*
*Үтеп китте бит, әй, тормыш та!*
*Ә мин һаман: үз өстенә алган*
*Йөктән арыналмаган кырмыска.*

Әнвәр Давыдов

Хәйран тамаша инде...

Энциклопедия институтыннан отпускага чыгып, дачада ял итеп ятканда, дөресрәге, тынычрак минутларымны язып-сызып, рәхәт-ләззәттә уздырганда бәләкәй оныгым белән Иделнең бер тармагында чупырдаганда, өемдә иминлек, үземдә иҗат вә дәрт гөрләп барганда, һич уйламаган-көтмәгән җирдән тәннәрем янарга тотынмасынмы! 30-35 градус эсседә оныгым белән коенырга йөреп, кәпәчсез-нисез генә бил тиңентен суда торган хәлдә оныгымны суга чумбылдатып, йөзәргә өйрәтүем ярамагандыр инде...

Ай-ваема карамыйча, калага озаттылар үземне, иртән температурам югары булса, табиб чакырырга әмер бирделәр. "Прокурор"ның әмеренә кем генә каршы тора алыр икән?! Утырдым да киттем улымның машинасына. Иртән табибәне чакырттым. Матурлыкның вә сәнгатьнең кадерен белүче табибәмә галереям бик ошады, яңа альбомыма биһуш булды. Мәгәр үзем бер дә "ошамадым"—әллә ниләр язып бетерде. Ялдан соң поликлиникага барырга кушып, хушлашты. Анда шулай тыныч кына кабинет саен анализ тапшырып, өйгә кайткач, укып-язып ятканда, бер кичне эссем янә күтәрелеп китмәсенме?

Төнлә белән хәлем хәл булды, мин инде кеше буласыма тәмам өметем өзеп, газизләрем белән, фани дөнья белән бәхилләшеп яттым. Иртә таңнан улыма хәлләр мөшкел икәнен чишеп, тизрәк әнисен алып кайтырга куштым. Ике-өч сәгатьтән алар кайтып та җиттеләр. Гомер иткән карчыгымның йөрәк җылысыннан тәмам эреп киттем, елмаеп азапланам.

Ул арада Марина атлы дус кызыбыз килеп җитте. (Ул безгә үз өенә кайткандай, теләсә кайчан сугыла.) Авырып ятуымны күреп, анализ кәгазьләремә күз салды, эсселегемне тәгаенләде дә:

—Безгә УЗИда каралырга кирәк. Моның өчен иң кулае алтынчы шифаханә булыр,—диде.

Без моңа каршы килмәгәнне күргәч, шундук үзе эшләгән "Ашыгыч ярдәм күрсәтү"нең түрәсенә чылтыратты:

—Менә мин кардәшләремә кергән идем дә, абзый чирләп ята икән. Утыз тугыз градус белән. Бүген кизүдә алтынчы шифаханә бугай, шунда алып барып, УЗИлардан каратасы иде үзен. Сез фәлән адрес белән машина җибәрсәгез иде.

Әкрен кеше киенгәләгәнче тегеләр килеп тә җиттеләр. Минем шифаханәгә кереп ятуга кул-аягым белән каршы икәнемне белгәч, елмайды гына табибә кыз бала:

—Сезне бит анда берәү дә шифаханәгә салырга алып бармый. Бу тирәдә УЗИ шунда гына. Рентгеннан карасыннар, УЗИдан. Шуның белән хәлегез дә, чирегез дә ачыкланыр,—диде.

Анда шалт-шолт барын да карадылар, аяк бармакларымнан алып чәч бөртекләремә кадәр тикшерделәр. Зур гәүдәле уролог:

—Анализ кирәк, бәвел анализы,—дигәнне ишеткәч:

—Миңа ясадылар инде,—дидем.

—Кайчан?

—Өченче көн.

—Юк шул, ярамый. Хәзер кирәк!

Анысын да кай арада ачыклап ташладылар. Табиб агай:

—Ул җитди авырый, газап чигә. Утыз тугыз градус белән аны урамга чыгарып җибәрә алмыйбыз. Дәваларга кирәк, шифаханәгә яткызабыз!—дигәч, карчыгым белән

үзара карашып алдык та, башка чарабыз юклыгын аңлап, ризалаштык соң...

Онытып торам икән әле: УЗИдан караганнан, рентгенга күренгәннән соң табиблар көлешеп алдылар:

—Уңъяк бөерендә коралл икән ләбаса авыруыбызның!—диделәр. Пленкага күз салган идем—үзем дә сокланып куйдым: баш бармак кадәрле озынча матур ташны тагын да килешлерәк төерчекләр бизәп тора икән ич! Мәрҗән дә мәрҗән, бу да мәрҗән! Әле бит аның, өч-дүрт см озынлыгы ташның, тырпаеп басып торуларын күрсәң!.. Шуннан бирле үземне коралл дип йөртә башладылар шифаханәдә.

Соңыннан белдем (күп нәрсәне белми генә үлүең бар бит әле!) поликлиника табибеннән: аның күзгә күренеп торганы куркыныч түгел икән; сул бөердәге комлы ташлары хәтәр, бәвел юлын шулар томалый икән; мәрҗән исә җилсенгән очракта гына азып китә дә сикертә—операциясез һич котылу юк икән...

Ходайның һәр бирмеш көнендә җаннары теләгәнчә укол кадый торгач, минем бөердәге теге вак-төяк партизан ташлар үз урыннарына кереп яттылар бугай. Һәрхәлдә, бактерияләр борчудан туктады, савыгам инде, дип сөенеп кенә ятканда, әлеге паразитлар барчасы ду кубып баш күтәрмәсеннәрме! Тик кенә торган җирдән миңа суык була башлады. Шулай эсселе-суыклы булып ятканда тешләрем әргән уйный гына лабаса! Урамда утыз өч градус җылы. Чакырдылар шәфкать туташын. Градусник куйса—утыз тугыз да тугыз градус икән ич! Тиз генә хәбәр бирделәр табибка да. Кай арада анысы атылып килеп җитте, дүрт-биш төрле укол кадарга әмер бирде: алар кулында җан тәслим кылсаң—ЧП санала икән ич. Кизүдәге шәфкать туташларының тәмам котларын алганмын—укол кадарга энәләр таба алмый азапланалар икән...

Моржмы син, түгелме, дип сорап тормадылар—өйделәр өскә одеял. Газаплы йокымнан уянып китү белән, иренемне чылатып алыйм дип, тумбочка өстенә кулымны сузуга, рәхмәтле бәндә Фәһим күршем:

—Менә монысы җылы чәй,—дип, кулыма бокал тоттыра.

Күземне ачар-ачмас кына бокалдан чәйне уртлап, янымнан һич китмичә кизү торган изге җанга сузамын. Янә оеп китәмен...

***

Имештер, галәмәт зур бина эчендә күңелемә якын затлар—Сәлих ага Вәлиди белән Байназар абый Әлминев әллә кайларга ияртеп алып кереп китәләр үземне. (Татарстан китап нәшриятында берсе директор, икенчесе баш рәссам иде.) Әллә нинди лабиринтлар аша керә торгач, бер бүлмәгә юлыгабыз. Анда, имештер, Сәгыйть абзый утыра, остазым Фәйзуллин. Күрше кабинетта Җиһангир абзый Ишиев. Икесе дә мәһабәт. Әнә тагын Сәхаб Урайский, Әнвәр Давыдовлар... Ул агайлар барысы да затлы, һәркайсы зыялы, бөтен игътибарынны үзенә җәлеп итеп тора. Алар сөйләшмәделәр. Фәкать елмаешып миңа мәрхәмәт-шәфкать күрсәттеләр. Оҗмахта булсын җаннары, тыныч йокласыннар, нәшрият өчен күп көч сарыф иттеләр газизләрем. Тик алар янында артык озак юанмадым: плащымны салып, дивардагы озын кадакка элдем дә ишеккә юнәлдем. Исән чакларында да, әлеге "күрешүдә" дә үземә ачык чырай күрсәткән фидакяр затлар белән хушлашмый-нитми генә чыгып китүем исә кайчан да булса, ахыры бер шулар янына ишек ачып керәсемне бәян итәдер инде...

Фани дөньядан китәргәме хәзер үк, әллә бераз сабыр итәргәме, дип уйланып ятканда, карт Әҗәл белән алышканда, мөгаен, бераз сабыр итү ягын каерганмындыр.

Мәгәр үзем "Илаһи комедия"нең авторы сыман карап-танышып йөрмәдем, бер читтән күзәтүемне белдем, күзләрем әллә кайдагы зат вә хәлләрне дә гаҗәеп әйбәт шәйләде. Үземне генә берәү дә күрми, янымнан үтеп-сүтеп, бәрелә язып йөриләр, тик берсе дә мине абайламый.

Ишекне ачып, зыялы картларым яныннан чыксам, гаҗәеп озын вә зур залга килеп кергәнмен, имеш.

Иң түрдә, уң кулда, диварга аркан Дамир Шакиров утыра. Өстәлендә китаплар, корректура табаклары. Нәшриятның директоры янына әледән-әле нәшрият кешеләре килеп тора, кулындагы кәгазьләрне ни рәвешле хәл итәсене киңәшләшә. Бухгалтерия башлыгы Әминә дә, корректураларын күтәреп Гөлшат апалары да,

производство башлыгы Зөлфия дә килә. Бераз уңдарак иләмсез дәү өстәл янында баш мөхәррирләр утыра, алар икәү, имеш—Харрас Әюпов белән Марс Шабаев. Нидер киңәшәләр, икесенең дә кулларында корректура. Аларга каршы өстәлләр янында техредлар Әнисә, Ания, Суфия, Вера, Наилә, Фәһимә, Фәния, Сания хәреф санап баш ваталар, линейка белән нидер үлчәп, кәгазьдә шуны карандаш белән билгелиләр. Шунда ук машинисткалар клавишаларга шакы-шокы суга торалар.

Әйләнә-тирәдә бәп-бәләкәй өстәл саен икешәр мөхәррир утыра: Фәния белән Сания, Марык белән Рәис, Фирая белән Наилә, Равил белән Лирон, Люция белән Роза, Ләйсән белән Очкын, Хисам белән Сәлихҗан... Алар башларын да күтәрмичә редакциялиләр.

Сульяктан колагыма сыерчыклар сайрагандай, күңелемә тансык чүкердәшү ишетелде. Борылып карасам—анда корректор кызлар кайсы кульязма, кайсы корректураны чагыштырып укыйлар икән. Анда береннән бере чибәрләр: Нәсимә белән Зөлфия, Зөмәррә белән Әлфинур, Мөфидә белән Рушания, Мәрьям белән Гүзәл кара-каршы утыралар. Гөлшатлары тыз-быз килә.

Каршы яктагы диварга озын буйлы, какча гәүдәле, буялган чәчле бер хатын сөялгән дә бәләкәй буйлы, юантык гәүдәле, зәһәрлеге йөзенә чыккан хатын белән авызга-авыз гайбәт саталар...

Каяндыр каршы яктан ике Илшат өр-яңа китаплар күтәреп килеп чыгалар да директор янына ашыгалар. Зур кызыксыну белән аларга кайбер техред, корректор тагыла.

Китапның һәркайсын әйбәтләп карыйлар да шундук елмаешып торучы Сабира ханым белән Нәсимәгә тантаналы рәвештә тапшыралар, имеш...

Нәшрият халкының шулай тыз-быз килүе аңлашыла булса кирәк: имештер, иске елның соңгы көне, план үтәргә тырышалар. Планны үтәүгә күп нәрсәләр бәйләнгән: үтисең икән—дәрәҗәң зур, синең урының түрдән; үтәмәсәң—чанадан чөеп кенә төшерүләре бик ихтимал...

Бу зур залда халык трамвайдагы сыман, гел хәрәкәттә, күпләр йөреп тора, кайберәүләр тамак ялгый. Төн уртасы күптән узган, кайсының тамагы ачкан, кайсының йокысы килә, күзләре йомыла. Шуңа карамастан берәү дә чыгып китми, нәшрият өчен һәркемнең җаны фида. Кайтырга куркырсың дип, каршыларга килүчеләр дә күренә башлады.

Менә сызылып таң атканы сизелде. Шул чагында производство җитәкчеләре директор каршына барып, быелгы планның ахыргы корректурасы типографиягә тапшырылды, чыгасы китапларның соңгы сигнальные алынды, менә алар, дип, кулларына тапшырдылар. Шунда гына директорның көләч йөзендә елмаю күренде:

—Рәхмәт, коллегалар! Бик зур рәхмәт! Сезнең тырышлык белән ирештек бу уңышка...

Мәзәк хәл инде...

Ахырзаман якынлашканда Әҗәл белән тартышып ятканда, чынлап торып уйласаң, адәм баласы үзенең гаиләсе белән, туган-тумачасы белән бәхилләшергә тиештер инде, югыйсә. Фани дөньядан китәргә җыенучы, гомумән, якыннарына үзенең соңгы сүзләрен-гозерләрен әйтеп калдырырга, варисларына исә үзенең үтәлмәгән вәгъдәләрен, башкарып чыга алмаган ниятләрен, эшләп бетермәгән, ярты юлда калган эшләрен, түләмәгән бурычларын тапшырырга тиештер сыман тоела. Һич югы бүген үзе эшләгән дәрәҗәле оешма (энциклопедия институты!), андагы асыл вә гали затлар белән хушлашырга, туры әйткән урынлы, әмма каты, аяусыз, дорфа сүзләре өчен түрәләрдән кинә сакламауларын үтенергә тиештер сыман тоела. Әмма бу артык акыллы, нормаль кешеләргә күбрәк хастыр. Чөнки дәрвиш аты күтәреп йөргән кеше алай эшләми икән. Дәрвиш дигән бәя алган зат үзе гомер буе эшләгән оешма белән: фидакяр хезмәт куйган гаҗәеп тату коллективтагы кешеләр белән, үзе сокланган, хезмәтләре вә һөнәри осталыклары алдында ихлас күңелдән баш игән, гомерләрен китап чыгарудай изге эшкә, ягъни иң авыр елларда да ана теленең гүзәллеген-камиллеген саклап калуга багышлаган, бернинди байлыкка-дәрәҗәгә алданмаган, үзләрен бик гади тоткан гали затлар белән бәхилләшүне һәммә нәрсәдән артыграк саный булса кирәк. Дәрвиш дип академик Тәлгат Галиуллин тикмәгә әйтмәгәндер шул..

## Соңгы җырым

*Нигезең нык булса, күңелең тыныч булыр.*
Татар халык мәкале

*Үз өендә бәхетле кеше генә чын-чынлап бәхетле.*
Л.Толстой

*Хатын—сөяркә түгел, дус ул, гомерлек юлдаш, һәм без аны олыгая төшкәч тә, корткага әйләнгәч тә яратырга алдан ук әзер булырга тиешбез.*
В.Белинский

Яшәүнең мәгънәсе, мөгаен, гомер юлын узып, дөньяның ачысын-төчесен татып та үзең сайлаган кыйблаңа тугрылык саклаган хәлдә, уңга-сулга карамыйча, ягъни кемгә дә булса ярарга тырышмыйча, яшь буынга ихлас күңелдән әйтеп калдырасы гозерен-сүзең булудадыр, чамаңны-хәлеңне дөрес бәяләп, васыятеңне күндереп калдырудадыр.

Социализм мохитендә яшәгән, эшләгән, яхшымы-яманмы гомер кичергән кайбер замандашларым хәзер инде, туй узгач дөмбергә дигәндәй, кайчандыр патшаны сүккән кебек үк, социализмны китереп чыгарган юлбашчыларны да, ул заманнарда хөкем сөргән гадәтләрне дә, яшәү рәвешен дә эттән алып эткә салу ягын карыйлар, ягъни тәти егетләр булып күренергә тырышалар. Миңа калса, бу инде атаңны сүгү белән бер. Әле үзең юньләп белмәгән-аңламаган заманага яраклашырга маташу гына егетлек түгел, һич тә!

Комсомолга керүемә дә, аннары утыз-кырык ел дәвамында партия әгъзасы буларак бушлай эшләп йөрүемә дә үкенмимен, һич юк! Чөнки партиянең максаты, һәркем укый алсын өчен чыгарган программасы, чынлап та, кызыгырлык иде. Тик менә җитәкчеләребез генә белгән, бернинди программага да теркәлмәгән, яшерен максат та яшәп килгән икән. Икейөзлелек нәкъ әнә шуның аркасында килеп чыккан лабаса! Шаклар ката идем ул чагында бер төрле сөйләп, икенче төрле эшләнүенә: имештер, милли мәдәниятләр гөрләп үсә. Чынбарлыкта шуның нәкъ киресе—татар мәктәпләре берәм-берәм урыс мәктәбенә әйләнә, мәдәният учаклары акрынлап ябыла, ягъни барча халыкны урыслаштырып бетерү максатында милли мәдәниятнең тамырына балта чабыла... Хәер, үз илебездә юньле социализм төзүне гамәлгә ашыра алмаган хәлдә дә, бөтен дөнья күләмендә революцияләр кубарып, коммунизм төзү идеясен алга сөрүче бәндәләрдән тагы ниләр көтмәк кирәк?! Үз өеңдә өйрә пешерә белмәгән көе, кеше өендә ботка пешергән кебегрәк килеп чыга. Яман бер гарьлек тудырганы янә шунда ки, башлары-күзләре тонган кайбер милләттәшләребез, татар мәктәпләре кирәкми, балаларыбызны урысча укытабыз, югыйсә алар ВУЗга керә алмаслар, дип, түрәләр кубызына биеп маташалар. "Халык" үзе шуны сорагач, партиягә дә, хөкүмәткә дә бернинди дәгъва куя алмыйсың.

Ярый, теге агайларның балалары гел урысча гына укып, югары уку йортларына керсеннәр, нинди дә булса һөнәр дә алып чыксыннар, диик. Мәгәр алар ана телен онытып, икенче бер телне юньләп үзләштерә алмаячаклар. Чөнки үзенең ана телен белмәгән кеше, гомумән, телнең нечкәлекләрен шәйләми, шуңа күрә бүтән телләрне дә ярты-йорты гына өйрәнә, манкорт хәлендә кала. Шуннан инде: "Минь двуязычный!"—дип кәпрәеп йөри. Кызганыч ки, техник интеллигенция арасында гына түгел, андый "шәхес"ләр безнең әдәбият өлкәсендә дә очраштыргалый... Ә бит үз телеңне әйбәтләп өйрәнүгә, камиллеккә омтылуга ни җитә!

Мин фәкать артык туры-төгәл-дөрес кешеләрдән куркамын. Урыслар аны "слишком правильный человек" диләр бугай. Андый затлар канун кысаларыннан да чыкмыйлар, бернинди хата да ясамыйлар, аларда һичбер төрле кимчелек булмас, хәтта әле изге ялганның да алар нәрсә икәнен һич белмәсләр.

Миңа калса, алар берәүне дә ихлас яратырга, дус итәргә, якын күрергә һәм, киресенчә, кемгә дә булса нәфрәт хисе белән янарга сәләтле түгел. Чөнки алар өчен һәммә кеше бертигез, һәркемгә фәкать шикләнеп кенә карый алалар, үзләре һәрчак битарафлар, бары тик алар аңлаганча дөреслек хөкем итәргә, һәрчак алар өстен чыгарга тиеш.

Минемчә, алар кешелек дөньясы өчен вампир дәрәҗәсендә куркыныч, хәтәр, явыз затлар. Чөнки берәүне гаеплегә санап хаталанган очракта да аңа карата мииһербансызлык вә шәфкатьсезлек кылудан тайчынмаслар, ә инде үзләрен һәрчак дөрес фикер йөртә дип,

туры юлдан бара дип, әлбәттә, хаклы дип санарлар, башкаларны буйсындыру ягын карарлар, үз сүзләрен яклап һәрчак лаф орырлар, хакыйкатьне аңлауда бик нык хаталанырлар.

Нигәдер кайсыбер кеше гомер буена иҗаттан битәр дан-шөһрәт ягын кайгырта. Шуның дәртенә бер керешкәч, азмы-күпме дәрәҗәләргә дә ирешкәч, аның инде иҗатка вакыты да калмый, ансыз да майтара алуына куанып-канатланып, гомумән, баш ватудан ваз кичә. Әнә шул рәвешле, таланты була торып та, иҗади чиләнүнең, камиллеккә омтылу-казганунын нәрсә икәнен дә оныткаңнан-оныта бара...

Кемнәрнеңдер кубызына биеп, аласы бүләк вә дәрәҗәле исемнәрнең барчасын алып бетергәннән соң, бичара мәхлук үзен күкләргә чөеп мактаучы, мәдхия җырлаучы һөнәрдәшләренә югарыдан торып карарга күнегеп китә дә... үзен классикларга тиңли башлый. Хәер, чамадан тыш узынып киткән чакларында классикларыбызны камчылап матбугатта чыкса да, моның әдәпсезлегенә, сантыйлыгына артык гаҗәпсенмиләр. Һәрхәлдә, аңа каршы авыз ачып сүз әйтергә беребезнең дә тәвәккәллеге җитми.

Һәй, дивана хыялый! Ичмаса бер әйләнеп карасачы артына: күрер иде шул чагында бер генә дә юньле әсәр иҗат итә алмаганын, тау хәтле китап чыгарып та, барчасының складта өелеп ятканын, хәтта әле шәп кәгазьдә, матур итеп басылган томнарының да китап киштәләрендә тузан җыеп, кукыраеп калкынганын. Әйе, әдип белән шагыйрь өчен иң яманы—әсәрләренең үзеннән элек үлүе, ягъни укылмавы, онытылуы...

Дәрәҗәле шәхес булгач, инде масаюдан арып-талып, дөнья куйгач, җыела халык моның җеназасына. Хөкүмәт исеменнән сүз әйтергә тиешле абзыйга язып тоттыралар шпаргалка—мәрхүмнеңниләр иҗат иткәнен беркем хәтерләми яки бөтенләй үк белми. Әйе, берәүгә дә рухи ләззәт китермәгән, берәүне дә борчымаган-дәртләндермәгән китапларны гадәттә һәммә кеше оныта... Бу юлы да шундый хәлнең кабатлануы табигый.

Ә классикларыбыз һәркемнең хәтерендә. Безнең гали замандашларыбыз Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Әмирхан Еникиләр иҗат иткән әсәрләр дә татар укучысының хәтеренә сеңгән. Гарсиа Маркес: “һәр әдипнең бер генә китабы була”,—ди. Ул инде, үзенчә, әдипкә мәшһүрлек вә дан китергән әсәрне күздә тотып әйтә булса кирәк. Һич югы бер әсәрең булсын, дигән сүз. Аның янына тагын ике-өч юньле китап өстәлсә дә, күркәм инде анысы, зыян итми. Шундый таләпне куючы авторның, әйтик, һәр иҗат иткән әсәре камил вә күркәм, бөтен дөньяда яратып укыла.

Хәер, үзебезнең татар әдәбиятында да бар андый бәхеткә ирешкән әдипләр—аларның һәрбер иҗат җимеше әле бүген дә көне-сәгате белән укучысына барып җитә. Ләкин... Ләкин әлеге чын иҗат ияләренең дан яулап чабарга вакыты калмый. Тик инде иң бәхетле, шөһрәтсез дә бәхетле әдипләр, томнары булмаса да аеруча бәхетле язучылар нәкъ әнә шулар. Чөнки аларның йөзләрчә, меңнәрчә укучылары бар, язганнарын яратып укыйлар, һәр яңа китабын түземсезлек белән көтеп алалар.

Сәнгатькә гашыйк булуымны мин очраклы бер хәл дип кенә бәяләсәм дә, ихтимал, ата-бабадан килгән мирасымда сәнгатькәр геннары ятадыр, без фәкыйрегез нәкъ әнә шуларның барчасын гамәлгә ашырырга бурычлы зат буларак дөньяга килгәндер. Тик минем хәлемнән килмәгән әлеге миссияне гамәлгә ашыру. Иң әүвәл, объектив шартлар булмаган: Бөек Октябрь давылы барча авылда мәхшәр китереп чыгарган, һәм ул мәхшәр аеруча уңган крәстиәнне кулак дип, бөтен оясын туздырып ташлау, фәкыйрь-фокраны исә күмәк хуҗалыкка туплап, ялкаулыкка һәм җавапсызлыкка өйрәтү белән очланган. Аннары инде—сугыш галәмәтләре. Беренче Бөтендөнья һәм Ватандашлар сугышы туктап, егерме ел вакыт узу белән, яңасы, Ватан сугышы, Икенче Бөтендөнья сугышы... Андый шартларда, ай-һай ла, җәмгыятьнең нинди генә катлау вәкилләре иҗади һөнәргә өйрәнә алды икән?!

Янә килеп, безнең изелгән милләтебезнең әледән-әле башына сугып торганда, гасырлар буе котыбыз алынып яшәгәнбез, куркак вә тыйнак булырга өйрәнгәнбез. Кая ул анда авыз ачып, рәссам буласым килә, дип әйтүләр! Кем генә хыялланыр икән скрипкә уйныйм, дип! Бик уйныйсың килә икән, үзең яса да уйна, өйрән әйдә, бездә “хөррият”... Әле шөкер диген, таптап китмәгән үзеңне теге “хөррият”...

Син аны тыйнаклык дисеңме, сабырлык яисә куркаклык дисеңме, бүтән берәр атама бирәсеңме, фәкать инде тәвәккәллек дия алмыйсың. Бер генә мисал. Гәрчә сабый чактан ук тезмә юллар тезгәләсәм дә, гомер буе үземне шагыйрьгә санамадым, бер генә шигыремне дә матбугат карамагына тәкъдим итмәдем. Хәтта әле әдәби тәрҗемә өлкәсендә

азау тешләр яргач та, берәр әсәрдә шигъри тәрҗемәне дә үзем ук башкарган очракларда шагыйрь кисәкләре акыл сатмакчылар. Күләм генә үзләреннән, һич бәхәсләшмим. Иҗатның хикмәтләре берәр һөнәргә дәгъва кылуда түгел, бәлки чиләнеп тә казганып камиллеккә омтылуда. Ирешүдә үк димим, чөнки әлеге камиллекнең чиге юк бит аның, ничек итеп ирешмәк кирәк...

Кайчагында миннән, бәхетлеме син, дип сорыйлар. Мондый кызыксынуларга бер дә кыланмыйча, әледән-әле үзгәрепләр торган заманага һәм замандашларымның психологиясенә яраклашырга тырышмыйча, фәкать уңай җавап кына бирергә туры килә. Яшьрәк чакта да, хәзер дә. Үземне сөеп-яратып йөрүче дусларыма да, хәтта әле итәк астыннан ут йөртүче, һәркемгә этлек эшләүдән тәм табып гомер кичерүче бәндәләргә дә.

Мин бәхетле, чөнки таза-сау, уңган-булган ата белән анадан мәхәббәт очкыны буларак яралып, хәлле генә гаиләдә фани дөньяга килгәнмен. Ике яшемнән "кулак малае"на әверелеп, балчык ызбада гомер кичерүгә дучар ителгәнмен, җир идәндә ачлы-туклы көн итү нәтиҗәсендә аяксыз калганмын, әниемнең яну-көюләре, үз сүзләре белән әйткәндә, утлы күлмәк киюләре, ике бите белән җир себерүләре аркасында кабат йөреп киткәнмен. Әтиемнән киң күңеллелек, миһербанлы-шәфкатьле булу осталыгын мирас итеп алганмын да әниемнән әдәбиятка мәхәббәт вә Нәптәй галавадан ук килгән иҗади сәләтне кабул итеп, аларның варисы булып калганмын. Дүрт-биш яшемнән матур әдәбиятны укый башлап, иң әүвәл Габдулла Тукайның сабыйларга атап язган шигырьләрендәге зирәклек вә тапкырлыкка хәйран калганым, кабат-кабат укыганым хәтердә. Әле бүтән авторларны белмәс борын, Тукай бик күп язган икән, минем шигырьләргә исем дә калмагандыр инде, дип уйлап алганым истә. Әмма ул уй башымнан яшен тизлегедәй үтеп кенә китте. Гәрчә ара-тирә рифмалы юлларны тезгәләсәм дә, аларны һичбер вакыт шигырьгә санамадым. Хәтта әле университетта үзем чыгарган "Молния" гәзитендәге тезмә юлларымны да. Чөнки алар җиңел кулдан гына языла һәм энә белән кое казудан бик тә ерак иделәр. Ә менә үзем чыгарган әкиятләрне сабакташларым да, төнгелеккә ат сакларга барган малайлар да оныталып тыңлый торганнар иде.

Мин бәхетле, чөнки Толстойлар, Ленинннар укыган университетка барып кердем, филология белеме алдым, ана теленең хәтсез генә серләренә төшендем, бик күп кызыклы, гайрәтле, талантлы, уникаль шәхесләр белән аралашып яшәдем.

***

Унынчыда укыганда ук безне төрле югары уку йортларына дәшеп йөрделәр. КАИдан агитләргә килгән егет безгә бизмән теориясен тәкъдим итте: бизмәннең бер башына үзеңә ошаган һөнәрнең кулай, икенчесенә кире якларын саласың; кайсы җинә, әнә шуңа карап киләчәгеңне үз теләгең белән хәл итәсең. Ярап куйды бит миңа шул "бизмән". Аңарчы, әниемне дәвалау нияте белән, медицина институтына керергә җыенган идем; уңай һәм кире якларны бизмәнгә салгач, медик була алмаячагым ачыкланды. КАИ, КХТИ, КИСИ, Авыл хуҗалыгы институтлары калды...

Шул заманда Казанның актыккы (!) татар мәктәбеннән егетләрне үзләренә чакырырырга өлкән күрс студентлары Ибраһим Нуруллин белән Рашат Гайнанов килде. Университетның тарих-филология факультетында әле шушы елларда гына татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ачылган икән дә анда ана телен инәсеннән җебенә хәтле өйрәнәләр икән! Әдәбиятны кайсыларыгыз ныграк ярата, дип сорашкач, малайлар Вакыйф Зыятдинов белән безнең якка ымлыйлар. Шуннан китә җентеклә6рәк, төплерәк сөйләшү. Икебезгә тәгаен өмет баглап, икенче килүләрендә безнең белән генә гәп корып җибәрәләр (авыр туфраклары җиңел булсын, изге җаннар иде, һәр икесе үз мәнфәгатен кайгыртa белмәде, милләтебез өчен янып яшәде).

Университетның мәһабәт колонналары янында йөргәндә дә, озын коридорларыннан барганда да, якты бүлмәләренә курка-курка гына аяк басканда да:

—Әгәр керә алсак...

—Монда укулар насыйп булса...—дип үзара хыяллана идек.

Гәрчә ант эчмәсәк тә, һичбер вакыт шпаргалка дигән нәрсәдән файдаланмаска сүз биреште к һәм шул вәгъдәбезгә иң кыен чакларда да тугрылыклы булып калдык. Үзебез ваз кичү генә түгел, хәтта әле бер карьеристның шпаргалка ярдәмендә генә "бишле"ләр алып, Тукай исемендәге стипендиягә үрмәләгәнен, кемнәргәдер тәлинкә тотканын

комсомол җыелышында кузгаттык та чын йөзен ачып ташладык. Гомумән, икейөзлелекне кичерә белмәдек. Без яшь идек, үзебезгә куйган таләпне бүтәннәргә дә куя идек. Һәй, диваналар, намуслы булырга алай гына өйрәтеп була димени бүре баласын!..

Имтихан-зачетларга ныклап әзерләнсәм дә, ике мәртәбә күңелсез хәлгә дучар булдым шул. Беренче курсны тәмамлаганда грузин һәм белорус поэзиясеннән зачет тапшырабыз. Алган билетым икәү булып чыкканын абайлаганда, аскы билетны өстәлгә кире куйганда, профессор каттый рәвештә:

—Билетларның икесен дә куегыз. Икенче килерсез,—диде.

Гафу үтенеп торудан файда юк иде. Борылдым да чыгып киттем. Икенче көнне деканаттан профессорның телефонын алып, үзебезнең кафедрадан чылтыратам, кичә сезгә зачетын тапшыра алмаган студент, дим. Профессор өенә чакырды—Ленин бакчасы аша гына икән моның өе.

—Сөйләшүеңә караганда, бер дә алай зачет тапшыра алмаган студентка охшамагансың әле,—дип көлешеп озатып калдылар өлкән курс егетләре.

Черек күл буеннан бик тиз таптым профессор А.Н.Вознесенскийның фатирын. Кәрәкерешкә моның китапханәсендәге байлыкны күреп хәйран калдым. Нинди генә китаплар юк иде аның озын-озын киштәләрендә! "Шагыйрь китапханәсе"ндә чыккан бәп-бәләкәй китапчыклар тезмәсен иң әүвәл шунда күрдем. Өйдәгечә генә киенгән, буй-буй күлмәгенең өске сәдәфләрен каптырмаган чал чәчле, Толстойдагы сыман калын кашлы картым мине шул китап дөньясында каршысына утыртты да креслосында иркенләп кенә кырынрак киткән хәлдә:

—Йәгез, кайсы халык поэзиясен өйрәндегез инде, егетем, грузиннарнымы, белорусларнымы?—диде.

—Икесе белән дә кызыксындым,—дигән җавапны ишеткәч, картымның акчарлак канатыдай аксыл куе кашлары югары сикергәндәй тоелды.

—Шулай укмыни? Әйдәгез алайса грузин поэзиясенә күз салыйк,—диде.

Гашыйк иде поэзиягә профессор. Тегеяки бу фәнне белү бер хәл, ә менә гашыйк булу—бөтенләй икенче. Әңгәмә корып җибәргәч, үзенә тиң гашыйк дәрвишне күргәч, ихлас җанланып китте, зачет алуын да онытты. Әдәп саклап тормадым, ул туктап калуга, аның фикеренә ялгап үземнекен әйтергә ашыктым, ул арада татар шагыйрьләрен дә кыстырып җибәргәләдем. Ул аннан да хәбәрдар икән.

Тик инде китәр алдыннан гына сантыйлыгым өчен, бимазалап йөргәнем өчен профессордан гафу үтендем.

Икенче күңелсезлек тә игътибарсызлыгым аркасында килеп чыкты. СССР тарихыннан имтихан тапшырасы. Бөтен курсыбызга лекция укыган доцент үзенең кафедрасына безнең группаны беренче тапкыр чакырды. Бәләкәй генә бүлмәдә кысылышып кына утырабыз. Бу минем каршыма туктап, үзенең Вера Николаевна икәнлеген әйтте. Дәшми генә калсаң да була бит инде югыйсә, тик мин шунда шыпырт кына:

—Очень приятно,—дип ычкындырганымны сизми дә калдым.

Зифа буйлы, кырыс кыяфәтле, ярыйсы ук чибәр ханымга минем сүзләр мәсхәрә булып ишетелгән.

—Приятномы, түгелме—анысын киләсе атнада күрербез,—диде.

Эдуард Касыймов, тагын ике-өч егет иң әүвәл төркем булып керәбез. Ул чагында күзлек кимәсәм дә, күз әлләни шәйләп житкермәдеме, әллә инде игътибарсызрак булыпмы икенче билеттагы сораулар урынына беренче билетның сорауларын сайрарга тотындым. Шул ук Урарту инде ул, аермасы кечтеки генә. Әмма доцент аны абайлый бит, яхшы ук абайлый. Тыныч кына тыңлап бетерде дә, төзәтергә яки искәртергә уйламыйча да, кырыс кына тавыш белән:

—Мин сезгә "икеле" куям. Хәзер билетыгызны карагыз. Кабат тапшырачаксыз!—дип игълан итте.

Күземә якын ук китереп карасам—чынлап та икенче икән. Башымны селектем дә, ләм-мим дәшмичә, бүлмәдән чыгып киттем. Сөйләвем урынсыз булса да, үзем "икеле" алсам да, файдасы тигән бит, әй! Эдуард билетны ахырдан өйрәнә башлый иде. Бу юлы беренчеләренә килеп житәргә өлгермәгән. Үзенә нәкъ беренче билет эләккән. Бетте баш, дип кенә торганда... берәү сайрарга тотынмасынмы! Шул сөйләгәннәрне язып барып, түкми-чәчми генә кабатлап чыга да... "бишле" ала.

Икенче көнне факультетыбызга килсәм, күзем шар булды—"Сталинец" газетасының нәкъ урта бер җирендә "Куда ведет вожак" дигән саллы гына мәкалә. Доцентыбыз минем

комсорг булуымны да, сессиядә имтиханнарны кемнең ничек тапшыруын да ачыклаган, бер дә иренеп тормаган.

Шул ук көнне таптым мин моны. Партком бүлмәсендә утыра иде. Шунда ук имтихан алырга риза булды, билетларын җилпәзә рәвешендә җәеп салды. Сорауларны игътибар беләнрәк укып, шундук җавабын да биргәнемне күргәч, өстәмә сораулар яудырырга тотынды.

—Сезгә "бишле" куя алмыйм: кабат тапшырасыз,—дип белдерде.

Минем дә телемә шайтан төкергән:

—"Бишле" артыннан куучылар без түгел,—дигән булдым.

Мин бәхетле, чөнки филология белеме алганнан соң, акны карадан аера башлагач, азмы-күпме көч сынарга ниятләдем. Дөресрәге, бабамнардан килгән иҗади һәвәслек мине тезмә вә чәчмә әсәрләр язуга этәрде. Әмма шул чагында тәрҗемә китапларының җинел кулдан эшләнүенә, халтурага юл куелуына гарьләнеп, бөтен көчемне, бар сәләтемне әдәби тәрҗемәгә юнәлдердем. Әлеге өлкәдә иң әүвәл халтурага киртә кую эшенә күп көч сарыф итеп, сәләтле вә белемле яшьләрне бергә туплый алдым, иҗади хезмәтне оештырып җибәрдем, үзем дә бүтән телләрдән иң камил, аеруча гуманистик утызлап китапны тәрҗемә итеп, укучыга саф ана телендә язылган китаплардай уку мөмкинлеген тудырдым.

Мин бәхетле, чөнки дөньяда бер укымышлы халкымда сынлы сәнгать белән кызыксыну уяттым: яраткан рәссамнарымның иҗатын тәфсилләп мәкаләләр яздым, кайсыберләренә каталог ясадым, альбомнарын чыгардым, әсәрләренә багышлап хикәяләр, ә инде милли сәнгатебезгә нигез ташын салучыга багышлап "Бакый" романын иҗат итә алдым.

Ике яшемнән "кулак малае" дигән кушамат тагылды, янә дә ун елдан әтием бинахак төрмәгә эләгеп, шул гаделсезлекне күтәрә алмыйча (ат күтәрерлек куәте бар иде үзенең), фани дөнья белән бәхилләште...

Биографиямдә әнә шундый кара таплар булгач, мине Казанда үзем теләгән җиргә, әлбәттә, эшкә алмадылар. Университетны тәмамлагач, Сарман урта мәктәбенә урыс балаларына сигез-унынчы сыйныфларда урыс әдәбиятын укытырга җибәрделәр. Гәрчә университетның татар теле һәм әдәбияты кафедрасында белем алсам да, татар мәктәпләре бетүгә юл тоту сәбәпле, үз һөнәремдә эш юк иде...

Сарман якларында яшәүче урыс вә татар балаларына, бер дә авырсынмыйча, үзем гаять яхшы белгән фәннән белем бирә башладым. Укытучылар коллективында, мөгаен, беркадәр егетләнеп тә йөргәнмендер әле.

***

...Бәйрәмне яшь укытучылар бергә каршыладылар. Кыюсыз гына егетләр шәраб агын, кибеттәге күчтәнәчләрне кайгыртсалар, туташларның һәркайсы үзенең сәләтен һәм уңганлыгын күрсәтергә тырышты. Хәер, уңганлык аларның һәркайсында җитәрлек иде. Сыйларның барысын да мактап туймадылар. Кәефләр күтәрелгән саен тостлар да, җыр вә мәзәкләр дә кызыклырак була барды. Мәҗлеснең аеруча кызып җиткән бер мизгелендә музыка яңгырады, парлы биюләр башланды. Гадәттә минем күзгә фәкать берәү генә күренә торган иде. Бу юлы да нәкъ шулай булды. Үз фәнен үлеп ярата, ахирәтләре белән һәрчак тату, фидакяр холыклы, арада бер тыйнагы, җитмәсә үзе чибәр дә... Күзең төшми нишләсен. Бергә биедек үзе белән. Күзләрен болай ук якыннан күргәнем юк иде әле. Минеке шикелле кысык та, коңгырт та түгел икән, зур соры күзләре белән туп-туры ягымлы итеп, якын күреп, үз итеп караган иде—эредем дә төштем. Кая инде ул бүтәннәргә күз ату да күз кысу—барысы онытылды. Ничек тә Анның янында әвәрә килергә тырышам, Анардан күземне һич ала алмыймын. Тагын бераз бергә булыйк әле дип, озата бардым. Кыз баланың тыйнаклыгы да, төпле фикер йөртүе дә күңелләремә хуш килде.

Миңа Казаннан ара-тирә хатлар килә иде. Өйдән дә, дус-ишләремнән дә. Мәктәп халкы, рәхмәт төшкерләре, ачып каравын карамаган, шулай да, кызлар хаты күргәч, бу иптәш өйләнгән икән ич, дигән имеш-мимеш тараткан. Әлеге яңалыкны мин Анардан ишеттем:

—Сине бит өйләнгән кеше диләр, ә үзең менә мине озата барасың. Моны ничек аңларга була инде?

Караңгыда елмаюым күренмәсә дә, җинел генә җавап бирдем, башлы-күзле булырга өлгермәгәнемне, моңа хәтле берәүгә дә ячы җибәрмәгәнемне төшендердем.

Шул көннән башлап очрашулар безгә торган саен кызыграк, мәгънәлерәк, тансыграк була барды. Бер-беребезнең дәресләренә кереп йөрдек, бер үк китапларны укыдык, фикер алыштык. Сөеклемнең намуслылыгы, төпле акыл белән уйлап сөйләшүе миңа бик тә ошады.

Көннәрдән бер көнне, кичен урамнан кар ерып йөргән чагында, бу мине туктатты да күземне йомарга, кулларымны алга сузарга кушты. Нишләтә икән инде, әллә үбәме үземне, дип, сабырсызланып көтеп торганда... уң кулыма ниндидер җылы килеп бәрелде—кәҗә мамыгының җылысы гына түгел иде бу, йөрәк җылысы, җан җылысы, мине кайгырту иде. Бичаракаем, ялан кул йөрүемне күреп, мине бияләйле итәргә ниятләгән—кай арада кәҗә мамыгы табып, аны эрләп, үз кулы белән бияләй бәйләп, үзе минем кулларыма кигезү ягын караган.

Күңелләрем тәмам эреп китте. Гәрчә бияләй дигән нәрсәне, була торып та, гомер эчендә бер кимәсәм дә, җирәнсу кәҗә мамыгыннан сөеклем үз кулы белән махсус минем өчен бәйләгән әлеге бияләйне кесәмдә йөртә торган булдым—һәрчак Аның күңел җылысын тоеп йөрдем.

Хикмәт бияләйдә генә түгел иде, әлбәттә. Хикмәт минем белән бергә яшь буынны тәрбияләүче, күзем төшкән берәүнең фәкать үзе өчен генә яшәмичә, бүтәннәр мәнфәгатен кайгыртып яшәвен сиземләвемдә булып чыкты. Өстәвенә һәркайсыбыз эгоист бит әле. Миндә, мөгаен, бик көчледер әлеге хис. Чит-ят җирдә үзем өчен әрнеп, кулымны да туңдырмаска, җанымны да җылытырга, миңа изгелек кылырга талпынып яшәүче асыл затның булуы күңелемдәге ташны эретеп җибәргәндер—йөземә елмаю иңде.

Бер-беребезнең дәресләренә кереп йөрү дә сөеклемнең холкын һәм үз эшенә булган мөнәсәбәтен өйрәнү өчен файдалы булып чыкты. Бер-беребезгә каты бәрелмәскә тырышып кына, дәрестә үзебезнең карашка җитешсезлек булып күренгән вагын-төяген уртага салып сөйләшә торган булдык. Тарихтан да, әдәбияттан да.

Әмма дәрестә яисә укытучылар бүлмәсендә күрү генә җитми башлады. Кичләрен күрешә торган булдык. Ара-тирә әңгәмә белән мавыгып, сөеклеңнән аерылып китмәү теләге шактый озак йөртә икән. Карлы юлдан ашыкмыйча гына атлый-атлый күрше авылга җиткән чакларыбыз да булгалады. Бүредән-фәлән сагаю дигән нәрсә һич уебызга да килмәде. Кайту юлына борылырга да бик ашыкмадык, чөнки сүзебез бетәрлек түгел, бергә булулары гаҗәеп рәхәтлек бирә иде.

Әнә шул әңгәмәләрдән без бер-беребезнең кайларда туганын да, шуннан бирле нинди сөенечләр кичергәнен дә, ниндирәк фаҗигаләр күргәнен дә белә идек инде. Ленинград, Псков, Новгород өлкәләренә фашистлар бик тиз килеп җиткәннәр. Товар поездына төялеп, көнчыгыш ягына агылучы совет халкын юл буе эзәрлекләп килгәннәр. Ә бервакыт ике нәни кыз туган, ниндидер станциядә самолетлар ташлаган бомбалар гөрселдәвеннән качып урман эченә шактый ерак кереп күздән югала. Әниләре көч-хәл белән эзләп таба үзләрен. Поездларына да көчкә өлгерәләр. Атна-ун көн шулай килә торгач, Татарстан җиренә дә җитәләр, Лениногорск районының Куваково дигән урыс авылына урнашалар. Өлкәнрәк балалар мәктәптә укуларын дәвам иттерә, бәләкәйрәкләре балалар бакчасына йөри. Авыл халкын да, бала-чаганы да, әйләнә-тирәдәге табигатьне дә мактап туя алмавы күңелемне бигрәк җилкендерде. Безнең авылда халык бераз кырысрак, минем ишеләрендә усаллык та хәттин ашкан, шуңа күрә сөеклемнең шултикле дә кече күңелле булуына сөенеп бетә алмадым.

Аның миңа уңай тәэсире әнә шул беренче ел танышлыгыбыздан ук башлангандыр. Элек миндә, ни генә әйтсәң дә, Кече Чынлыда гомер буе хөкем сөргән гадәтләр яшәп килә иде әле. Әйтик, берәү миңа нинди дә булса этлек эшли икән—ул инде миннән рәхим-шәфкать дигән нәрсә көтмәсен. Үч алмасам да, аңарга һичбер вакыт ачык чырай күрсәтми идем. Хәзер мин аларны оныту, игътибарсыз калдыру юлына бастым. Әллә бар андый кеше минем өчен, әллә юк... Мәктәптәге эшемдә дә үзгәрешләр була торды. Элек мин укучыларга карата чамасыз таләпчән идем—аларны зур укымышлы итәргә тырыштым. Әйтик, дәреслектә берәр язучыга бирелгән характеристиканы үзләштерү белән генә канәгатьләнмичә, әдипнең әсәрләрен укып чыгуны, характеристиканы шуңа таянып, бөтен иҗатына бирүне, ягъни үзләре аңлаганча, мөмкин кадәр тулырак бәяләүне таләп итә идем. Тора-бара таләпләремне укучыларның мөмкинлекләренә яраклаштыру ягына авыштым, аларның акыл шәрифләре әле ныгып җитмәгәне, яңа материалны, бөтенләй чит мәгълүматны үзләштерү, аны ахырынача аңлау чамасы чикле икәне белән исәпләшүне кулай таптым.

Бала-чага белән без әвәрә килгән арада көннәр язга авышты. Мәктәп гөрләп яшәде. Укучылар белән дуслык ныгыганнан-ныгый барды. Мәктәпкә яшьлек дәрте алып килгән яшь укытучылар нинди генә кызыклы кичәләр оештырмадылар да нинди генә фәннән укучыларга кыйммәтле мәгълүмат бирмәделәр!

Табигатьтәге язгы җанлану безгә дә гаять нык тәэсир итте, хисләребезнең бөреләнеп-дөрләп китүенә сәбәпче булды. Аның белән без торган саен бер-беребезгә ныграк якынайдык, күрешмичә генә бер көн дә яши алмый торган булып киттек, ихлас нык беректек. Серләребез мәктәпнең көндәлек тормышына, укучыларыбызның хыялга бай булуына, әллә нинди маҗаралар уйлап чыгаруына, мәзәк хәлләргә бәйләнгән булыр иде. Көннәр җылыткач, Минзәлә суы буенда йөри торган булдык, ямь-яшел чирәмгә ятып китап укыдык. Бер-беребезнең нindирәк әсәрләр белән кызыксынуы инде сер түгел иде. Хәер, дөньяга карашыбыз да бик тәңгәл киләдер шикелле иде. Югыйсә киләчәккә хыялый планнар корып, аларны гамәлгә бергә-бергә ашырырга ниятләп яши дә алмаган булыр идек. Мәгәр кавышуга һәркайсыбыз ирекле рәвештә килергә, хәзердән үк бер-беребезгә бәйле булып, мәҗбүрият аркасында гына өйләнешергә тиеш түгел идек. Нәфесемә буйсынып, бүгеннән үк сөеклемне үземнеке итәргә, кыз баланы рәнҗетергә һич уйламадым да. Ничектер егетлек миңа яраткан кызымны җиңү, аның каршылыгын сындырып, үз дигәнемә ирешү, буйсындыру сыйфатында килмәде, андый нәрсә уема да кермәде. Әллә әниемнең: "Кыз бала чәчәк шикелле, аның чәчәген өзсәң, ул бүтән беркайчан да чәчәк атмый, гомерлек бәлагә тара, бик тиз шиңә. Рәнҗетәсе булма кыз баланы!"—дигәне канга сеңгән иде инде, әллә үз нәфесемә үзем хуҗа булырдай көч вә кодрәтне егетлеккә санадым микән?..

Бер-беребездән башка яши алмаячагыбызны аңлагач, көзен кавышырга вәгъдәләшеп, җәйге каникулга икебез ике якка юнәлдек. Аның әтисе агроном кеше, һәм аларның гаиләләре әлегә җөмһүриятнең бер төбәгендә авылда яшәп ята иде. Сөеклем башта алар янына кайтып, аннан апаларына Кишиневка сәфәр чыгарга нияте барын әйтте.

Ай-һай, авырга килде аңардан башка гына яшәгән көннәрем! Искиткеч озын, кояшсыз, мәгънәсез булып тоелды һәр көнем. Өйдә кулым эшкә ятмады, күземә беркем күренмәде, ашаганым аш булмады, укыганым вә иҗади казгануым мәгънәсен югалтты... Аның янына Сарманга ашкындым.

Егерменче августта язгы сынауларын тапшырып бетерә алмаган укучылардан көзге сынауларны алдым. Бер урыс малае истә калган. Женя исемле ул малайның әтисе тимерче булып татар авылында эшли икән дә, шунда яшәгән балалар үз телләрен өйрәнә алмыйча иза чигәләр икән. Женя җәй буе күп укыган, шул әсәрләрне сөйли алды, язып та күрсәтте—алга китүенә сөенеп, "дүртле" куйдым үзенә.

Сынауларыбыз тәмамлангач, вәгъдәләшкәнебезчә, мәктәп янындагы ЗАГСка сугылып, язылыштык. Хатыным буласы заттан:

—Нинди фамилиядә буласыз?—дип сорагач, ул ике дә уйламыйча:

—Әлбәттә, Миңлебаева,—дип җавап кайтарды. Аның бу сүзләре йөрәгемә, әлбәттә, май булып ятты.

Өйләнешүен өйләнештек тә бит, әмма бергә-бергә яшәү өчен безнең урыныбыз юк иде. Ул елларда Сарман халкы читтән килгән яшьләрне өйдәшкә үзләренә кертергә бик алай атлыгып тормый иде. Шуңа күрә, язылышканнан соң да әле, рәсми төстә ир белән хатын саналсак та, яшәү өчен фатир эзләп, чын-чынлап кавыша алмыйча атна буе иза чиктек.

Аптырагач-йөдәгәч, хәләлем әлегә хәтле яшәгән Гәтүф абзый белән Шәмсениса апаларның таштан салынган иләмсез зур амбарларында кышка хәтле яшәп торырга ниятләдек. Кая анда "кызыл туй"лар үткәрү, яшьләрнең киләчәген кайгырту! Бердәнбер кайгыртучы кешебез Шәмсениса апа булып, ул гына, мескенкәем, без ятасы урын-җиргә ширпылар салып йөргән. Миндәге дәрт, әлхәмделилла, ширпысыз да җитәрлек иде - сөеклемне назлауның чиге-чамасы булмады, ахры. Үземә хәтле, ягъни зөфаф киченәчә беркемнең кулы тимәгән кыз баланы гаилә тормышына күнектерү әнә шундый кыен шартларда башланды. Дөресен әйткәндә, иләмсез зур таш амбарның кияү келәтенә әверелеп китүенә бердәнбер сөенүче кеше булса, ул, һичшиксез, мин идем.

Укытучыларның август конференциясенә без йокысыз төннән соң култыклашып барып кердек, дусларыбыз янына утырыштык. Дөнья фәкать безнең үзебез өчен генә үзгәрде. Хәзер инде яратышып йөргән һәм кичләрен сәгатьләр буе озатышкан, бер-беренә омтылган ике яшь йөрәк гаилә корып җибәрде, үзара чүкердәшеп-сөешеп яшәү өчен

рәсми рәвештә хокук алды. Әмма безнең кушылуыбызга бик сирәк кеше сөендә шикелле. Ихтимал, берәребезгә тагын да гашыйк булып, үзләренчә план корып йөрүчеләр булгандыр, андыйлары көнләшеп карагандыр; янә дә җирле халык үзләренә эшкә килгән укымышлы вә актив татар егетенең Ленинград ягыннан чыккан бер марҗа кызын сайлап алуына гарьләнгәндер; ә инде шунда яшәүче урысы-чуашы әлеге чибәркәйгә өйләнү өчен үзен лаеклырак санагандыр. Аннары тагын моңарчы тыныч кына кукыраеп утырган кырмыска оясына таяк тыгып бутаучы егет үзләрендә гомерлеккә төпләнеп калыр да майлырак калҗа даулар—теге яки бу җаваплы һәм дәрәҗәле креслога дәгъва кылыр, диебрәк фикер йөрткәндер, холкымны да, кыяфәтемне дә әлләни өнәп бетермәгәндер...

Иҗат кешесенең көен көйләп, җаена барып гомер кичерүләре, ипле генә дөнья алып барулары, ай-һай ла, берәүгә дә җиңел түгелдер. Чөнки әдип таң тишегеннән торып, кәгазьләренә күмелеп утырудан гайре берни белми, өй эшләренә, йортны алып бару мәшәкатьләренә катнашмау ягын карый. Чөнки шунсыз гына, унга ярылып кына китап язылмый. Гаиләдә, мөгаен, иренең иҗатка булган сәләтенә мөкиббән китүче, аңа кадәри хәл ярдәм күрсәтергә омтылучы асыл зат кына ирне ир итеп, аны зур фәкыйрьлектә дә ихлас яратып, аның, дөньядагы күп нәрсәгә битараф калган хәлдә, башы-аягы белән иҗат эшенә чумуын хөрмәтләп яшәргә сәләтледер. Ә инде тылың нык булганда—иҗатың да саллы була.

Эгоистлык хисе һәркайсыбызда бар инде ул, бар. Шуның аркасында без еш кына үз гаебебезне бүтәннәргә сылтыйбыз. Хәтта әле бәхетсезлеккә дучар ителгән очракта да моның сәбәпләрен читтән эзләргә тырышабыз.

Әйтик, бер кыз белән бер егет яратышып-сөешеп йөриләр, без барыбер өйләнешәбез инде, бер-беребездән башка яши алмыйбыз дип, язылышмаган-нитмәгән көе генә... кавышалар. Бала тугач кына, боларның мөнәсәбәтенә ачыклык керә. Егетебез, сөеклесе һич тә көтмәгән сүзләрне тезепме-тезә:

—Әни виноват, ул бит миңа татаркага өйләнмәскә куша...

Үзен гаепле санамый әлеге әтәч, анасына сылтый гаепне. Гомер буе шулай кыланачак эгоист "егет", үзенең бәхетсезлеген кемгә дә булса сылаячак. Ә соң сөеклесен кочканда, аның чәчкәсен батыраеп умырып өзгәндә, аны адәм рисвае иткәндә нәрсә уйлаган? Башына тай типмәгәндер ләбаса!.. Теге чакта егетләнгәч, ахыргача егет булып кал инде! Аның татар кызы икәнен бүген күрмәгәнсең бит! Милләтен яшереп, мин чегән яки чуаш, урыс яки яһүд кызы, дип сине алдап йөрмәгәндер ләбаса! Элегрәк нәрсә уйладың, кыз баланың чәчкәсен өзгәнче? Аны "ялгыз ана" язмышына дучар иткәнче?

Ә гөнаһсыз сабыегызның нинди гаебе бар, нишләп ул "атасыз", "җилдән туган", урам малае булып үсәргә тиеш әле? "Сөйгән" ярың белән кавышканчы һәммәкиен уйлыйсыларың бар иде. Ташың кызган чагында чамасыз кыю, тәвәккәл вә дәртле егет булгансың икән, берәү дә үзеңне көч белән түшәккә сузып салмаган икән, син инде үз сүзеңдә нык тор, егет булып кала бир, чүпрәк булма. Әниеңә дә, бүтән берәүгә дә түгел, синең үзеңә (!) гомер итәсе бит сөеклең белән. Хәер, әниең сүзеннән чыкмый торган тәти егет икәнсең инде, ул чагында һич югы ана сүзенә колак сал, аңарга ахыргача тугрылыклы булып кал. Бер генә ананың да үз малаена: кызларны адым саен мәсхәрәлә, ана эт хәленә төшер, авыл яки шәһәр буена балаларыңны чәчеп йөр, димәячәгенә иманым камил. Андый тәрбияле-тәүфыйклы зат икәнсең инде, кыз баланы рәнҗетмә, узынма, нәфесеңне тыя бел!

Халык телендә шундый бер мәзәк бар. Имештер, агалы-энеле ике егет алпавыт кызына гашыйк була. Чынлап та хәйран чибәр, зифа буйлы, нечкә билле, алтынсу чәчле житү кыз икән. Бер кашык сусыз да кабып йотарлык кыз икән. Тегеләй-болай гына кулга төшерерлек түгел дә түгел инде. Егетләрнең олырагы, хискә бирелеп, өйләнергә ниятли. Нечкәбилгә сиздерә бу: тәк тә тәк, өйләнәм мин сиңа, барыбер үземнеке итәм, ди икән. Мондый тәкъдимне ишеткәч тә, бик үк егылып төшми асыл зат. Каршы да һичбер сүз әйтми. Әмма үзенең бердәнбер катгый шартын куя:

—Синдәй пәһлеванга яр булырга ризасын риза да бит, мин фәкать чиркәүдә никах укытмыйча берәүгә дә кияүгә чыкмаячакмын,—дип игълан итә.

Мөселман егеткәебез уйга кала. Моның көймәсе комга терәлгәнне сизеп алган энекәше:

—Абый, чукынасыңмы инде, юкмы? Син чукынмасаң, үзем чукынам!—ди икән...

Хәер, безнең заманнарда да булгалый ул ара-тирә мәзәк хәлләр.

Юньле генә бакча күршеләрем бар иде. Ире татар, хатыны марҗа. Яшь чакларында икесе дә комсомол эшендә активлык күрсәтеп, болар икесе дә партиягә керәләр. Белемнәре

урта мәктәп чамасында. Боларның икесен дә Югары партия мәктәбенә җибәрәләр. Украинадан килгән кыз белән Татарстанда туган егет шунда танышып, дуслашып китәләр. Өйләнешәләр болар. Эшкә безнең Казанга кайталар. Ире партиянең өлкә комитетында эшли. Хатыны—райкомда. Шул арада читтән торып укырга да керә. Диплом алган чагында райкомның идеология секретаре креслосында утыра. Партия эше бирәүгә дә мәңгелек түгел, читтән торып, ерактан гына колак салып "белем алган", әмма ышанычлы кадр буларак, ул ханымны зур гына бер мәктәпкә директор итеп билгелиләр. Бу инде яшь буынны тырышып-тырышып нәкъ марксизм-ленинизм рухында тәрбияли, бүтән төрле юл юк. Боларның ике балалары шул ук коммунистик рухта тәрбияләнә.

Беребез дә мәңгелек түгел. Күрше ир-ат авырып түшәккә егыла. Ул арада, авырмыйча-нитмичә генә, көтмәгәндә моның хатыны үлеп китә...

Элеккеге райком секретаре, мәктәп директоры булган марҗа ханымны җирләгәндә, аларның обком йорты ихаталарында поп күрсәм, гаҗәпсенер идем. Ә инде мулла күргәч—егылыплар китә яздым. Ничек була инде бу, ә? Бердән, камун, ана камун, икенчедән, марҗа...

Коммунист апаларын күмәргә ерак юллар, күп михнәтләр чигеп, энеләре дә килгән иде. Шуларның өсләренә карап, бәгырьләрем әрнеде: әгәр шунда җир ярылса, ике дә уйламыйча, баштүбән атыныырлар иде сыман тоелды...

Ислам диненә камун марҗадан ни файда? Үз диненә-партиясенә хыянәт итеп, үзе шулай теләгәнме, әллә ире, үз белдеге белән, әүвәл тәредән урак-чүкеч, аннары ай чүкеп ясаганмы?.. Һәрхәлдә, гайре табигый кыланышның беркемгә кирәге юклыгына иманым камил. Исән чакта яхшы торсыннар, гадел вә тату гомер кичерсеннәр. Бүтән дингә күчеп, бигрәк тә бакый дөньяга киткәч, кеше көлдермәсеннәр иде кана!..

Моннан бер утыз-кырык ел элегрәк Татарстан китап нәшриятында Наташа дигән асыл зат эшләде. Безнең тату коллективта эшләүче фидакяр чибәрләр арасында да әлеге кыз бала үзенең мөлаемлеге, миһербанлы-шәфкатьле булуы белән аерылып тора иде. Нәшриятның үзендә өйләнмәгән егетләр санаулы гына калган булып, шуларның берсе, татар егете, моңа гашыйк иде. Аларның дуслашып китүләре нәшрият халкын сөендерә, үзләрен исә иҗади рухландыра, тагын да сөйкемлерәк итә иде. Тик менә өйләнешү мәсьәләсен хәл иткәндә... чибәр егетебез мәхәббәтен истән чыгарып җибәрде—гаиләне искиткеч матур татар кызы белән корып җибәрде. Наташабыз, әлбәттә, авыр кичергәндер әлеге хыянәтне, әмма бирешмәде. Эшендә әледән-әле берәр баскычка югарырак күтәрелеп, берзаман нәшриятның баш бухгалтеры булып китте. Алтын җирдә ятмый, диләр бит, моңа да тормыш итү өчен юлдаш табылды. Тик менә, кызганыч ки, әлләни озак бергә тора алмадылар—сөйкемле зат кыска гомерле булды. Наташаны искә алу мәҗлесендә ахирәте аның ире әйткән сүзләрне безгә җиткерде:

"Аптырыйм инде мин сезгә, әллә сезнең коллективыгыз артык әйбәт, әллә минем Наташам әүлия (святая) булган?!"

Әйе, коллективны әнә шундый әүлиялар, ягъни бүтәннәр мәнфәгатен кайгыртып яшәүче изге җаннар тәшкил итә. Андыйларның, аеруча тыйнак затларның кадерен белү һәркем өчен зарур. Ә менә аның кадерен белмәгән, милләттәшенә өйләнгән чибәр егетебез соңрак аңлады бугай үзенең хатасын: күңел төшенкелеге һәм үкенү аны эчүгә сабыштырды, гаиләсе таркалды... Бик кызганыч һәм гыйбрәтле хәл.

Явыз Иван гаскәрләре Казанны яулап алганнан соң нәсари-христианнар барлык мөселманнарны да чукындырып бетерергә өметләнәләр. Шушы олуг фаҗига аркасында татар халкы дин ягыннан икегә бүленеп кала шул, кала...

Әнә шундый олуг фаҗигане белгән хәлдә, һич кенә дә бүгенге көндә бер диннән икенчесенә күчүне хуплый алмыймын. Ә бар андый хәлләр, булгалый тора. Нәсари егетенең Чечнядә ислам диненә чыгуы минем өчен мөселманның чукынуы белән бер. Аның чып-чын тияр бәясе—үз халкына хыянәт итү, ягъни ата-баба диненнән ваз кичү дигән сүз, аларны сату дигән сүз.

Гәрчә без ике динне тотучы ике милләтнең вәкилләре буларак гаилә корып җибәрсәк тә, һәркайсыбыз үз динендә, үз милләтендә калды, үз телендә сөйләште. Безнең никахлашуыбыз ахирәт өчен түгел, бүгенге көндә бер-беребезгә ярдәмләшеп, хөрмәт итеп яшәү-көн итү өчен, рухи яктан бердәм, күңелгә якын зат белән бергә-бергә дөнья алып бару иде, тормыш кыенлыкларын җиңеп, халыкка тугрылык белән хезмәт итү иде.

Улыбызга бер яшь тулганда, хәләлемнең әтиләренә кунакка барырга ниятләдек. Башка чыгып, кеше өендә өйләштә яшәү тәмам җелегебезгә үтте. Дәрвишләр калавылыннан

килеп минем әнигә бездә яшәү һич мөмкин түгел иде: бердән, ишексез-нисез бүлмәбездә җәелергә түгел, борылырга да урын юк; икенчедән, алтмышның аргы ягына авышкан, йөрәк авыруыннан һич арына алмаган әбкәенә терекөмештәй тиктормас малайны карарга-тәрбияләргә әллә нидә бер тапшырып булса да, айлар-еллар буена даими рәвештә аңардан карату башыбызга да кермәде.

Хәләлемнең әнисе минем әнидән ун-унбиш яшькә яшьрәк, әле әукатлырак иде, шуңа күрә улыбызны беразга, фатир хәлләре җайланганчы, аларда калдырып тормабызмы, дигән исәп тә бар иде.

Әтисенең һөнәре игенчелек булып, сугышка чаклы Псков, Новгород, Ленинград төбәгендә агроном булып эшләгән, яңа сортлар чыгару белән мавыккан. Сугыш башланган көнне үк фронтка алынып, сугыштан соң турыдан-туры безнең якларда яшәп ятучы гаиләсе янына килеп, биш-ун ел Мамадыш районында колхоз рәисе була да, үз якларын сагынып, шунда кайтып, йорт салып җибәрә.

Ул тарафларга якынлаша барган саен карчыгымны нидер борчый башлаганын абайладым. Берни сизмәгәнгә салышып, кызыксынудан тыелып калдым, сабыр иттем. Үзен ниләр борчыганын ул үзе әйтеп бирде:

—Беләсеңме, безнең якларда гомер-гомергә, әнә татар килә, дип котлары алынып яши халык.

—Бала-чаганы куркытуларыдыр инде,—дигән булам, бер дә исем китмәгәндәй кыланам.

—Юк шул менә! Яше-карты дер калтырый!—ди карчыгым. Шуннан беравык тынып тора. Мине рәнҗетмәстәй сүзләр эзлидер, мөгаен. Киреләнеп маташкан малаен үгетләгән кыяфәт белән чынлап та үгетләү тонына күчә:—Нишләптер килеп җитмәгәннәр безгә татар-монголлар. Син бу якларга беренче булып аяк баскан татар кешесе. Үзеңне күрергә килсәләр, бер дә гаҗәпләнмә,—ди.

Хәер, "аю биеткәнне" күрергә дип махсус килүчеләр булмады. Халык арасына үзебез чыгып йөрдек. Бөтен әйләнә-тирәне айкадык, туган-тумачаларын күрдек. Алай берсе дә әлләни шаккатмады, чукындырырга маташучылар да күренмәде.

Әйе, бүгенге күзлектән караганда, безнең өйләнешүебез милли хиссияткә турыдан-туры хыянәт итү буларак бәяләнергә тиештер. Ә менә ярты гасыр элегрәк, Советлар Союзының күпмилләтле халыклары арасында әнә шундый катнаш никахлар тулып ята, гадәти бер хәл иде. Мин дә, гап-гади бер укытучы, бүтәннәрдән бернием белән дә аерылып тормаганмын. Тик инде бүген, дөньялар бик нык үзгәргәч, үземне совет идеологиясенең шул замандагы корбаны санасам, картаеп беткәч, беркемгә кирәгем калмагач, никах яңартам дип, тилереп йөри башласам, бу инде яңа хата булыр иде. Нәкъ менә әле күптән түгел генә дингә каршы лекцияләр укып йөргән атеистларның бүгенге милли сәясәткә яраклашу максаты белән, башларына кәләпүш киеп, салган баштан мәчеткә йөрүләре кебегрәк, фәкать күз буяу өчен генә, тәти егет булып күренергә, чын йөзеңне яшерергә маташу сыманрак килеп чыгар иде.

Миңа калса, идеология (дин яки партия) артык зур һәм гаугалы нәрсә, өйләнешү исә һәркемнең бәп-бәләкәй шәхси эшедер. Без икебез дә комсомол идек, аннары партиягә кердек, дини мәсьәләләрдән ерак тора идек. Ислам диненә дә, нәсари диненә дә ата-бабалар тоткан диннәр дип карадык һәм берсенә дә сүз тидермәдек. Әмма файда да китермәдек...

Туксанын тутырганнан соң кабат (илле-алтмыш ел коммунист булып йөргәннән соң) ислам диненә кайткан олуг акыл иясе һәм әдибебез миннән ни өчен марҗа кызына өйләнүемне сораштырды. (Коммунист чагында түгел, янә ислам диненә кайткач!) Аңа хөрмәтемне саклаган хәлдә, 1948 елгы хәлләрне сөйләп бирдем. Ул чакларда кыз балалар белән ир балалар бергә укымый иделәр. Уникенче мәктәп (бердәнбер татар малайлар мәктәбе!) укучылары сиксәненче мәктәп кызлары белән дуслашып алдык.

Көннәрдән бер көнне, алар соңгы имтиханнарын тапшырып ятканда, кызларның чәч толымнарына әбиләре гарәпчә язган бөти белән үзләре әзерләгән шпаргалканы икесен бергә яшереп йөргәннәре мәгълүм булды. Комсомол кызларның әбиләре язып биргән бөтиләрне чәч толымнарында йөртү факты гайрәтемне бик тә чигергәнен сөйләп биргәч, аксакалым сабыр гына елмаеп куйды:

—Алайса, син бик кызыл комсомол булгансың инде,—диде.

Әйе, чынлап та, шулай булганмын. Ихтимал, икейөзлелекне дә шул чакларда ук өнәп бетермәгәнмендер, комсомол дип койрык болгап йөрүләрен һич гафу итмәгәнмен. Үзем

исә комсомолга да, партиягә дә ихлас күңелдән ышанып кергәнмен, илгә һәм халкыма күбрәк файда китерим дип тырышып, актив рәвештә фидакяр эш күрсәтеп йөргәнмен, гомеремдә дә аумакайлыкка бирелеп, күз буяу-алдашу белән мавыкмаганмын.

Бу озын гомердә шактый китап укылды: татар әдәбиятының рөхсәт ителгәне дә, вакытлыча тыелып торганы да, шулай ук урыс әдәбияты белән дөнья әдәбиятының да үзем кирәк дип тапканнары читтә калмады.

Университетта укыган чакны стипендия акчама китап алганны күреп, сабакташларым:

—Тиле таш җыя, Кыям китап җыя,—дип көләләр иде үземнән.

Беренче курста ук А.И.Герценнең "Күргәнем-уйларым" ("Былое и думы") дигән кирпеч хәтле китабын күтәреп йөргәнемнән дә көлделәр. Биш-ун минут буш вакытым табылган саен укыган әнә шул гаҗәеп дәрәҗәдәге гыйбрәтле китаптан бер фикер илле ел буена хәтеремә сеңеп калган: ир белән хатын бер үк мохиттан булмаган очракта аларның үзара мөнәсәбәтләре хакында фикер йөрткәндә, автор, ашап-эчкәннән соң йокларга бик иртә ятсаң да, ул арада хәйран күп вакыт кала, аралашасы була, шунда хатын сине ызгыш-талаш, гайбәт-җәнҗал сазлыгына кертеп батыра, ди.

Бакчадамы-юлдамы, кунактамы-өйдәме хәләлем белән аралашу гомерем буе җан рәхәте булды. Аның эрудициясе дә, миңа калса, житеп ашкан, дөнья хәлләрен аңлавы да минекенә тәңгәл килә, фидакярлеге үземне сөендерә, хөсетлек чире икебезгә дә чит нәрсә. Бер-беребезнең вак-төяк кимчелеген күреп-кичереп, дорфа бәрелмәскә тырышып, сабырлык белән, тату гына картларча яшәп яткан көнебез...

Күп кешенең яше житкәч кырыкка... дип мәзәк итеп кенә сөйләүләредер. Чөнки берәр айдан илле туласы чакта булып узган хәлне һич онытасыларым юк.

Улыбыз кичтән дусларына куна китте: янәсе, военкага шуннан якын. Аулак өйдә күңел өчен генә, аз-маз гына укып яткандай булдык та бик тәмләп кенә, жиренә житкереп кенә назланыштык соң.

Иртән уянып китсәм—аулак өй бит!

Көлә минем чибәркәем:

—Кичә көне буе сайлауда булдым, монда изге эшем калган, бүген барып тормам инде, дип мөдиренә чылтырат, ичмасам,—дигән була.

Хәер, госел коенганнан соң, күтәренке күңел белән, хәзер килеп житәрмен, дип кенә хәбәр бирдем мөдиргә. Кәефләрем көне буе әйбәт булды, тау чаклы эшләр эшләнде.

Җанга тансык зат олыгаерга ирек бирми шул: син һаман яшь, һаман дәртле!

Иллене узгач әйткән кискенрәк сүзләрем искә төште әле. Шулай кичке наздан соң минем тетелеп йоклап киткәнемне күреп, үзенең чибәрлегенә һәм кодрәтенә сөенеп бетә алмый бәгырькәем. Менә күңеле булды газиземнең, ичмаса иртән үземне йокыдан уятмас, бимазаламас, дип йокы симертергә хыяллана. Чынлап та иртәнге якта ике-өч сәгать эшләп утырдым, тик инде Аның уянганын күңелем сизеп, тизрәк җылы юрган астына чумдым. Уяулы-йокылы берәүнең:

—Әллә бүген иртән ял итәсеңме дип уйлаган идем, мин дә бераз ял итмәкче идем мәхәббәттән...—дигәнен һич кабул итәсем юк иде.

—Шаярма әле, кызыкай, мин үлгәч, ял итәрсең!—дип ябырылдым.

Хәер, сөеклем дә бик тиз уянып житте—җан керде үзенә, бер дә иренмәде. Һәй, тилелек димә инде: эшкә тәки соңардым бит!..

Шундый хәлләр дә булгалады, дөнья булгач. Хәзер инде сагынып сөйләргә генә калды... Бер уйлап карасаң, эшкә дә чабасы түгел сигезенче дистәдә, рәхәтләнеп назлар-сөешер идең, һич югы, икең ике бүлмәдә йоклаганда, бүрекләр генә булса да бәрешер идең кана—юк шул, юк, ирендерә бит...

"Һәрнәрсәнең үз вакыт бар!"—дип бер дә белмичә әйтмәгән икән теге яшь укытучы... моннан ярты гасыр элек.

Хәер, аптырарга урының юк, һич тә: бөек шәхесләр булынмаган, дәрәҗәгә ирешү максат итеп куелмаган, кадәри хәл,—икешәр смена,—эшләнелгән, бар булганына шөкрана кылып гомер кичелгән, ашыйм дисәң—ашың, киим дисәң—киемең булган хәлдә, иртәгәге көнгә зур ышаныч баглап яшәлгән. Җүләр сатмыйча гына түгел, гомумән, берәүне дә сатмыйча, киресенчә, кешеләргә рухи байлык бирергә, ә инде яшь буынга белем бирергә ихлас тырышылган. Максатыңа ни дәрәҗәдә ирешелгәндер инде—анысы икенче мәсьәлә. Чөнки дөнья үзе син дигәнчә генә бармый, күп кенә төшенчәләр әледән-әле үзгәрә тора, кичәге исәбең бүгенгә әле тартып-сузып яраса да, иртәгә инде, әлбәттә, ярамый, рецепт белән яшәү мөмкин түгел, һич юк.

Яшь буын күп мәсьәләне үзенчә хәл итәчәк, үз көнен үзе күрәчәк, һич аптырыйсы түгел ничек яшәрләр дип, чөнки алар бездән көчлерәк тә зиһенлерәк, укымышлырак та акыллырак...

***

Бу арада бәйрәмнәр озаккарак сузылды. Улым белән Дәрвишләр калавылына барып кайттык—анда апама эшкә ярадык. Сынлы сәнгать музеенда көтеп торганнар. Алардан соң эшкә, энциклопедиягә сугылдым. Урманче музееннан ул арада халык качып өлгергән иде. Гәрчә Вакыйфны атна саен күрсәм дә, өйләренә барып чыгарга вәгъдәләштек. Хатыннар үзара чөкердәште, без шахмат уйнаштырдык. Миңленурның кәефе һәм кыяфәте алай артык зарланырлык тоелмады. Сыйлап йөргәндәй иттерде, елмайды, сабыр гына көлгәләп тә алды. Хәтергә килгәндә... һәммәбездә хәтәр инде ул хәтер хәлләре... Кичәле-бүгенле хәлләрне һич исемдә тота алмыймын. Фәкать сабый чаклар, балигъ булуым, кавышу-никахлашу еллары—шундый да ачык буяуларда, зур камиллек дәрәҗәсендә, һәммә детальләренә хәтле исемдә.

Көннәрдән бер көнне шулай кечкенә якта хәләлем белән икәүдән-икәү кәрт сугып, телевизор караштырып, сыйланып утырабыз. Бермәлне ничектер күңел нечкәреп китте дә, сөеклемә караган көе, көлеп җибәрдем.

—Нәрсәдән болай рәхәтләнеп көләсең әле?—ди.

—Беләсеңме, газизем, сиңа бит мин илле елга дип өйләнмәгән идем. Бер ун-унбиш, күп булса егерме елга дип кенә өйләндем. Шул арада бергә булсак, бәхет диңгезендә йөзәрмен, дигән идем. Шуннан да артык яшәү һич хыялыма килмәгән иде, газизем... Гомеркәйләребез шактый озакка сузылды ла!

Күңелем торган саен нечкәрә, бугазыма төен утыра, ул арада күз төпләрем тәмам дымлана.

—Беләсеңме, кырык-илле елдан соң да, миңа бүген дә, синең өсләреңә каравы, самими кыяфәтләреңне күрүләре күңелле, әйтеп бетергесез күңелле. Бәхет дигән серле нәрсә, мөгаен, нәкъ әнә шулдыр. Ихлас күңелдән сөену үзе бәхеттер. Минем моңа иманым камил!

—Дускаем, син шулай да татар кызына өйләнергә тиеш булгансың. Мин синең мәдәни үсешеңә азмы-күпме тоткарлык ясадым. Үз милләтеңдәге берәр кызга өйләнгән булсаң, юл киңрәк ачылыр иде...

—Мин бит урыс милләтенә өйләнмәдем, үзем яраткан кызны сайлап алдым. Нинди генә милләттән булсаң да, нәкъ менә сине сайлар идем. Өйләнешүебез дөрес булган. Ярты гасыр бергә яшәгәннән соң да үкенмимен, һич юк!

Әйе, гаилә корып җибәргәч тә бер-береңә хөрмәт саклап, яратышып-аңлашып, бер-береңне һәрчак тансыклап яшәүгә ни җитә!

Дөрес аңласын иде укучым. Татар кызын алмадым, марҗага өйләндем, дип мактануым түгел, бүтәннәрне әгитләвем дә түгел, һич тә! Үземә насыйбы шул булгандыр, күрәсең. Югыйсә, егет чагымда йөргән кызларым арасында татарлары да булмады түгел, булды. Тик миңа гомер буена юлдаш итәрдәе, мөгаен, очрамагандыр. Әллә бәлкем, иркә үскән берәрсе минем хәерче куышыдай барагыма тагылып кайтуны, шунда утын ягып бәрәңге пешерүне, укытучы яисә журналистның килде-китте хезмәт хакына ризалашып, фәкыйрьлектә гомер кичерүне үзе өчен хурлык санагандыр? Кичке сайрашуларда киләчәкне ничегрәк күзаллавымны тасвирлап, кылларын тарткалап караганмындыр инде, кызганыч ки, берәвен дә рухландыра алмаганмын. Һәрхәлдә, борчагыбыз пешмәде генә бит, пешмәде генә!..

Хәер, минем гаиләмдә байлык өмет итеп алданган хәләл җефетем акча яратучы, малга табынучы зат булып чыкса, бергә-бергә тату яши алмас идек. Андый чакта үз милләтеннән булуы да файда бирмәс иде. (Дөнья кысыр түгел, кызганыч ки, татар кызына өйләнгән татар егете дә аерылышкалый.) Ә менә үзе китмичә, тик инде ирне ир димичә, хөрмәт итә белмичә, кирле-мырлы сөйләшеп, акыл сатып, Ходайның бирмеш көнендә байлык даулап, фәлән кешеләрнең бал да май эчендә йөзүен үрнәк итеп, аларның байлыгына кызыгып, хөсетлек чире белән яши башласа, колак итемне ашаса, нинди милләт вәкиле булуына карап тормас идем—аерып җибәрер идем. Бала-чагабыз ятимлектә үсәр иде...

Мин бәхетле, чөнки үзем яраткан кызны алдым, шуның белән гомер кичердем. Ә инде хәләл җефетемнең бүтән милләттән, башка диннән булуына килгәндә, гафу

кылгыйсыз, мин аны үз мәнфәгатен генә кайгыртмыйча, башкаларның да чамасын-хәлен аңлап, аларга файда китерергә тырышып йөрүче, гомер буе фидакяр хезмәт куючы, минем фәкыйрьлегемә дә ризалашып яшәүче, татар дусларымны чын күнелдән хөрмәт итүче, барлы-юклы иҗатымны да ольылаучы, ә инде үземнең ана телен әйбәт белергә омтылуым алдында баш июче әүлиягә саныймын. Объектив бәя шул. Җаны теләгән җылан ите ашаган, диләр.

Сигезенче дистә белән баручы зат буларак, яшәгән хәтле инде яшәргә өметләнмим, дөньяны яшь буынга калдырырга әзермен. Дөнья сезгә, риза-бәхил! Сезләргә һич тә акыл сатарга җыенмыймын, чөнки мин пәйгамбәр түгел, фәкать үз акылы белән яшәгән дәрвиш кенә.

Тик инде, үзем сезнең яшьтә булсам, сезнең арада булсам, нишләр идем икән, дип фикер йөрткәндә... Һөнәремне үзгәртмәс идем, һич тә! Фәкать кече яшьтән музыка дөньясына чумып, хәзергечә мәшһүр музыкантларны тыңлау белән чикләнмичә, үзем дә скрипкәне яхшылап уйнарга өйрәнер идем; сынлы сәнгатьне исә тирәнтенрәк үзләштерер идем; әдәбият дөньясында күбрәк иҗат итәр идем, хәтта әле диссертацияләр яклаудан да ваз кичмәс идем... Әлбәттә, боларның барчасын башкарып чыгу өчен күбрәк вакыт сарыф итү сорала, шуңа күрә хәзергәчә дүрт-биш сәгать йокламыйча, ике генә сәгать йоклауга күчәр идем... Физик эшне чак кына арттырган тәкъдирдә дә спорт белән шуннан артык мавыкмас идем...

Ә инде өйләнү-гаилә кору мәсьәләсенә килгәндә, фикерем үзгәрми, искечә кала: бу—дәүләт вә җәмгыять хәл итәрдәй, зурдан кубып сөйләшердәй нәрсә түгел, бәлки һәркемнең шәхси эше, һәм бу мәсьәләне һәркем үз акылы, үз йөрәге-хисе белән "киңәшләшеп" хәл итәргә тиеш. Әмма ләкин шул ук вакытта башлы-күзле булуга җитди эш дип карау, гаилә коруны изге бер йолага санау, аннары инде гаиләңне саклау—һәркайсыбызның изге бурычы. Рецепты юктыр ул гаилә коруның. Ике дус та, ике туган да әлеге мәсьәләне бер үк төрле хәл итми торгандыр, мөгаен. Тик инде, минем уемча, кемнеңдер димләвенә буйсынып яки берәрсенең чибәрлегенә кызыгып кына өйләнү яисә кияүгә чыгу ярамыйдыр. Чөнки әлеге чибәрлекнең бик тиз шиңүе ихтимал, кешедәге рухи байлыкка бәйләнгән эчке матурлык кына гомер буе сакланучан.

Миңа калса, чын-чынлап гашыйк булган очракта гына, күңеленә бигрәкләр инде хуш килгән асыл затка гына өйләнешергә ярыйдыр. Анда да әле: кичә күреп гашыйк булдым, бүген өйләндем түгел, бәлки хисләреңнең ныклыгын, мәгъшуканның синә гомерлек сөйкемле вә сөйгән яр, тансык зат буласын тәмам ачыклап, бер-береңнең холкын яхшылап өйрәнеп, әлеге холыктагы кимчелекләргә түзеп тора алу-алмавыңны, ягъни тулаем хөрмәт белән каравыңны тәгаенләү, шуңа инану зарурдыр. Холыктагы кимчелекләрне дә исәпкә алмыйча ярамый, чөнки еш кына өйдәге ызгыш-талаш, киреләнү, кәҗәләнү, тәртәгә тибүләр нәкъ әнә шулар нәтиҗәсендә килеп чыга. Бигрәк тә байлыкка алдану аеруча фаҗигале очлана...

Чынлап та, әгәр без берәүнең чибәрлегенә һәм затлы сыйфатларына мөкиббән китеп, шуны үзебезгә гомерлек яр итеп сайлыйбыз икән, бергә яши башлагач, әллә нинди көтелмәгән хәлләрнең килеп чыгуы ихтимал. Ярый да бит сөеклеңнең әлеге "фокусларына" елмаеп та көлеп кенә карый алсаң, бик нык гарьләнгәндә дә күтәрелеп бәрелмәсәң, таләпнең олысын үзенә куя белсәң, үҗәтләнеп-киреләнеп китеп, аннан да яманрак "фокусларыңны" күрсәтмәсәң... Яисә инде, гайрәтләнеп, хәләлеңне "акылга утырту" юлына басмасаң... Көндез аны тукмап, кич житкәч аның куенына кермәссең ич инде! Хәер, бу дөньяда өйләнешкәннән соң үзара хөрмәтне югалтып, ягъни бер-беренә юл куймыйча, әрләшеп тә талашып яшәүче гаиләләр булган кебек, ызгышудан арыгач, суд белән аерылышкан гаиләләр дә житәрлек. Иң яманы—аерылган ирнең, еш кына эчкечелеккә бирелү нәтиҗәсендә, аерылган хатыны янында яшәп, алимент акчасына туенып яту сыман түбәнлеккә төшүедер...

Өйләнү—түгел сөйләнү, дип бер дә белмичә әйтмәгәннәр. Гаять житди мәсьәлә бу һәркем өчен. Сез, яшьләр, җитди акыл белән карасагыз иде бу эшкә. Сөеп-сөелеп өйләнешергә, сөеп-сөешеп, намуслы вә тату гаиләдә бергә-бергә гомер юлын мәгънәле кичәргә насыйп булсачы һәркайсыгызга!

✚

*Яшьләр иҗаты*



**Гөлнур Корбанова**

## ЧИШМӘ СУЛАРЫ САЛКЫН ШУЛ...

***

**Төн.**
**Ал алмадай кояш өзелгән,**
**төш юрала күктә, без күргән.**

**Таң.**
**Безгә таба кояш тәгәри!**
**Әле якты түгел әллә ни...**

**Көн.**
**Ак уйларга күмде безне көн,**
**чапты вакыт, өзеп тезгенен.**

**Кич.**
**Күңелләргә шатлык оялар:**
**зарыгып көткән җылы оя бар!**

**Чын.**
**Төннәр, көннәр, таңнар бер эздән**
**бер-бер артлы чират тезелгән.**

Гөлнур КОРБАНОВА – *яшь шагыйрә; шигырьләре вакытлы матбугатта даими басыла. Казанда яши.*

***

Бәхетеңне ят күзләрдән
ерак яшер.
Карар бәхетең башкаларга...
Һәм читләшер.

"Мин бәхетле!"—диеп, сөрән
салма, тиле!
Өркетерсең—качып китәр,
кайтмас кире.

***

Киләчәгем—якты юл иде,
шатлыклар да анда мул иде,
башка юллар таптым,
шунда учак яктым,
язмыш язганнары шул иде.

Күзләрең дә синең мут иде,
йөрәккәең тулы ут иде,
күңеленә бактым—
актарыплар аттым,
мин эзләгән якты юк иде.

Мин эзләмим хәзер яктылык,
яктылыгым булсын—ак болыт.

***

Атылдым мин, күп уйламый,
сөюнең кочагына.
Минем өчен сөю үзе
алган да салган иде шул
йөрәген учларына.

Ашыктым ник? (Йөрәкне бит
йодрык кадәрле диләр.)
Минем өчен йомарланган
йөрәк кебек шул йодрыкны
танымаганмын, җүләр...

***

"Син бит минем чишмәм" дидең,
чишмә идем мин чынлап.
Челтерәдем, чишмә төсле,
алсу таңымда җырлап.

Чишмә идем—хисләрем дә
чишмә суыдай чиста,
сусавыңны басыйм диеп,
мин тулдым синең учка.

Кулларың кинәт туңдымы—
уеңнан кире кайттың,
чишмә сулары салкын шул,
чишмә сулары салкын...

***

Кайгыларны—кара диләр,
сагышларны—сары.
Аларны акка манырдай
ак буяулар бармы?

Авыр диләр сагышларны,
кайгыларны—тирән.
Үлчәр өчен юк үлчәүләр...
Үлчәү—йөрәк микән?



# Гөлнара Җәлилова

## ҖИРГӘ БӘХЕТ ӨЧЕН ТУДЫМ МИН

### Йолдыз булсам

**Зөһрә кызның талир тәңкәләре**
**Чәчелгәннәр күккә йолдыз булып.**
**Кара төндә җиргә энҗе төшә,**
**Сөю-мәхәббәткә ташып, тулып.**

**Шул йолдызлар җиргә бәхет чәчә,**
**Йөрәкләргә бүләк итә илһам.**
**Мин бары тик сөю нурын гына**
**Чәчәр идем җиргә, йолдыз булсам.**

### Каләм дәфтәр ашый

**Төн патшасы миңа ишек кага,**
**Колагыма пышылдый ул: "Йокла! Йокла!**
**Ташла каләм белән дәфтәреңне,**
**Серле төшләр ниләр сөйли — шуны тыңла!"**

**Ялгышасың, Төн Патшасы, ялгышасың,**
**Дәфтәр, каләмсез яшәү ул — яшәү түгел.**
**Хисләр, ташып, ак кәгазьгә түгеләләр,**
**Йөрәк сыкрый, кыллар чиртеп җырлый күңел.**

**Тыеп булмый, шашкан хисләр ярга ташый,**
**Ә каләмем әле һаман дәфтәр ашый...**

### Мәхәббәт

**Мәхәббәт татлы ул, дигәннәр**
**Ялгышкан.**
**Мәхәббәт яралган, күрәсең,**
**Сагыштан.**
**Мәхәббәт — газапның упкыны,**
**Килешәм.**
**Мәхәббәт кодрәте тиңдәшсез,**
**Бирешәм.**

---

Гөлнара ЖӘЛИЛОВА – *Актаныш районында туган. Казан дәүләт университетының журналистика факультетында укый. "Синме бу, бәхет?" исемле җыентык авторы.*

Мәхәббәт — тыелган җимешнең
Татлысы.
Мәхәббәт — йөрәкләр хисенең
Затлысы.
Мәхәббәт — гашыйклар күңеленең
Мең кылы.
Мәхәббәт — йөрәкнең мәңгелек
Чоңгылы.

## Кыргый гөл

Сафлык аланында кыргый гөл ул,
Чәнечкеле аның таҗлары.
Чәнечкеләр аша карадылар,
Белмәделәр анда җан барын.
Кыргый гөл дә бер көн чәчәк атты, —
Кыргыйлыкта икән матурлык.
Горур гына башын күтәрде дә
Бар дөньяга сафлык тутырды.
Кыргый чәчәк кыргый бер аланда
Кыргый матурлыкка әйләнде.
Матурлыкка хәйран булды дөнья,
Сафлык белән бәхет бәйләнде.

## Көтәм...

Көнем тәмам. Бар җиһанда
Төн хакимлек итә.
Йөрәк уралган сагышка,
Җаным нидер көтә.
Көн дә тәмам. Кара челтәр
Бизәгендә Ак Ай.
Шатланырлык бер сәбәбем
Юк та кебек бугай.
Көнем тәмам. Тик мин генә,
Төн сакчысы кебек,
Йокламыймын, күктән сөю,
Могҗизалар көтеп.

## Җиргә бәхет өчен тудым мин

Әнкәй ак биләүгә төргән чакта
Миңа шулай диеп пышылдаган.
Аның сүзләренә Аллаһ үзе,
Фәрештәләр хәтта кушылганнар:
"Җиргә бәхет өчен тудым мин!"
Мукәй-мукәй җирдән шуышканда
Изге җирем дога кылган миңа.
Маңгаемнан үпкән мине үзе...
Изге Анам, бәхетлемен шуңа:
Җиргә бәхет өчен тудым мин!
Фатыйхасын биргән тумыштан ук
Җәбраил фәрештә — изге канат:
"Бәхетле бул!" — диеп пышылдаган
Колагыма минем кабат-кабат.
Җиргә бәхет өчен тудым мин!



## Лилия Гыйбадуллина

# Ә ҖИЛ ИСӘ ҺАМАН ИСӘ

### Өченче көн

Өченче көн мин күкләргә мендем.
Анда сине башка белән күрдем...
Өченче көн баш очында атылды бер йолдыз.
...Ул мин идем...

### Ә җил исә

Җир караңгы,
Күк караңгы,
Төн караңгы...
Юлга чыкты тынгысыз җил — төн карагы...

Күктә йолдыз бүген ничә?
Меңәрләгән иде кичә...
Йолдыз чүпләп караңгыдан, гомер кичә.
...Ә җил исә һаман исә, һаман исә...

Пычкымыни, ялгыз айны болыт кисә.
Нишләр җиһан, бу гөнаһын сизсә?
Нишләр галәм, төнге күктән ай да бизсә?
...Ә җил исә һаман исә, һаман исә...

***

Соры томан арада.
Күк ярлары аллана,
Ә төн, ай-һай, кара ла...

---

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА — *Актаныш районы Такталачык мәктәбенең соңгы сыйныф укучысы. Шигырьләре көндәлек матбугатта, шул исәптән журналыбызда да басылды. "Мин бәхетне күрәм!" ("Мәгариф", 2004) исемле китабы дөнья күрде.*

Таң җиле юлда уйный,
Сулыгып йолдыз сулый,
Һәр нурдан кояш ургый,
Иртәнге чыкны урлый...

Сүзләрне күзләр күмә.
(Ялгыш эндәшә күрмә!)
Күңел дөньяны күрә,
Юллардан еллар үрә...
Елмаям шуңа күрә!

***

Тама тамчы, тамга салып бозлы җиргә.
Таман гына бу тамгасы буйга, иңгә.
Томан булып, талымсыз күк җиргә иңә.
...Томырылып карга батты бозлы энә...

***

Кочагыңа атыласым килә
Күргән саен сине... төшемдә.
Мин салкыннан кабат туңам бүген.
Ә син, бердәнберем, өшемә!..
...Кермә бүтән, гамьсез, төшемә...

***

Минем хисләр хәерчесе буласым килми,
Бар җылымны җиргә биреп тә, туңасым килми,
Бу бушлыкка кулларымны сузасым килми,
Тормыш юлын, башым түбән иеп, узасым килми,
Бар кешелек күләгәгә чумганда да, качасым килми,
Кырыс заман кагыйдәсен ачасым килми,
Дусларымның хыянәтен белгәндә дә, аңлыйсым килми,
"Син бәхетле!" — дип, үземне алдыйсым килми...

## Минем йөрәк

Минем йөрәк — шаулы диңгез, әле йөзелмәгән,
Минем йөрәк — кызу чүлдер, әле йөрелмәгән,
Минем йөрәк — сихри дөнья, әле күрелмәгән,
Минем йөрәк — алсу алма, беркем үрелмәгән,
Минем йөрәк — яңа шигырь, әле язылмаган,
Минем йөрәк — ап-ак чәчәк, беркем кагылмаган,
Минем йөрәк — кара урман, һичкем адашмаган,
Минем йөрәк — тылсымлы төш, беркем саташмаган.

Минем йөрәк — яуланмаган, бары минеке ул!
Төшерә алсаң кулларыңа, сүнмәс бәхетем бул!...

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

**Мансур Вәли–Барҗылы**

## КҮҢЕЛ КЕМНЕ КӨТӘ?

Соңгы егерме елда бик тә нәтиҗәле иҗат итүче әдибебез Фоат Садриевның 1992 елда журналыбызда басылып чыккан "Таң җиле" романыннан Нуриасма образы хәтергә уелып калган. Үзенә бик тә кыен килгән бер көнне, газаплы һәм әрнүле кичерешләрдән соң, күнеленнән генә ул менә мондый нәтиҗә ясый:

"Аны кемнәр генә нинди генә хурлыклы сүзләр белән тамгаласалар да, кемнәр генә нинди генә ачулы күз карашлары белән чәнчесәләр дә, Нуриасма үзенең алар өчен буй җитмәс биеклектә торуын анлады. Бу–аның күптәннән төзегән сафлык дөньясы, аңа ул үзе генә патша, күпме генә, ничек кенә һөҗүм итмәсеннәр—бу патшалыкка беркемнең дә теле дә, кулы да зарар сала алмаячак иде".

Менә шушы кыска гына бер өзектә безнең заман героена хас булган үтә мөһим сыйфат: рухи сафлык һәм рухи ныклык ачык чагыла. Чыннан да, бүгенге тормышта (соңгы елларда бигрәк тә!) нык күбәеп, көчәеп киткән эреле-ваклы әшәкелек ташкынына каршы тора алу, шундый мохиттә яшәп тә буялмый, пычранмый кала алу—үзе бик тә зур батырлык, ныклык сорый бит! Ә Нуриасма исә буялмау гына түгел, ул вак-төяк әшәкелек ташкыныннан өстен кала, якты, көчле образ булып истә кала.

"Безнең заман герое" дип әйткәндә иң башта әдәбиятыбыздагы әнә шундый—рухи яктан көчле, рухи-әхлакый яктан пакь образлар күз алдына килә.

Журналыбызның 2002 елгы 11-12 саннарында басылып чыккан "Өермә" әсәрендә Мәдинә Маликова үзәккә шагыйрә Җәүһәрия образын куйган. Юк, Җәүһәрия: "Иҗат кешесенең эше—язу өстәле янында, яңа әсәрләр иҗат итү!"— дип кенә яшәми. Ул үзенең инициативасы белән "Хәйрия җәмгыяте" оештыра, шәһәрдәге ярдәмгә мохтаҗ картларны, авыруларны барлап чыга, аларның исемлеген төзи һәм үзе төрле-төрле оешмаларга, бизнесменнарга барып ялына-ялына акча яисә азык-төлек таба да—аларны әлеге кешеләргә илтеп бирә, өләшә. Авторның үзәккә, әлеге җәмгыять башына шагыйрәне—нечкә күңелле һәм гаять дәрәҗәдә саф вөҗданлы затны—куюы бер дә юкка түгел, билгеле. "Тулаем ил, җәмгыять башында да әнә шундый шәфкатьле, изге күңелле кешеләр торсын иде!" дигән фикер ярылып ята анда.

Әмма, әсәр героинясы Җәүһәриянең ният-максатлары изге булса да, аның әйләнә-тирәсендә ерткыч табигатьле адәмнәр күп. Алар яңа байлык туплау өчен бернәрсәдән дә чирканып тормыйлар һәм... Җәүһәриянең яшь гомере әнә шулар кулы белән өзелә. Әсәр бик тә фаҗигале тәмамлана. Әмма иң соңгы биттә безнең күңелгә өмет нуры да төшеп куя. Әсәр буена

Җәүһәрияне яклап, аңа булдыра алганча ярдәм итәргә теләп яшәгән Харис ин соныннан, Җәүһәрия үлгәч, болай ди:

"—Нигә булмасын?— диде Харис. —Халыкның уллары-кызлары җитәрлек. Бәяли генә белмибез. Кеше кадерен белү юк бездә. Кайчан да булса зурга омтыла торган, көчле, кыю шәхесләр табылыр, җәмгыять яңадан ачылыр. Менә дигән бинага ия булыр. Түбәсендә Кызыл Ай балкып торыр..."

Бу сүзләр укучыга тулаем ил, тулаем җәмгыять турындагы фикер булып аңлашыла һәм киләчәккә карата оптимистик уйлар уята.

Әйе, соңгы елларда иҗат итүче проза осталары безнең игътибарга әнә шундый—сокланырдай унай геройлар образларын куя алдылар. Ә бераз гына ераккарак карасак, без Аяз Гыйләҗевнын "Җомга көн кич белән" повестендагы Бибинурны, Әмирхан Еникинең "Әйтелмәгән васыять"ендәге Акъәбине күрербез. Үзләренең рухи ныклыклары, сафлыклары һәм фидакарьлекләре белән алар безнең хәтердә Габдрахман Әпсәләмов геройларына һәм Нәфисәләргә (Г. Бәширов), Миңлекамалларга (М. Әмир) килеп ялганалар. Алар, шул ук вакытта, хатын-кызның бөеклеген, аның яшәештәге төп ролен күрсәтү ягыннан безнең татар әдәбиятының зур казанышы булып та торалар. Ә Акъәби белән Бибинур исә—дөнья әдәбияты өчен дә кызыклы ачыш.

Татар прозасының танылган осталары XX гасыр дәвамында салган, төзегән төп юл әнә шундый иде. Югарыда без кыскача гына тукталып үткән образлар—алар әлеге олы юлның якты маяклары сыман еллар аша да балкып, нур чәчеп торалар. Алар әдәбиятыбызның көчен һәм шул ук вакытта халкыбызның рухи-әхлакый йөзен, характерын да күрсәтәләр. Милләтебезнең тулы вәкаләтле вәкилләре булып яшиләр.

Герой. Безнең заман герое.

Ә соңгы елларның реаль чынбарлыгында нинди соң ул—безнең еллар герое? Бүгенге тормышта без кемнәргә—нинди типларга—чыннан да "герой" дип әйтә алабыз?

Юк, үзләре бик тә кукраеп йөрсәләр дә, күпләгән сандагы үтергеч коралларга ия булсалар да, хәтта кайсыбер вакытларда байтак кына кешене куркытып тота алсалар да—төрле-төрле мафия корольләрен без герой дип әйтә алмыйбыз. Шулай ук төрле яшерен юллар һәм астыртын хәйләкәрлек белән дәүләт, ил, халык акчасын урлап харам байлык туплаучыларны—ил халкының иң зур күпчелеге тормышның очын очка ялгый алмыйча тилмергәндә— "герой" диярго тел бармый.

Хакимиятнең төрле җылы кәнәфиләренә менеп утырып ил, халык мәнфәгатеннән алда үзенең кесәсе турында уйларга ашыккан һәм шул максат белән көн-төн баш ваткан, кесә калынайтуның төрле ысулларын тапкан вак җаннар да "герой" дигән югары исемне, әлбәттә, күтәрә алмый.

Герой исеме ул, һичшиксез, зур батырлык, зур фидакарьлек белән бәйле.

Ә батырлык, фидакарьлек дигәндә минем күңелгә иң башта сугыш елларыннан Шакирҗан Мөхәммәтҗанов, Газинур Гафиятуллин кебекләр, сиксәненче еллар армиясе тормышыннан Рифкать Миргазизов сыман асыл, кыю егетләр килә.

Бу егетләр кылган батырлыкның, алар геройлыгының нигезе, мәгънәсе, әһәмияте нәрсәдә соң?

Соңгы елларда без менә бу сораулар турында бөтенләй сөйләшмибез, хәтта уйламыйбыз да бугай. Шуңа күрә, әйдәгез, алдагы фикерләргә күчкәнче, иң башта әлеге сорауларга җавапны ачыклап китик.

Иң башта шуны искә алыйк: Туган илне, Туган җирне дошманнан саклау өчен барган сугыштагы батырлык бу! Әнә шул изге көрәш вакытында Газинур да, Шакирҗан да үз иптәшләренең гомерен саклап калу, алар исән калсын өчен газиз тормышларын корбан итәләр. Әлбәттә, бүген безнең яшәештә эгоизм, хәтта ерткычлык инстинкты буенча гына эш итү үтә нык көчәйгән чагында, күпләр өчен менә мондый фидакарьлекне аңлау бик тә кыенлашты. Андыйлар өчен Газинур белән Шакирҗан батырлыгы бик зур бер ахмаклык шикелле генә тоела. Иң алга үз мәнфәгатең, һәм бары тик үз мәнфәгатең генә куеп яшәүчеләр өчен бу шулай. Ләкин бит әле Ил мәнфәгате дә бар! Ил мәнфәгатен алга куеп фикер йөртеп карасак (хәзер

андыйлар бик тә сирәк билгеле—әнә шул Газинурлар, Шакирҗаннар кебек бик аз алар. Һәм нәкъ менә шул сәбәптән: ягъни, андыйлар бик тә аз булганга күрә, Ил менә шушы көлке хәлгә килеп төште дә бит инде безнең!) без кемнең кем икәнен бик яхшы аңларбыз.

Бусы Газинурлар батырлыгының практик яктан карагандагы кыйммәте, әһәмияте булды. Әле бит тагын, моннан кала, әлеге фидакарьлекнең рухи яктан, фәлсәфи мәгънәдәге әһәмияте дә бар. Сөйләшүебезнең темасы геройлар һәм геройлык турында булгач, анысын да бирeдә ачыклап китү сорала, билгеле.

Кыскача гына итеп әйткәндә: алар, әлеге күренешләр, кеше табигатенең нинди зур рухи, әхлакый потенциалга ия булуын раслый. Физика галимнәре теге яки бу матдәнең асыл сыйфатларын ныклап белү, аңлау, төшенү өчен гаять зур тизлек хасил итә торган синхрофазотроннар кулланалар бит әле—шуның шикелле, сугыш чорында адәм баласы килеп эләккән критик, кискен ситуацияләр дә алар Кешенең кем икәнен, нинди икәнен ныклап белергә ярдәм итә.

Юк, сугыш чорында гына түгел! Әнә, Казаныбызның очучы егетләре, Михаил Девятаев батырлыгын кабатлап, әфган әсирлегеннән самолетка утырып качтылар бит әле!

Әнә, Карапетян дигән егет пассажирлары белән су төбенә төшеп киткән троллейбус эченнән бер үзе 18 кешене алып чыкты бит әле!

Ә гадәттән тыш хәлләр хезмәтендәге кыю, тәвәккәл егетләр үз гомерләрен куркыныч астына куеп, көн саен ничәмә батырлык кылалар.

Без бүген "капитализм" дигән кара урман ерткычлары арасына барып кергәч, кешене югары күтәрә, аны рухи һәм әхлакый яктан балкытып, нурландырып күрсәтә торган андый матур күренешләр турында уйламаска да күнегеп киләбез.

Ә соң үзебезнең әдәбият дөньясына килсәк, совет хакимияте елларында нинди каты сәяси һәм рухи басымга да бирешмичә, үзләренең эчке иманнарына, үзләренең олугъ иҗат һәм намус юлларына бөек тугрылык саклап кала алган Әмирхан ага Еники һәм Нурихан ага Фәттах—алар безнең чорның геройлары түгел идемени?! Күпчелек иҗатчылар партиянең өлкә комитетыннан өркеп яшәгәндә, хәйләкәррәк иҗатчылар үзләренә шәхси уңышлар яулау (һәм рәхәт тормышка ирешү өчен!) андагы түрәләр белән турыдан-туры яисә "интеллигентлар"ча әшнәлек иткәндә һәм алар кулыннан төрледән-төрле медальләр алганда—болар бит бары тик милләт, халык хакына олугъ Иҗат дигән Иманны гына таныдылар! Шуңа гына хезмәт иттеләр!

Язмабызның башында Фоат Садриевның роман героинясы Нуриасма уйлаган уйлар—алар нәкъ менә Әмирхан Еники белән Нурихан Фәттахка да төп-төгәл туры килә түгелмени?! Алар, әлеге сүзләр, бу әдипләрнең дә асыл табигатен, төп холкын, алар мәсләгенең, Иманының мәгънәсен ачып бирә түгелмени?!!

Үз гомерләренең, үз иҗатларының иң калку, иң зур казанышы итеп алар—бу ике әдип—берсе гасырлар буена үлмәстәй Акъәби образын, икенчесе ерак гасырлар төпкеленнән үлемсез рәвештә, данлы рәвештә атлап килүче татар кешесе, татар милләте образын тудырмадылармыни?!!

Күптән түгел, ә төгәлрәк итеп әйтсәк, журналыбызның быелгы 1-2 саннарында, Аяз Гыйләҗевнын "Кылдан нәзек, кылычтан үткен" дигән язылып бетмичә калган романын укыдык. Танылган халык язучысының яшьрәк буын прозаикларга үзенчә бер төрле васыяте кебегрәк кабул ителә бу әсәр. Романның эчке энергетикасының, рухи куәтенең көче сокландыра. Ә үзәккә салынган идеясе! Министр дәрәҗәсенә күтәрелгән Асаф Сәхипович һәм аның яшьлек дусты Фаязны икесен янәшә куеп караганда бигрәк тә ачык аңлашыла ул идея, ул мәгънә.

Министр кәнәфиенә утырыр өчен Асаф Сәхипович кемнәргә генә нинди генә ялагайлыклар кылмаган да, кемнәрне генә сатмаган. Яшьлек мәхәббәтеннән алып үз әтисенә булган мөнәсәбәткә кадәр—бөтен яшәү дәверендә һәммә изге, саф нәрсә изеп, таптап үтелгән. Әсәр ахырында әтисе дөнья куйгач министр улына хәбәр дә иттермәве, үз җәсәден җиргә индергәндә малаеның булмавын, катнашмавын теләү—үтә зур мәгънә, символика ала. Ягъни бу: министр кеше атасы-анасы юлыннан, үзенең

иле, милләте юлыннан аерылды дигән сүз инде. Төгәлрәк итеп әйткәндә: ата-ананың һәм илнең әлеге министрны кире кагуы булып чыга бу күренеш! Әнә шундый министрлар бит инде илдә һәм җәмгыятьтә революцион ситуация китереп чыгаралар һәм, ахыр чиктә, тәхеттән туп-туры тарих чүплегенә очалар.

Тәҗрибәле әдип А. Гыйләҗев әлеге типка Фаяз кебек эчкерсез һәм ныклы җирлеккә ия шәхесне каршы куеп, яшәешнең олы юлы кайда икәнен күрсәтә. Фаяз дан-дәрәҗә артыннан кумыйча тыйнак кына эшләп йөри. Аның каруы, Фаязның менә дигән гаиләсе, туганнары бар. Министр дустының үткәндәге вак-төяк әшәкелекләрен дә оныткан инде ул—бу аның кин күңеле өчен бер ваклык кына кебек кабул ителә, күрәсең.

Язучы үзенең әсәренә исемне "Кылдан нәзек, кылычтан үткен" дип куйганда да олы яшәешнең катгый рухи-әхлакый кануннарын күздә тоткан, ахрысы. Әйе, ил күзен, халык күңелен син алдый, хәйләли алмыйсың. Ил күзе синең кем икәненне, асылыңны белеп тора ул. Аның ышанычын, хөрмәтен казаныр өчен югары дәрәҗәләр һәм затлы кәнәфиләр мөһим түгел—ә намуслы яшәлгән гомер юлы мөһим! Ил күңеле үзенең һәр улын әнә шундый "кылдан нәзек, кылычтан үткен" рухи-әхлакый үлчәүгә салып үлчи һәм үзенең төгәл бәһасен бирә ул!

Әйе, Аяз Гыйләҗев үзенең тирән фәлсәфи мәгънәле әсәрләре белән дә һәм бер үк вакытта әдәбиятка кагылышлы мәкаләләре белән дә "заман герое" мәсьәләсенә зур өлеш кертте. Минем үземә дә аның белән бу хакта әңгәмә кылырга (ул басылып та чыкты) туры килгән иде.

Аяз ага бигрәк тә гыйбрәтле геройлар иҗат итәргә яратты. Ул мондый фикерне мәкаләләрендә һәм әңгәмәләрендә дә байтак кабатлады. Мисал өчен без аның белән 1972 елда үткәргән әңгәмәдә ул әлеге проблемага кагылып болай дип язган:

"Шәхсән минем үземне "гыйбрәтле" геройлар кызыксындыра. Мин шундый кешеләрне ятатам. Үзләре яшәгән чорга битараф булмаган, мәхәббәтне һәм нәфрәтне сиземли торган кешеләр... Уйлана һәм уйландыра торган кешеләр! Коммунизм идеалларына тугрылыклы кешеләр... Шул ук вакытта үз тугрылыкларын лозунг итеп күтәреп йөрми торган тыйнак кешеләр... Киң күңелле кешеләр... Сатылмаслар, алдашмаслар, дусдошманны аера белә торган кешеләр!.."

Әйе, үзенең әлеге принцибына тугры калырга тырышып иҗат итте Аяз ага һәм безгә журналист Идрис ("Урамнар артында яшел болын"), Исхак ("Берәү"), Бибинур ("Җомга көн кич белән) кебек онытылмас геройлар калдырды.

Ә инде әңгәмәбезнең икенче бер өлешендә ул әдәби геройларның укучылар күңелендә озак яши алу-алмавына бәйле уйлары белән уртаклашты:

"Бүгенге көн героена минем мәгълүм таләбем бар—герой икән, аның киләчәге булсын!

Теге яки бу герой язучы күңеле аша тормыштан китапка үтеп керә. Кем ул, нинди ул, үз чорының кадерле һәм онытылмаслык асыл сыйфатларына ияме ул—аның гомеренең озынлыгы шушы сорауларга бәйләнгән. Безнең китапларда еш кына бер көнлек персонажлар гомер итәләр һәм китап үзе тузганчы ук искерәләр, онытылалар... Димәк, язучы бүгенге көндә үз янәшәсендә иҗат итүче, көрәшүче, тормыш төзүче геройларга хыянәт итте дигән сүз. Ул бүгенге көн геройларын эстафета итеп алдагы буыннарга ялгый алмады".

Әйе, замана яшәеше китереп чыгарган зур-зур проблемаларны үзе язган әсәрләрнең үзәгенә куя иде Аяз ага. Аның башта Мәскәүдә генә басыла алган "Өч аршын җир" повестен аласыңмы, яисә "Әнгер-мәнгер" белән "Җиргә тапшырылган серләр" драмаларын искә төшерәсеңме, аларда иң элек социаль эчтәлекнең үткенлеге, актуальлеге һәм гаять зур проблемалылык күзгә ташлана. Нәкъ әнә шул проблемалылык аркасында инде—юллар арасына гына яшеренеп, качып кала алмаган үткен проблемалылык аркасында—Аяз Гыйләҗев үзе дә КПСС өлкә комитетының "сөекле" кешесенә әверелгән иде бит!

Ә. Еникиләр, Н. Фәттахлар, А. Гыйләҗевлар тоткан олы юлны дәвам итүче—

безне мавыктырырдай кызыклы геройлар иҗат итүче прозаикларыбыз тагын да бар, билгеле. Язмабызның башында Ф. Садриев һәм М. Маликова исемен әйтеп үткән идек. Соңгы елларда шулай ук нәтиҗәле иҗат итүче Радик Фәизовның оригиналь проблемалар күтәргән әдәби геройлары булды. Аның бигрәк тә "Телсез" һәм "Көнбагыш чәчәкләре" дигән хикәяләре истә калган. Алардагы кичерешләр драматизмы, алынган ситуациянен яналыгы һәм тирән рухи мәгънәгә ия булуы, язучы теленең үз геройларының күнел халәтенә тәңгәл рәвештә гаять тә музыкаль һәм югары зәвыклы булуы—болар соңгы еллар прозасының тулаем алганда да уңышы булып тора.

Ә шул ук Радик Фәизовның "Тәңре хөкеме" дигән фантастик повестен алып карагыз сез. ("Казан утлары", 1999 ел, 4 сан). Аның төп герое Сәетҗан аганы искә төшерегез. Бүген безнең татар халкы өчен генә түгел, бөтен кешелек җәмгыяте өчен гаять мөһим, гаять актуаль булган идеялар белән мавыгып йөри бит ул.

"Һәр көн иртән кояш белән бергә тордылар, урман аланына чыктылар. Иртәнге тынлыкта моңлы һәм тантаналы булып, еракларга кадәр адәм балаларының тавышы яңгырады:

—Исәнме, Табигать! Безне бу дөньяда яшәтүче, тамагыбызны туйдыручы, җаныбызга һәм тәнебезгә сихәт бирүче мәрхәмәтле табигать. Исәнме, Кояш! Барча-барча тереклек ияләрен, тере булмаганнарны да бердәй күреп яраткан, аларга тормыш биргән Кояш. Зәңгәр күк йөзе, яшел урман, агачлар, үләннәр, чәчәкләр—саумысез! Без, кешеләр, сезнең барчагызны да яңа туган көн белән тәбрик итәбез. Сезгә дуслык, туганлык сәламе җибәрәбез!

Шушындый ихлас күңелдән сәламләүдән соң, һаваның нинди булуына карамастан, хәтта өстән явып торса да, бергәләп иртәнге гимнастика ясыйлар, елга буена төшеп су керәләр. Аннары инде көндәлек эшләр башлана".

Болар—Җир шарындагы тормыш техника артык көчәю сәбәпле юкка чыкканнан соң Табигать кочагында яңа тормыш башлап җибәрүчеләр. Сәетҗан ага—алар арасында иң өлкәне, остаз.

Бу остазның югарыда без укып үткән сүзләре бүген бөтен кешелек дөньясы өчен дә үтә мөһим. Чөнки хәзер кешелек дөньясы, әлеге дә баягы техник үсеш аркасында, Олы Һәлакәт каршына килеп басты—тәмам якынлашты! Сәетҗан аганың әлеге сүзләре—акыллы кешенең дөрес юлга чакырып безгә дәшүе дә һәм шул ук вакытта бөек кисәтү дә булып яңгырый!

Менә шушы гаять актуаль темага безнең татар әдәбиятында уңышлы әсәрләр, геройлар иҗат ителү—уртак горурлыгыбыз ул.

Ә шулай да без бүгенге күпчелек геройларыбыздан канәгать дия алмыйбыз. Ни өчен?

Чөнки аларның күбесе әсәр дәвамында әллә никадәр, бик күп төрле күренешләрдә катнаша, башыннан әллә нәрсәләр кичерә—ә менә шул хәл-әхвәлләрнен чын мәгънәсендә вакыйга булырдайлары яисә бөтенләй дә булмый, яисә бик тә бик тә аз була. Әсәрнең күләме белән чагыштырып караганда үтә дә аз табыла алар.

Ә бу хәл үзе нилектән, ни сәбәпле килеп чыга соң?

Минемчә, моның иң төп һәм иң беренче сәбәбе—язучыларыбызның (биредә, әлбәттә, проза тармагында каләм тибрәтүчеләр күздә тотыла) игътибары нигездә тышкы дөнья вакыйгаларына, күренешләренә юнәлгән булуы. Ә күренеш һәм вакыйгаларның рухи һәм фәлсәфи асылы аларны аз кызыксындыру. Яисә бөтенләй дә кызыксындырмау, уйландырмау. Үз чиратында бусының сәбәбе—безнең прозаикларыбызның интеллектуаль дәрәҗәләренә, шул эчке рухи көчнең куәтенә, аның шәхес эчендәге потенциалына, аның ни күләмдә булуына килеп ялгана. Әнә шул сәбәпле безнең проза әсәрләрендә күренешләр бик күп, ә чын вакыйгалар, истә калырдай—әдәби геройның үзен дә безнең каршыда югары күтәрердәй тирән мәгънәле вакыйгалар—бик аз була. Соңгы елларда мафия һәм аның төрле-төрле вәкилләре турында язылган күпсанлы роман-повестьларның барысы да диярлек (Мәскәүдә яшәүче авторыбыз Р. Мирхәйдәровныкыннан кала) бу очракта мисал була ала.

Юк, биредә безнең күпчелек язучыларыбызны интеллектуаль, рухи көч

житмәүдә гаепләгәндә, без аларның барысын да әлеге Мәскәү авторы Р. Мирхәйдәров яки үзебезнең М. Галиев кебек язарга чакырмыйбыз. Мондый юлга басу прозаның колачын гаять тә тарайтыр, аның эчтәлеген саектырыр, халыкчанлыгын киметер иде. Без биредә Әмирхан ага Еники әсәрләрендәге сыман рухи куәт, эчке энергия, тирән мәгънә турында сүз алып барабыз. Әнә бит: мәрхүм Әмирхан агабызның тылсымлы күңеле гаптади татар сүзләре белән бөтен дөнья әдәбиятының иң югары сәнгать әсәрләре янәшәсендә тора алырдай бөек проза әсәрләре иҗат итте.

Минем нык инануымча, ул—үз әсәрләренең рухи-фәлсәфи һәм сәнгати көче белән, аларның һәммә яктан камиллеге белән үткән XX гасыр прозаиклары арасында аеруча зур биеклекләр яулаганы. Татар әдәбиятында үткән гасырның иң көчле, иң талантлы прозаигы кем дип сорасалар, мин, мәсәлән, Әмирхан Еники дип җавап бирәчәкмен!

Мондый мисаллар безгә, бигрәк тә яшь буын прозаикларга, әле яна башланып киткән XXI гасырда да якты үрнәк булып торачак.

Әлбәттә, чын реалистик прозаның Еникилар тоткан төп юлын дәвам иттерүчеләр яшьрәк буын каләм ияләре арасында да бар. Мәсәлән, Чаллыда яшәп иҗат итүче каләмдәшебез Вахит Имамов соңгы елларда иҗади үсеш кичерә. Бигрәк тә аның тарихи темага язылган әсәрләре киң популярлык казанды. Әмма биредә, безнең көн тәртибендә заман герое проблемасы торгач, бу әдипнең заман темасына язылган әсәрләренә тукталасы килә. Алар арасында иң уңышлысы һәм уку өчен дә кызыклысы, минемчә, "Могикан" повесте булды. ("Идел" журналы, 10 сан, 2000 ел).

Кайсы ягы белән кызыклы иде соң бу әсәр?

Минемчә, татар халкы, татар җире соңгы елларда дучар булган фаҗигане геройлар язмышы аша тәэсирле итеп тасвирлавы белән, әнә шул тетрәндергеч хәлне үзәккә куюы белән игътибарга лаек бу повесть.

Әсәрнең төп герое—"Могикан" исемле чабышкы ат. Ана исем сайлау, исем кушу повестьта шулай ук ышандырырлык итеп һәм бик тә мәгънәле күренешләр аша тасвирлана. Вәлит исемле яшүсмер һәм аның дуслары Америка язучысы Фенимор Купер әсәрләрен укып җенләнеп йөриләр. Аларның телләрендә дә — Чингачгук, мустанг һ. б. шуның ише сүзләр. Ф. Купер китабындагы вакыйгалар Америка җирлегендә бара: биредә яшәп яткан индиан кабиләләрен буйсындыру, тез чүктерү, юк итү өчен аяусыз көрәш бара!

Менә шушы урында әдип каләме татар укучысы өчен гаять мөһим булган эчке мәгънә катламын хасил итә. Укучы күңеленә бик тә таныш хискичерешләр агымын тудыра. Мондый эчке агым пәйда булуга күп фактлар ярдәм итә. Иң башта автор Могикан исемле яна гына туган бу колынның әнисе Шонкар исемле атаклы чабышкы булуын әйтеп уза. Бу момент укучы күңелендә татар халкының, төрки кавемнең данлы үткәненә, ерак тарих юллары буйлап узган язмышына бик ачык ишарә ясый, шулар хакында уйландыра.

Төгәл генә һәм төбәп әйтелмәгән очракта да ни өчен безнең күңелләрдә әнә шундый ассоциатив уйлар, фикерләр туа соң? Күрәсең, биредә безнең халык авыз иҗатында, һәм соңрак дәверләрдә шигъриятебездә, атның милли символга әйләнүе зур роль уйный торгандыр. Шагыйрьләребезнең ул хакта әллә никадәр шәп шигырьләре бар бит! Аннан соң, ат ул үзенең холкы-табигате белән дә безнең милләткә, холкыбызга бик тә охшаш, бик тә үз түгелме соң әле?! Ул—эшчән һәм күндәм дә, бер үк вакытта чыдам һәм көчле дә, ә инде ярышларда баш бирергә яратмаучы, карап торганда сокландырып чаба алучы менә дигән чабышкы да!

Могикан дигән яшь чабышкы белән якыннан танышканчы Вахит Имамов безнең күңелләргә әнә шундый уй-тойгылар, әнә шундый мәгънәле-хисле дулкыннар сала.

Ә инде әсәр геройлары Могикан белән яшүсмер Вәлитнең дуслыгы, аларның беренче чабышка чыгулары—болар шигырь дәрәҗәсенә күтәрелеп, автор үзе дә чын-чыннан илһамланып иҗат иткән урыннар! Биредә В. Имамов "Алмачуар"ны тудырган Г. Ибраһимовлар, ат турында берничә гүзәл повесть ("Хуш, Гөлсары" һ.б.) язган Ч. Айтматовлар дәрәҗәсенә үк күтәрелә.

Әмма вакыйга татар җирлегендә бара... Узган гасырнын житмешенче елларында... Татарларнын тарихи ватаны булган оҗмах кебек җирләрдә КамАЗ дигән гигант завод кору башлана.

Милләтнең гасырлар буена оешып, ныгып, үсеп килгән табигый җирлегенең җимерелүе, юкка чыгарылуы бу әсәрдә бик тәэсирле, тетрәндергеч күренешләр аша ачыла: күлләр-чишмәләр, авыллар юкка чыга, әйберләр югала-талана-урлана башлый, кешеләр арасында сугыш-үтереш күбәя, күпләр үзенә-үзе кул сала, асылына...

Вәлитнең күз салып йөрегән кызы Мәрьямне көчлиләр... Аннары инде Вәлиттән бүтән кешегә баш бирергә теләмәгән—биленә ияр салдырмаган Могикан әрәм була... Иң сонында яшүсмер егет Вәлит яна каланың иң биек йорты түбәсенә менеп аска ташлана!

Шулай итеп, әлеге зур завод, яна кала әсәрдә фаҗига чыганагы—бөтен кешелеккә, кешелеклелеккә, бигрәк тә татар милләтенә зур зыян китерүче Кара көч рәвешендә чагылыш таба. Алдарак Р. Фәизовның "Тәнре хөкеме" исемле фантастик повестен карап узган идек бит әле—ул әсәрдә бөтен җир шарындагы тереклекне зур Һәлакәткә алып килгән техника прогрессы—нәкъ менә шушы инде! Ул бүген безнең борын төбебездә, күз алдыбызда.

Әсәрдә безне сокландырган Могиканның үлеме, керсез күңелле яшүсмер егет Вәлитнең үз-үзен үтерүе—болар барысы да уяу җаннар өчен бүген зур кисәтү, ныклы искәртү!

Талантлы әдип В. Имамовның шундый тирән мәгънәгә һәм зур тәэсир көченә ия әсәр иҗат итүе—әдәби герой тудыруы—соңгы елларның кызыклы образлар галереясын тагын да баетты.

Сүземнең ахырында тагын бер мәсьәләгә тукталып узасы килә.

Безнең әдәбиятыбыз бүген Көнбатыш һәм бигрәк тә Америка идеологиясенә каршы позициягә басып, рухи яктан бай булган, чын кешелек сыйфатларына ия Кеше образын расласын, шуның өчен көрәшсен иде. Югыйсә, хәзер Рәсәй сәясәтчеләре дә Америка үрнәгенә ияреп, күбрәк физик көчне генә танымакчылар бит! Бөтен бәхәсле мәсьәләләрне бары тик физик көч ярдәмендә генә хәл итмәкчеләр. ("Будем мочить!" дигән девиз белән). Ә шул ук вакытта үзләре: "Каян килеп чыга бу терроризм?" дип аптыраган, гаҗәпләнгән кыланалар! Сон, бәхәсле мәсьәләләрне гаделлеккә таянып һәм сөйләшү-анлашулар ярдәмендә, бары тик шулар нигезендә хәл итәргә теләмәгәч—каршы якны бөтенләй тынларга да, ишетергә дә теләмәгәч—әлбәттә, терроризм килеп чыга инде ул!

Биредә әдәбият турында сүз барганда сәясәткә кереп чыгуның максаты шул иде: без, безнең халык, аларга каршы бары тик рухилыкны гына куя ала. Ә физик көчкә генә таяну исә аерым шәхесне дә, илне дә, тулаем дөньяны да бары тик тупикка гына алып бара! Ул—терроризмны барлыкка китерү һәм аны даими үсендереп, дәртләндереп тору юлы! Безнеке кебек чагыштырмача күпсанлы булмаган милләтләр өчен ул бигрәк тә ялгыш һәм куркыныч юл!

Безгә исә бүген әдәбият аша гына түгел, ә бөтен матбугат һәм радио-телевидение аша, рухи яктан бай, гармоник үсешкә ия Кеше тәрбияләү эшен оештырып җибәрәсе иде. Ягъни яшьләрне дә, тулаем милләтебезне дә рухи-әхлакый яктан тәрбияләү турында сүз бара биредә. Совет хакимияте елларында һәр мәктәптә һәм җәмәгать урыннарында "Коммунизм төзүченең әхлак кодексы" эленеп тора иде бит әле. Шуларны тормышка ашыру буенча байтак кына чаралар да үткәрелә иде. Бу яктан караганда "Идел" журналында быел январь аеннан башлап басыла килүче "Татарның әхлак кодексы" (аны Т. Миннуллин алып бара) һәр яктан хуплауга лаек. Инде хәзер мондый эшне республика күләмендә әһәмиятле программа буларак кабул итәргә һәм төрле оешмаларны (иҗат берлекләрен дә кертеп) колачлаган системалы чаралар рәвешендә тергезеп җибәрергә кирәк.

Заманыбызның унай героен тәрбияләп үстерү—әдипләребезнең генә түгел, ә бөтен җәмгыятебезнең уртак максатына әверелсен иде!

## Нурулла Гариф

# АКЛАНАЧАК ӨМЕТ

“Безнен заман герое”. Шушы темага язасым килеп йөргән фикерләремне туплап каләмемне алдым да, туктальш калдым. Ошамый миңа бу “герой” дигән сүз!. Безненчә түгел бу!. Инде татар турында борчылып, халкыбыз яшәешенә бәйле өмет уятырлык милләттәшләребезне эзлибез икән, ул безнең батыр, каһарман яисә милли әйдаман булсын. Кешелекле түгел, гади кеше булып яшәү дә батырлык саналган заманда— бигрәк тә!. Аннан — сугышлар заманы түгел хәзер. Бүгенге көндә халыклар анын яулау өчен барган көрәш тел, дин, гореф-гадәтләр аша уза. Рухи үлем яисә исән калу, милли тәрбия мәсьәләсенә тоташа ул.

Киләчәгебезгә өмет бирерлек милләттәшләребезне эзләп йөрим. Акылымнын бер читендә өметсезлеккә бирелгән шайтаннар кычкырып көлә: “Эзләгәнегез туарлык, туса да исән калырлык, яшәрлек җирлегегез бармы сон сезнен?”

Язучылар иҗат иткән, өмет белән яшәткән әдәби шәхесләр күп очракта шәһәрләрдә туа. Дөрес авылда туучылары да бар. Әмма алар, барыбер, әсәрнең башында ук авыл кысаларына сыймыйча шәһәргә яисә чит җирләргә китә. Гомер буе үз-үзен табарга омтылып яши. Без аларны дөнья читенә үк алып барып, язмыш кочагына ташлыйбыз. Аларга урман кисterәбез, нефть таптырабыз, җәһәннәмгә төшереп ташкүмер чаптырабыз яисә очсыз-кырыйсыз дингезләргә чыгарып, балык тоттырабыз. Урыс яисә башка милләт кешесе белән дуслаштырабыз. Аннан марҗага өйләндерәбез. Сонрак бер баетып, бер хәерчелек чигенә төшереп, төрле сынауларга ташлыйбыз. Башка милләтләр түзә алмаслык халәттә калдырабыз, әмма үтермибез. Чөнки аны әле картайтасы, үз язмышына ук охшатып, балаларын да төрле тарафларга таратасы бар. Аннан сон туган ягын, беренче мәхәббәтен исенә төшереп, уйландырасы бар. Күнелен телгәләп, яндырып азаплагач, туган авылына кайтарып үкендерәсе, туган туфрагы - йорт нигезенә тезләндерәсе, әти-әнисе кабере янында үксетеп елатасы бар. Татарның акылы бары төштән сон — гомер уртасы яисә ахырында гына — сонарып киләсе безнен акылга сендерелгән инде. Әйтерсен лә татар язмышы бары шундый гына булырга тиеш?!

Хәер, сюжетларнын башка төрлеләре дә бар. Мәсәлән, менә бер татар түрәсе, бае. Акчасы да, сөяркәләре дә күп, мөмкинлекләре дә зур. Нигә типтермәскә, ике тапкыр яшәми лә ул. Бездән сон ник дөньясы аркылыга килми... барыбер бер үләсе. Яшәп кал! Әйе, ул да әсәр ахырында ярык тагарак алдында калачак. Үкенү, чын үкенү туачак анда. Әмма эш узгач үкенүдән ни файда?! Монысы да татар язмышы. Без һаман милләттәшләрнең гыйбрәтләрен җыеп, гайбәтләрен генә чәчәбез сыман... Ә яшь буын, ялгышмаслык, үрнәк алырлык безнен заман каһарманы нинди булырга тиеш сон?

Без зур үзгәрешләр заманында яшибез. Бүгенге көн әдәби шәхесләре игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнми, төрле төзелешләргә китәргә, чирәм җирләрне эшкәртергә дә омтылмый инде. Хәзер армия хезмәте, сугыш хәбәрләре, базарлардагы алып-сатарларга бәйле акчалы, криминал темалар алга чыкты. Дөрес, бер мәңге үзгәрмәс тема калды калуын... Әмма мәхәббәт өлкәсендә дә хисләр чагылышы, ярату-яратышулар элеккеләреннән күпкә үзгә — шәрәрәк инде.

Халык язмышы өчен борчылмаган язучы булмый! Заман шәхесләре шул омтылыш, борчылулардан туа. Шул шәхесне эзләп, татарнын башкаласы,

анын да иң үзәге Бауман, элекке Проломный, әмма дөресе, булырга тиешлесе - Азатлык урамында йөрим. Кешеләрнең күзләренә карыйм... Тән ымсындыргыч кызлары, кайсы ишеккә керсәң шунда шәраб дингезендә йөзәрлек экзотик урыннары, һәр тишек-тәрәзәдән агылган бөтен дөнья халыкларының моң-сагышлары, дәртле җырлары... бар да бар монда. Әмма күңел ашкынганы, йөрәк талпынганы — миллилек кенә юк!

Тагын бер күңелдә калганы: матур кешеләр аз хәзер... Һәрхәлдә минем аларны Бауман урамында очратканым юк әле. Хәзерге яшьләр мәхәббәткә караганда мал-мөлкәткә күңелен күбрәк сала. Шул байлыкка әшнә-түрәлек кушыла, алары башка исәп-хисапларга бәйле мин-минлеккә тапкырлана. Шул сәбәпле матур кешеләр азайды. Сәләтле, матур, көчле кешеләр саф мәхәббәттән генә туа күрәмсең. Мин эзләгән шәхес тә шундый булырга тиеш!

Бауман урамында бар да бар, бар да сатыла. Кирәк булганча ал, күзең туйганчы кара, кешелегең югалганчы шулар арасында кал гына... Әлеге урамның ишек аллары мәрмәрдән булса да — тел-иманыңны, бар миллилегеңне суырып алырдай сазлыклы урын бу. Бу баткак җирдә мин эзләгән шәхес туа, туса да яши яисә үзе булып кала алмас... Бауман урамы шушы чикләрдә генә калып, безнең өчен гыйбрәт алырлык урын буларак кына саклана иде. Ул киңәеп, бар-юньгә таралса, кешелек дөньясы юкка чыгачак, анда милли каһарманнар туу түгел, гадиләренә дә исән калу мөмкинлеге булмаячак.

Заман шәхесен эзләп татар бистәсенә юнәләм. Уйлавымча, татарны күтәрерлек шәхесләр - милли әйдаманнар — шушы җирдә туарга, мәчет-мәдрәсәләрдә белем алырга тиеш. Ул көн әле туар! Әлегә татар бистәсе турында 20 елдан артык сөйләсәләр дә ул бүгенгәчә хәрабәләр эчендә ята бирә. Шул хәрабәләр эченнән чыгучылар ил-шәһәр күгендә түрә бүген. Алар — милли тәрбия алмаган, күңелләренә азан моңы сеңмәгән буын вәкилләре. Бу шәхесләр бүгенге көндә үз туган йортлары булган Татар бистәсенең каршы ягында гына Баскетхол, метро-юллар төзиләр. Ә бит әлеге төзелешләргә киткән акчаларның бер өлеше генә дә татар бистәсен тар читлектән чыгарып, гөлбакчага әйләндерергә җитәр иде!

Күңелдә тагын бер борчу бар. Барысы да элеккечә калса, әлеге хәрабәләр арасында замана шәхесләре туар микән? Монда вакытымны юкка сарыф итүдән куркып, халкыбызның гасырлар буена тибрәлгән асыл бишеге — татар авылына кайтам. Авылдадыр ул мин эзләгән заман кешесе. Ул тырыш, хезмәт сөючән, телле, динле һәм тәрбияле булырга тиеш!...

Авылдан чыгучылар — тырыш, сәләтле. Авылның иманы да чыгып бетмәгән, әхлагы да югалмаган әле. Шулай да безнең хыялдагы авыллар без күзаллаганнан үзгә инде. Без яшь чагындагы күреп белгән самими беркатлылыклары юкка чыккан аларның. Авылларның күбесе, шәһәр туганы кебек, газлы-сулы, асфальт юллы хәзер. Әлеге юллар авыл яшьләрен шәһәргә илткән. Шул сәбәпле авылдан чыгучыларның күбесе ил түрендә түрә хәзер. Бәлкем алар арасынннан табылыр мин эзләгән заман кешесе? Ил өстендә иләмән булып торучы милләттәшләребез дә күп. Татар язмышына, яшәеш-тормышына жан өрерлек, жай бирлек мөмкинлекләре зур булучылар күп әшли монда. Әле кайчан гына Ирек мәйданында ирек сорап шулар каршында торган идек без. Алар арасында чын дәрәҗәдәге милли шәхесләр дә аз түгел! Шәхсилеген генә кайгырткан шәхесләр арасында алар милләтебезнең энҗе бөртекләре булып күренә. Тик алар да бер үзләре генә нәрсә кырыр икән?

Шәһәр кешесе булганнарга авыл сыйфатларын саклап калу авыр. Шәһәрләр шәрәлекне яратып, чәч-төсләрне, уй-фикерләрне тиз үзгәртә. Шәһәрнең ымсындырган урыннары да күп анын. Тик барысы өчен дә акча кирәк. Гади кешегә акча табу чарасының иң өметлесе — базар юлы. Мин эзләгән шәхес тә шул тирәдә адашып калмадымы икән? Өметемне өзмим, базарда йөрим. Базар бай. Базар абзаның күзе зур, колагы барыннан да хәбәрдәр, уй-фикерләре дә аек. Базар күп төрле телләр белә, шул телләрдә

сөйләшә, сөешә. Шуңа да карамастан, анда да миллилекнең тамчысы да юк. Базарда халык бихисап. Бары да җаена җайлашып, бар теләгенне үтәргә әзер тора. Кайсы телдә сорасаң шул телдә җавап тоталар. Менә боларның һәрберсенә "герой" дәрәҗәсе бирсәң дә була. Мин эзләгән шәхес өчен дә кирәкле сыйфатлар күп монда. Әмма аларның бар алыш-бирешләре, елмаю, сайраулары бары да акча мөнәсәбәтләренә генә корылган шул. Акчага бәйлелек югалмый торган сыйфатка әверелгән урын бу. Бушка булганда монда үз туганың да артыгын сөйләшмәс. Шулай да, базар ошады миңа! Эзләгән һәм күрәсе, сокланып, өметләнәсе килгән шәхесемне бер ай гына булса да базарда эшләтеп алыр идем мин. Тик артыгын кирәкми. Гыйбрәт алыр өчен шунысы да бик җиткән...

Яшәүнең бөек мәгънәсе бар! Язучылар тудырган шәхесләр шул мәгънәне табарга ярдәм итәргә тиеш. Эзләүчеләре, өмет-хыяллар белән яшәүчеләре һәм шул юнәлештә хезмәт куючылар күп булганда заман батырлары безнең арада туачак. Вакыт узышында аларның сафлары да тулыланачак.

Шушы урында фикерем өзелеп, күңелдә бер хатирә яңара.

2002 елның май ае. Китап чыгару теләгеннән "Иман" нәшрияты башлыгы Вәлиулла хәзрәт янына бардым. Сүзебез шул ук темага—заманасын үзгәртерлек шәхесләр турында — бара. "Иман" нәшрияты китап чыгару эшенә әдәби әсәрләрнең темасына карап кына алына икән. Хәзрәт минем дини темаларга бәйле нинди әсәрләр укуым һәм аларның ахыры ничек бетүе турында сораша. Фәүзия Бәйрәмованың "Соңгы намаз" романы турында фикер алышабыз. Дини темага язылган күләмле беренче әсәр бу. Романның яхшы якларын билгеләп, ахырының фаҗига белән бетүе өчен генә борчылабыз. Хәзрәт миңа сорау бирә: "Нигә дингә килгән кешенең язмышы үлем белән бетәргә тиеш?Ниләр генә язмыйсыз — язмаларыгыз тулы өметсезлек! Өметсезлек белән кешене куркытып кына була, тәрбияләп булмый. Дингә килгән кешедә җаваплылык хисе, өмет һәм яшәү теләге уяныргa тиеш! Уйла, фикерең булса яз. Китабыңны чыгарырмын",—дип, ышандырып озатып кала. Кеше кушуы буенча әсәр язылмый ул. Әмма хәзрәтнең бу сүзләре уйландырды, күңелдә туган фикерләр кәгазь битләренә күчеп бетмичә тынычлап йоклатмады мине. Милли каһарманым белән бергә яшәдем, барын да уртак кичердем мин. "Акланган өмет" китабым шулай туды.

Язучы әсәренең шәхесе тормыштан алына. Дөрес, аның тормышы фантазияләр белән баетылып, төрле төсләргә маныла. Ә менә мин күреп белгән шәхес — бай. Ул беркемгә дә ялынмый, табынмый. Эшләмәсә дә байлыгы бар, туган-тумачасына, нәсел-нәсәбенә җитәчәк аның. Әмма аның күңеле тыныч түгел. Байлыгының күпләргә җитәсен белсә дә, кемнәргә каласын белми ул. Дөрес, ул башка буын вәкиле... Аннары гореф-гадәтләр югалган, әхлак тапталган вакыт... Җитәкче буларак эшләү мөмкинлеген бирүче кагыйдә буенча (кайберәүләр шундый кагыйдә бар дип саный), хатыны да башка милләт вәкиле. Нинди булыр, кемнәр чыгар аның нәселеннән? Гасырлар буе исән-имин килеп җиткән милли тормыш бу нәселдә аңа җиткәч кенә өзелеп калмасмы? Бу гөнаһлары өчен җәзабы нинди булыр? Шул тынгысыз уйлар аны кайчандыр мулла бабасы куылган авылына алып кайта... Шәһәрдән авылга капитал кайтаручыларга акчасын суга салучыларга карагандай вакыт бу—сиксәненче еллар ахыры... Дөньясы әле болганып кына утыра...

Минем каһарманым бабасының авылы белән бергә үз гаиләсен, нәселкиләчәген саклап калырга омтыла. Мәчетен сала, асфальт юлын төзетә. Авыл халкында бабасына карата сакланган хөрмәтне үзенә дә кайтара... Бабасы йортын торгызу эше белән йөргәндә кече улы мәдрәсәдә белем алучы авыл кызы белән танышып, кавыша. Ирендә һәм бөтен татар дөньясында барган үзгәрешләрдән баштарак куркып калган хатыны Надежда—Нажия дә югалып кала... Тик ул иренең теләк-омтылышларына каршы чыга алмый, гаиләсен саклап калу бәрабәренә аны аңларга тырыша...

Урыс ягына авышып бетә язган тормыш, акрынлап татар мохитенә дә йөз белән борыла. Авылдан килгән апалары ярдәмендә олы улының улы-кызы һәм оныклары да туган телләрендә сөйләшә башлыйлар. Кечкенә булсалар да аларның тормышта үз хыяллары да бар икән инде! Бер оныгының апасы кебек укытучы буласы килсә, икенчесе "үскәч олы бабам кебек мулла булам" дип хыяллана...

Бу сүзләрне ишеткәннән соң: "Ринатның күзләреннән, язның беренче шифалы яңгырлары кебек, яшьләр акты. Язмыш-язның ничәнче кат кырау-кыркуларына карамастан, оның-нәселендә киләчәгенә өмет биреп, иман орлыклары шытып чыгуына ничек шатланмыйсың?! Шуның өчен көрәшә, яши лә ул!".

Тик тормышта бары да алай шома гына бармый шул...

Дөнья күпкырлы. Анда һәркемнең үз "герое", милли каһарманы. Кемдер аны хыялында тудыра, кемдер күңелендә йөртә, кемдер аны тормышта үзе табып, табына. Без яшь чакта "герой"ларны чит халык вәкилләре: Павлик Морозов, "Александр Матросовлар" үрнәгендә көчләп такканнар иде. Үлемсатуга корылган үрнәкләр үз милләтебез арасында булса да... Бүген бар да үзгә инде. Тик татарны йолдызга меңгерсәң дә, җир күчәрен "майларга" дөньясының төбенә төшерсәң дә, горурланучысы, иярүчесе табылырмы икән?

Тормыш "геройларын" физик көчкә бәйле итеп кенә күрергә теләүчеләр дә юк түгел. Физик көчкә ия булу өчен күп акыл кирәкми. Җитмәсә, бу эшчәнлек, без яшәргә мәҗбүр ителгән дәүләтнең төп сәясәтенә әверелеп, мактала да бит әле! Физик сәламәтлекне нығыту өчен бар да бар хәзер. Хәлбуки көч, физик яктан сәламәтлекне кайгырту, күп очракта төрле сугышлар алып барырдай хәрбиләр кирәклектән чыгып эшләнә. Шунысы кызганыч: физик яктан сәламәт булучылар, рухи сәламәтлеккә, рухи камиллеккә бик омтылмыйлар. Бәлкем, көч акылдан алдан йөргән безнең заманда шулай булырга тиештер?! Өстәгеләр акыл көче Рәсәй империясен җимерәчәген белә һәм шуннан курка да.

Киләчәккә өмет тотып милли каһарман эзләп йөрим.

Гасырлар буе кол дәрәҗәсендә тотылган милләтебезне ничек коткарасы? Муса пәйгамбәр кебек чүлдә адаштырып йөртеп, коллык хисләрен юк итәрлек шәхесне каян табасы?! Чүле түгел, адашырлык калын урманнары да юк бит аның! Аннан соң, кырык ел түгел кырык көнендә дә башкалардан кырык елга артка калырдай заман хәзер.

Киләчәккә өмет тотып милли каһарман эзләп йөрим. Күңелемдә бер өмет — җавап та бар: иярүчеләре, ышанучылары булса, аларны әйдәрлек, җитәкләрлек милли каһарманнар табыла ла ул!

Шул сәбәпле безгә бүген ышанучылар, киләчәккә өметен югалтмаучылар катламын ачарга, шул үрнәктә яшьләрне тәрбияләргә кирәк. Бу эшне әдәби эшчәнлектә дә, көндәлек тормышта да нидән башларга кирәклеге инде билгеле... Беренче үзгәреш-адымны үзебездән башлыйк!

⁂

**Гаяз Исхакый**

# ИСЛАМ МӘМЛӘКӘТЛӘРЕНДӘ*

***

Фәләстин дөньяның иң зур диннәреннән булган исламият, христианлык һәм яһүдилекнең өчесенә дә мөкаддәс җир саналганга, анда булганнарны, анда күргәннәрне, анда ишеткәннәрне язып бетерергә һәм аларны мәҗмуга мәкаләсенә сыйдырырга һичбер төрле имкян (мөмкинлек) юк. Аларны, вакыты килгәндә, үземнең көн дә язып килгән хатирә дәфтәремне бастырырга кадәр калдырып торып, укучыны Мисырга таба алып китәргә мәҗбүрмен. Фәләстиннән Мисырга иң кыска булган юл—тимер юл. Кантарә дигән җирдә Суйэш (Суйәэш—Суэц) каналы аша чыгып, Мисыр туфрагына керелә. Бу канал Кызыл дингез берлә Ак дингезне (Урта дингезне) берләштереп, Африка берлә Азияне бер-берсеннән аера. Бу канал буенда инглиз гаскәре Мисыр өчен бик каты сугышканга һәм төрек гаскәре җинелеп чигү аркасында, Мисырны гына түгел, Фәләстин, Сүрияне дә ташлап чыгарга мәҗбүр булганга, бу җирләр яна төрек тарихы өчен дә мөһим урыннар.

Мин бу каналны беренче мәртәбә 1919 елның декабрендә Владивостоктан Триестка килешли үткән идем. Ул вакытта канал буенда ныгытылган җирләр дә күренеп торганга, Исмәгыйлия дигән шәһәр янында төрек әсирләренең дә лагерьлары күзгә ташланып торганга, шул хакта хатирә дәфтәремә озын гына язган идем. Хәзер дә шуңа арттырылачак нәрсә күп юк. Ләкин ул вакытта миңа төрек гаскәре лагеры дип күрсәтелгән җирдә берничә татар гаиләсе дә әсир булып яткан икән. Алар бер вакытны: "Ислам динен саклыйбыз",—дип мөкаддәс Мәккә һәм Мәдинәгә Идел буеннан күчеп килгән мөһаҗирләр булганнар икән. Дөнья сугышы вакытында гарәпләр инглизләр яклы булып, төрекләргә каршы сугыш ачкач, безнекеләр дә төрек саналып, йортлары-җирләре таланып, маллары алынып, бик күбесе үтерелеп, калганнары шул лагерьга ябылган булган икән. Аларның кайберләре, лагерьдан-лагерьга күчерелеп йөрткәндә, үлеп беткәннәр. Кайберләре Фәләстин, Сүрия һәм Төркия эченә таралып киткәннәр.

Мин аларны соңгы озын сәфәремдә эзләп таптым. Аларның туктамастан аккан күз яше эчендә башларыннан үткәннәрен сөйләгәннәрен сәгатьләр буе тыңлап тордым. Инглиз хатере өчен, гарәби-төрек дип, урыс хатере өчен, төреге-татар дип, һәрбер унгае килгәндә, һәр яктан кыйнала торган бу милләттәшләремнең кара бәхетенә мин дә эчемнән еглап утырдым һәм шул кара язмышның сәбәпләрен эзләдем. Бу эшкә инде шактый күп вакыт үткәнгә, шул мәсьәләләрнең эчендә булган гарәпләрдән дә аның сәбәбен сорадым. Алар:

—Бу диннәрен сакларга дип Хиҗазга күчеп килгән сезнең татарларга каршы һичбер дошманлыгыбыз юк. Сугыш вакытында эшләр шулай китәчәк иде. Ләкин алар гарәп гыйсъянын (фетнәсен) һичбер төрле аңламадылар. Хәлифәгә каршы баш күтәрәсез, мөселманлыкның мөкаддәс җирләрен кяферләр кулына бирергә телисез, без шуны күрер өчен кяфер җиреннән ислам туфрагына күчеп килдекмени? Кайтыгыз бу ялгыш фикердән. Юкса, кяфер буласыз, әстәгъфируллаһ (Ходай кичерсен!), әстәгъфируллаһ, дип сөйләделәр дә тордылар һәм безнең гади халыкка да тәэсир иттеләр. Мәккә шәһәрендә боларның башлыклары булган, татар шәкертләренә дә бик күп ярдәмдә булынган бай татар сәүдәгәре Гомәр карт бар иде. Ул гарәпләр арасында хөрмәтле бер мөселман иде. Шәриф Хөсәен аны үзенә чакырып: "Син татарларның хөрмәтле агасы, без сине татарларның консулы ясыйк. Син бөтен татарлар исеменнән миңа бәйгать (сүз; вәгъдә; ант) бир",—дигән. Гомәр карт та кып-кызыл чөгендер кебек булып: "Бу җир—Мәккәи мөкәррәмә. Дине исламның туган урыны. Син пәйгамбәрнең балаларыннан бер кеше. Мин дә динне саклар өчен кяфер йортыннан килгән мөһаҗир. Син ничек оялмыйча шул изге җирдә минем хәлифәгә (Госманлы солтаны бер үк вакытта хәлифә дә исәпләнгән) биргән антымны бозып, кяферләр эше артыннан

*Дәвамы. Башы 4 санда.

йөрүчеләргә ант итәргә кушасың? Син ничек пәйгамбәрдән оялмыйсың? Син мине консуллык берлә кыздырмакчы буласыңмы? Бөтен гарәп туфрагын гына түгел, бөтен Госманлы падишаһлыгын бирсәләр дә, мин иманымны сындырмыйм һәм антымны бозмыйм. Мин ялганчылык эшләргә теләсәм, аны урыс йортында эшләгән булыр идем. Син эш моның берлә генә кала, дип уйлыйсыңмы? Бөтен ислам дөньясы сиңа ләгънәт укыячак",—дип әмир Хөсәенне нәсыйхәтләргә тотынган (Бу биттә Мисырдагы "Җамигъ әл-Әзһәр мәчетенең рәсеме бирелгән). Табигый, Гомәр картның бу сүзләре инглизләргә дә ишетелгән. Үзе, балалары һәм аның милләттәшләре дә төрекчә хисап ителеп, маллары алынып, үзләре төрмәгә һәм лагерьларга ябылган, диделәр.

17-18 гасырларда кырым татарларының фидакарьлеге берлә генә дәүләтлекләрен саклаган Госманлы төрекләренең боларны "пис (шапшак) татар, хунхор (явыз; канечкеч) татар, монгол",—дип, кызыл һәм кара урысларның хәтере өчен, боларга һәр төрле авырлыклар ясауларының сәбәпләрен дә бик күп эзләдем. Бер төрек дипломаты (болай диде.) (Аның сүзләрен Г.Исхакый төрекчә китерә. Без аны татарчага якынайтып бирәбез):

—Әфәндем, без руслар, хосусан большевиклар белән дуст яшәү мәҗбүриятендәбез. Бу—бер дәүләт мәсьәләседер. Моның өчен русларны, хосусан большевикларны көчәндермәвебез ляземдер. Хәзерге әхвалгә багыгыз: сезнең татарлар бирегә килеп:— "Әфәндем, руслар безгә бу фәналыкны (зыянны) эшләде, ул фәналыкны кылды. Мәктәбебезне япты, җирләребезне алды",— дип кычкыра башладылар. Шикаять, гел шикаять. Валлаһ (Алла өчен), руслардан риза дигән бер кешене очратмадым. Болар безнең садә күңелләребезгә тәэсир итәләр. Бередә төрекчелек... кеби агымнар (карашлар) уяндырдылар. Дөресен әйткәндә, бу төр карашлар безнең күңелне болгаталар. Боларны эшләүчеләрнең һәммәсе—сезнең татарлар. Монда килеп оста итеп язалар, "төрекчелек, төрекчелек",—дип кычкыралар. Шул көннәрдә рус дусларымнан берсе бер китап күрсәтте. Бер әрмәни тарафыннан русча язылган бу китап сезнең татарларның анда үз мәмләкәтләрендә төрекчелекне таратуыгызны, төрекчелек өчен большевиклар белән дошманлык итүегез хакында яза. Коммунистлар партиясенә язылсалар да, төрекчелекне таратырга телиләр. Сез безгә дуслыкны бәхәс итәсез. Чынлыкта исә сезнең арадагы кардәшләр ни эшлиләр,— диде. Французча тәрҗемә ителгән берничә юл укыды. Борчылуымнан ни эшләргә белмәдем. Хәзер безнең эшләребезгә зыян китергән иптәшләрне мин безнеке дия аламмы? Әлбәттә, әйтмәм. Мин боларның мәмләкәтендә "төрк, төрк" дип кычкыруларына ярдәм итәрменме? Табигый, итмәм. Тыңлатмасам, ярар, ...кит, диярмен, куармын,—диде.

Мин моның да фикерен һәм аның фикерен йөрткән эгоизмын(?) аңладым. Ләкин изге урыннарны мөселманнар кулында сакларга теләгән Гомәр картның гарәплек ноктасыннан мөселманлыкка никадәр гөнаһ булганын һәм коммунист фиркасенә язылса да, төрекчелек сәясәтен йөртергә теләгән татар коммунистының урыс һәвәсенә китмәвенең төрекчелек ягыннан нинди зур гөнаһ булганын аңламадым. Вазгыятьләребез Гомәр карт берлә Шәриф Хөсәен вәзгыяте кебек булганга, сүзне кыска кисәргә мәҗбүр булдым. Бу татсыз вакыйгалардан татар укучысының үзенең дә төрле тәмсез мәгънәләр чыгару ихтималы юк түгел. Ләкин бу мәгънәләр таякны икенче якка бору төсен алмасыннар иде һәм без дә диндәш һәм кардәшләребезнең бу хәрәкәтләренә шулай җүләрләрчә җавап бирмәсәк иде. Чөнки болар да вакытлы һәм киләчәк эшләр.

Тимер юл Фәләстиндә һәм Мисырда да шактый былчырак. Вагоннар уңайсыз. Гүмрүк (таможня) мөгамәләсе дә Европадагы кебек түгел. Мисырның паспортларны карый торган полисе:

—Каһирәдә кайсы отельгә төшәсең?—дип җанымны алды. Мин, Каһирәгә беренче баруым булганга, һичбер отельнең исемен һәм адресын белми идем. Шуңа ачык җавап бирә алмагач, паспортымны алып калды да, аны отельгә урнашкач полис мәркәзеннән барып алырга кушты.

Мисырга төнлә берлә сәгать унберләрдә генә барып кергәнгә, табигый, шәһәрне һичбер төрле күрә алмадым. Андагы отельләрне дә белмәгәнгә, юлда туры килгән берсенә индем (туктадым). Ул пакь мәхәлләләренең берсендәге бер яхшы француз отеле булып чыкты. Мисырда минем мөэтәмәрдән (корылтайдан) бик күп гарәп танышларым булса да, элек үзебезнең татарларны эзләргә киттем. Сугыштан элек Русия берлә мөселман дөньясы арасында табигый мөнәсәбәт булганда, монда безнең Идел буеннан килгән укучыларыбызның саны бик күп була иде. Алар Мисырның милли-мәдәни агымнарында катышалар, илебездәге тәҗрибәләрен Мисырга китерәләр һәм Мисырда алган мәгълүматларын Идел буена алып кайтып тараталар иде. Соңгы гасыр башларындагы милли хәрәкәтләребездә зур урын алган галимнәребездән Муса Биги, Петербур имамы мәрхүм Лотфулла Исхакый, "Галия" мөдәррисе Зыяэддин әл-Камали, мөхәррирләребездән Закир әл-Кадыйри, Габделбарый Баттал әфәнделәр Мисырда елларча укып һәм укытып, өйрәнеп һәм өйрәтеп, илебезгә кайтып хезмәт

иткән кешеләр иде. Болардан башка да әллә никадәр мөдәррис, мөхәррир, галим һәм имамнар хәзерләнеп кайткан һәм шулар аркылы Мисырның сәяси агымнары берлә бергә, аның гыйльми тормышы да безнең Идел буена китерелеп мал ителгән иде. Гарәпчәдән бик күп китаплар безнең телебезгә тәрҗемә ителгән иде. Безнең кичергән дәверебез табигый булса иде, гыйлемгә сусавын калдырыр (? кандырыр) өчен бөтендөнья дарелфөнүннәренә тарала торган татар яшьләре бүген Мисыр дарелфөнүннәрендә дә йөзләп-йөзләп саналган булыр иде. Ләкин СССРдан чыгу кяферләргә тәмуггтан котылу дәрәҗәсенә китерелгәнгә, Мисырга соңгы унөч ел эчендә бер генә дә татар яше килә алмаган иде. Анда булганнары да сугыштан элек чыгып, дөнья өстеннән үткән туфаннан монда сокланып кала алган кешеләр генә иде. Мондыйлардан Уфалы бер яшь галимебезнең монда икәнлеген мин ара-сыра идарәгә язган хатларыннан белә идем һәм шуның аркылы башкаларны да таба алырмын дип уйлый идем. Шунар күрә беренче иттереп аны эзләргә киттем.

Автомобиль берлә озын юллар үтеп, тар һәм киң урамнар кичеп, "Әзһәр" ("Әл-Әзһәр" мәчете һәм университеты күздә тотыла.) янында булган бер бинаның алдына килеп туктадык. Бу минем якташым Хәмзә Таһир бәк хезмәт итә торган көтепханә иде. (Бирелә "Шәйх "әл-жамигъ әл-Әзһәр" Мөхәммәд әл-Әхмәди әз-Зәһуринең рәсеме бирелгән. Мондый аңлатма да бар: "Узган Рамазан бәйрәмендә большевикларның ислам диненә иткән золымнарына каршы протест ясаган кеше".–Х.М.). Эш вакыты булганга, ул үзе дә монда иде. Ул минем Кодестан язган хатымны ала алмаган булса да, Мисыр гәзитләрендә минем хакта язылган мәкаләләрне укып, минем Мисырга да килеп чыгуымны көтеп тора икән. Килеп-киткән бөтен татарның Мисырда бердәнбер өзелеп калган милләттәшен эзләп табучыларны бик күп мәртәбәләр күргәнгә, минем дә эзләп килүчәгемне белеп тора икән. 17 яшендә Дим буен ташлап китеп, 18 ел гарәп дөньясында укыган һәм кайнаган бу татар егете, кичә генә Уфадан чыккан кебек, саф татарча сүзләр берлә мине каршы алды. Әйләнә-тирәдәге кешеләрне, аллагы эшләрне онытып, ил-йорт хатирәләренә чумдык. Көтепханәнең ябылганын көтмичә үк чыгып киттек.

Без Мисырның ислам тарихында зур роль уйнаган "Әзһәре жамигъы" янында идек. Минем танышларымнан бик күп кеше бу жамигъда укыган булганга, мин аны мөмкин кадәр тизрәк күрергә тели идем. Кечкенә генә мәйданны чыгып, жамигъка якынлаштык. Ул тыштан караганда гарәп өслүбендә салынган жамигъларның берсе иде. Аяк капларын (киемнәрен.) салып эченә керәбез. Тирәсенә җәелгән калын намазлыкларда шәкердләр дәрес хәзерләп утыралар. Кайберләре намаз укый. Жамигъның үз ишегенә килеп җиттек. Анда безне капучы (сакчы; каравылчы) туктатты: "Хәзер дәрес вакыты. Керергә рөхсәт юк",—диде. Хәмзә Таһир бәк мине ислам корылтаена килгән мөсафир дип таныштып, аерым рөхсәт алды.

Мәсжед кояш батышыннан кояш чыгышына каршы иттереп, озайтылып салынган. (Бирелә Кодес шәриф мөфтисе Мөхәммәд Әмин Әл-Хөсәйни рәсеме түбәндәге язу белән бирелгән: "Большевикларның Русиядәге яшәүче мөселманнарга иткән золымнарына каршы Милләтләр Лигасына мөрәҗәгать иткән кеше".–Х.М.).

Буена караганда ике-өч мәртәбә киң, түшәме бик күп баганалар берлә тоттырылган. Аларның саны өч-дүрт йөз кадәр бар икән. Аларның кайберләре янында мөдәррисләре тәбәнәк кенә бер көрсигә аякларын бөкләп утырып, тирә-юньнәрендә идәнгә утырган шәкердләргә дәрес әйтәләр. Берсенең янында—кырык-илле, икенчесенең янында—унбиш-егерме. Шәкердләрнең барысы да уку яшендәге яшьләр. Дәресләр иртән сәгать сигездән кичке алтыга кадәр дәвам итә, өйлә намазы вакытында ике сәгать туктап торыла икән. Мондагы мөдәррисләр, төрек жамигъларындагы кебек, бугаз ярылганчы кычкырырга мәҗбүр булмаганга, мәсҗед эче сүз ишетелмәслек бер тавыш берлә тулмаган. Мөдәрриснең сүзен шәкерд бик җиңеллек берлә ишетә. Аларның берсенең сүзе икенчесен борчымый. Ун-егерме мең шәкерде бар дип сөйләнгән "Әзһәр"нең эчендә бары 400-450 шәкерднең генә болай дәрес тыңлап утыруы минем хушыма китмәде.

—Башка шәкердләр кайда?—дип сорадым.

—Хәзер монда яңа тәртипләр куелды. Жамигъда хәзер илаһия берлә фикъһе (мөселман юриспруденциясе) шөгъбәсе (факультеты, бүлеге) генә калды. Башка фәннәр яңа биналарга күчтеләр,—диделәр.

Аннан чыгып, "Әзһәр" күршесендәге анда укучы төрк шәкердләренең тора торган җирләренә киттек. Ул берничә катлы зур өй икән. Эчендә алтмышлап аерым бүлмәләр бар. Моннан башка тагы "Әзһәр" йортының эчендә төрк шәкердләре өчен егермеләп бүлмә бар. Моны "Рәвакыл-әтрак" ("Төркләр бинасы") дип атыйлар. Монда бөтен төрк илләреннән килгән укучыларга буш бүлмәләр бирәләр. Элеккеге заманнарда аның вакыфы аерым йөртелә торган һәм елда йөз мең Мисыр лирасы кадәр килере булган. Бу акчадан шәкердләргә һәм мөдәррисләргә магашлар (хезмәт хакы) бирелгән. Соңгы

кризислар аның килерен азайткан. Соңыннан "Әзһәр" вакыфларыннан "рәвак"ларга бүленүе бетерелеп, бөтен мали (милек) эшләре үзәкләштерелгән. Бөтен шәкердләргә бер төрле ярдәм бирелә башлаган. Элек һәрбер шәкердкә аена биш лира биргән булганнар; хәзер җиде лира бирәләр икән. "Әзһәр" янында бу төрк бүлегеннән башка, Һиндстан, Жавә (Ява утравы.), Хиҗаз, Әфган һәм башка кебек мөселман халыкларының аерым-аерым бүлекләре һәм аерым-аерым оешмалары, вакыфлары бар. Аларның үзләренең башлыклары (шәйхләре) бар. Төрк бүлеменең башлыгы—шәйх Габделхәмид Таһир исемендә бер чиркәс. Аның ярдәмчесе Шәмседдин әфәнде—Анатолий төрекләреннән. Бу "рәвак"ларның идарәләре бер мәркәзгә табигъ (буйсынулы). "Әзһәр"дә барысы 300 гә якын мөдәррис бар. Аларның магашлары аена унике Мисыр лирасыннан алып, илле лирага кадәр икән. Бөтен "Әзһәр"нең вакыфының еллык килере бер миллион Мисыр лирасына якын. "Әзһәр"нең бөтен укыту эшләренең идарәсе башында торучы "Шәйхел-Әзһәр" исемендә йөртелеп, ул шул ук вакытта Мисырның "Шәйхел-исламы" урынын ала һәм Мисыр голәмәсенең иң бөекләреннән сайланып куела. Бу урында бүген шәйх-Әхмәд Мөхәммәд әз-Заваһиди хәзрәтләре тора. Бөтен зур дини фәтвалар, фәрманнар аның имзасы берлә чыга. Узган Рамазан бәйрәмендә большевикларның ислам диненә каршы иткән золымнарына каршы игълан ителгән протест та шул бөек затның имзасы берлә чыкты.

Шәкердләрнең тора торган җирләрен карап бетергәч, "Әзһәр"нең көтепханәсенә кердек. Аның укыла торган бүлеме булган кебек, музә (музей)—иске кыйммәтле әсәрләр саклана торган бүлеме дә бар икән. Анда барлыгы сиксән мең җилд (том) иске китап саклана. Алар эчендә бик иске заманнардан калган, бик матур иттереп мәгълүм хаттатлар (күчерүчеләр; каллиграфлар) тарафыннан язылган бик күп фәрманнар да бар икән. Шул ук көтепханәнең бер бүлмәсенә Мисырның унтугызынчы гасырдагы зур галимнәреннән Мөхәммәд Габдәнең көтепханәсе китереп урнаштырылган.

Бүгенге көндә "Әзһәр"нең төрле факультетларында төрле яктан җыелган йөзгә якын төрк шәкердләре укып яталар. Алар арасында берничә төркестанлы булса да, безнең Идел буеннан һәм Кырымнан берәү дә юк. Күпчелек—кафкаслылар. Әгәр укырга ихласы һәм дөньяның ачысын-төчесен татырга теләгән яшьләребез булып, "Әзһәр"гә барып чыксалар, "Әзһәр"нең ишекләре һәм вакыфлары алар өчен һәрвакыт ачык. (Бу урында "Әзһәр"дәге дәрес вакытын чагылдырган рәсем урнаштырылган). Тик элгәреге күк, анда кереп укымыйча, ашап яту гына бетерелгән. Һәр шәкерд имтихан тотарга тиеш. Бирә алмаган шәкердләр мәдрәсәдән куылалар.

"Әзһәр"не карап бетергәч, ашап-эчеп, Мисырдан килгән корылтай әгъзаларын күрер өчен "Җәмгыяте шөббанел-мөслимин"гә ("Мөселман яшьләре җәмгыяте"нә) киттек. Бу җәмгыять—мөселман яшьләрен бер тәрбиядә һәм рухта үстерер өчен, соң елларда гына оештырылган һәм бик күп мөселман мәмләкәтләрендә үзенең шөгъбәләрен ачып өлгергән бер мөселман җәмгыяте. Ул бөтен дөньядан килгән мөселманнарның бер-берсе берлә күрешә, таныша торган һәм бер-берсенең дәрдләрен (проблемаларын) аңлаша торган бер мөселман мөәссәсе (оешмасы). Анда мине күптәнге таныш һәм туган-кардәш кебек каршы алдылар һәм Русия мөселманнарының хәле хакында биреләчәк беренче конферансның (лекциянең; докладның) үзләрендә бирелүен сорадылар.

Мисырда сәясәттә, мәдәният һәм фикер таратуда киң бер иркенчелек бар. Бу хөрриятттән файдаланып, аның сәясиләре төрле-төрле фиркалар (партияләр) ясаганнар. Алар шул фиркалар янында халыкны туплап, үзләренең сәяси һәм мәдәни фикерләрен тормышка тәтбикъ итәргә (ашырырга) тырышалар.

Төрле фиркаларның максатка барып житәр өчен иң кыска юл дип ышанган юллары бер-берсенекеннән башка-башка булганга, табигый, алар бер-берсе берлә кычкырышалар, талашалар. Бөтен дөньядагы хөрриятле мәмләкәтләрдә булган кебек, монда да кайбер вакытларны кызышып китеп, бер-берсен гаепләшәләр, талашалар. Алар үзләренең матбугаларында Мисырның мәсьәләләрен төрле төстә күрсәтеп, укучыларны да үзара талаштыралар.

Мисыр халкы, һәрбер иске (текста "һәрбересе") мәмләкәт халкы кебек, бик тиз күперенеп, кызып китә торган халык булганга, бу кычкырышлар күп вакытларда канлы вакыйгалар да тудыралар, зур-зур мәхкәмәләргә (судларга) сәбәп булалар. Ләкин боларның берсен дә безнең Русиядә күрергә өйрәнгән меңләп-меңләп тотулар (кулга алулар), йөзәрләп-йөзәрләп сөргенгә җибәрүләр һәм атуларның берсе булмый. Тавыш-тыныш бераз дәвам итә дә, тормыш тагын үзенең табигый юлына төшә...

Без Мисырга барганда да мондый фирка кычкырышларының бик кызу барып яткан чагы иде. Ләкин без монда, Мисыр зур бер мөселман мәмләкәте дип, үзебезнең кайгы-хәсрәтләребезне сөйләргә һәм белдерергә килгәнгә, үзебезнең эшебезне фиркачылыктан читтә тора торган "Җәмгыяте шөббанел-мөслимин"нән башладык. Бу җәмгыять—Мисырда гына түгел, бөтен гарәп дөньясында ислам мәдәниятен саклау

нигезенә корылган һәм мөселман яшьләрен бер төрле тәрбиягә алыштырыр өчен корылган бер оешма. Аның шөгъбәләре (бүлекләре), Гыйрак, Фәләстин һәм Сүриядә булган кебек, аның Һиндстан һәм Жавада (Явада да) шактый көчле тармаклары бар. Ислам дөньясында Мисыр бүген мәдәният ягыннан да һәм байлык ягыннан да беренче урында торганга, Каһирәдәге "Жәмгыять..." мәркәзлек урынын тота. Ул шул исемдә төрле жирләрдә клублар ача, оешмалар кора һәм шул ук исемдә зур бер мәжмуга чыгара. Бу мәркәзнен идарәсе танылган кешеләр кулында. Аның башында Мисыр Милләт мәжлесе әгъзасы, Мостафа Кәмал паша оештырган фирканең лидеры Габделхәмид Сәгыйдбәк тора. Ул—үзенең яшьлегеннән алып бу көнгә кадәр ислам дөньясының һәр почмагындагы милли-дини тартышларга катнашып килгән кеше. Ул Тарабулус (Ливандагы Триполи шәһәре) сугышларында мәрхүм Әнвәр паша һәм Гази Мостафа Кәмал пашалар берлә бергә Тарабулусны коткарыр өчен сугышка катышкан; Балкан сугышлары башлангач та, ул бердәнбер мөстәкыйль мөселман падишаһлыгына—Госманлы империяторлыгына каршы христиан дөньясының берләшеп һөжүм иткәнен күреп, үзенең мөселманлык вазыйфасын үтәргә—мөселман гаскәре берлә бер сафка булырга ашыккан кеше. Ул Балкан сугышында безнең илдән күнелле (ирекле; доброволец) булып килгән Гариф Кәримиләр берлә бергә сугышка кереп, яраланган.

Габделхәмид Сәгыйдбәк дөнья сугышы вакытында Төркиянең тагын бөтен яктан көчле дошманнар берлә чолганып алынганын күргәч тә, аның ислам мәхәббәте кузгалып, өченче мәртәбә күнелле булып сугышка катышкан һәм Мисырны кулында тоткан инглизгә каршы корал берлә көрәшкән һәм таралырга торган гарәп әфкяре гомумиясен (ижтимагый карашларын; жәмгыятен) хәлифәт тирәсендә берләштерергә хезмәт иткән (Госманлы солтаннары бер үк вакытта хәлифә дә хисапланган): Сийур могаһәдәсе (биредә Сьерра-Леоне килешүе күздә тотыла булса кирәк.) берлә Төркия бетереләчәк булгач башланган Гази Мостафа Кәмал пашаның (ягъни Ататөрекнең) истикъләл (азатлык) сугышлары вакытында Италиядә торып, Төркия файдасына бик күп матдимәгънәви хезмәт иткән. Ул үзе бик зур бер бай кешенең баласы булганга, бу эшләрнең барысын да үзе өчен һичбер файда күзәтми эшләгән. Исламият юлында күп һәм бик күп мал сарыф иткән бу кеше бүгенге көндә дә һәрбер мөселман өлкәсе өчен дөньяның бер читеннән икенче читенә китәргә хәзер тора. Шуның өчен дә "Шөббанел-мөслимин" жәмгыяте— Мисырның иң жанлы бер мөселман оешмасы.

"Шөббанел-мөслимин" жәмгыяте хәзерге көндә Төркия төрек очаклары ролен үйный. Аның рәисе дә Төркиядә соңгы 15 ел эчендә Хәмдалла Собхибәк торган урында тора. Бу жәмгыятьнең бинасы һәрвакыт төрле жирләрдән килгән мөселман мөсафирлары берлә тулы. Мин анда корылтайда очрашкан Гыйрак һәм Югославия вәкилләрен тагын бер тапкыр күрдем. Шунда ук Америкада ислам динен таратучы һәм шул юлда гомерен фида иткән һәм 20000 кадәр Америка караларын (негрларын) мөселман иткән Америка мөфтисе — кара гарәп, сәйд сани (икенче сәйд) Мажид Мөхәммәд әфәндене очраттым. Мин анда ислам мәдәниятенә сусап килгән Кытай мөселманнарын да күрдем. Бик күп гарәп өлкәләренең жәмәгать эшчеләре, Һиндстан мөселманнарының олугларыннан Шәүкәт Гали һәм аның иптәшләрен һ.б. таптым.

Анда безнең эшебезне тәмам кардәшчә каршы алдылар. Минем конференсым (чыгышым; лекциям) шимбә көнгә билгеләнде. Чакыру кәгазьләре таратылды, газитәләрдә игълан ителде.

Жомга килеп житте. Мин Мисырның зур жамигъларыннан (мәчетләреннән) берсендә намаз кылырга уйладым. Хәмзә Таһирбәк миңа тагын ярдәмгә килде. Мисырда жамигълар бик күп. Аларның мәшһүрләре: "Сәйдна Хөсәйн", "Сәйдәи Зәйнәб", "Имам Шафи", "Рәфагъи", "Гомәр бине Гас", "Жәмигъыл-Әзһәр" жамигълары һ.б. "Сәйдна Хөсәйн" жамигъында Хәзрәте Хөсәйннең зыяраты бар. Анда аның башы күмелгән. "Сәйдәи Зәйнәб"—рәсүлнең Зәйнәб исемле кызы хөрмәтенә салынган һәм Мисырның зур, мөбарәк жамигъларыннан. "Гомәр бине Гас" жамигъы— Мисырда беренче салынган мөселман мәсжеде. "Рәфагъи" жамигъы иң зур һәм бүгенге көндә Мисырның иң мөгътәбәр жамигъларыннан.

Халык бик күп була торган жамигъ булганга, мин "Рәфагъи"га барырга булдым. Бик артта калмыйм дип, сәгать 11 ләрдә үк жамигъның эченә кереп утырдым. Мин килгәндә, мәсжеднең эчендә, берничә жирендә "Корьән" укып утыручы берничә кешедән башка, берәү дә юк иде. Мәсжед бик зур, ишекләре төрле урамнарга ачыла. Монар күрә урам тавышы ишетелеп тора иде. Сәгать уникенче яртысы булды. Зур ишекләр янына барып, мөәзиннәре, карилары (кариэләре; "Корьән" укучылары) бик сузып, урамга таба кычкырып, төрле догалар укырга тотындылар. Бу догалар халыкны чакыру, гыйбадәт кылырга өндәү булсалар да, озак түгел иде. Төрле тавышлар берлә 15 минут сузылган бу чакырудан соң, халык мәсжедкә жыела башлады. Бер жирдә бер хафиз ("Корьән"не яттан укучы) бик матур тавыш берлә "Корьән" укырга кереште. Ул бик сузып-сузып, төрле тоннарга күчеп укый иде. Аны гарәпләр бик ихлас берлә, бик зур

күңел рәхәтлеге берлә тыңлар иде. Кайбер вакытларда катышып бер сүз дә әйтәләр һәм салаватлар да кушалар иде.

Менә мөәззин дә кычкыра башлады. Ул бер озын макам (көй, тавыш; моң) берлә без белгән азанны укыды. Ләкин ул аны шундый озын иттереп, тавышларын төрләндереп, уйнатып, бер төшереп, бер күтәреп укый иде, —безнең кебек читтән килгәннәргә аның сүзләре артыннан барып җитүе дә һәм аңлавы да бик авыр иде. Кари азан әйткәндә дә, үзенең укуыннан туктамады. Азан тәмам булды. Мәсҗед тулды. Арттан берәү "ас-салават" дип кычкырды. Халык гөрләп калкып, намазга керәште.

Монда, төрле мәзһәб кешеләре булганга, намаз уку бер төрле генә түгел иде. Кайберләре кыямда (намазның аягүрә үтәлә торган өлешендә) кулларын җибәреп торалар; кайберләре рөкүгъка (намазның иелеп тору, тезләргә таяну өлешендә) киткәндә тагын бер тапкыр колак кагалар; кайберләре безнең кебек укыйлар иде. Ләкин барысы да ике рикәгать кенә укыдылар. Намаз бетте. Хатиб мөнбәргә чыкты. Мөәззин азан укыды, арттагы мөәззиннәр аны кабатладылар. Хотбә (вәгазь) безнең хотбә китапларындагы гади бер хотбә иде. Суык кына, тонык кына укыды. Хотбәдә ләкин холәфаи рашидин (бирелә "тәүге хәлифәләр" күздә тотыла), хәлифә һәм үзләренең падишаһларына һич төпле дога юк иде.

Безнең муллаларның, урыс хөкүмәте бик каты тыя торып, хәлифәләргә дога кылулары һәм кайбер фетнәле мәсьәләләрдә иманнарның бу доганы яшерен генә укулары күз алдыма килде дә, бу мөселман илендә тулы хөррият эчендә моның эшләнмәве кызык тоелды.

Намаз бетте. Халык гөр итеп купты. Бер өлеше ишекләргә, икенче өлеше мәсҗед уртасына утырган вагыйз (вәгазь укучы) янына җыелды; өченче бер өлеше михраб янына җыелып, яңа бер имамга оеп, өйлә намазы укый башладылар. Болар Мисыр шәһәренең җомга намазы өчен шартлары тулмаган дип өйлә намазы укучы суган суфыйлар икән.

Мин бер вагыйз янына барып утырып, аның вәгазен тыңларга хәзерләндем. Вагыйз: "Әр-рижалу кавамун галяин-ниса",—дип башлады (ир—хатыннарга баш!—Г.И.) һәм шул фикерне баллаңдырып, татландырып сөйләргә керәште. Ул ирләрнең хатыннарга баш булуы өчен кирәк булган бик күп дәлилләр китерде. Хатыннарның хыянәтләреннән, хәйләләреннән бәхәс китте. Кечкенә вакытта мин үземнең әбием Мәхфүзә остазбикәнең һәм әнинең авыл хатыннарына сөйләгән бу дәлилләрне, мисальләрне (кинаяле хикәятләрне, мисалларны) бик күп тыңлаган идем һәм аларның ул хатыннарга ничек тәэсир иткәнен дә күргән идем. Ул вакытта алар миндә бер дә начар тәэсир калдырмаганнар һәм минем һичбер хисемне мыскыл итмәгәннәр иде. Ләкин бер Мисыр вагыйзенең моңа җентекләп-җентекләп сөйләве миндә бик ямьсез тәэсир калдырды. Ул мәрхүм әби-әниләрнең хатирәләре мыскыл ителә кебек тоелды.

Җамигътан чыгып, аннан бик ерак булмаган Мөхәммәд Гали паша[1] җамигын карарга киттем. Мисырның бүгенге сүлэләсенең (династиясенең; нәселенең) башы тарафыннан бина ителгән бу җамигъ Мисырның иске кальгасендә һәм Мисырның иң биек җирендә, тәмам төрек стилендә салынган. Тыштан караганда Истанбулдагы Валидә җамигына охшаган кебек күренә. Ләкин эченнән бик зур һәм бик бай бер җамигъ. Бик күп акча сарыф итеп эшләтелгәне һәрбер җиреннән күренеп тора. Намаз беткәнгә монда да вагыйзлар сүзләрендә дәвам итәләр иде. Мин дә берсе янына килеп чүктем. Вәгазь Кәүсәр суының тәмлелеге, татлылыгы һәм файдалыгы хакында иде. Бераз тыңладым. Ләкин монда да дәрдемә дәрман булачак бер сүз ишетә алмадым.

Минем җамигъләрдагы вәгазьләрне бик күп ишеткәнем бар. Алар, шөбһәсез, халык өчен бик кирәкле нәрсәләр һәм халыкка бик зур тәэсир дә ясый алалар. Төркия вагыйзлары үзләренең вәгазьләре берлә төрек гаскәрен кыздырып, утка-суга кертә алалар. Бик күп шәһәрләрне алдыралар. Бик көчле дошманнарны тар-мар иттерә алалар. Һәм җамигъ тагы халыкны электрикләнгән хәлгә китерә алалар: көннең актуаль мәсьәләләренең хәлендә файдалы йә зарарлы роль уйный алалар. Ләкин мондагы вагыйзлар бик вак мәсьәләләр берлә шөгыльләнәләр һәм халыкка да бик аз тәэсир итә беләләр.

Кич берлә бер театрга барырга ният иттем. Мисырның Милли театрында "Ләйлә вә Мәҗнүн" уйналганга, шунда киттем. Театр бинасы бик бай һәм матур. Бөтенләй гарәп ысулында салынган бер бина. Каралуы, саклануы да яхшы. Мондый театр бездә дә һәм Төркиядә дә юк. Мин яхшы ишетер һәм күрер өчен, урынны алдагы сафлардан алдым. Алданрак барып, килүче халыкны сәйр иттем (күзәттем). Килүчеләр пакь киенгән һәм үз-үзләрен тота белә торган кешеләр иде. Хатыннар ложаларда гына күренә. Түбәндә юк дәрәҗәсендә аз иде. Пәрдә күтәрелде... Декорацияләр яхшы эшләнгән, киемнәр

---

[1] Мөхәммәд Гали (1769-1849)—1805 елда Мисырда хакимиятне үз кулына ала. Илдә күп төрле реформалар үткәрә. Аның бу өлкәдәге гамәлләрен еш кына Петр I эшчәнлеге белән тиңлиләр (Х.М.).

гарәп ысулында. Ләкин уйнаучыларның күбесе үзләрен сәхнәдә тота белмиләр иде. Алар йә утырышып торалар, йә кулларын салындырып, кая барырга белмичә, үзләренең монда ни өчен кергәннәрен аңламыйча, аптырап сәхнә буе йөриләр иде. Драматик моментлар хәрәкәт һәм уен берлә жанландыра (бу сүз "жанларла" дип ялгыш язылган) алмыйлар иде. Аларның осталыгы декламационда, сүздә генә иде. Жанландырып күрсәтеләчәк күренешләр озын монолог төсенә керә, бик нечкә минутлар сүз берлә буылалар (бүленәләр) иде. Әсәрдә музыка бер дә катыштырылмаган иде. Ул шуның өчен әллә нинди корыган, коргаксыган хис калдыра иде. Уйнаучылардан Мәжнүн ролен уйнаучы Хөсәйн Рийаз берлә Ләйлә ролен уйнаучы Фатма Рөшди (Фатыйма Рәшиди?) ханымнар чын мәгънәсе берлә артистлар иде. Аларның икесе дә Аурупаның һәр театрында уйнарлык көчкә һәм осталыкка малик (ия) кешеләр иде. Ләкин режиссер бик зәгыйфь булганга, аларның тырышуы гына кирәкле нәтижәне бирә алмый иде. Хөсәйн Рийаз куәт ягыннан бик зур бер артист булса да, анын гәүдәсе Мәжнүн роленә туры килми иде. Ашый да, эчә дә һәм йоклый да алмый торган мәңгелек гашыйк, үзенең яндырган гыйшкын сөйләгәндә, көйдергән дәрден жырлаганда, бераз ябыграк, зәгыйфьрәк күренергә кирәк иде. Ләкин Хөсәйн Рийаз фил кадәр зур, жуан һәм тупас гәүдәле бер кеше иде.

Мин моннан соң да Мисырның шактый зур театрларында булдым. Боларның барысында да бер кимчелек бар: ул да—күрсәтелә торган тормышның авыр минутларын уйнап, жанландырып күрсәтү урынына—сөйләп аңлату ысулы (ысулын куллану). Гарәп теленең бик эшләнгән һәм бик бай булуы бу монолог-декламацион юлына кирәргә зур ярдәм итсә һәм гарәп караучысы моннан бер ләззәт тапса да,—бу юл театрның ибтидаилигын (башлангычын, тәжрибәсезлеген) күрсәтә. Бу сәгать берләргә кадәр сузылган монотон уеннары мине ялыктырсалар да, гарәпләр үзләре аны рәхәтләнеп тыңладылар. Мин Мисырның театрлары әле безнең татар театрыннан бик күп түбән икән дигән фикер берлә театрдан чыктым һәм безнең милли труппалар безне киләчәккә Мисырда нинди зур уңышлар ясый алачакларын уйлап өйгә таба борылдым.

26 нчы декабрь кичәсендә "Шөббанел-мөслимин жәмгыяте"нең залында минем беренче конферансым (лекциям; чыгышым) булды. Мин төрекчә сөйләдем. Жәмгыятьнең идарә әгъзаларыннан Мөхеддин әл-Хатиб бәк аны гарәпчәгә тәржемә итте. Ләкин тыңлаучыларның өчтән бере төрекчәне аңлыйлар иде. Мәсьәләгә кереп китеп, фикернең нинди юлда барганын аңлап алган үткенрәк кешеләр минем гарәпчәне махсус күбрәк катыштырып сөйләгән төрекчәмнән дә күп фикерне аңлап киләләр иде. Сүз башлану берлә бөтен зал тып-тын булып калды. Һәрбер кеше жанлы бер дикъкатькә әверелде.

Мин элек Русиядә яшәгән мөселманнарның утырган урыннарын санап, аерым-аерым төрк өлкәләренең кайсы елларда урыс кул астына керүләрен аңлаттым. Патша дәверендәге сәяси-мәдәни хәлләрен күздән кичереп, большевик дәверенә кердем. Русиядәге 30 миллион мөселманның большевик дәверендә өч яктан—мөселманлык, төркчелек һәм истикъляльчылык (азатлык) ягыннан—башка СССР тәбгаләреннән (кавемнәреннән) өч мәртәбә артык золымга мәгъруз калуларын (дучар ителүләрен) сөйләп, мисаллар китердем. Исламият Русия мөселманнары арасына моннан мең сәнә (ел) элек кергән бер дини тәгълимат булганга, һәм алар исламиятне саклар өчен һәрвакыт христиан урыслар берлә сугышып килгәнгә, ул монда халыкның канына һәм жанына сеңгән бер милли дин төсен алган. Шуның өчен мөселманнар һичбер төрле итеп алласызлык һәм динсезлеккә корылган коммунизм әсасен (тәгълиматын) кабул итә алмадылар, урысларның рухларындагы башбаштаклык (анархия) бу коммунизм әсасларын кабул итәргә ни кадәр киң мәйдан ачса, исламиятнең әхлак-мораль дисциплины мөселманнарга ул фикерне кабул итәргә шул кадәр манигъ (киртә) булды. Шуның өчен һәрбер динне үзенә дошман итеп игълан иткән большевиклек исламиятне ике кат дошман итеп таныды. Ул аның берлә христианлык һәм яһүдилеккә караганда әллә ничә өлеш артык көч берлә тартышырга керешге.

Русия мөселманнарынын йөздән сиксән бише—төркләр. Калган кыйсеме төрк мәдәниятенә мәгъруз калган чиркәсләр (Шәрыкта бөтен Кафказ таулары "Чиркәс" исемендә йөриләр). Русия милләт уларак һәрвакыт төрк милләте берлә тартышып килде. Элек ул 300 ел кадәр төркләрнең кул астында яшәде (Алтын Урда һәм Казан дәверләре). Соңыннан алар төркләрне жиңеп, үз кул астына алдылар һәм төрк милләтен бер милләт уларак бетерергә керештеләр. Урысларның бу хәрәкәте бер каршы хәрәкәт уятты. Төрк милләтендә бер милли уяну туды. 20 гасыр төрк милләтенең милли уянуының иң көчле бер дәвере иде. Милләтсез бер коммунизм жәмгыяте ятатам дип мәйданга чыккан большевик үзенең бу эшендә иң элек төрк милләтчелегенә бәрелде. Ул аны һичбер төрле әзәйтә алмаганга, ул ана каршы иң каты дошманлык вазгыятен алды. Шунар күрә төрк милләтчелеге коммунизмның иң зур дошманы булып танылды.

Большевикларның максатлары—бөтен дөнья күләмендә бер ижтимагый революцион

(революция) ясап, бер совет дәүләте дөньяга китерү. Аларның бөтен пропагандалары, тышкы сәясәтләре менә шушы максатны күздә тота. Алар чит илләрдә дә менә шул фикерне кабул итәчәк һәм итә алачак гонсырлар (элементлар; чыганаклар) эзлиләр. СССРның эчендә яшәүче милләтләр һәм шулар эчендә төркләр дә большевик дәүләтеннән аерылып чыгып, үзбашларына ирекле бер дәүләт корырга тырышалар. Алар Русиядәге хәзерге большевизм патшалыгын, урыс милләтенең идарә итү ягыннан банкрот булуы дип карап, аның кулыннан котылырга тырышалар. Төрк милләтенең аерым өлкәләре булган Төркестан, Кафкас, Кырым һәм Идел-Урал мөстәкыйль булырга тиеш. Большевик идарәсе бу милли истикъляль дәгъвасен күреп, бу яктан да төркләрне үзенең биәман (куркынычлы) дошманы итеп карый һәм аларга каршы җәбер-золымны арттыра. Большевизм хосусый милекне танымаганга, ул бөтен Русия халкының милкен дәүләтләштергән кебек, мөселманнарның да милкен талый. Ул бөтен русиялеләрнең гаиләсен бозган кебек, мөселманнарның гаиләсен дә бозарга тырыша. Шуңар күрә бүген Русиядә яши торган 30 миллионлы мөселманлык үзенең хәятен саклар өчен бик авыр тартыш алып килә. Үзеннән бик күп мәртәбә көчле булган дошман берлә хәят-мәтам (яшәү-үлем) дәгъвасын алып бара.

Ул үзенең истикъляль җәбһәсендә (мәйданында; фронтында) аның кебек Русиядән аерылып мөстәкыйль булырга тырышучы Украина, Гөрҗи (Грузия), белорус һәм фин кавемнәре берлә берләшеп, бер "Проматей" җәбһәсе берлә (берлектә) тартыш алып бара. Төрк җәбһәсенә килгәндә, Русиядә яшәүче төрк милләте төрле кабилә исемнәре берлә йөрсә дә, үзенең мәдәнияте һәм тарихы бер булганын һәм шулай ук дошманның уртак бер дошман булганын бик тирән хис итә. Ул бергә бара һәм бер-берсенә ярдәм итә. Русия читендә булган әфган, иран, кытай һәм анатол төркләренең бүген бу авыр хәлгә сәйирчинә (күзәтүче) булып торуларын күреп бик кайгырса да, вакыты килгәндә кардәш кардәшне таныр фикере берлә ул үзенең өмиден югалтмый һәм киләчәгенә зур бер ышану берлә карый. Исламият җәбһәсенә килгәндә, безнең эшләребез бик фаҗигале. Ислам дөньясында бүгенге көндә һичбер уртак мөәссәсә (нигез) юк. Бүген һичбер ислам дәүләте, кечкенә генә рәвештә булса да, ислам сәясәтен йөртә алмый, алар чит илдәге дин кардәшләрен химая (таяныч) итә алмыйлар һәм итмиләр. Большевикларның христиан диненә каршы золымнарына каршы, папа хәзрәтләре башта булган хәлдә, бөтен христиан дөньясы аякка калыкты. Яһүди динен кысуга каршы бөтен Аурупа һәм Америка яһүдиләре тавыш куптарды. Ләкин 30 миллион мөселман аларга караганда өч-дүрт мәртәбә артыграк золымга мәгъруз калса да, һичбер мөселман мөәссәсе, һичбер мөселман патшасы, һичбер мөселман дәүләте аларны химая итү турында бер авыз сүз сөйләмәде. Шуның өчен мин үземнең кардәшләремә шул 30 миллион мөселманның аһ-зарын ишеттерергә ислам мәдәниятенең бүгенге мәркәзе булган Мисыр мөселман дәүләтеннән мәгънәви ярдәм сорарга килдем. 30 миллионлы мөселманның тарихта охшашы күрелмәгән авыр хәлен сезнең мөселманлык вөҗданыгызга әманәт иттем. Мин шул сүзләр берлә конферансымны бетердем. Менә бердән кыямәт купты. Сүз сораучыларның исәбе-хисабы булмады. Бөтен зал бер авыздан әйткән кебек: "Безнең илебездә әллә никадәр качак урыслар, әрмәннәр ярдәм күрәләр дә (күрсәләр дә), без ни өчен Русия мөселманнарына ярдәм итмибез. Ник аларга каршы эшләнгән бу җәбер-золымны бетерергә тырышмыйбыз!?—ди иде. Бик күп кеше мине әйләндереп алып, башка җирләрдә дә конферанс бирүемне сорадылар, гәзитәләрдә туктамастан бу турыда мәгълүматны кинәйтергә тырышалар иде. Икенче көнне Мисырның бик күп гәзитәләрендә бу конферанс басылып чыкты.

Икенче көнне мин гарәп хариси музәханәсенә (гарәп милли мәдәнияте музеена) киттем. Гарәп мәдәниятенең бер күргәзмәсе урынын тотачак бу музәханә бик күп кыйммәтле әсәрләрне җыйган икән. Ләкин гарәпләр үзләренең милләтчелекләрендә без төрекләргә охшамыйлар. Алар бик куе милләтчеләр-шовинистлар. Шуның өчен боларга кирәк музәханәдә шактый күп фарсы, һинд һәм төрек әйберләре гарәп эше кебек күрсәтелгән һәм гарәп музәханәсенә ислам мәдәнияте музәханәсе төсе бирелгән иде. Ләкин ничек булса да, бу әсәрләрнең җыелып саклануы, югалмавы яхшы.

Мин яхшы ук авыр уйларга керергә мәҗбүр булган бер хасталык берлә 3-4 көн ятакта калырга тиеш булдым. Инде Сәгыйд Шамил дә килгәнгә, безгә Мисырдагы рәсми эшләребезгә керешергә вакыт бик житкән иде. Шунын өчен Габделхәмид Сәгыйдбәк аркылы Шәйхел-Әзһәргә телефон иттереп бер рандеву (очрашу) алдык. Шулай ук Мисырның иң зур фиркаләреннән булган Вафид башлыгы Нәлхас (Нәхас, Нилхас?) пашадан да бер көн билгеләттек. Шул ук көннәрдә "Шөббанел-мөслимин җәмгыяте" дә безнең хөрмәтебезгә бер чәй зияфәте (мәҗлесе) ясады. Мисырга килүебезгә бик аз гына вакыт үтүгә карамастан, инде аның эчке тормышына кереп бара идек. Мөселманлыкның зур хадимләреннән Габделгазиз Сәгалби хәзрәтләре берлә Габделхәмид Сәгыйдбәкләр безне Мисырның гыйлем, әдәбият һәм сәясәт фиркаләренең клубларын зиярәт итү берлә мәшгуль булса, кичләрен әле бер галимнең, әле бер

сәясинең, әле бер мөхәррирнең өенә чакырулы була идек.

Шул көннәрнең берендә Вафид фиркасенең башлыгы һәм иске Садрәгъзам Нәлхас пашаны да зиярәт иттек. Бу фирка—мәрхүм Зәгълүл паша фиркасе. Ул соңгы 10 ел эчендә Мисыр сәясәтендә зур роль уйнаган бер фирка булганга, аның рәисе булган Нәлхас пашаны да үзләренең матбугатлары "Әр-рәис" дип кенә йөртәләр. Алар үзләренең клубларын "Бәйтел-өммә" ("Диндәшләр йорты") дип атыйлар. Мәрхүм Зәгълүл пашаның хатынын да "Өммүл-мисрийун" (Мисырлыларның анасы) дип йөртәләр. Бу сүзләр халыкның күңеленнән чыгып бирелгән исемнәрме, әллә фирка матбугатының пропагандасы берлә генә туганмы—моны читтән килгәннәргә кыска вакытта гына аңлату җиңел түгел. Ләкин мисырлылар иске тарихлы бер милләт булганга һәм тарихларында да дөньяның мәшһүр әсәрләре зур әһрамлар (пирамидалар) булганга, алар сүздә дә зурлыкны-арттыруны бик яраталар. Монда бер кешене икенче берсенә таныштырганда да шагыйрь булса—"сәйд әш-шөгара" ("шагыйрьләр патшасы"), мөхәррир булса—"әмирел-әдиба" ("әдипләрнең әмире"), галим булса "әфзалел-фазла" ("фазыйлларның фазыйле"—галимнәрнең-галиме"), доктор булса—"хәкимел-хөкәма" дип тәкъдим итәләр. Башка эшләрдә дә шулай зур итүне, күтәрүне бер дә онытмыйлар. Әлеге югарыдагы исемнәрдә дә шундый берәр нәрсә бардыр.

Нәлхас пашаны күрер өчен без Вафиның клубына килдек. "Бәйтел-өммә"—бер зур сарай. Эченә кердек. Безне әллә никадәр андагы әгъзалар каршы алдылар. Зур бер хөрмәт берлә рәис бүлмәсенә керттеләр. Зур-зур салоннарны үттек. Аларның барысы да бик бай иттереп җиһазланганнар иде. Бу клуб Эстония рәис җөмһүренең (премьер-министрының) сараеннан зуррак та һәм баерак та иде. Монда каһвәләребезне эчкәннән соң, Нәлхас пашаның үз өенә алып киттеләр. Бусы да бер зур кунак, бер сарай иде. Безне монда да каршы алып, "әр-рәиснең" кабинетына керттеләр. Без кергәч, анда хазыйр булганнар (катнашканнар) барысы да аякка калыкты. Нәлхас паша үзе дә урыныннан торды. Түргә утырттылар. Габделгазиз Сәгалби безне тәкъдим итте һәм сөйләшүләр башланды. Вафиның шигаре (лозунгысы) бу вакытка кадәр "Әл-Мисру лил-мисрийюн" (Мисыр—мисырлыларның) булганга, ул гарәпчелек һәм мөселманчылык сәясәтеннән бераз ераграк тора. Мисыр сәясәтендә зур роль уйный торган христиан гарәпләрен куркытмас өчен, ул мөселманлык эшендә бик сак хәрәкәт итә иде. Без монда мөселманлык эше берлә килгәнгә, аларны мөселманлык сәясәтен тәгъкыйб итүчеләр кебек сөйли идек. Корылтайдагы әгъзаларның хезмәтләре өчен рәхмәтләр укыдык. Нәлхас паша безне бик тиз аңлады. Үзе бик үткен кешегә охшый. Сүзгә бик оста. Ул сөйләгәндә тыңлаучылар тәмам эреп китәләр иде. Ул Аурупаның иксез-чиксез либерализм фикерен үзенә бөтенләй сеңдергән. Ул Аурупаның империализмыннан озын-озын сөйли иде. Хәрәкәтләре берлә ул җәнүб (көньяк) мәмләкәтләрендә бик күп очрый торган кызу бер пропагандачы кебек иде.

Каһвәләребезне эчеп, күрешеп чыктык. Паша безне ишеккә чаклы озата килде. Ишек янында әллә никадәр фотографлар рәсемнәребезне алдылар. Зур дәфтәргә имзаларыбызны куеп чыктык. Без моннан туп-туры "Шөббанел-мөслимин" җәмгыятенә барып, Габделхәмид Сәгыйдбәк берлә бергә "Җамигыл-Әзһәр" шәехен зиярәт өчен Диния мөдириятенә киттек. Мөхәммәд әл-Әхмәди әз-Заваһири хәзрәтләре безне бик зур кадер-хөрмәт берлә кабул итте. Матур йөзле, үткен күзле, алтмыш яшьләрендә бер галим. Аның симасы (йөзе, кыяфәте) тамырларында төрек каны акканын күрсәтә. Сүзләре бик акыллы һәм төпле иде. Ул бик оста иттереп безгә бик күп сорауләр бирде. Шәйхел-Әзһәр хәзрәтләренә, мөселман дәүләте булган Мисырның Диния мөдириятенең рәисе сыйфаты берлә СССРда яшәгән мөселманнарның дин ягыннан җәберләнүләре хакында сөйләп, ислам дөньясының шул зур мөәссәсен (оешмасының) ярдәм итүен сорадык. Ул безгә: "Мисыр дәүләте мөселман дәүләте, Мисырның патшасы Мәлик Фуад ихласлы бер мөселман. Мин кулымнан килгән кадәр исламияткә хезмәт итүче бер мөселманчы. Русиядәге мөселманнарның җәберләнүләреннән бик мөтәәссир булдым (кайгырдым). Мин моны бөтен дәүләт адәмнәренә белдерәчәкмен. Без рәсми бер мөәәссәсә булмаганга, Русия мөселманнарын химая итүне дә (яклауны да) рәсми бер юлга куяр өчен, сез безгә бер рәсми гариза языгыз, кулыгыздагы вәсикаларны (дәлилләрне; материалларны) күрсәтегез",—диде. Без дә шулай итәргә булдык. Габделхәмид Сәгыйдбәк, бу эшне бөтенләй Аурупа ысулына куяр өчен, бер махсус комиссия ясауның мөнасиб икәнлеген сөйләде. Без дә аны муафикъ таптык. Шәйхел-Әзһәр дә бу хакта уйлашырга булды. Моннан соң да бик озын сөйләшеп утырдык. Шәйхел-Әзһәр миндә бик зур тәэсир калдырды. Ул мөселман галимнәре арасында бик сирәк очрый торган акыллы, тәрәкъкыйпәрвәр (прогресс яклы) бер галим; бик оста бер Шәрык дипломаты, киң күрешле бер ислам сәясие һәм фикре берлә чын мөселманчы. Без халкыбызның эше шундый төпле бер кешенең кулына эләгүенә сөенә-сөенә чыктык.

Инде безнең бурычыбыз, Шәйхел-Әзһәр сораган рәвештә, бер меморандум язып

биру,—большевик хөкүмәтенең исламиятне керчеләвен (?—кысуын.— Х.М.) объектив дәлилләр берлә күрсәтү иде. Мин Кодес корылтаена барыр алдыннан мондый бик күп дәлилләрне җыйган идем: большевикларның "Алласызлар җәмгыяте" чыгарган мәҗмугалар, большевик хөкүмәтенең диннәр (текстта "дәлилләр" дип ялгыш басылган) хакындагы декретлары, большевик гәзитләреннән алынган мәсҗедләрне ябу, голяманы хокуксыз калдыру, имамнарны сөрү хакында большевикларның үз куллары берлә язылган мәкаләләре, әмерләре һәм хәбәрләре. Ләкин болар урысча һәм татарча басылган китап, гәзит һәм мәҗмугалардан алынган булганга, аларны гарәпчәгә тәрҗемә итү кирәк иде.

Сәгыйдбәк берлә меморандумның ана хатларын("төп текстын") карар астына алдык ("үзебезнең җаваплылыкка алдык"). Икенче көнне мин шунын төп маддәләрен төрекчә яздым. Хәмзә Таһирбәк һәм берничә чиркәсләр берлә ясаган бер хосусый мәҗлестә аны укып чыктык. Меморандум фәнни язылган һәм маддәләр (статьялар, пунктлар) яхшы тәртип ителгән,—дип табылды. Ләкин мөкаддимәне (керешне), гарәп ысулы өчен, кыска һәм коры таптылар. Бу кыйсемне язу Сәгыйдбәк берлә чиркәсләргә тапшырылды.

Эшнең иң авыры хәзер большевикларның декрет-фәрман, мәкалә һәм хәбәрләрен гарәпчәгә тәрҗемә итү иде. Боларның урыс телендә булганнарына Русиядә укыган берничә христиан гарәпне табып булса да, татарчалары өчен Хәмзә Таһирбәктән башка кешебез юк иде. Шунар күрә бу зур йөкне ана йөкләдек һәм бер кочак китап, мәҗмуга, гәзитә биреп, шуларда минем тарафымнан күрсәтелгән урыннарның гарәпчәгә күчерелүен үтендек. Хәмзәбәк көн-төн утырып, шуларны хәзерли. Кафкаслы аркадашларыбыз да мөкәддимәне өлгерттеләр. Без меморандумны матбагада (машинкада.) бастырып, Шәйхел-Әзһәргә тәкъдим иттек. Шәйхел-Әзһәр бөтен эшне рәсми юлга куйды. Берничә голяма һәм мәэмүрдән (чиновниктан) ясалган бер һәйят (комиссия) алдында ул безнең кәгазьләребезне алды. Безнең биргән вәсикаларыбыз берәм-берәм номерлап язылды. Боларның Совет хөкүмәте вәсикалары булганлыгын исбат итү безнең өстебезгә йөкләнде.

Мондагы мәэмүрләр Совет системын бер дә белмиләр. Анда матбугатның коммунист фиркасенең диктатурасы астында гына булганын, һәрбер басылган китап коммунист цензурына табигъ (буйсынулы) икәнлеген, Совет илендә Аурупадагы мәгънәдә һичбер төрле матбугат, җәмгыять, сүз хөррияте юклыгын аңламыйлар. "Алласыз"ларның мәҗмугаларына килгәндә, алар: "Хәзер дөньяда мондый җәмгыятьләр бик күп. Алар Аурупаның бик күп мәмләкәтләрендә бар. Вөҗдан хөррияте булгач, әлбәттә, динсезләр җәмгыяте дә була ала. Андагы мөселманнар тотсыннар да, аларга каршы динлеләр җәмгыяте ачсыннар һәм динлеләр мәҗмугасы чыгарсыннар",— диләр. Без Совет хөкүмәтенең "Дин-әфиюн!"—дип башланган дин хакындагы декретын укыйбыз. Динсезләр җәмгыятьләренең Совет хөкүмәтенең әмере берлә эшләнгәне хакында коммунист фиркасенең съезд карарларын күрсәтәбез. Динлеләр җәмгыяте ясарга канун буенча имкян (рөхсәт.) юклыгын, бөтен матбага һәм кәгазь хөкүмәт кулында булганга, дини бер мәҗмуга түгел, бер догалык бастырырга да мөмкин булмаганын сөйләп, бик күп фактлар китерәбез. Большевикларның үзләреннән алынган бик күп дәлилләр берлә дәгъвабызны исбат итәбез. Без шулай итеп, беренче маддәбездә күрсәтелгән Совет хөкүмәтенең диннәргә мөсагадә (мөмкинлек) итмәгәнен исбат итә алдык. Бу бетү берлә тагын икенче бер сөаль бирелә: "Сез ислам динен башка диннәргә караганда артык кысалар, дигәнсез. Моңа дәлилләр кая. Безнең белүебезгә караганда, Совет илендә дин һәм милләт аермалары бетерелгән. Анда тигезлек, анда бер динне кыссалар, башкаларны да шулай ук кысалар. Кысмасалар—барысына да бер төсле могамәлә итәләр". Без тагы большевик мәҗмуга һәм гәзитәләреннән тәрҗемә итәргә тотынабыз. Мөселманнарның артык җәберләнүләрен күрсәткән цифрлар берлә берничә мисал китерәбез. Аларга большевикларның үзләре язып, үзләре баскан мәҗмугаларны һәм гәзитәләрне күрсәтәләр. Алар бу мәҗмуга берлә бу гәзитәләрнең нәширләре һәм мөхәррирләре кем икәнлеген, аларның нинди матбагада басылганлыкларына кадәр тикшерәләр, язалар. Без боларның барысының да коммунист фиркасе—Совет хөкүмәте тарафыннан эшләнгәнлеген исбат итә алабыз.

Сәгатьләр буе утырып, без әле бары ике маддәгә генә дәлилләр куя алдык. Безнең меморандумда 12 маддә булганга, мәҗлес дәвам итә. Сөаль өстенә сөаль бирелә. Без зур бер имтиханга тотылган кешеләр хәленә куелабыз. Кайвакыт ачуыбыз да килә. Ләкин дәгъвабезне исбат итәргә кирәк булганга, без дәлил өстенә дәлил вәсыйка бирә барабыз. Дүрт-биш сәгать сөргән мәҗлес барыбызны да арыта; Әзһәр голямасе дә безнең меморандумдагы маддәләрнең тугрылыгына иманын куәтләндерә. Шуны күреп, мин большевикларның исламны кысуларын күрсәткән, төрле мәҗмугалардан алган фотограф рәсемнәрен чыгарам. Монда клубка әверелгән мәсҗеднең манарасына эленгән кызыл байрак та бар; сыраханәгә чәверелгән (әйләндерелгән) мәсҗед ишеге өстенә асылган Ленин һәм Троцкий рәсемнәре дә бар. Монда динсезләрнең гает көннәрендә музик берлә ясаган демонстрацияләре дә бар. Монда татар кызларын дуңгыз асрарга

өйрәткән курста алынган рәсемнәр дә бар. Шулар янына динсезләрнең берничә җырлары кушыла. Голямаларга болар барысы да бик зур тәэсир ясый. Алар бер-берсенең күзенә карашып "Әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ. Безнең андагы дин кардәшләребез Әндәлусиядәге мөселманнарның күргәннәреннән зуррак золымнарга мәгъруз калганнар (дучар булганнар.) икән (Урта гасырларда Пиреней ярымутравында—Әндәлусиядә мәселман дәүләтләре яшәгән. Әмма алар ахыр чиктә христианнар тарафыннан рәхимсез рәвештә юкка чыгарыла.). Боларга ярдәм итү—дини фарыз!"—диләр. Бергә карап: "Безнең сездән бу кадәр җентекләп сорашуыбызга кәефегез китмәсен. Безнең чыгарган карарыбыз объектив дәлилләргә корылган булырга тиеш. Мөселман голямасы турында таралган кайбер ифтираларга (гайбәт-ялаларга.) урын калмасын дибез",—диләр. Алар шул хакта мәҗлес җыеп, карар бирәчәкләрен вәгъдә иттеләр. Без бөтен вәсыйкаларны калдырдык. Алар бу вәсыйкаларның (материалларның; дәлилләрнең) урысча булганнарын үзләре тәрҗемә иттереп карамакчы булдылар. Аларның урысча белә торган берничә христиан гарәпләре бар икән. (Болар элек Казан семинарияләрендә укыган гарәпләр икәнлеге соңыннан мәгълүм булды) Татарчаларының тәрҗемәсе өчен без тагын Хәмзә Таһирбәкне күрсәттек. Без өстебездән бер зур йөк төшкән кебек, өебезгә юнәлдек.

Без Шәйхел-Әзһәрнең туплыячак мәҗлесенең карарын көтәргә тотындык. Ләкин көннәр үтте. Карар чыкмады. Мәсьәләнең нинди юл алганлыгы да мәгълүм булмады. Без матбугатта һәм җәмгыятьләрдә үз эшебезне дәвам иттек. Хөкүмәт фиркаләренең клубларын һәм лидерларын зиярәт иттек. Алардан мәгънәви ярдәм сорадык. Мисырдагы бөтен гарәп гәзитләрен зиярәт итеп, аларга мәгълүмат бирдек һәм язуларын үтендек. Шуның аркасында Русия мөселманнары хакында берәр гәзит йә мәҗмугада берәр мәкалә чыкмаган һәм җәмгыятьләрдә бу турыда сүз сөйләмәгән бер көн калмады. Мисырның бөтен әфкяре гомумиясендә (иҗтимагый фикерендә; җәмәгатьчелегендә) большевизм-исламият мәсьәләсе иң актуаль бер мәсьәлә хәлен алды. Бу француз һәм инглиз гәзитләренә дә күчте.

Без Шәйхел-Әзһәрнең карарын көтүебездә дәвам иттек. Ләкин шул шау-шу һәм шул матбугат кампаниясе Совет хөкүмәтен дә куркытты. Совет хөкүмәте исеменнән бер кеше килеп: "Мин сездән мамык алыр идем",—дип, Мисыр хөкүмәтенә мөрәҗәгать итте. Мисыр—мамык мәмләкәте. Аның иң зур байлыгы—мамык. Ләкин соңгы кризә (кризис) Мисырның мамыгына бик каты тәэсир иткән. Урта хисап берлә 15-18 Мисыр лирасы торган мамыкның бәһасе сугыш башлангач 40 лирага кадәр күтәрелгән. Бу эштән Мисыр һичбер күрелмәгән рәвештә баеган. Бу, табигый, мамык кырларының да көннән-көн артуына сәбәп булган. Сугыштан соң мамык бәһасе үзенең табигый бәһасенә кадәр ингән. Соңгы ике елдагы кризәдә аның бәһасе 3 лирага кадәр төшкән. Шуна күрә Мисырның бик күп мамыгы сатылмыйча амбарларда ябылып калган. Менә шундый вакытта мамык алырга килүче кем булса да, аның Мисыр өчен бик кадерле кунак булуында шөбһә юк. Большевиклар мисырлыларның бу нечкә җирләреннән файдаланырга уйлыйлар. Алар мамык базарлыгына керешеп, бәһа-фәләндә килешкәч: "Алуын алачакбыз. Ләкин сезнең мәмләкәттә большевикларга каршы бик каты пропаганда бара. Сез шуны туктатмасагыз, безнең хөкүмәт сездән мамык алырга разый булмас. Сез бу Русия мөселманнары исеменнән сүз сөйләүчеләрне куыгыз!"—дип әйтәчәкләр иде. Бу большевик кешесе Мисырга килү берлә, хакыйкатән, безнең пропагандада бераз суыклык башланды кебек күренде. Ул хөкүмәт даирәләренә килде, китте. Сатулашты. Ләкин Мисыр хөкүмәтенең мөселманлыгы аның мәнфәгатьчелегеннән өстен чыкты. Мисыр матбугаты тагын үз юлына төште Рамазан бәйрәмендә Шәйхел-Әзһәрнең протесты чыкты. Шул ук бәйрәмдә Кодес мөфтисе әл-Хажи Әмин Әл-Хәсәйни дә "Мәсҗеде акса"да Русия мөселманнарының котылуы хакында дога кылып, андагы большевизм золымына каршы протест итте. Шул ук бәйрәмдә Русия мөселманнарының дини хакларын химая кылу хакында Милләтләр җәмгыятенә мөрәҗәгать күндерелде. Бөтен гарәп матбугаты тагын безнең Русия мөселманнарының эше берлә дулады. Без дә үзебезнең дини бурычыбызны үти алганыбызга шатландык. Беренче мәртәбә үз диндәшләребездән мәгънәви ярдәм күреп, сөенеп бәйрәм иттек.

Рамазан бәйрәмнәренә кадәр кулларына барып кирәрлек иттереп без бөтен дөньяның мөселман падишаларына Русия мөселманнарының вөҗдани хөрриятләрен саклау хакында аерым мөрәҗәгатьләр күндергән идек.[1] СССРдагы мөселманнарның хәлләрен күрсәтә торган бик күп материаллар да боларга кушып җибәрелгән иде. Алардан мөселманлык ярдәме үтенелгән иде. Без бу эшкә киң мөселманлык ноктасыннан караганга, мәйдандагы мөселман падишаларының танылганнарының берсен дә читтә

[1] Бу мөрәҗәгатьнең гарәп телендә язылган асылының кечерәйтелгән фотографиясе "Яңа милли юл"ның 8нче санында басылып чыкты (Г.И.).

калдырмадык. Мисыр мәлиге—Фуад, Хиҗаз мәлиге—Ибне әс-Согуд, Гыйрак короле—Әмир Фәйсал, Әфган әмире—Надир шаһ, Иран шаһы—Риза хан, Фас солтаны—Мәүләви Хәсән, Ямән имамы—Имам Яхья хәзрәтләренең барысына да аерым-аерым мөрәҗәгать иттек. Падишаларга әйтелгән мөрәҗәгатьләр аерым кешеләргә язылган хатлар кебек булмаганга, боларны да ригая итәргә (ольыларга) кирәк иде. Бу безнең кебек халык хезмәте артыннан йөреп, вакытын гарәп халкы арасында сарыф иткән кешеләргә сарайларның гореф-гадәтләрен белү-өйрәнү бик җинел түгел иде. Шунарга без сарай мәрасимен (йолаларын) өйрәнгән таныш-белешләрдән бу мөселман падишаларының исемнәрен, ләкабләрен (кушамат-титулларын) өйрәндек. Мөрәҗәгатьнең ни төсле булуы хакында без фикер ясадык.

Төрекчә язылган мәктүбне гарәпчәгә тәрҗемә иттереп, оста язучыдан матур иттереп яздырырга вә һичбер ноктасына кара тамызмыйча матур, пакь көенчә күндерергә кирәк иде. Чиркәс кардәшләребездән бер рәссам, күз нурын түгеп, безнең мөрәҗәгатьләребезне бик матур итеп язды. Бу зәхмәтле эш шактый күп вакыт алды. Алай да кайбер җирләрендә хаталар ясаштыргаладык. Мәсәлән, без Иран шаһы Риза хан Пәһләви хәзрәтләренә язылачак мөрәҗәгатькә... дигән бер гыйбарә язганбыз. Вәхаләнки (чынлыкта) Иран сарай гадәте буенча... (башкачарак) язарга кирәк икән. Инде боларны җибәрү ысулы калды. Падишаларга мөрәҗәгатьләрне почта берлә күндерү гадәт түгел. Үзебез барырга вакытыбыз-имкянебез (мөмкинлегебез) юк. Шунар күрә без Мисырда илчеләре булган мөселман дәүләтләренең илчеләренә барып күндерүләрен үтенергә, юкларына аерым пакетларда һава почталары берлә күндерергә карар иттек. Моны юлга чыгарыр өчен Мисырдагы Иран, Әфган, Хиҗаз һәм Гыйрак сәфирләренә (илчеләренә) кабул вакытларын сорап, мөрәҗәгать иттек. Сәфирләрнең барысы да безгә аерым-аерым көннәр билгеләделәр. Без аларны аерым-аерым барып зиярәт иттек. Аерым-аерым СССРдагы мөселманнарның хәлләрен аңлатып, дәүләтләренең, падишаларының мөселманлык бурычын үтәүләрен сорадык. Бу кабул итүләр кайберләрендә икешәр-өчәр сәгать сөрде, озын-озын конферанс төсен алды. Сәфирләрнең иксез-чиксез сөальләренә җаваплар бирергә мәҗбүр булдык. Мондагы мөселман сәфирләре ике-өч ай Мисыр матбугатында дәвам иткән Русия мөселманнарының ачы хәлләрен укып, ишетеп торганга, боларның һәммәсендә дә безнең эшебезне белүчеләрне, безнең Русия мөселманнары берлә кызыксынучыларны күрдек. Аларның бик күбесендә үзебезнең мәгънәви ярдәмчеләребезне таптык. Аларның барысы да үзләренең падишаларына безнең мөрәҗәгатебезне күндерәчәкләрен һәм үзләре тарафыннан язылуы кирәкле булган мәгълүматны бирәчәкләрен вәгъдә иттеләр. Мисыр мәлиге Фуад хәзрәтләренә үзебез илтеп тапшырдык.

Бу мөрәҗәгатьләрнең күндерелүе хакында вакытында Аурупа матбугатында бик күп язылды. Бу мөрәҗәгатьләрнең күбесе бәйрәм көнне барып җитәчәк булганга, без аларның тәэсирләрен көтә идек. Беренче Гыйрак падишасы Әмир Фәйсалдан хәбәр килде. Әмир хәзрәтләре бик зур дикъкать берлә мөрәҗәгатебезне укыганын һәм кулыннан килгән кадәр мөселманлык бурычын үтәргә хәзер булганын белдерә иде. Аралар ерак булганга, башкаларның җаваплары бераз кичексәләр дә, шул төстә иделәр. Бәйрәм бүләкләре арасында Сүрия мөфтисенең Русия мөселманнарының котылуын теләп җамигъда дога кылдыруы вә Сүрия мөселманнарының бу хакта "Җәмгыяте әкъваль"га ("Милләтләр лигасы"на) мөрәҗәгать итүләре(н) белдерә иде. Мисыр гәзитәләренең бәйрәм номерларының барысы да Шәйхел-Әзһәрнең протесты берлә тулы иде. Һәрбер гәзитәдә шул хакта мәкаләләр язылган иде. Вафид гәзитәләреннән "Кәүкәбеш-шәрык"та ("Шәрык йолдызы"нда) гарәпнең зур язучыларыннан Гыйяс Мәхмүд әфәнде генә шундый зур уртак мөселманлык мәсьәләсендә, фиркачылыктан аерыла алмыйча, Шәйхел-Әзһәрне "ник Тәрабүлус (Триполи) мөселманнарын химая итми (якламый)" дигән төстә тәнкыйтьле бер мәкалә язды. Бу мәкалә безнең кәефебезне бик бозганга, без икәүләп Вафид гәзитләрен зиярәткә киттек. Мин "Әл-Җиһад" берлә "Әл-Бәлаг"ка бардым; Сәгыйдбәк "Кәүкәбеш-шәрык"ка китте. Икенче көнне Вафиднең бөтен гәзитләрендә Шәйхел-Әзһәрнең ислам галәменә мөрәҗәгате хакында озын мәкаләләр язылган һәм Мисыр халкы диндәшләре булган Русия мөселманнарына ярдәмгә чакырылган иде. Бигрәк тә "Әл-Җиһад"та язылган мәкалә бик кыйммәтле иде. Мисырда француз дуслыгы фикерен алып баручы "Әл-Әһрам" гәзитендә зур бер мәкалә бар иде. Башка кечерәк гәзит вә мәҗмугаларның һәммәсе дә аңа зур урын биргәннәр иде. Хәтта көлке журналлар да безне Шәйхел-Әзһәр берлә бергә төшереп, үзләренчә мәсьәләгә катышканнар иде.

Гарәп матбугатының бу кадәр кайнарлык берлә мөзакәрә иткән (тикшерелгән) мәсьәләнең Аурупа матбугатына да күчүе бик табигый иде. Мисырның французча, инглизчә һәм итальянча чыккан гәзитләреннән башка, аларның Аурупа аҗанслары (агентлары; вәкилләре) тарафыннан таратылуы кирәк иде. Вена һәм Женева аҗансларының бу хакта телеграфлар күндерүләрен белсәк тә, инглиз, француз, итальян

һәм Америка матбугатының мондый эш эшләүләрен тоя алмадык. Шул юлда, безгә ярдәм итәр өчен, Мисыр матбугат әһеленә дә мөрәҗәгать иттек. Ләкин, ни өчендер, инглиз берлә француз ажанслары безне химая итү хакында Шәйхел-Әзһәрнең ислам дөньясына иткән мөрәҗәгатен таратмадылар. Алар бу эштә үзләренә бер зарарлы нокта күрделәрме? Әллә большевиклар берлә дуслык ясауны мөселман дөньясыннан артык күрделәрме?—Аңлый алмадык. Ләкин без бөтен гарәп дөньясындагы хәрәкәтебездә инглизләр берлә французларның һәм алар артыннан бара торган христиан гарәп матбугатының ярым галякасезлеге (бәйләнешсезлеге; тотнаксызлыгы), ярым дошманлыгы берлә каршылаштык. Инглиз тарафдарлыгы берлә танылган "Әл-Мокаттам" (Каһирә тирәсендәге тау исеменә мөнәсәбәттә бирелгән гәзит атамасы) берлә французларга бик якын торган "Әл-Әһрам" гәзитәләре бик озакка кадәр безнең дәгъвабезгә сәхифәләрен ябык тоттылар. Мисырдагы әфкяре гомумия (җәмәгатьчелек) җинеп китеп, безнең большевикларга каршы эшләребез бик зурайгач һәм безнең кем булуыбыз Америкадан килгән боксердан һәм Италиядән килгән биючедән мәгърур (билгеле) булып өлгергәч кенә, алар безнең эшләребез хакында мәкаләләр язарга керештеләр. Большевиклар тарафыннан уйдырылган "мөселман" корылтаен инглизләр ясатты, аның эшләрен инглизләр йөретте",—дигән сүзне һичбер тәнкыйтьсез кабул иткән төрек матбугатына монда уйларлык шактый гына материал бар. Ләкин уйлап торганча большевик уйдырып биргәнне кабул итәргә өйрәнгән кешеләргә "Аңлаганга—сүри ("печән жыя торган чыбык".)—сәнәк тә саз (музыка коралы.), аңламаганга—дәвал ("барабан".)—думбра да аз" мәкаленнән башка җавап юк.

Шәйхел-Әзһәрнең ислам дөньясына мөрәҗәгате яңа бер мәйдан ачты: гарәп матбугатында шул хакта яңа бер фикер туды. Ул да: Мисырның тарихи җамигъларының берсендә зур бер дини мәҗлес ясап, шунда Русия мөселманнарының хәлләрен тагын бер мәртәбә күздән кичереп, Русия мөселманнарына ярдәмне гамәли бер юлга кую һәм Мисырда Русия мөселманнарының эше берлә шөгыльләнә торган бер даими оешма мәйданга китерү иде. Бу шул эш берлә шөгыльләнә беләчәк төрле даирәнең олуглары берлә күрешергә-сөйләшергә тотындык. Ләкин Мисырда фиркачелек бик тирән җирләшкәнгә, бик күп хөрмәтле кешеләр үзләренең бу эшкә катышулары өчен икенче бер фирканең олугларыннан фәлан-фәланнең катышмавын шарт иткәнгә, без бик авыр вазгыятькә төштек. Без бик күп вакыт һәм көчебезне сарыф итсәк тә, әле шундый бер мәҗлесне ясап булу-булмау хакында шөбһәдә калдык. Читтән генә булса да безгә каршы кайбер интригалар барын күреп, бу эшне мисырлыларның үзләренә тапшырдык.

Минем монда торуым бик озаеп киткәнгә, илемдә-йортымда бик күп эшләрем булганга, мондагы дус-иш һәм фикердәшләрдән шул хәрәкәтне алып баруны үтенеп, юлга хәзерләндем. Мин Фәләстин аша Сүриягә кереп, Бәйрутта пароходка утырып, Италия юлы берлә Аурупага кайтачак идем. Аркадашым Сәгыйд Шамилбәк мондагы эшләрне бер изге нәтиҗәгә ирештерергә тырышачак иде. Мисырда таныган-белгәнем бик күбәйгән иде. Алар берлә күрешеп, юлга чыгачак булдым. Юлым Кантарада Суэйс каналын үтеп, Фәләстинга керәчәк иде. Моның өчен тагын бер инглиз визасы кирәк иде. Юлым бик озын булып, бик күп мәмләкәтләрне үтәргә тугры килгәнгә, визалар да бик масрафлы (кыйбат) иде. Гәзитәчеләргә визаны буш бирү гадәт хаденә килгәнгә, берничә мәмләкәттән башкасында, мин һәрвакыт визаны бушлай ала килә идем. Инглиз консулына да паспортымны суздым: "Мөхәррир, бушлай виза",—дидем. Мәэмүр (чиновник) күзләрен акайтып, төрек паспортымны әйләндереп-әйләндереп карады да: "Виза биреп-бирмәвебезне белер өчен, иртәгә килегез, бушлай булу ихтималы юк!"—диде. Күпме торачагын сорадым. Жиде доллар чамасы бер цифрны әйтте. Кодес-Шәрифкә барып, безнең анда сайлап калдырган... "Башкарма һәйәте"нең ни хәлдә барганын күрәсем килгәнгә, Яффа күршендә яһүдиләрнең яңа салган Тел-әл-Абиб" шәһәрен һәм Хәйфада илдәшем Габдулла Тимерне зиярәт итәсем килгәнгә, икенче көнне теләр-теләмәс тау чаклы акча биреп, инглиз визасын алдым. Озатырга Мисырдагы дусларымнан, ислам галәменең Мисырдагы мәшһүр хадимнәреннән бик күп кеше чыккан иде. Самими күрешүләрдән соң мин юлыма юнәлдем.

*Ахыры киләсе санда.*

# Адлер Тимергалин

## МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ГАЛИӘСГАР***—Мөселманнарда, хосусан төрки халыкларда очрый торган исем. *Гали*—олы, өлкән мәгънәсенә, ә *Әсгар*—кечек мәгънәсенә ия булганлыктан, бу исем беркадәр аптырашка да калдырырга мөмкин. Хикмәт шунда: риваятләргә караганда, Гали хәлифәнең улы Хөсәеннең төрле аналар тапкан угыллары арасыннан өчесенә бер үк Гали исеме кушылган була. Аларны берәр ничек аеру өчен өлкән угылны—*Али Әкбәр* (Өлкән Али/Гали) дип, уртанчысын—*Али Әусат* (Уртанчы Али/Гали) һәм кечесен *Али Әсгар* (Кечек Али/Гали) дип атап йөрткәннәр. Бу исемнәр башка мөселман халыклар арасында да таралыш алган (мәс., татарда *Галиәсгар Камал*).

***ГАНКА, ГАНКӘ*** *г.*—**1**.*Каф* тавында яшәүче мифик *Сәмруг кош*. Грифон, феникс. Ганка кошын гади кешегә күрү насыйб булмый, имеш. Аллаһы Тәгалә ганка кошларын камил итеп яраткан, ләкин алар адәмгә дошман булып киткәннәр. Ганка кошы гәүдәсе белән кояшны каплый ала, имеш. Кайбер риваятләрдә бу кошны *Ханзала бин Сафуан пәйгамбәр* юк иткән дип сөйләнә. **2**.Мәдрәсә телендә: ахмак, аңгыра, булмаган нәрсә. **3**.Поэзиядә ганка—ирешеп булмаслык нәрсәнең символы.

***ГАРӘБИЗМ***—Арабизм. //*Моңарчы әдәбият, матбугат дөньябызны каплап, әдәби-гыйльми әсәрләрне хезмәт халкына аңланмаслык ясауга сәбәп булган гарәбизмга каршы көрәш башларга, боларны чыгарып ташларга кирәк* (*Г.Ибраһимов*) әдипнең 1924 елда матбугат һәм әдәбият эшлекләләре каршында ясаган чыгышыннан).

***ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ***—Дөньяда киң таралган язулардан исәпләнә. Ул җир йөзендәге барлык халыкларның ун процентына хезмәт итә дип уйлыйлар. Гарәп теле рәсми дәүләт теле дип саналган егермедән артык илдә (Алжир, Бахрейн, Берләшкән Гарәп Әмиратлары, Иордания, Гыйрак, Йәмән Гарәп республикасы, Йәмән Халык демократиясе Республикасы, Катар, Комор (*Камәр*—Ай) утраулары (Җәзирә әл-Камәр), Кувәйт, Ливан, Ливия, Мавритания, Марокко, Мисыр, Оман (Гомман), Сүрия, Сомали, Судан, Сөгуд Гарәбстаны, Тунис (Түнис), Җибути һәм боларга Палестинаны (Фәлестан, Фәләстыйн) да өстәргә мөмкин) милли әлифба булып санала. Гарәп хоруфаты фарсы телле Иранда, урду телле Пакистанда, пушту һәм дари телле Әфганстанда, өлешчә Һиндстанда кабул ителгән. Ислам дине киң таралган Бангладеш, Һиндонезия, Малайзия, Мозамбик, Нигерия, Филлипин, Эфиопия кебек илләрдә дә гарәп әлифбасы киң кулланыла.

Гарәп язуы татар халкына да мең елдан артык хезмәт итеп килде һәм хәзер дә, 30 нчы еллардан алып башта латин графикасына, аннары кирилл хоруфатына күчүебезгә карамастан, хакыйкый мөселманнарга хезмәт итә.

***ГАРӘП ТЕЛЕ***—Классик гарәп теле Мөхәммәд Пәйгамбәрнең туган кабиләсе корәешләр сөйләшкән гарәп теленә нигезләнә. Идрис Шаһ үзенең "Суфизм" дигән китабында семит телләре арасында иң гади һәм анык тел булган гарәп теленең математик принциплар ярдәмендә иҗат ителгән ясалма тел булу ихтималы турында яза. Ләкин, билгеле булганча, академик Н.Я.Марр (1864—1934) гарәп телен "гаҗәеп сыгылмалы тел" дип санаган, ә ясалма телләргә бу сыйфат бер дә хас түгел. Филология күзлегеннән караганда, гарәп теле, әйтик, иврит теле белән чагыштырганда, күпкә борынгырак. Шуңа күрә иврит теленең грамматикасын гарәп телен өйрәнү нәтиҗәсендә алынган мәгълүматлар нигезендә төзегәннәр. Еврей галимнәре әдәбиятта куллана-куллана

*Дәвамы. Башы журналыбызның алдагы саннарында.*

мәгънәләре бозылган кайбер борынгы еврей (гыйбрани) теле сүзләренең беренчел мәгънәсен гарәп телен өйрәнү юлы белән ачыклый алдылар.

Гарәп теле – киң таралган телләрнең берсе. "Гыйракта, Сүриядә, Ливанда, Иорданиядә, Мисырда, Гарәп ярымутравында, Мароккода, Алжирда, Тунисга, Ливиядә, Суданда, Мальта утравында һ.б. җирләрдә яшәүче йөз миллионга якын кеше (хәзерге вакытта күбрәк тә – *А.Т.*) гарәпчә сөйләшә. Шул ук вакытта гарәп илләрендә бердәм гомумдәүләт теле булган әдәби тел белән беррәттән, күп санда җирле шивәләр дә кулланыла. Аларның иң әһәмиятлеләре: Азиядә – Гыйрак шивәсе, Сүрия шивәсе, Африкада – Мисыр һәм Мәгъриб шивәләре. Гарәп әдәби теленә иң якын булган диалект – Сүрия шивәсе" *(Мирза Мәхмүтов, 1965)*.

Коръән теле буларак, гарәп теле изге тел дип санала башлаган.

***ГАРӘП ЦИФРЛАРЫ*** – Күренекле гарәп математигы Мөхәммәд ибн Муса әл-Хәрәзми (787 – 850) саннарны (шул исәптән *нульне* – гарәпчә *сыйфрны*) һинди ысул белән язу ысулын кулланышка кертә. Хәрефләр ярдәмендә күрсәтүгә караганда, бу ысул күп тапкырлар отышлырак булып чыга. Хәрәзминең цифрлар турындагы хезмәте XII гасырда инглиз Аделард (1090 тирәсе – 1150 тирәсе) тарафыннан латин теленә тәрҗемә ителгәч, яңа ысул белән Европа да таныша. Хәрәзми яңа цифрларны һиндстанныкы дип күрсәткән булса да, тәрҗемәче, ялгышып, аларны гарәп цифрлары дип атый һәм бу хата гасырлар буе дәвам итә. Билгеле булганча, саннарны яңача тамгалауга кадәр греклар һәм римлылар саннарны латин алфавитындагы хәрефләр белән күрсәткәннәр. Күренекле итальян математигы Леонардо Фибоначчи (1170 тирәсе – 1230 тирәсе) тырышлыгы белән XIII гасыр башларында Италиядә яңа тамгалар гамәлгә керә. Шуннан соң арифметик хисаплау эшендә гадәттән тыш уңышларга ирешелә, чөнки эш күп тапкырлар тизләнә, ансатлаша.. Нәтиҗәдә тулаем математика, физика, астрономия фәннәре бик тиз үсеп китә.

Тагын кара: ***РИМ ЦИФРЛАРЫ, ҺИНДИ САННАР, ХӘРӘЗМИ.***

***ГАРӘПЧӘ ТУЛЫ ИСЕМ*** – Гарәпчә тулы исем түбәндәге өлешләрдән тора:

1) кешенең хөрмәтле исеме, титулы – *ләкаб*, мәсәлән: *Гыйззәтдин* (диннең хөрмәтлесе); 2) ата кешенең өлкән улының исеме буенча аталышы – *көнья*, мәсәлән: *Әбү Мөхәммәд* – Мөхәммәднең атасы; гомумән, гарәпләрдә угыл исеме буенча аталу хөрмәтле исем дип исәпләнгән, шуңа күрә хәтта баласыз кешеләр яки балалары үлгән кешеләр дә еш кына шушындый көнья алалар; 3) шәхеснең үз *исеме*, мәсәлән: *Гали*; 4) кешенең исеменә атасының ибн (угыл) сүзе аша ялганган исеме, мәсәлән: *ибн Хатиб* (аннан соң бабасының һ.б. исемнәре ялганырга мөмкин); 5) нәсел исеме (этник исем), бу кешенең чыккан төбәген күрсәтүче сыйфат – *нисеб*, мәсәлән: *әл-Багдади*. Тулаем алганда: *Гыйззәтдин Әбү Мөхәммәд Гали ибн Хатиб (...) әл-Багдади*. Боларга кешенең һөнәре буенча яки башка бер тышкы сыйфаты буенча *кушаматы* ялганырга мөмкин, ләкин бусы мәҗбүри түгел. Гарәпчә *Әбү* сүзе Иранда һәм Урта Азиядә еш кына кыскарып *бү* рәвешендә кулланылганлыгын әйтергә кирәк (Әбү-Таһир – Бу-Таһир). Шул ук илләрдә гарәпчәдәге *ибн* атаның һәм угылның исеме арасында *-и-* авазы белән алмашынырга мөмкин (Насыйр-и-Хөсрәү – Насыйр ибн-Хөсрәү). Урта Азиядә *ибн* не еш кына *бинни* рәвешендә әйтәләр, бездә дә ул *бин(е)* рәвешендә очрый.

Хәлифәт чорында гарәпләрдә баланы бәлигъ булганчы ата-анасы биргән исеме белән атап йөрткәннәр, бәлигъ булгач исә аңа көньясын әйтеп дәшкәннәр. Хәлифәткә аеруча хезмәт күрсәткән кешегә хәлифә яки солтан титул биреп, бу титул аның үз исемен дә, көньясын да алмаштырган.

*Тәхәллүс* сүзе исә псевдоним мәгънәсендә.

***ГАУРӘТ*** *г.* – **1.**Гәүдәнең түбәнге өлеше; җенес әгъзасы. // *Гаурәт җирләр* – тәннең кешегә күрсәтергә ярамый торган урыннары. Намаз укыганда гаурәт җирләрнең өртүле булуы фарыз. Аулак бүлмәдә булса да, ялангач көенчә намаз уку дөрес түгел. Ирләрнең билдән югары вә тездән түбән җирләре ачык булсалар да, намаз укулары дөрес булыр. Хатын-кызларның исә йөзләре вә беләзекләренә кадәр ике учлары вә тубыкларына кадәр аяк башлары гына гаурәт түгелдер. **2.**Гомумән, хатын-кыз мәгънәсенә дә ия.

Ибне Габбас Адәм галәйһиссәламнең гаурәт җире Бабил туфрагыннан яратылган дип яза.

***ГОЛЯМАИ СҮЭ*** *г.* – Гыйлемнәрен сүэ (начар) кулланучы яки сарыф итмичә яшереп яткыручы галимнәр. // *"Хакыйкатьтә, Аллаһ иңдергән гыйлемне яшерүчеләр һәм аның бәрабәренә дөнья малын сатып алучылар, корсакларына уттан башка нәрсә ашамыйлар, алар белән Аллаһы Тәгалә кыямәт көнне сөйләшмәс, аларны пакьләмәс тә һәм алар өчен рәнҗеткүче газаплар бар. Бу җәмәгать адашу юлын тугры юл бәрабәренә, газапны гөнаһлардан ярлыкану бәрабәренә сатып алдылар. Җәһәннәм утына алар ничек чыдарлар икән?"* "Бәкарә" сүрәсе, 174 – 175 нче аятьләр. *"Берәү белгән гыйлеменнән соралып та, аны яшерсә, Аллаһы Тәгалә ул кешегә кыямәт көнне уттан булган йөгән кидерер." (Хәдис).*

Чагыштыр.: *Галим гайре гамил.*

***ГОНВАН*** *г.* – **1.** Дәрәҗә, титул, ләкаб, исем, кушама*т.* // *Алтын Урдада хан гонванын тик Чыңгыз токымнары гына йөртә алган. (Р.Әхмәтьянов). Бән яшь вакытта безнең авылымызда чүпрәкче гонванында улан сатучылар, үзләре арбаларында утырган көенчә, як-якка карап: "Чүпрәк, чүпрәк! Чыгарыңыз күбрәк!" – дип, атларыны акрын гына атлатып, урам буенча кычкырып йөри торганнар иде. (Закир Һади). Гонван илә горурлану. Хаҗилык гонваны. Чемпион гонваны.* Үзбәк телендә: *хәрби гонван* – воинское звание, *профессорлык гонваны* – профессор дәрәҗәсе, *фәхри гонван* – почетлы исем. **2**.Китап, гәзит исеме, мәкалә исеме. // *18 нче номер "Әльислах"та "Бунлар онытылган!.." гонванлы бер мәкалә дәреҗ ителеп, русча укучыларга татарча да өйрәтелү тугърысында берникадәр нәрсә сөйләнгән иде. (Ф.Әмирхан). Боларның шундый сентименталь гонваннарына дикъкать итеп, эчләренә керсәң, кызгану катыш йөрәк әрнүгә башка бер нәрсә ала алмассың... (Г.Ибраһимов).*

***"ГОСМАН КОРЪӘНЕ"*** *тар.* – Сәмәркандта Урта Азия мөселманнарының Диния нәзарәте китапханәсендә саклана торган борынгы Коръән кулъязмасының ("асаре гатика"ның) традицион исеме, *Мосхәф Госмани.* Мәвараэннәһер халкы аны *Коръән-имам* дип тә атаган. Аның мәтене (тексты) Рәсүлулланың тол хатыны Хафизадагы китап буенча төзелгән. Ул берничә гасыр буена Сәмәркандта Хуҗа Әхрар мәчетендә сакланган һәм Госман хәлифә кушуы буенча күчереп язылган кануни Коръән күчермәләренең берсе дип исәпләнә. Бу Коръән китабының "озынлыгы бер аршин (70 см), иңе 12 вершок, калынлыгы 4 вершок булып, кәгазьләре хайван тиресеннән эшләнгән пергамент, Куфә язулары бик ачык, һәр биттә 12 юл, 353 кәгазь, 706 биттән торадыр" (калын һәм нык пергаментның бер ягы саргылт һәм шома, икенче ягы (бите) аксыл төстә, шулай да 69 пергамент урынына аңа охшатып эшләнгән кәгазь битләре ябыштырылган). Ривайәткә караганда, Госман хәлифәне шушы Коръәнне укып утырган вакытында Гали тарафдарлары үтергәннәр һәм хәзрәти Госманның каны Коръәнгә дә аккан. Кан эзләре аермачык беленеп тора, дөрес Коръән китабын тикшергән А.Ф.Шебунин ул эзләр очраклы рәвештә килеп чыкмаган дип бара.

1869 елда Төркестан төбәге генерал-губернаторы аны юк кына бәягә сатып алган һәм Петербургтагы Император китапханәсенә бүләк иткән. "Сәмәркандта ташландык булып ятканда кайбер битләре югалган, төпләре купкан хәлдә була. Әмма Петербургка килеп көтепханәгә кергәч, агачтан тартма ясап, шул тартмага куялар, өстен пыяла белән ябалар, ефәк җепләр белән тегеп төплиләр, һәр битенә номер сугалар". 1891 елда ориенталист А.Ф.Шебунин кулъязма Коръәнне палеографик яктан тасвирлый һәм бу күчермәнең төзелү вакыты VIII гасырдан да иртә түгел дигән нәтиҗәгә килә.

Петроград милли округының Төбәк мөселманнары үтенече буенча "Госман Коръәне" 1917 ел азагында Владимир Ульянов (Ленин) фәрманы белән Уфага җибәрелә һәм Мөселманнарның Дини идарәсе мөфтие Галимҗан хәзрәт Барудига тапшырыла. Ул анда 1923 елның 19 июненә кадәр саклана. Ватандашлар сугышы тәмамланганнан соң ук Урта Азия дини җәмәгасе Коръәнне Сәмәркандка кайтаруны таләп итә. Ләкин аны башта Ташкентка җибәрәләр (Ташкент Диния нәзарәтенә Мөсхәф Госманины 1923 елның августында Ризаэддин Фәхреддин хәзрәт оештырган махсус вәкаләт илә, ул

вәкаләттә Г.Гомәри һәм Г.Гыйсмәтиләр катнашкан. Зыяэддин әл-Кәмали Ташкент Диния Нәзарәтенә үзе илтеп тапшырды дигән хәбәрләр бар) һәм изге китапның язмышын урында хәл итәргә дигән компромисслы карар чыгарыла. 1926 елдан ул Үзбәкстан халыклары тарихы музеенда саклана. 1989 елның 14 мартында Урта Азия мөселманнарының 4 нче корылтаенда тарихи ядкяр Урта Азия мөселманнарының Дини идарәсе китапханәсе – Мавәраэннәһергә тантаналы төстә тапшырылды.

Шиһабетдин Мәрҗани бик искергән кулъязманың 1790 елларда Сәмәркандта булган вакытында Утыз Имәни тарафыннан төзәтелүе, югалган битләренең тутырылуы турында яза. Аның фикеренчә дә бу Коръән күчермәсенең Госманныкы булуы шикле. "Госман Коръәне"н Петербург китапханәсендә үз күзләре белән күргән Заһир Бигиев исә мосхәфнең Госман хәлифәгә катнашлыгы юк икәнен кистереп әйтә: "Чөнки мин күргән Коръән гаять зур иде, ә Хәлифә Госманның Коръәне, гыйлем әһелләрнең раславына караганда, ике кул яссылыгы кадәр киңлектә, бер кул яссылыгыннан артыграк озынлыкта булган".

Шулай итеп, татарларның да мәшһүр "Госман Коръәне"нә катнашы юк түгел икән. "Госман Коръәне"ндә һәр аять икенчесеннән дүрт яки җиде сызыкча белән аерылган, аятьләр төркемнәргә бүленгәннәр. Һәр сүрә күршесеннән бизәкле дүрткелләрдән торган төсле "тасма" белән аерыла. Сүрәләрнең исемнәре юк, ләкин 9 нчысыннан кала һәрберсе "Бисмилла" белән башлана.

1906 елда "Госман Коръәне"нең фототипик басмасы нәшер ителә *(С.Писарев тарафыннан)*.

Госман хәлифә заманында Зәйд бине Сабит хәзрәтләренең каләме белән күчереп язылган мосхәфләрдән берәрсенең сакланып калганлыгы турында мәгълүмат юк. Малик бине Әнәс хәзрәтләренең язуына караганда, хәлифә Госманның вафаты соңында аның Коръәне тарих күзеннән юкка чыга. Хәлифә вафат булгач, изге китапның Госманның угылы Халид хәзрәтләре кулында калганлыгы гына билгеле. Шуңа күрә: "Хәлифә Госманның Коръәне шушыдыр!" дип дәгъва итүчеләр байтак булган. "Ходай белер, күпме Коръән "Госман Коръәнедер", дәгъва итәр өчен күпмесе мәкер әһленең кулы белән мордар каннарга буялгандыр!" – дип яза Заһир Бигиев.

***ГӨНАҺ*** *ф.* – Язык, гаеп эш, мәгъсыять, убал, ис(е)м (суфичылыкта). Гөнаһ төшенчәсе кылган гамәлләргә генә түгел, әйткән сүзләргә һәм әйтелмичә калган уй-фикерләргә дә кагыла. Дини төшенчә дип исәпләнсә дә, гөнаһны аңлау фикер сөреше нәтиҗәсендә гакыл тарафыннан гына тудырылмаганга охшый. Аңсыз мәхлуклар да үзләренең хуҗалары гаепләрлек эш кылып ташлаганнарын сизеп гафу үтенгәндәй басынкыланып, мыштым гына йөриләр, ягъни гаебеңне сизү, ахыргы исәптә, табигый, интуитив, илаһи тойгы булса кирәк.

Адәм белән Һәуваның, Иблис коткысына бирелеп, җәннәттә тыелган җимештән авыз итү аркасында гөнаһлы булуы *асле-гөнаһ*, ягъни беренче *(беренчел)* гөнаһ дип атала. Ягъни адәм заты яратылыштан ук гөнаһлы.

Коръәннең "Гимран" сүрәсендә 129 аятьтә болай әйтелгән: "Аллаһ теләгән бәндәсен ярлыкар вә теләгән бәндәсен гөнаһлары өчен газаб кыйлыр. Ләкин тәүбә вә итагать белән Аллаһуга кайтучыга Ул ярлыкаучы һәм рәхимле."

Тукай:

*"Кем яраткан? Кем чыгарган? И гөнаһ ләфзы сине;*
*Мәгънәсезсең, сеңдералмый саф гакыл һәзмы сине!*
*Син кирәксез бер ләфызсың, син кабахәт, син оят,*
*Безгә артык бер йөгәнсең, бел, сиңа дошман хәят"*, – дисә дә, аның бу сүзләрендә гөнаһкярның аптырашта калган мизгелен, адашкан шагыйрьнең бәргәләнә-бәргәләнә пакь юл эзләвен күрү тиеш. Гөнаһыңны танып тәүбәгә килү асылда әхлакның нигезен тәшкил итә.

Фатих Әмирхан: "Әл исме ма хакә нәфсекә вә кәриһтә ән ятталигы галәйһиннас" *("Гөнаһ – күңелең шөбһәләнеп, халыкка белдертәсең килмәгән эштәр")* дигән хәдис-шәрифне мисал итеп китерә.

// *Гөнаһ шомлыгы* – бәхетсезлек; бәла. 1931 елгы "Татарча – урысча сүзлек"тә: *прегрешение*.

*"Изгелек искермәс вә тузмас, гөнаһ онытылмас"* дигән сүз дә бар.

Әдәбиятта гөнаһлы эш, гөнаһ, язык мәгънәсендәге *"мәгъсыять"* дигән гарәп сүзе дә очрый. "Суфичылык серләре" китабында гөнаһ сүзенең гарәп телендәге синонимнары итеп *зәнб, исм, кәбирә* сүзләре китерелгән. "Идегәй" дастанында гөнаһ мәгънәсендә *"убал"* сүзе кулланыла (*"Убалын кая куярсың?"*). Төрки телдә тагын шул ук мәгънәдәге *"суч"* сүзе дә бар (*"Сучләрем гафу әйлә"*).

***ГЫЙЛАВӘ*** *г.* – Өстәмә, кушымта. Мәс., Җамалетдин Юмаев Дәрдмәнднең "Кораб" шигыренә мондый гыйлавә язган:

*"Туктаган ул, тик торадыр*
*Бер урында әлсерәп,*
*Чит-читеннән ят кораблар*
*Китәлиләр хәл сорап..."* // *Гыйләвә кылу, гыйлавә итү – өстәү. Беренче китапта мөхәрриренең кульязмасын гыйлавә итәчәктер.*

***ГЫЙФФӘТ*** *г.* – **1**.Кызлык, сафлык, бөтенлек. Р.Фәхреддин гыйффәт турында түбәндәгеләрне яза: "Әлхасыйл, хәя белән гыйффәт хатыннарның мәгънәви гүзәллекләредер. Бу исә бер гүзәллектер ки, тышлары беренче дәрәҗәдә гүзәл булганнар белән алыштырылмас. Хәтта гүзәл булып та хәясы вә гыйффәте булмас исә, ул хатыннан ире вә башка яхшы дуслары тиз заманда нәфрәт итәрләр вә бизәрләр." **2**.Намус, йөз суы // *Адәм балаларын фәрештәләр дәрәҗәсенә күтәрә торган нәрсә гыйффәт булып, хайваннардан да түбән дәрәҗәгә төшерә торган нәрсә гыйффәтсезлекдер.* (*Р.Фәхреддин*). // *Гыйффәтсез калу – гаять зур намуссызлык, бәхетсезлек. Сафлыгыны, йөз агыны, абруены югалту була.* (*Суфия Галиева*). "Мөселманча тәрбия нигезләре". *Гыйффәт мәктәбе* – әдәп мәктәбе (русча – институт благородных девиц).

***ГҮЛ*** *г.* – Җен затыннан. Курыкканда күзгә күренә, гадәттә хатын-кыз җенесеннән була; ирләр җенесеннән булганын *Кутруб* дип *(кайчак Силату дип)* атыйлар. Аны койрыклы һәм мөгезле итеп күз алдына китергәннәр. Хәер, гүл теләсә нинди кыяфәткә керә ала дип тә ышанганнар. Гүлләр чүлләрдә, буш һәм калдау җирләрдә яшиләр, адәмнәрне алдап китереп, аларны ашыйлар имеш. Коръәндә гүл термины юк.

Астрономиядә Персей йолдызлыгындагы яктылыгы аермачык үзгәреп тора торган бета йолдызы рус терминологиясендә *Алголь* дип атала. Бу атамадагы *голь / гуль* өлеше гарәпчә *җен / иблисә / сихерче карчык* мәгънәсендә. Йолдыз исемнең татарча язылышын *Әлгүл* дип алганда дөресрәк булыр иде *(хәзерге вакытта русча язылыш кулланыла)*.

***ГЫЙДДӘТ, ГЫЙДДӘТҮЛМӘРЪӘ*** *г.* – Гарәпчә "бераз вакыт" мәгънәсендә. Тол калган яки иреннән аерылган хатынның икенче иргә бармый (яки элекке иренә кайтмый) торырга тиешле булган вакыты *(Коръәндә "Талак" сүрәсенең 4 нче аятендә гыйддәт өч ай дип күрсәтелә. Чыганакларда 4 ай да 10 көн дип конкретлаштыру да очрый. Гомумән, өч тапкыр айлыгы килеп узган вакыт)*. Шәригать хөкеме буенча балага беренче нәүбәттә ата хуҗа булып исәпләнгәнлектән, бу йола баланың атасы кем икәнлеген ачыклау өчен кирәк булган.

Исламга кадәрге чорда тол хатыннар начар бер өйдә, начар киемен киеп, бер елга кадәр беркая чыкмастан, тәненә су тигермичә, тырнагын кисмичә, чәчен тарамыйча гыйддәт сакларга тиеш булганнар. "Сыер" сүрәсенең 234 нче аяте бу таләпне юкка чыгара.

// *Гыйддәт чоры. Гыйддәт тоту. Гыйддәт саклау.*

***ГЫЙЛЕМ ӘЛ-ЯКЫЙН*** *г.* – Гыйлемнең өч дәрәҗәсеннән беренчесе – фикер йөртеп табылганы, башкалары – *гайн әл-якыйн (күз белән күреп табылган ышаныч)* һәм *хакк әл-якыйн* – дөреслегендә һич шик булмаган, ышанычлы белем.

*Хәтер*

**Бикә Рәхимова**

# УЛ БЕРЕНЧЕ ИДЕ

*Иң мөкатдәс, мәгънәле яшәлә торган гомер—тарихи ватанда узганы, иң зур мактауга лаек хезмәт—туган халкыңа багышланганы.*

Тәүфикъ Әйди.

Борынгы заманнарда ук төрле миссия белән дөнья буйлап йөрүче кешеләр булган. Аларны кодрәтле хакимият ияләренең канцелярия хезмәткәрләре, эшлекләләре аталап зур юлларга әзерләнгәннәр, кирәкле һәрнәрсә белән тәэмин иткәннәр, кулларына ышаныч хатлары тоттырганнар. Әлеге сәяхәтчеләр өчен махсус кәрваннар, экспедицияләр төзегәннәр, үзләренең хәер-догаларын биреп, кайсыларын тантаналы рәвештә, ә кайберләрен шыпын гына озатып җибәргәннәр.

Ә менә безнең көннәрдә горбәтлектә җәфа чиккән газиз халкының дөнья буйлап сибелгән бөртекләрен барып табу-барлау, күрешү-хәл белешү, татарлыгы җуелмаганнарының ничек тә рухларын күтәрү, ә татарлыгы югалып баручыларына үзләренең кемлеген исләренә төшерергә тырышу, тарихи ватан турында хәтерләрен яңарту, бер унайдан, гомумән дә башка халыкларга да мәгърифәтле татар милләте барлыгын белгертергә тырышу миссиясе белән иректә баштан, төп эшеннән аерылмыйча, үзенең шәхси ялы хисабына ерак юлларга чыгып китүчене батыр димичә, кем дисең инде? Әйе, татар әдәбиятының күренекле вәкиле Тәүфикъ Әйдине әле тора-тора батыр дип тә атарлар...



Сәвит чорында, 70-80 елларда (үзебезнең XX гасырга шулкадәр дә ияләшелгән, аны үткән гасыр дип әйтергә тел дә әйләнми) без—татар әдәбиятын сөючеләр—чит илләр турындагы мәгълүматларны күбрәк Миргазыян Юныс әсәрләрен укып ала идек. Хәзер менә шундый икенче бер төрле заман килеп ята ки, Тәүфикъ Әйди йөреп чыккан илләр (кайберләреннән кала) һәм элеккеге СССР җөмһүриятләре хакында ни генә белербез икән? Анда бүленеп калган милләттәшләребез хакында ни ишетербез? Күз күрмәгән, колак ишетмәгән юл чыгымнары аркасында ул яклардагы якын туганнар белән дә күрешә алмас булдык. Элек "күгәрчендәй гөрләшкән" Болгария, Румыния, Венгрия, Польшаны да "оныталар" бугай инде—анда, ул илләрдә дә безнең милләттәшләр байтак диләр бит. Менә бу очракта безгә Тәүфикъ Әйди әсәрләре ярдәмгә килергә мөмкин, һич югы, андагы милләттәшләребезне онытмаска бер кыңгырау булып торыр, әгәр дә алар һәртөрле кысу-җәберләү, яисә үзләренең ваемсызлыклары аркасында бөтенләй юкка чыгып бетмәсәләр...

Хәер, кая инде ул чит илләр! Татарның бүгенге көндә дәүләтчелек билгеләре булган җирлектә—Татарстанда халкыбызны упкынга аккандай йотылудан бергәләп саклыйсы, саклашасы иде. Тәүфикъ Әйди бу эшне нәкъ үзебезнең җөмһүрияттән башлаган да.

Искиткеч кызыксынучан һәм шул ук вакытта төгәл мантыйк, аек акыл белән

эш йөртүче сәяхәтчебез күзеннән татар тормышының, татар авылларының бер генә детале дә читтә калмый. Әйтик, авылда ничә йорт бар, ничә кеше яши, мәктәп нинди, укучылар ничәү, укытучылар житәрлекме? Авылда китапханә бармы? Анда ничә китап жыелган? Иң мөһиме—татарчасы күпме? Клуб эше ничек? Анда жырбию генәме? Әллә профессиональ сәнгатьнең нигез ташы булган фольклорга да игътибар бармы? Бу игътибар конферансье-алып баручының бер-ике мәзәк әйтүе белән бетәме, әллә төрле жанрлар буенча кичәләр үтәме? Әйе-әйе, мәсәлән, мәкаль, әйтем, табышмаклар кичәсе, бәет кичәсе һ. б. Тәүфикъ Әйти хәтта аерым фольклор клублары оештырырга тәкъдим итә: театр түгәрәге, хор, ансамбльләрне оештырган кебек. (Т. Әйди. Сайланма әсәрләр. "Сәхнәгә мәзәк кирәкме?" 11 том, 4-10 б.) Бүгенге әхлакый хәлләрнең авылларыбызда да чигенә житеп начарланганын күз алдында тотсак, фольклор клублары оештыру көнүзәк мәсьәләгә әйләнгән икән бит! Үз халкыбызның хикмәтле сүзләре белән "чыбыклап" тәрбияләү ихтыяжы туганлыгын һәрберебез күреп торабыз—шундый "пеше чыбык" бик күпләребезнең "аркасын эзли" түгелме?

Тәүфикъ Әйди өчен авыл кешесенең бер проблемасы да чит түгел. Авыл кешесенең кереме бармы? Ул ничек яши, очын-очка ялгый аламы? Әмма аның өчен иң борчыган мәсьәлә—татар китапларын, татар гәжит-журналларын татарларның уку мәсьәләсе.

Менә шунда ул үзенең үгетләү-пропагандалау эшен осталарча, хәтта ки, тылсымчыларча башкара да инде! Очрашуга килгән халык алдына ул аркасында һәм кулында күтәреп алып килгән зур сумкалардан "Казан утлары", "Ялкын" журналлары, ул вакыттагы "Яшь ленинчы", "Ватаным Татарстан" гәжитләре, бик күп татар китаплары чыга башлый һәм... "сорау алу" башлана: "Бусын укыйсызмы? Бусын алдыртасызмы?" Гәжит-журналларны яздырып алмасалар, китаплар укымасалар, Тәүфикъ Әйдидән рәхим-шәфкать көтә алмыйлар, үтергеч тәнкыйть утына тотылалар, соңыннан гына, йомгаклау сүзендә генә, "төзәлүләренә" өмет белдерелергә мөмкин...

Ләкин чын йөрәктән әйтелгән тәнкыйтькә, агит-үгетләүгә кеше үпкәләми, киресенчә, күнеле йомшара. Нәкъ шул 70-80 елларда "Казан утлары" журналының тиражы нык үсеп китүендә Тәүфикъ Әйдинең өлеше барлыгын танымый мөмкин түгелдер.

Агит-үгетләү дип яздым да Тәүфикъ Әйдинең "үгетбригада" сүзе искә төште. Язучы-галимнең яңа сүзләр барлыкка китерү, аларны куллану хакында да фикере кызыклы. Ул үзебезнең төрки телләр жирлегендә, татар жирлегендә үсеп чыкканнарын куллануны бигрәк тә хуплый. Яңа сүз башта гына чит сыман тоелырга мөмкин, тора-бара ул үзләшә, чит булып тоелмый башлый, мәгънәсе тирәнәя, киңәя, гомумиләшә дигән фикер үткәрә автор. Үгетбригада, уймасын (бусын сәнгать белгечләребез куллана да башлады) һәм башка байтак сүзләрдән тыш, Тәүфикъ Әйди язган, татар колагын иркәли торган "шөрск" (слива), "кирәз" (черешня) дигән сүзләрне дә кабул итеп аласы иде. Шөрек жимешенең исемен һаман да тырыша-тырмаша слива дип язабыз да, әйткәндә ыслива дибез. Көне-төне дигәндәй, гәжит дип сөйләп, язганда газет йә гәзит дип язган шикелле. Шөрек һәм гәжит матур, татарча яңгырый. Ләкин бездә яңа сүзләргә, яисә яңадан кулланылышка кереп китәргә мөмкин булган саф татарча яңгырашлы сүзләргә кайвакыт галимнәребез дә, ә кайчакта аны-моны бик аңлап бетермичә, әмма күңелендә ниндидер амбиция—галилек тузаны йөрткән укучыларыбыз да ташланучан була...

Тәүфикъ Әйди әкренләп үзенең эшчәнлеген—татарны барлауны, ягъни сәяхәтләрен—киңәйтә-җәелдерә бара, бер үк вакытта аның каләменнән мәкаләләр, хикәяләр, романнар, юлъязмалар коела тора. Аның һәр язмасын эзлеклелек, кайнар үгетләү характерлый. Татарга татар энциклопедиясе кирәклеген исбатлаган мәкалә 1977 елда ук язылган. (Сайланма әсәрләр. 11 том, 11—26 б.) Автономиягә генә ия булган республика милләтенә сәвит заманында энциклопедия тәтемәде—рөхсәт булмады. Әле дә хәтердә, бервакыт Бакыдан яшь азәрбайжан галимәсенә: "Бездә татар энциклопедиясе дә, аның институты да юк",—дигәч, бик тә исе китеп, аларда шул институтта биш йөз фәнни хезмәткәр эшләвен шактый һавалы итеп белдергән иде. Ул елларда без, сездә энциклопедия институты юкмыни, дигән сүзләрне ишеткәләп кенә яшәсәк, безнең Тәүфикъ Әйдиебез дөнья буйлап сәяхәт дәвамында башка халыкларның—бигрәк тә заманында татарлардан мәгърифәт юнәлешендә

бик зур ярдәмнәр күргәннәренен—союздаш республика шартларында шактый нык алга китүләрен күреп, бер шатланса, үзебезнең читен хәлләр өчен йөрәге кысылуын, каны бозылуын һәрбер әсәрендә, һәрбер җөмләсендә күрергә мөмкин.

Язучы, галим Тәуфикъ Әйди чын-чынлап югары кимәлдәге иҗатчы иде. Әгәр дә ул дөнья әдәбияты мәдәнияте югарылыгында һәм бер үк вакытта үз халкының үсеш нокталарын ачык билгеләп, хәбәр бирерлек дәрәҗәдә булмаса, аны Мюнхен шәһәрендә Бавария Язучылар оешмасының рәисе Аста Шайб исе китеп, авызын ачып дигәндәй, тынлап торыр идемени? "Әгәр мин эстон язучысы булсам, Шайб ханыма нимес теленә тәрҗемә ителгән дүрт йөз битле "Эстон әдәбияты" белешмәлеген, "Эстон новеллалары"н, эстон шагыйрьләренең махсус тәрҗемәгә дип әзерләнгән җыентыгын, реклама брошюраларын, берничә классик язучының буклетларын бүләк итәр идем",—ди Тәуфикъ Әйди. Безнең милләтпәрвәребезгә элек тә бөек дәүләтләре булган татарның кем икәнлеген нульдән башлап—өр-яңадан аңлатырга туры килә.

Тәуфикъ Әйди әсәрләрен укыйсың да, ул хезмәттәшлек иткән киңлекләрнең колачлыгын күрәсең дә: "Тәуфикъ Әйди үзгәртеп кору жилләрен тизләтүчеләрнең берсе булган икән",—дип хәйран каласың. Үзгәртеп корудан безгә килгән чагыштырмача ирек соңгы еллардагы уңышларны тудырды. Әмма үзгәртеп коруның уңай җилләрен бүгенге көндә кире якка борып җибәрү өчен бездә генә түгел, хәтта бөтен дөнья күләмендә йөгерешеп йөрүчеләрне күрсә, Тәуфикъ Әйдинең йөрәге тагын әрнер, тагын кысылыр иде. Дөньяда капитализм гына җиңеп чыккач, ике төрле системаның каршылыгы бетүгә эчләре пошучыларның ислам динен, ислам динендәге милләтләрне, ислам мәдәниятен мишень итеп алуын иблислек димичә, бүтәнчә ничек тә атап та, аңлатып та булмыйдыр. Ягъни ул көчләрнең үз иблислеген яшерү өчен, дөнья күләм яңа дошман уйлап табу тырышлыгымы бу дип аптырыйсың.

Ләкин, хәтта бер кешенең дә бөтен дөнья халкы белән дусларча мөнәсәбәт коруның зур мөмкинчелекләре хакындагы язмалары ташка басылган—китап булып дөнья күргән инде. Бу—Тәуфикъ Әйди әсәрләре. Аларны кешеләр укыр, халыклар арасында аңлашып яшәүдән дә кадерлерәк нәрсә юклыгын аңлаучылар, иншаллаһ, табылыр.



*Тәуфикъ Әйди казах язучысы Серик Түрәнбәк белән. Алма-Ата. Май, 1998 ел.*

Бер кешенең гаделлек, хаклык өчен, халык ireклеге өчен бик зур өлеш кертә алуын Тәуфикъ Әйдинең гагаузлар иленә барып кылган гамәлләре аша да күрсәтеп була. Гаҗәеп матур исемле Бишалма авылындагы (шагыйрьләр авылы дип тә йөртәләр икән) күптән түгел төзелгән этнографик музейдан һәм Молдованың башкаласы Кишиневтагы Фәннәр академиясендә берничә генә кеше эшләүче гагауз халкы бүлекчәсеннән башка бернинди дәүләтчелек билгеләре булмаган милләт үзенең Гагауз халык республикасын игълан итә! Әле нинди генә каршылыкларны җиңеп! Һәм әлифбаны, һәм мәктәпне, һәм газит-журналны һәм радио-информацияне һәм калган барлык нәрсәне өр-яңадан башлап. Шул эшчәнлекләрнең байтагын күреп торган, үзе дә катнашып ярдәм иткән Тәуфикъ Әйди гагауз халкының ул көннәрдәге геройларын һәм бөтен гагауз халкын да сөекле персонажлар дәрәҗәсендәге югарылыкка күтәреп илһам фантазиясе белән тасвирлый. ("Оҗмах утравы", 177-253 б.)

Автор гагаузлар турындагы язмаларын тәмамлаганда, ул халык өчен шатлык хисләре кичерү белән бергә, үзебезне алардан үрнәк алырга да чакыра: "Әгәр дә алар шулай уңышлы дәвам итсәләр, билләһи, "җиде миллион" дип кабатларга

яраткан татарны узып та китәргә мөмкин, чөнки ахыр чиктә эшне сан түгел, сыйфат хәл итә",—ди.

"Оҗмах утравы" китабының "Гөлчәчәкләр илендә кара болыт" бүлегендә тасвирланган милләттәшебез Фатыйма исемле кызның татар әдәбиятына тартылуы, ерак Туна (Дунай) буенда яшәсә дә, "Казан утлары" журналын яздыртып алуы, андагы сөйләм теле белән әдәби тел арасында шактый зур аермалыклар да булу сәбәпле, ярдәмлек сүзлекләр дә соратып алуы хакында хискә бирелмичә, күзгә яшьне китермичә укуы да мөмкин түгел. Шул бүлекне бу мәкаләгә дә тулысынча күчереп язасы килә башлый... Билгеле, күчереп язып булмый, әмма бу кыз бала гамәле хакында бөтен кешеләргә дә укытасы килә... Аннан, гомумән дә, китапны тулысы белән укытасы килә... Һәм бер "Оҗмах утравы"н гына түгел, "Йөртә безне язмышлар"ны да, "Без батырган сан калыккан" китабын да, "Аh, туган каумем газиз!" исемлесен дә һәм барлык башкаларын да, чөнки ул китапларның һәрберсендә безнең хакта язылган.

Алда әйтеп үтелгән Фатыйма исемле кыз Болгариянең Толбухин каласында яши. Тодор Живков заманында милли азчылыкларны кысу, бетерү, мөселманнарны көчләп паспортка христиан иseme белән яздырту газапларыннан да куркып калмыйча, "Казан утлары"н яздырта да инде ул. Тәүфикъ абыйсыннан сүзлекләр, китаплар да сорап ала. Кияүгә чыгып ире Сәгъдәт белән берсе—Тимер, икенчесе Алтай исемле ике малай үстерә. Болгариягә беренче мәртәбә Тәүфикъ Әйдине шушы яшь гаилә чакыра да инде. Шулай ук гаиләсе белән бергә.

Дунай (Туна) буендагы болгарлар белән Идел буендагы болгарларның кардәшлеге хакында бераз үз халкының тарихы белән кызыксынган Казан татары белә булыр. Җае туры килгәндә бу хакта әйтәбез, язабыз. Тәүфикъ Әйди, Болгариягә баргач, билгеле инде, болгар вәкилләре белән дә очраша. Шулар арасыннан язучы Николай Хайтов белән очрашуы истәлекле була. Тәүфикъ Әйди Дунай буе болгарлары белән Идел буе татарларының кардәшлеге турында бер унбиш минутлык нотык сөйләп ташлагач:

—Кызы-ык,—ди Николай Хайтов.

—Сез боларны белә идегезме?

—Күбесен беренче ишетүем.

Николай Хайтов Татарстанның аерым республика булуын һәм аның кайда урнашканлыгын белмәвен дә таный:

—Менә кардәшле-ек! Боларны элегрәк белсәм, Әрмәнстанга, Грузиягә барганчы, мин, әлбәттә, сезгә килгән булыр идем. Бүтәннәр дә юл салган булырие...

Н. Хайтов чын демократ язучы, мөселман болгарларны, төрекләрне, татарларны нык кысрыклаган елларда, ул аларны яклап, телевидениегә үндүрт серияле фильм сценарием эшләп бирә. Николай Хайтовның 1970 елда, "Казан утлары"ның беренче санында "Хикмәтле хикәяләр" исеме белән ике хикәясе басылган булган икән, чынлап та, бик тә хикмәтле, гаҗәп кызыклы хикәяләр...

Бер карaганда, Т. Әйди рәхәтләнеп йөргән икән кунакларда дигән фикер дә туарга мөмкин кебек. Ләкин алай ук микән? Беренчедән, Т. Әйди юлга чыкканчы фәнни экспедициягә баргандагы шикелле, гамәли һәм гыйльми әзерлек эшләре алып бара, икенчедән, юлда татар китапларын, гәҗит-журналларын тутырган авыр йөген күтәреп, бер дә таныш булмаган җирләргә аяк басулар, кайвакыт каршыларга тиеш булып та, аңлашылмаучылык аркасында беркемнең дә каршы алмавы, шуннан соң, йөген күтәреп, сыгылып килеп, ары-бире йөрүләр, тагын да уйламаганда килеп чыккан башка төрле стресслар дисенме—безнең сәяхәтче, галим язучыбызны берни дә өркетмәгән. Хәер, безнең борынгы бабаларыбыз: "Юл газабы—гүр газабы",—дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул инде.

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга Румыниядән килгән татар кызлары Нәдрәт белән Шөкерананы күреп калган идек, без беренче курста чакта алар бишенчедә иде. Алар укуны тәмамлап киттеләр дә суга төшкәндәй юк булдылар. Шуннан соң Румыниядән безгә килеп укучы татарлар булмады. Алар укып киткән елларда Румыниядә дә Болгариядәге шикелле шаукым чыккан—азчылык милләтләрне кысу, аларның мәктәпләрен, башка төрле уку йортларын бетерү—юкка чыгару, үз телендә сөйләшергә ярамаулар башланган булган икән. Тик ирле-хатынлы Әнвәр (ул шулай ук Казанда укыган) белән Нәдрәт бирешмиләр, бер генә җирдә дә татар китабын бастырып чыгарырга җай булмаса

да, татар әдәбияты фольклоры мәсьәләләре белән шөгыльләнәләр. Менә шул ике галим һәм Румыниядә яшәгән татар халкы тормышы белән безнең Тәүфикъ Әйдиебез барып таныша һәм алар турында яза да инде. "Дунай буендагы кардәшләр", "Оҗмах утравы" китабының 122-176 битләрен алып тора. Бер-берсе белән узыша-узыша эшләүче ике галимне—Әнвәр белән Нәдрәт Мәхмүтләрне автор яратып, хәтта ки шактый персонажлаштырып бирә, ягъни һәр ике галимнең аңа гына хас табигатьхолык үзенчәлекләрен ассызыклый, гомумән дә, Тәүфикъ Әйдинең иҗат фантазиясе публицистикасында да уйнап тора: бу жанрда "коры" телгә ул бик сирәк күчә. Гадәттә, авторның һәрбер публицистик, яисә юлъязма әсәрләрендә дә геройлар "матурланган"—җете, җанлы, кабарынкы—һәрберсен аерым танырлык итеп сурәтләнгән. Ул геройларны исәпли башласаң, ничә йөзләргә тула икән? Оноре де Бальзак француз тормышыннан образлар галереясен тудырган кебек, безнең Тәүфикъ Әйдиебез татар кешесе белергә тиешле күпме күренекле вәкилләребез һәм үзләренең барлыклары белән генә дә татар милләтенең яшәвен раслап торучыларыбыз хакында язып, бик тә үзенчәлекле геройлар галереясе тудырды. Тәүфикъ Әйди шуларның барысын да күңел кинлегенә сыйдырган. Аларның барысын да зиһен капкачы астына сыйдырып та бетереп булмыйдыр, бәлки.

Кайнар үгетче, ялкынлы өндәүче Тәүфикъ Әйди кайчакта үзенең позициясенең кайсы якта икәнлеген ачып та салмый. Бу бигрәк тә әдәби әсәрләрендә шулай. Биредә автор тормыш чоңгылларының кайнавына читтән караш ташлагандай яза. "Елан угы"нда, эсседә какланып, суыгында күгәреп көтү көтүчеләр кызганыч; Бохара дәүләтен саклап каласы иде, бәйсез итәсе иде дип көрәшүчеләрнең җиңелүе кызганыч; Фрунзе турында да иптәш Фрунзе дип сөйләнелә, игелек эшлибез—кан кадәшләребезгә якты көн китерешәбез дип шунда эшлеклелек күрсәтеп йөрүче безнең милләттәшләр шулай ук кызганыч... Ә чынында кемнең кем икәнлеген ачыклау күбрәк укучының үз ихтыярына куела, ягъни әсәрнең юл араларын укый белү мөмкинлеге дә аңа (укучыга) бирелә. Тәүфикъ Әйди укучысының шактый әзерлекле булуы сорала.

Талантлы язучыбызның публицистикасында зур тәэсир көченә ия, күзгә бәрелеп торган ике зур алым бар. Ул юлъязмаларында, әдәби әсәрләрендәгечә үк, геройларның эчке дөньясын ачу өчен, үткен, җете-җанлы диалоглардан гаять оста файдалана. Нәкъ менә шул кызыклы диалоглар укучыны "котыртып", әсәрнең бер битеннән икенчесенә әйди, чакыра, өнди, ялыктырмый укыта да инде! Икенче үзенчәлек: әсәрдәге бай фактик материал, сирәк очрый торган кыйммәтле информация. Тәүфикъ Әйдинең юлъязмаларын нәкъ менә шул сыйфатлары өчен, иң кызыклы сюжетлы әсәрләрне укыган кебек мавыгып, туктап торырга кирәк булганда да, менә тагын бер генә битне укыйм да, тагын берне генә дип... туктала алмый укыйсың. Һәм ул әсәрләрдән эстетик ләззәт кенә түгел, ә күпме гамь, күпме кичереш, күпме акыл көче, күпме мәгънә, күпме кителмәгән фәнни-информатик мәгълүмат, күпме милли аң, милли дәрәҗәлелек, милли аянычлылык та, милли үсеш тә аласың. Бәһаләп бетереп булмый! Аның әсәрләренә торып-торып та, алдагы буыннар да югары бәһа бирер әле. Хәзерге вакытта, татарны татар итәр өчен арабыздан вакытсыз киткән бу авторның әсәрләрен күбрәк укытасы килә. Ул бигрәк тә мәктәп балаларының милли аңын шәкелләштерүдә (формалаштыруда) җитди уңышларга китерер иде...

Тәүфикъ Әйди кызыксынучан язучы дисәк, билгеле, бу гына бик аз булыр. Аның Морат Аҗи фикер-фантазияләрен күтәреп алуы да бер дә гаҗәп түгел. Башларына кирегә әйләндерелгән "тарих гыйлеме" көчләп тутырылган адәм балаларының башкача фикерне дә ишетәсе килүе табигый хәлдер. Башкачарак фикер әйтүчегә, бәлки, Морат Аҗины да кертергә мөмкиндер. Безнең милли байрагыбыз булып хисапланырга лаек тарихчы галимебез Миркасыйм Госманов: "Әлбәттә, тарих дигән гыйлемнең күп очракта ярты ялган белән ярты дөреслек дигән ике өлештән торуы мәгълүм нәрсә",—ди. Морат Аҗи язмаларында да яртысы дөреслек булган очракта бик кызыклы нәрсәләр килеп чыга бит әле. Без әллә ничаклы халык җырларыбызда "кара кашлар, кара күзләр" дип җырласак, байтагында еш кына "аһ, бәгърем, зәңгәр күз" дип тә өзеләбез түгелме?! Ярый, болары бәлки шаяру гына да булсын ди. Ә менә хәзер славян булып саналып йөрүче, шул ук вакытта, нишләптер, хохол кушаматы алган украиннарның кара күзләре, кара кашлары, урыслардан үзгә җырлары, биюләре, киенүләре белән галимнәрне кызыксындырмый

мөмкин түгелдер. "Киев русе"нең асылын ачарга тырышуы белән Морат Аҗи хикәяләү-язмалары игътибарга лаек. Тәүфикъ Әйди моны анык тойган, билгеле.

Шулай инде, тою-сизү зур әһәмияткә ия. Ләкин Тәүфикъ Әйдигә болардан тыш, иң беренче чиратта, ышандыргыч дәлилләр белән эш итү хас. Бу унайдан язучының үзенең оппонентлары белән сөйләшү-диалогларын тәкъдим итәр идек. Андый сөйләшүләрнең дусларчасы да, бәхәсләшү рәвешендәгесе дә, нык каршы тору шәкелендәгесе дә авторның һәр унбер китабында тулып ята.

Үз халкыңны ышандыру, үз халкыңны "син бер халыктан да ким-хур түгел, башкаларда башка булса, бездә бүтән әйбәт сыйфатлар бар" дип рухландыру ул бик авыр эш—адәм баласы үзенең фактик урынын гына белеп тоярга гадәтләнгән. Ә татарны үткәне белән горурландыру өчен сандугачтай сайрап күрсәтсәң дә бик газаплы, читен эш. Намуслы, фәнни тарих урынына бөтен дөнья күләмендә диярлек ясалма, ялган тарих белән даим-даим җинеп, иблистәй тантана итүләрен күреп тору йөрәкне әрнетә. Карагыз инде, ә—цивилизациянең зур бер өлешен дөньяга бүләк иткән төркиләрне бөтенләй күрмәгәнгә, белмәгәнгә салышып яшәп ятуларын?! Безнең үзебезнең артык дөреслек белән бару галәмәтенең бер нәтиҗәсе дә бит әле бу. Фантазиябезне тамырдан кисәбез... Шул фантазияне элек гөрҗиләрдә, молдаваннарда, әрмәннәрдә күреп, шакката идек без, янәсе, ничек инде алай?... Шаккатып, авыз күтәреп калучы тагын да без булдык. Шуңа да әйтәсе килә: безнең халыкның рухын күтәрү, милли аңын үстерү өчен, бер түгел, мең дә бер Тәүфикъ Әйдиләребез булса да, бик тәгаен генә булыр иде әле! Үзенең сәяхәтләрендә—элеккеге СССР җирендәме, яисә башка чит илләрдәме, кайда гына булмасын—Тәүфикъ Әйди татар милләтен барлау, аңа карата башка милләтләрдә ихтирам, ярату уятырга тырышып йөрүче булды. Ул бу өлкәдә киң күләмдә эш алып баручыларның беренчесе иде. Кая гына барса да, кайда гына сөйләшсә дә, аның уенда, телендә бер генә нәрсә: без үзебезнең зур халык вәкилләре икәнлегебезне тоеп, белеп яшибезме, үзебезне үзебез ярата беләбезме? Сез—башка халыклар—Аурупада иң беренче булып корыч эретүче, үзәктән җылытудан файдаланучы мәгърифәтле татар халкын беләсезме? Җилекләренә төшә тегеләрнең...

Т. Әйди хезмәтләреннән бик күп шәхесләребез хакында да тулы мәгълүмат алып була, чөнки ул алар турында җентекләп өйрәнгән, ирәймичә башкаларны укыган, аннан соң, ул бөекләребезнең күбесен үзе барып күргән, шуннан соң гына, үз нәтиҗәләрен чыгарып язган. Ул безнең күбебезгә таныш өлкә—әдәбият-мәдәният өлкәсендә—эшләүчеләр хакында гына язмаган, дөньяның төрле кыйтгасында яшәп, тормышның, фәннең төрле-төрле юнәлешләрендә казганган татар бөекләре хакында яза. Мәсәлән, Шәүкәт Шиһабетдин улы Ибраһимов турында татарның киң массасы беләдер дип әйтеп булмыйдыр, мөгаен. Ә ул исә, СССР чорында, радиацион физика буенча иң күренекле галимнәрнең берсе булган икән. Атом-төш реакциясе казаннарының ныклыгы Шәүкәт Ибраһимовның теоретик һәм практик эшчәнлегенә дә барып тоташкан булган икән... Шундый дәрәҗәдәге галимнең 1923 елда Казанда тууын, Завод дигән урамда уйнап үсүен, Исмәгыйль Гаспринский исемендәге 12 мәктәптә укуын әйтеп үтәсе килә... Тәүфикъ Әйдинең "Без батырган саен калыккан" исемле китабы татар бөекләрен сурәтләүгә бигрәк тә бай. "Күк механигы" исемен алган галим-астроном Шәфика Шәрәф—аңлашыла ки, атаклы Шәрәфләр нәселеннән. Галимә белән күрешеп сөйләшкән Тәүфикъ Әйди аның киң карашлы, эрудицияле, яшәешнең бик күп өлкәләре белән кызыксынучы һәм белүче икәнлегенә гаҗәпләнеп сөенә. Иң мөһиме, Шәфика Шәрәф тә, югарыда сурәтләнгән Шәүкәт Ибраһимов та, туган җирдән ерактарак яшәсәләр дә, чын татарлыкларын һич кенә дә җуймыйлар. Һәрхәлдә, үзе барып күргән, әңгәмәләшкән бу геройлар хакында авторның тәэсири фикере шундый. Мондый уңай тәэсирләрне Тәүфикъ Әйди, Мәскәү галимнәре әйткәнчә, механика фәнен басып алган, берничә буын Нигъмәтуллиннар белән аралашудан да, Әстерханда туып-үсеп, Бакуда СССРның халык артисткасы исемен алган Мәрзия Даутованы яхшы белгән кешеләрнең аның турында сөйләүләреннән дә ала (Азәрбайҗанда, Бакуда яшәгән татарлар өчен таяныч, ярдәмче булып торган артистка ханым бу). Тәүфикъ Әйди әсәрләрендә сурәтләнгән Галия Измайлова, Әхмәт Кытаев, Латыйф Хәмиди, Мөслим һәм Ришат Абдуллиннар һәм тагын башка күпләр безнең горурлыгыбыз булып торырга тиешле, билгеле. Ул кешеләрнең даннарын татар файдасына да борып җибәрү безнең үзебездән дә тора. Кайбер халыклар шундый мөмкинчелектән ничек кенә файдаланалар! Ул

халыкларның безнең тирәдә үк булганнарын әйтеп үтеп тә була: гөрҗиләр, әрмәннәр, яһүдләр, төрекләр дә ул җәһәттән бигүк төшеп калганнардан түгел бугай. Төркиләрдән без, татарлар, бер-беренә елышу ягыннан бигрәк тә мактаулы урында түгел шикелле. Электән шулай булган ахры.

Дөньяда биш туган—биш борадәр (урыска "брат" булып кергән)—була торып, тирә-юньдә дошманнар күп дип бирешәләрме? Берләшә алмасаң, черкидән дә җиңелерсең! Ә Кубрат ханның биш угылы бер йодрыкка оеша алмаганнар! Бармаклар—туганнар—бишесе биш җиргә сеңгән. Киткән җирләре дә әле аның яна җирләр түгел, әтиләре аларга тәгаенләгән биләмәләре. Яна җиргә бару—кеше җиренә бару булыр иде. Ә кеше җирен басып, сугышып алырга кирәк. Дөньяда ул вакытта инде буш җирләр юк. Һәрбер җирдә катлы-катлы халыклар яши. Яна килгән җан иясенә хәтта кечкенә генә урам маэмае да үз җирен тәк кенә, сугышмыйча гына бирми. Кубрат хан угыллары килеп утырган җирләрдә шул вакытта каты сугышлар булган дигән тарихи дәлилләр дә, шул турыда сөйләүче тарихчы да юк бугай. Димәк, Кубрат хан заманында Бөек Болгарстанның биләмәләре чынында аның варислары килеп урнашкан чикләргә кадәр булган.

Тәүфикъ Әйдигә Урта Азия, Кытай эчендә калган Көнчыгыш Уйгырстан турында язу да җиңел бирелә, чөнки ул аларның телен белә, казах, үзбәк, уйгырларның китапларын асыл нөсхәсендә укый, аларның холык-фигыле ана якын, аңлаешлы. Билгеле, иң беренче итеп язучы үзенең игътибарын анда яшәгән үзебезнең милләттәшләребезгә юнәлтә. Тик бу кыска язмада Төркестан җирлегеннән алып Тәүфикъ Әйди тудырган геройлар палитрасын биредә җәеп күрсәтә алмавыбызны әйтеп үтәргә туры килә.

Тынгысыз язучыбыз әсәрләреннән төрек кардәшләребез хакында да күп мәгълүмат алып була. Бүгенге көндә төрек теле безгә якыная төшсә дә, күбебез аны белеп бетерә алмас инде, белгән очракта да, шагыйрьләре турында гына да берәр нәрсә ачыкларга теләсәң дә, йөзләрчә төрле шәкелдә чыккан антологияләрен актарырга туры килер иде. Ә бу—мөмкин эш түгел. Әлеге очракта да безнең язучыбыз китапларында байтак материаллар бар.

Авторның Балтыйк буе җөмһүриятләре хакындагы язмалары да кызыклыгы белән аерылып тора. Укы гына, әллә никадәр мәгълүмат, эстетик ләззәт ал! Аз санлы латыш, эстон, литва халыклары милли гәҗит-журналларын СССР заманында бер үк исемдәгесен гаилә саен бер генә данә түгел, икешәрне яздырып алган өчен дә менә хәзер үз дәүләтләрен торгызып яталар дисәк, ялгыш ук булмас. Чөнки алар бүтән гамәлләрендә дә нәкъ менә шул милли гәҗит-журналларына карата булган мөнәсәбәт кебек эш иттеләр. Әйе, күп сөйләшми генә үзләре өчен кирәкле эшләр башкардылар!

Тәүфикъ Әйди иҗат юлының башында ук бу зур эшләргә үзенең көче җитәсенә, максатына ирешәсенә ышанып, белеп, әзерләнеп керешкән дигән идек. Анарда хыял белән тормышчанлык икесе бергә органик рәвештә үрелгән. Әйе шул, туган халкың өчен эчендә янган утың таудай булса, ул сине нинди генә раштуа салкыннарында да суытмый, җылытып тора. Җылытып кына да калмый шул—яна-яна бөртегенә хәтле яндырып та бетерә! Гөлт итте дә, янды Тәүфикъ Әйди... Янудан яктылык булып әсәрләре калды, ләкин кызганыч ки: күпмесе, менә-менә каләмнән төшәм дигәндә, язучының тормышы белән бергә өзелгәндер, кәгазьгә төшми дә калгандыр...

Әгәр дә татар халкы алга таба да үзен зур халык итеп күрсәтәсе килә икән, Тәүфикъ Әйдине онытмау, хөрмәтләү, кадерләү белән бергә, аның турында башкаларның да исләренә төшергәләп тору хәерле булыр иде. Ул булган җирләргә, халыкларга моны җиткереп тору безнең үзебезгә дә отышлы булачак. Әлеге эшләр киләчәктә "Тәүфикъ Әйди укулары" шәкелендә дә булырга мөмкиндер. Язучыбыз булган җирләрнең берәр генә булса да вәкилен шундый мәҗлесләргә чакыру, күңеле "чуарлыктан" онытырга гына торган халыкның зиһенен безнең тарафларга да китерүгә бер сәбәп тә булыр иде.

Язманы Сибгат Хәкимнең "беренчеләр өзә үзәкне" дигән шигъри сүзен искә төшереп тәмамлыйсы килә. Бөтен дөнья татарларын барлау эшен Тәүфикъ Әйди башлады. Әйе, ул беренче иде... "Татар өчен әле күпме эшләр иде" дисең дә, йөрәк кысыла...

*Хәмит Ярминең тууына 100 ел*

**Фатих Урманче**

# ЯРМИ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ДӘВАМ ИТӘ

Татар халык иҗатына да, төрки-татар фольклорына да турыдан-туры мөнәсәбәте булган аерым сюжетларны, мотивларны, образ-персонажларның һәм әдәби алымнарның кайбер төсмерләрен ташка яки кәгазьгә теркәп калдыру бик ерактан—VI гасырлардан башлана. Ул чорларда халыкара, шул исәптән татар мифологиясенең һәм фольклорының иң актив һәм тирән мәгънәле персонажларыннан булган, төрки-татар кабиләләренең киң мәгълүм *тотемы* Бүре—Ак бүре образы белән нисбәтле мөһим сюжетлар Кытай язма чыганакларында теркәлеп, соңрак алар байтак язма чыганакларда, фәнни хезмәтләрдә урын алалар. VI—VIII гасырлардан безнең көннәргә хәтле килеп җиткән Орхон—Енисей язмаларында төрки-татар фольклорының һәм мифологиясенең илаһи персонажларыннан Югары Күк Алласы *Тәңре*, Җир—Су дөньясының хөкемдары изге *Җир—Су* (Ыдук Йир—Суб) һәм уңдырыш алиһәсе *Умай*, төрки-татар дастаннарының төзелеше-композициясенә бик якын торган сюжет-мотивлар, әдәби алымнар ярыйсы ук киң чагылыш таба. Шул ук рухтагы тагын да байрак мәгълүматлар Баласагуни Йосыф Хас Хаҗиб (1016—1021 еллар арасында туган—вафаты 1070 елдан соңрак) белән Мәхмүд Кашгариның (XI йөз) мәгълүм китапларында тупланган.



922 елда Идел—Чулман Болгарстаны рәсми рәвештә Ислам динен дәүләт дине дип игълан итә. Шуннан башлап XX гасырның 30 елларына хәтле татар язма әдәбияты да, фольклоры да, башлыча, Ислам тәгълиматы һәм мифологиясе йогынтысында үсә.

X һәм XII йөзләрдә Борынгы Болгарда Әхмәд ибне Фазлан (X йөз) белән әл-Гарнати (1080—1169), XIII йөздә Европа сәяхәтче-галиме Рубрук (1215 яки 1220 тирәсе — 1293), XVI—XVIII йөзләрдә шулай ук Көнбатыш Европа һәм урыс галимнәре татар халкының тормышы, гореф-гадәтләре һәм йолалары, әкиятләре, бәетләре, җырлары, мәкаль-әйтемнәре һәм табышмаклары буенча бай конкрет материаллар туплыйлар. Шулар арасында академик В.В.Радловның (1837—1918) Себер татарлары фольклорына багышланган махсус зур күләмле томын, венгр галиме Габор Балинтның (1844—1913) керәшен татарлары иҗаты әсәрләрен туплаган саллы китабын, фин галиме Һейкки Паасонен (1865—1919) җыентыкларын күрсәтеп үтәргә мөмкин.

Татар фольклористикасының фән буларак тулысынча оешуы бөек мәгърифәтче, энциклопедист-галим Каюм Насыйри (1825—1902) эшчәнлеге белән бәйләнгән. XX гасыр башына татар фольклор фәне шактый бай тәҗрибә туплаган, гуманитар фәннәрнең тулысынча формалашкан бик тә мөһим бер юнәлеше буларак килеп җитә. Табигый, бу фәннең алга таба үсешендә бөек әдипләр Габдулла Тукай (1886—1913), Галимҗан Ибраһимов (1887—1938), Фатих Әмирхан (1886—1926), шул чорларда ук киң танылган галимнәр: әдәбиятчы һәм фольклорчы-теоретик Гали Рәхим (1892—1943), Хуҗа Бәдигый (1887—1940), Фазыл Туйкин (1887—1938) һәм соңыннан олы галим, шагыйрь һәм драматург буларак танылган Нәкый Исәнбәт (1899—1992) исемнәре кушылып, фольклор фәне нык адымнар белән алга китә.

Югарыда кыскартылып китерелгән җитди мәгълүматларның барысы да татар халкының танылган һәм күренекле галиме, татар фольклористикасы тарихында

беренче фән докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының Тукай исемендәге премия лауреаты, кеше буларак бик тә мөлаем, мәрхәмәтле, һәрвакыт киң күңелле зыялы Хәмит Ярминең (Габделхәмит Хөснетдин улы Ярмөхәммәтовның) (1904–1981) фундаменталь фәнни тикшеренүләреннән һәм ул төзегән күпсанлы фольклор җыентыкларының саллы-саллы кереш мәкаләләреннән, комментарий-искәрмәләреннән алынды. Шулар үзләре генә дә Хәмит Ярминең ни дәрәҗәдә киң колачлы галим булуын бик тә ачык күрсәтә булса кирәк.

Мәгълүм ки, XX гасырның утызынчы еллары ахырына хәтле татар фольклор әсәрләрен халыктан җыю, бастырып чыгарып, яңадан халыкка кайтарып бирү һәм фәнни нигездә өйрәнү башлыча *стихиячел юнәлештә алып барыла*. Чөнки әлеге эшләрне башкару өчен махсус оештырылган фәнни үзәк булмый. Ниһаять, 1939 елда Татар тел һәм әдәбият фәнни тикшеренү институты оештырыла. Бу Институтның оештыручыларыннан берсе булган Хәмит Ярми шул ук 1939 елда институт составында *Фольклор секторы* да төзи. Шушы елларда фольклорчы-галим буларак формалашкан Хәмит Ярми, баштан ук әлеге Секторның төп эш юнәлешләрен, бик хаклы рәвештә, түбәндәгечә билгели: халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен махсус экспедицияләр оештыру; моңа хәтле басылып чыккан җыентыкларда, китапханәләрдә, архивларда сакланган, бигрәк тә регуляр оештырылып килгән экспедицияләрдә җыелган фольклор текстларын басмага әзерләү һәм татар халык иҗаты белән бәйле проблемаларны фәнни өйрәнү. Әнә шул юнәлешләрнең беренчесен тормышка ашыру буенча 1940 елда ук Сектор мөдире Х.Ярми җитәкчелегендә Себергә—академик В.В.Радлов эзләреннән махсус экспедиция оештырыла. Бу беренче экспедициянең иң җитди нәтиҗәләреннән берсе дип мәшһүр "Идегәй" дастанының аерым вариантларын язып алуны ассызыклап әйтеп үтәргә кирәк... 1945–1955 елларда Сектор оештырган фольклор экспедицияләре Татарстанның барлык районнарында йөреп, искиткеч бай материал туплый. Шуннан соң инде экспедицияләр татарлар күпләп яши торган күрше Киров, Пенза, Рязань һ.б. өлкәләргә, Мари Иле, Чуаш, Мордва, Удмурт республикаларында—җәмгысы 13 өлкәдә һәм 4 республикада булып, тагын да баерак, үзенчәлеклерәк материаллар туплый.

Татарстан һәм күрше өлкә-республикалардагы татар авылларын тулысынча йөреп чыкканнан соң, Хәмит Ярми, табигый, Сектор галимнәренең төп игътибарын Татарстаннан ераграк төбәкләрдә яшәүче татарлар иҗатын өйрәнүгә юнәлтә. Галимнең бу эше әйтеп бетергесез мөһим һәм перспективалы булып чыга. Чөнки татар халкының дүрттән өч өлеше Татарстаннан читтә яши. Академик В.В.Радловтан соң, бер гасыр вакыт узгач татар фольклорчылары алдында халык иҗаты әсәрләрен җыю өчен бөтенләй диярлек кутәрелмәгән һәм бик тә уңдырышлы "чирәм" ачыла: 1967 елдан башлап Хәмит Ярми җитәкчелегендә киң Себер якларына фольклор экспедицияләре оештырылып, ифрат та бай һәм бик тә үзенчәлекле әсәрләр язып алына. Хәтта әйтергә мөмкин, күпсанлы экспедицияләр нәтиҗәсендә татар фольклорчыларының татар халык иҗаты, аның байлыгы, жанр төрләре, яшәү шартлары турындагы карашлары принципиаль үзгәрешләр кичерә: татар халык эпосы (Себер татарлары), бәетләр, туй-йола җырлары (Себер татарлары, мишәр-татарлар, керәшеннәр), тарихи җырлар (Себер һәм мишәр-татарлар) кебек фундаменталь фольклор төрләре җыелып, әлеге проблемаларны яңа фәнни югарылыкта күтәрү мөмкинлеге туа.

Тулаем алганда, Хәмит Ярми 1940 елдан 1972 елга хәтле, ягъни 32 ел дәвамында татар халык иҗаты секторы оештырган күпсанлы экспедицияләрнең җитәкчесе буларак, бик зур тәҗрибә туплый. Хәмит Ярми оештырган экспедицияләрдә 1963 елдан 1970 елга хәтле шушы юллар авторына да катнашырга туры килде. Ул елларда экспедицияләргә әзерлек гадәттә 2–3 ай элек башланып, экспедиция үзе зур бер бәйрәм кебек оештырыла иде. Ел саен экспедицияләрдә 10–12 кеше катнашып, июнь–июль айларында, бер ай буена йөреп, халыкның көндәлек тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен, поэтик әсәрләрен җыеп, авыллар тормышында да актив катнашып, төрле лекция-докладлар, концертлар оештырып, экспедиция вәкилләре булган һәрбер авыл халкын озак йокыдан уятып һәм хәтта тирә-як авылларны шаулатып китә торган идек. Һәм әлеге экспедицияләрнең шулай матур һәм нәтиҗәле узуының төп сәбәпләреннән берсе—экспедиция җитәкчесенең кешеләр—әби-бабайлар, урта буын һәм яшьләр белән сөйләшә һәм сөйләштерә белүче, һәрвакыт "кесәсендә тылсымлы тел ачкычы йөртүче", гомумән—кешелекле, мәрхәмәтле, җор һәм үткен телле Хәмит абый Ярми булуы иде.

Тик ул 60–70 еллардагы экспедицияләр бихисап авылларда йөреп сансыз күп,

нигездә яңа, әлегә хәтле бернинди кәгазьгә теркәлмәгән, бернинди җыентыкта урын алмаган әсәрләр язып алып кайту белән генә тукталып калмый иде. Казанга кайткач, гадәттә иң авыр, "күңелсез" эш—ул да булса, тәфсилле исәп-хисап-отчет язу башлана иде. Тик сектор галимнәре бу ялыктыргыч эшкә дә ямь өсти беләләр иде. Мәсәлән, экспедиция нәтиҗәләре турында төрле газета-журналларда махсус мәкаләләр, экспедиция материалларыннан иң матур әсәрләр бастырып чыгарыла, шулай ук бик үзенчәлекле һәм тулысынча яңача яңгыраган радио һәм телетапшырулар оештырыла; халык арасында яшәгән аеруча оста җырчы, бәетче, дастанчыларны чакырып, махсус очрашулар уздырыла иде. Бәхеткә каршы, ул елларда радио һәм телевидение гади халык вәкилләре өчен хәзергечә ябык түгел иде әле.

30 елдан артык татар халык иҗаты секторын җитәкләгән Хәмит абый Ярминең икенче һәм өченче эш юнәлешләре—тупланган материаллардан киң катлам укучылар, мәктәпләр, студентлар өчен фольклор җыентыклары чыгару булды. Биредә без ул әзерләп чыгарган дистәләгән китапларның барысына да тукталуны максат итеп куя алмыйбыз. Тик фәнни яктан иң мөһимнәре турында гына берничә сүз әйтеп китәбез. Шул ук вакытта мәсьәләнең тагын бер мөһим ягын истән чыгармаска кирәк: җитди фольклор җыентыгы чыгару өчен, барыннан да элек, конкрет материалны фәнни яктан тирәнтен өйрәнеп чыгу таләп ителә. Димәк, без биредә Хәмит Ярминең халык иҗатын фәнни өйрәнү һәм конкрет җыентыклар чыгару мәсьәләсен бергә, бер бәйләмдә яктыртып барырга тиеш булабыз.

Киң колачлы галим һәм чын мәгънәсендә оптимист зыялы буларак, эшнең бу юнәлешен дә Хәмит Ярми бик тирәннән һәм зурдан башлый. Дөресен әйткәндә, академик В. В. Радлов, Габор Балинт, Хейкки Паасонен хезмәтләреннән соң 1940 елларга хәтле татар фольклорыннан зур күләмле һәм чын мәгънәсендәге фәнни җыентык-антология дөнья күргәне юк иде. 1940–1941 елларда Хәмит Ярми, үзенең халык алдында зур абруй казанып өлгергән бер төркем каләмдәшләре белән "Татар халык иҗаты" дип аталган 40 табак күләмендә антология төзеп, дөньяга чыгарырга әзерли.

Мәгълүм ки, 1940 елда "Совет әдәбияты" (хәзер "Казан утлары") журналында татар халкының олы галиме Нәкый Исәнбәт татар халык эпосының йөзек кашы булган "Идегәй" дастанының җыелма версиясен бастырып чыгара. Безнең сектор галимнәре дә бу изге эштән читтә калмый: дастанны аерым китап итеп чыгару өчен Х.Ярми җитәкчелегендә махсус комиссия төзелә: аның составына Н.Исәнбәт һәм Ш.Маннур кертелә.

Кызганычка каршы, Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле басмага тулысынча әзерләнгән әлеге мөһим китапларның берсе дә дөнья күрми кала...

Әлбәттә, шуның белән Хәмит Ярминең бу юнәлештәге җитди эшчәнлеге туктап калган икән дип уйлау хата булыр иде. Чөнки әле аталган антологияне төзү барышында Хәмит Ярми чын мәгънәсендәге фәнни җыентыклар әзерләү тәҗрибәсе туплый. Һәм 1940 еллар уртасында ук Х.Ярми белән Г.Бәширов икетомлык "Татар халык әкиятләре"нең беренче китабын басмага әзерләп бетерәләр, 1946 елда ул нәшер ителә. 1956 елда шул икетомлыкның икенче китабы дөнья күрә. Әлеге басмалар татар фольклористикасында зур әһәмияткә ия принципиаль яңа төр җыентыклар булып, үзләренең фәнни әһәмиятләрен әле бүген дә югалтканнары юк! Аларның яңалыгы түбәндәгеләр белән аңлатыла: җыентыкларның икесендә дә Хәмит абый тарафыннан язылган, татар фольклор фәнендә әкиятләргә багышланган зур күләмле беренче махсус фәнни мәкалә урын алды. Анда татар халык әкиятләрен халыктан җыю, бастырып чыгару һәм фәнни өйрәнү тарихы, әкиятләрне аерым жанр төрләренә бүлү—классификацияләү, аларның проблематикасы, әдәби-эстетик үзенчәлекләре кебек мәсьәләләр киң яктыртылган иде.

Бөек Ватан сугышыннан соң берничә ел узгач Хәмит Ярми югарыда күрсәтелгән антологиягә янадан әйләнеп кайта. 1951 елда "Татар халык иҗаты" дигән 40 табаклык том басылып чыга. Һәм бу адым—татар фольклористикасында һичшиксез зур, әле безнең көннәрдә дә әһәмиятен югалтмаган вакыйга булды дип бәяләнергә тиеш. Чөнки, беренчедән, китапта Хәмит Ярминең тулаем татар халык иҗатына багышланган зур күләмле монографик мәкаләсе урын алган. Аның беренче өлеше татар халык иҗатын өйрәнү—фольклористика тарихына багышланган. Анда автор шушы мәсьәләгә караган, дөресен әйткәндә, шул елларга хәтле беркемнең дә, хәтта гомумән күп булмаган фольклорчыларның да игътибарын җәлеп итмәгән бик күп чыганакларны: урыс, татар, Европа, Шәрекъ галимнәре, сәяхәтче, тарихчы, этнографларның

хезмәтләрендәге татар фольклорына кагылышлы өлешләрен "казып чыгара", К.Насыйри, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Х.Бәдигый, Г.Толымбайларнын бу өлкәдәге хезмәтләренә тиешле бәясен биреп бара. Аннан соң Кереш мәкалә авторы татар фольклорынын төп жанрларының һәркайсына: әкият, бәет, жыр, мәкаль-әйтемнәр, табышмакларга, Совет чоры фольклоры кебек ифрат та катлаулы, моңа хәтле рәтләп өйрәнелмәгән проблемага тәфсилле фәнни анализ ясый. Ә жыентыкнын төп өлешендә инде әле генә санап үтелгән жанр төрләренең иң матур үрнәкләре урын алган. Фәнни фольклор жыентыгына, аеруча зур күләмле антологиягә куела торган мөһим таләпләрнең тагын берсе—аның тиешле югарылыкта эшләнгән фәнни аппараты: искәрмә-комментарийлары, фольклорчыларнын үз телендә әйтсәк, һәрбер әсәрнең паспорты булырга—аның кайчан, кайда, кемнән (туган елы, һөнәре дә күрсәтелеп), кем тарафыннан, нинди шартларда язып алынуы, ничәнче кат басылуы, элегрәк нинди чыганакларда очравы турында мөмкин кадәр тулы һәм киң мәгълүмат бирелергә тиеш. 1951 елда дөнья күргән "Татар халык ижаты" антологиясе менә бу яктан да әле хәзер дә фольклор жыентыклары төзү өчен үрнәк булып торырлык.

Әлеге антология шул еллар вакытлы матбугатында югары бәя алып, бик тиз арада халыкка таралып бетә: аны икенче тапкыр бастырып чыгару ихтыяжы туа. 1954 елда китапның икенче басмасы да дөнья күрә... Мәсьәләнең иң кыйммәтле ягы шунда булды ки, менә инде ярты гасырдан артык Хәмит Ярми (баш редактор), Г.Бәширов (1901–1999), Х.Госман (1908–1992) һәм А.Шамов (1901–1990) әзерләп чыгарган "Татар халык ижаты" антологиясе күпсанлы милли мәктәпләр, педучилищелар, югары уку йортлары, хәзер инде төрле колледж-гимназияләр өчен дә *бердәнбер хрестоматия дә, дәреслек тә ролен бик уңышлы үтәп килде...*

Халык ижаты әсәрләреннән торган махсус һәм саллы жыентыклар чыгаруны Хәмит Ярми алга таба да эзлекле һәм нәтиҗәле дәвам итә. Шундыйларнын иң житдиләреннән берсе—1960 елда дөнья күргән "Бәетләр" китабы. Хәмит Ярми аны да зур тырышлык белән һәм принципиаль фәнни таләпләр нигезендә әзерли. Татар халык бәетләре буенча моңа кадәр дә аерым жыентыклар һәм мәкаләләр басылып чыккан булса да, шулар арасында Хәмит Ярми хезмәте абруйлы бер урын алып тора. Барыннан да элек, китапның кереш мәкаләсе махсус игътибарга лаек. Анда галим, гадәттәгечә жентекләп, татар халык бәетләрен жыю, фәнни өйрәнү һәм бастырып чыгару; бәетләрнең милли тарих белән бәйләнеше; аларның Болгар чорында ук барлыкка килеп, Казан ханлыгы чорында тәмам формалашуы; XVII–XX йөзләрдәге һәм Совет чорындагы үсеш тарихы; бәетләрнең проблематикасы; жанр үзенчәлекләре һәм поэтикасының барысын да тирән өйрәнеп, үзенең әле хәзер дә житди әһәмиятен югалтмаган фәнни күзәтүләрен бәян итә. Табигый, бу китапның да фәнни аппараты—искәрмә һәм аңлатмалары зур әһәмияткә ия.

Үзенең күп гомерен татар халык ижаты әсәрләрен даими жыю, бастыру һәм фәнни өйрәнүгә багышлаган Хәмит Ярминең фәнни яктан иң мөһим хезмәте—"Татар халкының поэтик ижаты" дип аталган зур күләмле монографиясе 1967 елда басылып чыга. Һичшиксез, бу монография шул еллардагы татар фольклористикасының *иң зур фәнни казанышы булды.* Чөнки моңа кадәр татар фольклоры проблемаларын андагы кадәр киң һәм тирән иңләгән бер генә фәнни хезмәт тә булганы юк иде. Монографиянең житди әһәмияте шунда иде ки, анда шул еллар татар фольклористикасының иң мөһим, актуаль һәм катлаулы проблемалары һәммәсе дә тиешле дәрәжәдә киң һәм тирән яктыртылган иде. Китапның беренче һәм иң зур бүлеге фольклор әсәрләрен халыктан жыю, фәнни яктан өйрәнү һәм вакытлы матбугатта, төрле фәнни жыентыкларда, гыйльми язмаларда бастырып чыгару тарихын, татар халык ижатына багышланган фәнни һәм фәнни-популяр мәкаләләр, очеркларны барлау һәм анализлау һ.б.ларны иңләнгән иде. Бу бүлек әле хәзер дә, бигрәк тә аспирантлар һәм яшь галимнәр өчен татар фольклористикасы буенча *энциклопедик характердагы мөһим чыганак ролен үтәп килә.* Чөнки Хәмит Ярминең әлеге монографиясеннән соң татар фольклористикасы тарихы буенча бер генә житди, зур күләмле махсус теоретик хезмәт язылганы юк... Шул ук монографиянең калган бүлекләрендә сүз татар халык ижатының әкият, бәет, мәкаль-әйтем, табышмак, жыр, мәзәк кебек мөһим жанрлары турында бара. Ул еллар идеологиясе таләп иткәнчә, монографиянең шулай ук зур бер өлеше Совет чоры татар фольклоры проблемаларына багышланган иде. Китапның соңгы битләрендә шактый бай библиография китерелә... Бу монографиянең әһәмиятен билгеләгәндә, шуны истән чыгармаска кирәк: менә 35 елдан артык инде Хәмит Ярминең "Татар халкының поэтик ижаты" монографиясе

дә югары уку йортларының татар факультетлары, мәктәп, мәдрәсә, педучилище, колледж, лицей, гимназияләр өчен *бердәнбер житди дәреслек ролен дә үтәп килә.*

Хәмит Ярми фәнни эшчәнлегенең тагын бер мөһим үзенчәлеге шунда—еллар үткән саен анын тикшеренүләренең эчтәлеге-мәгънәсе тирәнрәк ачыла бара. 60—70 елларда Совет фольклор фәнендә ифрат житди бер юнәлеш ачылып, төрле халыклар авыз ижатының күптомлыкларын чыгару эше башлана. Казакъ, үзбәк, кыргыз, мордва һ.б. халыкларда шул юнәлештә беренче житди адымнар атлана. Хәмит абый да әлеге бәрәкәтле идеяне күтәреп, күптомлыкнын Проспектын төзүне 1972 елдан халык ижаты секторы мөдире итеп билгеләгән фольклорчы-галим Илбарис Надировка тапшыра. Тиз арада татар фольклорынын 12 томлык жыелмасының тәфсилле һәм чын фәнни нигездә әзерләнгән *Проспекты* төзелеп бетә һәм сектор галимнәре күптомлыкны төзү эшенә керешә. Анын кыска жырларга багышланган беренче томы И.Надиров тарафыннан төзелеп, 1976 елда ук басылып та чыга. Өч китаптан торган әкият томнарынын баштагы икесен Х.Ярми һәм бөтен гомере буена секторда эшләп, Хәмит абыйнын күпсанлы экспедицияләр вакытында да, шулай ук бихисап жыентыклар төзүдә дә иң ихлас һәм тырыш ярдәмчесе булган Хәлидә апа Гатина төзиләр...

Хәмит Ярминең житәкче буларак тагын бер күркәм сыйфатын әйтеп үтми мөмкин түгел: ул халык ижаты секторын житәкли башлаган еллардан ук үз фәненең киләчәге турында зур кайгыртучанлык күрсәтеп, секторга аспирантлар ала башлый. Ул тәрбияләп үстергән аспирантларның барысы да соныннан да шул юлдан тайпылмыйлар. Шулар арасында 1972—1990 елларда, ягъни—18 ел буена сектор мөдире булган филология фәннәре кандидаты, өлкән фәнни хезмәткәр И.Надиров; танылган язучы һәм фольклорчы Э.Касыймов (1930—1986), хәзер инде фән докторлары Т.Галиуллин һәм шушы юллар авторы Ф.Урманче.

Татар халык ижаты өлкәсендә шулкадәр зур хезмәт күрсәтеп тә, фәннең шул юнәлеше буенча *доктор* исемен алу турында хыялланмау—гайре табигый бер күренеш булыр иде. Басылып чыккан фәнни жыентык, мәкаләләренең саны—бихисап. Татар халык ижаты буенча күләмле монографиясе дә бар. Димәк, сүз тик әлеге исемне формаль яктан яклап алу турында гына бара. Һәм 1969 елның 26 октябрендә Хәмит Ярми Алматыда, Казакъстан Фәннәр Академиясендә, татар фольклоры буенча беренче буларак, филология фәннәре докторы дәрәжәсенә тәкъдим ителгән диссертациясен уңышлы яклап чыга... һәм егерме ел буена татар фольклор фәненнән бердәнбер доктор булып кала...

Сөйләнгәннәрдән анлашыла булса кирәк: татар халык ижатына ниндидер катнашы булган һәрбер зыялы—мәктәп, мәдрәсә, гимназия, колледж укытучысымы ул, татар фольклоры буенча аспирантмы, лекцияләр укучы доцент яки профессормы—һәрвакыт үзенең беренче адымнарын Хәмит Ярми чыгарган "Татар халык ижаты" антологиясеннән, "Татар халкының поэтик ижаты" монографиясеннән, ул әзерләп бастырган әкият, бәет, жыр һ.б. жыентыкларыннан башлый.

1939—1971 елларда Хәмит Ярми, 1972—1990 елларда Илбарис Надиров житәкләгән фольклор секторы (*1988 елдан—халык ижаты бүлеге*) 90 нчы еллар башында тулысынча житлеккән фәнни оешма булып формалаша һәм Хәмит Ярми башлаган эшләрне уңышлы дәвам итеп килә. И.Надиров сектор мөдире булган елларда "Татар халык ижаты" күптомлыгы басылып бетә. 1989 елда бу фундаменталь басманы әзерләүдә турыдан-туры катнашкан бер төркем галимнәр: Х.Ярми (үлгәннән сон), И.Надиров, Х.Мәхмүтов, Л.Жамалетдинов һәм Ф.Әхмәтова Татарстанның иң абруйлы бүләгенә—Г.Тукай премиясе лауреаты дигән исемгә лаеклы дип табылалар. Бу үзе бик күп нәрсә турында сөйли: күрсәтелгән күптомлык әле хәзер дә, һичшиксез, киләчәктә дә халык ижаты белән кызыксынучылар, аны өйрәнүчеләр өчен *төп һәм иң мөһим фәнни чыганак булып кала бирәчәк.*

Татар халык ижаты бүлегенең тарихын тәфсилләп күзәткәндә, бик тә үзенчәлекле бер фактка тап буласын: 51 ел, ягъни—ярты гасыр буена бу бүлекне нибары ике кеше—ике зур галим житәкләгән: 1939—1972—Хәмит абый Ярми; 1972—1990—Илбарис абый Надиров. (И.Надировтан сон бу вазыйфага Хуҗиәхмәт Мәхмүтов билгеләнә, әмма ул мона вакытлыча эшләп тору шарты белән генә риза була.) Аларның тырышлыгы, оештыручы буларак зур таланты, кешелеклелеге, миһербанлыгы, галим буларак бөтен Институт халкы алдында тирән абруйга ия булулары нәтижәсендә 1990 еллар башына халык ижаты бүлеге зур булмаган, әмма ифрат та тырыш, унган, эшлекле һәм зур фәнни перспективалы ижади төркем булып формалашып өлгерә. Ул узган гасырның 90 еллары башыннан сон тагын да зуррак, житдирәк адымнар

белән алга китә. Моның төп сәбәбе бүлеккә яна житәкче килүдә генә түгел иде, билгеле. (1992 елның 1 сентябреннән бүлек мөдире итеп шушы юллар авторы чакырылган иде.) Мәсьәләнең ин житдие—күп еллар буена тәзелеп һәм ныгытылып килгән ышанычлы нигез булуда иде. Шул 90 еллар башында бүлек алдында торган ин мөһим проблемаларның берсе—фәнни кадрлар мәсьәләсе булып чыкты. Чөнки бүлек шактый "олыгайган". Анда—нибары өч фән кандидаты, бер генә аспирант та, бер генә фән докторы да юк... Чын күнелдән эшкә керешкәч, мәсьәләнең бу ягы да шактый тиз хәл ителде: чөнки элек-электән бүлекнең фәнни потенциалы бик нык һәм зур иде. Хәзер бүлектә барлыгы 10 фәнни хезмәткәр. Шуларның алтысы—фән кандидаты, дүртесе—фән докторы. Бүлектә шулкадәр доктор булгач, хәзер Институтның Диссертация советында фольклористика буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау мөмкинлеге дә ачылды. Әлбәттә, бүлеккә аспирантлар алу мөмкинлеге дә киңәйде: хәзер бездә 13 аспирант укый.

Шуның белән бергә фәнни жыентыклар һәм монографияләр чыгару эше дә уңышлы гына дәвам итеп килә. 1999 елдан башлап татар халык ижаты әсәрләренең урысча 14 томлыгын чыгару эшенә керешелде. Бу күптомлыкнын 1–2 томнары инде басылып та чыкты. Табигый ки, элегрәк дөнья күргән 12 томлыкның хәзер инде бер генә томын да һәм беркаян да табып булмый. Ә фольклор әсәрләренә ихтыяж зур! Шуның нәтижәсе буларак, хәзер бүлек хезмәткәрләре "Татар халык ижаты" жыелмасының 25 томлыгын әзерләү эшенә керештеләр. Иншалла, 2005 елдан башлап бу күптомлыкның да беренче китаплары дөнья күрә башлар.

Мәгълүм ки, безнең көннәрдә татар халык ижаты, махсус курс буларак, югары уку йортларының татар факультетларында, милли мәктәп, гимназия, колледж, педучилище, лицей һ.б.ларда укытыла. Димәк, тулаем алганда татар халык ижаты жыентыкларына сорау көннән-көн арта бара. Басылып чыкканнары да гадәттә китап кибетләре киштәләрендә тузан жыеп ятмый. Мәсьәләнең әнә шул ягын истә тотып, халык ижаты бүлеге хезмәткәрләре Мәгариф министрлыгы һәм "Мәгариф" нәшрияты белән берлектә 2000 елда татар фольклорының аерым жанрларыннан торган һәм "Энже чәчтем—энже жыям" дип аталган 10–12 табак күләмендәге китаплар сериясен чыгара башлады. Бүгенге көндә бу сериянең 9 китабы басылып чыкты инде. Аллагы бер–ике елда аның тагын 2 яки 3 китабын чыгарып, шуның белән серия тәгәлләнер дигән өмет бар.

Ни әйтсән дә, укытучы да, укучы да бер дәрескә дистәләгән китап күтәреп йөри алмый. Шулай булгач, татар халык ижатыннан махсус дәреслек кирәклеге күптән сизелә иде инде. Һәм, ниһаять, 2002 елда "Мәгариф" нәшриятында "Татар халык ижаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек" дигән махсус китап та дөнья күреп (авторы—проф. Ф.Урманче), вакытлы матбугат битләрендә югары бәя алды.

Мәкаләне йомгаклап кую өчен, тагын бер һәм бик тә мөһим фактны күрсәтеп үтәргә кирәк: 2002 елда гына да бүлек хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән 17 китап басылып чыкты. Шулар арасында—6 монография һәм 11 фольклор жыентыгы. Бирелә әлеге монографияләрнең кайберсен генә булса да атап үтү артык булмас: филология фәннәре докторы, баш гыйльми хезмәткәр Х. Ш. Мәхмүтов "Борынгылар әйткән сүзләр (VIII–XVII йөз төрки-татар ядкярләрендә афоризмнар)".—Казан: "Фикер" нәшрияты, 16 табак; Ф. И. Урманче. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья.—Казань: Татарское книжное изд., 16, 10 табак; филология Р. Ф. Ягъфәров. Татар халкының уен фольклоры.—Казан: Мәгариф, 17,3 табак һ.б.

Сөйләнгәннәрдән күренгәнчә, филология фәннәре докторы Хәмит Ярминең зур тырышлыгы, югары профессиональ әзерлеге, фидакяр фәнни эшчәнлеге нәтижәсендә оештырылган һәм нык үсеп киткән халык ижаты бүлеге хезмәткәрләре үзләренең зур остазларының бәрәкәтле традицияләрен бүген дә тырышып дәвам итәләр. Бүлекнең фәнни потенциалы ышанычлы. Димәк, бүлекнең ныклы нигезгә корылган әлеге традицияләре алга таба да уңышлы дәвам итәр дигән өмет бар.



## 83—МУТАФИФИН (КИМЕТЕП ҮЛЧӘҮ) СҮРӘСЕ

*(Мутафифин сүрәсе 36 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Мутафифин–сату, сәүдә эшләрендә алдаучылар, киметеп үлчәүчеләр, дигән мәгънәдәге сүз.)*

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Киметеп үлчәүчеләргә ләгънәт төшәр. *(Аларның Кыямәттәге хәле коточкыч яман булыр.)* **(2)** Андыйлар *(комсыз, намуссызлар)* үзләренә үлчәгәндә, мул итеп, артыгы белән үлчәтеп алалар. **(3)** Кешеләргә үлчәгәндә киметеп бирәләр. *(Яки үлчәүне бозалар, яки гер авырлыгын киметәләр, яки үлчәнәчәк әйберне ким салалар.)* **(4)** Яңадан тереләчәкләрен *(каты җәзага тартылачакларын)* белмиләрмени соң алар? **(5)** Бөек бер көндә **(6)** галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһ *(каршында җавап тотар)* өчен кешеләрнең каберләреннән кубарылып чыгасы көн килеп җитәр. **(7)** *(Үлчәүгә хилафлык кертүдән сак булыгыз)* яманлыклар язылган китап Сиҗҗинда булыр. **(8)** Сиҗҗинның ни икәне турында сиңа кем белдерде? **(9)** *(Сиҗҗин–ул бары тик яманлыклар гына)* язылган китап. **(10)** *(Кыямәт көнен)* ялганга чыгарганнарның хәле Кыямәт көнне бик тә яман булыр. **(11)** Алар ул көн турында гел ялган сөйләде. **(12)** Гәрчә, аны *(Кыямәт көнен)* азгынлыкта хәттин ашкан, гөнаһ кылу һәвәслеге белән мавыкканнар гына ялганга саный. **(13)** Аларның *(инкарьчыларның)* алдында аятьләребезне укыганда алар:

–Борынгылардан калган әкиятләр,–дип мыскыл итәләр. **(14)** Хәер, эш анда да түгел. Алар кылган яманлыклар тузан бөртеге булып, йөрәкләренә күгәрек куна бара, кер каплый бара. *(Шуннан соң алар кара йөрәкле булып кала.)* **(15)** Хәер, *(алар барыбер иман китермәстер, шөбһәсез ки)* ул көнне алар Раббыны күрү бәхетеннән мәхрүм булыр. **(16)** Соңра алар, һичшиксез, ялкынлы җәһәннәмгә керәчәк. **(17)** Аларга:

–Менә бу газап сез ялганга санап килгән нәрсә булыр!–дип әйтерләр.

**18.** Хактыр ки, игелекле кешеләрнең *(гамәл)* китабы, һичшиксез, Гыйллиюндә саклана. **(19)** Гыйллиюннең ни икәнен син белмисең. **(20)** Ул–игелекләр язылган китаптыр. **(21)** Ул китаплар янында Аллаһ хозурындагы фәрештәләр сакта торыр, киләчәктә игелекләрнең шаһите булыр өчен. **(22)** Шик юк ки, игелекле кешеләр *(җәннәт)* нигъмәтләре эчендә булыр. **(23)** Зиннәтле тәхетләргә утырып, алар бар нәрсәне тамаша кылачак. **(24)** Син аларны танырсың, аларның йөзе шул нигъмәтләрнең нуры белән балкып торыр. **(25)** Аларга мөһерләнгән шешәләрдән саф ширбәт эчерерләр. **(26)** Ул мөһерләр *(хуш исле)* мисыктан ясалган булыр. Сусаганнар шуны эчәргә омтылсын. **(27)** Ул ширбәткә Тәсним катыштырылган булыр. **(28)** *(Тәсним)* ул–Илаһи чишмә, аннан Аллаһка аеруча якын булганнар гына эчә. **(29)** Хактыр ки, гөнаһ эшләгән *(кяферләр)* иман китергәннәрне мыскыл итеп көлә иде. **(30)** Очрашкан чакларда, узып киткәндә алар бер-берләренә күз кысып, *(мөэминнәрне)* кимсетәләр иде. **(31)** Өйләренә дә алар шул мыскыллаудан ләззәт алып кайталар. **(32)** *(Мөселманнарны)* күргәндә алар:

–Болар, чыннан да, адашкан халык,–дип көлеп китәләр. **(33)** Гәрчә, алар *(кяферләр мөэминнәргә)* күзәтүче итеп куелмаган.

**34.** Менә бу көн *(Кыямәт)* иман китергәннәрнең *(кяферләрдән)* көлә торган көне. **(35)** Зиннәтле тәхетләренә утырып, алар барысын да күзәтер. **(36)** Кяферләр *(дөньяда кылмыш гөнаһларына күрә)* җәзаларын алдылармы?

# 84—ИНШИКАК (ЕРТЫЛУ) СҮРӘСЕ

*(Иншикак сүрәсе 25 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Иншикак-шартлау.)*
Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Күк шартлап, урталай ярылгач, **(2)** Раббыга буйсынып, Аның әмерен үтәп, **(3)** Җир сузылып, төп-төз булып, **(4)** эчендә булганнарның барчасын тышка атып, бушагач, **(5)** *(Җир)* Раббыга буйсынып, Аның әмерен үтәргә бурычлы.

**6.** Әй, адәм баласы, шиккә урын юктыр ки, син *(дөнья мәшәкатьләре аша, интегә-чабалана)* Раббың илә кавышырга омтыласың. Ахырда син *(Аллаһ белән)* кавышырсың да. **(7)** Китабы уң кул тарафыннан бирелгән кешегә **(8)** хисап тоту җиңел булачак **(9)** һәм ул шатлык-куаныч илә туганнары, гаиләсе белән *(җәннәттә)* кавышачак.

**10.** Әмма китабы сул иң өстеннән бирелгән кеше **(11)** шундук *(эшне аңлап)* үләсе килеп, *(ул җәзаларны күргәнче, үлсәм яхшырак булыр иде дип)* акыра башлар. **(12)** Ул дәһшәтле утка атылачак. **(13)** Ул гаиләсендә дә, кешеләр арасында да *(Аллаһтан, аның җәзасыннан курыкмыймын, дип)* мактана иде. **(14)** Чөнки ул, чыннан да, Раббы янына барырмын, дип башына да китерми иде. **(15)** Раббы аны *(ни кылганнарын)* бик яхшы күреп тора иде. **(16)** *(Чынбарлык ул уйлаганча булмады)* Шәфәкъ исеме белән әйтәмен ки, **(17)** барчасын үз караңгылыгына алучы төн исеме белән әйтәмен, **(18)** тулган Ай исеме белән әйтәмен: **(19)** Сез, һичшиксез, бер халәттән икенчесенә күчү *(яралу, туу, картаю, үлү)* мәҗбүрендәге затлар. **(20)** Шулай булгач, *(иман китермичә)* сез ни кыласыз? **(21)** Яннарында Коръән укыганда ни өчен соң алар сәҗдә китми? **(22)** Шулар өстенә кяферләр аны *(Мөхәммәд сөйләгәннәрне)* ялганга саныйлар. **(23)** Гәрчә, Аллаһ аларның күңелләрендә ниләр барын бик яхшы белеп тора. **(24)** Шуңа күрә, *(ий, Мөхәммәд)* син аларны хәтәр җәза бирүче газаплар белән кисәтеп куркытып тор.

**25.** Иман китереп, игелекле гамәлдә булганнарны Аллаһның иксез-чиксез нигъмәтләре көтә.

# 85—БУРУҖ (ЙОЛДЫЗЛАР) СҮРӘСЕ

*(Буруҗ сүрәсе 22 аятьтән тора. Мәккәдә иңгән. Буруҗ–каланча, манара.)*
Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.
*(Беренче аять төрлечә тәрҗемә ителгән, нигездә аларның барысы да дөрес кебек, шулай да тирәнрәк аңлар өчен, берничәсе тәкъдим ителә:*

**1.** Бихисап йолдызлыкларны үз эченә алган җиде кат Күк манарасы белән ант итәмен ки, **(2)** вәгъдә ителгән көн илә, **(3)** шаһит булган һәм шаһадәтлек кылучылар исеме белән әйтәмен ки, **(4, 5)** эче дөрләп торган ялкынлы, утлы чокыр казыткан бәндәгә әче каһәр иңсен. **(6)** *(Мөселманнарны шул утка ташлап яндырганны)* алар карап утырдылар. **(7)** Алар иман китергәннәрне ничек җәзалганнарына хөкемдарлары каршысында шаһит булачак. **(8)** Бердәнбер җиңелмәс кодрәт иясе булган Аллаһка, мактауга лаек Раббыга иман китергәннәре өчен аларны *(мөэминнәрне)* шулай газапладылар. **(9)** Күкләрнең вә Җирнең бөтен барлыгына Аллаһ кына ия. Аллаһ бөтен нәрсәгә берүзе шаһит.

**10.** Хактыр ки, иман китергән ирләрне, мөэминә хатыннарны җәзалаучылар, соңра тәүбәгә килмәсәләр, аларга җәһәннәм газабы хәзерләнгән. Ялкынлы утта яну—аларның өлеше.


**11.** Иман китереп, игелек кылганнар арыкларыннан чишмәләр агып ятучы җәннәтләргә керер. Бөек котылыш *(Сәгадәт)* шул булыр.

**12.** Хактыр ки, Аллаһның тотышы—хәтәр тотыш. **(13)** Иң башлап юктан бар итүче дә, ахырда тагын терелтеп, Үз хозурына алдыручы да—Аллаһ Үзедер. **(14)** Ул тәүбә итүче мөэминнәрне ярлыкаучы, *(итагать итүчеләрне)* сөюче. **(15)** Ул—Гарешнең хуҗасы. Бөекләрнең бөеге. **(16)** Аллаһ теләгәнен тәгәл башкаручы.

**17, 18.** Сиңа Фиргавен белән Сәмуд гаскәрләре турында хәбәр килеп ирештеме? *(Аллаһны инкарь иткәннәре өчен алар нинди һәлакәттә дучар булды.)* **(19)** Шулай булса да, кяферләр һаман инкарь итә; **(20)** Аллаһ аларны газабы илә чорнап алачак. **(21)** Иң дөресе шулдыр ки, алар инкарь иткән Китап—олуг мәртәбәле Коръән. **(22)** Ышанычлы урында *(Ләүхел Мәхфүздә)* саклланучы—Изге Коръән.

# ТАТАР КҮРКЕ — САБАНТУЙ

Халкыбызның рухи һәм мәдәни мирасларыннан Сабан туе һәркемгә киң мәгълүмдер. Аның хакында Каюм Насыйри, Гомәр Баширов, Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еникиләрнең матбугатта чыккан фикерләрен шактый укыдык. Сабан туе турында йөзләгән шигырьләр, җырлар иҗат ителгән. Рәссамнарыбыз Сабан туе темасын читләп үтми, бу темага шаян рәсемнәр иҗат итүдә дә фантазияләрен һич тә чикләмиләр, чөнки халкыбыз кебек озын гомерле Сабан туе мона азыкны мул бирә...




Ә менә шул Сабан туе турында мөкәммәл бер Коръән кадәр китапның басылып чыгуы рухи дөньябызны балкытып җибәрде. Аны адашым Дамир Шәрәфетдинов язган. Чөнки ул менә кырык елдан артык инде шул өлкәне өйрәнә килә. Татар көрәше, ат чабышлары турында ул, кем әйтмешли, көне-төне сөйли ала. Алай гына да түгел, бу төр ярышларны янартып гамәлгә куючыларның берсе дә ул. Алар турында матбугатта бәйнә-бәйнә никадәр мәкаләләре басылды. Көрәш буенча махсус әсбаплар, китаплар бастыручы да ул иде.

Менә шулай кереп китте ул Сабан туе дәръясына. Ул монда иң оста ишкәкче. Хәер, моңа гаҗәпләнерлек тә түгел. Көрәшсез, ат чабышларыннан башка нинди Сабан туе булсын, ди. Булмый ул! Дамир Шәрәфетдиновнең Сабан туе турында китап язуын очраклы дип әйтергә берәүнең дә теле әйләнмәстер. Йөрәген Сабан туе мәйданына әверелдергән әлеге шәхес кенә шушындый китапны язарга тиеш иде, әлбәттә.

Ул безнең өметләребезне аклады, һәм, ниһаять, өстәлләребезгә үзенең китабын куйды. Исеме дә нинди бит әле: “Татар барда—Сабан туе бар”.

480 битле бу китапның тышлыгын бизәүдә атаклы рәссамыбыз Лотфулла Фәттаховның барыбызга да таныш “Сабан туе” картинасын файдалану да отышлы булган.

“Тормыш турында традицияләр” (1978), “Остаз кыры” (1984), “Сабан туе—хезмәт бәйрәме” (1987), “Сабан туе—халыкның яшәеше” (1997) исемле китапларын элегрәк язмаса, Дамир Шәрәфетдинов бу китабын иҗат итә дә алмаган булыр иде, мөгаен. Шулай итеп, ул Сабан туе дигән мәйдан кадәр зур келәмнен җирлегең әзерләгән һәм аны күп җирләрдә уздырыла торган сабан туй бизәкләре белән тукыган. Анда Сарман Сабан туе да, Казан Сабан туе да, Нугай казакъларының, мишәрләрнең, керәшеннәрнең Сабан туйлары да нәкышланган. Гомумән, татар галәмендәге Сабан туйларның ачык төсмерләре бирелгән биредә.

Искиткеч, гаҗәеп һәм серле ул Сабан туе! Әле тәпи дә йөри башламаган сабыйның мәйданның читендә генә булса да үрмәләве күпме шатлык бирә! Ул һаман эчкәрәк үрмәли. Ә инде тәпи йөри башлаганнар бу мәйданга баһадирдай аяк басалар. Сабан туенда көрәшне башлап җибәрүче малайларны әйтәсе дә юк,—алар көрәштән бер башка

Дамир Шәрәфетдинов. Татар барда—Сабан туе бар.—Казан: «Гасыр» нәшрияты, 2003 ел.

үсеп чыгалар, хәер, җинелгәннәренен хәле бик шәптән булмыйдыр.

Сабан туенын гасырлар чоңгылыннан килгән тәртипләре бар.

*Сабан туе, Сабан туе,*
*Илдә берне сайлар туй.*
*—Кем батыр?—дип мәсьәләне*
*Кап уртага салган туй.*

Сабан туенын, халкыбыз тарихы кебек үк, бик озын тарихы бар. Анын тамырлары мәҗүсилек заманнарыннан сузыла, кабилә-кабилә, ыру-ыру булып яшәгән бабаларыбызнын ихластан кояшка табынып, бу йоланы чын күнелдән мул уңышка юрап бәйрәм ясауларына барып житә. Кытай, Монголия, Урта Азия, Көньяк Себер, Кавказ, Урал буе, Идел-Чулман-Агыйдел, Дон, Днепр, Дунай киңлекләрендә түл җыеп үсә Сабан туе.

Дамир Шәрәфетдиновнын әлеге китабын укып чыккач, мона тагын һәм тагын ышанасың. Хәзерге бәйрәмнәрдәге эчү-исерү күренешләренең Сабан буена бөтенләй ят икәнлеген тоеп, җанны иң әрнеткән әнә шул күренешләрнең һаман тамыр җәюенә борчыласың. Бер тәпән балнын төсен бер тамчы дегет җибәрә дигәндәй, әнә шулар олуг бәйрәмебезнең ямен киметә.

Шулай да Сабан туе хикмәтле бәйрәм инде. Аңа милли анны уяту оеткысы салынган. Сабан туе белән бергә халкыбызнын күпме уеннары, күпме физик күнегүләре саклап калынган. Мәйданга килгән һәр кеше җан рәхәте, рух сихәте ала икән, адәм баласына тагын ни кирәк?! Ул икенче Сабан туена кадәр матур итеп эшли дә, матур итеп яши дә ала. Бу инде үзе бер яшәү рәвеше дигән сүз. Сабан туе турындагы сүзләрнең борынгы кабер ташларыннан алып әллә кайлардагы, әллә нинди архив документларына кадәр сибелеп ятуы юкка гына түгелдер.

Дамир Шәрәфетдинов менә шуларны мең ярымнан артык чыганаклардан җыя-җыя олы бер гомумиләштерү ясый: Татар барда—Сабан туе бар.

Әйе, дөнья сәхнәсенә милләт булып күтәрелгән татар башка халыклар алдында үзенең Сабан туе белән таң калдыра, шунын белән ерак-еракларга сәяхәт итә, хәтта Рәсәй чикләрен үтә. Татар Сабан туен Үзбәкстанда, Казакъстанда, Төркиядә, Финляндиядә, Канадада, Германиядә, Австралиядә, Америкада алкышлыйлар. Димәк, Татарны алкышлыйлар.

Китапны укыганда әнә шундый хисләр кичерәсен һәм шундый бәйрәмне тудырган татар халкы өчен горурланасын да. Бу бәйрәмгә төрле милләт халкынын да үз күреп тартылуы өчен хозурланасын. Сабан туебызны яратып, якын күреп кабул итүләре өчен башка халыкларга да рәхмәт кенә әйтәсе кала. Күп кенә кардәш халыкларнын да бәйрәмнәрендә атка, көрәшкә бәйле йолаларнын булуы Сабан туебызның сөйкемле якларын арттыра, аны чыннан да мөбәрәк һәм түгәрәк итә. Ә бит дуслар, туганнар җыелган җирдә кечкенә генә шатлык та бөтененә җитә. Сабан туенда сайрашкан халык ел буена ыңгырашмый яши һәм эшли ала.

Көн дә бәйрәм, көн дә туй була алмый, әлбәттә. Бу халык авыз иҗатында да әйтелә:

*Ак калфагың ак түгел,*
*Калфак кияр чак түгел.*
*Уйнап-көлеп утырырга*
*Сабан туе чак түгел...*

Элек сабанга төшү алдыннан, бөтен хәстәрлекләр төгәлләнгәч бәйрәм иткән кешеләр. Шул заманнардан килгән җыр да бар:

*Сабан туйлары җиткәндә,*
*Парлап сабан җиккәндә,*
*Үпкә сүзләр шунда бетә*
*Кысып, суырып үпкәндә.*

Ата-бабалар телендә "сабан кергән", "сабан керешле" дигән гыйбарәләр булган. Бүген бик үк аңлашылмаган бу гыйбарәләрнең эчтәлеге ул заманда һәркемгә көн кебек ачык булган. Сүз сабан сөрергә җигелә башлаган өч яшьлек ат турында барган. Шундый атлар арасыннан чабыш атларын сайлап алганнар.

Ат чабышларын автор "Сабан туе күрке" дип бәяли. Аттан башка Сабан туен күз алдына да китереп булмый. Дамир Шәрәфетдинов китабынын ат чабышлары хакындагы бүлеген аеруча яратып язган. Китапта бирелгән кырык ике рәсем һәм фотоларнын тугызында атлар бар. Аларның барысы да Сабан туе көнне төшерелгән рәсемнәр.

Минем үземнең дә "Чыгарсынмы каршы алырга" дигән китабымда иллеләп робагый бар.

—Ә Сабан туе турында берәр робагый

бармы?—дип сораган иде Дамир Шәрәфетдинов.

—Бар,—дидем мин һәм эзләп табып ана Сабан туе турындагы робагыйны укыдым:

*Халкыбызның көзгесе ул—Сабантуй.*
*Үткәннәрнең бер төсе ул—Сабантуй.*
*Буыннардан-буыннарга татарның*
*Күчә торган билгесе ул—Сабантуй.*

Күптән түгел узган Сабан туйлары шаукымы белән йөргән чак иде бу.

Автор үзенең китабында Сабан туеның тулы тәрҗемәи хәлен биргән. Аның ничек дөньяга килүе, нинди үсеш юлларын үтүе жае чыккан саен истә калырлык итеп тәкърарлана. Элек тә, хәзер дә Сабан туен көтеп алганнар.

Рухи әхлак... Ул бары тик әйбәт, гүзәл холыкларны гына күз алдында тота. Дамир Шәрәфетдинов үзенең язма хезмәтләрендә, лекцияләрендә, әңгәмәләрендә Сабан туенын милли үзаңыбызны уятудагы әһәмиятен һәрдаим эчкерсезлек белән кузгатып торды. Сабан туеның халык тарафыннан еш кына "Татарстан бәйрәме" дип аталуының "серен" безгә житкереп килде. Әллә нинди сәяси, ижтимагый тетрәнүләрдә дә Сабан туе халкыбызнын горурланырлык милли бәйрәме булачагын искәртте.

Шуңа күрәдер дә аның "Татар барда—Сабан туе бар" дигән китабы бу олуг бәйрәмебезнең үткәнен өйрәнүдә, бүгенгесен гомумиләштерүдә яна бер этап булуы кемдә дә шик уятмас.

Ерак гасырларны кичеп камилләшә-камилләшә килгән Сабан туе үткәннәрдән генә түгел, киләчәккә дә изге күпер сала. Өзлексез дәвам иткән тормышыбызның тирән мәгънәсе символы буларак, ул каныбызда, жаныбызда яши һәм яшәр.

Сабан туе—милли бәйрәмебез. Соңгы вакытта аны интернациональ бәйрәм дип аңлатырга жыену күнелгә бераз шом да сала кебек. Татар янәшәсендә яшәгән һәр халыкны үз мәйданына тарта алган Сабан туе, әлбәттә, гаять тә олы исемнәргә, ихлас мактауларга лаек. Ләкин интернациональлек астында аның миллилеген оныттырырга маташу күренеше ята күрмәсен.

Татар күрке—Сабан туй. Аны төрле елларда, төрле сәбәпләр белән тыярга да тырышып караганнар, әмма бу барып чыкмаган. Хәзер Сабан туена халыкара дәрәжәдәге бәйрәм статусын бирү фикере ныгый бара. ЮНЕСКО житәкчелегенең дә кешелек дөньясының матди булмаган мирасы исемлегенә татар Сабан туен кертү ягында булуы бик тә куанычлы хәл, әлбәттә. Әлеге китапны башка телләрдә дә, беренче чиратта рус һәм инглиз телләрендә, басып чыгару бу мәсьәләне тизрәк хәл итүдә мөһим дәлил булыр иде.

Күп гасырлык тарихы булган татар Сабан туе жирдәге һәр халыкны чакырып, күнелен күтәрер, жанына жылы бирер, шатлык өстәр дигән өметтә калыйк.

**Дамир ГАРИФУЛЛИН,**
*Сарман.*

# *Хатлардан юллар*

* * *

Мин "Казан утлары" журналына шагыйрь Равил Фәйзуллинның 2002 елда радиодан чыгышын тыңлаганнан соң язылган идем. Инде менә ике ел алдырам. Бер укый башлагач аерылып булмый икән. Беренче санын алу белән редколлегия әгъзаларын да карап чыккан идем. Күренекле, дәрәҗәле, белемле вә зыялы кешеләр икән анда. Журналны уку әнә шул кешеләр белән аралашу да дигән сүз бит әле ул. Чөнки дөнья күргән әсәрләрнең барысы да аларның фатихасы белән басыладыр дип беләм. Шул уңайдан журналга бер сорау бирәсем килә – нишләп Казанда милли университет ачуны тизләтү мәсьәләсе күтәрелми. Бу мәсьәлә вакытлы матбугатта да бик аз яктыртыла кебек. Туган телендә белем алмаган, милли рухта тәрбияләнмәгән халык ничек сакланып калсын инде? Әнә, халык саны буенча 900 мең чамасы эстоннар инде ничә гасыр үз университетларын асрыйлар. Илдә сан ягыннан икенче урында торган халык, куәтле фәне һәм икътисады булган республика милли университет тотарга лаектыр дип беләм.

Шушы уңайдан Татарстандагы баш журналның фикерен беләсе иде.

**М. МИНҺАҖЕВ.**
Әлмәт.

*<u>Редакциядән:</u> Хөрмәтле Минһаҗев әфәнде! Татарстан Республикасы Президенты карары белән Казанда милли университет бинасын төзү эшләре кызу темплар белән алып барыла. Казанның 1000 еллыгына башкалабызның Татарстан урамында, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры каршында университетның тулы бер шәһәрчеге үсеп чыгар дип көтелә. Анда күп төрле факультетлар булдыру күздә тотыла. Укыту нигездә татар телендә алып барылачак.*

* * *

Хөрмәтле редакция!

Татар китапларында милләтебезнең никадәр белеме, рухи байлыгы тупланган. Ул мәкальләрне, әйтемнәрне генә алып карагыз. Халыкның меңнәрчә еллар туплаган тәҗрибәсе, сынамышлары бит алар. Мәкальләр – акыл хәзинәбез, тарихыбыз да бит әле. Бәлки, журналда аерым сәхифә ачып, шул мәкальләрне төрле тематика буенча туплап биреп барырга да була торгандыр. Хәзерге болгавыр заманда мәсләксез калган кешеләргә уйланырга сәбәп, этәргеч булыр иде.

Тагын… Әнә радиодан реклама урынына Козьма Прутков афоризмнарын әйтеп торалар. Ә бит безнең мәкальләребез күпкә тапкыррак та, акыллырак та.

**Җәмилә ӘХМӘТОВА.**
Яшел Үзән.

* * *

Әле менә башкорт гәзитләренең яңа гына басылып чыккан кайбер саннарын карап чыктым да кулыма каләм алмыйча булдыра алмадым. Чөнки алардагы үзгәреш шаккаттырды. Башкортстан матбугаты, радио һәм телевидениесе Татарстан җитәкчелегенә генә түгел, хәтта бөтен татар халкына карата тискәре мөнәсәбәтне ачыктан-ачык сиздереп торалар, бу гамәлләре көчәйгәннән-көчәя генә. Башкортстандагы татарларны "башкорт" дип игълан итү генә җитмәгән, алар фикеренчә, Татарстанда Ык һәм Сөн елгалары буендагы татарлар да "башкорт" икән ләбаса! Татарстан матбугатына юлны чикләп, башкорт басмалары Татарстан һәм татар халкы турында ялган мәгълүмат таратуны дәвам иттерәләр. Минемчә, вәзгыять инде соңгы чиккә килеп җитте. Бу шартларда Казан нишләргә тиеш, ул ничек ярдәм итә ала! Иң беренче чиратта, Уфада татар китапларын, гәзит-журналларын таратуны нык көчәйтергә кирәк. Мин үзем, мәсәлән, сезнең журналны аяктан егылганчы эзләп кенә кулга төшерәм. Казанда, Татарстанда чыккан татар китаплары белән дә шундый ук хәл. Икенчедән, Татарстан матбугатында Уфада һәм Башкортстанда яшәп ятучы татарлар, аларның тарихы, бүгенге хәле һәм проблемалары турында мәкаләләрне, фәнни тикшеренүләрне күбрәк басарга кирәк. Безне онытмагыз. Без, Аллага шөкер, җир йөзендә Казан бар, ул безнең башкалабыз, Татарстан – безнең өметебез һәм хокукларыбызны яклаучыбыз, дип яшибез.

Безнең янга ешрак килегез, Казан китапларын, журналларын алып килегез. Юкса монда "Казанда китап чыгару бетеп килә" дип язарга да күп сорап тормыйлар.

**Илһам ГАЛИМОВ.**
Уфа.

* * *

Кадерле "Казан утлары"!

Барлык хезмәткәрләрегезгә, авторларыгызга көн саен уңышлар, гаиләләрегезгә чиксез шатлыклар, тазалык-саулык, озын гомер телим. Сез безнең яралы җаннарыбызга шифа, рухыбызга дәрт, күңелләребезгә илһам бирәсез.

"Казан утлары"н инде байтак еллар өзлексез алдырып киләм. Бер юлын да калдырмыйча диярлек укып барам. Миңа бигрәк тә татар халкының тарихи үткәне турындагы язмалар якын. Чөнки алар халкым белән горурлык хисләре уяталар. Әйе, татар халкы бик борынгы чорлардан ук үтә эшчән булган, шәһәрләр артыннан шәһәрләр корган, дистәләгән дәүләт төзегән, пөхтәлек, тазалык, мәдәнилек һ. б. һ. б. яклардан аерылып торган, санап бетергесез талант ияләре тудырган, теләсә нинди һөнәрне бик җиңел үзләштергән, эшне тиз отып алган. Болгарлар, аларның бабалары һуннармы, скифләрме, сарматлармы – болар барысы да безнең буыннарыбыз, безнең кан, аларда безнең йөз-кыяфәт, безнең килеш-килбәт. Моны бары тик бөек үткәнебездән көнләшүчеләр генә инкарь итәр. Кара эчле көнчел "галим"нәр җитәрлек. Менә шунлыктан татарга пычрак атарга, аны бүлгәләргә тырышалар да. Әчынлабрак баксаң, Рәсәйдә урыстан кала татардан да шанлырак тарихлы халык юк та бит. Без болгар да, без нугай да, без типтәр дә, керәшен дә, кыпчак та... Без бөтенебез бергә олуг татар халкы. Кызганыч, хәзер теләсә кайда теләсә нинди тарих китаплары язалар, бастырып чыгарлар. Эт симерсә иясен тешләр, дигәндәй, теге яки бу халыкның, теге яки бу дәүләтнең формалашуында татарлар уйнаган хәлиткеч роль бозып күрсәтелә.

Дөрес, тарих безгә кырыс булды шул. Әле дә бердәмлек булмагач, безне берәм-берәм "ашыйлар". Кызларыбыз ят милләтләргә кияүгә чыгып чит милләт үрчетә. Сатлык җаннар ишәйде, битараф яшьләр күбәйде. Алар инде урысча укыйлар, Америка кинолары карап, эчкечелекне, фахишәлекне, үтерешләрне гадәти хәл дип саныйлар. Безгә татарча китаплар, тарихны дөрес яктырткан китаплар эчәр су, сулар һава кебек кирәк. Халык үз тарихын белсен. Юкса, монда Урал буе татарлары турында Башкортстанның рәсми органнары берсе артыннан берсе "сафсата китаплар" язып тараталар, халык аңын томаламакчы булалар.

Җаным әрнүгә түзә алмаганга күрә яздым боларны.

**Хөрмәт ЛОКМАНОВ.**
Башкортстан.

* * *

Хөрмәтле редакция!

Журналның быелгы өч санында басылган "Карга короле" романын бер сулышта укып чыктым. Минем рәхмәт хисләремне аның авторы Рауль Мирхәйдәровка да җиткерсәгез иде. Узган елларда да аның "Иртәләгән сагыш", "Һәрнәрсәгә акчалата" романнарын Сезнең журнал битләрендә йотылып укыган идем. Автор җинаятьчел даирә серләрен, дөньяда "Алланың кашка тәкәсе" булып яшәүче түрәләрнең асылын шулкадәрле оста күрсәтә, аларның дөреслегенә, чынбарлыктан алып язылганлыгына бер кәррә дә шикләнмисең. Кызганыч, ил башында шундый кешеләр утырган шул.

Үзем дә сизмәстән, мин Рауль Мирхәйдәров иҗатына мөкиббән киткән кешеләрнең берсенә әвереләдем бугай. Мөмкин булса, зинһар, хәбәр итсәгезче, журналда киләчәктә аның әсәрләре тагын басылачакмы? Һәм, гомумән, аның татарча басылган китапларын, шулай ук татар телендә чыккан әдәби китапларны Казаннан кайдан һәм ничек алдырып була?

**АЛМАЗ.**
Мәскәү.

*Редакциядән:* *Хөрмәтле Алмаз! Хатыгыз өчен рәхмәт! Табигый ки, журнал киләчәктә дә Мәскәүдә яшәп иҗат итүче татар әдибе Рауль Мирхәйдәров белән хезмәттәшлеген дәвам иттерәчәк. Ул безнең даими авторларыбызның берсе. Аерым алганда, аның "Җәяүле сәяхәтләр" романы татарчага тәрҗемә ителеп бетеп килә. Ул "Карга короле" романы да кергән дүрттомлык сериягә карый. Ә инде Р. Мирхәйдәровның татарча басылып чыккан "Иртәләгән сагыш" китабына һәм башка татар китапларына килсәк, аларны Казаннан,*

*Татарстан китап нәшриятыннан соратып алдырырга мөмкин. Адресы: 420111, Казан, Бауман урамы, 19. Татарстан китап нәшрияты. Нәшриятка шулай ук электрон почта белән дә мөрәҗәгать итеп була: E-mail: tki@books.kazan.ru http://www.tatarstan.ru/books/*

* * *

Кадерле редакция!

Журналның узган елгы 7-9 саннарында Камил Кәримовның "Сакау күке" романын укып чыктым. Әсәр үзенең мавыктыргыч фабуласы, эслүбе, җанлы теле белән миндә бик уңай тәэсир калдырды. Бер укый башлагач, аерылып булмый диярлек. Җитмәсә, роман каһарманнарының берсе минем ирем, инде мәрхүм Марат Әбдрәсүл улы Мөлеков булып чыкты.

Маратның романда сурәтләнгән биографиясендә кайбер төгәлсезлекләр очратсам да, аларны автор хыялында туган детальләр дип артык нык игътибар итмәгән идем. Әмма 9 нчы санның 22 битендәге мондый юллар битараф калдыра алмады: "Мәктәп дигәннән, Мөлековны эшеннән алдылар. Унынчы класс бетергән 100 бала урыс теленнән язма эш буенча имтихан тапшыра алмады. Көзгә калдырганнар. Анда да өч кенә кызның эше үткән. Син аларны беләсең, берсе Таҗи кызы, берсе Сәрвиназ кызы, өченчесе урыс теле укытучысы Бәйрәмгалинең сеңлесе иде. Калганнары катыргы ала алмады. Инде минем олы малаем яңадан унынчы класста укып йөри. Бәйрәмгали бөтен язма эшләргә "икеле" куйган, күчерергә ирек бирмәгән, әллә нинди хаталар эзләп тапкан. Мөлеков балаларны яклап маташкан, тыңламаганнар. Бөтен ил алдында хурга калдык..."

Мин биредә автор белән килешә алмыйм. Ни өчен? Чөнки мин 1952 елның августыннан 1956 елга кадәр ирем белән бергә Шәле мәктәбендә эшләдем һәм үз өстемдә тулы җаваплылык тоеп әйтә алам: Марат Мөлековны беркемнең дә беркайчан да эшеннән алганы булмады.

Әмма Шәле мәктәбендә 1952 елда чыннан да андый хәл булуы хак. Ул елларда һәр сыйныфта чыгарылыш имтиханнары була торган иде. Һәм нәкъ шул елны Питрәч районы мәгариф бүлеге мөдире булып эшләгән Ремизов барлык сыйныфларда укучыларның белем дәрәҗәсен ныклап үтә дә җитди итеп тикшерергә булган. Имтиханнарга РОНО инспекторларын җибәрделәр, ә алары исә төрмә надзирательләре шикелле кыйлана башлады, укучылар бәдрәфкә чыкканда хәтта артларыннан ияреп чыктылар. Табигый, бу балаларга тынычлап эшләргә ирек бирмәде. Урыс теленнән болай да көчле булмаган укучылар бөтенләй югалып калды, унынчы класстагы ун баладан нибары өчесе язма эшне уңышлы тапшыра алды. Ул елны Шәле мәктәбе өлгереш буенча 33 процент кына бирде. Бу инде үзенә күрә ЧП иде һәм хәтта РСФСР Мәгариф министры докладында Шәле мәктәбен Россиядә иң түбән өлгереш бирүче мәктәп дип телгә алып киттеләр.

Нәтиҗәдә, 1952 елның 31 августында мәктәп директоры Спиридоновны һәм тарих укытучысы Мөлековны (аңа ул вакытта егерме ике яшь иде) Татарстан АССР Мәгариф министрлыгы коллегиясенә чакырдылар. Мәктәп директоры Спиридоновны эшеннән алдылар, ә ел дәвамында үзен белемле, таләпчән педагог итеп күрсәтеп өлгергән М. Мөлековны директор итеп куйдылар. Шәле урта мәктәбе тарихында, һәрхәлдә, Мөлеков директор булып эшләгән чорда, бүтән андый вакыйга булмады. Моны ул елларда укыган укучылар да, мәсәлән, Татцик авылында яшәүче пенсионерка Разия Закирова раслый ала. Аллага шөкер, ул чорда Мәгариф министры булып эшләгән Мирза Мәхмүтов та исән әле. Аннан да белешеп була.

Мөлековны эшеннән алмау гына түгел, күп тапкырлар гариза язса да эшеннән бушатмадылар. Бары тик 1958 елда гына, Питрәч район газетасы редакторы Аитов Мәскәүдә аспирантурага укырга кергәч кенә, Мөлековны район газетасына редактор итеп күчерделәр. Һәм бары тик 1959 елның августында гына аның һәм минем үтенечемне канәгатьләндерделәр. Шул ук елны Марат Татарстан Мәгариф министрлыгына эшкә алынды.

Мин бу хат белән роман авторының хаталарын төзәтеп, аларны әсәр дөнья күргән журналны укучыларга да җиткерергә кирәк дип таптым. Чөнки Марат инде мәрхүм, ул үзен үзе яклый да, аклый да алмый. Әдәби әсәр булуга карамастан, әгәр героең тормыштан алынган һәм ул үз исеме белән бирелә икән, (аның изге максатларда эшләнгәненә шикләнмим, анысы өчен авторга чиксез рәхмәтлемен) хыялга мәгълүм бер дәрәҗәдә генә урын бирергә ярый торгандыр. Урыслар әйтмешли, "что написано пером, не вырубишь топором". Минем өчен дөньяда иң кадерле кеше, хәләлем булган Марат Мөлеков хакында аз гына төгәлсезлеккә дә күңел рәнҗи шул. Бигайбә!

**Рәшидә МӨЛЕКОВА.**

Казан.

## «Казан утлары» архивыннан

*Үткән гасыр башы хатирәсе булган бу рәсемдә Камил Мотыйгый (Төхфәтуллин Камил Мотыйгулла улы) (1883—1941). Нашир, журналист, җырчы. 1905—07 елларда "Әлгасрелҗәдид", "Уклар" журналларының, "Фикер" газетасының нашире һәм мөхәррире. Тукай белән якыннан аралашып яшәгән кеше.*





*Иң өлкән әдипләребезнең берсе—фронтовик шагыйрь Әдип Маликов. 1999 ел.*

*XX гасыр урталарында актив концерт эшчәнлеге алып барган мәшһүр баянчылар—Оркия Ибраһимова, Мохтар Әхмәдиев. 60 еллар.*





*"Казан утлары" журналында эшләүче язучылар-шагыйрьләр—Р. Гаташ, Р.Фәйзуллин, Н. Гамбәр, М. Закиров, М. Вәли археолог-галим Равил Фәхретдинов (сулдан икенче) белән Иске Казан шәһәре тирәлегендә. Июль. 2002 ел.*



*"Барыбыз да бер үк юлда...". Язучы, тәрҗемәче Шәһидә Максудова Арча зиратында, ире—халык язучысы Гариф Ахунов кабере янында. 2001 ел.*



*"Литературная газета"ның баш редакторы Александр Чаковский һәм язучы Әхәт Гаффар. Латвия. Дубулты иҗат йорты. 1985 ел.*

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Фирүзә Җамалетдинова



*Фирүзә Ислам кызы Җамалетдинова (Фәтхетдинова) 1960 елның 28 мартында Чүпрәле районы, Иске Кәкерле авылында туа. Мәктәп елларында ук шигырьләре "Ялкын" журналында, "Яшь ленинчы", "Татарстан яшьләре", "Социалистик Татарстан" газеталарында даими басылып килә.*

*Урта мәктәпне тәмамлагач, 1977-82 нче елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында белем ала. 1984 елдан Чаллыда яши. 21 нче мәктәптә укытучы, "Таң йолдызы" газетасында җаваплы секретарь, баш редактор булып эшли. Хәзерге вакытта "Мәйдан" журналының әдәбият, сәнгать һәм "Мәйданчык" бүлекләре редакторы.*

*Шигырьләре Татарстан китап нәшрияты тарафыннан 1987 елда басылып чыккан "Туган як җыры" исемле күмәк җыентыкта урын ала. 2002 елда Яр Чаллы типографиясендә "Яшен күзләре", "Уйлы җил", 2004 елда Татарстан китап нәшриятында "Тołымлы ай" исемле шигырь җыентыклары дөнья күрә.*

*Фирүзә Җамалетдинова проза өлкәсендә дә уңышлы гына эшли. Хикәяләре "Казан утлары", "Мәйдан", "Сөембикә" журналларында, "Мәдәни җомга", "Шәһри Казан" газеталарында чыгып килә. Фирүзә ТР Журналистлар берлеге әгъзасы. Аның республика матбугатында публицистик язмалары еш басыла.*

*Быелның 31 мартында Кабул итү коллегиясе карары нигезендә (рекомендация бирүчеләр—Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Рәдиф Гатауллин, Факил Сафин, Рәшит Бәшәр) Язучылар берлеге идарәсе Фирүзә Җамалетдинованы Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалыкка кабул итте.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.

Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2004 елның икенче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. **«Казан утлары»ның индексы—73210**, ярты елга язылу бәясе 101 сум 40 тиен.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***Казан утлары*** (наименование издания) Количество комплектов:

на **2004** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

***Казан утлары*** (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ______ руб.______ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб.______ коп. | |

на **2004** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда (почтовый индекс) (адрес)

Кому (фамилия, имя, отчество)

**100.5 FM**
**TATAR RADiOSI**
*слушают во всем мире*
*на www.tatarradiosi.ru*
*т. (8432) 19-100-5, 19-11-11*

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ГЛОБАЛЬ ЧЕЛТӘРДӘ

Кайда гына сибелмәдең син, әй бөек һәм горур татар халкы!.. Кайда гына угылларың, кызларың юк синең!.. Дөньяның кайсы почмагына барып керсәң дә, милләттәшеңне очратырсың. Татар булмаган җир юк ул: бигрәк тә Русиядә, Урта Азиядә, Балтыйк илләрендә, Финляндиядә, Төркиядә һәм АКШта байтак безнең татарларыбыз. Заманында төрле сәбәпләр аркасында туган нигезләреннән, Ватаныннан аерылып мөһаҗир булып киткән милләттәшләребез, үзләре белән мәдәниятебезнең ядкарьләрен: җырларын, шигырьләрен, бәетләрен, дастаннарын, әкиятләрен һәм, әлбәттә, иң бай олуг хәзинәсе булган татар телен дә алып киткәннәр. Чит җирләрдә яшәүче татарлар милли йөзләрен саклап калыр өчен, үзләре һәм бигрәк тә балалары җирле халык белән ассимиляцияләшмәс өчен төрле мәдәни чаралар үткәрәләр. Төрле төбәкләрдә елдан елга үткәрелеп килгән концерт, презентация, Сабантуй кебек мәдәни чаралар моңа дәлил.

Күптән түгел татар халкын бердәм итүче, җыр, сәнгать һәм эстраданы төрле яклап яктыртучы һәм, иң мөһиме, тәүлеккә егерме дүрт сәгать буе хезмәт күрсәткән, Казан һәм тирә-юньгә 100,5 FM ешлыгында таралучы **“Tatar radiosi”** глобаль Интернет челтәрендә дә туры эфирга чыга башлады. Хәзер теләге булган һәрбер кеше, дөньяның кайсы почмагында булмасын, http://www.tatarradiosi.ru Интернет сайтыннан радиобызны туры эфирда тыңлый ала.

Бигрәк тә еракта яшәүче татарлар өчен бу бик кирәкле һәм күптәннән көтеп алынган чара. Радио тыңлаучыларыбыз, сайтыбызның “Кунак бүлмәсе”нә кереп, “Рәхмәт сезгә! Сезне бик яратып тыңлыйбыз!” кебек ихласлы теләкләрен һәм шөкраннарын язып калдыралар. Хәтта тыңлаучыларыбыз арасында татар кешеләре генә түгел, чит якта торып, туган мәдәниятеннән ерак калган кардәш төрки кешеләре: Кырым татарлары, башкортлар, төрекләр дә байтак. Шулай итеп, дөнья күләмендә татарча хезмәт иткән радиобыз татарларны (һәм аларны гына да түгел!) берләштерә, уртак мәдәниятле итә... Финляндиянең Хельсинки шәһәрендә яшәгән татар шагыйрәсе һәм җырчы Җәмилә Низаметдин үзенең шигри юлларын безгә багышлаган:

*“**Tatar radiosi**”н кушып,*
*Җырлыйк әле онытылып,*
*Дусларыбызны яратып!*
*Сез булганга мин бәхетле,*
*Җырлыймын да җырлыймын,*
*Кайчагында, күңелем тулса,*
*Яшермичә елыймын!*

Әлеге шигырьгә, әлбәттә, иҗади караш белән түгел, ә хөрмәтле тыңлаучыларыбызның рәхмәте дип карарга кирәк. Бу язмалар, www.tatarradiosi.ru сайтында урнашкан “Кунак бүлмәсе”ндә язылган. Сайттагы форумда да татар кешеләре үзара уй-фикерләрен уртаклаша алалар, анда радио эшенә кагылышлы теләкләрегезне һәм киңәшләрегезне дә белдерергә мөмкин.

**“Tatar radiosi”**нда 100,5 FM ешлыгында һәм www.tatarradiosi.ru сайтында көтәбез сезне, хөрмәтле тыңлаучыларыбыз. Борынгы, популяр һәм өр-яңа җырлар, сәгать саен кайнар яңалыклар, сәлам юллаулар, төрле уеннар, конкурслар һәм тагын бик күп нәрсә бары тик сезнең өчен! Сез булганда — без бәхетле! Киләсе очрашуларга кадәр!

# İctimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ШИГЪРИЯТЛЕ ТЕЛ БӘЙРӘМЕ

Габдулла Тукайның туган көненә багышланган Шигърият бәйрәме быел Туган тел бәйрәме буларак та республикабыз күләмендә зурлап үткәрелде. Шушы уңайдан мәктәпләрдә, мәдәният сарайларында, театрларда, музейларда, күргәзмә залларында күп төрле чаралар оештырылды. Тукайның туган көне татарлар күпләп яши торган чит төбәкләрдә дә билгеләп үтелде.

26 апрель көнне иртән бер төркем әдәбият һәм сәнгать әһелләре Яңа Бистә зиратында Г. Тукай һ.б. күренекле каләм әһелләренең каберләрен, шулай ук үзәк мәдәният һәм ял паркында Һ. Такташ, Г. Камал, Ф. Әсгать, Ш. Әхмәдиев каберләрен зиярәт кылды. Аннары М. Җәлил, А. Пушкин, Г. Державин, М. Горький һәйкәлләренә чәчәк салынды. Башкалабыз үзәгендәге Г. Тукай һәйкәленә чәчәк салуда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин дә катнашты.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы каршындагы мәйданда оештырылган төп тантанада сәламләү сүзе белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин чыкты, язучы М. Юныска Республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелү турында Татарстан Президенты Указын игълан итте.

Шигъри митингны шагыйрь Х. Әюпов алып барды. Анда танылган каләм әһелләре Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Роб. Әхмәтҗан, Г. Рәхим, Р. Гаташ, М. Әгъләм, Р. Миңнуллин, Р. Вәлиев, Л. Шагыйрьҗан, Р. Вәлиева, Л. Газизова, Р. Мөхияр, Р. Идиятуллин, И. Гыйләҗев, Г. Морат, Р. Зәйдулла, Р. Бохараев, Р. Әймәт һ.б.лар үзләренең шигырьләрен укыдылар. Тантанада күренекле сүз остасы А. Арсланов, җырчылар Э. Җәләлетдинов, З. Сәхәбиева, Р. Маликов, И. Биктаһиров, шулай ук Х. Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры, гармунчылар ансамбле, мәктәп балалары чыгыш ясады.

Шигърият бәйрәмендә Татарстан Премьер-министры урынбасары З. Вәлиева, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова, Мәдәният министры И. Тарханов катнашты.

Бәйрәмнең икенче өлеше тулаем Туган телгә багышланган иде. Аны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары әзерләгән.

Соңгы елларда Г. Тукайның туган көне Балтач районында да киң билгеләп үтелә башлады. Бер төркем каләм әһелләре бөек шагыйребезнең Сасна Пүчинкәсе зиратында җирләнгән әнисе Бибимәмдүдә абыстайның каберенә чәчәк салды, Субаш авылы мәдәният йортында үткәрелгән әдәбимузыкаль кичәдә катнашты.

Күп еллардан килә торган гадәт буенча, Шигърият бәйрәме эстафетасын 27 апрельдә Г. Тукайның туган төбәге Арча районы кабул итте. Казаннан килгән кунаклар район үзәгендә Г. Тукай, Г. Бәширов, Г. Ахунов, М. Мәһдиевнең һәйкәл-бюстларын (аталыуллы Әбдрәшитовлар эше) ачу тантанасында катнашты. Алар көннең беренче яртысында Кушлавыч авылында булды, Тукаевларның музей-йортында мәктәп укучылары белән очрашты һәм, әлбәттә, Тукай-Кырлайда үткәрелгән шигъри митингта катнаштылар.

## Г. ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯЛӘРЕ КОМИТЕТЫ СОСТАВЫ

2004 елның 31 мартында Татарстан Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комитеты составын раслау турында карар кабул итте. Комитетның түбәндәге составы расланды:

З.Р. Вәлиева—Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары—Комитет рәисе;

А.И. Шутиков—Татарстан Республикасы Дәүләт халык уен кораллары оркестрының сәнгать җитәкчесе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты—Комитет рәисе урынбасары;

Г.Ф. Акчурина—Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының баш референты—Комитет секретаре.

Комитет әгъзалары:

А.А. Абзгильдин—Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге рәисе, Татарстан Республикасының халык рәссамы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

М.Г. Арсланов—театр белгече, сәнгать фәннәре докторы;

Ф.Р. Бикчәнтәев—Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

Р.И. Вәлиев—Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь;

Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова—Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, сәнгать фәннәре докторы;

Ш.Г. Галиев—Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

Ф.Г. Галимуллин—Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе, профессор, филология фәннәре докторы;

И.К. Зарипов—Россия Федерациясенең атказанган рәссамы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

Р.Ф. Кәлимуллин—Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге рәисе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе;

А.Н. Латышев—"Республика Татарстан" газетасы баш редакторы;

А.Б. Луппов—Казан дәүләт консерваториясе профессоры, композитор, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе;

Р.М. Миннуллин—Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, шагыйрь, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

Т.А. Миннуллин—драматург, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының Дәүләт премияләре лауреаты;

Р.М. Нургалиева—Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге идарәсе рәисе;

М.М. Сәфәров—"Ватаным Татарстан" газетасы баш редакторы;

А.Я. Славутский—В.И. Качалов исемендәге Казан Зур рус академия драма театры баш режиссеры, Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

З.Д. Сәнгатуллина—М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры солисты, Казан дәүләт консерваториясе профессоры, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

Р.А. Тажетдинов—Татарстан Республикасы Театр әһелләре берлеге идарәсе рәисе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

И.Г. Тарханов—Татарстан Республикасы мәдәният министры;

Р.Г. Фәйзуллин—Татарстан Республикасының халык шагыйре, "Казан утлары" журналы баш редакторы, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

Р.М. Харисов—шагыйрь, Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты;

Н. Ш. Хисамов—Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

### ТАТАР ПЬЕСАСЫ КОНКУРСЫ

"Яңа татар пьесасы—2004" конкурсы ТР Мәдәният министрлыгы, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, "Яңа гасыр" телерадиокомпаниясе, "Казан утлары" журналы һәм "Татарстан яшьләре" газетасы тарафыннан үткәрелә. Узган елгыдан аермалы буларак, анда 35 яшькә кадәрге авторлар көч сынашачак. Бәйге ачык рәвештә уза. Иң яхшы авторга—200, икенчегә—100, өченче урынга 75 мең сум акча биреләчәк. Иң яхшы инсценировка язучыга 100 мең сум күләмендәге махсус бүләк билгеләнә. Икенче номинация—Мәхмүт Галәүнең "Болганчык еллар. Мөһаҗирләр" роман-дилогиясенә нигезләнеп язылган иң яхшы инсценировка. Анда авторлар яше чикләнми. Бәйге ябык рәвештә үтә. Бу номинациядә җиңүчегә 200 мең сум тапшыру каралган.

"Яңа татар пьесасы—2004" ике этапта үтәчәк. Икенче этапта җиңүчеләр билгеләнә. Жюри рәисе—Миркасыйм Госманов. Җиңүче дип табылган пьесаларны җыентык итеп чыгарылачак һәм "Казан утлары"нда басылачак.

### ЯХШЫ СЦЕНАРИЙ ЯЗ

Татарстан Мәдәният министрлыгы каршындагы кинематография идарәсе кыска метражлы нәфис фильм өчен иң яхшы әдәби сценарий язучыларга ачык ярыш игълан итте.

30 минутлык сценарийда сюжет һәм геройларның холык-фигыльләре ачык итеп сурәтләнергә, шуның өстенә фильм табигый шартларда үтәргә, катлаулы техника, реквизит һәм костюмнар, күп сандагы актерлар таләп итмәскә тиеш. Аны Казанда төшерү күздә тотыла. "Татарстан. Яз. Мәхәббәт" шигаре астында үтүче бәйгедә язучы, сценарист, журналистлар гына түгел, теләгән һәркем катнаша ала. Сценарийларны 1 октябрьгә кадәр Мәдәният министрлыгы каршындагы кинематография идарәсенә тапшырырга кирәк. телефоннары: 92-88-44, 92-89-11. Конкурста җиңгән автор белән аның сценарием экранлаштыру буенча килешү төзеләчәк.

### ТАТАР ТЕЛЕ ИНТЕРНЕТТА

"Татмедиа" агентлыгында татар телендәге электрон газета мөхәррирләре һәм журналистлары белән "түгәрәк өстәл" үткәрелде. Анда ТР Президенты аппараты тышкы элемтәләр департаментының мәгълүмати аналитик секторы баш референты Азат Әхтәриев, РФ татарлары милли-мәдәни мохтәрияте рәисе Римзил Вәлиев катнашты.

Сөйләшүдә катнашучылар бүген татар телендәге электрон газеталар алдында торган проблемалар хакында фикер алышты, татар

телен интернетта кинрәк җәелдерүнең юнәлешләрен билгеләде, бу өлкәдә латин имлясының һәм, бигрәк тә, интернетта эшләү өчен тәҗрибә рәвешендә тәкъдим ителгән "Inalif" вариантының әһәмиятен билгеләп үтте.

## БЕЗГӘ ТАНЫЛУ КИРӘК

Берлинның Тюркология институтында татар мәдәнияте атналыгы узды.

Бу бәйрәмне институт хезмәткәрләре һәм Берлинда 1999 елда оешкан татар-башкорт мәдәни җәмгыяте оештырды. Максат—немец җәмәгатьчелеген, беренче чиратта Берлин зыялыларын, татар һәм башкортларның тормыш-көнкүреше, мәдәнияте белән таныштыру.

Атналык 26 апрельдә әдәби-музыкаль кичә белән башланды. Шул ук көнне "Казан-Берлин" фотокүргәзмәсе дә ачылды.

## ЯЗУЧЫ ЮБИЛЕЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында язучы, Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе Вахит Имамовның 50 яше тулу уңае белән зур әдәби кичә булды. "Утлы дала", "Сәет батыр", "Тозлы яра" кебек тарихи романнар, "Могикан" шикелле повестьлар, күп санлы хикәяләр, очерклар авторын Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, Мәдәният министры И. Тарханов, күренекле шагыйрьләр И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Миңнуллин, драматург Т. Миңнуллин һәм башкалар тәбрикләде.

Кичәгә Актаныш районы хакимияте башлыгы Э. Фәттахов җитәкчелегендә юбилярның якташлары—туганнары, дуслары, җирле талант ияләре дә килгән иде.

## МӘСНӘВИ ОСТА ЯДКАРЕ

Татарстан Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында Мәснәви Хәйретдиновның тууына 80 ел тулуга багышланган күргәзмә оештырылды. Биредә рәссамның 60 ка якын картинасы куелган. Аларның күбесендә Лениногорск күренешләре, Татарстанның көньяк районнары табигате чагыла.

Татарстанның халык рәссамы, атказанган сәнгать эшлеклесе М. Хәйретдинов тумышы белән Сарман районы Шыгай авылыннан. Ул—"Оператор", "Чирмешәндә", "Вахтадан соң", "Ана булу", "Игенче" кебек нефтьчеләр, авыл хезмәтчәннәре тормышы турындагы картиналар авторы. Республикабызда рәссам нәкыш остасы буларак танылды.

Күргәзмәне ачу тантанасында Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов, Рәссамнар берлеге рәисе Абрек Абзгильдин, әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашты.

## ҖЫРЧЫНЫ ИСКӘ АЛЫП

Мәскәүдәге "Космос" кунакханәсенең концертлар залында мәшһүр җырчыбыз Хәйдәр Бегичев истәлегенә зур кичә уздырылды. Кичәне Татарстанның РФдәге тулы вәкаләтле вәкиллеге, Флүн Гомәров җитәкләгән "Алмаз-Холдинг" фирмасы, шулай ук эшмәкәрләрнең матди ярдәмен алган Россиянең Европа өлеше мөселманнары дини идарәсе һәм Ренат Ибраһимов җыр театры үткәрде.

Мемориаль концертта Татарстанның халык артистлары Зөһрә Сәхабиева-Бигичева, Мөнир Якупов, Фердинанд Сәлахов, Рөстәм Вәлиев, Татарстанның атказанган артисты Илсаф катнашты. Хәйдәр Бигичевны искә алу концертына Башкортстанның халык артистлары Фәния һәм Рафаэль Амантаевлар, Ишморат Илбәков, Флорида Исмәгыйлова килгән иде. Кичәне Татарстанның халык артисты Рәшит Сабиров һәм Илдар Кыямов алып барды.

Фойеда Хәйдәр Бигичев башкарган җырлар язылган тасмалар сатылды.

## ГЫЙЛЕМ ӨЧЕН ЧИКЛӘР ЮК

АКШның Колумбия университеты профессоры Густав Бурбиел хәзерге татар әдәби теленең грамматикасын эшләде һәм нәшер итте.

Хезмәт бай эчтәлекле, җентекле булу белән бергә, күләме ягыннан да шактый саллы. 902 бит тәшкил итә. Шунысы үзенчәлекле, татар теленең морфологик категорияләре синтаксик функцияләре белән бәйләнештә бирелгән. Әлеге хезмәтне галим университетның төрки телләр факультетында укытуга бәйле рәвештә башкарган. Ә анда дүрт төрки тел өйрәнелә: татар, үзбәк, төрек, әзәрбәйҗан телләре.

Густав Бурбиел—атаклы тюрколог Анна Мария фон Габэн шәкерте. Үз фәненнән бик яхшы хәбәрдар. Мәсәлән, ул хезмәтендә татар кириллицасы, аның инглиз теле кануннарына ни рәвешле туры килүен нигезләп күрсәтә алган. Китапның лингвистик консультанты—филология фәннәре докторы Хәлиф Курбатов. Автор аңа ярдәме өчен китабында рәсми рәвештә рәхмәтен белдергән.

## ХИКМӘТЛЕ ФИКЕРЛӘР ҖЫЯБЫЗ

Татар ПЕН-үзәге башта рус телендә, аннан соң инглизчә татар халкының мәкальләре, хикмәтле фикерләре һәм әдәби миниатюралары китабын бастырып чыгарырга җыена. Халык авыз иҗаты мәкаль, әйтем, табышмаклар һ.б. рәвешендә төрле басмаларда дөнья күрсә дә, безнең билгеле шәхесләребезнең афоризмнары, хикмәтле фикер белдергән сүзләре бер тапкыр да нәшер ителгәне юк. Күп халыкларда бу эшнең уңышлы үрнәкләре бар. Бүген без Платон, Байрон, Пушкин әсәрләрен яхшы беләбез һәм күп кулланабыз. Шул ук вакытта үзебезнең Мәрҗани, Тукай, Исхакый кебек фикер ияләре, язучылар, күренекле җәмәгать эшлеклеләренең акыллы гыйбарәләрен бөтенләй диярлек файдаланмыйбыз.

Әлеге җыентыкның максаты—дөньяга

халык авыз иҗатының байлыгын гына түгел, ә бәлки вакыт сынауларын уңышлы үткән акыл ияләребезнең әдәби-фәлсәфи фикер киңлеген, тормыш тәҗрибәсен дә күрсәтү.

Татар ПЕН-үзәге милли әдәбият, фән, дин һәм мәгариф тарихы белгечләренә халкыбызның мәшһүр улларының әйткән сүзләрен, афоризмнарын, хикмәтле фикерләрен туплауда ярдәм сорап мөрәҗәгать итә.

Текстларны, чыганакларын күрсәтеп, түбәндәге адреслар буенча тапшыра аласыз:

Казан, К. Маркс урамы, 36 нчы йорт, Татар ПЕН-үзәге, Ә. Мушинскийга (тел: 92-56-38).

"Ватаным Татарстан" газетасы редакциясе, Ә. Сафиуллинга (43-53-82).

"Мәдәни җомга" газетасы редакциясе, Г. Моратка (92-45-78).

## РӘХМӘТ ХАТЫ

Хәзерге заман татар әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш керткән өчен язучы **Садриев Фоат Миңнеәхмәт улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

## ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Быелның 29 мартында яшь ягыннан иң өлкән язучыбыз **Сафа Сабир улы Сабиров** 89 яшендә вафат булды.

Сафа Сабиров 1915 елның 19 августында Татарстанның Питрәч районындагы Иске Йорт авылында игенче гаиләсендә туган. Дүрт яшендә—этисе, 11 яшендә әнисе үлеп, 1929 елга кадәр балалар йортында тәрбияләнә. 1929-1933 елларда Чувашстанның Алатырь шәһәрендә тимерьюлчылар ФЗӨ мәктәбендә укып, паровозчы-слесарь һөнәре һәм җидееллык белем ала. 1934-1938 елларда С. Сабиров Казан елга техникумында укый. 1938 елның сентябрендә аны армия хезмәтенә чакыралар. 1946 елның августына кадәр, сигез ел дәвамында, ул Ерак Көнчыгышта Хәрби Диңгез Флотында хезмәт итә.

С. Сабировның иҗат эше белән җитди шөгыльләнә башлавы да хәрби хезмәт елларына туры килә. Ул флот газетасы ("Боевая вахта"га язышa, Ерак Көнчыгыштагы "Красная Знамя" край газетасы редакциясе каршындагы әдәби берләшмәгә йөри, үзенең беренче әдәби әсәрләрен иҗат итә.

Хәрби хезмәттән кайткач 1954 елның ахырына кадәр Югары Идел пароходчылыгында Татарстан җирле агентлыгында диспетчер булып эшли. Монда эшләү ана бай тормыш материаллары тупларга мөмкинлек бирә. Шул материалларга нигезләнеп, ул "Совет Татарстаны" ("Ватаным Татарстан") газетасына, Казан радиосына күп мәкаләләр, очерклар яза. Соңга таба елгачылар, Куйбышев гидростанциясен, Казан елга портын төзүчеләр тормышын яктырткан очерк, хикәя-повестьлар иҗат итә. 1949 елда аның беренче мөстәкыйль китабы—нахимовчылар турындагы "Яшь диңгезчеләр" дигән повесте басылып чыга. Аннан соң "Дүрт елга буйлап", "Зур Идел туганда" кебек очерк-хикәя җыентыклары дөнья күрә.

1954-1957 елларда С. Сабиров "Совет Татарстаны" газетасының үз хәбәрчесе, ә 1957-1971 елларда Татарстан китап нәшриятында—матур әдәбият редакциясе мөдире, ә 1971 елның октябреннән 1975 елга кадәр (лаеклы ялга киткәнче) шул ук редакциядә өлкән мөхәррир булып эшли. Шул вакыт эчендә аның татарча һәм русча егермедән артык китабы басылып чыга.

1969 елдан СССР һәм Татарстан Язучылар берлекләре әгъзасы булган Сафа Сабир улы Сабиров соңгы елларда үзенең иҗади активлыгын тагын да көчәйтә төште. 1996 елда аның Татарстан китап нәшриятында "Идел йолдызлыгы" дип исемләнгән повестьлар, хикәяләр һәм истәлекләр җыентыгы дөнья күрде. Быел исә шул ук нәшриятта аның "Алтын балдаклы абыстай" дигән зур күләмле китабы басылырга әзерләнә иде...

Ихлас күңелле, олы җанлы, һәркемгә игътибарлы һәм ихтирамлы булган Сафа ага Сабировның якты истәлеге, язган әсәрләре безнең күңелләрдә озак сакланыр.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Кыз-балыклар. Рәссам **Ә.Ильясова** эше.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә **Асия Юнысова.**

# ЯҢА КИТАПЛАР

Факил САФИН. **Саташып аткан таң:** Роман-Трилогия.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.—527 б.
Тиражы—5000 данә.




Танылган язучы, Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты Ф. Сафинның бу әсәре алдагы елларда безнең журналда кыскартылган вариантында басылып чыккан иде инде. Өч кисәктән торган бу тарихи әсәрдә үткән тормышыбызда теге яки бу рәвешле эз калдырган реаль шәхесләр сурәтләнә.

"Саташып аткан таң" роман-трилогиясе тирән фәлсәфә, жанны кузгатырлык кичерешләр, әдәбиятыбызда моңарчы күрелмәгән фикер һәм тема катламнары, фактик материалларның муллыгы белән аерылып тора",— дип яза китапка кереш сүзендә шагыйрь һәм тәнкыйтьче Наис Гамбәр.

Китапның мөхәррире—Р. Заһидуллина, рәссамы—М. Разногорская.

Рафис КОРБАН. **Яра:** Шигырьләр.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.—287 б.
Тиражы—2000 данә.




Укучыларга балалар өчен язган шигырьләре, сәхнә әсәрләре белән яхшы таныш шагыйрь Рафис Корбанның бу китабында туган җир, халык, тормыш, мәхәббәт турында сөйләүче шигырьләре, җырлары урын алган. Алар, нигездә, соңгы 5-6 ел эчендә язылганнар. Дүрт бүлектән торган китапның "Татар күзләре" дигәнендә—гражданлык рухлы фәлсәфи шигырьләр, "Яшьлеккә кайту" бүлегендә—лирик-мәхәббәт шигырьләре, "Җыр җырлыймын бүген җырга" бүлегендә—җыр текстлары кергән. Дүртенче бүлек тәржемә шигырьләрдән (С. Ширази, С. Капутикян, Р. Кутуй һ. б.) тора.

Китапның мөхәррире—И. Ногманов, рәссамы—Ю. Щетинкина.



Асия Юнысова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)